Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
Татарстан Язучылар берлеге
Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты
Сарман муниципаль районы башкарма комитетының
мәгариф бүлеге
МБГБУ «Икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе»

# АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ – ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ ИМӘН БАГАНАСЫ

ТАССРның, РФСФРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык язучысы, Габдулла Такай, М. Горький исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВнең тууына 90 ел тулуга багышланган республикакүләм Аяз Гыйләҗев укулары материаллары

Җәлил бистәсе - 2018

**Т ө з ү ч е – р е д а к т о р л а р :**

**Шәйдуллина Ландыш Камил кызы –**
Сарман муниципаль районы МБГБУ «Икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе»нең югары категориялетатар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Гарипова Альбина Илфат кызы –**
Сарман муниципаль районы МБГБУ «Икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе»нең информатика укытучысы

**Аяз Гыйләҗев – татар әдәбиятының имән баганасы** (ТАССРның, РФСФРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык язучысы, Габдулла Такай, М. Горький исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВнең тууына 90 ел тулуга багышланган республикакүләм Аяз Гыйләҗев укулары материаллары). – Казан 2018. – 400 б.

## ТӨЗҮЧЕЛӘРДӘН

Бүгенге көндә мәктәп эшчәнлегендә иң мөһим юнәлешләрнең берсе – бала шәхесенең үзенә генә хас үзенчәлеген саклап, аның рухи үсеше өчен шартлар тудыру. Шулай ук яшь буынга туган телне өйрәтү, аны милли мәдәниятебез, гореф-гадәтләребез, традицияләребез рухында тәрбияләүнең татарның киләчәге өчен ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлеге һәркемгә дә яхшы мәгълүм. Якташ язучылар иҗатын өйрәнү – бу эшчәнлекнең бик нәтиҗәле бер тармагы, минемчә. Һәр төбәкнең күренекле шәхесләре була. Якташлары алар турында горурланып сөйлиләр, яшь буынны шулар үрнәгендә тәрбияләү максатын куялар. Якташ язучы, шагыйрь, журналистларыбыз иҗатын өйрәнеп, укучы күңеле туган як, аның хезмәт сөюче халкы, тормыш-көнкүреш вакыйгаларыннан алган тәэсирләр белән байый, горурлык хисләре арта. Ә укытучының иң зур бурычы, бәхәссез, якташ әдипләрнең әсәрләрен укучылар күңеленә җиткерү, алар иҗатын өйрәнү омтылышын тәрбияләү һәм, шул эшне башкарып, талантлы якташлары белән горурлык, ватанпәрвәрлек хисен үстерү, камилләштерү.

Туган ил, туган җир, туган тел... Кешене кеше, милләтне милләт иткән иң изге, иң кадерле төшенчәләр. Һәр милләтнең үз теле, үз моңы, үз җыры, үз туган җире бар. Шуны аңлаган яшь кеше милли рухлы шәхес булып формалаша. Яшь буынга моны даими кабатлап, гамәли исбатлап торырга кирәк. Ничек дисезме? Якташлар үрнәгендә. Аларның эшчәнлеге, аларның хезмәтләре, аларның тәҗрибәләре үрнәгендә!

Сарман ягы чын мәгънәсендә үз якташлары белән горурлана ала. Җырчыларыбыз, талантлы артистларыбыз, рәссамнарыбыз бар безнең. Милләтебез язмышы, аның киләчәге турында уйланып, халкыбызның рухи дөньясын баетуда хезмәт итүче әдипләребез күпме?!

Шуларны исәпкә алып, 2006 нчы елдан мәктәбебездә якташ язучылар иҗатын пропагандалау буенча актив эш алып барыла. Нефтьчеләребез ярдәме белән бистәбез горурланып исемен йөрткән каһарман-шагыйрь Муса Җәлилнең 105 еллыгына республикакүләм фәнни-гамәли конференция оештырудан башланып киткән иде ул. Ул вакытта без “Сарманнарның үткен каләме, еракларга китәр сәламе” исеме астында республика мәктәпләреннән язучыларыбыз иҗатына багышланган йөзләрчә тикшеренү эше кабул иттек.

2014 нче елда конференциябез “Гасырлар өнен тыңлап” дип аталды һәм без аны күренекле якташыбыз, филология фәннәре докторы, академик Хатыйп Йосыф улы Миннеголов эшчәнлегенә багышладык. Укытучылар, укучылар фәнни бәйгедә теләп катнаштылар. Ул тәэсирләр якты хатирә булып мәктәп тарихында язылып калды.

2017 нче елның феврале якташ язучыбыз Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рәфкать Кәраминең гомер бәйрәме белән истә калды. Шул уңайдан үткәрелгән фәнни-гамиәли конференция дә республикада теләктәшлек тапты. Шундый матур иҗади, тикшеренү эшләре кабул ителде, алар якланып, тиешле бәяләрен алдылар.

Быелгы ел без зур хөрмәт белән Аяз ага Гыйләҗевне искә алабыз. Исән булса, 17 нче гыйнварда аңа 90 яшь тулган булыр иде.

Аяз аганың иҗаты, аның гомер юлы бөтенебезгә тормыш китабы була торган иҗат. Биредә тупланган дәрес эшкәртмәләре, чаралар, методик ярдәмлекләрдә әнә шул фикер кызыл җеп булып сузылып бара. Эшләргә, өйрәтергә һәм өйрәнергә генә кирәк.

Ландыш Шәйдуллина, Сарман районы татар теле һәм әдәбияты укытучыларының район методик берләшмәсе җитәкчесе

## Гыйбрәтле язмыш сәхифәсе

XX йөзнең икенче яртысы татар сүз сәнгате талантлы әдипләргә, кабатланмас каләм осталарына шактый бай. Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев (1928-2002) алар арасында, мөгаен, тәүге урыннарның берсен алып торадыр. Аның үзенә генә хас драматик гомер юлы, бай һәм кыйммәтле иҗат мирасы бар.

Аяз Гыйләҗев Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында дөньяга килә. Әти-әнисе – укытучы. Бераздан аларның гаиләсе күршедәге Зәй районының Югары Баграҗ авылына күчеп килә. Булачак әдип шунда укый, әмма урта мәктәпне 1945 нче елда Сарманда тәгәлли. Бер еллап колхозда, ике ел Зәй районы яшьләр оешмасында бүлек мөдире булып эшләгәч, 1948 нче елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Тырышып укый, җәмәгать эшләрендә актив катнаша.

Сугыштан сон Советлар Берлегендә Сталин диктатурасы, репрессив ысуллар куллану, сәяси эзәрлекләүләр янә көчәеп китә. 1950 нче елда А.Гыйләҗевне Совет хакимиятен тәнкыйтьләүдә, татар мәнфәгатьләре өчен көрәшүдә гаепләп кулга алалар һәм җиде елга ирегеннән мәхрүм итәләр. Өченче дистәне яңарак кына ваклый башлаган, белемгә, иҗатка, бәхеткә омтылган яшь егет төрмәләрнең, шул исәптән Казакъстандагы сәяси “Карлаг” зинданының коточкыч газапларына дучар ителә: ирексезлек, ачлык, гаять авыр таш, бетон эше, кыскасы, совет җәһәннәме. Әмма күп гасырлык колониаль җәфаларга түзгән татар кавеме вакиле рухын сындырмый, ихтыяр көчен, әдәби талантына тугрылыгын саклап кала.

Биш ел утырганнан соң, А.Гыйләҗев, амнистиягә эләгеп, ирекkә чыгарыла, Казан университетында укуын дәвам иттерә. Аны тәмамлагач, 1957-1961нче елларда “Чаян”, “Азат хатын”, “Совет әдәбияты” журналлары редакцияләрендә эшли. .Аннан ике ел Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый. 1963нче елдан башлап ул – профессиональ язучы. Ике-өч ел Зәй шәһәрендә торуын исәпкә алмаганда, Казанда яши. 2002нче елның 13нче мартында шунда ук вафат та була. Кабере – Казанның Яңа бистә зиратында.

Әдипнең хатыны – Нәкыя ханым – татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Өч улы бар: Искәндәр – тарих фәннәре докторы; Мансур – күренекле драматург, атасы традицияләрен дәвам иттерә; төпчек улы Рәшат – табиб.

А.Гыйләҗев әдәби иҗат белән студентлык елларында ныклап шөгыльләнә башлый. Әүвәл аның әдәби, публицистик язмалары гәҗит-журнал битләрендә басыла. Тәүге китабы – “Рәтле кешеләр” исемле хикәяләр җыентыгы – 1959 нчы елда дөнья күрә.

Ярты гасырлык иҗат гомерендә А.Гыйләҗев – биш роман (“Урамнар артында яшел болын”,”Алтынчы августа кадәр”, ”Яра”, ”Йәгез,бер дога!”, “Балта кем кулында?”), егерме повесть (“Дүртәү”,”Зәй энҗеләре”,”Урталыкта”, “Язгы карваннар”, “Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят”,” Мең чакрым юл”, “Җомга көн кич белән”,”Әтәч менгән читәнгә” һ.б), күп санлы хикәяләр яза. Шулай ук күренекле драматург та. Аның кырыкка якын пьесасы бар (“Җиргә тапшырылган серләр”, ”Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз”, “Шамил Усманов”, “Хушыгыз, тургайлар”,”Шомырт чәчәк атканда”,”Сары чәчәк ата көнбагыш”, ”Әгәр бик сагынсаң”, “Җиз кыңгырау”һ.б). Әдипнең әсәрләре күп телләргә тәрҗемә ителгән. Пьесалары татар сәхнәләрендә генә түгел, дистәләгән башка халыкларның театрларында да куела.

Аяз Гыйләҗев – күпсанлы бүләкләр, шәрәфле исемнәр иясе: Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт һәм М.Горький исемендәге премияләр лауреаты (1983,1987), Татарстанның халык язучысы (1993), Татарстанның һәм Русиянең атказанган сәнгать эшлеклесе (1978, 1985).

Филогия фәннәре докторы, академик Х.Й. Миннеголовтан.
(А.Гыйләҗевнең “Өч аршын җир” повестенең төрекчә басмасына (2008)
кереш сүзеннән кыскартылып алынды)

Габдулхакова Инсия Зуфаровна, «Джалильская СОШ№2», Сармановский район
Мирсаяпова Гульназ Зуфаровна, «СОШ №17», г.Альметьевск

**Тема: Рассказы Аяза Гилязова**
**(Внеклассное чтение)**

**Цель:** знакомство с творчеством  Аяза Гилязова, изучение детских рассказов.

**1.Знакомство с биографией Аяза Гилязова. (Выступают ученики)**

**1 ученик.** Аяз Мирсаиидович Гилязов (Аяз Гыйләҗев; 1928-2002) – татарский советский и российский писатель. Народный писатель Республики Татарстан (1993).

**Биография**

**2 ученик**.Аяз Гилязов родился 17 января 1928 года в селе *Сарманово,* (ныне Татарстан) в семье учителя. Детство провёл в деревне Верхний Багряж (Заинский район).

Получил неполное среднее образование в местной школе. Вернулся в родной район, где закончил Сармановскую среднюю школу.

**3 ученик.** В 1948 году поступил в Казанский государственный университет.

В 1950 году был арестован и сослан в карагандинский лагерь, где содержались даже лауреаты Сталинских премий. Там Гилязов находился пять лет. В 1955 году был реабилитирован.

**4 ученик**. После освобождения вернулся в Казань и продолжил учёбу. Через полтора года начал сотрудничать с журналами «Чаян» и «Азат хатын». Стал редактором отдела прозы журнала «Совет әдәбияты» (сейчас «Казан утлары»).

**5 ученик.** В 1963 году окончил Высшие литературные курсы при СП СССР. После этого стал считаться профессиональным писателем.

**6 ученик.** Писал рассказы, очерки, фельетоны, статьи. Позднее, излюбленным жанром Гилязова стала повесть. Аяз Гилязов скончался 13 марта 2002 года

**2.Викторина по рассказам Аяза Гилязова**

1) Назовите главного героя рассказа «Суык»  (Искандар)
2) Что принёс папа Искандара домой в рассказе «Суык»? (термометр)
3) Как звали героиню рассказа «Матур»? (Разия)
4) Почему рассказ назвали «Матур»? (о кошке)
5) Чем хотел угостить Разыя Искандара? (треугольником)
6) Пение какой птицы услышали Алсу и Илдус? (соловья)
7) Герой какого рассказа Алсу и Илдус? (Алсу, Илдус и соловей)
8) Назовите мальчика из рассказа «Муйнак» (Халим)
9)  Имя отрицательного героя рассказа «Муйнак» (Тазетдин)
10) Смог ли Халил защитит собаку? (нет)

**3. Инсценирование  рассказа «Матур» (Выступают ученики)**

**4. Конкурс «Найди пару»**

(Ученикам даётся два конверта. В одном из них герой рассказов Аяза Гилязова, а в другом названия произведении. Ученики должны соотнести названия с героями рассказов)

1 конверт: Алсу, Искандар, Разия, Галия, Илдус, Халим, Тазетдин, Галимзян абзый

2 конверт: «Суык», «Матур», «Алсу, Илдус и соловей»

**5.Конкурс рисунков. (**Ученики отгадывают название произведения.)

(Ученики  выставляют свои рисунки  по произведениям  Аяза Гилязова)

**6. Отгадывание кроссворда**

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | **5** | | | |
| | | | | | | | | М | | | |
| | | **6** | | | | **4** | Х | а | л | и | л |
| | | А | | | | | | т | | | |
| **1** | И | л | д | у | с | | | у | | | |
| **2** | И | с | к | а | н | д | а | р | | | |
| **3** | М | у | й | н | а | к | | | | | |

По горизонтали:

1.Герой рассказ «Алсу, Илдус и соловей»

2.Герой рассказов «Суык» и « Матур»

3.Кличка собаки

4.Имя мальчика рассказа «Муйнак»

По вертикали:

5. Кличка котёнка

6. Имя героини рассказа

**7. По отрывкам угадывание названия рассказа Аяза Гилязова**

**1 ученик**

- Әби, - диде ул бервакыт, - бу тәти миңамы ?

- Юк, улым, - диде әбисе,- ул тәти сиңа кирәкми. Тәти түгел ул, ә термометр. Суык килгәнне күрсәтә торган. («Суык»)

**2 ученик**

Разыя, әнисе күрмәгәндә генә, өчпочмак кисәген өстәлдән бер читкә алып китте. Газета битен ертып алып, аның белән өчпочмакны бик әйбәтләп кенә төрде һәм киенеп урамга чыкты. («Матур»)

**3 ученик**

Сандугач шул килүеннән китмәде. Шунда оя ясады, шунда бала чыгарды. Бик яратты ул Илдусларның бакчасын. Алсу белән Илдус та ул бакчаны бик яраттылар. («Алсу, Илдус һәм сандугач»)

**4 ученик**

Беркөнне Хәлил кечкенә генә бер көчек күтәреп кайтты. Хәлимнең әнисе аңа җылы сөт эчерде, муенының сыдырылган урынына дару сөртте. («Муйнак»”)

**8. Презентация о творчестве и биографии Аяза Гилязева.**

**9. Оббщение.**

Ситдикова Розалия Хадиулла кызы, Мөбарәкшина Гүзәл Гарифҗан кызы,
Казан шәһәре, Совет районы, 111 нче рус -татар урта гомуми белем мәктәбе

## Мин намуслы яшәдем
## (Әдәби-музыкаль кичә, театр төркемнәре бәйгесе)

Сыйныфтан тыш чараны үткәрүнең максаты һәм бурычлары: укучыларда Аяз Гыйләҗев иҗатын өйрәнүгә кызыксыну тудыру; укучыларга милләтпәрвәрлек тәрбияләү; әдәби иҗатка сәләтле балаларны барлау һәм ачыклау; укучыларның сәләтләрен үстерергә ярдәм итү.

Гыйнвар аенда безнең мәктәбебездә халкыбызның яраткан язучысы Аяз Гыйләҗев туган көненә багышланган бәйрәм үткәрелә.

Бәйрәм мәктәпнең актлар залында уздырыла. Билгеләнгән сәгатьтә матур итеп киенгән укучылар залга җыйнала. Зал бәйрәмчә бизәлә. Сәхнәдә Аяз Гыйляҗев портреты. Талгын гына музыка уйный. Стеналарда язучының әсәрләренә караган балаларның рәсемнәр күргәзмәсе, иллюстрацияләр, укучыларның иншалары эленә. Аерым бер почмакта Аяз Гыйләҗев китапларыннын торган китаплар күргәзмәсе оештырыла. Укучылар алдан кереп, рәсемнәрне карыйлар, китаплар күргәзмәсе белән танышалар. Укучылар өчен "Иң яхшы театр төркеме", "Яшь каләм тибрәтүче", "Яшь рәссам", номинацияләрендә мактау грамоталары әзерләнә. Жюри әгъзалары билгеләнә.

Тантаналы музыка яңгырый. Сәхнәдә интерактив тактада язучының тормыш юлын һәм иҗатын чагылдырган презентация күрсәтелә башлый.

*...Мин намуслы яшәдем дип уйлыйм. Заманалар кайсыга борылмасалар да, мин үз юлымнан тайпылмадым.... Мин үз сукмагымда калдым... Минем тормышым, минем иманым – минем әсәрләремдә. Аларны җиңел кулдан сызып ташлап булмый. Мин шулай дип уйлыйм, шулай дип ышанам. (Аяз Гыйләҗев)*

**Беренче алып баручы.** Исәнмесез, кадерле укучылар, хөрмәтле укытучылар, әти-әниләр!

Бүген без бу залга халкыбызның яраткан язучысы Аяз Гыйләҗевнең туган көнен билгеләп үтәргә җыелдык. Бүгенге кичәдә без сезнең белән яраткан язучыбызның иҗаты һәм тормыш юлы буенча сәяхәт итәрбез. Аяз Гыйләҗевнең әсәрләреннән өзекләр тыңларбыз. Укучылар тарафыннан сәхнәләштерелгән төрле әсәрләрдән өзекләрне карап үтәрбез. Иң яхшы театр төркемнәренә, бәйрәмдә төрле номинацияләрдә катнашкан укучыларга мактау грамоталары бирелер.

**Икенче алып баручы.** Аяз Гыйләҗев. Бу исем һәр татар кешесенә, һәр мәктәп баласына яхшы таныш. Ул халык йөрәгендә туры сүзле, гадел, үткен телле, хакыйкатьне яклаучы, гаделлеккә омтылучы язучы булып кереп калды.

Язучыбызның әсәрләре кулдан-кулга йөреп, Россиядә төрле милләт телләренә тәрҗемә ителеп, бөтен дөньяга таралды.

**Беренче алып баручы.** Прозаик һәм драматург Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 нче елның 17 нче гыйнварында Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туа. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. Авыл мәктәбенең тугызынчы сыйныфын тәмамлагач, унынчы сыйныфны Сарман урта мәктәбендә укый. Мәктәп елларында укыганда ук әдәбияткә тартыла. *(Презентация дәвам ителә).*

**Икенче алып буручы.** Әдәбиятны яратуы аны Казан дәүләт университетына алып килә. Менә ул студент булу бәхетенә ирешә.1948 – 1950 нче елларда Казан дәүләт университетында укый. Аяз Гыйләҗевнең башлангыч иҗат тәҗрибәләре студентлык чорына карый. 1948 нче елны «Безнең хикәяләр» исемле җыентыкта яшь авторның «Ян, Учагым, ян!» исемле лирик рухтагы беренче хикәясе басылып чыга.

Бәхетле студент еллары. Хыяллар, алга куелган максатлар.... (*Сәхнәдә 8 нче сыйныф укучылары «Ян, Учагым, ян!»әсәреннән өзек күрсәтәләр)*

**Беренче алып баручы.** Ләкин хыяллар, алга куелган максатлар бер минутта юкка чыга. Аңа шәхес культының газапларын татырга туры килә. 1950 елның мартыннан башлап 1955 елның августына кадәр япь-яшь егеткә Казахстанда тоткынлыкта булырга туры килә. *(Презентация дәвам ителә)*

**Икенче алып буручы.** Рафаэль Мостафин бу хакта түбәндәге юлларны яза.

**Сәхнәдә 10 нчы сыйныф укучысы Р. Мостафин сүзләрен сөйли.**

*“Минем Аяз Гыйләҗев белән беренче күрешүем 1949 нчы елны, Казан дәүләт университетына укырга килгәч булды. Мин – беренче, Аяз икенче курста укый идек. Базык гәүдәле, имән төбе кебек нык егет бер күрүдә үк үзенең түгәрәк күзлек пыялалары артындагы акыллы, үткер күз карашы белән җәлеп итте. Үз-үзенә бик нык ышанган, зур максатларга омтылучы, сәләтле кеше иде ул. Башка укучылар лекция белән генә канәгатьләнсәләр, ул исә профессорлар биргән белем белән чикләнмичә, кич саен диярлек китапханәләрдә казына иде. Тыелган, ул вакытта «халык дошманнары» дип исәпләнгән язучылар – Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Хәсән Туфан әсәрләрен әллә каян табып, аларны җентекләп өйрәнеп, алар турында үз фикерләрен туплый иде.*

*Әлбәттә, мондый «башбаштаклык» ул чорда җәзасыз калмый. Кемдер «чаккан», күрәсең. 1950 нче елның мартында Аязның ятагы көтмәгәндә-уйламаганда бушап калды. Аның белән бер чорда Мәҗит Рафиковны, Гурий Тавлинны, тагы берничә кешене кулга алдылар. Бу – ул чорның иң өметле, иң сәләтле, башкалардан бер башка өстен яшь талант әһелләре иде...*

**Беренче алып буручы.** Сорау алулар, авыр хезмәт, төрмә тормышы... Болар яшь егетне сындырмый, киресенчә булачак язучы ныгый. Тагын да үҗәтләнеп, тормышкаябыша. Алдына куйган максатларыннан кире чигенми.

**Икенче алып баручы.** Казанга кайткач, ул университетта укуын дәвам итә һәм университетны уңышлы гына тәмамлый.Үз алдына куйган максатына ирешә *(Презентация дәвам итела)*

**Беренче алып буручы.** 1957 нче елның мартыннан 1961 нче елның августына кадәр А.Гыйләҗев матбугат эшендә: «Чаян» һәм «Азат хатын» (хәзер «Сөембикә») журналлары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, «Совет әдәбияты» ("Казан утлары") журналында проза бүлеге мөхәррире вазифаларын үти.

**Икенче алып баручы.** 1956-1960 нчы еллар арасында «Чаян», «Азат хатын», «Ялкын», «Совет әдәбияты» журналларында, республика газеталарында язучы өч дистәгә якын хикәя, фельетон, мәкалә һәм үзенең беренче күләмле әсәрләреннән — сугыш чоры авылы яшүсмерләре тормышына багышланган «Дүртәү» исемле повестен бастыра.*(9 нчы сыйныф укучылары “Дүртәү” әсәреннән бер өзекне уйнап күрсәтәләр)*

**Беренче алып баручы.** 1961-1963 нче елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укып кайтканнан бирле Аяз Гыйләҗев, язучы-профессионал сыйфатында, әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә.

**Икенче алып баручы.** Беренче әсәрләрендә үк язучының сиземләнгән язу манерасы – кырыс реализм, халыкчан образларга бай җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары, кайсы чор турында һәм нинди темага язса да, кеше шәхесенең катлаулы рухи дөньясын, эш-гамәлләрен анализлау – А.Гыйләҗев иҗат эшчәнлегенең төп асылын, идея-эстетик юнәлешен тәшкил иткән сыйфатлар.

**Беренче алып баручы.** 7 нче сыйныфта өйрәнгән “Өч аршын җир “ әсәре шуңа мисал булып тора. Шәмсегаян белән Мирвәли образлары укучыны үзенә тарта, җәлеп итә.

Әйдәгез, без хәзер “Өч аршын җир әсәреннән бер өзек карап китик.

*(7 нче сыйныф укучылары сәхнәләштергән “Өч аршын җир“ әсәреннән өзек сәхнәдә карала).*

**Икенче алып баручы.**"Өч аршин җир" (1962 ел), "Зәй энҗеләре" (1963 ел), "Урталыкта"(1969 ел), "Язгы кәрваннар"(1972 ел), "Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят" (1973 ел), "Җомга көн кич белән" (1979 ел), "Әтәч менгән читәнгә" (1979-1980 ел) әсәрләре белән Аяз Гыйләҗев үзен повестлар остасы итеп таныта.

**Беренче алып баручы.** Яраткан язучыбыз драматургиядә дә иҗади сәләтен күрсәтә. Татар дәүләт театры сәхнәсендә бер-бер артлы «Җиз кыңгырау» (1959), «Киек каз юлы» (1960), «Көзге ачы җилләрдә» (1961) исемле пьесалары куела. А. Гыйләҗев – ике дистәдән артык драма әсәре авторы. Кеше язмышының катлаулы борылышларын шактый нечкә психологик детальләр, тормыш күренешләре аша тасвирлый. Аның геройлары синең белән бергә яши, синең күптәнге танышың кебек тоела. Шуңа да аларның күбесе республика театрлары репертуарына кертелә.

(*10 нчы сыйныф укучылары"Яра" әсәреннән өзек күрсәтәләр)*

**Икенче алып баручы.** Драматургның кайбер пьесалары башкорт, авар, чуваш милли театрлары, рус театры сәхнәләрендә куела, «Җиз кыңгырау», «Югалган бер көн», «Өч аршын җир» (шул исемдәге повесть буенча инсценировка), «Эңгер-меңгер» исемле пьесалары исә, рус теленә тәрҗемә ителеп, Мәскәүдә «Советская драматургия» альманахында һәм күмәк җыентыкларда басылып чыга. «Югалган бер көн» пьесасы 1977нче елда Чехословакиядә словак телендә дә дөнья күрә.

**Беренче алып баручы.** Тематик яктан, А. Гыйләҗевнең күпчелек повестьлары авыл тормышына багышлана. Аларда кичәге һәм бүгенге авыл, аның гади кешеләре гәүдәләндерелә, әхлак, тәрбия мәсьәләләре; мәхәббәт, гаилә, намус, вөҗдан каршында җаваплылык, яшәү максаты, яхшы белән яманның кеше күңелендә барган мәңгелек көрәше гыйбрәтле язмышлар, тирән конфликтлы, драматик вакыйгалар аша яктыртыла. Автор үзенең әсәрләрендә гади кешенең рухи бөеклегенә дан җырлый. "Җомга көн кич белән" әсәрендәге Бибинур, Җиһангир образлары шуның дәлиле булып тора.

Хәзер без сезнең белән А.Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән" әсәреннән 10 нчы сыйныф укучылары тарафыннан сәхнәләштерелгән өзекне карап үтәрбез.*( 11нчы сыйныф укучылары"Җомга көн кич белән" әсәреннән өзекне сәхнәләштереп күрсәтәләр ).*

**Икенче алып баручы.** Язучы әдәбиятта үз сукмагын табып, беркемне дә кабатламыйча, рухи азатлык җырчысы буларак юл яра. Аның төп теләге – хакыйкатьне яклау, гаделлеккә омтылу иде. Язучы әсәрләреннән тоталитар режимга карата ачы нәфрәт, шәхес иреген чикләү белән килешмәү, гади кешеләрнең азатлыкка омтылышы аңкып тора. Соңгы елларда А.Гыйләҗев роман жанрында иҗат итүгә күп көч куя. Аның бер-бер артлы "Балта кем кулында" (роман), "Йәгез, бер дога!" (роман-хатирә) кебек зур күләмле әсәрләре дөнья күрде.

**Беренче алып баручы.** «Мин бераз төшенкерәк күңелле кеше», - дип әйтә ул үзе турында. Әсәрләрендә дә ул күбрәк кайгы-хәсрәт, татар халкына тарих китергән бәла-казалар турында яза. Төрмә дә аның өчен үзенә күрә бер мәктәп була. «Ул минем күземне ачты, тормышның ни икәнен аңлатты», - ди ул бер интервьюсында. "Йәгез, бер дога!" дигән зур күләмле әсәрендә нәкъ менә шул тормыш мәктәбе турында яза да инде ул.

Аяз Гыйләҗев тоткынлыкта чакта венгр егете Арпад Галгоци белән таныша. Аның прототибы "Йәгез, бер дога!" әсәрендә Хуродзе образында да чагыла. Ирекә чыккач та Аяз абый озак еллар дустын эзли. Әмма бер хәреф аркасында киткән ялгышлык, "Галгоци"ны "Голгоци" дип эзләү аркасында, барысы да нәтиҗәсез була. Венгр егете лагерьдә рәсем ясау остасы булган, Аяз Гыйләҗевнең да портретын ясаган. Аяз Гыйләҗев исә ул сурәтне Нәкыягә хат белән салып җибәрә. Язучының вафатыннан соң, шактый еллар узгач, шул портреттагы имза аша галимә Миләүшә Хәбетдинова Галгоцины эзләп таба. Хәзер ул Венгриянең танылган рәссамы, язучысы. Арпад Галгоци – Гыйләҗевләр гаиләсендә көтелгән кунак. "Тоткынлыкта алты ай гына бергә булсак та, ул минем өчен абый кебек булды. Үземне Аяз аркасында гына исән калдым, дип саныйм. Без аның белән

төннәр буе татар һәм венгр милләтләренең уртак яклары турында сөйләшә идек”, - дип искә алган Арпад Галгоци Казанга килгәч. Ул Аяз Гыйләҗевның ”Йәгез, бер дога” әсәрен венгр теленә тәрҗемә иткән. Китапның тышлыгына язучының тоткынлыкта чакта үзе ясаган сурәтен урнаштырган.

**Икенче алып баручы.** 11 нче сыйныф укучылары безгә ”Йәгез, бер дога!” әсәреннән өзек күрсәтерләр.

**Беренче алып баручы.** А. Гыйләҗев – Бөтенсоюз театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге, «Казан утлары» журналы һәм «Идел» альманахының редколлегия члены, озак еллар Татарстан Язучылар союзы каршындагы драматурглар секциясенә җитәкчелек итә һәм Язучылар союзына кабул итү комиссиясендә член булып тора, Татарстан язучыларының X съездында (1984) ул идарә члены итеп сайлана. Әдәбиятны һәм театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен аңа 1978 нче елда Татарстан АССРның, ә 1985нче елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә. А. Гыйләҗев – 1961 нче елда СССР Язучылар союзы члены булып тора. Ул – Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен 1993 нче елда, Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Аяз Гыйләҗевкә Татарстан Республикасының халык язучысы дигән мактаулы исем бирелә.

**Икенче алып баручы.** «Йәгез, бер дога!» әсәреннән менә мондый бер өзек китерәсе килә. «Милләтнең иң зур байлыгы – хәтер. Уртак хәтерсез милләтләр, милләт булудан туктап, гавам, халык төркеменә әйләнәләр... Милли хәтер бары тик үз җирендә бердәм булып яшәгәндә генә саклана ала һәм буыннар дисбесенең бөтенлеген, тулылыгын саклый...». Рафаэль Мостафин А. Гыйләҗевне “Милләтебезнең имән баганасы” дип атый.

**Беренче алып баручы.** А. Гыйләҗев – үз милләтенең чын патриоты, яклаучысы иде. Аның иҗади мирасы зур. Олы язучыбызның әсәрләре хәзерге көндә дә актуаль, укучылар аларны яратып укыйлар. Яраткан язучыбызның әсәрләре буыннан буынга күчеп, һәрвакыт халкыбыз күңелендә яши һәм яшәр.

*Тантаналы музыка уйный. Жюри әгъзалары бәйрәмдә катнашучы театр төркемнәренең, укучыларның эссе һәм иншаларын, рәсемнәрен, иҗади эшләрен бәяли. Тантаналы рәвештә төрле номинацияләрдә катнашкан укучыларга Мактау грамоталары тапшырыла.*

Зиннәтова Лилия Максут кызы,
Алабуга шәһәре, 10нчы санлы урта гомумбелем бирү мәктәбе

**Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән”әсәренә анализ ясау**

**Дәрес максатлары:** Укучыларны Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” әсәрен анализларга өйрәтү; “Җомга көн кич белән” әсәренә күзәтү ясау; эзләнү һәм чагыштыру ярдәмендә укучыларның фикерләү сәләтен үстерү; Аналарга тирән ихтирам, кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләү.

**Эш формалары**: Укытучы һәм укучы арасында эшлекле мөнәсәбәт.

**Көтелгән нәтиҗә**:

- предмет нәтиҗәләре: әсәрнең әһәмиятен һәм кыйммәтен ачу; дәресне тормыш белән бәйләү;

- шәхси нәтиҗәләр: геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирә белү; аналарга ихтирам, башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык, кеше кадерен белү кебек хисләр формалашу;

- метапредмет нәтиҗәләре: коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмат чаралары белән эшләү тәҗрибәсен ныгыту.

**Универсаль уку гамәлләре:**

- танып белү УУГ: укучыларның сорау куя белү, нәтиҗә ясый белү кебек фикерләү сәләтләрен үстерү, үз фикерләрен дөрес һәм матур итеп әйтүләренә ирешүне булдыру;

- регулятив УУГ: эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү; ихтияр көче, максатчанлык, активлык кебек сыйфатларга ия булуга ирешү;

- коммуникатив УУГ: төркемдә эшли белү; мәгълуматны туплау өчен күмәк эшчәнлектә катнашу.

**Җиһазлау:** А.Гыйләҗев портреты һәм әсәрләре, дәреслек, компьютер, проектор, “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”

**Дәрес тибы**: әсәргә анализ ясау

**Дәрес төре:** дәрес-дискуссия

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру**.Уңай психологик халәт тудыру.

**Укытучы**. Хәерле көн, укучылар. Сезне күрүемә бик шатмын. Утырыгыз. Укучылар, тактага күз салыгыз әле, тактада татар халкының “Ана күңеле – балада, бала күңеле – далада” дигән мәкале язылган. Бүгенге дәреснең эпиграфы итеп минем шушы сүзләрне аласым килә. Сез бу гыйбарәне ничек аңлыйсыз? (Укучылар җавабы)

**II.Белемнәрне актуальләштерү.**

Укучылар, сезнен өстәлләрдә ак кәгазь битләре ята, сез аларны урталай бөкләгез дә бер ягына ана, икенче ягына бала дип язып куегыз һәм һәр атама астына әлеге кешеләргә хас сыйфатларны языгыз. (Мәсәлән: Ана – шәфкатьле, кайгыртучан, баласын ярата һ.б.; бала – кечкенә, уйнарга ярата, әнисенең сүзен тыңлый, тыңламый, шаян һ.б.) Иң күп сыйфатларны санаган укучы җаваплары тыңлана. Укучылар кәгазьләргә игътибар итегез, алар ап-ак һәм чиста, шулай бит?! Хәзергә аларны читкәрәк алып куйыйк та, дәреснең төп өлеше, әсәрне анализлауга керешик.

**III. Төп өлеш**

**Укытучы**. Әсәрнең темасын билгелик. Әсәр нәрсә турында дигән сорауга җавап бирәбез.

**Укучы**. Әсәрдә Бибинур ятим калган балаларны үз балалары кебек тәрбияли.Ул яхшылык эшли.

**Укытучы.** Яхшылык сүзенең синонимнарын табыгыз әле.

**Укучы.** Игелеклелек, шәфкатьлелек, миһербанлылык һ.б.

**Укытучы.** Өстәлләрдә яткан “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ннән яхшылык сүзенең билгеләмәсен табып укыйк.(Беренче тапкан укучы җавабы тыңлана).

**Укытучы.** Әсәрнең төп темасы – тигелеклелек, шәфкатьлелек. Тема нинди вакыйгаларда чагыла һәм нәтиҗәсе нинди була?

**Укучы**. Бибинур игезәк туганы Зөһрәбануны Галикәй белән кавыштыра, ә туганы аңа гомере буе начарлыклар эшли

**Укучы**. Бибинур хуҗасыз этне өенә алып кайтып, аңа соңгы ризыгын бирә, соңыннан шул эт үзен талап үтерә.

**Укучы.** Бибинур ятим балаларны карап үстерә, алар картлык көнендә әниләрен оныта.

**Укытучы.** Укучылар, әсәрдә сюжет сызыкларын табыйк әле.

А) Бибинур мәхәббәте.

В) Бибинур һәм Зөһрәбану.

Г) Бибинур һәм балалары.

(Укучылар һәрбер сюжет сызыгының эчтәлеген сөйлиләр)

**Укытучы.** Әсәрдәге ярдәмче образны табыгыз, Бибинур нәрсә белән киңәшә. Бу нәрсәне символлаштыра икән?

**Укучы.** Буа тавышы. Буа тавышы әсәрнең башыннан ахырына кадәр ишетелеп тора. Бибинур аны иң авыр һәм шатлыклы чакларында ишетә, буа – аның иң якын киңәшчесе. Буа Бибинурның ялгызлыгын күрсәтә, аның кешеләр арасында киңәшер, шатлыгын бүлешер якыннары юк.

**Укытучы**. Әсәрнең төп персонажы – Бибинурга характеристика бирик. Ул ничек яши?

**Укучы.** Бибинур олы яшьтә. Балалары аны ташлый, ялгызы гына яши. Пенсия ала. Пенсиясе җитәр-җитмәс. Өйдәге бөтен яхшырак әйберләрне сатып, акчасын балаларына җибәрә. Киемнәре тузган, яңасын алырга акчасы юк. Өе иске. Бибинур әбигә кеше бик керми. Ул ялгыз. Ул эш ярата, авырлыкка түзә белә, гафу итә. Ул барлык кешегә яхшылык кына эшли. Балалар ятимлек ачысын татымасыннар өчен, Бибинур кулыннан килгәннең бөтенесен эшли: укыта, кеше итә. Алар турында начар сүз әйттерми.

**Укытучы.** Хәзер дәрес башында яза башлаган ак кәгазьләребез белән эшне дәвам итик. Бибинур нинди әни? дигән сорауга җавап язабыз (2 минут вакыт бирелә) (**Җавап.** Ул балаларын чынлап яраткан, алардан бернәрсә дә кызганмаган, балаларына акчалата да булышкан, картайгач, өйдәге әйберләрен сатып, хәтта пенсия акчасын да балаларына җибәргән. Балалары өчен барысына әзер. Һәрчак балаларын уйлый).

**Укытучы.** Хәзер кәгазьләрне бөкләнгән урыныннан ертыйк та балалар ягына Бибинурның балалары турында языйк. Аларның бер сыйфатын язган саен, ана турында язылган битне бөкләп барыйк (2 минут). (**Җавап.** Бибинурның балалары әниләренең кайтып хәлен дә белмәгәннәр. Байлык артыннан куганнар. Онытканнар, аларның күңеле далада, алар миһербансыз, тәүфыйксыз, мәрхәмәтсез).

**Укытучы**. Укучылар хәзер ике кәгазь битен чагыштырыйк әле: аналарга хас сыйфатларны язган бит, Бибинур балаларының сыйфатларын язган чакта сырланып, бөгәрләнеп бетте. Бу битне аналарның күңеле дип карасак, Аяз Гыйләҗевнең бу әсәрендә нинди проблемалар күтәрелүен ачыкларбыз. (Балаларның кылган һәр начарлыгы, уйланмый эшләнгән эшләре ана күңелен җәрәхәтли. Әниләрне хөрмәтләү – һәр баланың изге бурычы. Ата-аналар һәм балалар арасындагы проблема).

**Укытучы.** Ана күңеле итеп караган кәгазебез сырланса, бөгәрләнсә дә, ул пычрандымы, укучылар? Ни әйтерсез? (Ул ак калды, без әниләргә авырлыклар китерсәк тә, күңелләренә тирән яра салсак та, алар күңеле һаман чиста, пакъ. Алар һаман балаларын уйлый, алар дип яна-көя).

**Укытучы**. Укучылар, уйлап карагыз әле, ни өчен без иң элек кәгазь битен бөкләп кенә аналар һәм балаларга хас сыйфатларны яздык, соңрак икегә ертып яза башладык икән. Проблема эзләгез. (Балачакта бала һәм әни гел бергә, ләкин язмыш аларны кайчан да булса аера. Без моны кәгазьләрне ертып күрсәттек, шул чакта да бала анасын онытырга тиеш түгел. Бибинурның да балалары кечкенә чакта гел янында, үсеп җитеп таралышкач

кына, əнилəрен оныталар. Без өлкəннəрне хөрмəтлəү, ярдəм итү, өлкəн кешелəр язмышы, буыннар арасындагы бəйлəнешнең өзелүе, кеше күңеленең рухи байлыгы, əхлак мəсьəлəсе проблемаларын күрсəтə алабыз).

**Укытучы.** Укучылар, бу тема бүген дə актуальме? (Бу тема бүген дə актуаль. Хəзерге көндə дə үз əти-əнисен рəнҗеткəн, олыгайган көннəрендə тəрбиялəмəгəн, картлар йортында яшəткəн кешелəр бар. Аларны аналары, төн йокыларын калдырып, үстергəн, укыткан, кеше итəргə тырышкан. Ата-ананы, өлкəннəрне хөрмəт итергə, ярдəм итəргə, карарга кирəк).

**Укытучы.** Язучыларыбыз, шагыйрьлəребез бу теманы читлəтеп үтмилəр. Бу темага язучыларыбызның нинди əсəрлəрен белəсез? (Шəриф Камалның “Буранда” хикəясе, Шəриф Хөсəеновның “Əни килде” драмасы).

**III. Йомгаклау.**

Без бүгенге дəрестə бик күп эшлəдек, матур җавапларыгыз өчен рəхмəт. Инде эшлəгəн эшлəргə йомгак ясыйк:

1. Без бүгенге дəрестə ни белдек;
2. Нинди яңалык ачтык;
3. Килəчəктə тормышта кулланачакбыз.

**Укытучы.** Автор безгə ни əйтергə тели? (Ата-ана өчен бала – иң кадерле җан иясе. Аларның үз балалары турында гел яхшылык кына ишетəселəре килə. Ата-ана балаларының ярдəмен, хөрмəтен тоеп яшəргə хаклы).

**Өй эше бирү:**

Бибинур бəхетлеме соравына үз фикереңне язарга.

Бибинурга хат язарга.

“Бер уйласаң, без бит əнилəргə терəк булыр өчен туганбыз” дигəн темага бүгенге көн белəн бəйлəп сочинение язарга.

**Билгелəр кую.**

Рəхмəтуллина Рəмзия Рафик кызы,
Чишмə гомуми урта белем бирү мəктəбе, Алексеевск районы

## КВН
## (Аяз Гыйлəҗевнең “Язгы кəрваннар” əсəрен йомгаклау)

**Максат:** Укучыларда А.Гыйлəҗев иҗаты белəн кызыксынуны үстерү һəм фəнни-практик яктан эзлəнүне булдыруга омтылыш уяту. Халык авыз иҗатының төрле үрнəклəрен əсəрдəн индивидиуаль таптыру һəм практикада куллану. Гуманистик тəрбия үстерү.

**Материал**: презентация, укучыларның язмалары, тест, карточкалар, С.Хəким “ Язгы кəрваннар” шигыре

**Җиһазлау**: диапроектор, компьютер, портрет, карточкалар.

**КВН барышы:**

**Белдерү**

Бүген була КВН –
Гаҗəп күңелле уен!
8лəр көч сынаша,
Менə сиңа тамаша!

Кадерле балалар! Без бүген Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәренә йомгак ясарга җыйналдык. Ул КВН рәвешендә булыр. Ике команда көч сынаша. КВНның нәрсә икәнен сез беләсез инде. КВНга бары тик зирәкләр, тапкырлар, эшкә оста, сүзгә кыска булган укучылар гына җыела. Сезнең алды шундый ике команда. Бәйрәмегез котлы булсын! Зур уңышлар телим сезгә. Сизгер һәм кыю булыгыз. Белемегезгә таянып эш итегез! Ике команда да бергә:

Туган җирең Идел буе,
Һәр телнең бар туган иле.
Туган җирең кебек назлы
Җырдай моңлы татар теле.

Инде мөхтәрәм жюри әгъзалары белән танышып үтик. Таныш булыгыз: бүгенге бәйгедә гадел хөкемне менә шушы кешеләр чыгарачак (жюри әгъзалары белән таныштыру).

-Укучылар, ярышыбызны башлыйбыз. Ярышта 8 сыйныф укучылары катнаша. Әйдәгез, командалар белән танышыйк (командалар үз-үзләрен тәкъдим итә). Сүзне аларга бирәбез.

Ярыш уен формасында бара. Командалар алдан ук бүленә һәм һәрберсе үзе белән таныштырыр өчен визитка әзерли: исем, җыр, девиз, эмблема һ.б. сайлый.

Беренче тур – “Капчыктагы хикмәтләр”, икенче тур – “Син-миңа, мин-сиңа”, өченче тур “Тел чарлау” дип аталыр. Барыгыз да тиешле сорауларга җавап бирә алырсыз дип ышанып калам. Сезгә ике командага бүленергә кирәк.

- Беренче команда -“Зирәкләр”, икенче команда “Тапкырлар” дип атала.

Сәламләшү. (“Тапкырлар”: Тырышкан табар, ташка кадак кагар. “Зирәкләр”: Сынатмаска, бирешмәскә, артта калмаска!)

- Командалар белән таныштык, укучылар, ә хәзер уенга күчик.

**Беренче тур** “Капчыктагы хикмәтләр”дип атала, аны өй эше итеп, А.Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәреннән халык авыз иҗаты үрнәкләрен эзләнүләрдән, фразеологик әйтелмәләр, җырлар, такмаклар, кушаматлар, мәкальләр һәм әйтемнәр табарга кушкан идем.

**“Зирәкләр” командасы:**

**Фразеологик әйтелмәләр**

...Дамирның колагына гөмбә үскән...

...Арба тәгәрмәчләрем шаярышып җырлашалар...

...Әрдәнәләр чәлдерп кайтабыз.

...Икмәк тирәсендә акмаса да ,тама..

...Калын кенәгәсенә кадалган..

**“Тапкырлар” командасы.**

...Үрдәк кенә астына су кергәнен көтеп бакылдап утыра..

..Күрегенең җиде җиреннән тын өреп торган бакалы тальян..

...Машиналар турында ипилек-тозлык беләсем килде...

...Дамирның көнләшүдән бавыры кабарды..

...Утыралар шунда аналары яламаган нәрсәләр, сагыз чәйнәп...

**“Зирәкләр” командасы:**

**Халык авызы иҗаты буларак җырлар**

1.Алтын булып агаем ла!..

Әлә-лә-ләү!

Көмеш булып тамаем!..

Әлә-лә-ләү!

**“Тапкырлар” командасы.**

2. Ятсам төштә, торсам истә....

**“Зирәкләр” командасы:**

**Такмаклар һәм кушаматлар**

...Будрин Бурис-тракторист...!

...Дамир“Тамыр –Камыр..

**“Тапкырлар” командасы.**

...Шофер Гөргери...

...Торна Хәмит..

**“Зирәкләр” командасы:**

**Мәкальләр һәм әйтемнәр.**

Ир канаты аттан башка узмаган

Буран- кыян чыкмагае, сул кулымны күтәрә алмыйм...

**“Тапкырлар” командасы.**

Кем чанасына утырсаң...ни диләр әле?..

Иртәрәк килгән бәхетле кулларда.

**Нәтиҗә:**

Сүзне йомгаклап шуны әйтү урынлы булыр. Аяз Гыйләҗев үз әсәрендә халык авыз иҗатын бик тә оста һәм урынлы куллана. Алар: җырлар, фразеологик әйтелмәләр, такмаклар һәм кушаматлар, мәкальләр һәм әйтемнәр. Ул халыкчан. Әхлак-тәрбия бирә. Әсәрне тагын да матуррак, тулырак итеп аңларга ярдәм итә.

**Концерт номеры**

**2нче тур. “Син – миңа, мин – синңа”.** Төркемнәр бер-берсенә сораулар бирәләр.

**“Тапкырләр” - “Зирәкләргә”.**

**Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәрендә сугыш чоры балаларының батырлыгы һәм сугыш китергән афәт?**

Без... Сугыш ул ике ил арасындагы кофликт дип беләбез. Аңлатмалы сүзлектә ул – ике ил арасындагы кораллы көрәш, диелгән.

1...Аркылы-торкылы такталар белән ярым томаланган тәрәзәле бер-ике бүлмәсендә ялгыз карчыклар, тол хатыннар һәм җитү чәчле, җиткән тырнаклы балалар яшәп ята...

2...Сугыш башлангач, ире танкист булып китте. Сабира апаны алмадылар , йөрәгендә бар икән, диделәр... Булса да булгандыр, ире Орел каласы янында танкта янып һәлак булгач, идарә баскычы төбендә егылып чак дөнья куймады…

3...Мин кардыга җитәрәк атларны күмеп кайтып киләләр иде инде. Фураж да, солы да юк иде атларга, күгәрә башлаган салам белән җан саклап торалар икән бичаралар...

4...Болары – кичәге фронтовиклар. Алар җитди, кырыс, шушы гайре табигый җанланышның бар хикмәтен алар гына белгән кебек, фронтовиклар председательгә тартылганнар. Куллар шинель кесәсендә, һәр шинельдә кесә бар, һәр кесәдә кул гына юк...

5...Сугышның беренче аенда ук ятим калып, тол ананың сыңар канаты астында, туйганчы аш ашамыйча, күңел юанырлык кием кимичә, кайчагында кимсенеп тә, кайчагында чамасыз гарьләнеп тә яшәп килгән сынык күңелне нишләттең, Әдилә?!

6...Алабута катнашкан булса да, алда – ризык. Аны олыларга кирәк!...

**“Зирәкләр” “Тапкырларга”.**

**Аяз Гыйләҗев турында күренекле кешеләрнең фикерләре?**

1.“Аяз Гыйләҗев – татарның әдәби мирасына зур өлеш керткән язучы.”

ТР президентының киңәшчесе **Минтимер Шәймиев.**

2.“Аяз Гыйләҗев – әдәбиятыбызның төрле тармакларында ат уйнаткан кеше. Ул күренекеле прозаик, үзенчәлекле драмматург, үткен каләмле публицист һәм очеркист, ниһаять, усал телле тәнкыйтче”.

**Фәрваз Миңнуллин.**

3.“Халык язучысы Аяз абыйның мирасы татар халкы өчен зур хәзинә! Һәм ул мәңгелек! Аяз Гыйләҗев – киләчәктә иң укылачак, алай гына да түгел, бер кулыңа килеп эләккәч, кат-кат укылачак әдип!Ул милләтебез горурлыгы!”

**Фаил Ибраһимов.**

4.“Башка әсәр язмаса да, “Җомга көн,кич белән...” повесте генә дә А.Гыйләжев татар әдәбияты тарихында калыр иде”

**Тәлгат Галиуллин**.

5.“Шөкер татар әдәбияты олпат шәхесләргә, теленең нечкәлекләрен үтә сизгер тоемлаучы, һәр кәлимәне асылга утыртылган бриллиант кимәленә җиткерә белүче сүз осталарына бай булды, һәм аларның берсе дип, мин, һич икеләнмичә Аяз ага Гыйләҗевне күрсәтер идем...”

**Флүс Латыйфи**ның “Юксыну” дигән мәкаләсеннән.

6. “Язгы кәрваннәр” повесте “Казан утлары” журналында басылгач, **Сибгат ага Хәким**: “Аяз, мин синең ул повестеңне укыдым. Син анда, үзең кичергән яшьлек еллары рухын саклаган хәлдә, каләм көченең олпатлыгын раслаганың. Түзмәдем, шул исемдә шигырь яздым”, - дигән була.

**Концерт номеры**

**Өченче тур – “Тел чарлау”.** Монда укучылар төркемнәрдә тест сорауларына җавап бирәләр.

**Тест:**

1.Сәрвәр апа орчык күк бөтерелә.

а) сурәтләү чарасы б) чагыштыру в) фразеологизм

2.”Камыр”,”Тамыр”, кемгә әйтелә бу кушамат?

а) Дамир б) Әдилә в) Ибраһим.

3.Солы алып кайту Кәследән ничә чакрым?

а) 66 б) 60 в) 65

4.Ибраһим белән Әдилә Дамирга ничек карыйлар?

а) кимсетеп б) үртәбрәк в)үз итеп

5.Образлы әйтелмәләр

а) күңел сандыгы б) күзләр җиргә тәгәрәде в) тәмле чәй.

6.Кешене һәм тормышны бизи торган сыйфат

а) киң күңеллелек б) яхшылык в) елмаеп

7.Дамирның үз хыялы

а) трактор б) Әдилә в) колын

8.Әсәр кем исеменнән сөйләнелә?

а) Дамир б) Ибраһим в) Сабирә.

9.“Язгы кәрваннәр” әсәре кайсы вакытта язылган?

а) сугыш б) тынычлык в) ачлык

10.Яшәү мәгънәсе нәрсәдә?

а) байлык б) өмет в) шатлык

**Җаваплар:1б), 2а), 3в), 4в), 5 а), 6а), 7б), 8б), 9а), 10б).**

**Очколарны санау, җиңүче команданы билгеләү.** Жюри санаган арада, сүзне укучыларга бирик әле. Берничә концерт номеры карап китик.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә, Аяз Гыйләҗев әсәрләренең тәрбияви кыйммәте әйтеп бетергесез зур. Алар безнең милләтебезнең рухи байлыгы, милли үзенчәлекләре турында чорыбыз вакыйгаларына бәйләп язылган әдәби әсәрләр. Безнең чор кешеләренең яшәү рәвешләрен киләчәк буыннарга да алып бару вазыйфасы тапшырылган аларга.

Укуда да бер-берегез белән ярышып укыгыз. Уңышлар телим сезгә. Сау булыгыз!

Шакирова Рузалия Сәгыйть кызы,
Гали Акыш исемендәге 84 лицей-интернат, Яр Чаллы шәһәре

**А.Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәренә образлар бирелеше ягыннан анализ**

**Максат:** Язучының тормышы һәм иҗатын искә төшереп, әсәрнең темасы белән бәйләнешен ачыклау. Повестьта образлар бирелешен ачу, әсәрнең хәзерге чорда торткан урынын, актуальлеген билгеләү. “Язгы кәрваннар” әсәрендәге вакыйгаларны, әсәр геройларын күзәтеп, эзләнү, чагыштыру һәм нәтиҗәләр ясау ярдәмендә укучыларның фикерләү сәләтен үстерү. Укучыларда халкыбызның уңай әхлак сыйфатлары үрнәгендә кешелеклелек сыйфатларын үзләрендә булдырырга омтылыш уяту.

**Җиһазлау:** А.Гыйләҗев әсәрләре, язучының иҗаты буенча презентация, компьютер, проектор, 8 нче сыйныф өчен дәреслек, газета-журнал материаллары, тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин, шагыйрь М. Мирза сүзләре.

**Дәрес тибы:** яңа белем алу дәресе.

**Метод:** өлешчә эзләнү

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру.Уңай психологик халәт тудыру.**

- Хәерле көн, укучылар. Бер-берегезгә елмаегыз һәм утырыгыз.

**II. Актуальләштерү.**

**Үткән дәрес материалын презентация ярдәмендә искә төшерү.**

**Укытучы сүзе.** Күренекле шагыйрь Мөхәммәт Мирза Аяз Гыйләҗев турында: “Әдәбиятыбызның имән баганасы,”- ди. Бу чыннан да шулаймы?

Үзенчәлекле, берәүне дә кабатламый торган, дәреслекне ярып салучы язучы А.Гыйләҗевнең тормыш юлы, иҗатын искә төшерербез бүген.

**Язучының тормыш юлы, иҗаты турында презентация күрсәтү.** Слайдлар буенча укучыларның белемнәрен тикшерү. **1 нче** слайд күрсәтелә һәм сораулар:

**-** Кем, туган елы, туган җире, кайларда белем ала?

**2 нче** слайд күрсәтелә. Тикшерергә, нәтиҗә ясарга һәм үзбәя.

**3, 4, 5 нче** слайдлар күрсәтелә һәм 6 нчы слайдта сорау**.** Тормышының бу чоры турында кайсы әсәрендә яза? (укучылар җавап бирә).

**7, 8 нче** слайдлар күрсәтелә**.** Бу слайдлардан алган мәгълүматның (журнал исемнәре, ничәнче елдан язучылык аның һөнәренә әверелә) истә калганнарын әйтергә.

**Укытучы.** Кеше яши икән, бәхет татыр өчен яши, - дип яза А.Гыйләҗев.Ул үзен бик бәхетле кеше дип санаган

**9, 10, 11 нче** слайдларда гаиләсе күрсәтелә**.** Болар – аның дәлилләре.

**12 нче** слайд. Укырга һәм тематикасын **дәфтәргә кыскача язарга.**

**13 нче** слайд-сорау**.** 1960 нчы еллардан соң язган әсәрләрен һәм мактаулы исемнәрен санарга (укучыларның телдән җавабы)

**15-17нче** слайдлар буенча тикшерергә һәм **үзбәя куярга**

**Укытучы.** М.Мирза сүзләренә карата фикерләрегез, аның белән килешәсезме? (укучылар җавабы)

**III. Кызыксындыру(мотивлаштыру). Җиңү салюты күрсәтелә.**

Игътибарлы булыгыз! Ни өчен күрсәтелде? (Бөек Җиңү бәйрәменең 72 еллыгы булып узды.). Бу вакытта А. Гыйләҗевка ничә яшь булган? (17 яшьлек егет )

**IV. Уку мәсьәләсен проблемалы итеп кую, чишү.**

**Укытучы.** Аяз Гыйләҗев иҗаты турында тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин болай яза: “Аяз Гыйләҗев прозасы фикергә, фәлсәфи уйлануларга бай. Әсәрләрен укыганда, без уйлана һәм уйландыра белүче геройлардан тыш, дөньяның агышы, гомернең мәгънәсе турында, шулай ук дөньякүләм хәлләргә кагылышлы бик күп фәлсәфи фикерләргә юлыгабыз”.

- А.Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” исемле әсәренә һәм образлар бирелешенә анализ ясап, без бүген бу сүзләрне исбатларга тиеш.

- Кәрван сүзен сез ничек аңлыйсыз? Белмәсәгез, кайсы сүзлектән файдаланабыз? (Аңлатмалы сүзлектән)

- Кәрван – кемнең дә яки нәрсәнеңдер хәрәкәт итүче төркеме дигәнне аңлата.

- Әсәрнең исеме “Язгы кәрваннар”. Ни өчен язгы? (Чөнки әсәрдә вакыйга яз көннәрендә бара)

- Яз нинди ел фасылы? (Яшәрү, яңару, яшәүгә өмет фасылы)

- Әсәрнең жанры нинди һәм ни өчен? (Повесть: катнашучы геройлар күп, күләме, вакыт)

- Әсәрнең төп геройлары кемнәр?

**Дәфтәрләргә язып куябыз һәм кыскача язып барабыз**. Телдән тулы җавап бирәбез. (Әдилә, Ибраһим, Дамир – яңа гына ятим балалыктан чыгып килүче, сугыш чоры авырлыкларын кичергән 50 нче еллар яшьләре)

- Аерым калкып торган **тагын берничә герой** бар. Алар кемнәр? (Хәкимҗан абый – председатель, колхозны аякка бастыру өчен җанын да кызганмаучы сугыш герое. Сабираттәй – алга өндәп баручы, кыю, тракторист, өч балалы тол хатын, сугыштан контузияләнеп кайткан Габбас абый һәм аның нечкә күңелле, кеше хәлен аңлаучы кунакчыл хатыны Сәрвәр апа).

- Бу геройларга кабат әйләнеп кайтырбыз әле. Әсәрдә төп сүз нәрсә турында бара? (Повестьта юл сынаулары, ашлык ташу авырлыклары, мохтаҗлык, гаделсезлек күрсәтелә.)

- Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалар кайсы чорда, елларда бара?

- Бу чор турында нәрсәләр әйтә аласыз? Тарих, башка фәннәрдән алган белемнәрегезне файдаланыгыз. (Сугыштан соңгы авыр еллар, социализм).

- Автор нинди ысул (метод) белән язарга тиеш булган? (Социалистик реализм, бу тормышны мактап язу).

Төп геройларга әйләнеп кайтабыз: Ибраһим – Әдилә – Дамир. Алар арасындагы мөнәсәбәт нинди? (Ибраһим да, Дамир да Әдиләне ошаталар. Икесе дә аның мәхәббәтен яуларга тырышалар)

- Ибраһим турында сөйлибез. Дамир нинди?

- Әдиләне характерлаучы өзекләрне **дәреслектән табып укыйбыз**. (Апасының балаларын тәрбияли – миһербанлылык; Хәкимҗан абыйга солының Сарсазда гына да

булуын әйтү – туры сүзле булу; Кәсле ягыннан килгән халыкның солыны Сарсаздан алып китүен күргәч, халыкка әйтмәү – халыкның күңелен яраламау – изге күңелле, мәрхәмәтле булу)

- Аларны нинди сыйфатлар берләштерә? (Алар арасында, елларның нинди булуына карамастан, якты, матур кичерешләр, хезмәтне ярату, тиеш дип эшләү, киләчәккә ышаныч, бер-береңә тугрылык, алга юл ярып баручылар, Кәслегә юлны таптап, олыларның чаналарын үзләренә алып баралар) **Үзбәя куярга**

- Еллар авырлыгын сурәтләгән урыннарны **дәреслектән табып укыйбыз**. (Атлар өрлектә, ыңгырашалар.Тол хатыннар, ятим балалар. Ашханә янындагы табын, ризыклар, Габбас абый, Сәрвәр апа гаиләсе)

- Шулай булса да, автор табынны, Сәрвәр апалар гаиләсен матурлык хисе белән тасвирлый. Ни өчен? (Чөнки бу мизгелләрдә дуслык, бер-береңә миһербанлы булу, кыстау һ.б.)

Сабираттәй һәм Әдилә образлары турында нәрсә әйтә аласыз? Алар арасында охшашлык бармы? (Әйе, алар икесе дә лидер, алга өндәп баручы, туры сүзле хатын-кызлар.)

- Автор ни өчен бу ике геройны әсәргә керткән? (Сабираттәй йөрәк өянәгеннән үлә. Әдилә – Сабираттәйнең дәвамы, әйдәп алып баручы) **Язып куябыз.**

- Дәүләтнең толларга, ятимнәргә, халыкка карата гаделсезлеге, ягъни әсәрдәге төп фаҗига нинди? (Янәшәдә Сарсаз глубинкасында булган орлыкны халыктан 65 км ераклыктагы Кәследән ташыту һәм Кәсле авылы янындагы Чокырлы халкын орлыкка дип Сарсазга җибәрү, көзен барлык ашлыкны Чаллы элеваторына ташыту).

- Ни өчен фаҗига? (Чөнки дәүләт халыкны кайгыртырга тиеш, ә бу очракта киресенчә).

- А.Гыйләҗев ни өчен “Язгы кәрваннар” повестен язган? (Ул шушы авырлыкларны, шушы чорны үз күзләре белән күргән, кичергән һәм безнең дә боларны белеп, халыкның авыр елларда да бер-берсенә мәрхәмәтле, кайгыртучан, өмет белән яшәвеннән үрнәк алып, гыйбрәтләнеп яшәвебезне теләгән).

- Бүгенге көннәрдә өйрәнү кирәкме? Әсәр актуальме? (Әйе, кирәк. Без үзебезнең гыйбрәтле тарихыбызны белергә тиеш. Актуаль. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәт, хезмәт сөючәнлек, максатчанлыкка өйрәнергә кирәк әле) **Үзбәя куярга.**

**V. Яңа белемнәрне белемнәр системасына кертү.**

Әсәрдә образлар системасына, өлешчә әсәргә анализ ясаганнан соң, нәтиҗәләр чыгарабыз.

**1нче нәтиҗә.** Еллар нинди генә авыр булуга карамастан, халык нык ихтыярлы, хезмәт сөючән, бер-берсенә мәрхәмәтле, нечкә күңелле, кайгыртучан булып кала, авыр минутларда бер-берсенә терәк була.

**2 нче нәтиҗә.** Әсәрдә халкыбызның гүзәл гореф-гадәтләре искә төшерелгән: җор теллелек, егет-кызларның матур мөнәсәбәтләре, җыр-моң белән яшәү, бер-береңә булышу сокландыра.

**3 нче нәтиҗә**. Яшьләр яңалыкка (тракторчылыкка уку) омтыла, алар – халыкның таянычы һәм киләчәк өмете, алдан юл яручылар.

**4 нәтиҗә.** Чыннан да А.Гыйләҗев – фәлсәфәче, уйлана һәм уйландыра белүче геройлары бар, гомер, яшәү мәгънәсе турында уйландыра. Дәүләтнең халыкка мөнәсәбәте турында күтәрелгән проблемалар бүгенге көндә дә актуаль. **Үзбәя куярга.**

**VI. Рефлексия.**

Без бүгенге дәрестә бик күп эшләдек, рәхмәт сезгә. Эшләгән эшләргә йомгак ясыйк.

1.Без үзебезгә бүгенге дәрестән ни алдык?

2.Нәрсә белдек?

3. Нинди яңалык ачтык?

4. Киләчәктә нинди белемнәрне тормышта кулланачакбыз?

(Дәресебез бик эчтәлекле, мавыктыргыч һәм тәрбияви характерда булды. Бу әсәрне укыгач без үзебезгә бик күп яңалык ачтык. А.Гыйләҗев – фәлсәфи язучы икәнен белдек. Сугышның бик куркыныч нәрсә икәнен тоябыз. Кирәкми безгә сугыш! Тыныч һәм матур яшик! Күгебез һәрвакыт аяз булсын! Халкыбызның үткәненә тирән ихтирам белән карыйк! )

**VII. Өй эше.** Тыл хезмәтчәннәре турында проектлар әзерләп килергә.

**VIII. Бергәләп (үзбәяләрне берләштереп) билге кую.**

Гыйзәтуллина Линиза Минехөрмәтулла кызы, Галәветдинова Гүзәлия Хәмит кызы,
Казан шәһәре, Идел буе районы, 19 нчы гимназия

**Тема: Халык йөрәгенә уелып кергән “Бибинур”**
**(А.Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән...” әсәре белән “Бибинур” фильмын чагыштыру дәресе)**

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Метапредмет*: әдәбиятның кино сәнгате белән бәйләнешен күзәтү, чынбарлыкны танып белү үзенчәлеген ачыклау.

*Предмет*: татар кино сәнгате турында мәгълүмат бирү, “Бибинур”фильмын А.Гыйләҗевнең “Җомга көн, кич белән... ” әсәре белән чагыштыру, әсәрдә һәм фильмда күтәрелгән проблемаларны билгеләү, образ – характерларны ачыклау, эш-гамәлләренә бәя бирә белү.

*Шәхескә караган:* кино сәнгатенә кызыксыну уяну, үз халкың белән горурлану хисе булдыру.

**Материал:** 9 нчы сыйныф өчен “Татар әдәбияты” китабы, А. Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” повесте.

**Җиһазлау.** А.Гыйләҗев портреты, әсәр буенча презентация, М.Гыйләҗевнең “Бибинур” фильмының видео язмасыннан өзекләр, видеороликлар, карточкалар, А. Гыйләҗевнең төрле елларда басылып чыккан китапларыннан күргәзмә.

**Метод һәм алымнар:** проблемалы укыту, әңгәмә

**Дәрес барышы.**

**I.Оештыру өлеше.** Исәнләшү.Уңай психологик халәт тудыру.

**II.Төп өлеш.**

**Укытучы.** Укучылар, мин сезгә видеоролик карарга тәкъдим итәм. Аннан соң сорауларга җавап бирербез. (Укучыларга татар язучыларының әсәрләре буенча эшләнгән татарча фильмнардан өзекләр күрсәтелә. “Зөләйха”, “Ак чәчәкләр”, “Тапшырылмаган хатлар” һ.б.). Видеоролик буенча сораулар өстендә эш.

- Бу фильмнар сезгә танышмы?
- Әлеге фильмнар нинди әсәрләр буенча төшерелгән?
- Бу әсәрләрнең авторларын һәм төп геройларын атый аласызмы?

Укучыларның җаваплары тыңлана.

**Укытучы.** Белгәнебезчә, 2016 нчы ел – Россия күләмендә кино елы буларак игълан ителгән иде. Соңгы елларда кино өлкәсендә татар әдәбиятында танылган әсәрләр буенча берничә фильм төшерелде. Ә аларның берничәсен без видеороликта да күреп үттек. Татар классикларының әсәрләрен киң экраннарга беренчеләрдән булып чыгаручы режиссерлар Р.Төхвәтуллин, И.Ягъфәров, С.Юзеев, Н.Җамали, Ю.Фетинг. Әлеге фильмнарны тамашачылар яратып кабул иттеләр. Әлеге эшләр арасында А.Гыйләҗевнең "Җомга көн, кич белән..." әсәре буенча төшерелгән "Бибинур" фильмы да үз урынын алып тора. Фильм Татарстан тамашачысына беренче тапкыр "Алтын Мөнбәр" Халыкара мөселман киносы фестивалендә тәкъдим ителде. Әмма ул вакытта "Бибинур" конкурстан тыш күрсәтелде.

- Бүгенге дәресебездә дә А.Гыйләҗевнең "Җомга көн, кич белән... " әсәре буенча төшерелгән "Бибинур" фильмы буенча фикер алышырбыз, аны әсәр белән чагыштырырбыз, аермалы, уртак якларын табарга тырышырбыз. Сезгә бу фильмны өйдә карарга тәкъдим ителде.Үткән дәрестә А.Гыйләҗевнең "Җомга көн, кич белән... " повестена йомгак ясадык. Әйдәгез, хәзер шул дәрестә бирелгән өй эшләрен тикшереп китик. Биремнәр төркемнәргә бүленеп бирелде.

**1 төркем:** әсәрнең төп герое Бибинур образына характеристика язып килергә;

**2 төркем:** повестьтагы үзеңә ошаган эпизодны сөйләргә өйрәнергә;

**3 төркем**: әсәрдә күтәрелгән проблемаларны билгеләргә, дәфтәргә мисаллар язып килергә. (Укучыларның җаваплары тыңлана).

**Укытучы.** Әйе, укучылар, сез санап киткән проблемалар бүгенге көндә дә бик актуаль. Күргәнегезчә, алар фильмда да урын алганнар, ләкин бүгенге тормышка якынайтып бирелгәннәр. Ә бу фильм ничек төшерелгән, ничек барлыкка килгән икән соң? Хәзер фильмның режиссеры, эшләнеше, куелу тарихы турында (интернеттан алынган) "Как снимался фильм "Бибинур" дип аталган видеоролик (кыскартып бирелә) карап китәрбез.

- Әлеге проектның кайсы кинофестивальләрдә катнашуы, яулаган бүләкләре турында сөйләргә аерым укучыга мөстәкыйль эш итеп бирелгән иде, хәзер шул укучыны тыңлап узарбыз. (Укучының җавабы тыңлана).

**Укытучы.** Фильм турында сөйләшә башлаганчы, М.Гыйләҗев сүзләрен укып китәсем килә:

- "Бибинур" фильмында татар милләтенең бүгенге тормышы ничек бар, шулай ачып салына. "Без үзебез турында язабыз. Мине бу әсәрдә Бибинур карчык белән Җиһангир мөнәсәбәтләре уйландырды. Мин бит аны башка җирлектә яза алмыйм. Фильмда да кемдер урысча, татарча, инглизчә, кытайча сөйләшә. Тормышта да шулай бит", - ди автор.

Фильм буенча сораулар: Сез хәзер әсәрне генә түгел, фильмны да яхшы беләсез. Әйдәгез, берничә сорауга җавап биреп китегез.

- Сезгә фильм ошадымы? Бигрәк тә кайсы эпизод сезнең хәтерегездә калды?

- Нинди вакыйгалар, кайсы геройлар сездә кызгану хисе уятты? Кем өчен борчылдыгыз?

- Төп геройларга карашыгыз нинди?

- Җиһангир авылга нинди максат белән килә?Аны авыл халкы ничек каршы ала?

- Фильмга әсәрдә булмаган нинди персонажлар килеп керә, ә кайсылары киресенчә төшеп калган дип уйлыйсыз?

- Фильм әсәр сюжеты буенча төшерелгәнме?

- Режиссер ни өчен бүгенге заманга хас булган элементларны, күренешләрне фильмга кертте икән? Әлеге күренешләрне санап китегез. (Укучыларның җаваплары тыңлана).

**Укытучы.** Ә хәзер фильм белән әсәрнең уртак һәм аермалы якларына тукталып узарбыз. Бу эшне төркемнәргә бүленеп эшләрбез.Төркемнәргә биремнәр язылган карточкалар таратыла. Фильмнан карточкада язылган эпизодлар карап үтелә, шул ук өлешләр әсәрдән дә табыла. Әлеге эш-гамәлләргә карата укучыларның фикерләре тыңлана.

*1төркем.* Фильм аркылы Бибинурның балаларының читтәге тормышлары турында нәрсәләр белдегез? Әсәрдә әлеге момент ничек бирелә? Шул урынны табып, сәнгатьле итеп укып күрсәтергә яки рольләргә бүлеп уйнап күрсәтергә.

*2 төркем.* Габдуллаҗанның балалары фильмда Бибинурга ничек килеп әләгәләр? Әсәрдә әлеге хәлләр ничек итеп сурәтләнә? Шул урынны табып, сәнгатьле итеп укып күрсәтергә яки рольләргә бүлеп уйнап күрсәтергә.

*3 төркем.*Бибинур һәм Җиһангир ничек танышалар? Әлеге күренеш һәр икесендә ничек итеп күрсәтелгән? Шул урынны табып, сәнгатьле итеп укып күрсәтергә яки рольләргә бүлеп уйнап күрсәтергә.

*4 төркем.* Бибинур әби гомеренең соңгы мизгелләрен режиссер фильмда ни рәвешле итеп күрсәтә? Ә А.Гыйләҗев ничек итеп тасвирлый? Шул урынны табып, сәнгатьле итеп укып күрсәтергә. (Укучыларның җаваплары тыңлана).

**III.Рефлексия.**

**Укытучы.** Әсәрдәге һәм фильмдагы вакыйгалар турында да сөйләштек, сезнең фикерләрегезне тыңладык. Ә хәзер геройларга тукталып узыйк әле. Һәрберегезнең каршысында төрле төсләргә буялган түгәрәк. Мин атаган персонажга кайсы төс туры килә, шунда аның исемен язып куярга һәм ни өчен икәнен аңлатып, дәлилләп бирергә. (Мәсәлән: Бибинурга сары төс туры килә, чөнки ул кешелекле,ярдәмчел...)



- Бибинур, Җиһангир, Зөһрәбану, Нәҗип, Габдуллаҗан, Мирзаһит һ.б.

Укучыларның җаваплары тыңлана.

**Укытучы.** Инде әйтеп узганыбызча, фильмда да, әсәрдә дә төп образлар – Бибинур һәм Җиһангир. Аларны сез иң җылы төсләр белән чагыштырдыгыз. Автор әлеге геройларга нинди матур исемнәр сайлаган.Бу исемнәр нәрсәне аңлаталар икән? (Исемнәр сүзлегеннән карау).

Бибинур – нур чәчүче, Җиһангир – җиһанны яулаучы.

**Укытучы.** Чыннан да, Бибинур бар дөньяга “нур чәчә”, изгелекләр эшли, явызлыкка да яхшылык белән җавап бирә. Ә Җиһангир бар дөньяны колачлап, дөрес юлга кертергә тели.

**IV.Йомгаклау.**

**Укытучы.** Күргәнегезчә, укучылар, “Бибинур” фильмы без белгән, без укыган әсәрдән шактый нык аерыла. Фильмның режиссеры һәм сценарий авторларының берсе булган Юрий Фетинг бөтенләй башка юлдан киткән: заман китереп тудырган проблемага – глобальләшү шартларында тамырларыбыздан, җирдән аерылуның фаҗигасенә Бибинурның эчке дөньясын каршы куеп гаять тирән конфликт тудыра. Милләтләрнең һәм,

гомумән, кешелек дөньясының киләчәге турында тирән уйга сала. Татар карчыгының рухи дөньясы аша яшәешебезгә бәя биреп, ул “дөньяны матурлык коткарыр” дигән мәгълүм гыйбарәне тирәнәйтеп, дөньяны рухи чисталык һәм әхлак коткарыр, дигән нәтиҗәгә китерә. Фильмның яшь егетнең азан әйтүе белән тәмамлануы киләчәккә өмет калдыра... Чыннан да, милләтемнең киләчәге ышанычлы, халкымның яшәеше якты, бәхетле булыр... Халык күңеленә уелып кергән, тамашачы яратып караган бу фильм да әле озак еллар яшәр, онытылмас!

**V. Билге кую.**

**VI. Өй эше бирү.** Бер теманы сайлап язма эш язарга.

1.Бибинур карчыкның балаларына хат язарга.

2.Аксыргак авылының киләчәген мин ничек күрәм. (Фильмны дәвам итеп сценарий язарга).

3.Дөньяны изге күңелле кешеләр тота. (Элек укылган әсәрләр, каралган фильмнар буенча)

Васильева Римма Николай кызы,
М.К.Кузьмин исемендәге Иске Тәрбит урта гомуми белем бирү мәктәбе,
Кайбыч районы

## Аяз Гыйләҗевнең “Өтәч менгән читәнгә” повесте

Аяз Гыйләҗевнең “Өтәч менгән читәнгә” повесте буенча 11 нче сыйныфлар өчен технологик карта, укучыларның яшь үзенчәлекләрен, белем бирүдә федераль дәүләт стандартларын исәпкә алып төзелде. Технологик карта нигезендә Альберт Яхин концепциясе ята. Дәрес Ә. З. Рәхимовның иҗади үсеш технологиясенә корылган.

| Тема | А.Гыйләҗевнең “Өтәч менгән читәнгә” повестена анализ. |
|---|---|
| Максатлар | 1) дидактик: Укытучы белән укучы мөнәсәбәте аша эчтәлекне үзләштерү (сюжет сызыгы буенча вакыйгаларны аерып алу, уку мәсьәләсен куеп, повестька анализ ясарга өйрәнү. Күтәрелгән проблеманы, идеяне, чишелешне укучылардан таптыру. |
| | 2) үстерешле: фикер эшчәнлеге өчен гомуми җирлек булдыру (анализ вакытында туган фикерләрне таркатырга, чагыштырыга өйрәнү. Иҗади фикерләүне үстерү) |
| | 3) тәрбияви: тормыш тәҗрибәсе туплау, геройларның гамәлләренә бәя биреп, яшәү фәлсәфәсе турында уйлануны булдыру. Тугрылык, хөрмәт хисләрен үстерү, бер-береңнең кадерен белергә өйрәнү. Сәнгать әсәре тудырган А.Гыйләҗевкә ихтирам хисләре тудыру. |
| Планлаштырылган нәтиҗә | Предмет буенча:<br>Әсәргә анализ ясау ысулларын үзләштерү, әсәрнең сюжетын синтезлый белү, автор кулланган алымнарны табарга өйрәнү, әсәрнең темасын,идеясен, проблемасын, автор фикерен билгеләргә өйрәнү. Әсәрне укый белү, укыганны үз сүзләре белән сөйләп бирү һәм әсәрнең катнашучыларын табу, персонажларын, төп персонажны аерып ала белү күнекмәләрен үстерү. |
| | Метапредмет:<br>Бәхәсләрдә катнашу, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларыңны раслау һәм дәлилләү күнекмәләренә ия булу. Дөрестән дөрес түгелне аера белү, нәтиҗәләр формалаштыру, укыганны анализлау. |

| | |
|---|---|
| | Шәхескә кагылышлы: Тормыш тәҗрибәсе туплау, геройларның гамәлләренә бәя биреп, яшәү фәлсәфәсе турында уйлануны булдыру. |
| Төп ресурслар | Ноутбук, дәрес эшчәнлеге буенча презентация, китап күргәзмәсе |
| Уку эшчәнлеген оештыру | Дәресләрдә танып-белү эшчәнлеге академик Әхмәт Зәки улы Рәхимовның иҗади үсеш технологиясенә корыла.<br>Ягъни дәрестә танып белү эшчәнлеген оештыруның<br>• формасы – төркемнәрдә;<br>• методы – тикшерүле;<br>• контроль, бәя–үзконтроль,үзбәя;<br>• чаралар - белем чыганаклары, такта, укучының эш дәфтәре;<br>• нәтиҗәлелек - махсус белем күнекмәләр генә түгел, универсаль гамәлләр формалашуы өчен дә җирлек тудырылу;<br>• максат - дидактик максат, ягъни нинди махсус белем ни дәрәҗәдә күнекмәгә әйләнергә тиешлеге конкретлаштырыла. |

| Дәрес этабы һәм башкарылырга тиешле адымнар | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге (башкарылган гамәл) | Фаразланган, көтелгән нәтиҗәлек | |
|---|---|---|---|---|
| | | | предмет нәтиҗәлелеге (махсус белем, күнекмәләр ) | метапредмет нәтиҗәлелеге (универсаль гамәлләр) |
| I. Ориентлашу, мотивлаштыру этабы.<br>1. Өй эшләренә анализ. | Дәрестә уңай психологик халәт тудыру.<br>Өй эшләрен тикшерү (повестьны укырга, вакыйгаларны аерырга) | Төркемнәргә бүленеп,өй эшләрен искә төшерәләр, системалы итеп сөйлиләр | Эчтәлекне аңлап сөйләү, вакыйгаларны аерып күрсәтү, модельләштерү | *регулятив гамәлләр*: уку мәсьәләсен кую, чишү юлларын билгеләү, эффектив булганын сайлап ала алу, чишү, үз эшенә контроль ясый һәм бәя бирә белү күнекмәсе<br>– *танып – белү гамәле* – нәрсә эшләвеңә карамастан ысул аерып алу<br>–<br>*коммуникатив* (укучының тыңлый, ишетә, үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле җиткерә белү) |
| 2.Актуальләштерү. | Төркемнәрдә киңәшеп искә төшерегез әле, әдәби әсәрне укыганда беренче чиратта нәрсәгә игътибар итәбез? | *Көтелгән җавап:* Повестьның темасын билгелибез, идея, проблеманы табабыз, автор әйтергә теләгән фикерне ачыклыйбыз. Гомумән, повестьны анализлыйбыз.<br>*Шулай ук* персонажларга бәя бирәбез, әсәрнең эчтәлен (темасын) ачабыз, әсәрнең мәгънәсен(идеясен), автор куйган проблеманы һәм язучының проблемага карашын билгелибез | | |
| 3. Уку мәсьәләсен конкретла | Сюжет сызыгы нәрсәләрдән тора соң? | *Көтелгән җавап: Сюжет сызыгы вакыйгалардан тора* | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| штыру ситуациясе процессы | | | | |
| II. Уку мәсьәләсен (УМ) чишү этабы.<br>1. Уку мәсьәләсен адымлап чишү | Әсәрдә нинди вакыйгалар турында сөйләнә? Вакыйгалар бер-берсенә охшаганмы?<br>*Үзбәя кую өчен критерийлар:*<br>*1) мин биремне дөрес үтәдем–“5” ле*<br>*2) иптәшләрем ярдәменә таяндым – “4”ле*<br>*3) иптәшләрем әйткәнне генә кабатлый алам – “3”ле* | *Көтелгән җавап:*<br>- Мирфатыйх – Сәләхетдин мөнәсәбәте<br>- Фирүзә кайгысы<br>- Җәмил өмете<br>- Вәзилә теләге<br>- Хәйдәр белән Мидхәт теләге<br>- Зәйтүн белән Әнәс каршылыгы<br>- Хәйретдин язмышы<br>- Мирфатыйх белән Сәләхетдиннең дошманлашу сәбәпләре<br>-Мотоцикл – көзгеле шифоньер (127 тәңкә)<br>- 2 көзгеле шифоньер (198 тәңкә)<br>-“Москвич” – “Жигули” (чия төсле – лимон төсле) | | |
| 2. Модельләштерү. | Сюжет элементларын модель белән күрсәтегез.<br>*Үзбәя кую өчен критерийлар:*<br>*1) мин биремне дөрес үтәдем, модельне китерә алдым –“5” ле*<br>*2) иптәшләрем ярдәменә таяндым – “4”ле*<br>*3) иптәшләрем әйткәнне генә кабатлый алам – “3”ле* | Башлам (экспозиция): әсәрнең башланып китү күренеше.<br>Төенләнеш: этәчнең читәннән егылып төшүе, гауга чыгу.<br>Вакыйгалар үстерелеше: 2 – 9 нчы бүлекләр.<br>Иң югары нокта (кульминация): машина белән бәрелү вакыйгасы.<br>Чишелеш: Хәйретдин агайның авырып китүе, Мирфатыйх белән Хәйретдиннең туганнар булуы ачыклану, хаталарын аңлаулары.<br>Әсәр төп сюжет сызыгының төенләнешеннән башланып китә. Бу – беренче бүлек. Икенче – тугызынчы бүлекләр – вакыйга- | Вакыйгаларга бәя бирелә, аларны чагыштырып, әсәрдәге капма-каршылык табыла. | Сюжет элементларын модельләштереп күрсәтә белү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | лар үстерелеше. Унынчы бүлек – кульминация, унберенчесе – чишелеш, ләкин һәр бүлек мөстәкыйль сюжет – ярдәмче сюжет сызыклары да. | | |
| | Образлар бирелешен ачыклыйк.<br>*Үзбәя кую өчен критерийлар:*<br>*1) мин биремне дөрес үтәдем образлар бирелешен ачыклый алдым – “5” ле*<br>*2) иптәшләрем ярдәменә таяндым – “4”ле*<br>*3) иптәшләрем әйткәнне генә кабатлый алам – “3”ле* | Мирфатыйх, Сәлә-хетдин, Гөлбикә, Гөлмәрьям, Зәйтүн, Әнәс, Вәзилә, Җәмил, Хәйдәр, Мидхәт, Хәйретдин агай. Хәйретдин агайның тормышы күркәм. Ул үзе эшчән һәм юмарт, ярдәмчел һәм акыллы, яхшы күңелле кеше. Тормыштагы хәлләргә битараф булып кала алмый, борчыла, ярсый, кешеләрнең пошмас җанлы булуларына йөрәге әрни. Әсәрдә каберлекләр-не карап, чистартып тәртиптә тотарга кирәклеге дә кызыклы детальләр аркылы укучы күңеленә җиткерелә. | Образларга, вакыйгаларга бәя бирелә, аларны чагыштырып, әсәрдәге капма-каршылык табыла. | |
| | Образлар арасындагы мөнәсәбәтләрдә нинди проблемалар күтәрелүен ачыклыйк.<br>*Үзбәя кую өчен критерийлар:*<br>*1) мин биремне дөрес үтәдем, проблемаларны ачыклый алдым – “5” ле*<br>*2) иптәшләрем ярдәменә таяндым – “4”ле*<br>*3) иптәшләрем әйткәнне генә* | - байлык артыннан чамасыз кууның көнләшүгә сәбәп булуы<br>- байлык һәм үзең турында гына уйлауның мәхәббәт-тән өстен торуы<br>- авыл җирлегендә матурлык төшенчәсенең, үткәннәргә хөрмәт хисенең югалуы<br>- татар авылына эчкечелек, комсыз-лыкның нык үтеп керүе<br>- хатын-кыз | Әсәрнең проблемасы ачыклана. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | *кабатлый алам – “3”ле* | тыйнаклыгының югала баруы | | |
| | Әсәрнең идеясен билгелик. | Бәхетне кеше тырыш хезмәте белән эшләп табарга тиеш | Әсәрнең идеясе билгеләнә. | |
| III. Рефлексия, бәя этабы. 1.Рефлексия.. | Нәрсә эшләргә тиеш идек? (УМ искә төшерелә); ничек эшләдек? (чишү юллары искә төшерелә); нинди нәтиҗә ясадык? • | Повестьны вакыйгаларга таркаттык, сюжетын өйрәндек. Повесть-ны анализлап, бүгенге көн өчен актуаль булган проблемаларны, идеяне ачыкладык, персонажларга бәя бирдек | | *регулятив гамәлләр* Укучының үз эшчәнлеген анализлый белүе, нәтиҗә ясарга өйрәнү сәләте булдыру -*коммуникатив* (укучының тыңлый, ишетә, үз фикерен башкаларга дәлилле җиткерә белү) |
| Дәрескә гомуми бәя кую. | | Биремнәр үтәүдә алган билгеләрдән гомуми билге чыгарыла. | | |
| 3. Өйгә эш алу. | | “Бәхет өчен нәрсә кирәк?” темасына иҗади эш язарга | | |

Гайнуллина Рузанна Сергей кызы,
Пәрәү гомуми урта белем мәктәбе, Лаеш районы

**Аяз Гыйләҗев “Язгы кәрваннар” әсәренең 1нче бүлеген өйрәнү (татар мәктәбенең 8 нче сыйныфында татар әдәбияты дәресе)**

**Максат:** Язучының тормышы һәм иҗаты белән таныштыру; әсәрләре турында күзаллау булдыру. “Язгы кәрваннар” әсәренең 1 нче бүлегенә күзәтү ясау; эзләнү һәм чагыштыру ярдәмендә укучыларның фикерләү сәләтен үстерү. Укучыларда халкыбыздагы күркәм әхлак сыйфатларын үзеңдә булдырырга омтылыш уяту.

**Җиһазлау:** А.Гыйләҗев портреты һәм әсәрләре, 8 нче сыйныф өчен дәреслек, компьютер, проектор, газета-журнал материаллары.

**Дәрес тибы:** яңа материалны өйрәнү дәресе.

**Дәрес барышы.**

**I. Оештыру.Уңай психологик халәт тудыру.**

-Хәерле көн, укучылар.Утырыгыз.

Хәерле көн телим һәр бөҗәккә,
Хәерле көн телим гөлләргә.
Сөйкемлелек телим яшь кызларга
Һәм сабырлык телим ирләргә.

Хәерле көн телим юлчыларга,
Чәчәкләргә карап елмаям.
Җиргә якты, җылы нурын сипкән
Кояшыма карап куанам.

-Укучылар, бүгенге дәресебезне мин Ф.Зыятдинованың “Хәерле көн телим” дигән шигыре белән башлап җибәрдем. Мин сезнең барчагызга да исәнлек-саулык, бәхет телим. Бүгенге дәреснең эпиграфы итеп түбәндәге шигырь юлларын аласым килә: ”Без бәхетне эзләп йөрмик әле, бәхет безне үзе эзләсен”

**II. Актуальләштерү.**

- Ә нәрсә соң ул бәхет, укучылар? Бәхет сүзен сез ничек аңлыйсыз?

Бәхет – тулы канәгатьләнү халәте һәм хисе дип язылган сүзлектә. Бәхет төшенчәсе булдыклы, сабыр, түземле, тәрбияле кешеләргә күбрәк елмая кебек. Укучылар, сез бәхет турында нинди мәкаль-әйтемнәр беләсез?

**Мәкаль-әйтемнәр белән эшләү.**

**Үткән дәрес материалын искә төшерү**

-Без үткән дәресләрдә Т.Миңнуллинның "Бәхетле кияү"комедиясен өйрәндек. Нәрсә соң ул комедия?

-Кияүнең бәхете нәрсәдә?

-Нури чыннан да бәхетлеме? (Әйе,чөнки ул сабыр, акыллы кызга өйләнгән, ул аны ярата. Әби-бабасы да тәртипле, туган җанлы кешеләр. Бу авылның кешеләре дә эшчән, кунакчыл. Мондый авылга кияү булу – үзе бер бәхет).

- Менә шундый сәхнә әсәре бүләк иткән безгә Т.Миңнуллин. Ул – татар драматургиясе күгендә якты йолдызларның берсе. Аның иҗаты белән без чын күңелдән горурланабыз.

**III. Төп өлеш.**

- Әдәбиятыбыз күркәм, кодрәтле сүз иясләренә бай.Үзенчәлекле, берәүне дә кабатламый торган, дөреслекне ярып салучы язучы А.Гыйләҗевнең тормыш юлы, иҗаты белән танышырбыз бүген.

**Укытучының кереш сүзе.**

**1. Язучының тормыш юлы, иҗаты турында презентация күрсәтү.** Слайдлар буенча аңлатма биреп бару. "Кеше яши икән,бәхет татыр өчен яши", - дип яза А.Гыйләҗев. Ул үзен бик бәхетле кеше дип санаган. Чөнки аның яраткан хатыны Нәкыя ханым, уллары - Искәндәр, Мансур, Рашат һәм оныклары аңа иҗат итү өчен көч, дәрт биреп торганнар.

**Язучы турында каләмдәшләре (истәлекләр )**

- А.Гыйләҗевнең әсәрләре дә үзе кебек образлы, мавыктыргыч, соклангыч тел белән язылган. Проза әсәрләре белән бергә кызыклы пьесалар биргән драматург та ул. Бүген без әдипнең "Язгы кәрваннар" исемле повестен өйрәнә башларбыз.

- Кәрван сүзен сез ничек аңлыйсыз? (Терминның аңлатмасын дәфтәргә язып кую).

- Кәрван − кемнең дә яки нәрсәнеңдер хәрәкәт итүче төркеме дигәнне аңлата. Әсәрнең төп геройлары – Әдилә, Ибраһим, Дамир – яңа гына ятим балалыктан чыгып килүче, сугыш чоры авырлыкларын кичергән 50 нче еллар яшьләре.

Сугыш безнең илебезгә зур сынаулар алып килде. Хәтәр сугыш елларында илебезне сакларга Татарстаннан 560 меңнән артык кеше киткән. Кулына корал тотып сугышкан 100 меңнән артык якташыбыз СССРның орден һәм медальләре белән бүләкләнгән. 200дән артык якташыбызга Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирелде. Халкыбыз эштә дә, сугышта да сынатмады. Безнең Иске Салман авылыннан да 253 кеше фронтка киткән. Алар арасыннан 121 кеше яу кырында ятып калган. Менә тиздән зур югалтулар бәрәбәренә яулап алынган Бөек Җиңү бәйрәме җитә. Илебез-җиребез тыныч булсын, кабат сугышлар булмасын иде. Сугыштан соңгы еллардагы авыр тормышны без әдәби әсәрләрдән укып беләбез.

А.Гыйләҗевнең "Язгы кәрваннар" исемле повестендә юл сынаулары, ашлык ташу авырлыклары күрсәтелә. Шулай булса да, якты, матур кичерешләр, хезмәт сөючәнлек, дуслык, бер-береңә миһербанлы булу төшенчәләре урын алган. Киләчәккә ышаныч, бер-

беренә тугрылык, чабата белән кар суын ерып, 30-40 кмдан чәчүлек орлык ташучы яшьләр халыкның таянычы һәм киләчәк өмете булып аңлашыла.

**2.Дәреслек белән эшләү.** А.Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” повестенең 1 нче бүлеген уку һәм анализлау. Өзекләр уку һәм нәтиҗә чыгару.

1 нәтиҗә.Татар халкы элек-электән җыр-моң яраткан, кайгырса да, шатланса да ул җырлаган. Тырышып хезмәт иткән, җыр белән хезмәтне бергә бәйләп алып барган.

2 нәтиҗә. Өзектә халкыбызның гүзәл гореф-гадәтләре искә төшерелгән: бер-беренә булышу, авыр минутларда терәк булу, егет-кыз мөнәсәбәтләре.

3 нәтиҗә. ...Колхоз келәтендә бер бөртек симәнә юк... Бу юлларны укыгач, сугыш елларында тол калган аналар, ятим балалар күз алдына килә.Аларның ул елларда күргән газаплары аркасында чәчләре чаларган, йөрәкләре җәрәхәтләнгән.

- Бүгенгә без әсәрнең 1нче бүлегенә генә күзәтү ясадык. Барлык бүлекләрен дә укып бетергәч, “Кешеләрне шатландыру – үзе бәхет” дигән темага сочинение язачакбыз.

- Үзебезнең авылдан сугыш кырында ирләрен югалткан апаларыбыз бар:

Дәүләтшина Мәмдүдә, Нуруллина Мәүлия, Нуруллина Зөһрә, Нотфуллина Миңнегөл, Гарипова Бәдерниса, Миндубаева Габкария, Сафина Маһисәрвәр, Хәлиуллина Җомабикә, Хәбибуллина Габкария. Бу апалар бүгенге көндә инде барысы да мәрхүмнәр... Алар авыр сугыш барган көннәрдә үзләренең ныклы, ихтыярлы лыгы, хезмәт сөючәнлеге, нечкә күңелле булулары белән Җиңү көнен якынайтуга үзләреннән зур өлеш керткәннәр, сугыштан соң да намуслы хезмәт иткәннәр.

Ә сезнең, укучылар, сугыш чоры авырлыклары турында ниләр ишеткәнегез бар? Ниләр беләсез? Сезгә өй эшенә тыл хезмәтчәннәре турында проектлар әзерләп килергә кушылган иде. Әйдәгез, хәзер сүз сезгә бирелә.

**3.Укучылар чыгышы.**

Насыйбуллина Гөлинәнең карт әбисе Дәүләтшина Мәмдүдә турында ясаган истәлек-презентациясен карау.

Вәлиева Гөлфинәнең тыл хезмәткәре Хәбибуллина Халисә белән интервью – видеофильмын карау.

**Өй эше бирү.** Әсәрнең 1 нче бүлегенең эчтәлеген белергә. 259 биттәге сорауларга җавап әзерләргә. Сугыш чоры һәм сугыштан соңгы авыр еллар турында тыл ветераннарыннан язып алынган истәлекләр алып килергә.

**IV.Йомгаклау.**

-А.Гыйләҗевнең һәр әсәре гыйбрәтле, эчтәлекле. Тикмәгә генә аның әсәрләрен яратып укымыйлар. Аның бигрәк тә “Яра”, “Балта кем кулында?” дигән әсәрләрен яратып укыйлар.

Бүгенге дәрескә эпиграф итеп түбәндәге шигырь юлларын алган идек: ”Без бәхетне эзләп йөрмик әле, бәхет безне үзе эзләсен”. Дәрес башында без кеше өчен кирәкле бик матур сыйфатларны искә төшердек. Кеше акыллы, әдәпле, инсафлы, тырыш булса, аны һәркем ярата, хөрмәт итә, һәм бу кеше тормышта үз бәхетен табар. Алдагы дәрестә дә элеге темага сөйләшү-бәхәсебезне дәвам итәрбез.

Бүгенге дәресне йомгаклап, сезгә Р.Харисның “Кеше кайчан матур була?” дигән шигырен бүләк итәм.

**Билгеләр кую.**

Әсәдуллина Әлфия Мансур кызы, Хәбибуллина Миләүшә Хәмит кызы,
аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче урта
гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

## Сез һәрвакыт безнең белән, Аяз ага Гыйләҗев
## (Телдән журнал)

**Максат:** укучыларның А. Гыйләҗев турындагы белемнәрен ныгыту, белем дәрәҗәләрен сынау; күзаллауларын киңәйтү, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү; язучы иҗатына карата хөрмәт, горурлану хисләре уяту.

**Җиһазлау:** А. Гыйләҗев иҗатыннан торган китап күргәзмәсе, әдипнең портреты, әдип турында язылган плакатлар :

Аяз Гыйләҗев – татарның әдәби мирасына зур өлеш керткән язучы.

Минтимер Шәймиев.

Аяз Гыйләҗев – татар әдәбиятында иң күренекле урын алган, халкыбыз күңелендә тирән мәхәббәт казанган зур язучы.

Гөлшат Зәйнәшева.

Кичә барышы

**1 алып баручы**. Тормышның хәрәкәтен һәм закончалыкларын сәнгатьчә ача, яктырта белүче, эзләнүчән һәм тынгысыз каләм ияләренә әдәбият һәрвакыт мохтаҗ була. 50нче ахырында, 60нчы еллар башында яшь язучыларның бер төркеме: Р. Төхвәтуллин, Г. Ахунов, Ә.Баянов, А.Гыйләҗев яңа кыйммәтләрне җанлы тормыш рухында, сугыш елларында үскән яшьләр күзәтүе һәм кичерешләре рәвешендә әдәби образларда гәүдәләндерү теләге белән прозага килеп керәләр. Шулар арасында А. Гыйләҗев зур урын алып тора.

Аяз Гыйләҗев – талантлы һәм үзенчәлекле прозаик. Ул – татар әдәбиятын уй-фикерләренең торгынлыгыннан коткарып, алтмышынчы-сиксәненче еллар әдәби агымын дәррәү кузгатып, хөрлеккә таба борып җибәрүче язучы.

Халык язучысы Аяз абыйның мирасы – татар халкы өчен генә түгел, бөтен кешелек дөньясы өчен зур хәзинә! Ул мәңгелек! Аяз Гыйләҗев киләчәктә тә иң күп укылачак, алай гына да түгел, бер кулыңа килеп эләккәч, кат-кат укылачак әдип!

**2 алып баручы.** Аяз Гыйләҗевнең иҗат колачы шактый киң. Без аны беренче чиратта, күренекле прозаик буларак хөрмәт итәбез. Тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин аның күпкырлы иҗатын җирдән бәреп чыккан кайнар чишмә белән чагыштыра.

**1 алып баручы.** “Бәләкәй чакта сукмаклар синеке! Ялантәпи, тып-тып басып, дөнья белән танышу әнә шул җәяүле сукмаклардан башлана. Кая карасаң да, сиңа ят ярлар, моңарчы син күрмәгән, күрә алмаган сер дөньясы”,- дип яза А.Гыйләҗев “Балачак сукмаклары” дигән истәлегендә.

А.Гыйләҗевнең балачак сукмаклары кайчан, кайда башланган соң? Шуның белән тулырак танышыйк. Без бүген чарабызны телдән журнал рәвешендә алып барырбыз.

**Журналның беренче битен ачыйк. Ул: “Әдипнең тормыш юлы” дип аталыр.**

**2 алып баручы.** Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 нче елның 17 нче гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Әтисен Югары Баграҗ авылына укытырга җибәрәләр. Балачагы, яшьлеге шул авылда, язучы сүзләре белән әйткәндә, “юмарт күңелле, кунакчыл, гади, үтә кешелекле, риясыз-хәйләсез керәшеннәр арасында үтә.

**1 алып баручы.** Авыл мәктәбенең тугызынчы сыйныфын тәмамлагач, унынчы сыйныфны Сарман урта мәктәбендә белем ала. 1948-1950 нче елларда ул Казан дәүләт университетында укый. Аңа да шәхес культы газапларын татырга туры килә. 1950 нче елның мартыннан 1955 нче елның августына кадәр кыен сөргенлек шартларында ташчы, бетончы, бригадир булып эшли.

Казанга кайткач, университетта укуын дәвам итә. 1957 елның мартыннан 1961 елның августына кадәр А.Гыйләҗев матбугат эшендә: «Чаян» һәм «Азат хатын» (хәзер «Сөембикә») журналлары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, «Совет әдәбияты» ("Казан утлары") журналында проза бүлеге мөхәррире вазифаларын үти.

1961-1963 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укып кайтканнан бирле Аяз Гыйләҗев, язучы-профессионал сыйфатында, әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә. Аяз Гыйләҗев хатыны Нәкия белән өч егет үстергәннәр. Аларның берсе – галим Искәндәр Гыйләҗев, икенчесе – драматург Мансур Гыйләҗев, өченчесе – малтабар Рәшат Гыйләҗев. Аяз Гыйләҗев 2002 елның 13 мартында вафат була.

**2 алып баручы.** Хәзер исә, әкрен генә **журналыбызның “А. Гыйләҗевнең иҗатына күзәтү” дип аталган битен ачабыз.**

(А. Гыйләҗевнең иҗат иткән китаплары күрсәтелә). А. Гыйләҗевнең башлангыч иҗат тәҗрибәләре студент елларында башлана. Аның “Ян, учагым, ян!” исемле лирик рухтагы беренче хикәясе 1948 нче елда ук дөнья күрә. Ә беренче китабы “Яшьлек юлларында” дип атала. Әлеге китап турында Хәсән Сарьян түбәндәге фикерне әйтә:

“1960 нчы елда басылган әлеге китапта беренче китапка хас кимчелекләр булуга карамастан, анда барыбер бүгенге җитлеккән язучы-художник А.Гыйләҗевнең инде сизелеп торган чалымнары бар иде. Бу китап татар әдәбиятына Аяз Гыйләҗев дигән бер язучы килгәнен хәбәр итте”.

Шулардан башланган иҗат чишмәсен бер дә саектырмыйча, А.Гыйләҗев үзен бик күп санлы хикәяләр, романнар, драма әсәрләре авторы итеп таныта.

**1 алып баручы.** “Аяз Гыйләҗевне язучы итеп таныткан әсәре, миңа калса, “Үги ана яфраклары” дигән егерме генә битле хикәясе булды. Бу хикәядә бернинди ялган юк, уйдырма юк; авторның һәр сүзе самими. Шул сүзләрдән ул, чын тормыш дөреслегенә һич тә хилаф китермәстән, “Менә бу тормышның үзе!” дип әйтә торган, хәтта үзеннән дә гүзәлрәк булган бер тормыш төзеп куйган”, – дип язган Хәсән Сарьян алда әйтеп үтелгән истәлегендә.

Шулай ук, әлеге әсәр турында Марат Әмирханов исә: “Үги ана яфраклары” хикәясен мин татар әдәбиятында мәхәббәт турында язылган иң самими, иң сәнгати әсәрләр рәтенә кертәм”,- дип искә ала. (Хикәядән өзекләр белән танышу).

“...Кемдер аның исемен яңгыратып кычкырган кебек булды. Ул колагы белән ишетүдән бигрәк күңеле белән сизенеп як-ягына каранды һәм Галәмәйләр тыкрыгыннан чыгып килүче аны күрде. Ул ап-ак күлмәк кигән иде.

Егет үз күзләренә үзе ышанмыйча машинасы белән бергә дерелди, калтырый иде.

Аның белән!

Янында ул утыра!

Кыз ярым көлемсерәп егеткә күз ташлап ала һәм, аның уйларын аңлаган кебек, бер сүз дә эндәшми. Икесе дә күрешү кинәтлегеннән исәңгерәп шактый вакыт сүзсез бардылар...”

**2 алып баручы.** “Башка әсәрләр язмаса да, “Җомга көн, кич белән...” повесте белән дә А. Гыйләҗев татар әдәбияты тарихында калыр иде”, - дигән фикере белән Тәлгат

Галиуллин бик хаклы. Татар хатын-кызларына хас күркәм сыйфатларны үзенә туплаган, сөттән ак, агым судан пакь, намуслылык, җаваплылык үрнәге булган Бибинур карчыкны сурәтләве өчен генә дә рәхмәтле без язучыбызга.

**1 алып баручы.** Ә “Язгы кәрваннар” повесте “Казан утлары” журналында басылгач, Сибгат Хәким: “Аяз, мин синең ул повестеңны елый-елый укыдым. Син анда, үзең кичергән яшьлек еллары рухын саклаган хәлдә, каләм көчеңнең олпатлыгын раслагансың. Түзмәдем, шул исемдә шигырь яздым”, - ди. Хәзер шул шигырь белән танышыйк. (Сибгат Хәкимнең “Язгы кәрваннар” шигыреннән өзек укыла).

**2 алып баручы. Журналыбызның өченче бите “Үзем турында үзем” дип атала.**

(А. Гыйләҗевнең истәлекләр китабыннан өзекләр укыла, карточкалар күрсәтелә).

**1 алып баручы.** Мин үзем күргән, тормышлары, яшәешләре, кылган гамәлләре белән мине баеткан бик күп кешеләр алдында зур бурычлы әле. Мин унҗиде яшемә хәтле авылда яшәдем. Сугыш еллары һәм аннан соңгы еллар иде бу. Шул елларның истәлеге минем өчен аерата газиз һәм кадерле. «Берәү», «Дүртәү» повестьларында мин бу истәлекләрнең бер өлешен язарга тырышып та карадым. 1972 елда «Язгы кәрваннар» һәм «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» исемле кечкенәрәк күләмдә ике повесть яздым. Бу минем үземнең авылдашларыма, якты шәхесләргә, Югары Баграж кешеләренә, Зәй буйларына бурычымны кайтаруым гына. Әсәрләргә геройлар тормыштагы үз исемнәре белән кермәсәләр дә, географик һәм биографик дөреслеккә ябышып ятмасам да, бу әсәрләр минем янәшәмдә яшәгән гүзәл авылдашларым турында. Яшәгән саен миңа алар хезмәтенең гадилеге һәм бөеклеге, алар яшәешенең матурлыгы һәм авырлыгы ныграк күренә сыман. Моңарчы язылган әсәрләремдә берникадәр тарлык барын үзем дә сизеп йөри идем, тәнкыйтьчеләрнең дә сүзе урынлы булды, әмма мин үзем белгән, үзем яраткан кешеләр алдында бурычлы булып калмаска тырышырмын.Хәзер дә тормыш белән бәйләнешне ычкындырмаска тырышам. Ел саен диярлек үз авылыбызга кайтам, башка төбәкләргә чыгам, йөрим. Тормыш көнләп түгел, сәгатьләп үзгәрә. Тормыш агышыннан ычкынып төшеп калмаска кирәк. Барыбыз да шуңа омтылабыз. Тормыштан артта калмас өчен, аның хәрәкәтен генә түгел, үзгәрмәс кыйбласын да яхшы белергә кирәк. Туган иленә, халкына бирелгәнлек, туган теленә сүнмәс мәхәббәт – менә ул язучының үзгәрмәс кыйблалары! Тормыш шартлары, яшәү күренешләре көнләп-сәгатьләп үзгәреп торса да, бу бөек төшенчәләр – мәңгелек, һәм шушы мәңгелеккә тугры кешеләр генә үзгәрешләрне халык белән бергә сиземли алалар.

**2 алып баручы.** Укучылар, без бүгенге кичәне Ркаил Зәйдулланың “Аяз Гыйләҗевкә” дигән шигыре белән йомгакларбыз. (Шигырьдән өзек укыла).

Асылгәрәева Розалия Әнәс кызы, Тихонова Резедә Рәфәт кызы,
аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче мәктәбе, Сарман районы

**Аяз Гыйләҗев - татар әдәбиятының мәңгелек сүнмәс уты (әдәби кичә)**

**Максат:** Укучыларны язучының тормышы һәм иҗаты белән таныштыру; әсәрләре турында күзаллау булдыру; иҗатына кызыксыну тәрбияләү; укучыларда телгә, кешеләргә ихтирам хисләре тәрбияләү

**Кичә барышы**

**Укытучы.** Исән булса, бүген күренекле татар язучысы Аяз ага Гыйләҗевка 90 яшь тулган булыр иде. Халык язучысы Аяз абыйның мирасы татар халкы өчен зур хәзинә! Һәм

ул мәңгелек! Аяз Гыйләҗев – киләчәктә иң укылачак, алай гына да түгел, бер кулыңа килеп эләккәч, кат-кат укылачак әдип! Ул – милләтебез горурлыгы! Аның тормыш юлын искә алып үтик.(Әзерләнеп килгән укучылар тормыш юлына күзәтү ясыйлар).

**1укучы.** Татарстанның халык язучысы, романчы, хикәяче, драматург, публицист Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында хәзерге Татарстан Республикасының Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туа. Бала чагы һәм мәктәп еллары күршедәге Зәй районының Югары Баграҗ исемле керәшен татарлары авылында уза. Шул авыл мәктәбенең тугыз сыйныфын һәм Сарман урта мәктәбендә унынчыны тәмамлаганнан соң, берникадәр вакыт колхозда эшли, аннары ике елга якын комсомолның Зәй район комитетында бүлек мөдире хезмәтендә була. 1948 елда Казанга килеп, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Монда ул, уку программасындагы фәннәрне яхшы үзләштерү белән бергә, беренче курстан ук бик мавыгып университет каршындагы әдәби түгәрәккә йөри, анда үзенең язган беренче иҗат тәҗрибәләре белән уртаклаша, фикер алышуларга, диспут-бәхәсләргә актив катнаша.

1957 елның мартыннан 1961 елның августына кадәр А.Гыйләҗев матбугат эшендә: «Чаян» һәм «Азат хатын» (хәзер «Сөембикә») журналлары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, «Совет әдәбияты» ("Казан утлары") журналында проза бүлеге мөхәррире вазифаларын үти.

1961-1963 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укып кайтканнан бирле Аяз Гыйләҗев, язучы-профессионал сыйфатында, әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә. Аяз Гыйләҗев 2002 елның 13 мартында вафат булды.

**2 укучы.** Аяз Гыйләҗевнең башлангыч иҗат тәҗрибәләре студентлык чорына карый. Ләкин аның актив иҗат эшчәнлеге 1956 елдан башлана дияргә була. Беренче әсәрләрендә үк анык сиземләнгән язу манерасы – кырыс реализм, халыкчан образларга бай җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары, кайсы чор турында һәм нинди темага язса да, кеше шәхесенең катлаулы рухи дөньясын, эш-гамәлләрен анализлау – А.Гыйләҗев иҗат эшчәнлегенең төп асылын, идея-эстетик юнәлешен тәшкил иткән сыйфатлар. "Өч аршин җир", "Зәй энҗеләре", "Урталыкта", "Язгы кәрваннар", "Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят", "Җомга көн кич белән", "Өтәч менгән читәнгә" әсәрләре белән Аяз Гыйләҗев үзен повестьлар остасы итеп танытты.

**3 укучы.** Тематик яктан А.Гыйләҗевнең күпчелек повестьлары авыл тормышына багышланган. Аларда кичәге һәм бүгенге авыл, аның гади кешеләре гәүдәләндерелә. Аяз Гыйләҗев – ике дистәдән артык драма әсәре авторы да. Аларның күбесе республика театрлары репертуарына кертелгән.

Соңгы елларда А.Гыйләҗев роман жанрында иҗат итүгә күп көч куйды. Аның бер-бер артлы "Балта кем кулында" (роман), "Йәгез, бер дога!" (роман-хатирә) кебек зур күләмле әсәрләре дөнья күрде.

"Җомга көн кич белән" һәм "Өтәч менгән читәнгә" повестьлары өчен А.Гыйләҗев 1983 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Әдәбиятны һәм театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен аңа 1978 елда Татарстанның, ә 1985 елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә. Ул – М.Горький исемендәге премия лауреаты да. Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен 1993 елда, Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Аяз Гыйләҗевкә Татарстан Республикасының халык язучысы дигән мактаулы исем бирелде.

**I. Аяз Гыйләҗев иҗатына багышланган стендка күзәтү ясау, китаплар күргәзмәсе белән таныштыру.**

Киң колачлы талант иясе иде ул. Проза өлкәсендә, драматургия өлкәсендә дә зур уңышларга ирешкән язучы. Ул әдәбиятка 60 нчы елларда килеп керә. Бу чор фикерләрнең каршылыклы чоры. Ләкин ул үз сүзен курыкмыйча әйтә килә. Бу адымга аны тоткан кыйбласының дөреслегенә ышаныч кына этәрә алгандыр. Аның кайсы гына әсәрен алсаң да, алар халык өчен, ил өчен борчылган олы әдипнең алыштырмас хәзинәләре.

Драма әсәрләре төрле театр сәхнәләрендә уйнала. Аның пьесалары белән танышкач, укучы уйлана, дөнья гаме белән яши башлый. Аяз ага – актив шәхес. Ул бик күп очрашуларда катнашкан, төрле конференцияләрдә чыгыш ясаган, бик күп яшь әдипләргә хәер-фатихасын кирәкле киңәшен әйткән остаз да. Аяз ага хатлар язарга яраткан. Ул бик күпләрнең яраткан остазы була. Бу стендта сез аның каләмдәшләре, фикердәшләре, чордашларының аның иҗаты, үзе турында да әйтелгән фикерләр белән таныша аласыз. Аның иҗаты үз бәясен алды.

**II. Сыйныф укучылары катнашында Аяз Гыйләҗевның “Дүртәү” хикәясен сәхнәләштерү.**

**IV.Аяз Гыйләҗевның тормыш юлы һәм иҗаты буенча тест эше үткәрү.**

1. Аяз Гыйләҗевнең әтисенең исеме язылган рәтне күрсәтегез:

а) Мияссәр ә) Мирсәет б) Миңлегали

2. Язучының мәктәп еллары кайда уза?

а) Зәй районында Югары Баграж авылында

ә) Балык Бистәсе районында Котлы Бөкәш авылында

б) Минзәлә районында Бикбау авылында

3. А.Гыйләҗев 10 нчы сыйныфны кайда тәмамлый

а) Сарман районы Сарман урта мәктәбендә

ә) Актаныш районы Актаныш урта мәктәбендә

б) Арча районы Арча урта мәктәбендә

4. Ул ... КДУга укырга керә.

а) 1946 нчы елда ә) 1948 нче елда б) 1945 нче елда

5. А.Гыйләҗевкә ... халык язучысы исеме бирелә.

а) 1991нче елда ә) 1994 нче елда б) 1993нче елда

**V.Йомгаклау**

**Укытучы.** Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең иҗаты халык күңеленә бик якын. Ул үзенең әсәрләрендә тормышның иң авырткан мәсьәләләрен чагылдыра. Аяз Гыйләҗев – кыю каләмле язучы. Аяз Гыйләҗевне җәмгыятьтә гаделлекнең булмавы, бәхетсез халыкның язмышы борчый. Ул татар милләтенең киләчәге өчен борчыла. Милләт өчен, гади халык өчен янып-көеп яшәгән әдипнең иҗатын онытмау, бу бөек шәхесне зурлау бездән тора.

Күренекле әдип,Татарстанның халык язучысы, Тукай һәм Исхакый исемендәге дәүләт бүләкләре иясе Аяз Гыйләҗевнең иҗаты – әдәбиятыбызның кыйммәтле бер өлеше. Аның бай иҗаты киләчәк буыннарга да хезмәт итәр, якты истәлеге халкыбыз күңелендә мәңге сакланыр.

Фахразиева Лилия Фәнүз кызы,
4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Әлмәт шәһәре

**Әдәбиятыбызның имән баганасы**
**(сыйныфтан тыш чара эшкәртмәсе)**

**Максат.** А.Гыйләҗев иҗатына күзәтү ясау. Геройлары белән таныштыру.Укучыларда А.Гыйләҗев иҗаты белән кызыксынуны үстерү. Гуманистик тәрбия бирү.

**Җиһазлау.** Презентация, китаплар күргәзмәсе, видеоматериаллар (спектакль һәм кинофильмнар), җырлар.

**Сәхнәдә Бибинур** (Бибинур образындагы укучы) ("Җомга көн кич белән") күренә. Ул Гайшә кабере янына килә: "Гайшә! Менә ни уйладым әле мин: миңа бу дөньяны кичеп сезнең янга килергә вакыт җитте бугай... Беләм, минем баш очыма берәү дә йолдыз кадамас, мин бик гади яшәдем, гомергә гади кеше булып калдым. Шулай да үкенмим, газапланмыйм, үз бурычымны үтәдем бугай. Беркем дә минем турыда яман сүз әйтә алмас. Беркем дә! Мин шулай уйлыйм, бәлки, хаталанамдыр... Синең алда да гаебем бардыр, Гайшә. Булмый калмас. Мин шулай уйлыйм. Шулай дип беләм. Шуңа синең катыңа киләм. Аңлашыйк, Гайшә.Кешеләр сөйли, күп сөйлиләр. Балалар мине ташлады дип, аларны гаеплиләр... Кем уйлаган дөньялар болайга әйләнеп китәр дип... Шулай да мин аларны гаепләмим. Рәнҗемим мин аларга! Ата йортын ташладылар, диләр. Имеш, менә ничә еллар инде хат та язмыйлар! Ярдәм дә итмиләр, имеш! Анысы да хак, Гайшә, тик мин ярдәмгә мохтаҗ түгел, Гайшә, мохтаҗ булмадым да..."

**"Бибинур" фильмыннан өзек күрсәтелә.**

**Сәхнәдә Мирвәли** (Мирвәли образындагы укучы) ("Өч аршин җир") күренә:

-Карачурага кайт дисең син... Шунда кал дисең, Шәмсегаян... Менә кайтып барабыз... Кайчан исә бу юлларны үтәрмен дә Карачурага кайтырмын дип һич уйламый идем инде мин. Күрәсеңме кич булды... Иртәгә көн чалт аяз булыр, боерган булса. Кояш бик кызарып, моңаеп баеды... Карачура... Хәтереңдәме, син авылның иң матур, иң сылу кызы идең... Мин Нөркәй ярминкәсенә киткәч, сине Түбән авыл егетләре урларга йөри икән дигән хәбәр ишеттерделәр. Шуны ишеткәч, әткәйнең акбүз айгырына менеп алдым да ярминкәне ташлап авылга чаптым! Ничек? Мирвәлидән узып кыз алыргамы?.. Булмы торсын әле... Дус егетләр белән Түбән авылларның тәҗе, камыт бауларын турап бетереп, үзләрен җир күмере ясап тукмап җибәргән идек без... Исеңдәме икән, икенче көнне син туганнарга, Имән урамына чыгып бара идең. Кулыңда бәләкәй генә төенчек, ярминкә күчтәнәче, имеш. Башыңда бөрчекле яулык, өстеңдә бәбәй итәкле яшел күлмәк иде... Безнең тыкрыкка җитүгә, мин сине күтәреп алып үзебезгә алып кергән идем... Син бер дә карышмаган идең, Шәмсегаян. Әткәм-әнкәм рәнҗер дип кенә үксеп-үксеп елаган идең...

**Укытучы.** Әйе, укучылар, без бүген татарның әдәби мирасына зур өлеш керткән язучы, усал телле тәнкыйтьче, милләтебез горурлыгы, әдәбиятыбыз тарихында эз калдыручы, сүз остасы, олпат язучы, шагыйрь, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Мөхәммәт Мирза (Илфак Ибраһимов) сүзләре белән әйтсәк: «Әдәбиятыбызның имән баганасы» булган Аяз ага Гыйләҗевкә багышланган әдәби-музыкаль кичәгә җыелдык.

**Илһам Шакиров башкаруында "Сарман буйларында" җыры яңгырый.**

**1 нче укучы**. Аяз Гыйләҗев – Илһам ага Шакиров, Клара апа Булатова, Гөлшат апа Зәйнәшева һәм башка шундый бик күп талантлы шәхесләрне биргән Сарман төбәгеннән.

Аяз Гыйләҗев – искиткеч талантлы һәм гаять үзенчәлекле әдипләребезнең берсе. Аның тормыш юлы бик гыйбрәтле. Хәзер аның турында тулырак сөйләп китәсем килә. 1928 елның 17 гыйнварында Сарман районындагы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә ул. Илебез өчен авыр елда – 1945 елда Сарман урта мәктәбен тәмамлый. Берникадәр вакыт авылда, районда эшли. 1948 елда Казан университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Үзенең хөр фикерлелеге аркасында, ул укуыннан куыла һәм ирегенннән мәхрүм ителә. Ул заманда да үз карашларын кыю һәм принципиаль яклаучыларны яратмаганнар. 1950 елның мартыннан 1955елның августына кадәр Аяз Гыйләҗев кыен сөргенлек шартларында ташчы, бетончы, бригадир һәм десятник булып эшли. Казанга әйләнеп кайткач, Аяз Гыйләҗев университетта укуын дәвам иттерүгә ирешә, аны уңышлы тәмамлап чыга. 1951-1961 елларда Аяз ага матбугат эшендә: “Чаян”, “Азат хатын”, “Совет әдәбияты” журналларында эшли. 1961-1963 елларда Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый, шуннан соң ул әдәби иҗат эше белән язучы-профессионал сыйфатында шөгыльләнә.

**Укытучы.** “Әтине эшкә Чукмарлы авылына җибәрәләр, әни бер-бер артлы өч малай табып өйдә утыра. Әтине, яшь мөгаллим дип, район читендәге Югары Баграж авылына укытырга җибәрәләр, авыл Зәй районы карамагына күчкәч тә безнең гаилә Багражда калган. Минем балачагым, яшьлегем әнә шул авылда, юмарт күңелле, кунакчыл, гади, үтә кешелекле, рыясыз-хәйләсез керәшеннәр арасында үтте. Олысы-кечесе безне хөрмәт итә иде. Көрәк сакаллы, абруйлы авыл агайлары әниемне яратып, гади укытучы хатынын зурлап “апа” дип эндәшәләр иде”, - дип искә ала А.Гыйләҗев “Балачак сукмаклары” дигән хатирәләрендә.

**2 нче укучы.** Аяз Гыйләҗевнең башлангыч иҗат тәҗрибәләре студентлык чорына карый. 1948 елны «Безнең хикәяләр» исемле җыентыкта яшь авторның «Ян, Учагым, ян!» исемле лирик рухтагы беренче хикәясе басылып чыга. Ләкин аның актив иҗат эшчәнлеге 1956 елдан гына башлана дияргә мөмкин. 1956-1960 еллар арасында «Чаян», «Азат хатын», «Ялкын», «Совет әдәбияты» журналларында, республика газеталарында язучы өч дистәгә якын хикәя, фельетон, мәкалә һәм үзенең беренче күләмле әсәрләреннән берсе – сугыш чоры авылы яшүсмерләре тормышына багышланган «Дүртәү» исемле повестен бастыра. Бер үк вакытта ул драматургиядә дә иҗади сәләтен күрсәтә. Татар дәүләт театры сәхнәсендә бер-бер артлы «Җиз кыңгырау» (1959), «Киек каз юлы» (1960), «Көзге ачы җилләрдә» (1961) исемле пьесалары куела. Матбугатта бераз соңрак – 1966 елда дөнья күргән һәм кеше язмышының катлаулы борылышларын шактый нечкә психологик детальләр, тормыш күренешләре аша тасвирлаган «Берәү» повесте да язылуы буенча әдипнең шушы чор иҗатына карый.

**3 нче укучы**. Беренче әсәрләреннән үк анык сиземләнгән язу манерасы – кырыс реализм, халыкчан образларга бай җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары, кайсы чор турында һәм нинди темага язса да, кеше шәхесенең катлаулы рухи дөньясын, эш-гамәлләрен заманның гуманистик идея-эстетик карашлары югарылыгыннан торып анализларга, аларны бүгенге чынбарлыктагы, җәмгыять үсеше процессындагы актуаль мәсьәләләр, социаль-әхлак проблемалары белән тыгыз бәйләнештә гәүдәләндерергә омтылу А. Гыйләҗев иҗат эшчәнлегенең төп асылын, идея-эстетик юнәлешен тәшкил иткән бу сыйфатлар әдипнең алтмышынчы-җитмешенче еллар да язылган проза әсәрләрендә аеруча калку чагыла. Ул үзен бигрәк тә повестьлар остасы итеп таныта. «Өч аршын җир», «Зәй энҗеләре», «Урталыкта», «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Мең чакрым юл», «Җомга көн, кич белән», «Әтәч менгән читәнгә»

(1979-1980) – әнә шуның мисаллары. «Җомга көн, кич белән» һәм «Әтәч менгән читәнгә» повестьлары өчен А. Гыйләҗев 1983 елда Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

**4 нче укучы.** Тематик яктан А. Гыйләҗевнең күпчелек повестьлары авыл тормышына багышланган. Аларда кичәге һәм бүгенге авыл, аның гади кешеләре гәүдәләндерелә, әхлак, тәрбия мәсьәләләре: мәхәббәт, гаилә, намус, вөҗдан каршында җаваплылык, яшәү максаты, яхшы белән яманның кеше күңелендә барган мәңгелек көрәше гыйбрәтле язмышлар, тирән конфликтлы, драматик вакыйгалар аша яктыртыла. Автор үзенең әсәрләрендә гади кешенең рухи бөеклегенә дан җырлый.

А. Гыйләҗевнең матбугат дөньясы, яшь журналистлар тормышы һәм хезмәте турында язылган «Урамнар артында яшел болын» исемле романында да мораль-этик мәсьәләләр үзенчәлекле чагылыш таба.

**“Яланаяклы кыз” телевизион фильмыннан өзек күрсәтелә.**

**5 нче укучы.** А.Гыйләҗев – ике дистәдән артык драма әсәре авторы. Аларның күбесе республика театрлары репертуарына кертелгән. Алтмышынчы-җитмешенче еллар дәвамында Татар дәүләт академия театры драматургның «Җиргә тапшырылган серләр», «Шамил Усманов», «Эңгер-меңгер», «Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз», «Хушыгыз, тургайлар»; Республика татар дәүләт драма һәм комедия театры: «Кара күзле кызлар», «Шомырт чәчәк атканда», «Кичке эңгәмәләр», «Сары чәчәк ата көнбагыш», «Шикәрем син, балым син», «Ефәк баулы былбыл кош»; Әлмәт татар дәүләт театры: «Яланаяклы кыз», «Җан җылысы», «Әгәр бик сагынсаң», «Әткәй җырлый да, елый да», «Кар астында кайнар чишмә» кебек пьесаларын сәхнәләштерә. Республика татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә «Сары чәчәк ата көнбагыш» пьесасы буенча куелган спектакль өчен театрның баш режиссеры Р. Тумашев 1976 елда Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнә. Драматургның кайбер пьесалары башкорт, авар, чуваш милли театрлары, рус театры сәхнәләрендә куела, «Җиз кыңгырау», «Югалган бер көн», «Өч аршын җир» (шул исемдәге повесть буенча инсценировка), «Эңгер-меңгер» исемле пьесалары исә, рус теленә тәрҗемә ителеп, Мәскәүдә «Советская драматургия» альманахында һәм күмәк җыентыкларда басылып чыга. «Югалган бер көн» пьесасы 1977 елда Чехословакиядә словак телендә дә дөнья күрә.

**Укытучы.** Әлмәт дәүләт драма һәм комедия театры тарафыннан 72 нче сәхнә сезонында «Кар астында кайнар чишмә» әсәре кабат сәхнәгә менде.

**«Кар астында кайнар чишмә» спектакленнән өзек күрсәтелә**

**1 нче укучы.** Аяз Гыйләҗевнең күпчелек әсәрләрендә сугыштан соңгы авыл тормышы сурәтләнә. Автор заман авырлыгын күтәрүче авыл халкының язмышы өчен үтә дә борчылып яза. “Дүртәү” исемле повестенда әдипнең тоталитар система урлап калган биш еллык фаҗигале гомере һәм шул хәлне аңлауга, бәяләүгә киткән берничә еллык шәхси тәҗрибәсе ята.

Вакыйга сугыш елында бара. Авылның тотнаклары унөч яшьлек дүрт егете - Әкмәл, Барый, Вакыйф, Ибраһим район үзәгенә олаулар белән ашлык илтәләр. Рәхәтләнеп чыр-чу килеп уйнарга тиешле балалар авылның ныклы ир-атларына әйләнәләр һәм бөтен авырлыкны үз җилкәләренә күтәрәләр. Көне-төне яңгыр яуганга, амбардагы ашлык та кыза башлаган. Аяк асты боламыкка әйләнгән, көннең караңгылыгыннан авыл күренми. Автор безгә сугыш дәһшәтен, кешеләр өстенә килгән фаҗигане күрсәтә.

Унөч яшьлек әлеге дүрт егет бала гына булсалар да, зурларча фикер йөртәләр. Аларга зур бурыч йөкләнгән. Шул бурычны үтәп чыгу – зур горурлык. Сугышта ятып

калган туганнары, фашистларның ояларын туздыручы әтиләре, абыйлары өчен алар колхозның бөтен эшләрен эшләргә дә әзерләр. Әтиләре батырлыкны фронтта күрсәтсәләр, алар монда батырлык эшлиләр.Үзләрен колхозның хуҗалары итеп тоюлары белән алар туган илгә булган мәхәббәтләрен күрсәтәләр.

**2 нче укучы.** Сугыш чорында үскән яшүсмерләрнең тормышын кырыс буяулар белән күрсәткә әсәрләрнең тагын берсе – "Язгы кәрваннар" повесте. Бу повестьның сюжеты чәчүлек симәнә орлыгы алып кайту белән бәйле. Монда саф мәхәббәт тә, авыл кешесенең югары әхлагы, намусы да ачыграк сизелә, язучының әйтергә теләгән фикере дә үткен хәнҗәр кебек күренеп тора.

Язучы әсәрдә авыл халкының гүзәл әхлак сыйфатларын да күрсәтә, шул ук вакытта шул яхшы кешеләрнең начар шартларда яшәү сәбәбен дә ачыкларга тырыша. Аеруча яратып Әдилә образын иҗат итә. Әдилә апасы үлгәч, җизнәсе янына кайтып, ятим балаларны тәрбияли. Аның турында җизнәсенә кияүгә чыга икән дигән сүзләр дә йөри. Ләкин кыз күңеле аны кабул итми.

Аяз Гыйләҗев әсәрнең азагында авыл кешесенең мәшәкатьле тормыш сәбәпләрен ачыклый. Район җитәкчеләренең мәгънәсез юлга куулары нигә кирәк булды икән, дөрестән дә. Бәлки үзләренең көчлелекләрен күрсәтү, үзләрен шәхес итеп таныту өчен. Автор ил өстенә килгән фаҗиганең, заман авырлыының кеше тормышында чагылуын күрсәтә. Илгә килгән афәт бер генә кешене дә читләтеп үтмәгән.

**3 нче укучы.** Аяз Гыйләҗев сугыш чорында чыннан да булган хәлләрне, яз-көз җитсә, бер авылдан икенче авылга мәгънәсез йөк ташулар, спекулянтларның рәхәтләнеп сату-алу итеп йөрүләрен сурәтләп, ил фаҗигасен тагын да катлауландырган сәбәпләрне күрсәтә. Шундый ук фикерне аның 1973 нче елда язылган "Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят" повестенда күрергә мөмкин. Автор монда авылда совет кешесе арасында бара торган көрәшне, икейөзлелекне күрсәтә. Шуңа күрә дә ул геройларны ике төркемгә бүлеп карый. Ләкин бу төркемгә кергән һәр образның үзенчәлеге бар. Бер төркемдә тыйнак һәм саф күңелле Арзу, тырыш Рәфгать, Искәндәр, күп еллар колхозда рәис булып хезмәт итеп ял итүче Хәбибрахман карт булса, икенчесендә тиз коткыга бирелүче Сирай, сигез балалы гайбәтче Мәүлиха һәм чулак Гыйбадулла.

Әсәрдә без кешеләр язмышын сугыш китергән фаҗигага бәйләп карадык. Чыннан да, бу әсәрдә кешеләрнең авыр тормышына китергән сәбәп – сугыш икәнлеге күренә.

**Түбән Кама Татар дәүләт драма театры тарафыннан сәхнәләштерелгән "Яра" спектакленнән өзек күрсәтелә.**

**4 нче укучы.** Аяз Гыйләҗевне һәрвакыт гади колхозчы язмышы, крестьян тормышы кызыксындырып һәм уйландырып торган, аның авыр хәле борчуга салган. Автор үзе җирне яратучы кеше буларак авыл яшьләренең җир белән аралары ераклашуга тирән көрсенә һәм моның сәбәбен ачыкларга тели.

"Качак" повестенда сүз авылдан китәргә җыенучы Тәнзилә турында бара. Шушы ук хәл "Берәү" повестенда Исхакта күзәтелә. Ләкин сюжет сызыгы икесендә ике төрле үсә. Бер төрлерәк характердагы кешеләрнең язмышлары төрлечәрәк килеп чыга. Бу әсәрләрнең сюжетлары катлаулы түгел. Ике әсәрдә дә игенчеләр, колхозчылар тормышы сурәтләнә. Бу әсәрләрдәге ике герой авыл тормышыннан канәгать түгелләр. Чөнки авылда яшәү рәхәт түгел. Крестьян авылга бәйләп куелган. Ул бернинди ял күрми, рәхәт күрми, туйганчы ипи ашый алмый. Эш тә эш. Качак – бу исем Тәнзиләгә адреслап әйтелгән әлбәттә, чөнки ул колхоздан качып китеп бара. Ничек качып китсә, шулай ук шәһәрдән дә качып кайтып җитә.

**5 нче укучы.** Инде “Берәү” повестына килсәк, “Ни өчен яшьләр авылдан китә?” дигән сорауга җавап табасы килә. Бу сорау авылның киләчәген кайгыртып һәм авыл халкының язмышларын күреп борчылганнан соң туа. Әсәрнең төп герое – Исхак. Ул кечкенәдән авылны яратып, үз итеп үсә. Алдагы тормышын авыл белән бәйләр өчен авыл хуҗалыгы институтына укырга керә һәм бик яхшы укый. Эшкә ул зур дәрт һәм зур кызыксыну белән тотына. Ләкин егетнең йөрәгендә җир хуҗасы булу хисе сүнә. Колхоз рәисенең эшчеләргә колларга караган кебек каравы, аны авылны ташлап чыгып китәргә мәҗбүр итә. Җәмгыятьнең  нигезендә ныклы таяныч булмаганга күрә, тоталитар системага колларча буйсынган авылдашларының пассивлыгына һәм алар ягыннан ярдәм килмәгәнгә күрә шәһәргә китеп, үзе өчен яңа мохитта яши башлый.

**Асылъяр башкаруында “Сөю хакына” җыры яңгырый (“Яланаяклы кыз” фильмыннан)**

**Укытучы.** А.Гыйләҗев иҗатында Галимҗан һәм Хәбибрахман карт, Шәмсегаян һәм Бибинур карчык кебек саф күңелле, намуслы, тырыш, уңган хезмәт кешеләренә күп урын бирә.

**1 нче укучы.** Халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәрендә дә Бөек Ватан сугышы чорында халыкның язмышы, көнкүреше сурәтләнә. “Язгы кәрваннар” әсәренең төп темасы булып, сугыш чоры авылы кешеләренең, аеруча яшьләрнең яшәешен сурәтләү тора. Әдипнең максаты – шул чордагы тыл каһарманнарының батырлыгын укучыга җиткерү. Хәзерге буын, якты дөньяда яшәве белән сугыш чоры каһарманнарына һәм ул елларның авыр йөген җигелеп тарткан ил кызларына бурычлы булуын онытмаска тиешлеген искәртү.

Повестьта сугыш чорында эшне төптән җигелеп тарткан Хәкимҗан абзый, Сабирәттәйләргә алмашка үсеп килүче, шулай ук бик яшьли тормыш арбасына җигелгән Ибраһим, Дамир, Әдиләләр яшәеше сурәтләнә.

Аяз Гыйләҗевнең “Ефәк баулы былбыл кош” спектакленнән өзек күрсәтелә.

**2 нче укучы**. “Күпләр иҗатларын тәхеткә баскыч итеп кабул иттеләр һәм хәзер дә шулай яшиләр. Мин үзем беркайчан да нindидер мөнбәрләргә үрелмәдем дә, аңа омтылмадым да. Хакимиятнең никадәр куркыныч көч икәнен бик күптән аңладым. Шулай булмаса, төрмәгә дә керми идем һәм баштан кичкәннәрем хакында документаль әсәр дә язмый идем. Төрмә минем өчен зур бәхет булды. Ул миңа тормышның нәрсә икәнен аңлатты”, - дип яза Аяз ага Гыйләҗев.

Аяз Гыйләҗевнең туксанынчы еллар башында язып тәмамлаган һәм тәүге тапкыр 1993 елда «Казан утлары» журналында дөнья күргән, сәяси тоткынлыкта үткәргән алты елга якын гомеренә багышланган «Йәгез, бер дога!» исемле романы рус теленә Татарстанның беренче президенты, бүгенге көндә дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев тәкъдиме белән тәрҗемә ителгән.

**3 нче укучы.** Бу әсәрнең бер героеның прототибы  Арпад Галгоци  болай дип искә ала: “Төрмәдә Аяз Гыйләҗевне яхшы хәтерлим. Таңга кадәр сөйләшә идек, ул миңа – үзенең милләте, ә мин аңа үзебез турында сөйли идем. Төрмәдә төрле кешеләрне очраттык, явызлыкның да, мәрхәмәтлелекнең дә шаһиты булырга туры килде. Әмма тоткыннар арасында үз милләтенең асыл уллары күп иде. Арабызда төрле милләт вәкилләре бар иде: алман, поляк, япон, кытай, латыш... Үзем ике татар егете белән якыннан аралаштым, аларның берсе – Аяз. Безне өмет яшәтте, кайчан да булса моннан чыгачагыбызга ышандык. Сөйләшү, аралашу, фикерләш безгә сынмаска ярдәм итте, көч бирде”. Романны Арпад Галгоци венгр теленә тәрҗемә итә.

Әсәрне русчага тәрҗемә иткән Татарстан язучылар берлеге әгъзасы Наил Ишмөхәммәтов "Йәгез, бер дога!" романының гаять мөһим үзенчәлегенә, аның нигезенә салынган фикергә игътибарны юнәлтә. “Аяз Гыйләҗев белән бергә күпме намуслы кешеләр утырган – алар тәвәккәл дә, батыр йөрәкле дә, үз сүзе һәм эшенә тугры да булган. Аларның күпчелеге кеше каны белән тапланмаган. Әмма берәүне дә аерып тормыйча, барысын бергә – яшүсмерләрдән алып картларга кадәр – утырткannar да куйганнар. Аяз Гыйләҗев безне бар кешене дә кара буяу белән тамгаламаска өйрәтә. Кемдер үз саласында сатлык җан булган өчен башкалар җавап бирмәскә тиеш дигән фикерне яңгырата”, - дип ассызыклап әйтә ул.

**4 нче укучы.** Әйе, “торгынлык” чоры дип аталган елларда кешенең кемлеге эшли белүе түгел, яши белүе белән билгеләнә иде. “Яши белү” тегесенә дә, бусына да оста җайлашуны аңлата. Түрә – үзеннән кечерәкләргә хан да, хөкемдар да. Бу “Балта кем кулында?” романында бик гыйбрәтле гәүдәләнгән. Романда заманыбызның асылын аңларга тырышучы геройларның тирән уйланулары табигый урын ала. Менә Фәридун Фазлыев исемле кешенең яшәү мәгънәсе турында фикерләре. Алар кешенең усал табигатьле булып үзгәрә баруына иҗтимагый аңның дөрес юнәлештә тәрбияләнмәгәнлеге сәбәпче икәнен төшендерә.

**Укытучы.** “Кеше яши икән,бәхет татыр өчен яши“,- дип яза А.Гыйләҗев.Ул үзен бик бәхетле кеше дип санаган.Чөнки аның яраткан хатыны Нәкыя ханым, уллары – Искәндәр, Мансур, Рашат һәм оныклары аңа иҗат итү өчен көч, дәрт биреп торганнар. “Малайлары белән горурланды Аяз. Очар кошлар үз балаларын очарга өйрәткән шикелле, тормышта югалып калмаска, кешеләр арасында кеше булырга өйрәтте ул. Искәндәр карап торырга юаш булып күренә. Ләкин ул юашлык түгел, сабырлык. Белеме – төпле. Бик яшь килеш галим булды, бүген ул фәннәр докторы, Казан дәүләт университетының факультет җитәкчесе. Мансур – Аязның уртанчысы. Ул, әтисе юлыннан китеп, әдәбият дөньясында яши. Шактый драма әсәрләре язып, алар күп театрларда уңыш белән баралар. Аязның төпчеге – бәләкәче – Рашат, бизнес белән шөгыльләнә”, - дип язган иде Туфан ага Миңнуллин аның уллары турында.

**5 нче укучы**. Аяз Гыйләҗев иҗаты белән төрек укучысын таныштырган Фатих Котлу татар әдәбияты классигын үз остазы дип атый. Ул язучы белән 2000 елның апрелендә таныша. Сөйләшү вакытында Фатих Котлу Аяз Гыйләҗевка кайсы әсәрен төрек теленә тәрҗемә ителүен теләр идең дигән сорау биргән. Аяз Гыйләҗев: “Өч аршын җир” әсәре”,- дип җавап кайтарган. 2002 елда язучы вафат була. Фатих Котлу аның 2000 елда җиткерелгән теләген васыять итеп кабул итә һәм тәрҗемә эшенә тотына.

“Тәрҗемәгә ике ел таләп ителде. Тәрҗемә эше зур авырлыклар белән барды. Аяз абыйның теле, сүзләре, аның фәлсәфәсе шул кадәр тирән – аңа алыну зур батырчылык булуын шул чакта гына аңладым...”

Шуннан Фатих Котлу “Җомга көн кич белән” әсәрен тәрҗемә итәргә алына. Ул 2013 елда нәшер ителә. “Аяз Гыйләҗев фән, әдәбият өлкәсендә танылсын өчен аның ике әсәре генә җитми. Шуңа да мин аның унбер әсәрен тәрҗемә итмичә туктамаска булдым. Бүгенге көндә “Язгы кәрваннар”ның тәрҗемәсе әзер. Хәзерге вакытта чиратта “Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят”. Ул да ел азагына кадәр төгәлләнер дип ниятлим. Киләчәктә мине Аяз Гыйләҗевне төрки дөньяда таныткан шәхес буларак телгә алсалар, бу минем өчен иң зур бәхет”, - ди Фатих Котлу.

Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, тәрҗемәче Фатих Котлу туган иле Төркиягә барып кайткач, бер күңелле хәбәр җиткерә. Истанбулның Фатих университеты

филология факультетының төрки телләр бүлеге доценты Абдүлкадир Чәкич классик әдибебез Аяз Гыйләҗев әсәрләрен үзенең диссертация темасы итеп алып, аларны өйрәнә башлаган икән.

**1 нче укучы.**“...сәфәрдә йөргәндә, бер татар академигын очраттым. Ул миңа Аяз Гыйләҗевне укырга тәкъдим итте. Өйгә кайту белән әдип турында мәгълүмат туплый башладым, тәэсирләрем гел уңай булды. Әлбәттә, язучының татар халкы тарафыннан яратып укыла торган һәм югары бәяләнгән “Өч аршын җир”, “Җомга көн кич белән” кебек әсәрләре төрек теленә дә тәрҗемә ителүен белдем. Укый торгач, Аяз Гыйләҗевнең фәнни эш өчен үзем теләгән язучы икәнен аңладым. Миләүшә Хәбетдинова һәм Гүзәл Сәгыйтованың язучының иҗаты турындагы академик мәкаләләрен уку фикеремне тагын да ныгытты. Диссертация темасы итеп татар язучысы Аяз Гыйләҗевне сайлавым белән җитәкчем дә килеште”, - ди Абдүлкадир Чәкич.

**2 нче укучы.** А.Гыйләҗев әсәрләре сезне нәрсәсе белән җәлеп итте? дигән сорауга яшь төрек галиме болай җавап бирә:

- Мин игътибар иткән элементларның берсе – иҗатта персонаж алга куела. Вакыйга, сюжетка караганда, күбрәк герой тирәсендә формалаша. Бу – Аяз Гыйләҗевнең әдәби стиленең уңышлы алымы. Тагын да әһәмиятлерәге – метафоралар. Әйтик, “Өч аршын җир”дә һәм “Җомга көн кич белән”дә зират хәтерне гәүдәләндерә (символлаштыра). Зират бетмәсә, үткәннәре бездә мәңгелек булачак. Шуңа күрәдер, “Өч аршын җир”дә Шәмсегаянның үз туган җирендә җирләнәсе килә. Ә “Җомга көн кич белән”дә Җиһангир Ташлыярга килүбелән зиратны төзекләндерергә керешә. Ике китапта да символик элементлар бар.

Үз фикерләрен дәвам иттереп, Абдүлкадир Чәкич болай ди: “Ә менә үз ана телендә иҗат иткән Аяз Гыйләҗев үз идеяләренә тиешле игътибарны җәлеп иттерә алмаган. Әмма аның әсәрләре шундый ук югары дәрәҗәдә булган. Мин аның академик тикшеренүләрдән һәм әсәрләрен төрле телләргә тәрҗемә иткәннән соң, тиешле игътибарга ирешүенә ышанам”.

**Укытучы.** Әйе, Татарстанда Миләүшә Хәбетдинова, Гүзәл Сәгыйтова кебек хөрмәтле галимәләр Аяз Гыйләҗев иҗатын бик җентекләп өйрәнеп, фәнни хезмәтләр яза. Фатих Котлу да әдипнең иҗаты һәм тормышы турында яхшы белә. Шулай да, Аяз Гыйләҗевның әдәбияттагы урыны ачык билгеләнсә дә, иҗади мирасы әле чын-чынлап, тирән итеп өйрәнелмәгән. Моның сәбәбе бик гади: аның әсәрләре әзер кысаларга, кабул ителгән концепцияләргә сыеп бетми. Аның проза, драматургия, публицистика, әдәби тәнкыйть өлкәләренә керткән яңалыгын, иҗади ачышларын бәяләү, аңлау һәм аңлату киләчәк буын тәнкыйтьчеләре бурычы булып кала бирә.

**3 нче укучы**.“Мин милләттәшләремдә, җирдәшләремдә, замандашларымда әле сүнеп бетмәгән, заманның явыз тизлеге белән капланып өлгергән Туган илгә мәхәббәтне кайтарырга телим”, - дип язган Аяз Гыйләҗевнең, татар теле кыл өстендә торган бүгенге көндә, тел турында язып калдырган сүзләр бигрәк тә актуаль яңгырый. Менә аларның берничәсе:

- Иң беренче – үз телеңне камил бел! Аңа зур хөрмәт белән кара, башкаларны шуңа өйрәт. Онытма: Синең Телең дөньядагы иң камил, иң бөек ундүрт телнең берсе. Телеңнән йөз чөергәннең – теле көяр!

- Милли хисең турында кычкырып йөрмә, эчеңдә тот! Аны эштә күрсәт, гомерең буе йөрәгеңдә сакла, күңелеңдә үстер, җаныңда тот. Күп сөйләшми генә зур эшләр башкар, әмма әйткәнеңне һәрвакыт: “Мин әйттем!”- диң. Безнең бабайлар-бөек ханнар

шулай дигәннәр. Үзеңне һәрчак татар морзасы яисә ханы итеп той. Онытма: һәр татар үз эшендә хан булырга яратылган!! Татар булуың белән мактанма. Әмма, Горурлан!!!

- Без – татарлар юаш, басылган халык. "Уянабыз, уяндык!" – бер гасыр буена үз-үзебезне алдап юанабыз. Татар халкы дөнья йөзендә үз миссиясен үтәп соңгы сулышын алып ятмыймы? (“Ватаным Татарсан” 1995 нче ел, 24 нче март)

- Татар әдәбиятының киләчәге татар халкының һәм татар теленең язмышы белән бәйле.

**4 нче укучы.** А. Гыйләҗев1983 нче елда Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә. 1978 нче елда Татарстанның, ә 1985 нче елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә. Ул М.Горький исемендәге премия лауреаты да. 1994 нче елда А.Гыйләҗев Татарстанның халык язучысы дигән исемгә лаек була.

**Укытучы.** Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең иҗаты халык күңеленә бик якын. Ул үзенең әсәрләрендә тормышның иң авырткан мәсьәләләрен чагылдыра. Илдә барган сәяси ялгышларны, курыкмыйча, әсәрләре аша тәнкыйть итә. Нәтиҗә ясап шуны әйтәсем килә: Аяз Гыйләҗев – кыю каләмле язучы. Ул хөкүмәт тарафыннан җибәрелгән хаталарны яшерми, әсәрләре аша искәртә, җитди сәяси һәм милли проблемаларны укучы алдына куя. Аяз Гыйләҗевне җәмгыятьтә гаделлекнең булмавы, бәхетсез халыкның язмышы борчый. Ул татар милләтенең киләчәге өчен борчыла. Бер әңгәмәсендә ул Әзһәр Шакировка болай ди: “Мин язуын яздым, менә шуларны укырлык татар кешесе булырмы? Менә нәрсә борчый мине”.

Безнең бүгенге кичәбез Аяз абый Гыйләҗевның рухына шатлык иңдерсен. Ә сез, укучылар, А.Гыйләҗев турында белемнәрегезне киңәйткәнсездер, әдибебезнең әсәрләре сездә кызыксыну тудыргандыр дип өметләнеп калам.

Милләт өчен, гади халык өчен янып-көеп яшәгән әдипнең иҗатын онытмау, бу бөек шәхесне зурлау бездән тора. Күренекле әдип,Татарстанның халык язучысы, Тукай һәм Исхакый исемендәге дәүләт бүләкләре иясе Аяз Гыйләҗевнең иҗаты әдәбиятыбызның кыйммәтле бер өлеше. Аның бай иҗаты киләчәк буыннарга да хезмәт итәр,якты истәлеге халкыбыз күңелендә мәңге сакланыр. Ул безнең әдәбиятыбызның имән баганасы булды һәм шулай булып калачак та. (Аяз Гыйләҗев иҗатына багышланган видеоматериал күрсәтелә).

Нуретдинова Айгуль Гамирзяновна, “Джалильская СОШ №2”; Сармановский район,
Валиахметова Заря Азатовна,"СОШ №16", г.Альметьевск

**Аяз Гилязов – писатель жизни татарского народа**

Цели: раскрыть жизненный и творческий путь Аяза Гилязова. Приобщать детей к ценностям межличностных отношений. Воспитывать любовь к Родине, родному краю, к культуре и традициям своего народа через творчество писателя. Воспитать у учащихся такие качества, как добро и милосердие, отзывчивость и вежливость, чуткость и внимательность

Задачи: содействовать формированию УУД.

1.Личностных: способствовать полноценному восприятию изучаемого материала, умению выражать свои мысли, выработке позитивной самооценки, положительное отношение к занятиям.

2.Регулятивных: Учить оценивать правильность выполнения своих действий, вносить необходимые коррективы, принимать позиции слушателя, читателя в соответствии с поставленной задачей.

3.Познавательных: развивать способность к познанию, выполнять несложные логические действия, работать с информацией, формировать исследовательские умения.

4. Коммуникативных: использовать доступные речевые средства для передачи своего впечатления, понимать содержание материала, уважать мнение собеседников, проявлять интерес к излагаемой информации, учить работать в группах, коллективно.

Материалы и оборудование: портрет Аяза Гилязова, произведения писателя.

План проведения:

-Организационный момент;

-вступительное слово учителя;

-знакомство с новым материалом;

-групповая работа: информация учащихся;

-беседа;

-подведение итогов.

Ход мероприятия.

I. Орг. момент.

II. Вступительное слово учителя.

Учитель: Добрый день дорогие дети! Есть на красивейшей планете Земля удивительная страна. Самая большая страна в мире! Это – Россия. И есть в этой стране замечательная республика, которая называется Татарстан. Ребята, назовите столицу Татарстана (ответы детей).

Учитель: Правильно Казань!

В городе огромном, среди сотен школ

Есть одна, в которую учиться ты пришел.

Есть одна, в которой жить нам всем, друзья.

Есть одна такая. Без нее нельзя.

Это наша Джалильская школа №2.

Учитель: А теперь я хочу проверить, хорошо ли вы знаете свой район и его историю.

Вы должны ответить на мои вопросы:

- Как наш район называется? (Сармановский)

- Кто является президентом нашей республики? (Минниханов Рустам Нургалиевич)

- Как называется главная улица столицы? (улица Баумана).

- Какие еще улицы Казани вы можете назвать? (Сафиуллина, Кутуя, Чуйкова, Габишева, Аяза Гилязова и другие)

Учитель: Хорошо. Среди названных улиц есть улица Аяза Гилязова. Кто из вас знает, кто такой Аяз Гилязов? (ответы детей).

А теперь внимательно посмотрите на доску, прочитайте тему нашего классного часа (читают хором).

III. Знакомство с новым материалом.

Сегодня наша встреча посвящена памяти народного писателя Республики Татарстан Аяза Гилязова. Группа ребят подготовила информацию о творчестве писателя.

Ученик. Аяз Гилязов родился 17 января 1928 года в селе Чукмарлы (ныне Татарстан) в семье учителя. Детство провёл в деревне Верхний Баграж (Заинский район).

Получил неполное среднее образование в местной школе. Вернулся в родной район, где закончил Сармановскую среднюю школу.

Ученик. В 1948 году поступил в Казанский государственный университет, где ранее учились Владимир Ульянов-Ленин, Л. Н. Толстой, С. Т. Аксаков, П. И. Мельников-Печерский. В 1950 году был арестован и сослан в карагандинский лагерь, где содержались даже лауреаты Сталинских премий. Там Гилязов находился пять лет. В 1955 году был реабилитирован.

Ученик. Писать Аяз Гилязов начал ещё в университете. Активно стал заниматься литературной деятельностью после освобождения из лагерей. Он публиковал в журналах рассказы, очерки, фельетоны, статьи. В 1958 году написал Аяз написал свою первую повесть «Их было четверо». Начиная с 1950-х годов его пьесы стали появляться на сцене театра рядом с произведениями его современников Х. Вахитова, Ш. Хусаинова, И. Юзеева, Д. Валеева, Т. Минуллина, Н. Фаттаха.

Ученик. Прославившим его жанром стали повести, в которых он затрагивал острые проблемы современности. Одна за другой вышли «Три аршина земли», «Жемчужина Зая», «В середине», «Весенние караваны», «Любовь и ненависть». Произведения Гилязова отличаются удивительно ярким, мелодичным и естественным языком написания.

Ученик. Откликаясь на социальные проблемы, вставшие перед татарским народом в 1980х, остро почувствовав гибель своих исторических корней в процессе урбанизации, Аяз Гилязов, а также его соратники на литературном поприще Мухаммад Магдеев, Вакиф Нуруллин, Рафаэль Тухватуллин, продолжили разрабатывать в своём творчестве деревенскую прозу.

В повести «Взлетел петух на плетень» Гилязов снова исследует духовное состояние современной татарской деревни, подчёркивая своеобразие национальной психологии и с горечью осознавая, что корысть, зависть, жадность, погоня за материальными благами проникли и в жизнь деревни и сознание её жителей.

Учитель. Кому посвящены эти произведения? (Ответы детей)

Учитель. Аяз Гилязов скончался 13 марта 2002 года. Аяз Мирсаидович Гилязов похоронен на Старотатарском кладбище Казани. В заключение беседы прошу вас ответить на вопрос: Какие произведения Аяза Гилязова вы знаете? («В пятницу вечером», «Три аршина земли», «Взлетел петух на плетень»).

Учитель. Я очень хочу, чтобы всегда в нашей республике был мир и покой, чтобы веротерпимость и уважительное отношение к представителям другой веры, национальности и культуры у нас стали нормами жизни. Чтобы вы, дети, выросли умными и здоровыми. Чтобы сбылись все ваши мечты и также как Аяз Гилязов, каждый в своем деле, прославил Татарсстан. А сейчас, ребята, ваша главная задача – хорошо учиться.

IV. Итог занятия.

Рефлексия.

- Ребята, вам понравился классный час?
- Что нового вы узнали сегодня?
- Вас заинтересовало творчество Аяза Гилязова?

Учитель. А теперь, дорогие дети, заканчивая классный час, хочется сказать большое спасибо всем и выразить надежду, что он помог нам больше узнать о замечательном татарском писателе Аязе Гилязове. Закончить наше мероприятие хочу словами дагестанского поэта Расула Гамзатова:

«Мне хотелось сказать и взрослым, и детям, всем школьникам – пусть наши имена, наши песни, наша честь, наши доблесть и мужество не уйдут в землю, в небытие, а останутся назиданием для будущих поколений. Пусть добрые люди пребывают в добре, а плохие станут хорошими».

- Вы согласны с высказыванием поэта Расула Гамзатова? Спасибо всем за участие в нашем классном часе!

Михайлова Әлфия Мостафа кызы,
Ләке төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**"Татар әдәбиятының имән баганасы - Аяз Гыйләҗев"
темасы буенча башлангыч сыйныф укучылары өчен класс сәгате эшкәртмәсе**

**Максат:** Аяз Гыйләҗев иҗаты белән таныштыру; китаптан дөрес файдалану кагыйдәләрен искә төшерү. Күренекле шәхесләр белән горурлану, аларны ихтирам итү хисе тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Аяз Гыйләҗевнең китапларыннан күргәзмә, тест үткәрү өчен карточкалар, кешенең төрле хисләрен аңлатучы рәсемнәр, презентация, "КОНЭРС" өчен портретлар һәм язучы-шагыйрьләр турында мәгълүматлар язылган карточкалар

**Сыйныф сәгатен үткәрү планы:**

1. Кереш әңгәмә.

2.Китап белән файдалану кагыйдәләрен искә төшерү.

3.Уку мәсьәләсен кую – "КОНЭРС"

4. Уку мәсьәләсен чишү – Аяз Гыйләҗев иҗаты белән танышу. (Китапханәченең китап күргәзмәсе буенча эше)

5.“Муйнак” хикәясе өстендә эш.

6.Рефлексия. Тест чишү һәм слайд буенча үз-үзеңне тикшерү.

7. Йомгаклау Өй эше бирү.

**Сыйныф сәгатенең барышы**

**1 Кереш әңгәмә.**

1.Китап турында табышмак әйтү:

Агач түгел - яфраклы, тун түгел - тегелгән, кеше түгел - сөйли. Ул нәрсә?

2.Сорауларга җавап бирү:

Кем китап укырга ярата? Ни өчен? Китап булмаса, нәрсә булыр иде? Сез китапларны каян аласыз?

3. Мәкальләрне ничек аңлыйсыз: Китап – тормыш көзгесе. Китап – галим, телсез мөгаллим. Китапсыз йорт – кояшсыз көн. Китап язмышы – халык язмышы.

4. Нинди китаплар була? (Әдәби китаплар, дәреслек, Кызыл китап, Хәтер китабы, сүзлекләр һ. б.)

**2. Китаптан файдалану кагыйдәләрен искә төшерү**

1. Китаплар чирләргә мөмкинме? ( җаваплар тыңлана -нинди очракларда һәм аны ничек дәваларга)

1 укучы Х.Халиковның “Китап докторы” шигырен сөйли.

Әбиләр дә авырый,
Бәбиләр дә авырый.
Салкын тисә аз гына
Тотам шуңа сак кына,
Авырдымы чак кына,
Чирен шундук күрәм мин,

Дару кирәк барсына. Чарасын да беләм мин.
Чирли хәтта китап та. Китапларың чирләсә,
Ник көләсең? Чынлап та! Үз кулыңнан килмәсә,
Бите төшә, ертыла – Миңа китер туп-туры,
Ул бит көн дә тотыла. Мин – аларның докторы

2. Сингапур структураларыннан “ТЭЙК ОФ – ТАЧ ДАУН”структурасы буенча эш (уңай җаваплар булганда укучылар басалар һәм кул чабалар)

1. Кем соң тоткан кулына чиста, тышланган китап(+)

2.Аның китапларында юк пычрак. Юк бер тап.(+)

3. Аның китабы эчендә ята ручка, карандаш (-)

4. Монысы китап укый, авызына каба аш.(-)

5. Бөгәрләмә битләрен дип, ул өйрәтә энесен(-)

6. Кил инде , укы инде, дип, аптырата әнисен.(-)

7. Чиста кулы белән ача тотып китап битләрен (+)

8.Ә бу малай ертып алган татар теле битләрен.(-)

9. Китап тотып теннис уйный, бу тагын нинди бала?(-)

10 Походка барган чакта да ул һәрчак китап ала.(+)

11.Китапны шкаф эчендә саклый икән бу бала.(+)

12 Ә монысы эзли китап, тик таба гына алмый. ( - )

13. Бусы хәтта тузанын да сөртә икән китапның.(+)

Кем икән аны өйрәтте яратырга китапны?

3. “Китап” (И. Гайфетдинов) җырын башкару.

**3. Уку мәсьәләсен кую**

1). Кайсы авторларның китапларын яратып укыйсыз?

– Безнең Татарстаныбыздан нинди язучы, шагыйрьләрне беләсез?

2). Якташ шагыйрь, язучылардан кемнәрне атый аласыз? (Дамир Гарифуллин, Ямаш Игәнәй, Әзһәр Габиди)

3). Сингапурның "КОНЭРС" структурасы буенча эш Кем турында сүз бара, шул язучы я шагыйрьнең портреты куелган почмакны сайларга.

1.Татар халкының бөек улы, герой шагыйрь 1906 елның 15 февралендә элекке Оренбург губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе Шарлык районы) Мостафа авылында крестьян гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга килә. 1913 елда аның әтисе Мостафа абзый, ишле гаиләсен ияртеп, Оренбург шәһәренә күчә һәм вак-төяк сату эшләре белән шөгыльләнә башлый. (Муса Җәлил).2. Түбәндәге юллар кемгә багышлана? Ул – безнең якташ шагыйребез. 1981 елда аның «Сәфәр чыгам» исемле беренче җыентыгы чыга. 1983 елда шагыйрьнең кече яшьтәге балалар өчен «Йолдыз булып ян» һәм 1984 елда «Хәзинәләр иле» исемле китаплары басыла. 1987 елда – «Игелекле төбәк», ә 1989 елда аның «Мин әтигә охшаган» исемле шигырьләр җыентыклары дөнья күрә. (Ямаш Игәнәй)

3. Әниемнең кызы юк бит"шигыренең авторы кем? (Клара Булатова)

Әниемнең кызы юк бит.
Мин әнигә бер генә.
Кызы да юк, эше дә күп
Әнинең берүзенә.
Әниемнең кызы юк шул,
Мин булышам әнигә.

Аш пешерәм, җыештырам,
Кер юышам әнигә.
Магазиннан сөт апкайтам,
Ипигә дә йөгерәм.
Әниемнең кызы юк та —
Малае бар бер дигән!

4. "1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. Авыл мәктәбенең тугызынчы сыйныфын тәмамлагач, унынчы сыйныфны Сарман урта мәктәбендә укый. Быел аның тууына 90 ел булды". Бу юллар кем турында сөйли?

Кайсы автор турында без әдәби уку, класстан тыш уку дәресләрендә,класстан тыш чараларда сөйләшмәдек? Менә бүгенге класс сәгатебезне шул авторга багышлаячакбыз.

4. **Уку мәсьәләсен чишү. ( Аяз Гыйләҗев иҗаты белән танышу).**

-Аяз Гыйләҗев дигән язучыны ишеткәнегез бармы? (Язучы турында белгәннәрен сөйләтү) Китапханәченең китап күргәзмәсе буенча эше (язучының иҗаты турында мәгълүматны презентация буенча тулыландыруы, китаплар белән таныштыруы, әсәрләргә кыскача анализ бирүе) Прозаик һәм драматург Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. Авыл мәктәбенең тугызынчы сыйныфын тәмамлагач, унынчы сыйныфны Сарман урта мәктәбендә укый. 1948-1950 елларда ул – Казан дәүләт университеты студенты. Аңа да шәхес культының газапларын татырга туры килә. 1950 елның мартыннан башлап, 1955 елның августына кадәр кадәр Казакъстанда тоткынлыкта була. Казанга кайткач, университетта укуын дәвам итә. 1957 елның мартыннан 1961 елның августына кадәр А.Гыйләҗев матбугат эшендә: «Чаян» һәм «Азат хатын» (хәзер «Сөембикә») журналлары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, «Совет әдәбияты» ("Казан утлары") журналында проза бүлеге мөхәррире вазифаларын үти. 1961-1963 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укып кайтканнан бирле Аяз Гыйләҗев, язучы-профессионал сыйфатында, әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә. Аяз Гыйләҗев 2002 елның 13 мартында вафат булды. Аяз Гыйләҗевнең башлангыч иҗат тәҗрибәләре студентлык чорына карый. Ләкин аның актив иҗат эшчәнлеге 1956 елдан башлана дияргә була."Өч аршин җир", ”Зәй энҗеләре", "Урталыкта","Язгы кәрваннар", "Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят", "Җомга көн кич белән", "Әтәч менгән читәнгә" әсәрләре белән Аяз Гыйләҗев үзен повестьлар остасы итеп танытты. Тематик яктан А.Гыйләҗевның күпчелек повестьлары авыл тормышына багышланган. Аларда кичәге һәм бүгегенге авыл, аның гади кешеләре гәүдәләндерелә. Аяз Гыйләҗев – ике дистәдән артык драма әсәре авторы да. Аларның күбесе республика театрлары репертуарына кертелгән. Соңгы елларда А.Гыйләҗев роман жанрында иҗат итүгә күп көч куйды. Аның бер-бер артлы "Балта кем кулында" (роман), "Йәгез, бер дога!" (роман-хатирә) кебек зур күләмле әсәрләре дөнья күрде. Мактаулы исемнәр һәм дәүләт бүләкләре: "Җомга көн кич белән" һәм "Әтәч менгән читәнгә" повестьлары өчен А.Гыйләҗев 1983 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Әдәбиятны һәм театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен аңа 1978 елда Татарстанның, ә 1985 елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә. Ул – М.Горький исемендәге премия лауреаты да. Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне

өчен 1993 елда, Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Аяз Гыйләҗевкә Татарстан Республикасының халык язучысы дигән мактаулы исем бирелде.

**5."Муйнак" әсәрен тыңлау һәм балалар белән фикер алышу**

-Муйнакны ничек итеп күз алдына китердегез?

-Аның кайсы яклары сезгә ошады?

-Авторга бу эт ошыймы,әллә ул аны тискәре итеп күрсәтергә телиме?

-Ни өчен авылдагы бөтен кешегә карата мәрхәмәтле эт Таҗетдинне яратмый?

-Таҗетдингә сезнең әйтәсе сүзләрегез бармы?

-Автор бу әсәре аша безгә нәрсә әйтергә теләде икән?

- Муйнак кебек этегез булуын теләр идегезме? Ул сезнең эт белән охшашмы?

-Бу әсәрне тыңлаганда нинди хисләр кичердегез? (курку, шатлану, аптырау һ.б. – рәсем-схемалар арасыннан тиешлесен табып күрсәтү һәм аңлату ).

**6. Рефлексия Тестны чишү һәм слайд буенча тикшерү.**

1.Гыйләҗевнең исеме ничек?

а)Абдулла ә) Аяз б) Ямаш

2. Ул кайда туган?

а) Чукмарлы авылында ә) Ләке авылында б) Югары Баграж авылында

3. Кайсы песи Аяз Гыйләҗевнеке??

а) Матур песи ә) Академик песи б) Карак песи

4. Кайсы әсәрне Аяз Гыйләҗев язган?

а) “Акбай” ә)“Сарбай” б)”Муйнак”

Бүген мин үземә шундый яңалык алдым-.....

Бүгенге класс сәгатендә мин үземне мактый алам......

Класс сәгатеннән соң минем .... килә.

Бүген мин булдырдым.....

**7. Йомгаклау Өй эше**. Муйнакның рәсемен ясарга.

Һадиуллина Гөлнара Әкмәлетдин кызы,
Сарман гимназиясе, Сарман районы

## Һөнәрне ничек сайларга? (Сыйныф сәгате)

**Максат:** балаларга булачак һөнәрләрен сайларга ярдәм итү,барлык һөнәрләрнең дә кирәкле һәм мөһим икәнлеген аңлату

**Җиһазлар:** төрле профессия кешеләре турында презентация, А.Гыйләҗевның “Тәрәзәләр”әсәре, портреты, чиста дәфтәр битләре

### Сыйныф сәгате барышы

**1.Оештыру өлеше**

-Исәнмесез, кадерле балалар! Кәефләрегез ничек? (бармаклар белән күрсәтәләр: бармак өскә караса – әйбәт, аска караса – начар була.) Рәхмәт, сезнең шушы күтәренке кәефләрегез көн буена дәвам итүен телим.

**2.Сыйныф сәгате темасын ачу**. Экранда төрле һөнәр ияләре күрсәтелә.

-Бу рәсемнәрне нәрсә берләштерә? (Алар барысы да нindiдер һөнәр ияләре) Димәк, бүгенге сөйләшүебез төрле профессияләр турында булачак.

**3.Тема өстендә эшләү**: Балалар, вакыт дигәнең бик тиз үтеп китәчәк. Сез дә тиздән һөнәр сайлау алдында калачаксыз. Бәлки сез хәзердән үк кем булачагыгызны беләсездер,

бәлки әле ул турыда уйламагансыздыр. Әйдәгез әле, бүген серләребезне ачыйк. Үскәч кем булырга телисез? Кайсы һөнәр сезнең күңелгә якын, шул почмакны сайлыйбыз. ”Минем булачак һөнәрем”(“Конэрс”структурасы)

А) медицина өлкәсенә кагылышлы һөнәрләр Б) укытучы В) техника белән бәйле һөнәрләр Г) спорт белән бәйле һөнәрләр Д) башка һөнәрләр

-Ә хәзер һәр почмак үзе сайлаган һөнәр турында кластер ясый. Бу һөнәрнең нинди өстенлекләре бар? Сез ни өчен аны сайладыгыз? (төркемнән бер укучы эшләрен яклый)

Нәтиҗә: бар һөнәр дә кирәкле икән.

**4.А.Гыйләҗевнең “Тәрәзәләр”әсәре өстендә эш**.(Экранда авторның портреты күрсәтелә)

-Автор турында нәрсә беләсез? (якташ язучыбыз)

-Балалар, сезгә А.Гыйләҗевнең “Тәрәзәләр” әсәрен укырга бирелгән иде. Ничек уйлыйсыз, ни өчен мин әлеге әсәрне бүгенге сыйныф сәгатенә укырга куштым икән? Бүгенге сөйләшүнең әсәр белән нинди уртаклыгы бар? (Һади оста тәрәзәче булып өлгерә, үз һөнәрен бик ярата)

-Малай кечкенә чагында нинди була? Ул сездә нинди хисләр уятты?

-Әгәр Һади күрше хатынның тәрәзәсен ватмаган булса, нәрсә булыр иде?

-Әсәр безне нәрсәгә өйрәтә?

-А.Гыйләҗев хезмәте белән бәхетле кеше.Үзе үлсә дә, аның әсәрләрен һаман да яратып укыйлар.Ул бик күп мактаулы исемнәр алган язучы.

**5.Йомгаклау**

-Әйе,нинди генә һөнәр сайласаң да, аны яратып, күңел биреп башкарырга кирәк. Эшкә бару кеше өчен газаплы түгел, ә сөенечле булырга тиеш. Шул вакытта гына һөнәрең сиңа шатлык китерер. Кеше бәхетле булыр.

**6.Рефлексия:** Сезгә бу сөйләшү файдалы булдымы? (бармаклар белән күрсәтү)

-Үзегез өчен нинди яңалык алдыгыз?

Җавпларыгыз өчен рәхмәт! Сыйныф сәгатебез тәмам.

Шакирова Дилбәр Сәгыйть кызы,
Тау Иле урта гомуми белем мәктәбе, Мамадыш районы

## Аяз Гыйләҗев - безнең күңелләрдә
## Сыйныфтан тыш чара

**Максат:** балаларның Аяз Гыйләҗев әсәрләре буенча белемнәрен ныгыту, уен барышында үзләренең тапкырлыкларын, осталыкларын күрсәтә белергә өйрәтү; язучы иҗатына, тормышына кызыксыну, горурлык хисе тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Аяз Гыйләҗев портреты, әсәрләренә карата ясалган рәсемнәр,презентация.

Кичәнең барышы:

(Залда музыка яңгырый.)

Алып баручы. Хәерле көн, балалар! Ә кем белә, без бүген нинди кичәгә җыелдык икән соң? (Аяз Гыйләҗевнең туган көне якынлаша.) Бик дөрес. 17нче гыйнвар көнне – прозаик һәм драматург Аяз Гыйләҗевнең туган көне.

Татар халкы язучысы, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Аяз Гыйләҗев – татар әдәбиятының күренекле бер шәхесе. Ул – татар милләтенең талантлы, көчле рухлы икәнлеген бөтен дөньяга раслаучыларның берсе.(Слйд №1) Без бүген аның

тормыш юлы, иҗаты буенча үткәреләчәк кичәгә җыелдык. Кичә уен формасында, ике командага бүленеп үткәрелә. Уеныбыз 5 турдан торачак. Уен-ярыш булгач, сезнең белемнәрегезне жюри әгъзаләре бәяләп барачак. Әйдәгез, алар белән танышып китик. (Танышу.)

Алып баручы. Уенның I турын башлыйбыз. Һәр командага да өй эше бирелгән иде. Сез командага исем сайларга һәм девиз табарга тиеш идегез. Әйдәгез, сүзне капитаннарга бирик.

1нче команда. Безнең исем: "Дуслык". Девиз: Дуслык – безнең җиңү теләге.

*Бергә:* "Ялкын"лыларга дусларча кайнар сәлам!

Телик бер-беребезгә без,
Сәламәтлек һәм уңыш!
Кайсыбыз җиңеп чыкса да,
Бетмәсен безнең дуслык!

2 нче команда. Безнең исем: "Ялкын". Девиз: Ялкындай янып яшәргә, җиңәргә - бирешмәскә!

*Бергә:* "Дуслык" командасына ялкынлы кайнар сәлам!

"Ялкын"дай янып яшәгез,
Көч сынашыйк без бүген.
Үскәч тә искә алыйк без
Бүгенге уйнау көнен.

II тур.

Алып баручы. Икенче тур "Бездән сорау - сездән җавап" дип атала. Сорауларга дөрес һәм тиз җавап бирергә кирәк.

1 нче командага (Слайд№2)

1.Аяз Гыйләҗев туган ел? (1928нче ел)

2.Язучының туган авылын әйтегез. (Чукмарлы)

3.Аяз Гыйләҗевнең әнисенең исеме ничек? (Мөгаттәрә)

4.Язучының мәктәп еллары кайда уза? (Зәй районының Югары Баграж авылында)

5.“Җомга көн кич белән...” повестенда кешелекле дип кайсы әдәби образга әйтә алабыз? (Бибинур)

6."Өч аршын җир” повестенда авыру хатынның исеме ничек? (Шәмсегаян)

7.“Йәгез, бер дога!” әсәре нинди жанрда язылган? (Роман-хатирә)

2 нче командага (Слайд№3)

1. Аяз Гыйләҗевнең әтисенең исеме (Мирсәет)

2. Урта мәктәпне ул кайда тәмамлый? (Сарман районы урта мәктәбендә)

3. Ул кайчан КДУга укырга керә? (1948нче елда)

4. Ул нинди бәхетсезлек кичерә? (“Халык дошманы” дип гаепләнә)

5. Аяз Гыйләҗев үлгән ел. (2002нче ел)

6. Тематик яктан Аяз Гыйләҗевнең күпчелек повестьлары нәрсәгә багышланган? (Авыл тормышына)

7. “Өч аршын җир” повестеның төп идеясе? (Туган җирнең һәр кеше өчен изге урын булуы)

Алып баручы. Ә хәзер I нче һәм II нче тур нәтиҗәләре буенча сүз жюри әгъзаларына бирелә. (Жюри әгъзаларының сүзе тыңлана.)

III тур.

Алып баручы. Ә хәзер икенче өй эшенә күчәбез. Һәр команда яттан Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” әсәреннән бер өзекне сөйли.

IV тур.

Алып баручы. Бу тур "Бу өзекләр кайсы әсәрдән " дип атала. (Слайд №4,5)

Һәр төркем, чиратлап, әсәрнең исемен әйтә.

1. Бүген җомга көн. Бүген ул тып-тыныч. Тыныч диярлек. Ниһаять, үзенә язганны башкарды, дөньядагы барлык бурычын үтәде. Балаларына да ачу сакламады ул, Зөһрәбануны да кичерде.... Барысы да язмыш китабында шулай язылган идеме икән? ("Җомга көн кич белән")

2. Борылмага барып җитәбез дигәндә генә, алар каршысына ашыгыч ярдәм машинасы килеп туктады. Шәмсегаян: “Миңа арбада рәхәтрәк, машинага кермим”,- дип карышса да, аттан төшәргә туры килде... Менә борылманы үтте машина. Үргә менә башлады, күмелде... Кыр өстендә ят, чит булып, бензин белән дару катнаш ачы бер ис калды...("Өч аршын җир")

Алып баручы. Ә хәзер III нче һәм IV нче тур нәтиҗәләре буенча сүз жюри әгъзаларына бирелә. (Жюри әгъзаларының сүзе тыңлана.)

V тур.

Алып баручы. Бу турыбыз "Игътибарлымы без?" дип атала. Һәр команда чиратлашып җавап бирә. (Слайд №6,7)

1. Кайсы әсәр артык?

а) "Өч аршын җир" б) "Зәй энҗеләре" в) "Җомга көн кич белән" г) " Буранда"

2. Бу әсәрләрнең кайсын Аяз Гыйләҗев язмаган?

а) "Җомга көн кич белән " б) " Әтәч менгән читәнгә" в) "Бәхилләшү" г) " Йәгез, бер дога!"

3. Бу юллар кайсы әсәрдән?

Бүген дүшәмбе. Сабан туена төгәл бер атна бар. Россиянең бөтен почмакларына, авылның иң сөенечле бәйрәменә чакырып, телеграммалар инде киткән, кемнәрдер инде юлда. Бибинур гына беркемне дә көтми, ул гомуми бәйрәм, кайтканнарның уртак шатлыгы белән, авыл сөенече белән шатланып яшәячәк.

а) "Җомга көн кич белән " б) "Өч аршын җир" в) " Йәгез, бер дога!" г) " Зәй энҗеләре "

4. “Балта кем кулында?” әсәре нинди жанрда язылган?

а) повесть б) роман в) хикәя г) драма

Алып баручы. Хөрмәтле жюри әгъзалары, бүгенге бәйрәм дәвамында белемнәрен сынап караган балаларга гомуми бәя бирер минутлар да якынлаша. Без язучыбыз Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗаты турындагы презентацияне караган арада, сез фикерләрегез белән уртаклашып алыгыз. (Нәтиҗә ясала, җиңүчеләр дипломнар һәм истәлекле бүләкләр белән бүләкләнә.)

Алып баручы. Шуның белән прозаик һәм драматург Аяз Гыйләҗев иҗатына багышланган уен-кичәбез тәмам. Барыгызга да сәламәтлек, уңышлар телибез.

Ильина Дилүзә Рафак кызы,
Ләке төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Татар теленнән белемнәрне барлыйбыз**

Татар теле дәресләрендә мөстәкыйль рәвештә язма күнегүләр эшләү эзлекле белем алуны тормышка ашыра, укучыларның белемнәрен ныгыта, грамоталылыкны үстерә. Менә шуларны күздә тотып, укучылар һәм укытучыларга ярдәм итү максатыннан, әлеге җөмләләр тупланды. Укучыларның белем дәрәҗәләренә, активлыкларына карап, дәреслектәге бирем-күнегүләргә өстәп, әлеге җөмләләрне дә бирергә мөмкин. Материалны үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү өчен дә уңайлы.

Бу җөмләләр алынган текстлар әдәплелеккә, гаделлеккә, матурлыкка өнди; үзендә кешелеклелек сыйфатлары булдыруга ярдәм итә; телебезнең бетмәс-төкәнмәс бай мөмкинлекләрен күрсәтә һәм уй-фикерне төгәл, ачык итеп бирергә өйрәтә. Җөмләләрдәге тел-сурәтләү чаралары сүз байлыгын арттырырга һәм телебезнең бай хәзинәсен гамәли куллана белүгә ярдәм итә.

Ниһаять, татар теле буенча Бердәм Республика тестированиесенә әзерлек максатында да мондый җөмләләрне тикшерү белү файдалы булачак. Әлеге материал укучыларда туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләүдә ярдәм итәр, язучы турында күбрәк белү, геройлар язмышы белән кызыксыну теләге уятыр, әдәби китапларны күбрәк укырга тартыр, дип уйлыйм.

Белгәнебезчә, татар мәктәпләренең 8 классы өчен тәкъдим ителгән дәреслектә кушма җөмлә синтаксисына зур урын бирелгән. Гади җөмлә синтаксисыннан соң, укучыларга кушма җөмләгә керешеп китү ул кадәр үк авыр түгел, әмма темалардан соң ныгыту материаллары өчен күнегүләр җитәрлек түгел, дип саныйм. Шуны истә тотып, мин танылган якташыбыз, язучы Аяз ага Гыйләҗевнең төрле елларда иҗат ителгән әсәрләреннән файдаланып, күнегүләр җыентыгы ясадым. Җөмләләрне темалап бүлеп бирдем. Дәреслектәге кагыйдәләр, теоретик материал җитәрлек дип уйлыйм, кушма җөмләләрнең структураларын үзгәртмичә бирергә тырыштым. Артык озын җөмләләрне, эчтәлеге һәм конструкциясен бозмыйча кыскарттым, аны (……) тамгасы белән күрсәттем.

**Тезмә кушма җөмләләр**

**Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр.**

1.Табакка иң әүвәл малайларның кулы кереп китте, алар, ак күмәчне тиз-тиз чәйнәп, арага бәрәңге кыстыра башладылар.

2. Ул сыер савучыларга май тутырды, үзе күзен шакмакландырып һаман Нәҗипне күзәтте.

3. Зәйнәпне рәис иртәтеп килде, килүенә партиягә алдылар үзен.

4. Сабит иркәләп кенә Наиләне култыклады, Нәҗип арттан иярде.

5. Кыр иркен, урын аулак, хәвеф-хәтәр юк.

6. Олы малайның күзе шар булды, керфекләре леп-леп бәргәләнде.

7. Машиналар килә торды, алардан ирләр төшә торды.

8. Тормышыбыз үзгәрер, сихәтләнеп эшли башларсың, балалар исәер...

9. Идрис башын чайкап өскә менеп китте, Вәлиәхмәтов бүләкләрен кочаклап аска ашыкты.

10. Әхәтнең елмаюы каядыр качты, ике каш арасында тирән чокыр хасыйл булды.

11. Хәзер тегермән ишелеп юкка чыккан, буасы киткән, буа артындагы тирән-тирән чокырларда каралҗым су ята.

12. Кар китте, сукмаклар төште.

**Теркәгечле тезмә кушма җөмләләр**

1. Завод вәкилләре аның сүзләрен көлеп кенә үткәрә килделәр, ә комбинат эшчеләре аның артында чыш-пыш нидер сөйлиләр иде...

2. Авырлыкны бергәләп бүлешербез, әмма төп башны син күтәрәсең.

3. Барын да эшләдек, тик юлның үзен карарга гына вакытыбыз булмады.

4. Тәгәрмәчләр теләр-теләмәс кенә урыннарыннан кузгалдылар, һәм арба каты җиргә менеп тә утырды.

5. Я ул узып китә, я мин алга чыгам.

6. Вакытым да җитмәде, теләгем дә булмады.

**Иярченле кушма җөмләләр.**

**Иярчен вакыт җөмләләр**

1. Идрис һушына килгәндә, алар кочаклашып, яшь чыршылар арасына кереп баралар иде.

2. Бала тугач башлана икән аның мәрәкәсе!..

3. Тегеләр үкереп рычагка тотынганда, Мөзәккир чытырдатып күзен йомды.

4. Бер-берсенә күз ияләшә төшкәч, очрашу үз сукмагын тапты тагын.

5.Габдулла җиргә сеңгәч, иптәшләре бу сукмакның үтә хәвефле икәнен аңладылар.

6. Идрис, мышкылдап, тиргә батып барып җиткәндә, янгынчылар анда иде инде.

7. Бакчаларда кыяр-шалканнар өлгергәндә, безнең сарай түбәсе тәмам штабка әверелә иде.

8. Мин төшкәндә, сушилка янында ике ат бар иде инде.

9. Әкмәл арбасын төяп бетергәндә, мин Фәхри абыйның тынычсызланып, авыл ягына күз салганлыгын күреп алдым.

10. Мин барып аны-моны эшләгәнче, Барый, атын атын кинәт бер якка борып, тәҗе баавын өздерде.

11. Дамир күрсәткәч кенә, янына бардым хайванның.

12. Кыз, радио тагын чыштырдагач, аяк очларына гына басып, репродуктор янына килде.

**Иярчен шарт җөмләләр**

1. Дәвамы кирәк икән, үз ишеңне тап, парыңны.

2. Доброволецлар язалар икән, бүген үк китәм.

3. Кызлар белән җиңелчә генә күңел ачып утырса, дөньясы кителер идеме?

4. Атом бомбалары ява башласа, кая куярмын мин баланы?

5. Юлда кара мәче очраса, әллә кайлардан урап уза.

6. Күршең үзеңнән әйбәт икән-тормыш бара.

7. Ул чыгып китә икән-кемдер кайтып керергә тиеш.

8. Әгәр эти белән әни таныса, калам.

9. Бик олы кунак килсә, тавык суялар.

10. Кыз биргәндә аналар бәхетне яңача татыса, ул өйләндергәндә аталар бәхетле борчыладыр.

12. Әгәр кичәге хәл Әхәткә ишетелсә, ул эшне болай озакка сузып маташмас, чатылдатып гаеплəп ташлар иде.

**Иярчен кире җөмләләр**

1. Кыз карышса да, алар кафега таба юл алдылар.

2. Лиданың кашлары җыерылса да, Идрис аяусыз рәвештә дәвам итте.

3. Дилә анын тавышын ишетмәде, алай да ул Идриснең кара-кучкыл ябык йөзендәге үзгәрешне абайлап өлгерде.

4. Наилә ялынса да, Әлфия Мортазина акча алмады, киресенчә, кергәннәре өчен рәхмәт әйтеп, телефон номерын язып бирде.

5. Баграж авылын өч яктан урманнар ураган булса да, безнең эти әрәм-шәрәм иткәнне өнәми.

**Иярчен күләм җөмләләр**

1.Наилә яшь чагында аның курнус борыныннан, сул як казнасында өскә калкып торган тешеннән җай чыккан саен көлә иде.

2. Көче җиткәнчә, сыланып җиргә сеңде егет.

3. Көн яктырган саен, аның аңы ачыла барды

4. Тик яшен камчысының угы шулкадәр көчле, кермәгән тишеге, үтә алмаган почмагы юк.

5. Тирә як шулкадәр караңгы иде ки, алдагы атлар миңа юньләп күренмиләр.

6. Әмма җир һәм һава шулкадәр туксырган иде: урман ягыннан искән җил су тамчыларын куып китерә.

**Иярчен рәвеш җөмләләр**

1. Әхәт сөйләвенчә, Идрис гаҗәп дәрәҗәдә гадел, хатын-кызга хөрмәтле, гаилә бәхетен олылый белә торган итагатьле кеше.

2. Ишек артларында кешеләр үзләре булып яшиләр, үз төсләре белән, үз язмышлары кушканча.

3. Алар, үзләре дә сизмичә, Лидалар йортына борылып кайттылар.

4. Өченче партиядә Һашимның үзәк пешкасы ачык юлга чыгып, аклар арасына кыю гына барып кергәндә, балкон ишегендә Булавина күренде.

5. Юл тарайганнан-тарая барып, без арбалар яныннан килә алмас булдык.

6. Каны туңып, тәне калтырады.

7. Иреннәре ят колаклар ишетмәслек итеп сак кына пышылдыйлар.

**Иярчен аергыч җөмләләр**

1. Командировкадан Әхәт кайтып төшкән көнне редакциягә Вәлиәхмәтов килеп керде.

2. Син, чигәләре бәсәрә башлаган өметле яшь журналист, кунак кабул итә беләсеңме?

3. Әхлак ягы саф булмаган кешедән нинди өмет көтәргә була?!

4. Кан баскан күзе Зәй ягыннан шуып килгәндәй кыймылдаучы Мөнирне шәйләп алды.

5. Тик нигә ул гаепләү актын хәзер, өметсезлек тулган юлда, хәсрәт диңгезенә батып барганда игълан итте.

6. Картның организмында табиблар белә алмаган нидер бар.

7. Менә ул кузаклары тугаеп килгән борчак басуын урталай ярган туры юл белән төшеп килә.

8. Ул көннең тагын бер бөек шатлыгы бар: мин зур колхоз табагына тутырып күршеләргә угыз коймагы ташыйм.

**Иярчен сәбәп җөмләләр**

1. Эчтәге чисталык, пөхтәлек күзгә ташланып торганга, өчесе дә аяк киемнәрен салып керделәр.

2. Матавык арасында эш табылгач, биана да, килен дә бер мәлгә җиңеләеп калдылар.

3. Авыр, газаплы юлга чыгу күңелне куркытканга, ана күз алдына китермәскә тырышу балалык булгандыр инде.

4. Ат җиккәндә, көч җитмәгәч, чөелдерек бавын өчәүләп-дүртәүләп тарта идек.

5. Озын ялым арттан күндәмрәк йөргәнгә, мин Барый артыннан кузгалдым.

6. Гыйшкың төшеп, хатынын да син үтерткәнсеңдер әле.

**Иярчен тәмамлык җөмләләр**

1.Әхәт тә озатырга төшәр дип, Дилә башына да китермәгән иде.

2. Радио тыңламыйсың, күрәм.

3. Арада бик гадел, киң күңелле кешеләр бар иде, алар белән көймәгә утырып ауга чыкты.

4. Әни, әбиләр язмышында ниндидер бер закончалык, хәтта явыз рух, язмыш каһәре бар дип саныйм мин.

5. Алайса аңлатып бирегез: нигә  юк кына кызлар менә дигән егетләргә чыгалар да көнләшерлек гомер итәләр?

6. Шул ук тукталышта ашыга-ашыга  кешеләр арасына посып үзләрен күзәткән ике утлы күз барын алар бөтенләй абайламадылар.

7. Әхәтнең сүзләре бер дә шаяруга охшамаганын сизеп Лида бик борчылып тыңлый иде.

8. Ихата да, капка да йортта ир-ат кулы юклыкны кычкырып торалар.

9. Карыным ач дип юри генә әйттем.

10. Машина узганны күргәч өметләнеп куйган идем дә...

**Иярчен ия җөмлә**

1. Яхшы булды: әллә кайда, җәһәннәмдә төшеп калган тәгәрмәчне күтәреп килә-килә егетнең иңбашлары чиләнгән иде.

2. Әллә ялган, әллә чын: хәзерге заман кешеләренең авызы ашаганда гына ачыла, имеш.

3. Баш турында нәни генә калкулык бар икән, пуляларда шул саклап калган.

4. Ул ишекле –түрле йөри башлады, бу аның чамадан тыш дулкынланганын күрсәтә иде.

5. Элегрәк кәҗә асраган төз лапас астында ваклаган утынын тота, шулар ишелеп төшкән.

6. Аны бераз шикләндергән нәрсә шул булды:ишек алдында хәрәкәт туктады.

**Иярчен хәбәр җөмләләр**

1. Авыл кешесенең шул инде: шатлыгын уртаклаша башласа да, авызы кара кан белән тула.

2. Мөһимрәге шул: без өч замандаш басып торабыз.

3. Соңгы сүзем, васыятем шул:  мине Карачурага алып кайтып күм.

**Иярчен урын җөмләләр**

1. Ирек кайда, шунда тәртип булды.

2. Кыз кая барса, тегеләр дә шунда пәйда булалар.

3. Мәхәббәт дулаган җирдә һичшиксез кан коелырга тиеш микәнни?

4. Кая җибәрсәләр, шунда бара Бибинур.

**Иярчен максат җөмләләр**.

1. Лиданың сынык күңелен күтәрер өчен, ул азрак тынычлансын дип кенә башланган сүз менә кайларга кереп китте.

2. Хәсрәтемне диңгез юмасмы дип, ул бик озак ярга якын-тирәдә коенды.

**Катлаулы төзелмәләр**

**Күп тезмәле җөмләләр.**

1. Алдагы вагоннар ягыннан дөбердәгән тавыш килде, тәгәрмәчләр күндәм генә кузгалыштылар, Идрис тә сәгатенә карап алды.

2. Иренең чын күңелдән теләк теләвен күреп Диләнең күзләре дымланды, битенә куе кызыллык йөгерде, ул татлы иреннәре белән ялт кына аның яңагына кагылып алды.

3. Алар бер-берсенә карап көлеп җибәрделәр, арадагы киеренкелек йомшады, сүзләр җиңеләйде...(...)

4. Халыкның тыгыз дулкыны сыекланды, шау-шу сизелерлек кимеде, алар да вокзал алдындагы киң мәйданга чыктылар.

5. Үз якларында саран гына сибәләгән яңгыр монда ару шәбәрткән, асфальтта гөрләвекләр тәгәри, күлләвек ярып машиналар йөзә, чибәр-чибәр ал иренле апалар, туфлиларын тотып чәп-чәп яланаяк йөгерәләр.

6.Дилә төнлә уянып китте, йокысы шундук качты, күрше караватта Оксана мышык-мышык елый иде.

7. Тормыш болай да болгавыр, мөнәсәбәтләр катлаулы, яшәү мәшәкатьле.

8. Дөрес, ул шактый төз басып йөри башлады, сулыш алуы иркенәйде, тәненә әз-мәзләп ит кунды.

**Күп иярченле катлаулы кушма җөмләләр.**

**Тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләләр.**

1. Ярты төн авышкач, кеше аяк эзләре тынгач, бүлмәгә якты ай нуры кереп тулгач кына, ул караватыннан торды һәм Идрискә хат яза башлады.

2. Бар нәрсәсе җитеш югыйсә: белеме, һөнәре бар, дәрәҗәсе, даны җитәрлек, семьясы тигез, акчасы күп.

3.Аякларың йөри, гәүдәң хәрәкәтләнә, көч-егәрең әкрен генә кайта, хәлең тагын да яхшырыр дип ышанам.

4.Өйалды ишеге ачык, өй ишеге дә бикләнмәгән, бу йортта шундый гадәт.

5. Әхәт Лидадан аста үз чагылышын күреп сәерсенде: чәч чәбәләнгән, күз тонган, әллә каушаудан, әллә эчүдән йөз агарып каткан.

6. Дөрес, ул бераз кыдрачрак булса да,

7. күпмедер йөгереп узгач, Идриснең сулышы буылды, күкрәген уып адымын сирәгәйтте, шул чакта аны янгын машинасы куып җитте.

**Тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләләр**

1.Баланың кайсы инстинкты алгарак китәр, анысы тирә-якка, бала яшәгән мохитка бәйләнгән.

2. Идрис күзе күнеккәч кенә абайлады: янгынны тамаша итәргә куаклыктан байтак яшь-җилкенчәк җыелган икән, алар бер-берсенә нидер күрсәтеп кычкырып көләләр.

3. Башта нык кына киреләнсә дә, Шәмсегаян Мирвәлине җиңде: алар үз яннарына Таифә карчыкны да сыйдырдылар.

4. Кибет авыл хатын-кызларының штабы ул, монда дошман разведкасы белә алмаганны да беләләр.

**Бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләләр**

1.Мораль ягы пычрак кешенең кулы чиста булуына ышанмыйм мин.

2. Атом сугышы башланса, бу сугышта халык кырылып бетеп, армия генә исән калачак.

3. Күрә авыл: җил чыкты исә, агу болынга оча, тауларга куна, урманга тарала.

4. Габдулла савыгып яткан госпиталь нәни шәһәргә урнашкан булса да, тимер юл буена, вокзалга кадәр аны йөк машинасы белән төшереп куйдылар.

5. Мышкылдап, коры җеп бөртекләре калмыйча, редакциягә барып керсәләр, җизнәләре анда юк икән.

6. Аннары үз киләчәгемне алданрак беләсем килә: берәр җай чыгып, мине Нисачаян чага калса, син нишләрсең?

7. Мин Нөркәй ярминкәсенә киткәч, сине Түбән авыл егетләре урларга йөри икән дигән хәбәр ишеттерделәр.

8. Тик бер авыр шарты бар:чакма ташы белән чын корыч бәрелешкәндә генә чәчрәп көлтә-көлтә очкын чыга.

9. Ялгызлык газабы иренең ачуыннан көчлерәк булып чыкты:ул кайтканда, Шәмсегаян эшкә кергән иде инде.

**Берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләләр**

1.Күзенә карап ул әтисен танымады: кашы коелган, керфекләре сирәкләнгән, кабаклары җепшеп салынган күз тонык һәм җансыз иде.

2.Галикәй авыз ерса да була: улы-килене янында, үзе дә тик ятмый, сунарга, балыкка йөри, бәхете бар, буш кул белән кайтмый.

**Катнаш кушма җөмләләр**

1. Ай яктысы әле саран, йолдызлар ишәйсәләр дә, алардан коелган нурда сәйлән җыярлык түгел, юл күренми, язын –көзен казылганхыянәтчел чокырларга майлы су тулган.

2. Яраланганын илгә хәбәр итеп тормады Габдулла, “хат языймчы”, дип ике-өч тапкыр кулына каләм алды, сүзләре әле ачулы, әле ярсулы иде, дәфтәр битендә аларга урын табылмады.

3. Гаиләдә була торган ызгыш-талашларның сәбәбе кайчакта онытыла, чөнки ирхатын еш кына сәбәпсез ызгышалар, ә талашу урыны күңелдә уелып кала.

4. Шушы атналык бакчалар оешкач кына, яратмыйм дип әйтергә телем әйләнми, шулай да эшкә дәртем сүрелде.

5. Аның сүзгә кушылуын Мөнир тагын өнәмәде, кеше күрмәгәндә генә, энесенең балтырына типте, тез өстенә кунаклаган чәкчәк тагын бер якка янтайды һәм икенче почмагы җимерелде.

6. Идрис чыгып киткәч тә, Ниса кузгалырга ашыкмады, Идрис ябып бетермәгән ишекне тартып куйды, Рәкыйп өстәленнән папирос алып кабызды.

7. Офык белән кояш нурлары тоташып, аның күзе сукырайды, гәүдәсе кинәт җиңеләйгән кебек тоелды.

8. Борын төбендә выжт иттереп бәләкәй ак көймә туктагач кына, ул исенә килгән кебек булды, көчле йөнтәс куллар аны ике яктан эләктереп алдылар да җиңел генә күтәреп көймәгә меңгерделәр .

9. (...)безнең авырулар бер чамадарак, ул да мин кичергәнне кичергән, бик күп якларыбыз бер-берсенә охшаган иде.

10. Икенче көнне, балалар уянуга, кайнар бәрәңге, буын атып, өстәлдә утыра иде, саплары сынып беткән чиста чынаякларга яңа сауган хуш исле сөт салынган, юка, тигез телемнәр белән ипи дә киселгән иде.

Гайфуллина Зөлфия Нуриман кызы, Муртазина Альбина Николай кызы,
аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче,
Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Аяз Гыйләҗев - татар әдәбиятының мәңгелек сүнмәс йолдызы (башлангыч сыйныф укучылары өчен телдән журнал формасында төзелгән сыйныф сәгате)**

(Сыйныф бүлмәсе бәйрәмчә бизәлгән. Китап күргәзмәсе оештырылган).

Укытучы. Сарман... Илаһи самимилек бөркеп торган әлеге шигъри исем йөрәкләрдә тылсымлы моң сыман кабатлана, ул исемне ишетүгә күңелләр канатлана, җанга пакьлек, сафлык иңә. Сарман ягы чын-чыннан бәхетле як. Ул тырыш як, моң чишмәләре уянган як. Сарман үзе дә, авыллары да табигатьнең матур җиренә урнашкан. Халкы ачык, киң холыклы, күңелле, талантлы, җырга-моңга оста, ярдәмчел һәм эшчән. Төбәгебездәге авылларның, алар янындагы су-чишмәләрнең матурлыгы шагыйрьләребезне шигырь язарга һәм композиторларыбызны ул шигырьләргә көй язарга этәрә. Сарманга багышланган җырлар да шактый. Хәер, үзенә багышлап язылган җырлары ягыннан Сарманга тагы кайсы як кына тиңләшә ала икән? Әмма безгә иң кадерлесе - моннан бик күп еллар элек халык үзе тудырган, инде күптән республикабызның шигъри визиткасына әверелгән борынгы "Сарман" җыры (**Җыр яңгырый.)**

**1 нче укучы:** Сандугачлы, зәңгәр тааулы, яшел аланлы Сарман якларын дөньның татарлар яшәгән һәр тарафында яхшы беләләр. Картада безнең Сарман районы кечкенә генә йөрәкне хәтерләтә. Шул йөрәк тулы моң ташып тора. Моң иясе булган Илһам Шакиров, Зөһрә Сәхәбиева, Зөһрә Шәрифуллина, Гөлдәния Хәйруллина кебек җырчыларның бу якларда тууы һәм үсүе табигый кебек.

**2 нче укучы:** Бик тә күренекле, исемнәре еракларга билгеле каләм ияләрен үстергән Сарман ягы. Халыкның тирән хөрмәтенә ия булган язучыларыбыз Аяз Гыйләҗев, Сөббух Рафиков, Мәдинә Маликова, бертуган Изаил һәм Марсель Зариповлар, Диләрә Зөбәерова, Рәфкать Кәрами, Адлер Тимергалин, Хәниф Хәйруллин, шагыйрьләребез Клара Булатова, Әзһәр Габиди, Дамир Гарифуллин, Гөлшат Зәйнәшевалар олы әдәбиятка юлны Сарманнан башлаганнар.

**Укытучы:** Бүгенге сыйныф сәгатебез телдән журнал формасында булыр. Без халыкның тирән хөрмәтенә ия булган язучыларыбыз Аяз Гыйләҗевкә багышлыйбыз. Исән булса, бүген күренекле татар язучысы Аяз ага Гыйләҗевкә 90 яшь тулган булыр иде. Ул - милләтебез, районыбыз горурлыгы!

**Телдән журналның 1нче бите “Тормыш юлы”**

**Укучы:** Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районындагы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган.Балачагы һәм мәктәп еллары күршедәге Зәй районының Югары Баграҗ исемле керәшен татарлары авылында уза. Өченче класста кечкенә Аяз беренче шигырен яза: “Чыгарган беренче такмагым – шигъри юлларым хәтердә калмаган, соңгы юлы гына исемдә...” Дүртенче класстан шигырь-поэмалар яза башлап, бишенчедә “Ул үскәндә” повестен “әмәлләргә тотына”, күп санлы нәни пьесалар яза...

Шул авыл мәктәбенең тугыз сыйныфын һәм Сарман урта мәктәбендә унынчыны тәмамлаганнан соң (1945), берникадәр вакыт колхозда эшли, аңнары ике елга якын комсомолның Зәй район комитетында бүлек мөдире хезмәтендә була.

**Укучы**: 1948 елда Казанга килеп, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Монда ул, уку программасындагы фәннәрне яхшы үзләштерү белән бергә, беренче курстан ук бик мавыгып университет каршындагы әдәби түгәрәккә йөри, анда үзенең язган беренче иҗат тәҗрибәләре белән уртаклаша, фикер алышуларга, диспут-бәхәсләргә актив катнаша.

**Укучы:** 1957 елның мартыннан 1961 елның августына кадәр А.Гыйләҗев матбугат эшендә: «Чаян» һәм «Азат хатын» (хәзер «Сөембикә») журналлары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, «Совет әдәбияты» ("Казан утлары") журналында проза бүлеге мөхәррире вазифаларын үти.

1961-1963 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укып кайтканнан бирле Аяз Гыйләҗев, язучы-профессионал сыйфатында, әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә.

**Укучы:** Аяз аганың тормышында иң аянычлы чор ул 1950-1955 еллар. Бу елларны язучы Казахстан далаларында, Сталин концлагерьларында уздырырга мәҗбүр була. Ни өчен? Бары тик әсәрләрендә чагылган, шул чор режимына бик үк туры килеп бетмәгән үткен үтке фикерләре өчен.

**Укучы:** Аяз азат булып туган якларына кайткач, алар өйләнешәләр. Бер-бер артлы өч уллары туа. (Гаилә фотоларын күрсәтү). Искәндәр – профессор, Мансур – язучы, драматург. Рәшат – табиб, эшмәкәр.

**Укучы**: Аяз ага уллары белән бик горурлана. “Мин татар дөньясына өч татар үстереп бирдем. Киленнәрем дә татарлар, оныкларым да татар булыр” дип әйткән сүзләре дә бар. Һәм чыннан да, бүгенге көндә уллары, киленнәре, оныклары бер гаилә булып, куанып яшиләр.

**Җурналыбызның 2 нче бите “Әдәби эшчәнлеге”**

Киң колачлы талант иясе иде ул. Проза өлкәсендә, драматургия өлкәсендә дә зур уңышларга ирешкән язучы. Ул әдәбиятка 60 нчы елларда килеп керә. Бу чор фикерләрнең каршылыклы чоры. Ләкин ул үз сүзен курыкмыйча әйтә килә. Бу адымга аны тоткан кыйбласының дөреслегенә ышаныч кына этәрә алгандыр. Аның кайсы гына әсәрен алсаң да, алар халык өчен, ил өчен борчылган олы әдипнең алыштырмас хәзинәләре. (Китап күргәзмәсе белән таныштыру).

"Өч аршын җир", "Зәй энҗеләре", "Урталыкта", "Язгы кәрваннар", "Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят", "Җомга көн кич белән", "Әтәч менгән читәнгә" әсәрләре белән Аяз Гыйләҗев үзен повестьлар остасы итеп танытты. Драма әсәрләре, төрле театр сәхнәләрендә уйнала. Аның пьесалары белән танышкач, укучы уйлана, дөнья гаме белән яши башлый.

**Өлкән сыйныф укучылары башкаруында Аяз Гыйләҗевнең “Әтәч менгән читәнгә” әсәрен сәхнәләштерү (өзек) карап кителә.**

Укучы: Аяз ага – актив шәхес. Ул бик күп очрашуларда катнашкан, төрле конференцияләрдә чыгыш ясаган, бик күп яшь әдипләргә хәер-фатихасын кирәкле киңәшен әйткән остаз да. Аяз ага хатлар язарга яраткан.

**Журналыбызның 3 нче бите “Әдәби эшчәнлегенең нәтиҗәләре – бүләкләре”**

"Җомга көн кич белән" һәм "Әтәч менгән читәнгә" повестьлары өчен А.Гыйләҗев 1983 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Әдәбиятны һәм театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен аңа 1978 елда Татарстанның, ә 1985 елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә. Ул – М.Горький исемендәге премия лауреаты да. Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш

керткәне өчен 1993 елда, Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Аяз Гыйләҗевкә Татарстан Республикасының халык язучысы дигән мактаулы исем бирелде

**Җурналыбызның 4 нче бите “Хезмәт итүче алмаш тәрбияләгән шәхес”**

Аяз Гыйләҗев татар әдәбиятына көчле әсәрләр генә түгел, ә үзеннән соң милләт өчен хезмәт итүче алмаш тәрбияләгән шәхес.

Драматург Мансур Гыйләҗев әтисенең эшен дәвам итүче язучы (слайд). Мәрәсим вакытында ул да әтисенең ата сыйфатларын барлап узды. “Бүгенге көндә әтинең тәрбияләү прициплары, аның киңәшләре бик актуаль булыр иде. Чөнки хәзер дөнья, бигрәк тә балалар, яшьләр Интернет дөньясына кереп китте, тормыш кыйммәтләре онытыла башлады. Ә әти безне тормыш гүзәллекләрен күрергә өйрәтә иде. Авыл, табигать төшенчәләрен белеп үстек. Ул безге гел урманга йөртә иде. Бергәләп гөмбә җыябыз, күлдә балык тота идек. Ә хәзер бит балага андый мөнәсәбәт онытыла башлады. Кайберәүләр туган җиренең кайда икәнен дә белми. Әти гомер буе кешелек кыйммәтләрен алга сөрде. Безне дә шулай тәрбияләде”, - ди Мансур Гыйләҗев.

(Мансур Гыйләҗев әсәре буенча - "Яра" спектакленән видеоязма карау).

**Йомгаклау**

Укытучы. Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең иҗаты халык күңеленә бик якын. Ул үзенең әсәрләрендә тормышның иң авырткан мәсьәләләрен чагылдыра.Ул татар милләтенең киләчәге өчен борчыла. Милләт өчен, гади халык өчен янып-көеп яшәгән әдипнең иҗатын онытмау, бу бөек шәхесне зурлау бездән тора. Аның бай иҗаты киләчәк буыннарга да хезмәт итәр, якты истәлеге халкыбыз күңелендә мәңге сакланыр. Сарман җирлегенең күренекле вәкилләре турында һәм Аяз Гыйләҗевнең иҗатын өйрәнүне дәвам итәргә кирәк.

Газизова Рәмзия Асфан кызы, Бәдертдинова Илсөяр Изаил кызы,
аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче,
Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**А.Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” әсәрендә Ана образы**

**Дәреснең тибы:** Семинар дәрес.

**Максат:** Әсәрнең төп герое Бибинур образын ачу. Бәйләнешле сөйләм, логик фикерләү күнекмәләрен ныгыту. Балаларда әниләргә карата хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлау:** А.Гыйләҗев турында альбом, “Сөембикә” журналы, портрет, дәфтәр, дәреслек, әсәрнең тулы басмасы.

Дәрес барышы.

Кереш. Укытучының кереш сүзе. Дәрес максаты белән таныштыру.

А.Гыйләҗевнең кыскача биографиясен тыңлау.

Әсәрнең кыскача эчтәлеген тыңлау.

Алдан бирелгән сораулар буенча әңгәмә.

Төп өлеш. Сораулар:

Бибинур һәм Җиһангир мөнәсәбәте (Җиһангир – җиһан (дөнья) биләүче).

Икесе дә кеше ярата, кеше бәхете өчен көч түгә фикеренә укучы чыгышы аша килү. (Ул әби өчен рухи һәм матди терәк).

Бибинурның үз эшенә карашы. (Укучы ат белән булган вакыйганы сөйли, җаваплылык хисен ачыклый).

Героиня – табигать. Укучы 304 нче биттән өзек укый.

-Табигатьне аңлый белүче нинди була соң? (Кече күңелле, мәрхәмәтле...).

- Җомга көн әби юлга чыккач, яңгыр явуны ничек аңлатып була? (Табигать елый).

Бибинур – Зөһрәбану. (Укучы сөйләменнән туганлыкны кадерләүче фикере чыгарыла).

Бибинурның авылдашларына, аларның Бибинурга мөнәсәбәте.

- Һаман да кешеләр кайгыртуын Зөһрәбану белән Галикәйне кавыштыру мисалында күреп үттек. Балалар бакчасы мөдире Хәнифәне искә төшерик әле. (Укучы сөйли һәм 316 биттә язылганнарны укый).

Бибинур – балалары. (Укучы сөйли. Ананың балаларга гомер буе тугры булуын ачыклау).

- Ә балаларга карата нинди сүз кулланып була? (Тугрылык – хыянәт. Кеше бәхете өчен яшәүчеләр намуссызлык, битарафлык алдында көчсез. Аларның күңелләре изге. Алар бары яхшылык эшләүне белә, ә начарлыкны кабул итә алмый).

- Әсәрнең исеме, геройның җомга көн юлга чыгуы, нәрсәгә инандыра? (Әбинең изге булуына).

- Геройны ничек күз алдына бастырдыгыз? (Зәңгәр күзле, ак яулыклы, ягымлы йөзле, җыйнак гәүдәле...).

“Алтын мөнбәр” фестивалендә тәгъдим ителгән “Бибинур” фильмы турында сөйлиләр. (2009, төп рольдә татар халык артисты Фирдәвес Әхтәмова.(“Сөембикә” материаллары).

- Сөйләшүне йомгаклап, мәкальләргә тукталыйк.

Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен.
Картлык шатлык түгел.
Картларга юл куй, үзең дә картаерсың.
Бала чакта олылардан курыксаң, олайгач, балалардан куркырсың.

Дәрес йомгаклап, билгеләр куела.

Әгълиуллина Рәсимә Мөхәмәтгали кызы, Зарипова Эльмира Мансур кызы,
Тайсуган төп гомуми белем бирү мәктәбе, Әлмәт районы

**Сугыш чоры балаларының батырлыгы һәм сугыш китергән афәт**
**(Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәре буенча проект эше)**

Аяз Гыйләҗев – әдәбиятыбызның төрле тармакларында ут уйнаткан кеше. Ул күренекле прозаик, үзенчәлекле драматург, үткен каләмле публицист һәм очеркист, ниһаять, усал телле тәнкыйтьче.

Аяз Гыйләҗев иҗатын тулы итеп күз алдына китергән кеше әйтер: автор иманын җилләр агымына карап алыштырып торган әдип түгел икән. Каләменнән чәчелеп калган таза орлыклар, алардан үсеп чыккан шытымнар әдип йөргән сукмакларның йөз кызартмаслык олы юлларга барып чыкканлыгын күрсәтә. Бу сукмаклар ахыр чиктә язучыны хакыйкать биеклегенә алып килгәннәр.

Аяз Гыйләҗев татар әдәбиятын уй-фикерләрнең торгынлыгыннан коткарып, алтмышынчы-сиксәненче еллар әдәби агымын дәррәү кузгатып, хөрлеккә таба борып җибәрде, әдәби чараларны да кыю рәвештә яңартты. Аның «Өч аршын җир», «Язгы кәрваннар», «Әтәч менгән читәнгә», «Җомга көн кич белән», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Яра», «Балта кем кулында», «Йәгез, бер дога!», «Урамнар артында яшел болын» кебек проза әсәрләре, күп санлы пьесалары (алары кырыклап) бүгенге һәм

үткән тормыш агымын тирәнрәк аңларга ярдәм итте, татар әдәбиятына яңача рух өрде, замандашыбыз образларын сәнгатьчә ача алды. Шуңа күрә аны Язучылар берлегенең рәисе Мөхәммәт Мирза (Илфак Ибраһимов) «әдәбиятыбызның имән баганасы» дип атады.

Проект эшенең актуальлеге:

А. Гыйләҗевнең тормыш һәм иҗат юлы шомартуга яки бизәүгә мохтаҗ түгел. Аның әдәбияттагы урыны ачык билгеләнсә дә, иҗади мирасы әле чын-чынлап, тирән итеп өйрәнелмәгән. Моның сәбәбе бик гади: аның әсәрләре әзер кысаларга, кабул ителгән концепцияләргә сыеп бетми. Аның проза, драматургия, публицистика, әдәби тәнкыйть өлкәләренә керткән яңалыгын, иҗади ачышларын бәяләү, аңлау һәм аңлату киләчәк буын тәнкыйтьчеләре бурычы булып кала бирә.

Максат: укучыларны Аяз Гыйләҗевның “Язгы кәрваннар” әсәре белән таныштыру; “Язгы кәрваннар” әсәре аша, сугыштан соң халыкның тормышы белән таныштыру.

Бурычлар:

Аяз Гыйләҗев иҗаты белән танышу. Аяз Гыйләҗевның “Язгы кәрваннар” әсәре белән танышу. Сугыштан соң Тайсуган авылы халкы тормышын өйрәнү.

**Төп өлеш**

Прозаик һәм драматург Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстан АССРның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. Шул авыл мәктәбенең тугыз классын һәм Сарман урта мәктәбендә ун класс тәмамлаганнан соң (1945), берникадәр вакыт колхозда эшли, аннары ике елга якын ВЛКСМның Зәй район комитетында бүлек мөдире хезмәтендә була. 1948—1950 елларда ул — В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты студенты, ә 1950 елның мартыннан башлап 1955 елның августына кадәр Казакъстанда яши һәм төзелештә ташчы, бетон коючы, бригадир һәм десятник профессияләрен үзләштерә. Аннары, яңадан Казанга кайтып, университетта укуын дәвам иттерә. 1957 елның мартыннан 1961 елның августына кадәр А. Гыйләҗев матбугат эшендә: «Чаян» һәм «Азат хатын» журналлары редакциясендә әдәби хезмәткәр, «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында проза бүлеге редакторы вазифаларын үти. 1961—1963 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укып кайтканнан бирле Аяз Гыйләҗев, әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнде.

Аяз Гыйләҗевнең башлангыч иҗат тәҗрибәләре студентлык чорына карый. 1948 елны «Безнең хикәяләр» исемле җыентыкта яшь авторның «Ян, Учагым, ян!» исемле лирик рухтагы беренче хикәясе басылып чыга. Ләкин аның актив иҗат эшчәнлеге 1956 елдан гына башлана дияргә мөмкин. 1956— 1960 еллар арасында «Чаян», «Азат хатын», «Ялкын», «Совет әдәбияты» журналларында, республика газеталарында язучы өч дистәгә якын хикәя, фельетон, мәкалә һәм үзенең беренче күләмле әсәрләреннән — сугыш чоры авылы яшүсмерләре тормышына багышланган «Дүртәү» исемле повестен бастыра. Бер үк вакытта ул драматургиядә дә иҗади сәләтен күрсәтә. Татар дәүләт театры сәхнәсендә бер-бер артлы «Җиз кыңгырау» (1959), «Киек каз юлы» (1960), «Көзге ачы җилләрдә» (1961) исемле пьесалары куела. Матбугатта «бераз соңрак—1966 елда дөнья күргән» һәм кеше язмышының катлаулы борылышларын шактый нечкә психологик детальләр, тормыш күренешләре аша тасвирлаган «Берәү» повесте да язылуы буенча әдипнең шушы чор иҗатына карый.

Беренче әсәрләреннән үк анык сиземләнгән язу манерасы — кырыс реализм, халыкчан образларга бай җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары, кайсы чор турында

һәм нинди темага язса да, кеше шәхесенең катлаулы рух» дөньясын, эш-гамәлләрен заманның гуманистик идея-эстетик карашлары югарылыгыннан торып анализларга, аларны бүгенге чынбарлыктагы, җәмгыять үсеше процессындагы актуаль мәсьәләләр, социаль-әхлак проблемалары белән тыгыз бәйләнештә гәүдәләндерергә омтылу һәм, ниһаять, әдәби-осталык, форма өлкәсендәге өзлексез эзләнү, тәҗрибәләр — язучы-художник буларак, А. Гыйләҗев иҗат эшчәнлегенең төп асылын, идея-эстетик юнәлешен тәшкил иткән бу сыйфатлар әдипнең алтмышынчы-җитмешенче еллар» да язылган проза әсәрләрендә аеруча калку чагыла.

Сугыштан соңгы авылның язмышы хакында тирән борчылу, аның үсеш юллары турында уйлану һәм авылда яшәүчеләрне шәхес итеп танып, аларның рухи дөньяларына игътибар итү татар әдәбиятында күп булды. Алтмышынчы еллар прозасында нәкъ менә сугыш еллары һәм аннан соңгы еллар авыл мәсьәләсенең мөһим урын алуы, икенче яктан, бу чор авылының хәзерге күпчелек язучыларыбызга барыннан да якынрак һәм танышрак булуы белән аңлатыла. Бу мәсьәлә белән аеруча Р.Төхфәтуллин, А.Гыйләҗев, Н.Фәттах, Ә.Баянов, М.Мәһдиев кебек урта буын язучыларының кызыксынуы да шулай ук бер дә очраклы хәл түгел.Чөнки аларның балалык һәм яшьлек еллары нәкъ менә әлеге чор авылында үткән. Бу авыл тормышын аларга үз күзләре белән күрергә, аның авырлыкларын һәм кыенлыкларын үз җилкәләрендә татырга туры килгән.

Аяз Гыйләҗевның дә күпчелек әсәрләрендә сугыштан соңгы авыл тормышы сурәтләнә. Автор заман авырлыгын күтәрүче авыл халкының язмышы өчен үтә дә борчылып яза.  Сугыш чорында үскән яшүсмерләрнең тормышын кырыс буяулар белән күрсәткән әсәрләрнең берсе – “Язгы кәрваннар” повесте. “Язгы кәрваннар”да чәчүлек симәнә орлыгы алып кайталар. Ләкин соңгысында саф мәхәббәт тә, авыл кешесенең югары әхлагы, намусы да ачыграк сизелә, язучының әйтергә теләгән фикере дә үткен хәнҗәр кебек күренеп тора.

Язучы әсәрдә авыл халкының гүзәл әхлак сыйфатларын да күрсәтә, шул ук вакытта шул яхшы кешеләрнең начар шартларда яшәү сәбәбен дә ачыкларга тырыша. Аеруча яратып Әдилә образын иҗат итә. Әдилә апасы үлгәч, җизнәсе янына кайтып, ятим балаларны тәрбияли. Аның турында җизнәсенә кияүгә чыга икән дигән сүзләр дә йөри. Ләкин кыз күңеле аны кабул итми.

Аның турында аеруча яратып Ибраһим сөйли. Ятимнәргә ана булган кызның шушы батырлыгын бәяләргә сүзләр җитми. Аларның Ибраһим белән булган мәхәббәтләре дә саф, әхлакка барып тоташкан самими мөнәсәбәт.

Автор Ибраһим, Дамир образларын да яратып иҗат итә, аларга үзенең уңай мөнәсәбәтен белдерә. Яшьләрнең хезмәттән тайчанмавы, бер авырлыксыз җир читенә дә барырга ризалык бирүләре башкаларда да хезмәткә дәрт уята.

Ибраһим авыл эшеннән канәгать, хезмәт өчен үзен кызганмый.Алар инде үзләрен зурлар итеп, колхозның терәге итеп саныйлар. Аларның үзләренә йөкләнгән бурычларын намуслы үтәп чыгуларына һичшиксез ышанырга була. Атлар карауччы Дамирның атлар өчен җанын да ярып бирергә әзер торуы куанычлы хәл. Ашамаган малларның күзләрендәге моң Дамирның да күзләренә күчкән. Атлар колхозның зур байлыгы. Ләкин Дамир аларны йөкләнгән бурычтан бигрәк, аларга булган мәхәббәте өчен карый.

Менә алар алтмыш чана алтмыш биш чакрымдагы Кәслегә симәнәгә баралар. Авылдан ерак юлга чыга алырлык барлык кеше дә кузгалган. Хәтта йөрәк өянәкле Сабирәттәй дә түзеп ята алмаган. Халык берсүзсез ризалык белдереп олы юлга кузгала. Авыл халкының бердәмлеге, колхоз рәисен хөрмәт итүе дөньның ачысын татыган

кешеләрнең әхлагын күрсәтә. Ләкин шушы юл яшәү чыганагы булган икмәкнең амбарга кайтып керүе авыл халкына күпмедер дәрәҗәдә кыймматкә төшә, чөнки ерак юлга сәфәр Сабирәттәйнең үлеме белән тәмамлана. Аның үлеме район башлыкларының мәгънәсез әмерләре нәтиҗәсендә була.

Аяз Гыйләҗев әсәрнең азагында авыл кешесенең мәшәкатьле тормыш сәбәпләрен ачыклый. Район җитәкчеләренең мәгънәсез юлга куулары нигә кирәк булды икән, дөрестән дә. Бәлки үзләренең көчлелекләрен күрсәтү, үзләрен шәхес итеп таныту өчен. Ләкин иң әһәмиятлесе – яшьләрнең моны аңлап алуы.

Әсәрдә автор ил өстенә килгән фаҗиганең, заман авырлыгының кеше тормышында чагылуын күрсәтә. Илгә килгән афәт бер генә кешене дә читләтеп үтмәгән. Ирләр сугыш эчендә йөргән, ә Әдилә, Ибраһим кебек балалар әтиләре өчен тормыш арбасына җигелгәннәр, ил өчен икмәк җитештергәннәр. Уеннарыннан аерылган бер гөнаһсыз балаларның йөзләрендә бәхет, шатлык чалымнары калмаган. Алар тынычлыкны тартып алган фашистларга ләгънәт укыйлар. Шуның белән беррәттән Аяз Гыйләҗев шул чорда чыннан да булган хәлләрне, яз-көз җитсә бер авылдан икенче авылга мәгънәсез йөк ташуларын сурәтләп ил фаҗигасен тагын да катлауландырган сәбәпләрне күрсәтә.

Халыкта «Үз язмышың үз кулыңда» дигән әйтем бар. Әйе, күп очракта бу шулай. Үз язмышыңны үзең төзисең, әйләнә-тирәдәге якыннарың, дусларың, җәмгыять тә синең язмышыңа күпмедер тәэсир итә. Ә инде бөтен кешелекнең, җәмгыятьнең тоткан юлын, язмышын гел башка якка үзгәрткән зур тарихи вакыйгалар да булырга мөмкин. Безнең ил тарихында әнә шундый зур фаҗигаләрнең берсе Бөек Ватан сугышы булды һәм миллионлаган халыкның язмышын берничә минут эчендә үзгәртте дә куйды. Сугышның ачы хәсрәтле җиле һәр өйгә, һәр гаиләгә, һәр кешегә килеп сарылды.

Әсәрдәге вакыйгалар сугыш чорын үз башыннан кичергән һәр кеше өчен бик таныш һәм якын.

Тайсуган авыл халкының да авылда калган хатыннарның һәм олы яшьтәгеләрнең хәлләре аяныч була. Ул вакытларда хөкүмәт көз көне бөтен икмәкне себереп алып бетерә. Яз көннәрендә өч бәясе белән колхозларга сатып, аны башка күрше авылларның амбарларыннан бәләкәй арбаларга 50-100әр кг салып ташыйлар. Ач-ялангач хатыннар хәлдән таеп кайтып авалар. Аңардан кала яз көннәрендә эскерт урыннарында сөрелми калган җирләр көрәк белән казылалар. Көнгә ике- өч сутый каты җирне ач килеш казырга тиеш булалар иде. Шундый авыр шартларда да алар һич сукранмыйча эшләделәр.

Бүгенге көндә 96 яшен тутырып, Тайсуган авылында туган, шунда гомер итүче Шәйхетдинова Майкәүсәр Раян кызының да яшьлегенең иң матур еллары сугыш вакытына һәм сугыштан соң авыр елларга туры килгән. Көзен егерме чакрым ераклыктагы районга икмәк ташысалар, язын, шуны ук күтәреп, кире алып кайтканнар. Авылга Зәй елгасы аша чыкканда, күтәрәмле чабаталары су белән тула торган булган. Кайвакытта көненә икешәр дә барганнар алар. Урак урганда, көнгә 30 сутый норма булган. Сугу машиналарын кул белән әйләндергәннәр, ашлыкны җилгә көрәк белән тотканнар, шулай чистартканнар. Майкәүсәр апа фермада учётчик булып та эшли. Бөтен язу эшләре аның өстендә була, күрше Габдрәхмән авылына үгез җигеп сөт илтә торган була.

Черек бәрәңге, алабута кушып пешерелгән күмәч, кычыткан ашы – болар төп ризыклары булган. Майкәүсәр апа уен-көлкене ярата. Хәлен белергә килгән укучыларны ачык йөз белән каршы ала. Янына килгән яшьләргә, балаларга тормышта максат куярга, теләкне тели белергә өйрәтә. Аның күңелендә изгелек, яхшылык кына. Авыр сугыш

елларында да шушы хисләр яшәргә көч биргән. Өмет, теләк һәм тырышлык Җиңү көнен якынайткан. Тылдагы һәр кешенең хезмәте – ул зур батырлык.

**Йомгак**

Күренекле язучыбыз Аяз Гыйләҗев «Язгы кәрваннар» повестенда тылдагы кешеләрнең күңел матурлыкларын, олы җанлы, киң күңелле булуларын, үзләренең хәле хәл булса да, башкалар турында кайгыртып яшәргә омтылуларын Сабирәттәй, Хәкимҗан абый, Сәрвәр апа, Габбас абыйлар аша сурәтләсә, сугыш та җиңә алмаган яшь җаннарның күңел матурлыгын, мәхәббәтнең, дуслыкның олылыгын Ибраһим, Әдилә, Дамир образлары аркылы безгә җиткерә. Өмет, теләк көчле булганда, яшәү дә матур булачак. Аларның һәркайсының тормышы – үзенә күрә батырлык.

Тематик яктан, А. Гыйләҗевнең күпчелек повестьлары авыл тормышына багышланган. Аларда кичәге һәм бүгенге авыл, аның гади кешеләре гәүдәләндерелә, әхлак, тәрбия мәсьәләләре; мәхәббәт, гаилә, намус, вөҗдан каршында җаваплылык, яшәү максаты, яхшы белән яманның кеше күңелендә барган мәңгелек көрәше гыйбрәтле язмышлар, тирән конфликтлы, драматик вакыйгалар аша яктыртыла. Автор үзенең әсәрләрендә гади кешенең рухи бөеклегенә дан җырлый.

Аяз Гыйләҗевне һәрвакыт гади колхозчы язмышы, крестьян тормышы кызыксындырып һәм уйландырып торган, аның авыр хәле борчуга салган. Автор үзе җирне яратучы кеше буларак авыл яшьләренең җир белән аралары ераклашуга тирән көрсенә һәм моның сәбәбен ачыкларга тели.

Алда әйтелеп үткәнчә, Аяз Гыйләҗев һәрвакыт авыл тормышы белән кызыксынып, аның киләчәге, үткәне өчен борчылып язучы әдип. Без карап үткән повестьта да авыл кешеләре иңне иңгә куеп сугыш афәтен бергә күтәрәләр. Ил өстенә килгән фаҗиганы бергә кичерәләр. Автор бу кешеләрнең кичерешләрен, психологиясен дә сугыш дәһшәте белән бәйләп күрсәтә. Чөнки һәр кешенең уенда тизрәк сугышны җиңү һәм бәхетле тормыш төзү тора. Инде сугыштан соңгы чорларны тасвирлаган әсәрләрдә геройлар бәхет өчен көрәшәләр, үз максатларына ирешү юлында күп каршылыкларга очрыйлар. Бу чор геройлары кырыс холыклы, тормышның ачысын- төчесен татыган кешеләр. Язмышларына буйсынучы кешеләр белән беррәттән, бүгенге көн белән ризалашмаучы яшьләр дә бар. Алар бәхетле, матур киләчәк турында, уңайлыклары булган эш урыннары турында хыялланучы замана яшьләре. Шушы яшьләрнең заманага, җәмгыятькә мөнәсәбәтле фикер каршылыкларын ачып бирү әдипнең бу чор геройларын иҗат итүдәге үзенчәлеген күрсәтеп торучы бер мисал булып тора.

Салимгараева Альфия Мидхатовна, Гордюшина Лилия Зульфаровна,
“Джалильская СОШ №2”, Сармановский район

## Классный час: «Память сердца»

**Цели:** изучить жизнь и творчество А.Гилязова в период репрессий; развивать навыки самостоятельного анализа художественных произведений, подготовки сообщений по различным источникам, формировать навыки публичного выступления.

Предварительная работа: подготовить сообщение об основных фактах жизни и творчества А. Гилязова; собрать для выставки книги писателя на татарском и русском языках; подготовка компьютерной презентации.

**Возраст учащихся:** 16-17 лет

**Оборудование:** выставка книг писателя на татарском и русском языках, портрет поэта, тематические слайды.

**Место проведения:** актовый зал школы

**Ход мероприятия:**

Ученик читает стихотворение:

Память – это как клятва,
навечно,
Желтым пламенем жалит
и жжет.
Потому что и живет бесконечность,
Что в ней долгая память
живет!

Учитель истории: Сегодня на нашем мероприятии мы вспоминаем нашего земляка, знаменитого прозаика, драматурга, публициста и очеркиста, литературного критика и писателя – Аяза Гилязова, который родился в деревне Чукмарлы Сармановского района и которому 17 января исполнилось бы – 90 лет!

Печатные издания, документы, воспоминания родных и близких писателя сохранили для нас интересные факты из личной и творческой жизни.

Ученик 1: Народный писатель Татарстана, лауреат Государственной премии ТАССР им. Г. Тукая и Государственной премии РСФСР им. М. Горького, литературных премий Союза писателей Татарстана им. Г. Исхаки и С. Рафикова, Заслуженный деятель искусств ТАССР и РСФСР А. Гилязов по праву может считаться одним из самых талантливых и самобытных представителей татарской культуры XX-XXI.

Аяз Гилязов родился 17 января 1928 года в семье учителя. Детство провёл в деревне Верхний Багряж (Заинский район). Получил неполное среднее образование в местной школе. Вернулся в родной район, где закончил Сармановскую среднюю школу. В 1948 году поступил в Казанский государственный университет.

В 1950 году был арестован и сослан в карагандинский лагерь, где содержались даже лауреаты Сталинских премий. Там Гилязов находился пять лет. В 1955 году был реабилитирован.

После освобождения вернулся в Казань и продолжил учёбу. Через полтора года начал сотрудничать с журналами «Азат хатын» и « Чаян». Стал редактором отдела прозы журнала «Совет эдэбияты» (сейчас «Казан утлары»).

В 1963 году окончил Высшие литературные курсы при СП СССР. После этого стал считаться профессиональным писателем.

Писал рассказы, очерки, фельетоны, статьи. Позднее, излюбленным жанром Гилязова стала повесть.

Аяз Гилязов скончался 13 марта 2002 года.

Ученик 2: Женился Аяз Мирсаидович ещё в 1950-х годах. В семье Аяза Гилязова и Накии ханум выросло три сына. Известный писатель часто с гордостью говорил: *«Кто ещё из писателей для татарского народа вырастил таких троих сыновей?»* .

Первенец Искандер родился 31 августа 1958 года. Он закончил историко-филологический факультет того же университета, что и его отец. Стал известным учёным, возглавил кафедру истории татарского народа КГУ. В последнее время активно занимается изучением истории татарской диаспоры и эмиграции XIX—XX вв. Женат, имеет двух дочерей, Галию и Миляушу.

Мансур Гилязов пошёл по стопам отца и стал драматургом. Пишет киносценарии. Имеет также специальность архитектора. Влюбился с первого взгляда и женился на своей избраннице. Они подарили Аязу Мирсаидовичу троих внуков, которых зовут Зифа, Муса, Арман..

Младший сын, Гилязов Рашат Аязович, занимается прдпринимательством и, как и его отец, имеет трех сыновей.

Учитель литературы: Писать Аяз Гилязов начал ещё в университете. Активно стал заниматься литературной деятельностью после освобождения из лагерей. Он публиковал в журналах рассказы, очерки, фельетоны, статьи. В 1958 году написал Аяз написал свою первую повесть «Их было четверо»..

Начиная с 1950-х годов его пьесы стали появляться на сцене театра рядом с произведениями его современников Х. Вахитова, Ш. Хусаинова, И. Юзеева, Д. Валеева, Т. Минуллина, Н. Фаттаха.

Интересовался произведениями молодых писателей. Давал положительную оценку повести Разиля Валеева «Собачье сердце».

Прославившим его жанром стали повести, в которых он затрагивал острые проблемы современности. Одна за другой вышли «Три аршина земли», «Жемчужина Зая», «В середине», «Весенние караваны», «Любовь и ненависть». Произведения Гилязова отличаются удивительно ярким, мелодичным и естественным языком написания.

Откликаясь на социальные проблемы, вставшие перед татарским народом в 1980х, остро почувствовав гибель своих исторических корней в процессе урбанизации, Аяз Гилязов, а также его соратники на литературном поприще Мухаммад Магдеев, Вакиф Нуруллин, Рафаэль Тухватуллин, продолжили разрабатывать в своём творчестве деревенскую прозу.

В повести «Взлетел петух на плетень» Гилязов снова исследует духовное состояние современной татарской деревни, подчёркивая своеобразие национальной психологии и с горечью осознавая, что корысть, зависть, жадность, погоня за материальными благами проникли и в жизнь деревни и сознание её жителей.

Главным прототипом в его произведениях был он сам, в судьбе положительных героев отражена и его судьба. Естественно, литературные герои, зачастую, образы собирательные. Но всё же, большей частью, писал о своей судьбе.

Ученик 3: Тема сталинских лагерей также находила отражение в творчестве татарских писателей. Она раскрывается у Аяза Гилязова в рассказе «Давайте помолимся», а также его современников, Ибрагима Салахова («Колымские рассказы»), Факиля Сафина («Обманчивый рассвет»).

Несмотря на то, что при жизни Аяз Гилязов имел хорошее отношение со стороны власти – у него была и Тукаевская премия, и Госпремия Российской Федерации, и звание народного писателя, о многом он не мог тогда говорить открыто в силу объективных причин.

В 2000-х годах друг семьи Гилязовых, ныне член Союза писателей Татарстана, Фатих Кутлу, перевёл повесть «Три аршина земли» на турецкий язык. Турецкое издание вышло в свет в 80-ю годовщину со дня рождения Аяза Гилязова. В Турции повесть приняли очень тепло. Некоторые стали называть Гилязова татарским Стендалем.

Сейчас Кутлу работает над переводом ещё одной повести Аяза Мирсаидовича – «В пятницу вечером».

После смерти писателя осталось много неопубликованных писем, как личных, так и профессиональных. Права на публикацию он завещал своей жене Гилязовой Накие Ильгаметдиновне.

Учитель истории: 30 октября – день памяти жертв политических репрессий. В Татарстане в число неугодных попали около 60 татарских писателей. Их судьбы сложились трагично.

Память человека – богатство веков. В памяти народа сохранены периоды исторической гордости своей страны и события черных дней в душах людей. К сожалению, таких черных камней было брошено слишком много в годы политических репрессий. В Республике Татарстан после проведенных работ по реабилитации осужденных по статье 58 о «врагах народа» увидели свет множество томов Книги памяти жертв политических репрессий. В этих книгах имеются данные о наших земляках живших в Сармановском районе 615 человек осуждены по этой статье. Из них: из деревни Мортыштамак – 25, Боламыка – 1, Бикасаз – 4, Ляки – 4, Старое Каширово – 4, Нуркеево – 2.

Ученик 4: Судьба распорядилась так, что Аяз Гилязов оказался в числе политических заключенных в лагере Карлаг НКВД СССР. Спустя годы писатель написал роман-воспоминание « Ягез бер дога» на татарском языке, посвященное событиям этого периода, о лично пережитом опыте лагерей, о людях-мучениках ГУЛАГА. Произведение было переведено и на русский язык.Книга была презентована в 2016 году в Москве ( в Музее истории ГУЛАГА).

Ученик 5: (Общие сведения о Карлаге НКВД) Один из крупнейших исправительно-трудовых лагерей ОГПУ-НКВД СССР был создан в 1930 году на территории трех районов Карагандинской области - Тельманского, Жана-Аркинского и Нуринского. Ранее на этой территории располагался КазИТлаг ОГПУ-НКВД. На его основе и был создан Карагандинский ИТЛ ОГПУ-НКВД. В дальнейшей ведомственной переписке Карлаг именовался – «Карагандинский исправительно-трудовой лагерь ГУЛАГА НКВД (ИТЛ). При сношениях с другими ведомствами – «Карагандинский совхоз НКВД». Одной из главных целей создания Карлага была организация крупной продовольственной базы и бесплатной рабочей силы для бурно развивающейся промышленности Центрального Казахстана, в частности – Карагандинского угольного бассейна. Карлаг был организован не на «пустом месте» и не на территории «необжитой степи». Уже в первые годы его образования первоначальная территория стала быстро прирастать за счет соседних районов на севере и на юге. По всей отведенной под лагерь территории жило коренное население – казахи, а также русские, украинцы и немцы, которые переселились в эти края в 1906-1907 годы. С образованием лагеря в 1931 году началось принудительное выселение населения с отведенных для него территорий. Для этой операции привлекались войска НКВД. Судьба коренного населения – казахов сложилась особенно трагично. В это время в степи началась коллективизация, обездоленные, выселенные с мест обитания люди перебираются в Караганду и в ближние к Караганде районы. В Караганде в это время начиналось строительство шахт и многие переселенцы использовались как неквалифицированная рабочая сила. За чашку баланды и паек хлеба несчастные люди в тяжелейших условиях трудились по 12 часов на строительстве объектов народного хозяйства. Огромное количество конфискованного скота – крупного рогатого, овец, лошадей, верблюдов – было передано специально для этой цели созданной организации «Востокмясо». Одновременно проводились

насильственные меры по внедрению оседлости среди кочевого населения. После изгнания коренного населения пустующие земли заняли многотысячные колонны заключенных.

Ученик 6: Этапы заключенных из центральных областей России пребывали один за другим. Заключенные растекались по всей степи – одни строили железную дорогу Карабас-Моинты, другие – бараки скотобазы, кошары, жилье для начальства, казармы для ВОХРа, штрафные изоляторы – ШИЗО. Для этого строительства зачастую разбирались старые постройки. Строго запрещалось использовать для этих целей саманный кирпич из стен казахских могильников, но запрет зачастую нарушался. Управление Карлага подчинялось только ГУЛАГу НКВД, которое находилось в Москве. Республиканские и местные партийные и советские органы никакого влияния на деятельность руководства Карлага не имели. Карлаг был образованием колониального типа со своей метрополией в Москве. Аппарат управления был довольно громоздким. Отделы: административно-хозяйственный (АХО), учетно-распределительный (УРО), контрольно-плановый (КПО), культурно-воспитательный (КВО), отдел кадров (для вольнонаемных), снабжения, торговли, третий опер-чекистский (ОЧО), лечебный, финансовый, транспортный, политотдел, Спецотдел. Был большой производственный отдел земледелия, куда входили службы землеустройства, мелиорации и ирригации, животноводства и ветеринарии (ветбаклаборатория, центральная ветаптека), механизации.

Ученик 7: В Карлаге усилиями заключенных были построены мясокомбинат и промкомбинат (кожи, валенки, полушубки), стекольный и сахарный заводы, ремонтный завод и ремонтные мастерские, маслозавод, маслобойка, мельницы, пошивочные мастерские, овощехранилища, овощесушилки и т.д. В лагере была прокуратура, лагерный суд и тюрьма. Действовал большой учебный комбинат для подготовки кадров средней и массовых квалификаций из числа заключенных. Для детей вольнонаемных в Долинке была полная средняя школа и интернат. При управлении лагеря были организованы СХОС (сельскохозяйственная опытная станция по растениеводству) и НИС (научно-исследовательская станция по животноводству). Обе станции имели собственные экспериментальные (опытные) базы. Кроме того, действовала специальная экспедиция по нагулу крупного рогатого скота и овец. В Карлаге было около 20 сельскохозяйственных отделений (совхозов) со своими производственными участками и фермами. Связь между управлением и отделениями лагеря осуществлялась посредством собственной почтовой службы и по радио».

Учитель литературы: Безжалостный каток репрессий прокатился по всему бывшему Советскому Союзу, подмяв генофонд страны. Тысячи людей были расстреляны, миллионы подвергнуты моральным и физическим унижениям и мучениям, а их семьи и близкие обречены на долгие годы страданий и бесправного существования. Нам известны имена советских писателей, которые попали в сталинский режим репрессий: А. Солженицын, В. Шаламов, Н. Заболоцкий, Н. Гумилев, О. Мандельштам, Б. Пильняк. С произведениями этих писателей мы будем знакомиться на уроках русской литературы.

Учитель истории: Жизнь и творчество Аяза Гилязова затрагивает интересные факты из жизни нашей страны. Где простой народ переживает всю тяжесть репрессивной машины. У писателя много последователей. И отрадно, что это прежде всего его сыновья: Мансур Гилязов – драматург, чьи пьесы ставятся на сцене театра Г. Камала; Искандер Гилязов – научный деятель, который посвятил себя изучению истории татарского народа и развитию татарской драматургии; Рашат Гилязов – предприниматель.

Токранова Эльвира Ильяс кызы
Балык Бистәсенең 2 нче урта мәктәбе, Балык Бистәсе районы

**Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” повестенда шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләре**

**Максатлар:** А.Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәрендә шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләре бирелешен ачыклау. Тема аша язучы иҗатының төп юнәлешләренә ачыклау. Әдәби әсәрләр укуга, язучы иҗатына кызыксыну, әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

***Шәхескә кагылышлы:*** Шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләрендә үз-үзеңне тота белү, кешелекле булып кала белү турында төшенчәләрне аңлауга ирешү.

***Метапредмет:***

*Танып-белү УУГ:* уку мәсьәләсен чишү максатында анализ башкару, сәбәп- нәтиҗә бәйләнешләрен кора белү, гомумиләштерүләр ясау;

*Коммуникатив УУГ:* хезмәттәшлек итү, әңгәмәдә катнашып үз фикереңне белдерү, дәлилли белү;

*Регулятив УУГ:* уку мәсьәләсен куя белү, төркемнәрдә эш күнекмәләрен максатчан файдалану, бер- береңне бәяли белү һәм үзбәя.

***Предмет:*** Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” повестенда шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләренең ничек ачылуын аңлау.

**Дәрес тибы:** белемнәрне ныгыту дәресе

**Методлар һәм алымнар:** Күрсәтү-аңлату, эзләнү, әңгәмә, сүзлекләр,текстлар белән эш, төркемнәрдә эш, гомумиләштерү һәм нәтиҗәләр ясау.

**Дәресне җиһазлау:** Ярдәмлек һәм белешмә әдәбият, мультимедиа презентация, язучы китапларыннан күргәзмә, биремнәр язылган карточкалар һәм текстлар.

**Кулланылган әдәбият:**

Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге.- Казан: Мәгариф, 2007.-231 б.
Татар теленең аңлатмалы сүзлеге.Ф.Ганиев ред.- Казан: “Матбугат йорты”, 2005
Татар әдәбияты тарихы. 6нчы том. 60-90нчы еллар.- Казан. “Раннур”,2001
А.Гыйләҗевнең китаплары.

**Дәрес барышы:**

| Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге |
|---|---|
| **I. Оештыру- мотивлаштыру**<br>-Исәнмесез, укучылар! Без бүген төркемнәрдә эшләячәкбез. Мин сезнең бер- берегезгә ярдәм итеп, янәшә утыруның җылылыгын тоеп эшләвегезне телим.Сез бер җәмгыять. Төркемнәрдә башлап йөрүчеләрне билгелик. Бүгенге дәрес һәркайсыбыз өчен файдалы булыр дип өметләнәм. (слайд1) | - *Төркемнәрдә лидерлар билгеләнә.* |
| **II. Актуальләштерү**<br>- Әйтегез әле, сезне алдаганнары, кыерсытканнары бармы? Сез мондый очракта ни эшлисез, нинди хисләр кичерәсез? Әгәр дә сезне өлкәннәр кыерсытса, кимсетсә? Әгәр дә сезне шул чакта кем дә булса якласа, сез аңа рәхмәтлеме?<br>- Укучылар, кызганыч, кешелек законнарын бозсалар да, кайбер кешеләрнең гаделсезлегенә куркып күз йомабыз, я әйтми калу яхшырак дип уйлыйбыз... Кешеләрнең бергә яшәү даирәсе “җәмгыять” дип атала. Әйдәгез, аның төгәлрәк билгеләмәсен белик әле, “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”нә мөрәҗәгать итәбез. | *Көтелгән җаваплар:*<br>*-Әйе.*<br>- Ачу килү, аралашмау, елау, кемгәдер ярдәмгә мөрәҗәгать итү<br>- Дәшми калырга да мөмкин. Ачуыңны йоту, яки аралашмау.<br>- Әйе, әлбәттә. |

| | |
|---|---|
| “Тормышта аерым бер тарихи шартларда берләшкән кешеләр бергәлеге” Димәк, бер заманда яшәүчеләр без барыбыз да җәмгыять. (слайд 2)<br>- Бәхеткә каршы, кешелек җәмгыятенең уңышсыз якларын ачып салучылар да бар безнең арада. Шундыйларның берсе – язучы А.Гыйләҗев. Аның тормыш юлын искә төшерик әле.(слайд 3)<br>- Укучылар, язучы биографиясендә аның иҗат тематикасына нык тәэсир иткән, дәреслектә язылмаган эпизодлар да бар. Димәк, аның уй- фикерләре һичкемгә зыян китермәсә дә, җәмгыятьнең кайбер вәкиләре башкача уйлаган, төрле әләкләүләр аркасында егетне университеттан куалар һәм ирегеннән мәхрүм итәләр. Язучы башка сез белгән күп язучылар: Х.Туфан, Ш.Усманов, Г.Ибраһимовлар кебек үк .1950-1955нче елларда сөргендә булу да язучының хөр уйларын бүлми, ул әсәрләрендә кешелек кануннарын бозучыларны фаш итүне дәвам иткән. (слайд 4,5) | 1 укучы тормыш этапларын искә төшерә. |
| **III. Уку мәсьәләсен кую**<br>- Сез өйрәнгән “Язгы кәрваннар” әсәре җәмәгатьчелектә зур бәхәс уяткан әсәрләрнең берсе. Әсәр ни турыда? Менә хәзер төркемнәрдә эш башлыйбыз. Кем барлык тематик яссылыкларны да билгели алыр икән? Арада иң әһәмиятлесе төп тема була. Безнең максатыбыз - шуны ачыклау. (слайд 6,7) | - төркемнәр тематиканы билгели. (якынча җаваплар)<br>1. Сугыштан соңгы чорда авыл халкының авыр тормышы.<br>2. Кешеләрнең үзара ярдәмчеллеге, бердәмлеге.<br>3. Мәхәббәт. |
| **IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү**<br>- Мәхәббәт темасы кайсы образлар аша тасвирлана? Әдилә белән Ибраһимның хисләре ничек күрсәтелә?<br>- 2,3 темалар буенча төркемнәрдә сөйләшик әле. Һәр төркем әсәрдә нәкъ шушы тема булуына дәлилләр табарга тиеш. (слайд 8) | (якынча җаваплар)<br>1 Ашарларына юк. Колхозда симәнә дә калмаган. Бергә ашаган чактагы ризыклар. Киенү рәвешләре.<br>2 Ибраһим, Дамирның барысы өчен чана тартуы. Ярлы күршеләрдән үзләренә өйгә чакырулары. |
| **Ял минуты.** Басабыз. Кулларны тоташтырабыз- чылбыр буенча, үзәккә. Кулларыбызны иң башына куябыз. Аркаларны терәп басабыз. Мин сезнең шушындый бердәм булуыгызны телим, укучылар.Бәлки төркемнәрнең бер- берләренә сораулары бардыр? | Ял моменты. Физик күнегүләр. |
| Мин сезгә өй эшә итеп сугыштан соңгы чор балалары, ягъни сезнең әби-бабаларыгызның бала чакта күргәннәрен сорашырга бирем биргән идем. Әйдәгез сөйләп карыйк әле. | -берничә укучы фикере, әсәрдәге чорлардан соң булса да, сугыштан соң илнең аякка озак басканын аңлау; |
| **V. Беренчел ныгыту**<br>Укучылар, әсәрдәге төп теманы ачыклау өчен мин сезгә әсәрнең тулы вариантыннан өзек тәкъдим итәм. Ул ни турыда, ачыклыйк әле.<br>-Кәслегә кешеләр ни өчен барган иде?<br>- Аларның авылы кайсы глубинкага якынрак?<br>- Сабирәттәй нигә үлә?<br>- Каршыга очраган кешеләр Сарсазга нигә киләләр?<br>- Алар әйткән сүзләр белән килешәсезме?<br>- Хәкимҗан абыйның әйткән сүзләрен бәяләгез.<br>- Ул нигә Әдилә белән Ибраһимга дөреслекне әйтергә кушмый? (слайд 9,10,11) | *Укучыларга биремнәр язылган карточкалар тәкъдим ителә. Алар төркемнәрдә сорауларга җавап әзерлиләр һәм кем җавап бирәчәген ачыклыйлар. Сорауларга җаваплар алына, өстәмәләр кертелә.* |
| **VI. Рефлексия . Өйгә эш.**<br>Әлеге вакыйганың килеп чыгуы - кемнәрнеңдер уйлап бетермәвендә. Ә бит ул кеше гомеренең өзелүенә сәбәче булды. | (якынча җаваплар) |

| | |
|---|---|
| Җәмгыятьтә һәркемнең үз урыны бар дигән идек. Кеше шул урынны бизәп тора. Үз вазифаларын төгәл башкарган кешеләр булган җәмгыять гадел булачак.<br>- Һәр төркем әсәрдәге вакыйга турында үз фикерен әйтсен иде. Ә бүгенге көндә аңлашылмаучылык, төгәлсезлек, җавапсызлык аркасында мондый вакыйгалар килеп чыгарга мөмкинме? Мин сезгә җәмгыятьтә үз урыныгызны табуыгызны телим.<br>Төркемнәрнең эшен бәяләү, укучыларга билгеләр кую. Өй эше. Түбәндәге темалардан берсен сайлап, үз фикереңне яз: " Кеше кадерен кеше белергә тиеш", " Сыйныфыбыз укучылары яхшырак укысын өчен мин ни эшли алам?"<br>Дәрес тәмам. Уңышлар сезгә. | - Җәмгыятьнең кешеләр коллективы булуын искә төшерү, кайсы заманда да эшнең уңышы кешеләрдән торуы турында фикерләр, җавапсызлыкны тәнкыйтьләү сүзләре<br>- Хөкүмәт, җитәкчеләрнең кеше хокукларын яклау буенча эшчәнлек алып барырга тиеш булуы. |

Идрисова Гөлшат Язкәр кызы,Әсәдуллина Әлфия Мансур кызы,
аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче, Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе,
Сарман районы

**Җәннәт аналарның аяк астында**

(Аяз Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән "әсәре һәм М.Гыйләҗевнең "Бибинур" фильмы аша ана образын ачу. 11 нче сыйныфның татар төркеме)

**Максат**: Әсәрнең эчтәлегенә төшенү,идеясын ачыклау. Укучыларда иҗади фикерләү сәләтен үстерү, үз хисләрен һәм фикерен эзлекле, матур, төгәл итеп әйтә, аңлата белүләренә ирешү. Игелеклек, мәрхәмәтлек, шәфкатьлелек, намуслылык сыйфатлары тәрбияләү, әниләргә карата мәрхәмәтле булырга, ата-ана хакын белергә өйрәтү.

**Материал**: А.Гыйләҗев "Җомга көн кич белән "китабы

**Җиһазлау:** А.Гыйләҗев портреты, әсәр буенча презентазия, М.Гыйләҗевнең "Бибинур"фильмының видеоязмасыннан өзек, А.Гыйләҗевнең төрле елларда басылып чыккан китапларыннан күргәзмә,"Сөембикә " журналларыннан өзекләр.

**Метод һәм алымнар**: проблемалы укыту,әңгәмә

Дәрес барышы

1.**Оештыру, уңай психологик халәт тудыру.**

**2.Төп өлеш.**

Укытучы: Әй, хәтирә, хәтер баласы,
Һәр көн саен атлап кая барасың?
Тормышта бит хәзер бик күпләре
Онытып бара газиз анасын.
Газиз әнкәләрен кирәклеген
Нигә онытабыз икән иртәрәк.
Бала, тыныч кына утырып, уйлап кара?
Әнкәеңә күрсәт, кадер, хөрмәт!
Гомер кыска уйла, бала, соңга калма!

Кешеләрдә яхшылык сыйфатлары кими баруың сәбәпләре нәрсәдә? Бу күренеш заманга бәйлеме икән? Бүген дәрестә шулар хакында сөйләшербез. Хәзер "Җомга көн кич белән" повестена якынрак килик. Әсәр ничек башланып китә? (Кötелгән җавап: картаюны кешеләр төрлечә кичерә: күзләре начар күрә, аяклары йөрмәс була...)

- Бибинур да шушы ук хәлне кичерәме? (Бибинур картлыкны башка төрле тоя.Ул табигатьнең матурлыгын тоймас була. Кошлар сайравына игьтибарсыз, тургайлар килүен сизми, гөрләвекләр тавышы белән хозурланмый).

- Бибинур зиратка ни өчен бара? (Үзендә җаваплылык сизә, өч баланы үзенә алуы белән Гайшә алдында үзем бурычлы саный, булган мәшәкатьләрен Гайшә белән генә сөйләшә, уртаклаша ала).

- Әни! Дөньядагы бердәнбер иң матур, иң кадерле, иң татлы сүзләрнең берсе. Әниләрне бәхетле итү өче без нәрсәләр эшли алабыз?

-Укучылар, ни өчен Бибинур балаларын Сабан туена көтә? (Туганнар очраша торган иң зур бәйрәм ул.Үзләренең тамырларын белмәсәләр, буыннар чылбыры югалыр, дип курка).

- Бибинур тормыш белән авыл халкы арасындагы каршылык нәрсәләрдә чагыла? (Бибинур балаларын гел аклый, авыл халкына үпкәли. Авыл халкы балаларының самоварына кадәр алып китүләрен гаепли, әниләрен онытуын кискен хөкем итә).

- Бибинур белән балалар арасындагы каршылыкны нәрсәдә? (Бибинур – изге, беркатлы, балаларын һәрвакыт аклый, гомерен алар өчен корбан итә. Балалар – комсыз, мәрхәмәтсез, әниләрен өйне таратып бетерүдә гаеплиләр, әниләренә түбәнсетеп карыйлар).

- Бибинур белән табигать арасындагы каршылыкны күрсәтегез. (Бибинур – этләрне ашата, карый, ә алар аны талап үтерәләр.

-Укучылар, нинди нәтиҗә ясап була? (Бөтен яшьлеген, тырышлыгын балаларга биргән Бибинурны балалар бар дип тә белмиләр, бернинди хөрмәт хисләре юк. Бу – балалар тарафыннан булган мәрхәмәтсезлекнең иң югары ноктасы. Улы үзен үстергән ана белән телефоннан сөйләшүне дә кирәк тапмый).

- Әсәр белән фильмның азагын искә төшерик әле. Ике Бибинур арасында нинди аерма бар? (Әсәрдә гомере буе яхшылык кына эшләп яшәгән Бибинур мәгънәсез үлем белән үлә. Фильмда Бибинур заманга ярашканрак, буыннар чылбырын саклап калу өчен, үзенең гомере бәрабәренә Җиһангирне коткарып кала).

-Укучылар, дәрес башында бирелгән сорауга җавап бирик инде хәзер. Кешеләрдә яхшылык сыйфатлары кими баруың сәбәпләре нәрсәдә? Бу күренеш заманга бәйлеме?

- Әйе, укучылар, тормыш артыннан куып, туганлык, үзара ярдәмләшү, олыларны олы итү, мәрхәмәтлек, миһербанлык сыйфатлары югалып бара. Бу сыйфатларның югалуы олы фаҗигаләргә китерә. Бүгенге көндә күпме ата-ананың балалары тарафыннан кимсетелеп, йортларыннан куып чыгарылуы, картлар йортына элэгүләре турында, ул гына да түгел, хәтта үтерүгә барып җиткән очраклары да көндәлек матбугат битләреннән дә, зәңгәр экраннар аша да күреп-ишетеп торабыз. Хәзер шул темага караган кайбер мәгълүматларны карап китик әле.(Слайдлар карала). Укучылар ,бүгенге тема сездә нинди хисләр калдырды? (Балалар эти-әниләргә мәрхәмәтле булсыннар иде, аларга булышсыннар, авыр сүзләр әйтмәсеннәр, рәнҗетмәсеннәр иде).

- Әлеге темага багышланган тагын нинди әсәрләр укыганыгыз яки фильмнар карагныгыз бар? (Әмирхан Еники “Әйтелмәгән васыять”, “Матурлык”, Шәриф Камал “Буранда”, Хәсән Сарьян “Бер ананың биш улы “, Туфан Миңнуллин “Әниләр һәм бәбиләр”, Шәриф Хөсәенов “Әниемнең ак күлмәге “ һ.б.)

- Ә нинди мәкальләр беләсез? (Җәннәт – аналарның аяк астында. Ана күңеле – балада, бала күнеле – далада. Баланың бармагы авыртыр, ананың йөрәге авыртыр. Ана янында бала ятим булмый).

**Ш.Йомгаклау өлеше .**

Өй эше бирү: ”Ана – бөек исем“ темасына инша язарга.

Билгеләр кую. Дәрескә йомгак.

Гыймалетдинова Нурзия Минәхмәт кызы,
Кизләү төп гомуми белем мәктәбе, Алексеевск районы

**Бәхет өчен нәрсә кирәк?**

*(* XI сыйныфта А. Гыйләҗевнең*“Әтәч менгән читәнгә”* әсәрен өйрәнү дәресе эшкәртмәсе)

**Максат:** Язучы Аяз Гыйләҗевнең иҗатына күзәтү ясау. Әсәргә анализ ясау барышында әсәрдә уздырылган төп фикерләрне ачыклау, образларны барлау, аларга бәя бирү. Әсәрдә күтәрелгән төп проблемаларны табу. Язучының әдәбиятка керткән яңалыгын ачу. Укучыларда Аяз Гыйләҗев иҗаты белән кызыксыну хисе уяту. Бәйләнешле сөйләм үстерү. Укучыларда әдәп-әхлак кагыйдәләре булдыру. Дуслык-туганлык хисе тәрбияләү. БӘХЕТ төшенчәсен анлауга ирешү.

**Җиһазлау:** дәреслек, язучының портреты, китаплар күргәзмәсе, язучы иҗатына багышланган тестлар, мультимедиа, компьютер, магнитофон, язучының тормышын чагылдырган рәсемнәр.

**Дәреснең барышы:**

Эпиграф: *“ Бәхет өчен нәрсә кирәк?”* **(Әсәрдән китерелгән сүзләр)**

**1. Оештыру.** Укучыларны барлау. Сәламләү.

-Исәнмесез, укучылар. Кәефләрегез ничек? Барыгызга да хәерле көннәр, яхшы кәеф теләп әдәбият дәресебезне башлыйбыз. Бүгенге дәресебезнең максаты – Аяз Гыйләҗевнең “Әтәч менгән читәнгә” әсәренә анализ ясау. *(*Эпиграфны укыла. Укучыларга: ”Нәрсә ул бәхет?” соравы бирелә.( Җаваплар тыңлана). Безгә бу сорауны әсәр герое Җәмил бирә.

“Аяз Гыйләҗев – татарның әдәби мирасына зур өлеш керткән язучы. Аның әсәрләре – һәрберсе милләт, ил язмышына битараф булмаган оста каләм иясе кулы белән язылган хәзинәләребез. Аяз Гыйләҗев әсәрләренең тәрбияви кыйммәте әйтеп бетергесез зур. Алар – безнең милләтебезнең рухи байлыгы, милли үзенчәлекләре турында чорыбыз вакыйгаларына бәйләп язылган әдәби әсәрләр. Безнең чор кешеләренең яшәү рәвешләрен киләчәк буыннарга да алып бару вазифасы тапшырылган аларга. Ул күпләргә үрнәк булырлык төпле гаилә башлыгы, тирән фикер иясе булды. Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең мирасын яратып һәм хөрмәт итеп яшәсәк, рухи офыкларыбыз киңәер” Минтимер Шәймиев

“Аяз Гыйләҗев турында уйлаганда, әсәрләрен укыганда, ул бәгырьләрне тетрәндерерлек дәрәҗәдә якын булып күз алдына баса. Шул ук вакытта ул буй җитмәс еракта, биеклектә торгандай. (Якташ язучыбыз Т.Галиуллин сүзләре) (Бу сүзләр язып куелган. Укытучы балалар белән укый.)

Аяз Гыйләҗев “Җомга көн кич белән...”(1979) һәм “Әтәч менгән читәнгә”(1980) повестьлары өчен 1983 елда Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

**II. Үткән дәрес темасын актуальләштерү.**

Аяз Гыйләҗев турынданиләр беләсез? (Укучылар чыгышы. А.Гыйләҗевнең биографиясен сөйләү (презентация күрсәтелә).

Аның нинди әсәрләрен беләсез? (Укучылар чыгышы).

**1нче укучы** Прозаик һәм драматург Аяз Мирсәет Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югар Баграҗ авылында уза. Авыл мәктәбенең тугызынчы сыйныфын тәмамлагач, унынчы сыйныфны Сарман урта мәктәбендә укый. 1948-1950 елларда ул – Казан дәүләт университеты студенты. Аңа да

шәхес культының газапларын татырга туры килә. 1950 елның мартыннан башлап 1955 елның августына кадәр Казахстанда тоткынлыкта була. Казанга кайткач, университетта укуын дәвам итә. 1957 елның мартыннан 1961 елның августына кадәр А.Гыйләҗев матбугат эшендә: “Чаян” һәм “Азат хатын” (хәзер “Сөембикә”) журналлары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, “Совет әдәбияты” (“Казан утлары”) журналында проза бүлеге мөхәррире вазифаларын үти. 1961-1963нче елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укып кайтканнан бирле Аяз Гыйләҗев, язучы-профессионал сыйфатында, әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә.

Аяз Гыйләҗевнең башлангыч иҗат тәҗрибәләре студентлык чорына карый.Ләкин аның актив иҗат эшчәнлеге 1956 елдан башлана дияргә булა.

**2 нче укучы** Беренче әсәрләрендә үк анык сиземләнгән язу манерасы – кырыс реализм, халыкчан образларга бай җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары, кайсы чор турында һәм нинди темага язса да, кеше шәхесенең катлаулы рухи дөньясын, эш-гамәлләрен анализлау – А.Гыйләҗев иҗат эшчәнлегенең төп асылын, идея-эстетик юнәлешен тәшкил иткән сыйфатлар. “Өч аршин җир”, “Зәй энҗеләре”, “Урталыкта”, “Язгы кәрваннар”, “Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят”, “Җомга көн кич белән”, “Әтәч менгән читәнгә” әсәрләре белән Аяз Гыйләҗев үзен повестьлар остасы итеп танытты.

Тематик яктан А.Гыйләҗевнең күпчелек повестьлары авыл тормышына багышланган. Аларда кичәге һәм бүгегенге авыл, аның гади кешеләре гәүдәләндерелә.

Аяз Гыйләҗев – ике дистәдән артык драма әсәре авторы да. Аларның күбесе республика театрлары репертуарына кертелгән.

“Җомга көн кич белән” һәм “Әтәч менгән читәнгә” повестьлары өчен А.Гыйләҗев 1983 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Әдәбиятны һәм театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен аңа 1978 елда Татарстанның, ә 1985 елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә. Ул – М.Горький исемендәге премия лауреаты да.

Иҗади эшчәнлегенең соңгы елларда А.Гыйләҗев роман жанрында иҗат итүгә күп көч куйды. Аның бер-бер артлы “Балта кем кулында” (роман), “Йәгез, бер дога!” (роман-хатирә) кебек зур күләмле әсәрләре дөнья күрде.

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен 1993 елда, Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Аяз Гыйләҗевкә Татарстан Республикасының халык язучысы дигән мактаулы исем бирелде.

Аяз Гыйләҗев 2002 елның 13 мартында вафат булды. (Гыйләҗевләрнең нәсел шәҗәрәсе күрсәтелә)

**Укытучы.** Аяз Гыйләҗевнең “Әтәч менгән читәнгә” әсәрен өйдә укып килергә кушылган иде. Әсәр сезгә ошадымы? (Укучыларның җавабы тыңлана.)

**III Уку мәсьәләсен чишү.** Әсәргә анализ ясау . Әдәби әсәрнең жанры – повесть.

**Укытучы.** Повесть жанры әдәбиятның чәчмә әсәрләр төренә керә. Күләме ягыннан хикәядән зур, романнан кечкенә. Төзелешендәге үзенчәлек – повестьта янәшә килүче ике яки өч сюжет сызыгы була. (Әсәрнең эчтәлеген искә төшерү).

**3нче укучы**га сүз бирелә. Элек дус, ярдәмләшеп яшәгән Мирфатыйх белән Сәләхетдин һәм аларның гаиләсе арасында булган дуслык югала, читән биегәя, аның арасыннан кояш та үтми башлый. Капкалар бикләнә. Гаилә әгъзалары бер-берсен күрәалмас дәрәҗәгә җитә. Һәр кеше конфликтка керә.

**Укытучы**. Аларның сәбәпләрен түбәндәге таблицадан күреп була

Сәләхетдин – Мирфатыйх: байлык җыю

Зәйтүн – Әнәс: усаллык, шуклык, мактанчыклык, начар уку – яхшы уку)

Вәзилә – Җәмил: намуслылык, мәхәббәт

Гөлбикә – Гөлмәрьям: көнчелек

Хәйдәр – Мидхәт: көнчелек

Хәйретдин – Зәйтүн: узганнарга хөрмәт югалу

- Әсәрнең идеясен табыйк. Идея – авторның теләге. Язучы нәрсә әйтергә тели? (Бәхетне кеше тырыш хезмәте белән эшләп табарга тиеш, ди. Әсәрнең темасы – байлык артыннан куып, кешеләрнең бер-берсенә ихтирамы югалу, мәхәббәтнең кадере китү, мал җыю, олыларга, үткәннәргә хөрмәт югалу).

**Укытучы.** Әсәрдәге сюжет сызыкларын билгелик. (Укучыларның җаваплары тыңлана). Нәтиҗәләр ясыйк. (Шулай бер-берсеннән көнләшеп, уздырырга теләп диван һәм башка җиһазлар, машиналар алына, мунчалар салына. Балалар арасындагы дуслык бетә.

Бу сюжет сызыклары, вакыйгалар үстерелеше рәвешендә төп сюжет сызыгы белән кисешәләр. Беренче бүлек – төп сюжет сызыгының **төенләнеше**. Сәләхетдиннәр читәненнән Мирфатыйхлар әтәче егылып төшә. Аңа Сәләхетдиннең төпчек малае Зәйтүн рогаткадан аткан икән. Моны күргән Хәйретдин агай гауга чыкты дип уйдый.

Вакыйгалар үстерелә, ике гаилә мөнәсәбәтләре ачыклана бара. Мидхәт белән Хәйдәрнең, узышып, машина бәрдерүе, шул вакытта Гөлбикәнең кулы сыну, ә өйдә Мирфатыйх белән Сәләхетдиннең ызгышып, соңгысының хатыны кебек кулын сындыруы – әлеге мөнәсәбәтләрнең иң биек **(кульминицион) ноктасы**.

**Укытучы**.Автор күтәргән проблемалар турында сөйләшик. (Байлыкның көнләшү китереп чыгаруы. Мәхәббәтне байлык яки үз теләгеңә алмаштыру. Игелекле кешенең хөрмәтле булуы. Авылда матурлык, үткәннәргә хөрмәт югалу. Татар авылына эчкечелек, комсызлык үтеп керү. Хатын-кыз тыйнаклыгының югалуы.

Сюжет сызыгы элементлары табыла. Мисаллар белән аңлатыла

БАШЛАМ. Әсәрнең башланып китү күренеше.

ТӨЕНЛӘНЕШ. Әтәч читәннән егылып төшә.Гауга чыга.

ИҢ ЮГАРЫ НОКТА. Машина белән бәрелү вакыйгасы.

ЧИШЕЛЕШ. Хәйретдин агай авырып китә, Мирфатыйх белән Хәйретдиннең туганнар булуы ачыклана.Хаталарын аңлау

**V Әсәрдә образлар бирелеше.**

**Укытучы.** Укучылар, әсәрдәге Мирфатыйх, Сәләхетдин, Гөлбикә, Гөлмәрьям, Зәйтүн, Әнәс, Вәзилә, Җәмил, Хәйдәр, Мидхәт, Хәйретдин агай образларына характеристика бирегез. Төп һәм ярдәмче образларны билгеләгез. Үзегезгә ошаган образны табыгыз. (Күпчелек укучылар Хәйретдин образын ошаткан: Хәйретдин агайның тормышы күркәм. Ул үзе эшчән һәм юмарт, ярдәмчел һәм акыллы, яхшы күңелле кеше. Тормыштагы хәлләргә битараф булып кала алмый, борчыла, ярсый. Кешеләрнең пошмас җанлы булуына йөрәге әрни аның. Кешеләрнең битараф булуына борчыла ул. Әсәрдә каберлекләрне карап, чистартып тәртиптә тотарга кирәклеген әйтә).

**5нче укучы.** Әсәрнең символлары – әтәч һәм читән. А.Гыйләҗев бик оста итеп символларга мөрәҗәгать итә, гыйбрәтле образлар иҗат итә. Җәмгыятьтәге тискәре күренешләрне тәнкыйтьли, тормыштагы матурлыкны күрсәтә белә. Байлык артыннан куып, кешеләр дошманлашып бетәләр. *(Р. Фәхретдин сүзләре китерелә).*

VI. Рефлексия Дәрестә ниләр эшләдек? Ниләр белдек?

VII. Нәтиҗә ясала.

**Укытучының йомгаклау сүзе.** Якташ шагыйребез Гакыйль Сәгыйров сүзләренә язылган “Бәхет бит ул” җыры укытучы башкаруында тыңлана.

Аннары дәрес башында ук куелган сорауга җавап алына. (Сәламәтлек, әти-әниең, туган телең, туганнар-дуслар, яраткан хезмәтең, яраткан кешең булу, кешеләргә файда китерү һ.б.).

Укучыларга рәхмәт әйтеп, билгеләр куела, өй эше бирелә:

1. “Әтәч менгән читәнгә” повестенда миңа ошаган образ”

2.“Әхлаклылы кеше – бәхетле кеше” темасына сочинение язарга.

Габдулхакова Инсия Зуфаровна, Зямилова Гульнур Раисовна,
«Джалильская СОШ№2», Сармановский район

**Классный час: «С любовью к животным. Знакомство с творчеством АязаГилязева»**

**Цель:** Воспитание учеников, как активных, отзывчивых людей. Воспитание гуманных общечеловеческих качеств у детей – забота, сострадание животным.

**Материалы для занятия**: рассказ Аяза Гилязева «Муйнак»

**I.Беседа о доброте, о добром отношении к животным.**

**Учитель:** Дорогие друзья! Перед тем как сообщить тему нашего разговора я хочу вас спросить: Кто себя считает себя добрым человеком?(Поднимают руки). Кого можно считать добрым человеком?

-Что означает понятие доброта?(Ответы детей)

**Учитель:** Это были ваши мысли, высказывания, рассуждения о доброте. А вот как объясняет понятие доброта толковый словарь Ожегова: «Доброта – это отзывчивость, душевное расположение к людям, стремление к бескорыстной помощи ближнему». По отношению к кому можно совершать добрые дела, поступки?(Близким людям, товарищам, животным).

**1 ученик.** 4 октября отмечается Всемирный день защиты животных. Решение празднования всемирного дня животных было принято в 1931 году на международной конференции сторонников движения защиты животных, проходивших во Флоренции.

**2 ученик.**4 октября - день ангела и день смерти монаха Франциска Ассизского. Он основал орден, носящий его имя, и считается защитником и покровителем животных. На протяжении всего эволюционного пути животные стали незаменимыми помощниками в человеческой деятельности.

**Учитель:** Ребята, у кого из вас есть дома животные? ( Ученики поднимают руки и рассказывают о том, какие животные содержатся в доме)

**Учитель***:* Как вы думаете, ребята, от кого нужно защищать животных домашних или диких? (От жестокого обращения людей с животными, от стихийных бедствий, например, от пожаров и наводнений)

**II. Беседа об отношениях людей к животным по рассказу Аяза Гилязева «Муйнак»**

**Учитель:** Расскажите, как появился во дворе Муйнак? (Принёс Халим)

- Смог ли Муйнак подружиться с другими животными? (ученики рассказывают).
- Как заботился Халим о своём друге Муйнак?
- Какой собачкой подрос Муйнак?
- Почему житель деревни Тажетдин невзлюбил собаку?
- Чем закончился рассказ?

- Почему Халим не смог защитить своего друга?
- Как отражается в рассказе «Муйнак» жестокое отношение людей к животным?

**III. Иллюстрирование рассказа АязаГилязева «Муйнак»** (ученики показывают свои рисунки и рассказывают)

**IV.Знакомство с биографией АязаГилязева.**

**1 ученик**. Аяз Гилязов родился 17 января 1928 года в селе Сарманово в семье учителя. Детство провёл в деревне Верхний Багряж (Заинский район). Получил неполное среднее образование в местной школе. Вернулся в родной район, где окончил Сармановскую среднюю школу. В 1948 году поступил в Казанский государственный университет.

**2 ученик.** В 1950 году был арестован и сослан в карагандинский лагерь, где содержались даже лауреаты Сталинских премий. Там Гилязов находился пять лет. В 1955 году был реабилитирован.

**3 ученик.** После освобождения вернулся в Казань и продолжил учёбу. Через полтора года начал сотрудничать с журналами «Чаян» и «Азат хатын». Стал редактором отдела прозы журнала «Совет эдэбияты» (сейчас «Казан утлары»).

**4 ученик**. В 1963 году окончил Высшие литературные курсы при СП СССР. После этого стал считаться профессиональным писателем. Писал рассказы, очерки, фельетоны, статьи. Позднее излюбленным жанром Гилязова стала повесть. Аяз Гилязов скончался 13 марта 2002 года.

**Учитель.** В каких ещё рассказах Аяз Гилязев написал об отношениях детей к животных? (“Алсу, Илдус һәм сандугач”, “Матур”)

**V.Итог**

**Учитель**: Нельзя обижать, и другим не позволять обижать животных, таких же существ, как и мы с вами. Будем к ним чувственны и милосердны. Ведь только ничтожный и слабый духом человек может обидеть животное. Не давайте в обиду и не обижайте наших меньших братьев. Любите животных, берегите и защищайте их.

Габдуллина Раушания Сәлим кызы,
Түбән Каманың 29 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе

## Сагынабыз сине, Аяз абый!

(Әдәби-музыкаль кичә)

Зал бәйрәмчә бизәлә. Экранда әдипнең портреты, "Сагынабыз сине, Аяз абый!" дип исемләнгән әдәби газета урын ала, әдип иҗаты турында түбәндәге фикерләр яктыртыла:

Аяз Гыйләҗев – татарның әдәби мирасына зур өлеш керткән язучы.

Татарстан Республикасының Беренче Президенты Минтимер Шәймиев

Аяз Гыйләҗев – әдәбиятыбызның төрле тармакларында ат уйнаткан кеше. Ул күренекле прозаик, үзенчәлекле драматург, үткен каләмле публицист һәм очеркист, ниһаять, усал телле тәнкыйтьче.

Фәрваз Миңнуллин.

Халык язучысы Аяз абыйның мирасы татар халкы өчен генә түгел, бөтен кешелек дөньясы өчен зур хәзинә! Һәм ул Мәңгелек! Аяз Гыйләҗев – киләчәктә иң укылачак, алай гына да түгел, бер кулыңа килеп эләккәч, кат-кат укылачак әдип! Ул – милләтебез горурлыгы.

Фаил Ибраһимов.

1 алып баручы. "Әдәбият" дип аталган Йолдызлыктан үзләренә рухи азык алучылар – бәхетлеләр. Бәхетлеләр, чөнки бу Йолдызлык үзенә нурны Тукайлар, Әмирханнар, Җәлилләр, Исәнбәтләр, Еникиләр һәм башка бик күп олпат әдипләребезнең илһам чишмәсеннән ала. Сүзебез шушы Йолдызлыкның якты бер нуры булып балкыган әдибебез Аяз Гыйләҗев турында.

2 алып баручы. "Бәләкәй чакта сукмаклар синеке! Ялантәпи, тып-тып басып, дөнья белән танышу әнә шул җәяүле сукмаклардан башлана. Кая карасаң да, сиңа ят ярлар, моңарчы син күрмәгән, күрә дә алмаган сер дөньясы", - дип яза Аяз Гыйләҗев "Балачак сукмаклары" дигән истәлегендә. А.Гыйләҗевнең балачак сукмаклары кайчан, кайда башланган соң? Шуның белән тулырак танышыйк.

1 укучы. Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районындагы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Әтисен Югары Баграж авылына укытырга җибәрәләр. Балачагы, яшьлеге шул авылда, язучы сүзләре белән әйткәндә, "юмарт күңелле, кунакчыл, гади, үтә кешелекле, риясыз-хәйләсез керәшеннәр арасында" үтә.

2 укучы. Авыл мәктәбенең тугызынчы сыйныфын тәмамлагач, унынчы сыйныфны Сарман урта мәктәбендә укый. 1948-1950 елларда ул - Казан дәүләт университеты студенты.

Аңа да шәхес культының газапларын татырга туры килә. 1950 елның мартыннан 1955 елның августына кадәр кыен сөргенлек шартларында ташчы, бетончы, бригадир һәм десятник булып эшли.

Казанга кайткач, университетта укуын дәвам итә.

3 укучы. "Чыгарган беренче такмагым – шигъри юлларым хәтердә калмаган, соңгы бер юлы гына исемдә... "Идәндә шомырт коя" иде аның соңгы юлы... Баштагы юллары "Яфрак ярата бәрәннәр... тамаклары тиз туя... Тамак туйгач сикергәләп, идәнгә шомырт коя" булды шикелле",- дип яза әдип.

Аның каравы, А. Гыйләҗевнең башлангыч иҗат тәҗрибәләре кайчан башлануын анык кына әйтә алабыз без. Башлангыч иҗат тәҗрибәләре студентлык елларында башлана аның. "Ян, учагым, ян!" исемле лирик рухтагы беренче хикәясе 1948 елда ук дөнья күрә.

1 алып баручы. Шуннан башланган иҗат чишмәсен бер дә саектырмыйча, А. Гыйләҗев үзен бик күп санлы хикәяләр, публицистик мәкаләләр, повестьлар һәм романнар, өч дистәдән артык драма әсәрләре авторы итеп танытты.
Тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин әйткәнчә, "Аяз Гыйләҗев – әдәбиятыбызның төрле тармакларында ат уйнаткан кеше. Ул күренекле прозаик, үзенчәлекле драматург, үткен каләмле публицист һәм очеркист, ниһаять, усал телле тәнкыйтьче".

2 алып баручы. "Аяз Гыйләҗевне язучы итеп таныткан әсәре, миңа калса, "Үги ана яфраклары" дигән егерме генә битлек хикәясе булды. Бу хикәядә бернинди ялган юк, авторның һәр сүзе самими, шул сүзләрдән ул, чын тормыш дөреслегенә һич тә хилаф китермәстән, "менә бу тормышның үзе!" дип әйтә торган, хәтта үзеннән дә гүзәлрәк булган бер тормыш бинасы төзеп куйган", - дип язган иде Хәсән Сарьян бу хикәя хакында. *(Хикәядән өзек белән танышу).*

1 алып баручы. Язучы Марат Әмирханов остазыннан "Иң уңышлы әсәрләрегездән беренче итеп кайсын атар идегез?" –дип сорагач, ул: "Яра" повесте", - дип җавап бирә.

"Яра" – дөнья укучысына тәкъдим итәрлек әсәр... "Яра"ның нигезен мәхәббәткә мәдхия тәшкил итә". М. Әмирхановның "Яра" повесте турындагы бу фикерләренә без дә кушылып, мәхәббәт турында җыр тәкъдим итәбез.

*(Җыр. “Мин сине ничек яраттым!” С. Садыйкова музыкасы, Р. Фәйзуллин шигыре).*

2 алып баручы. "Башка әсәр язмаса да, "Җомга көн, кич белән..." повесте белән генә дә А. Гыйлҗев татар әдәбияты тарихында калыр иде",- дигән фикере белән Тәлгат Галиуллин бик хаклы. Татар хатын-кызларына хас күркәм сыйфатларны үзенә туплаган, сөттән ак, агым судан пакь, намуслылык, җаваплылык үрнәге булган Бибинур карчыкны сурәтләве өчен генә дә рәхмәтле без язучыбызга. *(Әсәрдән өзек тәкъдим итү).*

1алып баручы. "Шөкер, татар әдәбияты олпат шәхесләргә, телебезнең нечкәлекләрен үтә сизгер тоемлаучы, һәр кәлимәне асыл мәгънәсен белеп, алтын кысага утыртылган бриллиант кимәленә җиткерә белүче сүз осталарына бай булды. Һәм аларның берсе дип, мин, һич икеләнмичә, Аяз ага Гыйләҗевне күрсәтер идем..." Бу юллар Флүс Латыйфиның "Юксыну" дигән мәкаләсеннән. Язылганнарга мисал итеп, "Урамнар артында яшел болын" романын гына китерү дә җитәдер, минемчә.

*(Гәрәй Рәхимнең "Урамнар артында яшел болын" шигыре укыла).*

2 алып баручы. Каты бәгырьле, кырыс табигатьле, бик таләпчән күренгән язучыбыз күңелендә татар җырлары аерым урын алып торган.

"Татар җырлары – безнең милли фәлсәфәбез. Татарча уйларга, укырга, югары үрләргә мөмкинлек калмаганда, ул барлыгын, яшәешен,өмет-өметсезлеген җырларга салган, хыялларының иң мөкатдәсен җырга күчергән..." Бу – Аяз Гыйләҗев сүзләре. Әлеге фикер белән килешми мөмкинмени?! Әйдәгез әле, үзәкләргә үтәрлек бер татар моңын, татар җырын тыңлап китик.

(*Җыр.”Син сазыңны уйнадың”. Татар халык көе. Н. Исәнбәт шигыре).*

1 алып баручы. "Язгы кәрваннар" повесте "Казан утлары" журналында басылгач, Сибгат ага Хәким:"Аяз, мин синең ул повестеңне җылый-җылый укыдым. Син анда, үзең кичергән яшьлек еллары рухын саклаган хәлдә, каләм көчеңнең олпатлыгын раслаганың. Түзмәдем, шул исемдә шигырь яздым,"- дигән була. Хәзер шул шигырь белән танышыйк.

*(С.Хәкимнең "Язгы кәрваннар" шигыре укыла).*

2 алып баручы. Аяз Гыйләҗев үзен эзләнүчән һәм үзенчәлекле драматург буларак та танытты."Көзге ачы җилләрдә", "Җиргә тапшырылган серләр", "Китмәгез, тургайлар", "Шомырт чәчәк атканда", "Хәдичәнең кече улы", "Яланаяклы кыз"... Болар А. Гыйләҗев иҗат иткән сәхнә әсәрләренең бик азлары гына.

"Аязның пьесалары белән танышкач, укучы тыныч кына кала алмас, уйланыр, дөнья гаме белән дә яши башлар дип ышанам. Талантлы драматургыбыз Аяз Гыйләҗев белән һәр очрашу истә калырлык вакыйга ул", - дип яза Рәүф Игъламов "Аяз Гыйләҗев - драматург" дигән мәкаләсендә. Моңа өстәп, бары: "Әйе, Аяз абый пьесалары гамьле, мәгънәви,тәрбияви...",- дип кенә әйтәсе кала.

*(Бер пьесасыннан өзек сәхнәләштерү).*

1 алып баручы.Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның һәм Русиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Русиянең М. Горький исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, талантлы әдип Аяз ага Гыйләҗевкә багышланды бу кичә. Флүс Латыйфи сүзләренә каләмдәшләренең сагыну хисләрен, күпсанлы укучыларының юксыну тойгыларын өстәп, "Сагынабыз сине, Аяз абый, тирән фәлсәфи әсәрләреңне сагынабыз... Әдәбиятка һәм безгә Син кирәк, бик-бик нык кирәк идең шул!" - дибез.

Закирова Роза Ахмед кызы, Муллагалиева Халидә Миннесаяф кызы,
Менделеев шәһәренең беренче гимназиясе

**Кеше язмышы кем кулында?**

(9нчы сыйныфта “Бибинур” фильмы буенча үткәрелгән дәрес эшкәртмәсе)

**Максат:** Әдәбиятның образлы дөньясын кино сәнгате күренеше буларак аңлау, әдәби әсәрнең эстетик ягын кабул итү; татар әдәбияты һәм мәдәниятенең әхлакый һәм рухи кыйммәтләрен якынайту; әдәбиятны тарих, җәмгыять белеме предметлары белән бәйләп, дөнья, яшәү, кешелек җәмгыяте турында күзаллау формалаштыру, татар киносына кызыксыну уяту.

**Дәрес формасы:** “Йолдыз сәгате” уены.

**Техник чаралар:** проектор

**Дәрес барышы:**

**I. Оештыру, ориентлашу.**

Хәерле көн, укучылар. Узган дәрестә без сезнең белән “Бибинур” фильмын карадык. Бу кино берегезне дә битараф калдырмады, күңелләрегездә каршылыклы хисләр уятты дигән фикергә килдек. Шуңа күрә без сезнең белән бүген тагын бер тапкыр каралган вакыйгаларга әйләнеп кайтып, бер-беребез белән аралашып алырбыз. Дәресебез үзенчәлекле уен формасында узачак. Шуңа күрә дә без сезне ике командага бүлдек. Сезнең максат – караганнарны искә төшереп, мөмкин кадәр сорауларга дөрес җавап бирү. Һәр дөрес өчен командага фишкалар бирелә. Дәрес ахырында фишкалар санына карап, җиңүчеләр ачыкланачак. Шулай итеп, уеныбызны башлыйбыз.

**II. Уку мәсьәләсен чишү этабы**

**1. “Бибинур” фильмы буенча кереш сораулар.**

1.1. Фильм ничәнче елда төшерелгән? (2009)

1.2. Фильмның режиссёры кем? (Юрий Фетинг)

1.3. Өлкән Бибинурны кайсы артист уйный? (Фирдәвес Әхтәмова)

1.4. Руслан Мустафин нинди персонажны уйный? (Мансур)

1.5. Фирдәвес Әхтәмова - нинди театр артисты? (Г. Камал)

1.6. Фильм нинди конкурста ике бүләккә лаек була? (6 халыкара мөселман киносы фестивалендә)

1.7. Фильм нинди киностудиядә төшерелә? (Сабантуй)

1.8. Фильмда Бибинур ролен ничә кеше уйный? (3)

1.9. Фильм нинди әсәргә нигезләнеп төшерелгән? (Аяз Гыйләҗевның “Җомга көн кич белән...”)

1.10. Җиһангир ролен кем уйный? (Эрнест Тимерханов)

**2. Бер атналык тормыш.**

2.1. Фильм нинди күренештән башлана? (Бибинурның төшеннән)

2.2. Төшендә Бибинурга Вәли нәрсә бирә? (шырпы)

2.3. Бибинур иртән нәрсә көтүенә очрый? (сарык)

2.4. Мансур туңдырманы ничә сумга сата? (12)

2.5. Бибинур почта аша посылкада малаена нәрсә җибәрергә тели? (кильки, карабодай ярмасы, алма)

2.6. Телеграммага нинди сүзләр яздырырга тели? (җомга көн кич белән үләм, кайт)

2.7. Этнең кушаматы ничек? (Кызылбай)

2.8. Балаларны Ленинградка җибәрмәс өчен, Бибинур печәтле кәгазьне нишләтә? (ашый)

2.9. Бибинур почтага посылка җибәрергә атнаның кайсы көнендә бара? (сишәмбе)

2.10. Җиһангир бөтен җирләрен кемгә калдыра? (Мансурга)

**3. Кем сүзләре?**

3.1.“Шырпы – ут, ут – үлем” (Вәли)

3.2. “Америкага ризык җибәрергә ярамый” (почтальон кыз)

3.3. “Нәрсә, ничәмә еллар буе миңа җиңел булдымы әллә? Мин бит гел синең турында гына уйладым” (Мирзаһит)

3.4. “Барысы да Аллаһ кулында” (Бибинур)

3.5. “Боздырам мин сезне. Барыбер минемчә булачак” (Зөһрә)

3.6. “Бүгеннән башлап бөтен җирләр – Маркиз Карабасныкы” (Җиһангир)

3.7. “Мин барыбер җиңәм. Минем тавышым үзенчәлекле” (Мансур)

3.8. “Шикләнмә, Ленинградта балаларга рәхәт булыр” (Зәмирә)

3.9. “Әти, сиңа кылыч бирәләрме?” (Нәҗип)

3.10. “Син нәрсә инде, Бибинур, Мин бит сугышка китмим” (Габдулла)

**4. “Театр нурга илтә...”**

Ике команда да өчәр минутлык кино буенча сәхнәләштерелгән өзек әзерләргә тиеш иде. Хәзер шуларны карап китәбез.

**5.Финал.**

Фильм төшерелгән киностудия исеменнән, ягъни САБАНТУЙ сүзендәге хәрефләрдән мөмкин кадәр күбрәк сүзләр төзергә кирәк (ата, ана, саба, туй, ант, тай ...)

**III. Рефлексия.**

Укучылар, сезгә фильм ошадымы? Тагын татар фильмнарын карарга теләгегез бармы? Нинди темаларга карыйсыгыз килә?

Әйдәгез, дәрес башында куйган сорауга җавап биреп карыйк әле: чыннан да, кеше язмышы кем кулында соң? (фикерләр тыңланыла)

Уен тәмам. Җиңүчеләр билгеле. Барыгызга да уңышлар телибез.

Хәлилова Гөлүсә Зөфәр кызы,
Балык Бистәсенең 2нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Балык Бистәсе районы

**А.Гыйләҗевнең “ Җомга көн кич белән...” повесте**

**Максат:** А.Гыйләҗевнең “Җомга көн, кич белән...” әсәрен анализлау, идея эчтәлеген ачу. Укучыларда дөнья, яшәү, табигать, кешелек җәмгыяте турында күзаллау формалаштыру.Миһербанлылык, шәфкатьлелек, ата- анага, өлкән буын кешеләренә мәхәббәт хисе тәрбияләү.

**Материал**: Дәреслек, А. Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән...” әсәре.

**Җиһазлау**: Язучының портреты, терәк схемалар, укучылар язган сочинениелар, әниләр турында җырлар, тестлар, укучылар әсәр буенча ясаган рәсемнәр, компьютер һәм экран, образга характеристика схемалары.

**Дәрес барышы**.

I .Уңай халәт формалаштыру.

**Укытучы.** Исәнмесез, хәерле көн, укучылар! Кәефләрегез ничек?

Ф.Зиятдинованың “Хәерле көн телим” шигыре укыла.

Таңнар саен хәерле көн телим,

Аяз күкләр телим җиремә.
Кояшлы көн телим бар кешегә
Һәм иминлек телим илемә

Бүген бездә бәйрәм, безгә кунаклар килде. Татар халкы кунакларны сый-хөрмәт белән каршы алырга ярата. Без дә кунакларны якты йөз белән каршы алыйк. Үзебезнең белгәннәребез белән уртаклашыйк. Дәрес темасын билгеләү өчен экранда хәрефләр күрсәтелгән, сез шулардан сүзләр төзегез.(Укучылар парларда эшлиләр). Әйе, укучылар бүгенге дәрестә без А.Гыйләҗевнең "Җомга көн, кич белән..." повестен өйрәнүне йомгакларбыз, әсәрдәге образлар һәм идея-проблемасы турында фикер алышырбыз.

II. Актуальләштерү.

**Укытучы.** Әдәби әсәргә анализ ясау – катлаулы эш. Язучының кайсы чорда, нинди шартларда яшәгәнлеген һәм иҗат иткәнлеген белгән очракта гына без әсәрдәге вакыйгаларга, андагы образларга дөрес бәя бирә алабыз. Мин сезгә Г.Афзалның А.Гыйләҗевка багышлап язган шигырь юлларын укыйм. Шушы юлларга нигезләнеп, сез аның иҗатын ачык күзалларсыз дип уйлыйм.

Син бик усал, ач арыслан кебек,
Усаллыгың җитәр йөз елга.
Юаш кына малай идең элек,
Усаллата икән бу дөнья.

Халык шагыйре Г.Афзал үз каләмдәшен "усал" дип кенә калмый, ни өчен аңарда бу сыйфатның барлыкка килүен дә әйтеп бирә.

**Укытучы.**А.Гыйләҗевне дөнья ни өчен усаллатты икән? Уйлагыз, фикер алышыгыз.(**Көтелгән җавап.** Аны КДУның 2 курсында укыганда, советка каршы коткы таратуда гаепләп кулга алалар. Тоткынлыктагы 5 ел гомер эзсез калмаган).

**Укытучы.** Әсәр 1979 нчы елны язылып беткән. "Матур лозунглы" совет чынбарлыгы, икейөзлелек, әхлаксызлык, әдәпсезлекне тудырды. Туры сүзле, намуслы кешеләргә яшәү нык кыенлашты. Бүген без анализ ясыйсы әсәр герое да шушы система корбаны.

III. Төп өлеш.

**Укытучы.** Ә хәзер әйдәгез сөйләшүне әсәрнең үзенә юнәлтик.

Әсәрнең исеменә игътибар итик әле. Ничек атала? Ни өчен күпнокталар куелган? (Чөнки җомга көн электән бездә бәйрәм көн. Ул – дин, әхлак, изгелек көне.)

Ә әсәрдә нинди бәйрәм турында сүз бара? Авыл халкы белән бергә бәйрәмне кем һәм нинди өмет белән көтә? (Бибинур)

Ә хәзер сезнең белән видеосюжет карап үтик. (Бибинурның почта янына төшеп балаларыннан хәбәр көтүе)

Бибинур кем ул?Аның турында нәрсә белдегез? (**Көтелгән җавап.** Бибинур ялгыз яши. Ул инде олы яшьтә. Ул Габдуллаҗанның өч баласын тәрбияләп үстерә).

**Укытучы**. Бибинур, бәхетеннән ваз кичеп, ни өчен Габдуллаҗанга кияүгә чыга? (**Көтелгән җавап.** Бибинур балалар бакчасында эшли, шуңа күрә ул Габдуллаҗанның әнисез калган балаларын якын күрә, аларны кызгана. Бу балаларны җәлләү, аларга ярдәм итү теләге Бибинурны, сөйгән егетен ташлап, Габдуллаҗанга кияүгә чыгарга этәрә).

**Укытучы.** Ул аларны ничек тәрбияли? (**Көтелгән җавап.** Бибинур балаларны үз кочагына ала, бөтен көчен, яшәү рәвешен аларга бирә,укыта, хәленнән килгәнчә ярдәм итә.(Дәреслек)

**Укытучы.** Балаларның, үсеп кеше булгач, Бибинурга мөнәсәбәтләре ничек? (**Көтелгән җавап.** Алар аңа ярдәм итү турында уйлап та карамыйлар, хәтта хәлен белеп хат та язып салмыйлар, алай гына да түгел, аның өендәге барлык әйберләрен үзләре белән алып китәләр).

**Укытучы.** Бибинурның үксеп елардай чаклары, авырлыклар алдында югалып калганы булдымы? Кыенлыкларны җиңеп чыгарга ул каян көч тапты? (**Көтелгән җавап.** Ирен сугышка озатты, өй тулы бала-чага калды. Соңрак иренең үлүе турында хәбәр килде, әмма Бибинур балалар хакына барсына да түзде. Берәүне дә дошман күрмәде, ачу сакламады, гаепне үзеннән эзләде, эзләгәч тапты).

**Укытучы.** Аның тормыш кагыйдәсе нинди? (**Көтелгән җавап:** Авыр сүзләр ишетсәгез, үткәреп җибәрегез).

**Укытучы.** Шушы кагыйдәне үтәп ул ничек яшәде? (**Көтелгән җавап.** Кимсетсәләр гафу итә белде, очраганда кешеләрне сөендерде. Кайгылы хәбәрләрне дә ияләренә җиңеләйтеп җиткерде. Көчсезне яклады, көчлеләрне тыелырга өйрәтте, явызны үгетләде, усалның күңеленә шәфкать җылысы җибәрергә тырышты. Менә шундый изге күңелле ана гомер көзенә ялгыз керә. Гомеренең соңгы көннәрендә дә үзен ташлаган балалары турында уйлана).

**Укытучы.** Укучылар, бүгенге көндә дә Бибинур әбинең балалары кебекләр, ягъни картлык көннәрендә әти-әниләрен язмыш иркенә ташлап калдыручылар бармы? (Җаваплар тыңлана)

**Укытучы.** Укучылар, сезгә бер притча сөйләп китим әле. Бер малай әнисе белән генә тора. Ул, улы начарлык эшләгән саен, рәшәткәгә бер кадак кага бара. Еллар уза, бала үсеп буйга җитә. Беркөнне ул кадакларга игътибар итә һәм әнисе янына килә. - Әни, нигә син шулай күп итеп кадак кактың? - ди. Әнисе: - Улым, менә син бер начарлык эшләгән саен, мин бер кадак кага бардым. Күрәсеңме, ничаклы алар? - ди. Улы уйга кала һәм гел яхшылыклар гына эшләргә сүз бирә. Шулай эшли дә. Менә ул да ир уртасы булып җитешә, әнисе дә олыгая. Әнисе янына беркөнне килә дә: - Әни, кара әле, рәшәткәдә бер кадак та калмады. Мин яхшылык эшләгән саен берсен ала бардым, начарлыкларыма каршы яхшылык эшләдем, - ди. Ә әнисе болай ди:

-Улым, әйе син күп яхшылыклар эшләдең һәм шулай итеп, начарлыкларыңны бетердең дә кебек, тик әнә, кара әле рәшәткәләргә, никадәр кадак эзләре. Аларның эзләре калган бит.

Нәтиҗә. Начарлыкны эшләмәскә кирәк, чөнки күңел ярасы төзәлми. Бигрәк тә әти-әниеңнең хәтерен калдырырга ярамый. Әниләрне рәнҗеткәннән соң ялгышыбызны аңлап аңлап гафу үтенсәк тә, йөрәктә эзе кала. Шуңа күрә тормышта яхшы гамәлләр генә кылып яшик.

**Укытучы**.Укучылар, сез үз әниләрегез турында иншалар да язган идегез, кем укырга тели? (Сочинениелар тыңлана.)

**Укытучы.( Ял минуты. Релакс.)** Ә хәзер күзләрегезне йомып, рәхәтләнеп, әниләрегезнең ягымлы йөзләрен күз алдыгызга китереп аларга багышланган җыр тыңлыйк.(Ишегалдың синең яшел чирәм... җыры).

Әсәрне анализлауны дәвам итәбез.

**Укытучы.** Повесть ахырына таба без Бибинурны өлкән яшьтә итеп күрәбез. Дөнья белән алыш-биреше тәмам дип уйлау аңа җиңел бирелми. Берничә көн хатирәләр тозагыннан ычкына алмый азаплана. Аннан соң зиратка Гайшәнең кабере янына бара. Ни өчен зиратка килә? (**Көтелгән җавап.**Ул үзе үстергән балалар турында, аңа хат та

язмаулары хакында бирәүгә дә сөйләми, тик аның моңа эче поша. Һәм һәрчак Гайшәнең кабере янына килеп, балаларның үз әниләре белән сөйләшә.Алар үз әниләрен дә онытканнар, Бибинур шуңа бик рәнҗи, ә бу турыда ул бары балаларның үз әниләре белән генә сөйләшә ала).

Әңгәмәдән соң Ф.Батталның "Тормыш сабаклары" мәдхиясен брошюра итеп ясап таратыла. Бер укучы укый. Бу мәдхия буенча өй эше биреләчәге әйтелә.

**Укытучы.** Бибинур балаларын гаеплиме?Дәрес башында карап киткән өзекне искә төшерик.(Укучылар дәрес башында сәхнәләштереп күрсәткән "Почта янында" өлешен искә төшерү). Миңлегөлнең хәбәре Бибинур карчыкка ничек тәэсир итә? Ул балаларын кыен хәлдә калдырмас өчен нинди карарга килә? (Укучыларның җаваплары тыңлана).

IV. Ныгыту.

**Укытучы.** Төп образга күзәтү ясадык, ә хәзер аны уратып алган, аның белән гомер кичергән авыл кешеләрен, ярдәмче образларны, барлыйк та әсәрнең композициясен билгелик. (Төркемнәрдә эш) (8 нче слайд)

(Зөһрәбану, Мирзаһит, Габдуллаҗан, Җиһангир, Миңлегөл, Зәкия). Бу образлар турында нәрсәләр әйтә аласыз? (**Көтелгән җавап.** Зөһрәбану – Бибинурның игезәге (явыз); Мирзаһит – Бибинурның яратып йөргән егете; Габдуллаҗан – ире(мескен, 3 бала белән ялгыз кала, шушы балаларны җәлләп, Бибинур киләчәк бәхете, мәхәббәтеннән баш тарта); Җиһангир – Бибинурның картлыгындагы мәхәббәте; Зәкия – күрше карчыгы; Галикәй – Бибинурның сөйләшә алырдай кешесе; Миңлегөл – почтада эшли, редакциягә хат язучы).

Укытучы. Ә хәзер символик образлар буенча эшлик. Теория буенча тест эшләп, белемнәребезне тирәнәйтик. (Сюжет элементлары экран аша күрсәтелә)

**Башлам.** Бибинур белән таныштыру

**Төенләнеш.** Сабантуй якынлашу

**Вакыйгалар үстерелеше.** Бибинур балаларын көтә, өметләнә.

**Иң югары нокта.** Бибинур хат язылу хакында белә, юлга чыга

**Чишелеш.** Үлем (Шыр ялангач өйне җиһаз белән тутырыйм, дип, Бибинур күрше авылга китә. Җомга көн, кич белән...).

- Бибинурның соңгы адымын ничек бәялисез? Аның урынында булсагыз, сез нишләр идегез?

- Урманда Бибинурга кайчандыр үзе ашатып йөргән этләр ташлана. Автор моның белән ни әйтергә тели? Әсәрнең идеясен билгеләү.(Балаларның җаваплары тыңлана).

**Укытучы нәтиҗә ясый.** Бибинур карчык – туган туфрак рухын саклаучы кеше, татар халкының традициясе, рухи байлыгы. Ә әсәр аның үлеме белән тәмамлана. Алай гына да түгел аның үлеменә үз кешеләре, хәтта үз эте дә сәбәп була. Милләт үзен-үзе юк итә, дип борчыла автор. Ә аның балалары туган җирдән, туган туфрактан аерылганнар. Туган җирдән, туган туфрактан аерылганнар – тамырсыз агач кебек. Тамырсыз калгач әхлакый сыйфатлар да, күркәм гадәтләр дә югала бара, җәмгыять авырый, аны дәваларга кирәк. Әсәр безне җәмгыятьне әхлакый, рухи яңарту, сәламәтләндерү кирәклеге турында да кисәтә. Ә Бибинур исә шушы авыру җәмгыять корбаны.Димәк, әсәр халык каршында торучы афәткә ишарә ул. Киләчәккә куркыныч яный.

**V.Йомгаклау.** Миңнеруй Хәбибуллинаның "Ана догасы" шигыреннән өзек укыла, дәрескә йомгак ясала, билгеләр куела.

Бик тиз үстең, бигрәкләр дә инде, балам!

Бәхет-шатлык юрый бугай үтәр юлың.

Күзләремне иркәлидер зифа буең,
Йөрәгемә ял буладыр кылган уең.
Иртә-кичен теләкләрем тели-тели,
Ходаемнан бәхет сорыйм сиңа, балам.
Явызлардан, азгыннардан ерак йөртсен,
Гомерең буе тәүфыйк белән инсаф бирсен.
Саф күңелең чагылыш тапсын күзләреңдә,
Иман нуры балкып торсын йөзләреңдә.
Мәхәббәтле күренсәңче күрер-күзгә,
Миһербанлы булсаңчы дим йорт-нигезгә.
Кызыллыклар китерә күрмә илгә-көнгә.
Сабырлыкка ни җитә соң җир йөзендә.

**VI. Өй эше. (**сайлап алып әзерләнергә)

1.Анага мәдхия язарга.
2.Ана образына характеристика язарга.
3. Таратылган брошюра буенча фикер алышуга әзерләнергә.

Дәрескә тест.

1. “Җомга көн кич белән ..” повесте кайсы әдәби төргә карый.
а) лирик; ә) эпик; б) драма.
2. Бибинурның ялгызлыгына ишарә итүче символик образны билгеләгез.
а) хат; ә) яшел чирәм; б) зират.
3. “ Ул балаларын **олы дөньяга чыгарып җибәрде**” җөмләсендә кулланылган тропны билгеләгез.
а) фразеологизм; ә) чагыштыру; б) эпитет.
4.Әсәрдә геройларның үзара аралашуын ачыклый торган сөйләм формасын атагыз.
а) реплика; ә) ремарка; б) диалог.
5.Әсәрдәге **саран бакалар** тел-сурәтләү чарасын атагыз.
а) эпитет; ә) метафора; б) чагыштыру.
Җаваплар.1. Эпик 2. Яшел чирәм. 3. Фразеологизм 4. Диалог. 5. Метафора.

**Дәрескә өстәмә**

Фәнзаман Баттал

“ Тормыш сабаклары”

Әткәм яки әнкәм кабере янына бассам, сәер дә, гаҗәеп тә бер уй туа: гүрләренә төшеп, һәр икесен йомшак кына сөясем һәм ... гафу үтенәсем килә. Еллар үткән саен, ныграк уйлыйм: үзләренә каршы да әйткәләгәнмен, кайбер сүзләрен тыңламаганмын, ярдәм итүем дә чамалы булган...

Үземне юатып та карыйм. Мондый чакларда көянтәләп су ташуларым да, көннәр буе утын яруларым да, үсеп җиткәч вә аерым яши башлагач, яраткан чәйләрен, кирәкле даруларын юнәтеп, җибәреп торуым да, бүләкләр, күчтәнәчләр белән кайтуларым да искә төшә. Тик бераздан юанычларым кабат җимерелә – игелегем бик тә, бик тә аз тигән... Үләр алдыннан һәркайсы рәхмәт әйтте, бәхиллеген бирде, югыйсә. Мин бу хакта һичвакыт язмам дип уйлаган идем. Кинәт болай уйладым: ” Туктале, хәзерге малайлар һәм кызлар да ялгышып яшәми микән? Аларның бер генә сүзләрен тыңламау да гомер буе үкендерә икән бит...”

...Менә синең әтиең сиңа нindидер гозерен әйтә, йомыш куша. Кушканны, әйткәнне үзеңә зур бәхет һәм мәртәбә санап, җиренә җиткереп үтә.

Синең тәртипсезлекне күреп әниең ничек өзгәләнә. Монысын да мәңгелек итеп исеңдә калдыр, әниең бу дөньядан киткәч үкенмәслек булсын. Яхшы бел: олуг табигать законнары бозылмаса, өлкән буын синнән иртәрәк үлә. Шомлы тоелыр бу сүзем, бераз куркытыр да. Әмма нишләмәк кирәк, тормыш агышы шундый. Үкенүләрем кимрәк булсын дисәң, алар исән чакта карашларына күләгә төшермә, яхшы укуың, матур яшәвең, игелекле гамәлләр кылуың белән сөендер. Ә ата-ана гүргә кергәч тә сиңа бәхет тели.

Ибрагимова Альфира Наил кызы, Хабибуллина Гөлнара Флорис кызы
Зур Нөркәй урта белем бирү мәктәбе филиалы –
Юлтимер төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

## Шушы яктан, шушы туфрактан без

(“Бәхетле очрак” уенының методик эшкәртмәсе)

“Шушы яктан, шушы туфрактан без” дип исемләнгән “Бәхетле очрак” уены Сарман ягы төбәге әдипләренең иҗади мирасын өйрәнү, пропагандалау һәм укучыларда фәнни-тикшеренү күнекмәләре формалаштыру максатыннан үткәрелде.

Үзебезнең интеллектуаль уеныбызга түбәндәге бурыч һәм максатларны куйдык: укучыларның туган як турындагы белемнәрен тирәнәйтү; Аяз Гыйләҗев турында белемнәрне тирәнәйтү, язучының иҗаты белән танышу; Сарман төбәге язучылары турында күбрәк белергә омтылыш тәрбияләү; танып-белү активлыгын үстерү; үзара дуслык, иптәшлек мөнәсәбәтләре урнаштыру һәм команда булып эшләү күнекмәләре формалаштыру.

Максатларыбызга ирешү өчен укучыларга Сарман төбәге, якташ язучыбыз Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай, М.Горький исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты Аяз Гыйләҗев турында мәгълүмат тупларга һәм тикшеренү эше алып барырга кушылды. Уенга 5-8 класс укучылары чакырылды. Уен дүрт турдан торды, сорау-җавап рәвешендә үткәрелде. Уен А.Гыйләҗевнең тормыш юлында булган кызыклы вакыйгалары белән бизәлде. Уен ахырында командалар бүләкләр белән бүләкләнделәр. Уен эчтәлекле, мавыктыргыч һәм бик кызыклы үтте.

**Җиһазлау:**командаларга өстәл, уен өчен кирәкле күргәзмә әсбаплар, экран, компьютер, Аяз Гыйләҗевны, аның иҗат юлын һәм әсәрләрен чагылдырган презентация.

**План.**

I. Кереш өлеш.
1. Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.
2. Чараның темасын билгеләү.
3. Чараның максаты белән таныштыру.

II. Төп өлеш.
1. Командаларга бүленү (исем, капитаннарны билгеләү)
2. Жюри әгъзаларын сайлау.
3. 1 нче тур “Кем тизрәк?”
4. 2 нче тур “Капитаннар алга”
5. 3 нче тур “Син миңа, мин сиңа”
6. 4 нче тур “Ребуслар чишү”

III. Йомгаклау.
1. Аяз Гыйләҗевның тормыш юлы һәм иҗаты буенча нәтиҗә ясау
2. Командаларны бүләкләү.

**Чараның барышы**

**Кереш өлеш.**

Укытучы. – Исәнмесез, укучылар!

Хәерле көннәр сезгә.
Зиһен һәм тел ачкычлары
Телимен һәммәгезгә.

Үзебезнең чираттагы чарабызны башлыйбыз. Бүгенге чарага сез Аяз абый Гыйләҗев турында әзерләнеп килдегез. Һәм без язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәребезне камиллләштерергә тиеш булабыз.

**Төп өлеш.**

Укытучы. Бүгенге чарабыз "Бәхетле очрак" уены рәвешендә узачак. Уенда ике команда катнаша. Хәзер командаларга бүленәбез. Һәр каманда үзенә Аяз Гыйләҗев иҗаты белән бәйләп исем уйларга һәм капитаннарны билгеләргә тиеш була. Сез уйлаган арада без жюри әгъзаларын сайлай торабыз. (Жюри әгъзаларын сайлау)

1 нче команда "Уйлап табучы". Капитан - Адилә

2 нче команда "Дуска җавап". Капитан - Азамат

Укытучы. Димәк, безнең уенда"Уйлап табучы" һәм "Дуска җавап" командалары көч сынаша. Уенны башлыйбыз.

1 нче тур. "Кем тизрәк?" дип атала. Әлеге турда сезгә сораулар бирелә, ә сез аларга тиз һәм дөрес итеп җавап бирергә тиеш буласыз. Кайсы команда җавап бирә алмый, сорау көндәш командага күчә. Бирем аңлашылдымы?



Укучылар. Аңлашылды.

Укытучы. 1 нче турны башлыйбыз.

1. Аяз Гыйләҗевнең туган көне, ае, елын атагыз (17 гыйнвар 1928 ел).
2. Әтисенең исеме ничек? (Мирсәет)
3. Аяз Гыйләҗевнең бала чагы һәм мәктәп еллары кайда уза? (Бала чагы һәм мәктәп еллары күршедәге Зәй районының Югары Баграҗ исемле керәшен татарлары авылында уза)



4. Сарман урта мәктәбен тәмамлаганнан соң кайда эшли? (Сарман урта мәктәбендә унынчыны тәмамлаганнан соң (1945), берникадәр вакыт колхозда эшли)
5. Укуын тәмамлагач, КДУның кайсы бүлегенә укырга керә? (татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә)
6. Беренче хикәясе кайчан басылып чыга? (1948 елда)



7. Беренче хикәясен атагыз ("Ян, учагым, ян!")
8. А.Гыйләҗевнең тормыш иптәшенең исеме ничек? (Нәкыя Гыйләҗева)
9. А.Гыйләҗев кайда туган? (Сарман районы Чукмарлы авылында)
10. Иң беренче сәхнә әсәрен атагыз ("Җиз кыңгырау")
11. Аяз Гыйләҗев эшләгән журналларны атагыз ("Чаян", "Азат хатын", "Совет әдәбияты")
12. Язучының актив иҗат эшчәнлеге кайсы елдан башлана? (1956 елдан)

13. Тематик яктан А.Гыйләҗевнең күпчелек повестьлары нәрсәгә багышланган? (авыл тормышына багышланган)

14. 1983 нче елда язучы нинди повестьлары өчен Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды? (“Җомга көн кич белән”, “Өтәч менгән читәнгә”)

15. Ничәнче елда татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен, ТР Президенты Указы нигезендә, А.Гыйләҗевкә Татарстан Республикасы халык язучысы дигән мактаулы исем бирелә? (1993 елда)

16. Аяз Гыйләҗев кайчан вафат була? (2002 елның 13 мартында)

Укытучы. Шушының белән сораулар бетте. Жюри нәтиҗәне ясый тора, ә без алдагы турга күчәбез.

2 нче тур “Капитаннар алга!” дип атала.

Аяз Гыйләҗев белән Нәкыя апа өч ир бала табып, тәрбияләп үстергәннәр. Өлкән уллары КФУда галим, тарих фәннәре докторы.Уртанчы уллары архитектор һөнәренә укыган, ләкин драматургия өлкәсендә үз көчен сыный. Кече уллары табиб һөнәрен үзләштергән, ә бүгенге көндә – малтабар.



*Капитаннарга сорау*: Аяз Гыйләҗевнең балаларының исемнәрен атарга. Сезгә 3-4 минут бирелә.

Өлкән уллары Искәндәр, уртанчысы – Мансур, кечесе – Рашат дип җавап бирергә тиеш идегез.

Укытучы. 3 нче турга күчәбез. Ул “Син миңа, мин сиңа” дип атала. Бу турда командалар бер-берсенә Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗатына караган кызыклы сораулар бирелә. Сораулар һәр командага да икешәр. Әгәр команда сорауга җавап бирә алмый икән, команда үз соравына үзе җавап бирә.

Укучылар.

1. Аяз ага Гыйләҗев өчен дөньяның сигезенче могҗизасы нәрсә? (“Зәй энҗеләре” дигән әсәрендә Зәйдә төзелеп яткан ГРЭСның төнге утларын күргәч, менә ул дөньяның сигезенче могҗизасы! дип язган)

2. Аяз Гыйләҗевның тормыш иптәше Нәкыя апа кем булып эшләгән? (рус мәктәбендә татар теле укыткан)

3. Аяз Гыйләҗев үзенең тормыш иптәше белән ничек таныша? (хат аша)

4. “Йәгез, бер дога!” романын язганда Аяз абый нәрсәне җентекләп өйрәнә? (Коръәнне).

Укытучы. Хәзер 4 нче турны башлар вакыт җитте. Әлеге турда без командаларның башваткычларны чишүдә җитезлекләрен һәм осталыкларын карарбыз. Һәр командага да ребус бирелә. Әлеге ребусны дөрес чишсәгез, Аяз абый Гыйләҗевның әсәренең исеме килеп чыгарга тиеш.



**а=е**



Җавап: “Китмәгез, тургайлар!” драматик повесте

Укытучы. Шушы тур белән уеныбыз тәмамлана. Сүзне жюрига бирәбез. (Уенга нәтиҗә ясала).

**Йомгаклау.**

Укытучы.Аяз абый Гыйләҗев тумышы белән җырларда көйләнгән, бик күп мәшһүр затларны, шул исәптән әдәбият һәм сәнгать әһелләрен биргән атаклы Сарман ягыннан, татар теленең, халык моңының табигый төбәгеннән.

Күренекле әдип, Татарстанның халык язучысы, Рәсәйнең М.Горький исемендәге, Җөмһүриятебезнең Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләкләре исе, Рәсәйнең атказанган сәнгать эшлеклесе Аяз Гыйләҗевнең әсәрләре әдәбиятыбызда иң кыйммәтле урын алып тора. Үзенең кыюлыгы, хөр күңеле белән башкалардан аерылып торган талантлы каләм иясе. Гаделлек тантанасына ирешү өчен катлаулы тормыш юлы үткән әдип. (Уенда катнашкан командаларны истәлекле бүләкләр белән бүләкләү).

Укытучы.Укучылар, әлеге уенда катнашканыгыз өчен бик зур рәхмәт. Сау булыгыз.

Гордюшина Лилия Зөлфар кызы, Нуртдинова Гөлнар Салихҗан кызы,
икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Әнием йөрәге - әдәби әсәрләрдә**

(Сыйныф сәгате эшкәртмәсе)

**Максат:** әниләрнең газиз, кадерле кеше булуларын, аларның һәркем өчен бер генә булуын төшендерү. Әдәби әсәрләргә таянып ана образын тулырак ачу, укучыларда әниләргә карата кадер-хөрмәт, ярату, олылау хисләре булдыру.

**Җиһазлау:** китап күргәзмәсе, аудиоязма, ана һәм бала сурәтләнгән рәсемнәр күргәзмәсе (презентация), әдәби әсәрдән өзекләр

Класс сәгатенең барышы

Аудиоязмада “Әнием – син якты кояшым” җыры яңгырый.

**Татар теле укытучысы.** Әни – һәркем өчен кадерле, изге зат. Аналар булмаса, кешелек яшәүдән туктар иде. Тормышыбызга ямь бирүче иң шәфкатьле, иң мәрхәмәтле газиз кешеләребез – әниләр. Әниләребез безне сулышлары белән җылыта, назлары белән иркәли, гомерләре буе безнең өчен сызлана. Балалары чын кеше булып үссә, чиксез горурлана. Кешегә сабый чагыннан башлап, олыгайгач та әни кирәк. Суга бата башлаган бабай да: «Әни!» - дип кычкырган, ди имеш.

**Рус теле укытучысы.** Есть прекрасное существо на свете, у которого мы всегда в неоплатном долгу – это Мама. Мама.. Для каждого человека – большого и маленького, молодого и пожилого мама – самый родной человек на свете. Все лучшее в каждом из нас исходит от матери, давшей нам и самое бесценное – жизнь.

**1 нче укучы.** Әни, әнием, әнкәй! Кадерләп, назлап әйтәбез. Күңелебездәге бөтен рәхмәтне шушы гади сүзгә салабыз, һәрвакыт яныбызда булган, уңышларыбыз өчен шатланып, кайгыларыбызны уртаклашып яшәгән газиз әниебезгә дәшәбез. Әни... Өч хәрефтән торган бу сүздә күпме наз, җылылык һәм күңел тойгысы! Әни... Һәр кеше өчен иң кадерле, иң сөйкемле зат ул!

**2 нче укучы.**

Не обижайте матерей,
На матерей не обижайтесь.
Перед разлукой у дверей
Нежнее с ними попрощайтесь…

Пишите письма или скорей
И слов высоких не стесняйтесь,
Не обижайте матерей,
На матерей не обижайтесь.

**Татар теле укытучысы.** Укучылар! Сез әниләр турында нинди әсәрләр беләсез?

**Укучы.** Ә. Еники «Әйтелмәгән васыять», «Матурлык», Р.Фәизев «Ике әни», М. Җәлил «Яшь ана».

**Укучы.** Х.Сарьян «Бер ананың биш улы», Ш. Хөсәинов «Әни килде», Т. Миңнуллин «Әниләр һәм бәбиләр».

**Укучы.** М. Юныс «Шәмдәлләрдә генә утлар яна», Р. Миңнуллин «Әни кирәк», (Экранга язучыларның китаплары һәм әсәрләреннән сурәтләр чыга)

**Рус теле укытучысы.** А в русской литературе?

**Укучы.** Из русской литературы можно привести много произведений, в которых авторы говорят о роли матери в жизни человека.Перечислим некоторые произведения: Н.А.Некрасов поэма "Мать", В.П.Астафьев "Сопричастный всему живому...", К.Г.Паустовский "Телеграмма", В.Распутин "Женский разговор", В.Богомолов "Сердца моего боль", В.Закруткин "Матерь человеческая", Л Улицкая "Дочь Бухары".

(Экранга язучыларның китаплары һәм әсәрләреннән сурәтләр чыга)

**Татар теле укытучы.** Шулай итеп, татар һәм рус әдәбиятында әниләр темасын чагылдырган бик күп әсәрләр бар. Бүген без сезнең белән якташ язучыбыз Аяз Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән" әсәре һәм В. Шукшинннның «Әни йөрәге» әсәрләренә тулырак тукталырбыз.

**3 нче укучы.** Материнское сердце – любящее, все почувствует, все простит. Именно о такой материи идет речь в рассказе В. Шукшина «Материнское сердце». Мать главное героя (Витьки Борзенкова) родила пятерых детей, рано осталось вдовой. Сначала пришла похоронка об отце в 1942 году, в 1945 году погиб старший сын, в 1946 году от истощения умерла дочь. Следующие два сына выжили и теперь жили в разных городах. Из последних сил мать выходила Витьку. Все распродала, осталась нищей. Сын вырос крепкий, ладный. Все хорошо, но пьяный – дурак-дураком становился.

**4 нче укучы.** Аяз Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән" әсәрендә төп герой – Бибинур. Ул өлкән яшьтә. Балалары зур үсеп, чыгып киткәннәр. Балалар ятимлек ачысын татымасыннар өчен, Бибинур кулыннан килгәннең бөтенесен эшли: укыта, кеше итә, соңгы акчасын да аларга бирә. Бибинурның балалары әниләренең кайтып хәлен дә белмиләр. Байлык артыннан куып, әниләрен күптән оныткannар. Бибинур гомере буе балаларын көтеп яши. Ә бит әниләрне хөрмәтләү – һәр баланың изге бурычы.

**4 нче укучы.** Сколько в материнской любви богатства чувств, вечной доброты и самоотверженности! Между матерью и ребенком устанавливаются дружеские, доверительные отношения. Она разделяет и горести, и радости своего сына, выступает его советчиком, предостерегает от опрометчивых поступков.

**5 нче укучы.**

Көннәр якты булсын өчен,
- Әни кирәк!
Йокы татлы булсын өчен
-Әни кирәк!
Җил- яңгырдан саклар өчен
-Әни кирәк!
Усаллардан яклар өчен
-Әни кирәк!
Ашлар тәмле булсын өчен
-Әни кирәк!
Дөнья ямьле булсын өчен
-Әни кирәк!
Иң кирәкле кеше җирдә
-Әни димәк!!!

**6 нчы укучы.**

Мы порой жестоки к старикам бываем,
Часто обижаем пожилых матерей,
Как нас воспитали, быстро забываем,

Служим ли примером для своих детей?

Вспомните слова мои, выросшие дети:

Не жалейте ласки старым и больным ,

Вы с годами сами будете мудрее,

Доброта вам будет счастьем дорогим

**Татар теле һәм рус теле укытучылары.** Нам очень хочется, чтобы вы никогда не забывали своих матерей. Куда бы ни забросила вас судьба, помните, что есть один человек, который свое сердце, все свои думы отдает вам. Это мама всегда предостерегает нас от неудач, а за наши успехи радуется до слез. Помните наши слова, ведь это слова и учителей, и женщин, и матерей.

Халиуллина Люция Гатуф кызы,
Александровка төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**А.Гыйләҗевнең тормыш юлына һәм иҗатына багышланган“Тамчы шоу” уены**

Укытучы. Татар халкы язучысы, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты А. Гыйләҗев – татар әдәбиятының күренекле бер шәхесе. Ул – татар милләтенең талантлы, көчле рухлы икәнлеген бөтен дөньяга раслаучыларның берсе. Аның иҗаты тематикасы, проблема үткенлеге,идея-эстетик үзенчәлеге белән хәзерге татар әдәбиятында аерым урын алып тора. Аяз Гыйләҗев – әдәбиятыбызның төрле тармакларында ут уйнаткан кеше. Ул күренекле прозаик, үзенчәлекле драматург, үткен каләмле публицист һәм очеркист, ниһаять, «усал телле тәнкыйтьче». Быел аның 90 еллыгы!

Бүген без А.Гыйләҗевнең тормышы һәм иҗаты турындагы белемнәрне сынау өчен “Тамчы шоу” уенына җыелдык. Уенда катнашу өчен 8-9 нчы сыйныф укучыларын чакырам. Рәхим итегез!

- Уенның беренче турында командалар үзләре белән таныштырып үтәләр.

1. Команда “Батырлар”. Девиз: “Батырга каян да юл такыр”
2. Команда “Зирәкләр”. Девиз: “Зирәк һәр җирдә кирәк,
   Тик чын зирәк бик сирәк”

- Икенче тур А. Гыйләҗевнең тормыш юлына багышланган.

“Батырлар” командасына сораулар.

1. Аяз Гыйләҗевнең әтисенең исеме (Мирсәет)

2. Язучының мәктәп еллары кайда уза? (Зәй районында Югары Баграж авылында)

3. А.Гыйләҗев 10 нчы сыйныфны кайда тәмамлый? ( Сарман районы Сарман урта мәктәбендә)

4. Ул ничәнче елда КДУга укырга керә? (1948 нче елда)

5. А.Гыйләҗев ничәнче елда кулга алына? (1950 нче елда)

“Зирәкләр” командасына сораулар.

6. “Урманнар артында яшел болын” әсәренең жанры? ( Роман)

7. А.Гыйләҗевкә Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе кайчан бирелә? (1983 нче елда)

8. А.Гыйләҗевкә кайчан халык язучысы исеме бирелә? (1994 нче елда)

9. 1979 нчы елда кайсы әсәре басылып чыга? ( “Җомга көн кич белән...”)

10. Быел А. Гыйләҗевнең тууына ничә ел тулды? (90 яшь)

- Өченче тур. “Урталык” сүзеннән кайсы команда күпме сүз ясый ала?

- Дүртенче тур – “Командирлар ярышы”.

“Батырлар” командасы командирына сораулар.

1. Кем ул Аяз Гыйләҗев? (Прозаик һәм драматург)

2. Язучының балачак еллары ничек үткән? (Ачлык, сугыш елларында)

3. “Җомга көн, кич белән...”әсәренең жанры нинди? (Повесть)

4. Ул беренче әсәрләрен кайчан язган? (1948)

5. Ни сәбәпле А. Гыйләҗевне биш елга Казахстанга җибәрәләр? (Төрмәгә утырталар )

“Зирәкләр” командасы командирына сораулар.

1. Аның беренче хикәясе ничек атала? (“Ян, Учагым, ян!”)

2. Аның кайсы әсәре буенча фильм төшерелгән? (“Җомга көн,кич белән...”)

3. Аның китаплары нинди телләргә тәрҗемә ителгәннәр?( Башкорт, авар, чуваш, рус)

4. Аяз Гыйләҗев үзе дә тәрҗемә эше белән шөгыльләнәме? (Юк)

5. Аяз Гыйләҗев проза гына язганмы? (Проза һәм драма)

- Бишенче тур. “Җомга көн, кич белән...” әсәре буенча сорауларга җавап бирү. Сораулар бер үк вакытта бирелә (Сорауларга тулырак җавап бирергә)

1) Ни өчен Бибинур әбигә дөнья белән хушлашу җиңел түгел? (Бибинур әбинең балалары белән күрешәсе, аларга соңгы сүзне әйтәсе килә)

2) Ни өчен Бибинур әби Гайшә кабере янына килә? (Ана вазифасын тиешенчә үтәү-үтәмәү хакында хисап тота)

3) Ни сәбәпле Сабантуйга кайткан балалар Бибинур әбине тәнкыйтьлиләр? (Мал-мөлкәтнең үзләренә тотылганын аңламыйлар...)

4) Бибинур әби «бәхет» төшенчәсен ничек аңлый? (Ул бәхетне балаларда күрә)

- Алтынчы тур. “Геройны таны”

1. ... 44нче яшенә чыккач,язгы кыр эшләре төгәлләнеп, Сабан туена нәкъ бер атна калды дигәндә кинәт вафат булды (Җиһангир Сәфәргалин)

2. Аксыргакның атаклы стилягасы. Шәһәрдә нинди кием модадан чыкканын беләсең килсә, аңа гына бар. Төпчек малае, театр художнигы, бар акчасын кием-салымга тотып яшәүче җилбәзәк егет... (Галикәй)

3. ...төртмә иде теле, сәлам биргәннәрнең дә йөзенә кара сүз әйтә,кырку иде холкы, дөньяга нигәдер ачуланып туган иде бу чибәр кыз бала... (Зөһрәбану)

4. ... коммунист иде. ... саф намуслы, азга да канәгать була белгән, үзеннән бигрәк, авыл турында, башкалар турында кайгырта белгән кеше иде. (Габдуллаҗан)

5. Ул балаларының өчесен дә юындырып, өс-башларын арулап өстәл кырына тезеп утырта, хатны иҗекләп, сүзләрне кабатлап, һәр җөмләсенә басым ясап озаклап укый (Бибинур)

6. Бибинур өер башын таныды, әйе, бу ул иде, моннан ике ел элек, кышкы суыкларда саламга төреп, тамагына җылы аш ашатып, соңгы ризыкларын бүлешкән аның ... ... иде (эте Карабай)

- Ә хәзер сүз жюрига бирелә (Җиңүчеләр бүләкләнә)

А.Гыйләҗев әсәрләренең нигезендә язучының кайнар йөрәге, татар халкын, аның тере җанлы кешеләрен хөрмәт итүе, яратуы сизелә. Бибинур, Галикәй, Шәмсегаян, Мирвәлиләр – бары тик татар дөньясында гына була алган, шул дөньяның үзенә генә хас үзенчәлекләрен туплаган бөек шәхесләр. Шуларның батырлыгы, кешелеклелеге язучыга якты маяк, мәңге сүнмәс җылылык булган.

Бүгенге көндә без якташ язучыбыз булган А.Гыйләҗев белән горурланабыз аның хезмәтенә сокланабыз. Киләчәк буыннар да А.Гыйләҗевнең әсәрләрен яратып укырлар дигән теләктә калабыз.

Баязитова Гөлфинә Фәһим кызы,
Казан шәһәренең 117нче гомуми урта белем бирү мәктәбе

**Туган җирдән аермасын язмышлар**

(А. Гыйләҗевнең ”Берәү”, “Җомга көн кич белән”, “Өч аршын җир” әсәрләре буенча)

**Максат:** А.Гыйләҗевнең тормыш юлын, иҗатыбуенча белемнәрне ныгыту, укучыларда әсәрләргә анализ ясау күнекмәләрен үстерү, әсәрләрнең әһәмиятен билгеләү; туган телебезгә, җиребезгә мәхәббәт хисен формалаштыру, әсәрләрдә күтәрелгән мәсьәләләр аша укучыларда әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү; тормыш тәҗрибәсе бирү, укучыларны үз фикерләрен дөрес, эзлекле әйтә белергә өйрәтү, иҗади фикерләү сәләтен үстерү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Шәхескә бәйле:** геройларның яшәү кыйбласы аша нәтиҗәләр ясау һәм рухи сәламәтлек, укучыларда телгә, туган җиргә мәхәббәт, кешелеклелек, шәфкатьлелек хисләре тәрбияләү.

**Метапредмет:** булган вакыйгаларга нигезләнеп, әсәр геройлары яшәгән чорга характеристика бирү.

Предмет: укучыларның А. Гыйләҗев турында белемнәрен ныгыту, укылган әдәби әсәрләрнең уртак идея, проблемасын ачыклый белү.

**Җиһазлау:** компьтер, проектор, интерактив такта, интернет челтәре, “Аяз Гыйләҗевнең биографиясе” видеопрезентациясе, портреты, китапларына күргәзмә, татар теленең аңлатмалы сүзлеге.

**Эш формалары:** фронталь эш, төркемнәрдә эш.

**Дәрес барышы.**

I.Мотивлаштыру-ориентлаштыру.

1. Дәресне оештыру. Исәнләшү.Уңай психологик халәт тудыру.

-Исәнмесез, хәерле көн! Кәефләрегез ничек? Элек-электән үк борынгы бабаларыбыз балаларын яхшы гамәлләр генә кыларга, өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәткән. Алар бер-берсенә күңел җылысын кызганмыйча, үзара ярдәмләшеп, тату гомер иткәннәр. Әйдәгез әле, без дә бер - берегезгә күңел җылысы-елмаю бүләк итик. Урамда балкыган кояш кебек, бер-берегезгә карап елмаегыз да гәүдәләрне туры итеп куеп, дөрес итеп утырыгыз. Кәефегез яхшы булсын, гел елмаеп торыгыз. Әгәр ярдәм кирәк икән, гел янәшә булыгыз!

Шушы җылы мөгаләмәдә дәресне башлап җибәрик.

II. Актуальләштерү. Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән яраткан туган җир, аның һәркем өчен дә кадерле булуы турында әңгәмә оештыра.

- Укучылар, нәрсә соң ул туган җир, нинди була ул? Туган җир дигәч, сезнең күз алдына нәрсәләр, кемнәр килә? Туган җирегез турында сез нәрсәләр әйтә аласыз? Мин сезгә туган җирегезгә кагылышлы фоторәсемнәр алып килергә кушкан идем. Без алардан үзебезнең альбомны төзедек. (җаваплар тыңлана).

- Әйе, укучылар. Һәр кешенең үз туган җире бар. Аны һәркем үзенчә ярата, хөрмәт итә. Рәссамнар туган җиренә багышлап рәсем ясый, язучылар хикәяләрдә сурәтли, шагыйрьләр шигырьләр чыгара. Ә кемдер туган җиренә булган хисләрен күңелендә йөртә

-Туган җир турында нинди әсәрләр беләсез? (укучыларның фикерләре).

III. Уку мәсьәләсен кую. Укытучы бүген дәрестә туган җир турында сөйләшәчәкләрен, язучы А.Гыйләҗев иҗаты белән танышачакларын әйтә.

IV.Уку мәсьәләсен өлешләп чишү (презентация)

1.Язучының иҗаты, тормыш юлы турында мәгълумат.

-Кем ул Аяз Гыйлаҗев?Аның турында нәрсәләр беләсез?(язучы).

Укытучы: Әйе, укучылар, күренекле прозаик, драматург, М.Горький һәм Г.Тукай премияләре лауреаты, халык язучысы ул – А.Гыйлаҗев. Бүген без искиткеч гүзәл, тылсымлы, хикмәтле, серле дөньяга – А. Гыйләҗев геройлары дөньясына сәяхәт кылырбыз. Бүген дәрестә без аның әсәрләре белән танышырбыз, аларда күтәрелгән проблемаларны, авторлар әйтергә теләгән фикерләрне ачыклауны максат итеп куярбыз. Бүгенге дәресебезгә мин республикабызның беренче президенты, киңәшчесе Минтимер Шәймиев сүзләрен эпиграф итеп алам. “Аяз Гыйләҗев әсәрләре – татарны милләт, ил язмышына битараф булмаган оста каләм иясе кулы белән язылган хәзинәләребез. Аяз Гыйләҗев әсәрләренең тәрбияви кыйммәте әйтеп бетергесез зур. Алар – безнең милләтебезнең рухи байлыгы, милли үзенчәлекләре турында чорыбыз вакыйгаларына бәйләп язылган әдәби әсәрләр. Безнең чор кешеләренең яшәү рәвешләрен киләчәк буыннарга да алып бару вазифасы тапшырылган аларга. Ул күпләргә үрнәк булырлык төпле гаилә башлыгы, тирән фикер иясе булды. Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең мирасын яратып һәм хөрмәт итеп яшәсәк, рухи офыкларыбыз киңәер“. Укытучы: (презентация карау) А. Гыйләҗев киң колачлы талант иясе иде ул. Проза өлкәсендә, драматургия өлкәсендә дә зур уңышларга ирешкән язучы. Ул әдәбиятка 60 нчы елларда килеп керә. Бу чор-фикерләрнең каршылыклы чоры. Ләкин ул үз сүзен курыкмыйча әйтә килә. Бу адымга аны тоткан кыйбласының дөреслегенә ышаныч кына этәрә алгандыр. Аның кайсы гына әсәрен алсаң да, алар халык өчен, ил өчен борчылган олы әдипнең алыштырмас хәзинәләре.

Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 нче елның 15 гыйнварында Сарман районы Чукмарлы авылында туган. Ләкин аның балачагы Зәй районы Югары Баграж авылында уза. Әтисе Мирсәет, әнисе Мөгәттәрә укытучылар булалар. Алар өч бала тәрбияләп үстерәләр: Алмаз, Аяз һәм Азат. “Тәңремә рәхмәтлемен: ул мине туганда ук шигъри күңелле иткән. Шулай уйлыйм, хәтергә сеңеп калган вакыйгалар шуны сөйли” дип яза әдип “Балачак сукмаклары”нда һәм бу сүзләрнең дөреслеген А.Гыйләҗевнең мәктәп елларында язылган, беркайда да басылмыйча, бары тик кадерле истәлекләр генә булып сакланган кулъязмалары раслый. (Кулъязмаларга игътибар итү).

Тик Аяз аганың сукмаклары такыр гына булмый. 1948-1950 елларны ул университет студенты. Ул университетны ташлап яңадан авылына кайта. Моның төп сәбәбе: ачлык, ялангачлык. Аяз аганың тормышында иң аянычлы чор ул – 1950-1955 еллар. Бу елларны язучы Казахстан далаларында, Сталин концлагерьларында уздырырга мәҗбүр була. Ни өчен? Бары тик әсәрләрендә чагылган, шул чор режимына бик үк туры килеп бетмәгән үткен үткен фикерләре өчен.

Аяз ага бу чор турында мавыгып сөйләргә яратмаган. Ләкин үз сүзләре белән әйтсәк, ул бу чорны “бәхетле чор” дип атый. Чөнки ул биредә бик күп кызыклы шәхесләр

белән таныша, бик күп гыйбрәтле язмышлар аның күз алдыннан уза, кыскача ул сөргендә вакытта үзенең әсәрләре өчен бик күп материал – “әдәби чимал” тупларга өлгерә.

Аяз ага үзенең хатынын Нәкыя апаны кечкенә кызчык чагында ук күргән була. Шунда шаяртып “Кайтырмын да, өйләнермен үзеңә”, дигән сүз дә ычкындыра. Сөрген чорында ул энесе Алмаз белән очраша, Нәкыя турында сораша, һәм тәвәккәлләп аңа хат яза, Нәкыя аның өченче хатына гына җавап бирә.

Аяз азат булып туган якларына кайткач, алар өйләнешәләр. Бер-бер артлы өч уллары туа. (Искәндәр – профессор, КФУның факультет деканы. Мансур – язучы, драматург. Рәшат – табиб, эшмәкәр. Аяз ага уллары белән бик горурланган. “Мин татар дөньясына өч татар үстереп бирдем. Киленнәрем дә татарлар, оныкларым да татар булыр” дип әйткән сүзләре дә бар.

Укытучы: Аның нинди әсәрләрен беләсез? (Укучылар җавабы: “Өч аршын җир”, “Зәй энҗеләре”, ”Урталыкта”, “Язгы кәрваннар”, “Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят”, “Җомга көн кич белән”, “Әтәч менгән читәнгә”. Аяз Гыйләҗевнең "Йәгез, бер дога!" романы венгр теленә тәрҗемә ителде).

Укытучы: Беренче әсәрләрендә үк язу манерасы – кырыс реализм, халыкчан образларга бай җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары, кайсы чор турында һәм нинди темага язса да, кеше шәхесенең катлаулы рухи дөньясын, эш-гамәлләрен анализлау – А. Гыйләҗев иҗат эшчәнлегенң төп асылын, идея-эстетик юнәлешен тәшкил икән сыйфатлар.

Укытучы: Аның кайсы әсәрләре буенча фильм төшерелгән?

Укучылар: А.Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” һәм “Өч аршын җир” әсәрләре буенча төшерелгән “Бибинур” фильмы татар киносының Казан халыкара фестивалендә 2010нчы елда Гран-при алды.

Ял итү. Укучылар, ә хәзер әйдәгез ”Чәчелгән хәрефләр” уенын уйнап алабыз. (Интерактив тактада чәчелгән хәрефләрне җыеп, А. Гыйләҗев әсәрләре исемнәрен табалар. (Җаваплар: “Язгы кәрваннар”. “Дүртәү”, “Бибинур”, “Әтәч менгән читәнгә, ”Урталыкта”).

Укытучы: Укучылар, сезгә өй эше итеп язучының үзегезгә ошаган бер әсәрен укып килергә кушылган иде. Укыгансыздыр, дип уйлыйм. Хәзер төркемнәрдә эшләрбез. Укылган әсәрләрегез белән бер-берегезне таныштырырсыз (балалар төркемнәрдә эшлиләр).

1 төркемнең җавабы: Без А. Гыйләҗевның “Берәү” повесте белән таныштык. Укыгач, “Ни өчен яшьләр авылдан китә?” дигән сорауга җавап табасы килде. Бу сорау авылның киләчәген кайгыртып һәм авыл халкының язмышларын күреп борчылганнан соң туа. Әсәрнең төп герое – Исхак. Ул кечкенәдән авылны яратып, үз итеп үсә. Алдагы тормышын авыл белән бәйләр өчен авыл хуҗалыгы институтына укырга керә һәм бик яхшы укый. Эшкә ул зур дәрт һәм зур кызыксыну белән тотына. Аның эшенә рухын күтәрүчеләр тимер рухлы Нурулла, Хөсәен бар. Ләкин кисәктән генә Исхакның авыл белән арасы өзелә. Йөрәгендә җир хуҗасы булу хисе сүнә. Моны ни белән аңлатырга? Коммунизм ясыйбыз дип йөрүчеләр үзләре үк яшьләргә аяк чалалар. Район вәкиле Тазюков, култык астына утау чүпләрен кыстырып кайтып килгәндә хатыннарны яңаклаучы колхоз председателе Гыйльми Салихы хезмәт уяләренә бары тик кол итеп кенә карыйлар, аларны мәсхәрәлиләр. Яшьләрнең эшен җинаять дип кабул итәләр. Исхак билгеле үзенең шәхесен богаулап торган бу хезмәт коллыгыннан котылу теләге белән авылны ташлап чыгып китә. Җәмгыятьнең нигезендә ныклы таяныч булмаганга күрә,

шул чордагы системага колларча буйсынган авылдашларының пассивлыгына һәм алар ягыннан ярдәм килмәгәнгә күрә шәһәргә китеп, үзе өчен яңа мохитта яшәргә мәҗбүр була. Әсәрнең драматизмы – Исхакның туган җиреннән читләшүендә, аерылуында. Якташларының, туганнарының, дөнья күргән олы кешеләрнең үзенә карата мөнәсәбәтләре салкыная башлавын тою-егеткә иң кырыс һәм катгый хөкем. Безгә әсәр бик ошады. Башкаларга да тәкъдим итәбез.

2 төркем: Без Аяз Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән..." повестен укыдык. Повестьта Бөек Ватан сугышы чорындагы татар авылы тасвирлана. Повестьнең үзәгендә олы кеше – тәҗрибәле, тормышның ачысын-төчесен татыган, гомер юлының ахырына якынлашып килүче Бибинур образы. Аның бар кылган эше – игелек эшләү. Ул – чын күңеленнән чиста ярату белән ярата ала торган герой. Үз бәхетеннән баш тартып, чит кеше балаларын үз балаларыдай итеп тәрбияләп үстерә, аларга бар җылысын, ана назын бирә. Тик балалары аны оныталар, алар үз дөньялары белән генә яшиләр. Аларга хәтта "Туган" төшенчәсе дә ят. Алар битараф. Балаларның шәфкатьсезлеге башка яклардан да күренә. Нигә Бибинур өенә хәтта кунак чакырмый? Алай гына да түгел, кешенең өенә кергәнен яратмый? Чөнки авылдагы бердәнбер салам түбәле йорт Бибинурныкы. Ә ни өчен соң? Кайчандыр хәлле генә булган йортның эчендәге барлык әйберләрне балалары алып китеп бетергән. Чәй куеп эчерерлек чәйнеге дә калмаган әбинең. Бу аның кунак яратмавыннан түгел, ә оялуыннан. Монда ана күңеле – балада, бала күңеле – далада дигән мәкаль бик урынлы булыр иде. Әсәр Бибинурның үлеме белән тәмамлана. Аны үзе караган эте үтерә. Бибинурның эте белән балалары арасында ниндидер охшашлык та бар кебек. Алар үзләренә яхшылык эшләгән кешене онытканнар. Алар әниләрен генә түгел, туган илләрен дә, туган телләрен дә – кешене кеше итеп бизи торган иң гүзәл сыйфатларын да югалтканнар. Авыл сабантуйлары – туганнар очраша торган иң зур бәйрәм. Бибинур да балаларын көтә, ләкин бер генә баласы да шушы олы бәйрәмгә кайтмый. Үзләренең тамырларын белмәсләр, буыннар чылбыры югалыр, дип курка ана кеше. Ә бит бу битарафлылык, шәфкатьсезлек кебек сыйфатлар көннән-көн арта бара. Мондый гаделсезлек, мондый хәлләргә юл куярга ярамый, күңел сукырлыгыннан котылырга кирәк.

Укытучы: Рәхмәт икенче төркемгә. Бик актуаль тема күтәрдегез, укучылар. Чыннан да, әниләргә карата мондый шәфкатьсезлек бүгенге тормышта кимеми, киресенчә, артып тора. Укучылар, ә бит Бибинур язмышы – татар милләтенең рухи байлыгы. (җаваплар). Монда милләт проблемасы да, туган җиргә мөнәсәбәт урын алган. Ә ни өчен әсәр "Җомга көн кич белән" дип атала? (Көтелгән җавап: Сабантуй атнасы, җомга көн кич белән авылга сабантуйга бик күп кеше кайта. Бибинур гына ялгыз, һаман балаларын көтә. Тик балалары кайтмый. Ул ялгыз. Шуңа күрә дә әсәр "Җомга көн кич белән" дип атала.

Укытучы: Рәхмәт сезгә, укучылар. Өченче төркем, сүз сезгә.

3 нче төркем. Без А. Гыйләҗевнең "Өч аршын җир" повесте белән таныштык. Әсәрнең үзәгенә кискен бер мизгелдә хата кылган һәм шул ялгышы өчен гомерлек газапларга дучар ителгән Мирвәли язмышы куелган. Мирвәли яши башлаган чор – авыр чор, авылда күмәкләшү бара, колхозлар оеша. Бу яңалык авыл халкын икегә бүлә. Мирвәли кулак та, дошман да түгел, ләкин бер мәлдә ул авылдашлары, ил каршында гафу ителмәслек хата эшли. Мал-мөлкәтен, мал-туарын яндырып авылдан чыгып кача. Әлбәттә, ул күмәк хуҗалыкта да хезмәтеннән тәм табып эшләр иде. Чөнки ул моңарчы гадел яшәгән, яшь чагында әтисе йортында ялчы булган. Соңыннан да тегермәндә хезмәт

куйган, сугышта яраланып орден алган. Ләкин шул чор җәмгыятенә хезмәт итүче авыл активистларының этисеннән калган мал-мөлкәтнең язмышын хәл иткәндә Мирвәлинең фикерен сорап та тормаулары аны бик нык рәнҗетә: барысын да күмәк хуҗалыкка бирәсең, бетте-китте.Үзәктә тагын бер язмыш – Мирвәлинең хатыны – Шәмсегаян. Әсәрдә Шәмсегаянның туган җирен сагынуы, кичерешләре бик тирән, көчле. Бары тик китаплар, туган җир кырларын карта дәрәҗәсендә искиткеч төгәл сурәтләгән чигүле сөлге генә бераз сагышын басарга ярдәм итә. Җирсеп, гомере буе бәгырен телгәләгән туган туфрагын сагыну хәсрәтеннән үлем түшәгенә егылган Шәмсегаянның үзе талпынган Өч кое, нарат белән кочаклашып үскән каен белән кавышам дигәндә гомере өзелә. Мирвәли, хатынының мәете белән сөйләшеп, тормышын күздән кичерә, яшьлегендә тарихи вакыйгалар аркасында хата ясавын таный. Авылдашлары аны аны гафу итәләр. Ә Мирвәлигә авылдашлары кичерүе генә түгел, ә үзе алдында йөзе аклану, намусы чистару, үзен-үзе кичерү дә кирәк. Мирвәлине балалык дусты адашы – Мирвәлинең хөкем итүе очраклы түгел. Ул гади авылдаш кына түгел, ул – Мирвәлинең намусы, вөҗданы. Мирвәли – адашы аңа: «Еллар буе кара тир түгеп эшләп берни алмаган чакларыбызда безне кимсетмәделәрме? Әрнемәдекме?.. Тик туган җиребезне каһәрләп мөртәткә әйләнеп чыгып качмадык!», - дип белдерә.

Укытучы: Искиткеч матур әсәр укыгансыз, укучылар. Ә бу повестьнең төп идеясе нинди?

Укучылар: Туган җирнең һәр кеше өчен изге урын булуы. Ул кешенең җир тормышы чикләнгәнлеккә, адәм баласы кем генә булмасын, үз гомерендә ни генә кылмасын, соңгы сыеныр урыны җир икәнлеккә ишарә бирә. Илдә нинди генә җилләр иссә дә, кешенең туган җирен каһәрләргә хакы юк икәнлеген белдерә.

Укытучы: Әсәр сезгә ошадымы, ул бүгенге көндә дә актуальме? Ошаса да, ошамаса да, ни өчен? (Җаваплар: туган туфракка хыянәт итү темасы һәр заман өчен актуаль; дөрес яшибезме дип уйландыра; туган җирнең олы икәнлеген төшендерә; изге төшенчәләрне кадерләргә өйрәтә. һ.б.)

Укытучы: Әйе, укучылар, автор Мирвәлинең шәхси фаҗигасе аша кулаклар белән беррәттән чит җирләргә сөрелгән урта хәлле крестьяннарның гомумфаҗигале язмышында күтәрә.

Укучылар, А.Гыйләҗевнең искиткеч матур әсәрләрен укыгансыз. Бу әсәрләрнең барысында да язучы нинди уртак теманы күтәрә? (Җаваплар: туган җир темасын). Дөрес, укучылар, әлеге әсәрләрне укыгач, безнең күңелләрдә матур, нәфис хисләр уяна, без әхлакый кыйммәтләрне аңлыйбыз, уйлана башлыйбыз, матурлыкка омтылабыз. Без тагын шуны әйтә алабыз. Кеше бер вакытта да үзенең туган туфрагын онытмаска тиеш. Ә туган туфрак – синең этиең, әниең, туганнарың, туган өең! Без карап үткән әсәрләрдә күтәрелгән проблемалар бүгенге көндә дә бик актуаль. Бигрәк тә телебезгә куркыныч янаганда, татар телебез кыл өстендә торганда әдип язып калдырган сүзләр бигрәк тә актуаль яңгырый: үз телеңне камил бел, җиде буын бабаларыңның исемен бел, ата-аналарыңны санла, аларга шәфкатьле бул, балаларыңны матур татар рухында тәрбиялә, милләтеңнең йолаларын сакла, халкыңның үткәнен бел, аны башкаларга да өйрәт.

Проза һәм драматургия өлкәсенә караган кайсы гына әсәрен алсак та, аларда Туган иленә, халкыңа бирелгәнлек, туган теленә сүнмәс мәхәббәт хисләре урын алган. А. Гыйләҗев – үз халкының бүгенге язмышын, реаль мөмкинлекләрен дөрес аңлаган, аның серле, хәтта аңлаешсызрак киләчәге өчен дә чып-чынлап кайгырып, көенеп яшәгән, алда аны нинди хәвеф-хәтәрләр көтәсен дә сизеп-тоеп борчылган моңлы шәхес ул.

V.Рефлексия. (нәтиҗәләрне бәяләү, укучыларның уку эшчәнлегенә үзбәя бирүе). Рәхмәт, укучылар, чыгышларыгыз өчен. Без әле А. Гыйләҗев әсәрләре белән танышуны дәвам итәрбез

1.Укучылар, бүгенге дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Бүгенге сөйләшү сезнең өчен файдалы булдымы? Кайсы ягы белән? А. Гыйләҗев турында нәрсәләр белдегез? Аның нинди әсәрләре белән таныштык? Дәресебезнең темасын исебезгә төширик әле (”Туган җирдән аермасын язмышлар” )

- А. Гыйләҗевнең без танышкан әсәрләре бу теманы яктыртамы? (җаваплар).

2. Ә хәзер үзегезнең дәрестәге эшегезне бәяләгез.

Үзбәя. Кызыл түгәрәк: миңа дәрестә уңай, җиңел булды. Яшел түгәрәк: миңа дәрестә кызык булды, күп яңалык белдем, ләкин катнашырга кыенсындым. Зәңгәр түгәрәк: дәрестә авыр булды, ләкин кабатлармын, өйрәнермен.

3. Өй эшен аңлату һәм яздыру. Ул 3 дәрәҗәдә бирелә.

Укытучы: Тәкъдим ителгән биремнәр арасыннан үзегез эшли алырлык биремне сайлап көндәлекләрегезгә языгыз: а) А.Гыйләҗевнең әсәрләрендәге бер геройга характеристика язарга; ә) бүгенге дәрес турында мәкалә язарга; б) “Минем туган җирем” темасына сочинение язарга.

Укытучы: Дәрес тәмам, укучылар. Барыгызга да рәхмәт. Исән-сау булыгыз.

| |
|---|
| Класс: 9 (татар төркеме) |
| Предмет: татар әдәбияты |
| Тема: Шәфкатьлелек һәр заманда кирәк, шәфкатьлерәк булыйк, кешеләр!» (А.Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән» повесте буенча) |
| Максат: 1. А.Гыйләҗев тормышы, иҗаты буенча алынган белемнәрне ныгыту, камилләштерү.“Җомга көн кич белән..” әсәренең төп героена характеристика бирү.<br>Укучыларны хәзерге яшьләрнең яшәү рәвеше турында әңгәмәгә тарту, сөйләм телен, фикерләү сәләтен үстерү.<br>Укучыларда ата-анага, өлкәннәргә шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләү. Шәфкатьле, кешелекле булу мөселманнар өчен иң күркәм сыйфатларның берсе икәнлеген аңлату, әдәп-әхлак тәрбиясе бирү. |
| Планлаштырылган нәтиҗәләр:<br>Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр: өлкән буынга, туган җиргә, балаларын кадерләп үстергән аналарга ихтирам хисләре тәрбияләү; кешелеклелек тәрбиясенә юнәлеш бирү, индивидуаль эшчәнлек стилен формалаштыру.<br>1. Метапредмет нәтиҗәләр:<br>Регулятив УУГ: әсәрнең төп проблемасын табу, геройларның эшчәнлеген бәяләгәндә, үзеңнең, башкаларның фикерен дөрес бәяләү, төп нәтиҗәне чыгару эшчәнлегендә катнашу өчен тырышу.<br>Танып-белү УУГ: танып белү максатын аңлау, аңлап укый белү,укылган тексттан кирәкле мәълуматны табып аера белү,дәрестә алган мәгүлүматлардан файдаланып, сорауларга җавап бирү.<br>Коммуникатив УУГ: төп фикергә килгәнче, төрле җавапларны тыңлау; төркемнәрдә эшләгәндә, төрле мисаллар белән үз фикереңне дәлилләү; әсәрнең төп фикерен табу һәм формалаштыру,фикерләү сәләтен үстерү.<br>Предмет нәтиҗәләр:А.Гыйләҗев тормышы, иҗаты буенча алынган белемнәрне ныгыту, камилләштерү. “Җомга көн, кич белән...» әсәренең эчтәлеген белү, анализлый алу, укучылар белән әсәрдә үткәрелгән төп фикерне ачыклау. |
| Төп төшенчәләр: сабан туе, җомга, игелек, шәфкать, ятим. |
| Пространство оештыру: фикер алышу, әңгәмә, чыгышлар, сорауларга җавап, шәхескә юнәлдерелгән укыту технологиясе. |
| Төп ресурслар: А. Гыйләҗевның ” Җомга көн кич белән” повесте; аңлатмалы сүзлек, интернет. |
| Өстәмә ресурслар: А.Гыйләҗев турында күренекле шәхесләрнең сүзләре язылган плакатлар,презентация, интерактив такта, автор тормышы, иҗаты буенча язылган карточкалар, «Бибинур» фильмы , видеоязмалар. |

| Предметара бәйләнешләр:психология, татар теле. | | | |
|---|---|---|---|
| Эш формалары:фронталь эш,индивидуль, төркемнәрдә эш. | | | |
| Дәреснең тибы:әсәр өйрәнүне гомумиләштерү дәресе. | | | |
| **Дәрес этабы** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **УУГ** |
| **I.Оештыру. Эшкә кызыксыну тудыру**<br><br>Максат: дәрес эшчәнлегенә керешеп китү ихтыяҗы булдыру өчен шартлар тудыру. | *Дәресне башлау. Уңай эмоциональ халәт тудыру.*<br>Исәнмесез, хәерле көн! Кәефләрегез ничек? Элек-электән үк борынгы бабаларыбыз балаларын яхшы гамәлләр генә кылырга, өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәткән. Алар бер-берсенә күңел җылысын кызганмыйча, үзара ярдәмләшеп, тату гомер иткәннәр. Әйдәгез әле, без дә бер - берегезгә күңел җылысы - елмаю бүләк итик.Урамда балкыган кояш кебек, бер-берегезгә карап елмаегыз да гәүдәләрне туры итеп куеп, дөрес итеп утырыгыз. Кәефегез яхшы булсын, гел елмаеп торыгыз. Әгәр ярдәм кирәк икән, Гел янәшә булыгыз! Шушы җылы мөгаләмәдә дәресне башлап җибәрик. | Укучылар кулларны кулга тотынышалар, күңелдән генә бер-берсенә изге теләкләр телиләр, бер-берсенә карап елмаялар.<br>Хәерле көн, укытучым! | КУУГ: классташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү<br>ШУУГ:дустанә мөнәсәбәт, укучыга, укытучыга хөрмәт. |
| **II. Актуаль-ләштерү.**<br>Максат: элек үзләштергән белемнәрне мөстәкыйль рәвештә искә төшерү мөмкинлеге булдыру | *Шигырьне уку*<br>*Кирәксездер, артык җаннар белән*<br>*Тулыр иде күптән җиһаннар-*<br>*Ярый әле җирдә аз булса да*<br>*Мәрхәмәтле изге җаннар бар!*<br>*Ф. Яруллин.*<br>Хөрмәтле укучылар, бу дөньяда чорлар, дәверләр алышынганда да үзләренең кыйммәтләрен югалтмаган төшенчәләр бар. Алар-гомумкешелек сыйфатлары. Алар-мәңгелек. Алар яши, алар-гомерлек. Әнә шундый төшенчәләрнең берсе-шәфкатьлелек.<br>Укучылар, нәрсә соң ул шәфкать? Шәфкатьле булуны ничек аңлыйсыз?<br>*Бик дөрес. Кайсыгыз аңа фәнни телдә аңлатма бирә ала?*<br>*Бу сүзнең антонимы ничек була? Ул нәрсәләрдә чагыла?*<br>*Әйе, укучылар, мондый кешеләрне икенче төрле кызгануны белми торган, рәхимсез аяусыз кешеләр дип тә йөртәләр. Тормышта матурлык белән ямьсезлек, биеклек белән түбәнлек, мәрхәмәт белән* | Әңгәмәдә катнашу, сорауларга авап бирү<br><br>Сорауларга җаваплар.<br><br>Кешеләргә карата яхшы мөнәсәбәттә булу, аларга ярдәм итү; гел изге гамәлләр кылу, игелекле булу; өлкәннәргә, сабыйларга, мохтаҗларга игътибарлы булу. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә: шәфкатьле-кызганучан, мәрхәмәтле, күңелле. Шәфкать итү-яхшылык итү, игелек күрсәтү, ярдәм итү.<br>Шәфкатьсезлек.<br>Мондый кешеләр күбрәк үзләре турында гына уйлыйлар. Алар һәркемне, һәрнәрсәне рәнҗетергә мөмкин...<br><br>Укучыларның җаваплары | ШУУГ:уку эшчәнлегендә бер-берсе һәм укытучы белән хезмәттәшлек оештыру.<br>РУУГ: үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белү.<br>КУУГ: тыңлый белү, диалог төзүдә катнашу.<br>ТБУУГ: төп билгеләрне аерып күрсәтү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **III. Уку мәсьәләсен кую.**<br>Максат: яңа белемнәр кабул итүне оештыру, үзләштерүгә юнәлеш бирү.<br>**IV.Уку мәсьәләсен чишү** | *явызлык янәшә яши, ә шулай да ничек итеп шәфкатьле, игелекле булырга соң?Мәрхәмәт хисенең көчен, яшәү мәгънәсенең асылын аңлата торган әсәрләр дә байтак. Шулар арасында А. Гыйләҗевның "Җомга көн кич белән" әсәре үзенә бер урын тота.*<br>Без бүген дәрестә шәфкатьлелек турында сөйләшәчәкбез, А.Гыйләҗев иҗатын искә төшереп үтәрбез.<br><br>Әсәр турында сөйләшүне башлаганчы, А.Гыйлаҗевнең биографиясе буенча берничә сорауга җавап бирегез әле.<br>1.Кем ул Аяз Гыйлаҗев?<br>2.Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе аңа нинди әсәрләре өчен бирелгән?<br>3. "Җомга көн, кич белән..." әсәре бик күп телләргә тәрҗемә ителеп, илебезнең төрле төбәкләрендә ятатып укыла. Тагын шуны да искәртеп китмичә булмый: нәкъ шушы әсәр эчтәлегенә нигезләнеп, "Бибинур" исемле фильм төшерелде.<br>Ә хәзер, әйдәгез, үзебезнең "Җомга көн, кич белән..." әсәренә әйләнеп кайтыйк.<br>Әсәрнең төп герое-кем?<br>Бүгенге дәрестә без сезнең белән Бибинур образы, аның повестьта бирелеше, аңа авторның мөнәсәбәте турында сөйләшербез.Әсәр исеменә салынган эчке мәгънәне ачыкларбыз.<br>- Сез өйдә әлеге әсәрдән өзекләр белән таныштыгыз. Хәзер эчтәлекне тирәнрәк, төгәлрәк ачарга тырышырбыз. Иң беренче, әсәрнең исеменә игътибар итик әле, ул ничек атала?<br>Җомга нинди көн ул?<br>Әйе, атна буена нинди гамәлләр кылынган, шуларга нәтиҗә ясау, яки хисап бирү көне, ә кич белән көн-көн ахыры, көне буе эшләнгән эшләргә нәтиҗә ясау, хисап бирү вакыты.<br><br>Димәк, автор инде әсәрнең | Күренекле прозаик, драматург, М.Горький һәм Г.Тукай премияләре лауреаты, Халык язучысы ул А.Гыйлаҗев).<br><br>"Җомга көн, кич белән...", "Әтәч менгән читәнгә" әсәрләре өчен, 1982 елда.<br><br>Бибинур.<br><br>*"Җомга көн кич белән..."*<br>Татарлар, мөселманнар өчен - изге көн, мәчеткә бара торган көн. | РУУГ:дәреснең максатын билгеләү, аңа формулировка ясау, укытучы ярдәмендә үз эшчәнлегеңне планлаштыру.<br><br>ТБУУГ: уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү, төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру укыганнарны анализлау.<br>КУУГ: башкаларның сөйләмен ишетеп һәм тыңлап, үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү, үз фикерләреңә ышандыра белү.<br>РУУГ: үз эшчәнлегеңне контрольгә алу.<br>Шәхси УУГ:укучының башкарган эшенә җаваплылык хисен арттыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | исеменнән үк анық эчтәлегендә ни буласына ишарә ясый.<br>**3.***Әсәр эчтәлегенең укучылар тарафыннан аңлану дәрәҗәсен ачыклау әңгәмәсе.*<br>Бибинурның портретына игътибар итик әле. Нәрсә ул портрет? Аның нинди төрләре була?<br>Бибинур нинди? | Сабантуй атнасы. Җомга көн кич белән авылга Сабантуйга бик күп кеше кайта. Бибинур әби генә ялгыз. Аның янына беркем дә кайтмый. Ул берүзе утырып кала, һаман балаларын көтә. Шуңа күрә дә әсәр “Җомга көн кич белән”дип атала. | |
| | Әйдәгез, моны тагын да яхшырак күзаллау өчен, фильмнан өзек карыйк.<br>Тагын өстәп нәрсә әйтә аласыз? | ***Җаваплар.***<br>***Төркемләп эш:*** 1төркем - тышкы, 2 төркем эчке сыйфатларын дәреслектән табалар, һәр төркемнән берәр укучы тактага, калганнар дәфтәрләренә язалар, эчке портретына мисаллар китерәләр<br>**Портреты**<br>**Тышкы** **Эчке**<br>кечкенә бай буйлы күңелле<br>сабыр ябык<br>мәрхәмәтле<br>олы яшьтә (һ.б.) түзем<br>ярдәмчел<br>Өзек карау. | РУУГ: һәр төркемнең бәясен тыңлап, нәтиҗә чыгару, алдагы адымнарны фаразлау.<br>КУУГ: коллектив фикер алышуда катнашу |
| | Бибинур, бәхетеннән ваз кичеп, ни өчен Габдуллаҗанга кияүгә чыга? | Бибинур - ... бәләкәй генә гәүдәле, ябык аркалы, авылдашлары күзенә дә алай артык чалынмаган, тыныч холыклы, йомшак тавышлы, этисе төсле зәп-зәңгәр күзле, ярдәмчел, оста, җитез, чиста, сабыр татар карчыгы.Ул Габдуллаҗанның 3 баласын тәрбияләп үстергән, аларга гел ярдәм итеп яшәгән. Пенсия акчасын да балаларына җибәреп бара. Үзенең өсендә кырык ямаулы күлмәк ыштан, тузган яулык, ләкин карчык бик чиста, өендә чүп булмаса да аны гел җыештырып тора.) | ШУУГ: уку эшчәнлегендә бер-берсе һәм укытучы белән хезмәттәшлек оештыру.<br>РУУГ: үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белү. |
| | Ул аларны ничек тәрбияли? Чын әни кебек Бибинур балаларны яратамы? Ул алар өчен нәрсәләр эшли? | Бибинур балалар бакчасында эшли, шуңа күрә ул Габдуллаҗанның әнисез калган якын күрә, аларны кызгана. Бу балаларны кызгану, аларга ярдәм итү теләге Бибинурны, сөйгән | КУУГ: тыңлый белү, диалог төзүдә катнашу.<br>ТБУУГ: төп билгеләрне аерып күрсәтү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Татар халкында шундый мәкаль бар: “Тапкан ана түгел, баккан ана.” Аңлатып бирегез әле.<br>Шулай итеп, аналарының күңеле һәрвакыт кемдә булган?<br>Балаларның, үсеп, кеше булгач, Бибинурга мөнәсәбәтләре ничек?<br><br>Ә балаларының күңеле аналарында булганмы?<br><br>Менә шул балалары турында Бибинур кемнәр белән сөйләшә?<br><br>*Ул ничек яши?*<br><br>*Бибинурның өе нинди?*<br><br>Ни өчен яшел чирәм? Яшел чирәм нәрсәне аңлата?<br>Әйе, укучылар, чирәм әбинең ялгызлыгына ишарә ясый: трактор, машина таптамаган, җир бозылмаган.<br><br>Бибинур татар хатын-кызларына хас нинди сыйфатларны үзендә туплый? | егетен ташлап, Габдуллаҗанга кияүгә чыгарга этәрә.<br>Әйе, без аны балаларның әнисе дип әйтә алабыз. Чөнки ул аларны шундый авыр елларда үстергән, үз кочагына алган. Бөтен көчен, яшәү рәвешен аларга бирә, укыта, хәленнән килгәнчә ярдәм итә.<br>Җаваплар.<br>Аналарының күңеле балада булган.<br>Балалары таза тормыш белән яшиләр. Шулай да әниләренә ярдәм күрсәтәсе урынга алар хәтта хат та язып салмыйлар. Бер генә җылы сүз дә юк. Авылдашлары моны яратмый.<br>Юк, балаларының күңеле аналарында булмаган. Алар әниләренең кайтып хәлен дә белмәгәннәр. Әнигә түгел, акчага, байлыкка табынып яшәгәннәр. Чынлап та, аларның күңеле читтә - далада булган.<br>Балалары турында ул хәзер авылда беркем белән дә сөйләшми, аксыргаклыларның алар турында, сүз кузгатканнарын да яратмый, сөйләштерми дә. Балалар белән ул дөньяда бары тик бер кеше белән – аларны тудырган ана – Гайшә беләп генә сөйләшә ала. Алар икесе генә сөйләшә алалар,шуның өчен ул Гайшә каберенә йөри.<br>Коры пенсиягә яшәгәнгә, аның ашау-эчүе дә каты-коты гына. “Бәрәңге тәгәрәтеп пешерсә, ул аны өстәл янына килгәләп, көне буе чемченеп ашап бетерә”. Эчке киемнәре ямаулы. Аңасын алып кияргә акчасы юк.<br>Өе- ишелеп төшәргә торган салам түбәле йорт. Ишегалды яшел чирәм.<br>Тапталмаган,чөнки бу өйгә кеше аз керә. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Ә сез ничек уйлыйсыз, автор үз героен яратамы? Ни өчен?<br><br>Бик дөрес. Бибинур-искиткеч гүзәл герой.Ул ярата белә, шәфкатьле була белә. Шул игелекле гамәлләреннән мәгънә таба. А. Гыйләҗев кешедәге шул матурлыкны юксына. Юкка гына автор аны Биби дип атамый. “Биби” фарсы теленнән “хуҗабикә” дип тәрҗемә ителә. Габдуллаҗан өенә Бибинур яктылык, нур алып килә.<br>Ә Бибинурның язмышы ничек төгәлләнә соң?<br>Әйе, Әби кич, кояш баегач, җомга үткәч үлә. Ул бу дөньялыктагы бурычларын үтәп бетерергә тели. Зөһрәбануның тормышын җайлый. Галикәйгә ярдәм итә, әти-әнисенең нигезен хуҗалы итә.<br>Бибинурның эте белән балалары арасында охшашлык юкмы?<br><br>Ә сезгә Бибинур ошадымы? Дөрес, укучылар. Әйе, Бибинур кебек кешеләр тормышыбызны матурлыйлар, мәхәббәтнең олылыгын раслыйлар. Шәфкатьлелек, игелеклек үрнәге булып торалар.<br>Бибинур-татар милләтенең рухи байлыгы. Туган туфрагын саклаучы кеше, чын татар анасы.<br>Кешеләрдә яхшылык сыйфатлары, шәфкатьлелек кими баруның сәбәпләре нәрсәдә дип уйлыйсыз?<br><br>“Җомга көн, кич белән...”әсәре хәзерге вакытта да актуальме?<br><br>Бибинурның балалары кебек әти-әнисен оныткан кешеләр бармы? | Бибинур татар хатын-кызларына хас иң яхшы сыйфатларны үзенә җыеп алган. Ул – эш ярату, авырлыкка түзә белү; кимсетсәләр, гафу итә белү; сер саклый белү. Бибинур - дөнья каршысында да, Алла каршысында да изге җан. Ул барлык кешегә яхшылык кына эшли.<br>Ярата. Ул аны җылы хисләр белән яратып иҗат иткән. Автор аның белән бергә шатлана да кайгыра да .<br><br>Бибинурның гомере бик аянычлы өзелә. Аны үзе караган эте үтерә.<br><br>Бибинурның эте белән балалары арасында ниндидер охшашлык та бар кебек. Алар үзләренә яхшылык, шәфкатьлелек эшләгән кешене онытканнар.<br>Җаваплар. Әйе. Ул үч саклый белми, гафу итә белде, көчсезне яклады, усалның күңеленә шәфкать җылысы җибәрергә тырышты. Гайбәт сөйләмәде.<br><br>Бездә сатыла торган китапларда кеше үтерү, фахишәлек турында сөйләнелә.Телевизордан пычрак күренешләр бик күп күрсәтелә. Әлбәттә заманга бәйле, кешеләр байлык, дәрәҗә артыннан куып, ата- | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Әйе, укучылар, тормыш артыннан куып, туганлык, үзара ярдәмләшү, олыларны олы итү мәрхәмәтлелек, миһербанлылык сыйфатлары югалып бара. Бу сыйфатларның югалуы олы фаҗигаләргә китерә. Бүгенге көндә күпме ата-ананың балалары тарафыннан кимсетелеп, йортларыннан куып чыгарылуы, картлар йортына илтеп ташлаулары турында, ул гына да түгел, хәтта үтерүгә барып җиткән очракларны да көндәлек матбугат битләреннән дә,<br>зәңгәр экраннар аша да күреп-ишетеп торабыз. Хәзер шул темага караган кайбер мәгълүматларны карап китик әле. (слайдлар карала) Укучылар, бүгенге тема сездә нинди хисләр калдырды? | анасын, туганнарын оныта бара, көнчелек, тупаслык, дорфалык сыйфатлары алга сөрә.Әби-бабайларның дәрәҗәсе төшә, балалары алардан аерым яшәргә тырыша.<br>Бу тема бүген дә актуаль. Хәзерге көндә дә үз эти-әнисен рәнҗеткән, олыгайган көннәрендә тәрбияләмәгән, картлар йортында яшәткән кешеләр бар. Аларны аналары, төн йокыларын калдырып, үстергән, укыткан, кеше итергә тырышкан. Шул балалар картлык көннәрендә ярдәм итмиләр. Алар иртәме-соңмы үзләре дә картаячаклар. Алар үзләренең балаларына нинди үрнәк күрсәтәчәкләр. Син эти-әниеңне ничек карасаң, киләчәктә балаларың да сине шулай тәрбияләр.<br>Шуңа күрә бер-беребезгә, эти-әниләребезгә шәфкатьле, мәрхәмәтле булыйк.<br>Җаваплар. | |
| **VIII. Рефлексия. Уку эшчәнлегенә нәтиҗә.**<br>Максат: дәрестәге эшчәнлекне анализлау, белемнәрне бәяләү һәм киләчәккә перспектива билгеләү; үз фикереңне дәлилләү, дәрестә алган белемнәрнең әһәмиятен аңлау, аларны киләчәктә куллана белү | **Укытучы укучылар белән берлектә эшкә йомгак ясый.**<br>Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чи<br>Укучылар, мин сезгә дәрес башы<br>Яруллинннның шигырьнән өзек укыг<br>Анда әйтелгән мәрхәмәтле жан<br>Бибинурга туры киләме?<br>Мин аның белән килешәм. Кешелеклелек сыйфатлары бетү милләтнең, илнең бетүенә китерә.Балаларның шәфкатьсезлеге карап үстергән әниләрен генә түгел, туган илләрен дә, туган телләрен дә- кешене кеше итеп бизи торган иң гүзәл сыйфатларын югалтуга китергән.<br>Укучылар, үзегезне бүгенге дәрестә эшегезне бәяләгез (җөмләләрне язып бетерергә)<br>Иптәшегез белән киңәшегез.Ул сезгә нинди бәя бирде? Язып куегыз.<br>Кешелек һәрвакыт борчып килгән шәфкатьлелек, намус, җирдә дөрес итеп яшәү, әти-әни алдындагы | Җаваплар.<br>Язучы кешеләрдә яхшылык сыйфатлары кимегәнгә кайгыра, борчыла. Кеше үз гомерендә күбрәк изгелек эшләргә, башкаларга карата ихтирамлы, игътибарлы булырга, кылган гамәлләре өчен җавап бирә белергә тиеш<br>Укытучы тараткан кәгазь битләренә әлеге дәрес турында фикерләр языла:<br>Мин бүген дәрестә.... өйрәндем.<br>Кызыклы булды:...<br>Мин ... аңладым.<br>Мине .... гаҗәпләндерде.<br>Мин .... телим.<br>Мин ... билгесенә лаек. | ШУУГ: үз уңышларың, уңышсызлыклары ң сәбәпләре турында фикер йөртү.<br>ТБУУГ:фикерне аңлы һәм ирекле рәвештә әйтеп бирү.<br>РУУГ: үз эшчәнлегеңне контрольгә алу.<br>КУУГ: Иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү, хезмәттәшлек алымнарын билгеләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | бурычны үтәү кебек төшенчәләр мәңгелек. Аларны үзеңдә булдыру өчен Кеше булу кирәк. Һәм мин дә сезнең чын кешеләр булуыгызны телим. Рәхмәт сезгә, балалар! Матур җавапларыгыз, төпле фикерләрегез өчен рәхмәт. | | |
| **Өй эше**<br>Максат: өй эшен хәбәр итү, аны башкару ысулын аңлату | **Өй эше 3 дәрәҗәдә тәкъдим ителә:**<br>1нче дәрәҗә (мәҗбүри): Әсәрне тулы вариантта укырга;<br>2нче дәрәҗә (ярым иҗади): Әти-әниләр турында мәкальләр, шигырьләр тупларга;<br>3нче дәрәҗә (иҗади): “Кешеләрдә яхшылык сыйфатларының кими баруы һәм аның сәбәпләре” дигән темага хикәя төзергә.<br>Билгеләр куела. | Үз мөмкинлекләреннән чыгып, биремнәрне сайлап алалар. | ТБУУГ: белем дәрәҗәсен исәпкә алып, өй эшен сайлау. |

Нәбиуллина Гөлназ Ринат кызы,
Яр Чаллы шәһәренең 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе

**Аяз Гыйләҗев «Җомга көн кич белән» әсәрен анализлау тәҗрибәсеннән**

Мәктәптә альтернатив дәреслекләргә нигезләнеп төзелгән программада Аяз Гыйләҗев иҗатын һәм әсәрләрен өйрәнү түбәндәгечә куелган: «Тормыш юлы. Иҗаты. «Җомга көн, кич белән». Повестька анализ. Әсәрнең фокусын табу. (Буа тавышының фокус булуын күп тапкыр кабатлануыннан беләбез.) Буа тавышының мәгънәсен табу.

Программа нигезендә түбәндәгеләрне үзләштерү каралган.

Бибинур әбинең игелеге, шәфкатьлеге, сабырлыгы, горурлыгы, мәхәббәте. Балаларының рәхимсезлеге дә, тормыш авырлыгы да җиңә алмаган көчле рухы – борынгылар рухы. Мондый изгелекнең безнең тормыш өчен кирәк булуы. Язучының, Бибинур әби кебек әбиләр белән бергә, изгелекнең дә югалуына борчылуы. Аяз Гыйләҗевнең язу стиле – парадоксларны яратып куллануы. «Парадокс» атамасына аңлатма. Йомгак.

Әсәрләрдә идеологиягә каршы куелган милли рух идеалы. Бөек Ватан сугышы елларында үзкыйммәткә әйләнгән шәхес матурлыгын тасвирлау. Шәхес кичерешләрен вакыйга, хәтта сюжет бөтенлеге итеп хәрәкәткә китерүне аңлату.

Уңай геройны милли рухларын саклап калган өлкән буын итеп сурәтләү» [Татар урта гомуми белем бирү мәктәпләрендә альтернатив... 2008: 66-67].

Программа нигезендә, әсәр шул рәвешчә анализлана дип тәкъдим ителә. Шул ук нигездә, югары сыйныфларда Аяз Гыйләҗев иҗатын һәм аның «Җомга көн кич белән» повестен сыйныфтан тыш дәрес итеп яисә өстәмә дәрес итеп оештырырга да мөмкинлек бар.

Максатыбыз – Альберт Яхин тарафыннан тәкъдим ителгән анализ калыбында Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән» әсәрен укучыларга сыйныфтан тыш дәресләрдә яисә өстәмә дәресләрдә анализлауны тәкъдим итү.

§1. Мәктәптә Аяз Гыйләҗев «Җомга көн кич белән» әсәрен анализлау

Сыйныфтан тыш яисә өстәмә сәгать итеп бирелгән дәрестә укытучы дәреслектә бирелгән текстка [Яхин 2008: 292-319] яисә җыентыкка [Гыйләҗев 1982] нигезләнә.

Моңа өстәмә буларак чыгарылган методик кулланмада [Яхин 1996: 131] Альберт Яхин тарафыннан әсәрне анализлау үрнәк тә бирелә.

Иң беренче эш итеп повестьның сюжеты ачыклана. Повесть сюжетын: Бибинурның яшьлектәге мәхәббәте, картлыктагы мәхәббәте, туганы Зөһрәбануга мөнәсәбәте, балаларын яклавы дип берничә сызыкка бүлеп өйрәнү эшне җиңеләйтә. Ләкин сюжетны сөйләп чыгу әсәрнең эчтәлеген табу дигән сүз түгел. Эчтәлек анализ нәтиҗәсендә табыла. Әсәрне өлешләргә таркатуның максаты – аның төзелешен табу. Максатка ирешү өчен өстәмә эчтәлек бирердәй өлешләр эзләнә. Бу эшне әсәр сюжетын бик яхшы белгәндә генә башкарып була.

Әсәрнең сюжетына карата түбәндәге биремнәр һәм сораулар куела.

1. Сюжет сызыкларының һәрберсендә диярлек берничә вакыйга бар. Шуларны җыеп бөтен бер сюжет, бер вакыйга итеп күз алдына китерегез, дигән бирем бирелә. Тәмамлануын күрсәтегез. Бик кыска итеп шуны әйтеп бирегез.

2. Сюжет сызыкларының үзара бәйләнешләре дә булырга тиеш. Шул бәйләнешне табыгыз.

Икенче – әсәрнең төзелеше өстендә эш алып барыла. Әсәргә эчтәлек өсти торган вакыйгаларын автор ничек кенә булса да үзенең укучысына күрсәтергә тырыша. Шундый вакыйгаларның берсе – буа тавышы. Бу тавыш әсәрнең башыннан ахырына кадәр ишетелеп тора. Аңа Бибинур карчык та, автор да кат-кат бәя бирәләр. Тиктомалга кабатламавын искәртеп, Аяз Гыйләҗев аны иң хәтәр вакыйгалар янына куя, әнә шул вакыйга белән бәйләп карарга өнди. Буа тавышы белән бәйле вакыйгалар, ягъни турыдан-туры буага караган вакыйгалар әсәрнең бер өлеше була ала. Икенче өлешне ачыкларга керешкәнче, бу образ ныклап өйрәнелә. Укытучы укучылар алдына сораулар куя.

1. Буаның үзенә генә караган сыйфатларны табыгыз һәм 1 нче, 2 нче, 3 нче һ.б. дип дәфтәрләрегезгә язып куегыз.

2. Буа тавышы Бибинурга яки авторның үзенә нинди вакыйгалар белән бәйле рәвештә ишетелә башлый? Ул вакыйгалар башкаларыннан кай яклары белән аерылып торалар?

3. Бу тавыш Бибинурга ничек тәэсир итә? Һәм ул аңа карата нинди мөнәсәбәттә?

Повестьның буа тавышы белән бәйле өлеше әсәр эчтәлеген кайсы яктан ачыклый һәм баета? Бу сорауга җавап бирү өчен, вакыйгаларның башкаларын өйрәнергә кирәк. Әмма алар күп һәм төрле. Мәсәлән: Бибинур көтелмәгән эш эшли – яраткан егетенә кияүгә чыгудан баш тарта да яратмаган кешесенең хатыны була. Икенче төрле әйткәндә, бер нәрсә ниятли, шуның киресен эшли.

Сюжет сызыкларының башкалары да шуңа охшашлы көтелмәгән борылыш ясавын күрәбез. Башка вакыйгаларда да укучы бер нәрсә көтеп торганда, шуның киресе белән очраша. Кыскартып сюжетның ахыры баш өлеше белән каршылыкка килә дип әйтергә мөмкин.

Бу алымны Аяз Гыйләҗев күп кабатлый. Шуңа күрә аны язучының стиль үзенчәлеге дип бәялибез. Алга таба сюжеттагы шундый көтелмәгән борылышларның башкалары да таптырыла. Шундый борылышларны табу өчен укытучының сораулары, биремнәре мондыйрак булырга мөмкин.

1. Бибинурның яшьлек мәхәббәте ни өчен шулай көтелмәгән борылыш белән тәмамлана?

2. Көтелмәгән дәвамы булган башка вакыйгаларга да шундый ук сорау куегыз һәм аларга да җавап бирегез.

3. Бибинур үзе: «Ятим балаларны кызгандым», – дип җавап бирә, үзен аклар өчен башка сәбәпләр дә таба. Ләкин бу җавап Бибинур карчыкның үз аңлатмасы гына әле. Яшь, чибәр кызның үз теләге белән үзен үзе бәхетсез итүенә авылдашлары бөтенләй башка бәя бирәләр. Берәүләр аны кызганалар, икенчеләре акылсызлыкта гаеплиләр.

4. Ә авторның үз бәясе нинди?

Аяз Гыйләҗев, әлбәттә, үз бәясен повестенда турыдан-туры сөйләп тә биргән булыр иде. Әмма кеше хисләрен бер генә мәгънәле эчтәлек бирә ала торган төшенчәләр белән әйтеп бирергә мөмкин түгел. Моның өчен әдәбиятның үз алымнарыннан файдаланырга кирәк. Аяз Гыйләҗев тә шулай итә.

5. Авторның Бибинур мәхәббәтенә карата бәясен әсәрнең кайсы урыныннан белеп була?

6. Повестьта авторның башка вакыйгаларга биргән бәясен дә әйтегез.

Алга таба табышлар гомумиләштерелә. Мондый нәтиҗә ясала: повестьның беренче өлеше буа тавышы булса, икенчесе – вакыйгаларның табигый юлдан тайпылуы, үзенә үзе каршылыкка килүе. Без аларны нәкъ менә шул уртак сыйфатларына нигезләнеп гомумиләштерәбез һәм бөтен бер өлеш дип исәплибез.

Икенче өлештәге һәр вакыйга каршылыкка корылган, һәр каршылык «Ни өчен?» дигән сорау тудыра. Җавапсыз сорау¬ларга проблема, диләр. Димәк, әсәрнең икенче өлеше тоташ проблемалардан гыйбарәт.

Икенче өлешне җыйдык, гомумиләштердек һәм иң әһәмиятле ягын таптык. Хәзер повестьның беренче өлешенә кире әйләнеп кайтабыз һәм аның ни өчен өзлексез кабатланып торуын белә алабыз. Буа тавышы әлеге сорауларга җавап була алмыймы? Авторның әйтәсе килгән фикере шул тавышның мәгънәләрен тапкач ачыкланмыймы?

Әсәрнең төзелешен, ягъни буа тавышы эчтәлегенең төп вакыйгаларга бәйләнешен табу – эчтәлек табу дигән сүз. Әлеге фикерне укучылар дәфтәргә дә язып куялар.

Шунда ук Аяз Гыйләҗевнең стиле дә тикшерелә. Стиль язучының яраткан алымна ры булуын яхшы беләбез. «Җомга көн, кич белән» повестенда Аяз Гыйләҗевнең аеруча яратып кулланган алымы – сюжет сызыкларын парадокс итеп төзү.

Парадокс дип күпчелек тарафыннан кабул ителгән фикерләргә, күзаллауларга кискен рәвештә каршы булган, кеше ышанмаслык булып тоелган фикер яки күзаллауларга әйтәләр.

Укучы сюжеттагы һәр табигый булмаган борылышка игътибар итә һәм: «Нигә болай булды соң әле?» – дип үзенә үзе сорау бирергә мәҗбүр була.

Җавапны ул әсәрнең буеннан-буена сузылган, күп тапкыр кабатланган метафора-вакыйга белән бәйләнештә таба. Җавапта әсәрнең эчтәлеге ята.

«Җомга көн, кич белән» повестеның бу төзелеше Аяз Гыйләҗев иҗат иткән әсәрләрнең күбесенә хас. Моңа кадәр өйрәнгән авторларда очрамаган бу алым Аяз Гыйләҗевнең иҗат үзенчәлеге, стиле дип әйтә алабыз.

Повестьны укыганда игътибар итәргә кирәк булган бер момент бар: әдип вакыйгаларны әле бер персонажы, әле икенчесе авызыннан сөйләтә. Алар һәрберсе вакыйгаларга үз бәяләрен бирәләр, бу бәяләр күп очракта бер-берсенә капма-каршы була. Көтмәгәндә, битараф бер күзәтеп торучы булып, автор үзе хикәяләргә керешә. Ләкин аның яраткан алымы – үзе персонажга әйләнеп әсәр вакыйгаларына бәя бирү. Шундый чакта ул үзен әсәр эчендә бик иркен тота: бу парадоксны аңламаслар ахры дип, борчылып, Бибинур

уйларын, аның эшләгән эшләрен аңлатырга керешә. Фәлсәфәгә бирелеп китә, хәтта, лирик герой вазифасын үтәп, үзенең хисләре турында да сөйли башлый. Пафоска бирелергә дә күп алмый. Укучысына мөрәҗәгать итеп, аңа да акыл биреп ташлый.

Хикәяләү алымындагы бу үзенчәлеген Аяз Гыйләҗев башка әсәрләрендә дә кабатлый. Шуңа күрә интонациянең еш үзгә¬рүен шулай ук стиль үзенчәлеге дип саный алабыз. Стиль әсәр төзелешен тулыландыра, эчтәлекне ачарга ярдәм итә, аны аңлата.

Нәтиҗә ясала. Бибинур әби буа тавышын иң шатлыклы чагында да, башын кая куярга белми йөргәндә дә ишетә башлый. Буа тавышы – читтән килгән өн. Әмма ул Бибинурның үзенә генә ишетелә һәм аны гына борчый, каядыр өнди, нидер эшләргә кыстый. Бу тавыш аның игътибарын җәлеп итеп кенә калмый, һәр эшенә катнаша.

Нинди тавыш соң ул? Кайгы белән шатлыкны уртаклашып, ни эшләргә кирәклекне сүзсез генә әйтеп торучы тавыш.

Буа ул – туган җир билгесе. Туган ил табигатенең тавышы. Ул Бибинур әбигә туган туфрак хисе аша тәэсир итә. Бибинур әби карарларын үзе кабул итә, әмма моны ул туган туфрак хисенә буйсындырып эшли. Нәкъ менә шул хис Бибинурның шәфкатьлеген мәхәббәтеннән өстен чыгара. Ятим балаларга ярдәм итү омтылышын даими, тотрыклы бәхет дип ышандыра. Карт Габдуллаҗан өенә китерә.

Мәхәббәт ул кеше ихтыярына буйсынмыйча килә, аңардан рөхсәт сорамыйча китә. Ул, буа шаулавы кебек, кешене үз көченә буйсындыра, аның ихтыяр көчен, акылын җиңә һәм бөтенләй мәгънәсез булып күренгән эшләр эшләтә.

Буа шаулавын мәхәббәт итеп тә кабул итәргә була.

Бибинур үз гомерендә егетләрне яратырга өлгерми кала. Үги балалары өчен ул җанын да кызганмый. Әмма балалары шундый ук хис белән җавап бирә алмыйлар. Балаларга булган мәхәббәт тә үги балаларны кызгану, шәфкатьлек күрсәтү булып кына кала. Ә бит адәм баласы үз гомерендә әле үзенең оныкларын да яратып өлгерергә тиеш. Кеше мәхәббәтнең шундый өч төрен үтсә генә, бәхетле була ала. Бибинур оныкларын, дөресрәге, үги балаларының балаларын бөтенләй күрми. Аның мәхәббәте, буа кебек, иреккә чыга алмыйча кала. Ул, буа кебек, азлап кына, ләкин тавышланып, зарланып кына ага. Ләкин мәхәббәт хисе иреккә чыгарга ашкына. Моның өчен ул уңайлы шарт кына көтеп ята. Ниһаять, шарт туа, авылга нечкә күңелле, кешеләрне хөрмәт итә торган, матурлыкка гашыйк кеше килә. Һәм Бибинур күңелендә буылып торган мәхәббәт тышка бәреп чыга. Хәзер ул Җиһангирны уллары итеп тә, оныклары итеп тә ярата. Үз егетенә, иренә, улларына, оныкларына булырга тиешле мәхәббәт бөтенләй башка кешегә багышлана. Әмма ул кеше шундый мәхәббәтләрнең барысына да лаек.

«Буа тавышы – кечкенә елгачыкның ирек даулавы, моңы, зары. Шуңа күрә ул мескен Бибинур карчыкның да тормышта үз урынын, кешечә яшәргә шарт, ирек, хокук даулавына метафора булып килә» дигән фикер дә туарга мөмкин.

Бу фикер белән дә килешергә мөмкин. Ирексезлекнең нидән гыйбарәт булуын ачыклыйк. Бибинур әби бөтен гомере буе башкаларга ярдәм итә. Ул – шәфкать анасы – башкача яшәүне күз алдына да китерми. Ярдәм итүне ул кемгәдер яхшылык эшләү дип тә уйламый. Шәфкатьлелек – Бибинур әбинең гадәти яшәү рәвеше. Шуңа күрә ул танышына да, таныш булмаган кешеләргә дә, дошманнарына да ярдәм итәргә генә тора. Шул максатында яшьлеген дә, мәхәббәтен дә, гомерен дә кызганмый.

Яхшылык һәрвакыт кешеләргә яхшылык булып кайткан. Элек шулай булган. Ләкин заманалар үзгәргән, заманалар белән бергә кешеләр дә үзгәргәннәр. Яңа заман үзгәрткән кешеләр өчен риясыз игелек кирәкмәс бер сыйфатка әйләнгән. Бибинур карчыкны

аңламыйлар һәм аңларга теләмиләр дә. Намусы ни кушса, Бибинур шуны эшли. Аның һәр кылган гамәле – үзе өчен табигый гамәлләр. Зөһрәбану аның турында гайбәт таратып йөри – Бибинур сеңлесеннән үч алырга җыенмый да, киресенчә, ничек кенә булса да аны бәхетле итү турында борчылып уйлана. Үстереп кеше иткән балалары ташлаганнар – Бибинурның иң зур кайгысы – шуларны кешеләр каргышыннан аяп калу.

Бибинурның мәшәкатен дә, кайгысын да авыл халкы аңламый, шуңа күрә әби үз эченә йомыла, үз эчке дөньясы белән яши башлый. Аны берәү дә рәнҗетми, иреген кысмый. Әмма Бибинур шуңа карамастан ирексез: ул ялгызлыгы, йомыклыгы, кайгыларын кешеләр белән уртаклаша алмавы белән ирексез.

Йомгак ясала. Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә төп игътибар кеше язмышын сурәтләүгә юнәлтелә. Ул – олы кешеләр язмышы. Өлкән кешеләр язмышының иң зур драмасы – заман белән уртак тел таба алмауда.

Бу конфликт бик үзенчәлекле: өлкәннәр буыннар арасындагы җепләрнең өзелүен күреп борчылалар, бәйләнешне торгызырга тырышалар. Ә аларның уллары белән оныклары картларга каршы көрәшмиләр. Алар олылар әйткәнне, гомумән, колакларына да элмиләр. Бу каршылык гаилә эчендәге проблема чикләренә генә сыешмый.

Әдипне буыннарны туган туфрак хисе бәйләп тора. Ә бабайлар буынын балалар буыны белән бәйләүче туган туфрак хисен һәр ике әдип милләтне яшәтә ала торган иң куәтле көч дип исәпли.

Аерым кешеләр язмышы, шул рәвешле, милләт язмышы югарылыгына күтәрелә.

Аяз Гыйләҗев әсәрендә дә өлкән буын вәкилләре үзләренең язмышларын милләт язмышы белән бәйләмиләр. Милләт үзе аларның иң изге ышанычларын таптап, изеп китә. Әдипне милләтнең үзен үзе һәлак итүе борчый. Туган туфрак хисен югалтуны әхлаксызлык дип бәяли.

Мондый күренешләрне Әмирхан Еники иҗатында да күререгә мөмкин. Әдипләр татар халкында үзен милләт буларак саклап калырлык көч барлыгын күрсәттеләр. Аны һәр әдип үзенчә атады һәм үзенчә тасвирлады. Бу көчне Әмирхан Еники әлегә авыл кеше¬ләрендә сакланып калган туган туфрак хисендә, Аяз Гыйләҗев исә игелек хисендә күрде. Әдипләр бу көчнең яшь буынга күчүен дә күрсәттеләр: Клара белән Җиһангир – шул өметне дәлилләүче геройлар.

Шул рәвешчә, Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән» әсәренә анализ ясау мөмкин. Әсәрне үзләштерү максатыннан чыгып, биремнәр һәм сораулар бирелә. Иң мөһиме әсәр буенча укучы мөстәкыйль рәвештә уйларга һәм иҗат итәргә тиеш. Укучыга уйлау, ягъни әсәргә анализ ясау, гомумиләштерү алымнары да, фикерләү процессы буларак үрнәк алда китерелгән рәвештә булырга мөмкин.

Смирнова Гөлнара Рәшәт кызы,
Менделеевск шәһәренең 1 нче гомуми белем бирү мәктәбе

### “А.Гыйләҗев: тормыш тәрәзәләре” темасына квест эшкәртмәсе

Аңлатма язуы

Соңгы елларда, чыгарылыш сыйныфы укучысының портреты, социаль заказ үзгәрү, белем бирү системасындагы модернизацияләргә бәйле рәвештә уку-укыту эчтәлегенә дә, метод һәм формаларга да үзгәрешләр кертелде. Таралыш ала башлаган уку-укыту формалары арасында квест-дәресләрне дә атарга була. Квест, бер яктан, уен технологиясенә нигезләнгән дәресләргә тартым булса, икенче яктан, укучыларның эзләнү-

тикшеренү эшчәнлеге күнекмәләрен дә камилләштерә. Гадәттә квестлар мажаралы юл ситуациясенә нигезләнәләр: укучылар, бирем арты бирем эшләп, телгә “һөҗүм ясаучы көчләр” белән көрәшәләр һәм җиңеп чыгалар. Без җитдирәк рәвештә корылган квест эшкәртмәсен тәкъдим итәбез.

Квестның максаты: укучыларның командада эшләү күнекмәләрен арттыру; укучының шәхес буларак үсешен тәэмин итү, фикер йөртү күнекмәләрен, хәтерен камилләштерү; укучыларның А.Гыйләҗев тормышы һәм иҗатына карата кызыксыну, ихтирам тәрбияләү.

Квестның бурычлары:

1)белем бирү бурычы: А.Гыйләҗев биографиясе, иҗаты иҗатының бүгенге көндәге роле турында мәгълүмат булдыру.

2)үстерешле бурыч: игътибарлылыкны үстерү.

3) тәрбияви: А.Гыйләҗев тормышы һәм иҗаты турындагы белемнәрен тикшерү.

Материал һәм җиһазлар: маршрут язылган кәгазь, интерактив такта, презентация, карточкалар.

Квестның шартлары: квестка кала берничә көн элек катнашучылар билгеләнә, шулай ук Мирвәли, Бибинур рольләре өчен укучылар сайлана, квестның темасын хәбәр итәргә кирәк. Квест 9-11 нчы сыйныф укучылары өчен тәкъдим ителә.

Үткәрелү урыны: мәктәп кабинетлары, актлар залы.

Үткәрелү вакыты: бер сәгать.

Башлам

Укытучы: Кадерле укучылар! Быел мәртәбәле язучы, драматург, әдәбиятыбызның имән баганасы саналган Аяз Мирсәет улы Гыйләҗевкә 90 яшь тула. Аяз Гыйләҗев турында да тормыш-яшәешкә карата анык үз фикере булган, әдәбиятта да үз сукмагын тапкан гаҗәеп язмышлы әдип, беркемне дә кабатламаган рухи азатлык җырчысы, дип әйтсәк, хакыйкатькә хилафлык китермәбез. А.Гыйләҗев калдырган рухи мирас үзенең колачы, фәлсәфи һәм психологик тирәнлеге белән күпләрне таң калдырырлык. Без бүген әдипнең тормыш юлы эзләреннән барып, аның иҗатын тагын да тирәнрәк аңлауга ирешербез. Команданың әйдәманы, рәхим итеп, маршрут кәгазен алыгыз. Кадерле укучылар, юлыгызга ак җаймә! Хәерле сәгатьтә! (Команда маршрутны карый, анда мәктәпнең география кабинетына илтә торган юл сызымы күрсәтелгән, маршрутның беренче ноктасы “Сарман районы, Чукмарлы авылы” дип билгеләнә. Укучылар сызым ярдәмендә география кабинетына килеп җиткәндә, кабинет ишегенә дә “Сарман районы” дигән язуны күрәләр. Кабинетта Сарман районы фотосурәтләре куелган презентация яктыртылып тора, кабинетта татар авылы өе декорация элементлары урын ала).

Укытучы: Исән-сау килеп җиттегезме, кадерле кунаклар? Юмарт Сарманыбызга рәхим итегез. Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районындагы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Р. Аймәт белән әңгәмәсендә язучы гаиләсен, балачагын сагынып искә алып, түбәндәгеләрне сөйли: “Әти Минзәләдә педучилищеда укый башлаган, әнием шунда ук кызлар мәктәбендә белем алган. Минзәләдә танышканнар алар, шунда ук кавышканнар. Әтине эшкә Чукмарлы авылына җибәрәләр, әни, бер-бер артлы өч малай табып, өйдә утыра. Әтине, яшь мөгаллим дип, район читендәге Югары Баграҗ авылына укытырга күчерәләр. Авыл Зәй районы карамагына күчкәч тә, безнең гаилә Багражда калган. Минем балачагым, яшьлегем әнә шул авылда, юмарт күңелле, кунакчыл, гади, үтә кешелекле, риясыз-хәйләсез керәшеннәр арасында үтте”. Әтисенең туган якларыннан шактый еракта

төпләнеп калуын әдип үзе, мулла баласы булуыннан курыкканлыктан, дип фаразлый. “Йәгез, бер дога!” исемле роман-хатирәсендә болай дип яза: “Нигә туган төягеннән шактый ерак-тарак, чит-ят керәшеннән арасында калырга булганын мин соңгы елларда гына аңладым. Мулла малае булуыннан курыккандыр, ахрысы!”

А.Гыйләҗев 1945 елда Сарман урта мәктәбен тәмамлый, аннан соң берникадәр вакыт авылда, районда эшли һәм 1948 елда Казан университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Укучылар, сез әдип тормыш юлы белән яхшы таныш, әйткәннәрем – исегезгә төшерү максатыннан гына. Ә хәзер беренче һәм бик җитди биремне тыңлагыз. Без А.Гыйләҗев тормышы һәм иҗатына кагылышлы презентация эшләдек. Сезнең бурычыгыз – һәрбер слайдка туры килерлек язуны уйлау һәм презентациягә шуларны кертү. Авырлык килеп чыккан очракта кабинеттагы китаплардан, журналлардан файдалана аласыз. Башкару өчен 10 минут вакыт бирелә.

Без презентациянең күләме биш-алты слайдтан да артмаслык итеп төзедек. 1 слайд А.Гыйләҗевнең туган ягы, районына багышлана. 2 нче слайдта әзерлекле укучылар А.Гыйләҗевнең шәҗәрәсен өйрәнеп, аның әнисе ягыннан Бикчура хан токымыннан булуын раслаган һәвәскәр археолог Д.Гарифуллинны таныйлар, 3 нче слайда язучының китаплар тупланмасы, 4нчесендә тарихчы Татарстан республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры, тарих фәннәре докторы, җәмәгать эшлеклесе, А.Гыйләҗевнең улы Искәндәр Гыйләҗев, 5 нчесендә “Җомга көн, кич белән” әсәре буенча төшерелгән фильмыннан сурәтне танып, слайдларга я исем бирергә, я 1-2 җөмлә белән асъязу төшерергә тиеш булалар. Укытучы укучыларның белем дәрәҗәсенә карап, алдан сыйныфта шушы мәгълүматлар тупланган памяткалар, мәкаләләр әзерләп куя ала. Укучыларның эшенә бәя биргәндә, тизлеккә дә (10 минутка сыешырга тиешләр), җавапларның оригинальлегенә дә карый.

Укытучы: җавапларыгыз бик ошады, сезгә алдагы юлыгызда уңышлар телибез. Юлыгызны дәвам итегез! (Укучылар маршрут кәгазьләренә карап, юлларын дәвам итәләр. Анда алдагы тукталыш “Казан шәһәре” буларак билгеләнгән. Әлеге шәһәр буларак бизәлгән кабинетның схемасы бирелә. Кабинетта Казан шәһәре күренешләре фотолары эленеп куелган).

Укытучы: А.Гыйләҗев 1948 елда Казан университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Студентлык елларында ук ул хөр фикерлелеге, үз карашларын ачык һәм принципиаль яклаучы буларак танылa. Үзе турында ул болай ди: “Яшьтән үк йомык булмаган үткен күзем белән татар кыйналган дөньяны карап үстем”. Әмма дошманнары, көнләшүчеләр төрле әләкләр ярдәмендә егетнең университеттан куылуына, иркеннән мәхрүм ителүенә ирешәләр. Егерме ике яшьлек А.Гыйләҗев, шул рәвешле, “Җинаятьләр кодексы”ның дәһшәтле 58 нче маддәсе буенча гаепләнеп һәм хөкем ителеп, илнең каймагы булган меңнәрчә шәхесләр арасында, чыннан да, хакимиятнең тоткан юлына аңлы рәвештә каршы булган кешегә әверелә. Казанга әйләнеп кайткач, А. Гыйләҗев университетта укуын дәвам итә, аны уңышлы гына тәмамлый. 1957 – 1961нче елларда ул матбугат эшендә: “Чаян”, “Азат хатын”, “Совет әдәбияты” (хәзерге “Казан утлары”) журналларында эшли. 1961 – 1963 елларда Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый. Шуннан соң профессиональ язучы сыйфатында бары тик әдәбият эше, иҗат белән генә шөгыльләнә. Укучылар, алдагы бирем сезнең А.Гыйләҗев әсәрләре белән таныш булуыгызны күрсәтеп торачак. Сезгә рәсемле карточкалар таратылачак. Алар ни рәвешле әдип тормышы һәм иҗаты белән бәйләнгән икән? Сездән шул хакта җавап көтәбез.

1 нче карточкада 1955 дигән сан һәм Казан күренеше яктыртыла. Көтелгән җавап: А.Гыйләҗев 1955 нче елның августында сөргеннән Казанган кайта.

2 нче карточкада әтәч рәсеме төшерелгән. Көтелгән җавап: “Әтәч менгән читәнгә” исемле повестен яза.

3 нче карточкада балта рәсеме төшерелгән. Көтелгән җавап: “Балта кем кулында?” дигән повестен иҗат итә.

4 нче карточкада яшүсмерләрнең, авыл хатыннарының чана белән иртә язда каядыр йөк белән барулары тасвирлана. Көтелгән җавап: “Язгы кәрваннар” әсәрен яза.

5 нче карточкада “Чаян”, “Азат хатын”, “Совет әдәбияты” журналлары фотолары ябыштырылган була. Көтелгән җавап: шул исемдәге журналларда эшли.

6 нчы карточкада Г.Афзал фотосы һәм шигырь юллары язылган була:

Син бик усал, ач арыслан кебек,
Усаллыгың җитәр йөз елга.
Юаш кына малай идең элек,
Усаллата икән бу дөнья.

Көтелгән җавап: Г.Афзал шушы шигырь юлларын А.Гыйләҗевкә багышлый.

Укытучы: Бик яхшы, әлеге тукталышта сез ... балл җыйдыгыз. Алдагы тукталышта да уңыш юлдаш булсын! (Укучылар маршрут кәгазьләренә карап, алдагы кабинетка юл тоталар. Кабинет ишегендә “Кунакханә” дигән язу беркетелгән).

Укытучы: Без сезне үзебезнең кунакханәдә каршы алырга шатбыз. Калган кунакларыбыз белән таныштырырга рөхсәт итегез. Кунаклар сезгә таныш икән, аларга карата фикерегезне белдерә аласыз, без сезгә өстәмә баллар бүләк итәбез.

“Бибинур” булып киенгән укучы чыгышы: Ана – дөньядагы иң изге кеше. Нәкъ менә ул башта сине 9 ай буена йөрәге астында күтәреп йөртә, аннары мең газап белән дөньяга китерә. Әмма Аналык вазифасының иң мөһимнәре болар түгел әле, иң мөһиме – баланы намуслы гражданин итеп тәрбияләү, аякка бастыру. Мин балаларыма, үги булса да, үз, йөрәгемә якын балаларыма бар көчемне, сабырлыгымны баглап үстердем. Аһ, кызганыч, балаларым картлык көнемдә кайтып та, хат язып та сөендермәделәр. Самовар, тегү машинасын кайтып алырга гына кайттылар. Балаларым, заман шаукымы ияреп, матди кыйммәтләр артыннан куып, мине оныталар. Әмма алар шунысын белсеннәр: берсен дә каргамыйм, бүген берәрсе ярдәм сорап килсә, соңгы күлмәгемне дә бирер идем. Картлыгымдагы бердәнбер шатлыгым – Җиһангирга булган хисләрем.

“Мирвәли” булып киенгән укучы чыгышы: Минем тормышым үтә гыйбрәтле, каршылыклы, гаепләр дә тагарлык, акларлык та катлаулы юл ул. Мин кечкенәдән эшләп үстем, гадел һәм хак яшәдем. Яшь чагында атам йортында ялчы хәлендә эшләдем, соңыннан да гомерем эш белән үтте тегермәндә хезмәт иттем, сугышта каты яраланып, орден алдым. Сугыштан да мин туп-туры эшкә, хезмәткә кайтам, туган ягының исен, төсен сагынып, бодай тулы капчыкларга капланып сыкрыйм. Өйләнү өчен дә бай кызын түгел, атам каршы булуга карамастан, йөрәгем кушканны – ярлы кызы Шәмсегаянны сайлыйм. Әтинең өенә сыймагач, без авыл карчыгы Таифәгә өйдәш булып кердек. Тырышып эшләдек, бәхетле гаилә кордык. Яшьлек, мәхәббәт белән тулган көннәр бик тиз үтте. Ул арада илдә үзгәрешләр башланды: революция, гражданнар сугышы, колхозлаштыру. Көннәрдән бер көнне әти үлеп, булган бар мөлкәт миңа күчә. Авылның ярлылар комитеты байларның йорт-җирен, мал-мөлкәтен тартып алу, үзләрен авылдан сөрү турында карар чыгара. Мин булган мөлкәтне яндырып, авылдан киттем. Әмма минем усаллыгым, ачуым, йөрәк ярсуым авылдашларыма карата түгел, аларны кол хәленә

төшергән, системага юнәлдерелгән иде. Иң нык кимсеткәне – мөлкәтеннән баш тарту хисабына авылда яшәп калу түгел, үзем белән киңәшмәгәннәре, үзен чакырмыйча гына шундый җитди карар чыгарулары. Әйе, карт көнемдә мин туган нигезгә кайтып егылдым, авылда минем исемне дә кушмыйлар икән балаларга. Әмма минем гаебем никадәр зур – вакыт үзенең дөрес карарын чыгарыр. (Укучылар, сөйләгәннәр буенча геройларны танысалар, аларга карата фикерләрен белдерсәләр, өстәмә балл бирелә).

Укытучы: Сезне соңгы тукталыш көтә, хәерле юл, укучылар! (укучылар маршрут кәгазе буенча актлар залына керәләр).

Алып баручы: Кадерле укучылар, квестның соңгы тукталышында сезне сәламләргә рөхсәт итегез! Сез бүген А.Гыйләҗевнең тормыш һәм иҗат юллары сукмаклары буенча йөрдегез. Әмма иң куркыныч сукмаклар әле читләтеп узылды. Мин монда 1950 – 1955 нче елларда тормыш арасын, А.Гыйләҗевнең сәяси тоткын рәвешендә газап чигүләрен күздә тотам. 1950 елның мартыннан 1955 елның августына кадәр Аяз Гыйләҗев аяусыз сөргенлек шартларында ташчы, бетончы, бригадир һ.б. сыйфатында хезмәт куя. Ул Казан – Свердловск – Петропавел – Карабас – Актас – Волынка – Майкудук – Чиләбе – Казан маршрутын, тоткын буларак, рәшәткәле вагоннарда, кысан машиналарда, урыны-урыны белән җәяү дә уза. Әнә шулай төрмә әдипкә бай тормыш тәҗрибәсе бирә. А.Гыйләҗевнең үзенең сүзләре белән әйткәндә, "Төрмә минем өчен зур бәхет булды. Ул миңа тормышның нәрсә икәнен аңлатты". 1963 елда А.Гальчок "Старательский вальсок" дигән җыр иҗат итә. Анда түбәндәге юллар бар:

Вот так просто попасть в богачи,
Вот так просто попасть в первачи,
Вот так просто попасть в палачи,
Промолчи, промолчи, промолчи!

А.Гыйләҗев әсәрләре дәшмәүгә, хакыйкатьне качыруга каршы чыгалар, алар гарип сәясәтнең никадәр корбаннар китерүе бәрабәренә яшәвен ачык күрсәтәләр. Дәшмәү – коллык билгесе, сатылу билгесе. Дәшмәү хисабына яшәп калып була, әмма бу инде тезләнгән килеш яшәүгә тиң. Сез А.Гыйләҗев әсәрләре белән яхшы таныш икәнегезне күрсәттегез. Бу белем сезгә тормышны, хакыйкатьне аңларга ярдәм итәр, дип уйлыйм. Әлеге тукталыш – квестның соңгы тукталышы, эшегезнең нәтиҗәләре турында гадел карарны жюри әгъзалары игълан итәр. Ә мин сезгә алдагы тормышыгызда ак бәхетләр, уңышлар телим. Катнашучыларның, квестка әзерләнгәндә ярдәм итүчеләрнең һәрберсенә олы рәхмәтемне белдерәм.

Данилова Зөлфирә Сәләхетдин кызы, Әшрәфуллина Розалия Илдар кызы,
Алабугадагы 10 нчы урта мәктәп

## Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗатына багышланган "Нәрсә? Кайда? Кайчан?" интеллектуаль уены

**Максат:**

Язучының тормышы һәм иҗаты буенча алган белемнәрен практикада куллана алуларын тикшерү һәм тирәнәйтү; әсәрләре турында күзаллау булдыру. Эзләп табу эшчәнлеген, интеллектуаль сәләтен үстерү. Әдәбият белән кызыксынучы, коллективта эшли белүче шәхес тәрбияләү.

Үткәрү формасы: интеллектуаль уен.

**Җиһазлау:** уен өстәле, бүлем номерлары язылган конвертлар,”кара тартма”, әйләнмә, ком сәгате, аудиоязмалар, интерактив такта.

**Уен барышы.**

Аудиоязмада салмак кына музыка уйный.

Алып баручы. Хәерле көн, укучылар, укытучылар, килгән кунаклар! 10нчы урта мәктәбендәге 11нче сыйныф укучыларының “Нәрсә? Кайда? Кайчан?” интеллектуаль клубы сезнең игътибарыгызга бөек татар прозаигы, драматургы Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗатына багышланган интеллектуаль уен тәкъдим итә.

Уенда катнашучыларны, төркем җитәкчесе белән таныштыру. Клубның президенты – Хәләфин Аяз. Сүзне аңа бирәбез.

Интеллектуаль клуб президенты. Минем кулымда ябалак – барлык чор һәм халыкларның мәңгелек акыл һәм зирәклек билгесе. Уку елы азагында без аны интеллектуаль клубның иң яхшы укучысына тапшырачакбыз.

Алып баручы. Уенның кагыйдәләре бик гади. Сезнең алдыгызда – 11 конверт. Аларның һәрберсендә бер сорау. Ул сорауларны Алабуга шәһәрендәге 10 нчы мәктәп укытучылары һәм укучылары төзеде. Бүгенге уеныбыз безнең мәктәп бусагасында уза. Сез 2 нче гимназиянең 11 нче сыйныф укучыларына каршы уйныйсыз. Без алар белән менә берничә ел инде хезмәттәшлек итәбез. Хөрмәтле яшь белгечләр, уен өстәле артында үз урыннарыгызны алуыгызны сорыйм. Экранда уенчылар үзләренең сорауларын һәм җавапларын тәкъдим итәчәкләр. Игътибар белән тыңлап, җавапларыгызны әйтергә әзерләнегез. Уңышлар сезгә!

Уенның беренче соравы. Аяз Гыйләҗев Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, М.Горький исемендәге премия лауреаты, Татарстан Республикасының халык язучысы. Ул кайда, кайчан, нинди гаиләдә дөньяга килгән? (Җавап: Прозаик һәм драматург Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган).

Уенның икенче соравы. Аяз Гыйләҗевнең: “Мин татар дөньясына 3 татар үстереп бирдем”,- дигән сүзләре кемнәр турында бара? Алар бүгенге көндә нәрсә белән шөгыльләнәләр? (Җавап: Аның 3 улы бар: Искәндәр – КФУда профессор; Мансур – язучы-драматург; Рәшат – табиб, эшмәкәр).

Уенның өченче соравы. А.Гыйләҗевнең иҗат эшчәнлегендә драматургия жанры да зур урын били. Аның каләме белән кырыктан артык исемдә күп актлы комедия, трагедия һәм драмалар языла. Аларның күпчелеге Казанның Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры сәхнәләрендә куела. Ә хәзер сорау: Аяз Гыйләҗевнең кайчан һәм нинди әсәре буенча кайда “Гран-при”га лаек булган фильм төшерелгән? (Җавап: 2010нчы елда “Бибинур” драмасы буенча Мамадыш районы Алгай авылында фильм төшерелгән).

Уенның дүртенче соравы. Драматургның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган “Җомга көн кич белән” әсәрендәге төп геройны атагыз. Бу исемнең мәгънәсен тормышы белән бәйләп аңлатып бирегез. (Җавап: “Җомга көн кич белән” әсәрендәге төп герой – Бибинур. Бибинур – “яктылык өләшүче” мәгънәсендә. Әсәрдәге төп образ 3 ятим балага гомерен багышлый, аларга әти-әни тәрбиясен бирә, чит балаларга яктылык өләшә, караңгы көннәрендә кояш булып балкый).

Уенның бишенче соравы. Ә хәзер – кара тартма. Тартма эченә нәрсә салынган? Табышмакны игътибар белән тыңлагыз. Тартма эчендәге әйбер язучының әсәре белән бәйле.

Саранланма, тырыш сатып алырга,
Күңелле булыр юлда барырга.

Җавап: “Җиз кыңгырау”.

Уенның алтынчы соравы. Репрессияләр шаукымы иҗади студент яшьләрне дә читләтеп үтми: 1950 ел башында Казан югары уку йортларында укучы бер төркем татар студентларын, шул җөмләдән А.Гыйләҗевне, «советка каршы коткы таратуда һәм милләтчелектә гаепләп», кулга алалар. А.Гыйләҗевнең тоткынлыкта кичергәннәре турындагы романын атагыз. Ул кайчан һәм кайда язылган? (Җавап: “Йәгез, бер дога”, 1997 нче ел, Казан).

Музыкаль тәнәфес. “Утырып уйлар уйладым” дигән татар халык җыры Гөлшаттан сезгә бүләк булып яңгырасын.

Уенның җиденче соравы. Югары белем алып, язучы булырга хыялланган егерме ике яшьлек егет Казакъстандагы совет концлагерьларында биш елга якын җәфа чигәргә мәҗбүр була. “Гулаг” лагеренда Аяз Гыйләҗевнең нинди псевдонимнары булган? (Җавап: Аны башта Чыңгыз, аннары Батый дип йөрткәннәр).

Уенның сигезенче соравы. Тематик яктан А.Гыйләҗевнең күпчелек повестьлары авыл тормышына багышланган. Аларда кичәге һәм бүгенге авыл, аның гади кешеләре гәүдәләндерелә. Авторның сан кергән әсәрләренең исемнәрен атагыз. (Җавап: “Берәү”, “Өч аршын җир”, “Дүртәү”, “Мең чакрым җир”).

Уенның тугызынчы соравы. Иң беренче Гәрәйханның читәннән егылып төшүе кош-кортлар дөньясында гаять көчле ыгы-зыгы кузгата: “Китте кытаклау, купты тавыш, кузгалды ыгы-зыгы, әкәмәт!” Сорау: түбәндәге өзек кайсы әсәрдән, сүз нәрсә турында бара? (Җавап: “ Әтәч менгән читәнгә” әсәреннән, Гәрәйхан кушаматлы әтәч турында).

Уенның унынчы соравы. Әдипнең унынчы сыйныфта гына русча китаплар укый башлаганы билгеле. “Үзем укыйм, үзем үкереп елыйм, китапны әле тотып ыргытам, әле кочаклап алам. Нигә минем дөньяма иртәрәк кермәде икән?” - дигән сүзләре кайсы рус язучысының әсәре турында сүз бара? (Җавап: Ф. Достоевскийның “Преступление и наказание” романы).

Уенның унберенче соравы. Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә татар телен ихтирам итү, телебезне олылау, милли рух, милләтнең яшәеше өчен борчылу сыйфатлары чагылыш тапкан. Кызларыбызның чит милләт егетләренә кияүгә чыгуларына җаны сыкраган. Ул андый татарларны ничек дип атаган? Әсәрнең исемен әйтегез. (Җавап: “Балта кем кулында” повестенда канында, җанында милли рух булмаганнарны “ямаулы татарлар” дип атаган.

Алып баручы. Уеныбыз ахырына якынлашты. Хәзер сүзне жюрига бирик.

Жюри нәтиҗә ясаганчы, А.Гыйләҗевнең “Бибинур” фильмыннан өзек карау.

Жюри нәтиҗә ясый. Дөрес җавап бирүчеләргә бүләкләр тапшырыла, уенга нәтиҗә ясала.

Алып баручы. Уеныбыз бик эчтәлекле, мавыктыргыч һәм тәрбияви характерда булды. Без үзебезгә бик күп яңалык ачтык. А.Гыйләҗевнең һәр әсәре гыйбрәтле, эчтәлекле. Аяз абый әсәрләрен укыганнан соң бик озак уйланып йөрисең, ул бернәрсә турында яза, ә фикере, мәгънә бөтенләй икенче. Әсәрнең асылы тирәндәрәк ята. Менә

шунда мәгънәсен аңлап алгач, синең күңелендә язучыга рәхмәт хисләре уяна. Тикмәгә генә аның әсәрләрен яратып укымыйлар.

Күгебез һәрвакыт аяз булсын! Халкыбызның үткәненә тирән ихтирам белән карыйк!

Гарифуллина Ландыш Ринат кызы,
Алабирде урта гомуми белем бирү, Тәтеш районы

**Мәхәббәт ул – тылсым**

Аяз Гыйләҗев истәлегенә багышлап үткәреләчәк конференциядә катнашып карау теләге тууның сәбәбе – аның әсәрләрен яратып укуымда, аның геройларына үлеп гашыйк булуымдадыр, мөгаен. Шушы мәхәббәтемне сөйләргә туган мөмкинлек мине яңадан әсәрләрне кулыма алырга, Аяз Гыйләҗевнең геройларын күңелем аша үткәрергә өндәде. Укытучы шундый булырга тиеш инде, үзе укыткан фәнен яратырга, авторларны хөрмәт итәргә тиеш диярсез. Килешәм! Ләкин мәктәп елларымнан бирле минем белән бергә атлаучы геройларым - аның геройлары. Еллар уза барган саен, укучыларыма күңел байлыгымның иң нечкә серләрен әйтергә юллар эзләп, үзем укыган әсәрләргә гашыйк иттерә алуым- бәлки мәхәббәтемнең олы булуын аңлатуның бер юлыдыр.

Эх, әдәбият дөньясының бөтен матурлыгын ачар өчен “балтаны“ укытучы кулына тоттырсалар икән ул... Нишлисен белер идем. Рәхәтләнеп әсәрләр аша тәрбияләп, киштәләрдә җыелып яткан китапларга тузан да кундырмас идем. Үземнең матур мәктәп елларын исемә төшерәм дә, йөрәгем кысылып куя. Көн аралаш китапханә юлын таптарга, китапларны йотлыгып укырга беркем дә өйрәтмәгән бит безне. Әниләрнең орышулары да, күзләрнең әчетеп авыртуы да туктата алмаган. Шундый балаларны кире кайтарасым килә бүгенге тормышка. Яңалыкка омтылабыз дип, китап укудан биздереп, телебезне оныттыруга кадәр барып җитүебез куркыта. Араларында мине аңлаучы, рәхмәтле укучыларымның булуы гына җилкенеп атларга, күзләремдә очкыннарны сакларга ярдәм итә...

Еракка киттең бит диярсез. Юк, китмим, әйтәсе фикеремә ерактан килмәкче булам.

Аяз Гыйләҗев турында бертуктамый сөйлисе дә сөйлисе килә. Аның иҗаты күпкырлы һәм уңдырылышлы. Тормыш баскычларының төрлесеннән атлаган һәм әсәрләрендә шуны күрсәтә алган талант иясе.Шөкер, кулга алып укыр өчен әсәрләре бар. Укучыларга аның исен тойдыра алуым белән үземне бәхетле саныйм. Эш тәҗрибәмдә, укучы белән язучы арасында ныклы күпер салуда бер алым булып торган дәрес турында әйтеп китәргә телим.

Мәхәббәт – кемне дә битараф калдырмый торган олы хис. Укучылар шул темага сөйләгәнне бик яраталар. Мәхәббәт турындагы әсәрләрне бирелеп укыйлар. Ә инде язучы биографиясендә мәхәббәткә бирелгән урын нindидер сер булып кала бирә. Бу турыда дәреслекләрдә язылмый, ә укучының шул турыда ишетәсе килә.

Матур җырлар, шигырь уку кичәләре уздырганда, үзебез яратып укыган авторларның мәхәббәт тарихларын сөйлибез. Шулай итеп, әсәрләрне тагын да теләп укыр өчен юллар ачабыз.

...Беренче сыйныфта гына укыса да, кинәт үсеп киткән, курач кызыкай Нәкыянең тездән түбән төшеп торган ак ыштан балагыннан чеметеп тартып: “Әй, кызый, минем тирәмдә бик чыркылдап йөрмә, бер заман кайтып өйләнермен әле үзеңә”, – дигән була унынчы сыйныфта укып йөргән егет.

“Ник тарттым икән ыштан балагыннан! Соңыннан, байтак еллар үткәч, язмыш безне гомерлеккә кавыштыргач, исем китеп, еш кына уйланган мизгелләрем булды,”- дип, искә ала Аяз Гыйляҗев.

Язучының күңел сандыгына җыелган уй-фикерләрен укучыларым игътибарына тәкъдим итәм. “Ир-атлар фронтта. Сугыш еллары хатын-кыз укытучыларның кайсын кая таратып бетерде. 1944 нче елда мин укыган Югары Баграж урта мәктәбен яптылар. Мин унынчы классны ата-бабамның туган төбәгенә – Сарман мәктәбенә кайтып тәмамларга ниятләдем. Әнием үскән Югары Әхмәт авылында төп йортта төпчек малай Мирзаһит абый гаиләсе. Мин дә аларда, әбием Зөләйха янында  яшәп, Сарман мәктәбенә укырга йөрдем. Чын татар авылын күреп калуым белән бәхетлемен! Саумы, Югары Әхмәт! Саумы, Уралның койрыгы булган Текәй таулары! Шул тауларның күкрәгеннән бәреп чыккан Бузат чишмәсе! Исәнме, Ялгыз каен! Йомшак эңгер каплаган тарлавыклар! Исәнме, минем мәхәббәтем!..Булачак кәләшем Нәкыяне дә шушы авылда тапкан кеше бит мин.

Җиңгәм  44 нче елда бәби алып кайткач, бишек тирәсендә 7-8 яшьләрдәге, тал чыбыгыдай нәзек, кара күзле бер кызны шәйли башладым. Нәкыя шушы кыз иде инде.

Без дүрт малай үстек, гаиләбездә кызлар булмады. Нәкыянең җиңел сөякле, үтә җитез булуына игътибар иттемме, әллә аның бишектәге бәбигә ихлас мәхәббәте сокландырдымы, туганнан бирле үзен язучы итеп тойган яшь егет кызны җентекләп күзәтә башлады. Нәкыя мәктәптән кайта да йөгереп безгә керә: килә, бит-кулларын юып, кыз бишегенә тотына. Бәби йокламаган булса, аның бармакларын берәмтекләп үбә, бәби дә аны зарыгып көткәндәй елмая, көлеп тә куйгалый. Бер-берсенә сүзсез тартылган ике җылы җанны  күзәтеп мин дә сөенәм.

Бу авылда яшәгәч, мин инде күп нәрсәләр беләм. Нәкыянең әнисе – тол хатын, ире төрмәдә үлгәннән соң да, хуҗалыкны менә дигән иттереп алып бара.  “Әнкәсенә карап кызын ал!”- дип акыл беркеткән безнең бабайлар. Яшь   аермабыз тугыз ел булса да, Нәкыягә күз салуымның төп сәбәпләре шулардыр дип уйлыйм: Зөләйха әбиемнең изге нияте, мохит, җылы күңелле ихлас татар дөньясы, бишек тирәсендәге сокландыргыч гамәлләр, әнкәсенең уңганлыгы, чисталыгы...

Һәм көннәрдән бер көнне ачыктан-ачык, туп-турыдан мәхәббәт аңлату: “Күп чыркылдап йөрмә, кайтырмын да өйләнермен!”

Фәрештәләрнең дәррәү “Амин!” дигән чагына туры килдеме, яшьлегемдәге дуамал хыялларымның күпчелеге тормышка ашты. Мин Нәкыягә өйләнеп, уртак тормыш корып җибәрдек. (әйтеп китәсем килә: үзем дә бит, олыга  кияүгә чыгам дип сөйләнеп йөреп, 10 яшькә олырак егеткә  кияүгә чыккан кыз.  “Амин!” дигән сүзнең көченә бик ышанам.)

Тормышымдагы авыр көннәрне җиңәргә, Нәкыягә булган җылы хисләрем ярдәм итте. Черек күл төрмәсендә  Нәкыяне исемә төшердем. Кияүгә чыкмаган икән, Аллага шөкер! (энекәштән сораштым)

54 нче елда Нәкыягә беренче хатымны яздым. Һәм китте...

“Сагынасыңмы?” – диләр,  
Хисләр өчен,  
Бу сүз, дуслар, бик, бик кечкенә.  
Мин сагынам дисәм,  
Бу авазда  
Җир тетрәгән тавыш ишетелә...

һәм.. Ниһаять! “Исеңдәме, “кайтып өйләнермен” дигән сүзләрне онытмадыңмы? Шул көннәр килеп җитә, Син ризамы?”

Нәкыянең җавабын алгач, мин тигез җирдә тәгәрәп киттем. “Мин “риза” дисәм, ә син кайткач үзгәрсәң ?!” дип язган иде ул. Җиде юл чатында аңгыраеп басып торганда (сәяси тоткын булуымны онытырга ярамый) чәчәк кебек кызның “Риза” дигән сүзе чамасыз зур бәхет иде.

...Безнең өйләнешү студентлар арасында нәни генә сенсация булды. Бишенче курсның сазаган кызлары беренче курста кияүгә чыккан “дурочка”ны күрер өчен махсус күзәтеп йөргәннәр. Ике яктан да курсташлар (мин дә 56 нчы елның февралендә университетның икенче курсында укый башладым) “Туй!”дип өзми-куймый тыкырдата башлагач, өч көн туй иттек...

1958 нче елда улыбыз Искәндәр туды, аннары Мансур, төпчегебез Рәшат. Нәкыя малайлар гына табарга теләде һәм Аллаһе Тәгалә безнең теләкләрне ишетте. Тәҗрибәмнән чыгып әйтә алам, бала чын кеше булып үссен өчен, әби-бабай җылысын татып калырга тиеш. Әби балаларны бик яратып үстереште”.

Нәрсә ул мәхәббәт дигәндә, бу матур гаилә тарихын мисал иттереп китерергә яратам укучыларыма. Мәхәббәт хатларын бернигә алыштырып булмый. Көн саен хат язган Аяз Гыйләҗев. Архивларында йөзләрчә хат саклануы билгеле. “Яңгыр, кар дип тормыйча, утыз чакрым араны эһ дип җәяү узган ул”, - дигәч, балалар сәерсенеп карашалар. Нәкыя ханымның истәлекләреннән алынган сүзләрне укымыйча мөмкин түгел. “Аяз абыйның хатлары кайнар өермә булып мине урап алдылар да яңа давыллы хисләр дөньясында яшәтә башладылар.Тора- бара егетемнең күзлеге дә, тәбәнәк буе да онытылды. Минем янымда әйткән сүзендә нык торучы, эшләгәндә ару-талуны белмәгән, ата-анасына хөрмәтле, көчле рухлы, талантлы егет калды. Аны ничек яратмыйсың! Аяз мине элеккедән дә ныграк ярата, дип уйлыйм”...

Мәхәббәтнең гомере чикләнмәгән... Мәхәббәт шулдыр инде күрәсең...

Шушындый истәлекләр белән танышкач, укучыларым авторга соклану катыш кызыксыну белән карыйлар һәм... әлбәттә инде, әсәрләрен укырга телиләр. Ә аннары геройларны ярату, алар белән яшәү, аларга ошарга тырышу, я, киресенчә, төзәтергә ашыгу. Үзебез яшәгән тирәлекне күзәтү, “аларны эзләү”...

Укучы белән укытучы арасында күпер салучы геройлар, рәхмәт сезгә! Бу геройларның атасы булган хөрмәтле язучыбыз Аяз ага Гыйләҗевкә рәхмәт!

Яхина Алсу Халит кызы,
Ләшәү-Тамак төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

## Дус беленер авырлыкта, ир беленер батырлыкта

(Сыйныф сәгате)

**Максат**: Кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрдә дуслыкның иң кирәкле сыйфат булуына ышаныч тудыру. А.Гыйләҗевнең “Дүртәү” хикәясе геройлары аша дуслык хисен хөрмәтләү,авыр вакытларда ярдәмләшү кирәклегенә төшендерү. Үзеңдә дуслык, иптәшлек хисләрен гомерлек итәрлек көч табу.

**Җиһазлау:** А.Гыйләҗевнең “Дүртәү” хикәясе, дуслык турында мәкальләр, “Дуслык кагыйдәләре”, ноутбук, “Чын дустым” җыры, кисмә кояш һәм болыт рәсемнәре.

### Сыйныф сәгате барышы

**1.Уңай психологик халәт булдыру.**

-Укучылар, әйдәгез әле бер-беребезгә матур итеп елмаеп карыйк. Күктәге кояш та безнең елмаюдан көнләшсен. Без кояштан алган яктылыкны, җылыны бер-беребезгә тапшырыйк. Кояш нурлары кебек безнең кәефләребез дә якты булсын.

(Укучылар үзләренең кәефләрен рәсемнәр ярдәмендә күрсәтәләр. Яхшы булса, кояш рәсеме, начар булса, болыт рәсеме күтәрәләр).

**2.Уку мәсьәләсен кую.**

Авыл читендәге өйдә бер көтүче яшәгән. Яңгырлы бер төндә өч кеше аның ишеген шакыган.

- Минем өем бик бәләкәй шул, берегез генә керегез. Сез кемнәр соң? - дип сораган көтүче.

- Без – Дуслык, Бәхет һәм Байлык. Иң кирәклебезне үзең сайла...

**Төркемнәрдә тикшерү өчен сораулар:**

-Көтүче кемне сайлаган?

-Дуслыкны.

-Ни өчен?

- Дуслык керү белән өйгә Бәхет тулган, Байлык килгән.

-Класс сәгатендә сүз нәрсә турында барачак?

- Дуслык турында.

**Үз-үзеңә бәя кую.**

**3.Уку мәсьәләсен чишү.**

Төркемнәрдә тикшерегез:

**1 нче бирем.** Нәрсә ул дуслык?

Ул бер төрле караштa булу, фикерләрнең уртак булуы, бер-береңне ихтирам итү, бер-берең турында кайгырту...

Берәр нәрсә белән мавыгу, аны ярату хисе (китап белән дус булу, спорт белән, табигать белән ...)

**Үз-үзеңә бәя кую.**

**2 нче бирем.** Үзегез укыган китаплардан, караган кинофильмнардан нинди геройларның дуслыгын үрнәк итеп куя аласыз?

**Җаваплар:**

1.А.Гыйләҗевнең “Дүртәү” хикәясе буенча фикерләр тыңлау.

а) Аяз Гыйләҗевнең **“Дүртәү”**хикәясендәге малайларның дуслыгы мактауга лаек. 1944 нче ел. Сугышның халыкны тәмам хәлсезләндергән чагы. 9-10 яшьлек малайлар да, колхозда ат белән элеваторга икмәк ташу эшендә катнашалар. Вакыйф, Әкмәл, Барый, Ибраһим исемле малайлар өлкәннәр эшли торган авыр эшләрне эшлиләр. Алар 60 чакрым ераклыктагы элеваторга, атлар белән ашлык илтергә чыгалар. Караңгы көзге юлда төрле кыен хәлләргә юлыгалар. Ибраһимның аты сазлыкка баткач, аны кыенлык белән, Хафиз бабай өйрәткәнчә, тартып чыгаралар. Малайлар авырлыкны бергә җиңәләр.

б) Ял иткән арада, барлы-юклы ризыкларын бергә бүлешеп ашыйлар.

в) Юлда бер-берсен чиратлап йоклаталар.

г) Йөкләрне арбага төягәндә дә чиратка салып башкаралар. Башта берсенә, аннары икенчесенә, өченчесенә, дүртенчесенә төйиләр.

д) Малайлар эч серләрен дә бер-берсе белән бүлешәләр. Бертугандай якын кешеләргә әйләнәләр.

2. В.Нуруллинның “Үгез, бүреләр һәм без” хикәясе буенча укучыларның фикерләрен тыңлау.

1) Сугыштан соңгы авыр еллар сурәтләнә. Мәктәптә укыган өчен, утын алып барырга кирәк. Күрше авылга өч малай йөреп укый. Әсәрдәге төп геройның утын алып барырга мөмкинлеге юк. Ике иптәше, аңа утын алып кайту өчен, үгез җигеп урманга баралар. Урманда бүреләргә очрыйлар. Мең бәлалар белән өйләренә кайталар. Мәктәпкә тиешле утынны илтеп бирәләр.Тормышта күп авырлыклар күрсәләр дә, бер-берсен ташламыйлар, чын дуслар булып калалар.

**Үз-үзеңә бәя кую.**

**3 нче бирем.** Дуслык турында нинди мәкальләр, әйтемнәр беләсез?

**Җаваплар:**

Дустың булмаса-эзлә, тапсаң – югалтма.

100 сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын.

Яхшы дус – кыйммәтле хәзинә.

Яхшы дус алтыннан кыйммәт.

Чын дуслык – югалмас байлык.

**Үз-үзеңә бәя кую.**

**4 нче бирем.** Экраннан төрле ил халыкларының мәкальләрен уку, мәгънәләрен аңлату.

1)Юләр дустың булудан акыллы дошманың артык (Монгол).

2)Дусны ашыкмыйча гына сайла, тапкач – тиз алыштырма.(Америка).

3) Дус беленер авырлыкта,
Ир беленер батырлыкта.(Татар).

4) Араларын ут белән дә,
Су белән дә аерып булмас.(Татар)

Бу мәкальләрнең кайсысы А.Гыйләҗевнең “Дүртәү” һәм В.Нуруллинның “Үгез, бүреләр һәм без”хикәяләрендәге малайлар дуслыгына туры килә?

Укучыларның җавабы тыңлана.

**Үз-үзеңә бәя кую.**

**5 нче бирем.** Дуслыкның нинди төрләрен беләсез? (Аларны схемада да күрсәттерергә мөмкин.)

1) Кызлар дуслыгы.
2) Малайлар дуслыгы.
3) Һөнәри дуслык.
4) Халыклар дуслыгы.
5)Туганнар дуслыгы.
6) Табигать белән дуслык.
7)Хайваннар белән дуслык .
8) Илләр, дәүләтләр арасындагы дуслык.
9) Төрле милләт кешеләре арасындагы дуслык.

**Үз-үзеңә бәя кую.**

**6 нчы бирем.** Төркемдә “Дус булу кагыйдәләре“н уйлап язу.

1)Дусларың белән әдәпле бул!
2) Авыр чакта дустыңа булыш!
3) Дустың белән бәхәсләшмә, гадел бул!
4) Үз гаебеңне дустыңа аударма!
5) Дусларың алдында масайма!

**Үз-үзеңә бәя кую.**

**Тема буенча нәтиҗә чыгару.**

- Әдәпле балалар арасында дуслык сыйфатларын булдыру, булган дусларыңны югалтмау өчен нәрсәләр эшләргә?

**Көтелгән нәтиҗәләр.**

1.Ике телдә дә дуслык, иптәшлек турында әсәрләр уку.

2.Яхшы дуслык гадәтләре тәрбияләү.

3.Дуслык турында мәкальләр, әйтемнәр туплау.

4.Дуслык турында җырлар өйрәнү.

**4. Рефлексия.**

Бүгенге класс сәгатендә нәрсәләр белдегез?

Үзегезгә нинди нәтиҗәләр ясадыгыз?

**5. Йомгаклау.**

“Чын дустым”җырын башкару.

Шайдуллина Гөлназ Ришат кызы,
Ләшәү-Тамак төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

## Аяз Гыйляҗевнең тормыш юлы һәм иҗаты, “Язгы кәрваннар”повесте

**Класс**: 8

**Предмет:** Әдәбият

**Тема:** Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗаты, “Язгы кәрваннар”повесте

**Максат һәм бурычлар:** Аяз Гыйләҗевның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу. Ишетеп, күреп тану күнекмәләрен, сөйләм телен һәм фикерләү сәләтен үстерү. Туган як язучылары иҗатына кызыксыну уяту, аларга карата мәхәббәт һәм хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Дәресненң тибы:** Яңа белем үзләштерү дәресе

**Предметара бәйләнеш:** рус теле, тарих, сәнгать.

**Эшне оештыру:** фронталь, төркемдә, индивидуаль.

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучылар эшчәнлеге** | **Һәр этапның белем бирүче үстерешле биремнәре, дәрескә материал** |
|---|---|---|---|
| **1 этап**<br>**Оештыру өлеше**<br>*Максат:* укучыларны уку эшчәнлегенә мотивлаштыру, дәрескә уңай психологик халәт булдыру. | Балаларны эшкә әзерләү. | Укытучыга игътибар итү. Дәрестә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре формалаштыру. | Сәламләшү<br>Дежур укучы белән әңгәмә **(слайд №1)** |
| **2 этап. Өй эшен тикшерү. Укучыларның тирәк белемнәрен яңадан барлау һәм төзәтмәләр кертү. Белемнәрне актуальләштерү.**<br>**Максат:**<br>алдагы дәрестә алган белемнәрне искә төшерү. | 1. Фронталь эш оештыру.<br>2. Туфан Миңнуллин иҗаты буенча кыскача нәтиҗә ясау. | Т. Миңнуллин тормыш юлы һәм иҗаты буенча кроссвод чишү | - Укучылар, үткән дәрестә без татар халкының күренекле драматургы һәм аның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышкан идек. Өй эшенә мин сезгә әлеге теманы кабатлап килергә кушкан идем. Хәзер мин сезгә кроссвордлар таратам, өй эшен искә төшереп, шуларны бергәләп чишеп алабыз. Сораулар: |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 1. Т. Миңнуллинның этисенең исеме<br>2. Т. Миңнуллин эшләгән журнал исеме.<br>3. Балалар өчен язылган пьеса-әките.<br>4.Катнаш никах турындагы әсәре "...+Вера"<br>5.Эссе сүзенең синонимы<br>6. 1979 елда Т. Миңнуллинга нинди Дәүләт премиясе бирелә?<br>7. Училищаны тәмамлагач кайсы театрда эшләгән?<br>8. Тиз түгел.<br>9.Т Миңнуллинның туган авылы?<br>10. Әлеге әсәрнең тулы исеме "... авыл кешеләре" .<br>11.Торак пункт. |
| **3 этап. Уку мәсьәләсен кую. Дәреснең темасын һәм максатларын ачыклау** | Укучыларны активлаштыру, кроссвордта килеп чыккан ачкыч сүз аша яңа теманы һәм дәреснең максатларын билгеләүгә юнәлеш бирү | Бирелгән башваткычта яшерелгән сүз аша яңа теманы билгеләү | - Укучылар, игътибар белән карагыз әле, кроссвордның җавапларын тапкач, сары шакмакларда нинди сүз килеп чыкты?<br>- Ул сүз нәрсә белдерә?<br>- Ничек уйлыйсыз бу кеше кем икән? Аның турында ишеткәнегез бармы?<br>- А. Гыйләҗев – күренекле язучы һәм без аның тормыш юлы һәм "Язгы кәрваннар" повесте белән таныша башлаячакбыз. Димәк, безнең алда нинди максатлар тора? **(слайд №9)** |
| **4 этап. Яңа материалны аңлату (уку мәсьәләсен чишү)**<br>**Максат:** уку күнекмәләрен үстерү өстендә эшләүне формалаштыру, таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсен истә калдыру, шигырьнең эчтәлеген аңлау | 1. Укучыларның әзерләп килгән чыгышларын тыңлау<br><br>2. Хронологик таблица төзү<br><br>3.Сүзлек өстендә эш. (Экранда)<br><br>Биремнең үтәлешенә контроль булдыру | 1.Аяз Гыйләҗевның тормыш юлы һәм иҗаты белән кыскача танышу, хронологик таблица төзү<br><br>2."Язгы кәрваннар" повестен укый башлау<br><br>3.Яңа сүзне сүзлек дәфтәрләренә язу | - А. Гыйләҗевның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү ясау, "Язгы кәрваннар" повесте белән таныша башлау<br>**(слайд №10-15)**<br><br>***Кәрван-1)*** Чүлләрдә, далаларда кешеләр белән бергә бара торган, аркаларына йөкләр салынган хайваннар төркеме;<br>***2)*** Хәрәкәт итүче төркем. |
| **5 этап. Динамик пауза** | Укучыларга ял оештыру, тәртибен контрольдә тоту. | | Музыка куела. Күзләргә гимнастика ясау, кулларны һәм аркаларны ял иттерү<br>**(слайд №16)** |
| **6 этап. Белемнәрне беренчел ныгыту.**<br>**Максат** : ишетеп, күреп тану күнекмәләрен, бәйләнешле сөйләм | 1. Укучылардан повестьне укыту<br>2. Үз фикерләрен әйтүгә ирешү, нәтиҗә ясарга өйрәтү. | 1. Повестьнең беренче өлешен уку<br>2. Сорау-җавап бирүдә катнашу. | Сорауларга җавап бирү:<br>- Вакыйга кайда һәм кайчан бара?<br>- Әсәр кем исеменнән хикәяләнә? |

| | | | |
|---|---|---|---|
| телен үстерү. | Дөрес фикергә килүгә юнәлеш бирү, укучыларның үзара “бәхәс”ен контрольдә тоту | | - Кызның җырлавы һәм җыр үзе нәрсә белән чагыштырыла? Шул урыннарны табып, тагын бер кат укыгыз. **(слайд №17-20)** |
| **7 этап. Белемнәрне яңа ситуациядә иҗади куллану һәм эзләп табу.** **Максат:**укучыларның игътибарлылыгын тикшерү, хаталарны төзәтү. | Практик эзләнү эшен оештыру. Биремнең үтәлешенә контроль булдыру. | Практик эзләнү эшендә катнашу. Үзара ярдәмләшеп, биремне үтәү | - Укучылар, әсәр геройлары сездә нинди тәэсирләр, фикерләр уятты? - Ибраһим белән Дамирның үзара мөнәсәбәтләрен анализлагыз. - Персонажлар барсы да бертөсле сөйләшәме? - Сөйләмнәреннән чыгып, ул геройлар турында нәрсә әйтә аласыз? (**слайд №21**) |
| **8 этап. Өй эше турында мәгълүмат** **Максат:** үз мөмкинлекләреннән чыгып, биремнәрне сайлап алу | Өй эшенә өч төрле бирем тәкъдим итү, аңлату, сораулар булса, җавап бирү | Өй эшенә бирелгән биремне аңлау, көндәлеккә язу | 1. Повестьнең беренче өлешен укырга, эчтәлекне белергә. 2. А. Гыйләҗев турында презентация әзерләргә. **3.** Укыган өлештән сурәтләү чаралары табу. **(слайд №22)** |
| **9 этап.** **Нәтиҗә һәм бәяләү. Рефлексия.** **Максат:** дәрестә эшләнгән эшләргә нәтиҗә ясау. | Үз фикерләрен әйтүгә ирешү, нәтиҗә ясарга өйрәтү. | Нәтиҗәләр ясыйлар. Үзләренә билге куялар. | 1. Бүгенге дәрестә нәрсә белдек? 2. Бигрәк тә нәрсә истә калды? 3.Тагын нәрсә белергә кирәк? |

Мингалеева Рәмзия Әхмәтзакир кызы,
Масловка урта гомуми белем бирү мәктәбе, Балык Бистәсе районы

## Аяз Гыйләҗев. “Җомга көн, кич белән...”

## 9 нчы сыйныфта (татар төркеме) БиС технологиясе буенча үткәрелгән дәрес

**Үткәрү формасы** : карта “ Телдән дәрес - 1”. Технология БиС.

**Ресурслар:** дәреслек. Татар әдәбияты: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 9 нчы сыйныфы өчен дәреслек (татар балалар өчен). З.Н.Хәбибуллина, Х.Г.Фәрдиева, Ә.Н.Хуҗиәхмәтов. – Яңартылган 3 нче басма. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2005 ел, проектор, презентация.

**Кулланылган әдәбият:**

1.Качество в образовании.Технология БиС. Технологическая карта «Устный урок -1». Обучающий фильм на русском языке.
2.Интернет ресурсы:http://knigabis.kz/; https://www.youtube.com/user/VassermanF

Дәреснең билгеләрдә фактик нәтиҗәсе:

| Билге | 5 | 4 | 3 |
|---|---|---|---|
| Укучылар саны | | | |
| Гомуми саннан чыгып % | | | |

**Максат:** Дәрестә укучыларның теманы үзләштерүләрен 63% үстерүгә ирешү. Укучыларның тизлеген, фикер йөртүләрен , сүз байлыкларын үстерү.

**Бурыч:** Технологик карта регламентын үтәү.

**Планлаштырылган нәтиҗә:** Куйган максатка ирешү.

**Дәреснең 1 нче төре.** Яңа теманы өйрәнү һәм беренчел ныгыту буенча оештырылган дәрес түбәндәге өлешләрдән тора: мотивация - актуальләштерү - яңа теманы кабул итүгә әзерлек - яңа тема үзләштерү - теманы үзләштерү дәрәҗәсен беренчел тикшерү - ныгыту - анализ - рефлексия.

Укытучы дәрес башлаганчы тактага МПМ (таблица), дәреснең темасын, сыйфатлы өлгереш нормативын 5 – 4 63%, (сыйныфтагы укучылар саныннан чыгып исәпләнә, бу дәрес очрагында, мәсәлән 5 укучының 4 се уңай билге алса, нормативка туры килә дип санала), технологик картаның исемен, дәрес этапларын алдан язып куя.

**“Телдән дәрес - 1” картасы буенча эшнең структурасы һәм тәртибе**

| | | |
|---|---|---|
| Оештыру өлеше. Мотивация | Карта буенча эш тәртибе аңлатыла. Башта сүзне укытучы ала. Укучыларга уңышлар тели. Аннан соң сүз сыйныфның актив ( лидер ) укучысына бирелә. | Уңъяк тактаның өске өлешенә тиешле норма күрсәткече куела : 63% |
| Актуальләштерү | **Өй эшен тикшерү** *( перекрестный опрос)*<br>1. Бибинур кем ул?<br>2. Гомере буе кешеләргә яхшылык эшләгән Бибинур бәхет төшенчәсен ничек аңлый?<br>3. Бибинур зиратка ни өчен килә?<br>4. Гайшә кем ул?<br>5. Бибинур ничә бала тәрбияләп үстерә?<br>*Сораулар дәреслекнең 130 – 136 нчы битләре буенча бирелә.*<br>МПМ(таблица) дагы + лар санала, тактадагы 1 нче этап кырыена тамгалар ( <63% ка ирешелмәсә, яки >63% ка ирешелсә) куела. Мәсәлән, 5 укучының 4 сендә + булса Перекрёстный опрос > дип куела. | **Беренче билге.** Барлык укучыларга да белемнәре өчен плюс яки минус тамгасы куела. Карта буенча эш аңлатыла. Башта сорау бирелә, аннары МПМ га тамга куела.<br><br>*Тактага нәтиҗә язылып барыла.*<br><br>**1 нче этап ----** |
| Яңа теманы кабул итүгә әзерлек | **Терәк сүзләр** *( опорные слова)*<br>Укытучы кыскача дәрестә үтеләчәк тема турында аңлатма бирә.<br>***Аяз Гыйләҗев. “Җомга көн, кич белән...”***<br>**Терәк сүзләр.**<br>***1. Төш***<br>***2. Җомга***<br>***3. Редакция***<br>***4. Сәке***<br>***5. Җиһангир***<br>***6. Корреспондент***<br>***7. Аксыргак***<br>* Балаларга истә калдыру өчен 30 секунд вакыт бирелә. Шуннан соң, терәк сүзләр ябыла. Укучылар истә калдырганча дәфтәрләренә язалар. Вакыт чыккач, укучылар дәфтәрләрен алмаштырышалар һәм сүзләрне саныйлар. Укытучы нәтиҗәне МПМ га язып бара. | **Икенче билге.** Барлык укучыларга да белемнәре өчен плюс яки минус тамгасы куела<br><br>Истә калдыру өчен, вакыт нормасы:<br><br>**7 сүз – 30 сек.**<br>10 сүз – 45 сек.<br>12 сүз – 1 мин.<br>14 сүз – 1 мин 15 сек.<br>16 сүз – 1мин 50сек.<br>18 сүз – 2 мин 15 сек.<br>21 сүз – 2 мин 30 сек.<br>*Тактага нәтиҗә язылып барыла.*<br>**2 нче этап -------** |
| Яңа теманы үзләштерү | Укучылар текстны укыйлар. *( Дәреслекнең 137-143 нче битләре укыла. Әгәр дә текстның күләме зур булса, укытучы укылачак өлешне генә сайлап алырга мөмкин . )* | 1 бит уку өчен, 4 минут вакыт бирелә. Димәк, 2 бит – 8 минут. |
| Теманы үзләштерү дәрәҗәсен беренчел тикшерү | **Беренчел тикшерү.** *( перекрестный опрос)*<br>Укытучы МПМ буенча, укучыларга сорау бирә. Сораулар тәртип буенча булмаска да мөмкин. Бу этапта, җавап биргән вакытта, укучылар тексттан | **Өченче билге.** Барлык укучыларга да белемнәре өчен плюс яки минус тамгасы куела |

| | | |
|---|---|---|
| | файдалана алалар.<br>**Сораулар:**<br>1. *Бибинур карчык ни өчен көн дә почтага килә?*<br>2. *Миңлегөл Бибинурга нинди хәбәр әйтә?*<br>3. *Ни өчен Бибинурның корреспондентны китертәсе килми?*<br>4. *Күршесе Зәкия Бибинурга нәрсә алып керә?*<br>5. *Ни өчен Бибинур самавыры һәм җөй машинасы юклыкка борчыла?*<br>Этап тәмамланганнан соң да , кемнең 2 минус тамгасы була, шул укучыга ***коткару бөҗрасы*** **(спасательный круг)** бирелә . Алар кул күтәреп, дөрес җавап бирсәләр, үзләренең минусларын төзәтә алалар. Укучылар җавап бирә алмаса, җавапны калган укучылар бирә .<br>***Коткару бөҗрасы өчен сораулар***<br>1. Тула самавыры ничәнче елгы була?<br>2. Бибинур яши торган авылның исеме ничек?<br>3. Зәкия Бибинурга ничә сум акча кертә?<br>Укытучы алган җаваплардан чыгып, аңламаган өлешләрне үзе аңлата. | *Тактага нәтиҗә язылып барыла.*<br><br>**3 нче этап -------** |
| Ныгыту | **Икенчел тикшерү . (** *критический опрос)*<br>Укучыларга 2 дөрес, 3 хаталы сорау бирелә. Сорауның беренче өлешендә сорау алмашлыгы, икенче өлешендә хата булырга тиеш.Укытучы МПМ буенча сорамаска да мөмкин. Дәреснең бу этабында укытучы укучыларга дәреслекләрне ябарга куша. Бу юлы да “коткару бөҗрасы” ташларга мөмкин. Кемнең минуслары күп, шуларга сораулар бирелә.<br>**Сораулар:**<br>*Күршеләре Бибинурны хөрмәт итәләрме? ( дөрес)*<br>*Ни өчен Миңлегөл артистлар килүен хәбәр итә?( ялгыш)*<br>*Ни өчен Бибинур Хәсәннең әткәсе янына барырга тели? ( ялгыш)*<br>*Вәли карт Җиһангирның әтисеме?(дөрес)*<br>*Ни өчен Зәкия мәк чәчәкле күлмәклекне Миңлегөлгә бүләк итә? ( ялгыш)*<br>***Коткару бөҗрасы өчен сораулар***<br>Бибинур үз балаларын тәрбияләп үстерәме?<br>Корреспондент кайсы шәһәрдән килергә тиеш?<br>Бибинур тәрбияләп үстергән балалар аның хәлен беләләрме?<br>***** Укытучы тикшерүдән соң, нәтиҗә ясый һәм авыр өлешләрне яңадан 1-2 минут аралыгында аңлата. | **Дүртенче билге.** Барлык укучыларга да белемнәре өчен плюс яки минус тамгасы куела<br><br>*Тактага нәтиҗә язылып барыла.*<br><br>**4 нче этап -------** |
| Анализ<br><br>Вакыт – 5 минут | **Темага караган сүз байлыгы**<br>*( тематический словарный запас - ТСЗ )*<br>Укучылар өйрәнгән теманы сочинение, эссе яки сүзтезмә формасында язалар. Теркәгечләр, кисәкчәләр һәм бәйлекләр сүз исәбенә керми. Сүзләр кыскартылырга тиеш түгел. | **Бишенче билге.** Барлык укучыларга да плюс яки минус тамгасы куела<br><br>*Тактага нәтиҗә язылып барыла.* |

| | | |
|---|---|---|
| | ***Норма – 63 сүз***<br>* Вакыт чыккач, укучылар дәфтәрләрен алмаштырышалар һәм сүзләрне санайлар. Сүзләр саны нормага туры килсә – плюс, ә туры килмәсә минус тамгасы куела. Укытучы тикшерүдән соң, нәтиҗә ясый һәм авыр өлешләрне яңадан 1-2 минут аралыгында аңлата. | **5 нче этап -------** |
| Рефлексия | Укытучы кыскача дәрескә анализ ясый. Билгеләр буенча аңлату эшләре алып бара. | |
| Билге | Журналга билгеләр түбәндәгечә куела:<br>*“ 5”ле – 4-5 тамга*<br>*“ 4” ле – 3 тамга*<br>*“ 3”ле – 2 тамга*<br>*“ 2”ле – 1 тамга* | Укучыларның 63 % ы<br>“ 4” ле һәм “ 5”ле билгесе алырга тиеш. |
| Өй эше | 4 тамга алган һәр укучыга да өй эше бирелә.<br>*Өй эш :* Текстны укырга һәм кыскача эчтәлеген сөйләргә | |

**Этаплар:**

1. **Өй эшен тикшерү** (перекрёстный опрос)
2. **Терәк сүзләр** ( опорные слова)
3. **Беренчел тикшерү** (перекрёстный опрос )
4. **Икенчел тикшерү** ( критический опрос)
5. **Темага караган сүз байлыгы** ( ТСЗ )

**Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн, кич белән...” әсәренә анализ**

I. Дәреснең максатлары:

1. Әсәрне өйрәнүне йомгаклау, аның эчтәлегенә төшенү, аның идеясын ачыклау.
2. Кешеләрдә яхшылык сыйфатлары кими баруның сәбәпләрен ачыклау.
3. Укучылар күңелендә шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек тәрбияләү.

II. Принциплар:

1) дидактик принциплар: коммуникативлык, уку-укыту процессының тәрбияви характерда булуы, гомумкешелек;

2) хосусый принциплар: әдәби әсәрне сүз сәнгате буларак кабул итү, әсәрне субъектив кабул итү.

III. Укыту ысуллары: укытучы сүзе, дәреслек белән эшләү, иҗади уку, өлешчә эзләнү ысулы.

IV. Укыту алымнары: сорау-җавап алымы, укытучы сөйләме, әсәрне үзлектән уку.

V. Укыту барышын оештыру чаралары: дәреслек, әдәби материал.

VI. Дәреснең төре: әдәби әсәрне ныгыту дәресе.

Дәрес планы

I. Башлам өлеше:

1) исәнләшү;

2) укучыларның дәрескә әзерлеген тикшерү.

II. Актуальләштерү этабы:

1) укучыларның дәрескә әзерлекләрен барлау;

2) алдагы белемнәр белән бүген үзләштереләсе белем арасында бәйләнеш булдыру;

3) шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек турында фикер алышу.

III. Яңа белем күнекмәләрен формалаштыру этабы:

1) “Җомга көн кич белән...” әсәренә анализ ясау;

2) әсәрнең нәрсәгә багышлануыннан, нәрсә турында язылуыннан чыгып, темасын билгеләү;

3) әсәр белән “Бибинур” фильмының уртак һәм аермалы якларын билгеләү ;

4) укучыларның фикерләрен тыңлау.

IV. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту этабы:

1) әсәрләрдә геройларга хас булган сыйфатларны билгеләү, укучылардан таптыру;

2) гомере буе кешеләргә яхшылык эшләгән Бибинурның “бәхет” төшенчәсен ничек аңлау сыйфатларын билгеләү.

V. Йомгаклау:

укучылардан дәрестә эшләгәннәрне әйттерү, аларны дәрес темасы белән бәйләттерү;

VI. Өйгә эш бирү: “Җир йөзендә Бибинур кебекләр бармы?” темасы буенча үз фикереңне яз.

Дәрес барышы

I. Укытучы: Исәнмесез, укучылар!

Укучылар: Исәнмесез!

Укытучы: Бүген сыйныфта кем кизү тора? Дәрестә кемнәр юк?

Укучы: ... .

II. Укытучы: Ә хәзер дәфтәрләрне ачабыз һәм бүгенге числоны язып куябыз. Дәресне башлаганчы, әйдәгез, өй эшен тикшереп алыйк. Сез Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн, кич белән...” әсәрен тулысынча укып килергә тиеш идегез. Безнең бүгенге дәресебез ныгытуга багышлана.

III. Яхшы, укучылар, хәзер дәресебезне дәвам итәбез.

Бүген без Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн, кич белән...” повестен йомгакларбыз һәм әсәргә, аның геройларына анализ бирербез. Дәресебезнең башында, әйдәгез әле, бер фильмнан өзек карап үтик. ( укучылар “Бибинур”киносыннан өзек карыйлар.)

Укытучы: Укучылар, кинодагы Бибинур белән әсәрдәге герой арасында нинди аермалыклар һәм охшашлыклар бар? (Укучылар белән фикер алышу була. Соңрак укытучы фильмда катнашкан артистлар турында кыскача мәгълүмат бирә. )

Укытучы: Укучылар, “Бибинур” фильмының сюжет сызыгы болайрак корылган: инде өлкән яшьтә булган Бибинур төш күрә. Ул тиз арада җомга көнне бу дөнья белән саубуллашырга тиеш икән. Бибинур, үлгәнче, бурычларын биреп бетерергә һәм Мәңгелек белән очрашуга әзерләнергә тиеш. Әмма көтмәгәндә аның авылында криминал белән шөгыльләнүче эшкуарлар һәм җир биләүчеләр пәйда була. Алар иске зират урнашкан җирне табыш китерерлек итеп сатып җибәрмәкче була. Аларның берсе – Җиһангир исемлесе озак еллар чит илдә яшәп кайткан һәм мул тормышка ияләнгән кеше була.

Укытучы: Укучылар, Фирдәвес апа белән аның героинясы Бибинур арасында нинди параллельлек бар? ( укучыларның җавабы ) Чыннан да, балалар, аларның эчке һәм тышкы тәңгәллеге шулкадәр тирән. Фирдәвес апа үзе: «Бибинур кебек булып булмый, нинди генә әйбәт кеше дә тормышта барыбер конфликтка керми кала алмый», – дип сөйләсә дә, үзенең гамәлләре, дөньяны кабул итүе, хәтта язмыш биргән сынаулары белән дә ул героинясына бик якын. Ялгызлык... ул үзе дә шул хакта сөйли: әтисен сугыш ала, бик яшьтән әнидән кала – әнисе 42 яшендә дөнья куя, көттереп кенә табылган яры – ире дә иртә бакыйлыкка күчә, бердәнбер кызы да бүген үзеннән еракта – Миланда яши. Әсәрдәге Бибинурны да бит ялгызлыктан ире Габдуллаҗанның таш һәйкәлгә уеп язылган исеме

белән сөйләшеп йөрүләрен, алма бакчасында ирен янәшә тоеп, гел үзалдына сөйләнеп йөрүләрен күз алдына китерегез. Ул бит бигрәк тә ялгыз.

Укытучы: Укучылар, ә хәзер янәдән әсәргә әйләнеп кайтыйк әле. Сез безгә таныш булган “Җомга көн, кич белән...” повестенда кешелекле дип кайсы әдәби образга әйтә алабыз? (Бибинур)

- Кайсы вакыйгалар аша сез бу турыда әйтә аласыз? Әйдәгез өзекнең кыскача эчтәлеген искә төшерик. Вакыйгаларга бәя бирик.

- Бибинур образына тулы бәяләмә бирегез. (Бибинур – бәләкәй генә гәүдәле, ябык аркалы, авылдашлары күзенә дә алай артык чалынмаган, тыныч холыклы, йомшак тавышлы, этисе төсле зәп-зәңгәр күзле, ярдәмчел, оста, җитез, чиста, сабыр татар карчыгы.Ул Габдуллаҗанның 3 баласын тәрбияләп үстергән, аларга гел ярдәм итеп яшәгән. Пенсия акчасын да балаларына җибәреп бара. Үзенең өсендә кырык ямаулы күлмәк ыштан, тузган яулык, ләкин карчык бик чиста, өендә чүп булмаса да аны гел җыештырып тора.

“Кимсетсәләр, гафу итә белде, очраганда кешеләрне сөендерде, кайгылы хәбәрләрне дә ияләренә җиңеләйтеп җиткерде, көчсезне яклады, усалның күңеленә шәфкать җылысы җибәрергә тырышты. Гайбәт сөйләмәде, берәүне дә тулаем дошман күрмәде, әләкли белмәде, әҗәтен түләмичә калмады, какмады-сукмады...” Авыл кешеләренә серен сөйләми, гел көндәше Гайшә каберенә барып эч серләрен аңа бушата. Шуларга өстәп ул әле тагын үз сүзендә торучан һәм сүзен кистереп әйтүчән, уңганлыгы дөньяга мәгълүм булган карчык.

Укытучы: Бибинур, бәхетеннән ваз кичеп, ни өчен Габдуллаҗанга кияүгә чыга? (Бибинур балалар бакчасында эшли, шуңа күрә ул Габдуллаҗанның әнисез калган балаларын якын күрә, аларны кызгана. Бу балаларны жәлләү, аларга ярдәм итү теләге Бибинурны, сөйгән егетен ташлап, Габдуллаҗанга кияүгә чыгарга этәрә)

Укытучы: Ул аларны ничек тәрбияли? (Бибинур балаларны үз кочагына ала. Бөтен көчен, яшәү рәвешен аларга бирә, укыта, хәленнән килгәнчә ярдәм итә.)

Укытучы: Балаларның, үсеп, кеше булгач, Бибинурга мөнәсәбәтләре ничек? (Алар аңа ярдәм итү турында уйлап та карамыйлар, хәтта хәлен белеп хат та язып салмыйлар, алай гына да түгел, аның өендәге барлык әйберләрне үзләре белән алып китәләр.)

Укытучы: Бибинур тәрбияләгән балалар ни өчен шундый булып чыкканнар икән? (Төрле җаваплар, бәхәсләр туарга мөмкин.)

Укытучы: Бибинурны гаепле дип саныйсызмы? (Укучыларның җавабы)

Укытучы: Мин Бибинурны гаепле дип санамыйм. Ул чит кеше балаларын бик яшь килеш тәрбиягә алган, үзе дә бала гына була, тәҗрибәсе юк. Нигә аңа өлкәнрәк кешеләр ярдәм итмәгән? Авыл кешеләре кая караган? Алар Бибинурның мондый эшкә баруына сәерсенеп караганнар. Бибинур олыгайгач та яхшылык эшләдемме, әллә яманлыкмы дип үзе дә соравына җавап таба алмый. Ул мәгънәсез балалар өчен үзен корбан итә. Ә хәзер, балалар, сезнең фикерләрне тыңлап үтәсем килә. ( Укучыларның фикерләре төрле булырга мөмкин)

Укытучы: Бибинур урынында булсагыз, сез нишләр идегез? (Укучыларның фикерләре)

Укытучы: Әсәрнең ахырында Бибинур кайчандыр үзе ашатып йөргән этләр аны талап үтерәләр. Автор моның белән ни әйтергә тели? (Укучыларның җавабы. Этләр дә балалары кебек Бибинурның кадерен, миһербанлыгын аңламыйлар, оныталар.)

IV. Ныгыту.

1. Мәкальләр белән эшләү.

А) Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен.

Б) Картлык шатлык түгел.

В) Картларга юл куй, үзең дә картаерсың.

Г) Балачакта олылардан курыксаң, олыгайгач, балалардан куркырсың.

Д) Яманлык беркайчан да яхшылык белән тәмамланмый.

Е) Яхшылык ит, каршысына яхшылык көтмә.

2. Укучылар дәреснең әһәмиятен ачыклыйлар һәм "бәхет" төшенчәсенә үз карашларын белдерәләр.

Укытучы: Язучы бу әсәре аша нәрсә әйтергә тели? Сез аның фикере белән килешәсезме? Бибинур үзен бәхетле дип уйлыймы икән соң? (Укучыларның җаваплары)

Укытучы: Язучы кешеләрдә яхшылык сыйфатлары кимегәнгә кайгыра, борчыла. Кешелеклелек сыйфатлары бетү милләтнең, илнең бетүенә китерә.

Кырыслык белән генә алга барып булмый. Шуңа күрә бер-беребезгә, әти-әниләребезгә шәфкатьле, мәрхәмәтле булыйк. Бибинур әби өчен «бәхет» – ул балаларның бәхете.

V. Йомгаклау өлеше.

Фирдәвес Әхтәмованың тормыш фәлсәфәсе дә Бибинурныкы кебек: «Беркайчан да үз-үземә каршы килеп, күңелем кушмаганны эшләмәдем. Аллаһы Тәгалә: нәрсәне дә булса үзгәртә алсаң – тырыш, үзгәртә алмасаң – сабырлык белән үткәр, дигән. Сабыйлар хакына үзеннән күпкә олы тол иргә кияүгә чыгып, ялгызы шул балаларны аякка бастырып, картлык көнендә ялгызлык сынауларын берәүгә дә рәнҗемичә сабырлык белән кичә алган Бибинур да шулай дияр иде.

VI. Өй эше. "Җир йөзендә Бибинур кебекләр бармы?" темасы буенча үз фикереңне яз.

Харисова Ильсеяр Музагитовна, Галиева Лейсан Анваровна,
Талипова Ляйсан Равилевна, «Джалильская СОШ №2», Сармановский район

**Сценарий внеклассного мероприятия**

на основе романа «Топор в чьих руках?»

**Тема мероприятия: «Главная ценность – человек»**

**Цель внеурочного мероприятия:** вызвать у обучающихся интерес и эмоциональный отклик на события истории нашей страны времён тоталитаризма и сталинских репрессий; сформировать представление о недопустимости государственного беззакония в отношении граждан своей страны.

**Задачи внеурочного мероприятия:** формирование основ нравственности, патриотизма и стремления к позитивной самореализации; приобщение обучающихся к примерам мужества и несгибаемости советских людей; формирование уважения к военно-историческому прошлому и к старшему поколению;

**Ход мероприятия:**

Ведущий 1. Ежегодно 30 октября, начиная с 1991 года, в России и бывших странах СССР отмечают День памяти жертв политических репрессий.

Ведущий 2. Репрессии, проходившие в СССР можно разделить на несколько этапов: 1 этап: политические репрессии со стороны большевиков в Советской России, которые начались сразу после Октябрьской революции 1917 года, а также в годы

Гражданской войны. При этом жертвами репрессий становились не только активные политические противники большевиков, но и люди, просто выражавшие несогласие с их политикой.

Ведущий 1. 2 этап: начался с принудительной коллективизации сельского хозяйства и ускоренной индустриализации в конце 1920-х — начале 1930-х годов, а также укреплением личной власти Сталина. Многие исследователи относят к жертвам сталинских репрессий осуждённых по ст. 58 УК РСФСР 1926 года «Контрреволюционные преступления», а также жертв раскулачивания.

Ведущий 2. В дальнейшем репрессии носили более упорядоченный характер. В предвоенные годы началось массовое выселение целых народов. Жертвами депортации стали поляки, курды, корейцы, буряты и другие народы. 3,5 миллиона исчисляется количество репрессированных по национальному признаку с середины 40-х по 1961 год. Депортация коснулась 14 народов целиком и 48 – частично. В послевоенные годы репрессии применялись к пленным, врагам народа, перешедшим на сторону фашистов. По данным КГБ СССР в 1930—1953 гг. репрессиям подверглись 3 778 234 человека, из которых 786 098 было расстреляно, а остальные направлены в гигантские рабовладельческие хозяйства системы ГУЛАГ.

Ведущий 1. Крупнейшие лагеря, в которых отбывали наказание заключенные, находились на Соловках, на Колыме, в Казахстане. В результате все исправительно - трудовые лагеря вошли в единую систему Главного управления лагерей и мест поселений (ГУЛАГ). Так оформлялась система лагерей, охватившая практически всю страну. Ведущий 2. Условия содержания заключенных в этих лагерях привели к большим человеческим жертвам. Жён заключённых и их детей, как правило, тоже подвергали репрессиям. Женщин отправляли в лагеря, на каторжные работы. А детей или в лагеря, или в детские дома.

Ведущий 1. Ныне известны невероятные по своим масштабам цифры расстрелянных, репрессированных, заключенных в тюрьмы, разбросанных по детским домам. Только по неполным данным их число превышает десять миллионов человек. Тысячи инженеров, сотни тысяч замученных, расстрелянных, загубленных партийцев, миллионы крестьян, оказавшиеся жертвами раскулачивания, маршалы и генералы, ученые и поэты, писатели и артисты, которые на самом деле были преданы Родине. Вечная память безвинно погибшим. Объявляется минута молчания.

Ведущий 2. Среди них и видный татарский прозаик и драматург Аяз Мирсаитович Гилязов, который родился 17 января 1928 года в деревне Чукмарлы Сармановского района Республики Татарстан, в семье учителя. Детство и школьные годы прошли в деревне Верхний Баграж Заинского района. Закончив девять классов сельской школы, продолжил обучение в Сармановской средней школе. В 1948-1950 годы он учился в Казанском государственном университете. Как и многим его соотечественникам, ему пришлось на себе испытать все тяготы периода культа личности: с марта 1950 по август 1955 года он прошел буквально все круги ада карагандинских лагерей. Возвратившись в Казань, он продолжил учебу в университете. С марта 1957 года по август 1961 года А.Гилязов являлся литературным сотрудником редакции журналов "Чаян" и "Азат хатын", редактором отдела прозы журнала "Совет әдәбияты". Закончив в 1963 году в Москве Высшие литературные курсы при Союзе Писателей СССР, начал заниматься профессиональной литературной деятельностью. В 1988-1989гг. он написал свой роман

“Топор в чьих руках?” Этот роман очень сложное и своеобразное произведение, об этом говорит и его название.

Ведущий 1. Внимание автора сконцентрировано на двух площадках состоящее из многоступенчатых лестниц - руководители, правящие над простыми людьми и душа человека, его характер, житье-бытие, цели и желания. Человеку свойственно заглядывать в будущее, пытаться распознать его очертания. Неудовлетворенность настоящим, советской действительностью, заставила его задаться вопросом: каким должно быть будущее, в котором можно чувствовать себя счастливым, в котором можно осуществить свои надежды, реализовать идеалы?

Ведущий 2. В этом романе отображается возможный вариант общества будущего. Главный герой Аяза Гилязова – Назип Нургалиев - это человек мыслящий, субъективно порядочный, пытающийся следовать зову сердца в условиях античеловеческой тоталитарной системы. Он нацелен на более общие категории бытия, что делает его героем и социальным, и наднациональным одновременно, придает тому или иному произведению писателя действительно крупный масштаб, выходящий в общечеловеческие сферы.

Автор всячески подчеркивает житейскую беспомощность своего героя. Тот и шагу ступить не может без советов жены - красавицы Наили. Однако, подчеркивает писатель, его мнимая непрактичность - лишь внешнее проявление принципиальной общественной пассивности героя, особенно бросающейся в глаза на фоне надвигающейся катастрофы тоталитарной системы, основанной на коммунистической нравственности и морали. Отверженные герои тоталитарной системы Назип и Наиля жаждут сиюминутных радостей и наслаждений, которые позволили бы хоть на миг забыть встающие перед ними ужасы бытия, неустроенности и безработицы. Однако любовь, которую так отчаянно жаждут герои, приносит им только горе, разочарование и страдание. За нежелание жить по регламентам тоталитарной системы, Назип Нургалиев, из перспективного и подающего надежды инженера, превращается в изгоя общества, теряет хорошо оплачиваемую должность, а его жена Наиля становится любовницей своего начальника - типичного представителя командно-административной системы. За своеобразный бунт во время проведения официальных юбилейных торжеств его арестовывают и этапом отправляют в сибирский город Томск.

Ведущий 1. В романе есть ещё один пример – Фаридун Фазлыев. Хотя у него нет никаких почетных грамот и тем более высоких достижений, он смог себя сохранить. Его уважают и знают, как хорошего врача. Он сохранил свои человеческие достоинства в лагерях и в тюрьме, он не разделяет людей на «высших» и на «низших». Общество хочет избавиться от справедливых и честных людей и даже тогда он остается среди тюремщиков «представителем справедливости». В трудные минуты Назип приходит к нему, чтобы излить душу, но один раз он делает подвиг, когда узнает, что ордер на квартиру предназначался Фаридуну Фазлыеву. Назип отказывается от квартиры, и добивается, чтобы квартира досталась врачу.

Фаридун Фазлиев говорит главному герою примерно следующее: "Раньше я считал, что власть портит человека, но со временем понял, что власть подбирает в свои ряды таких же людей, какие находятся при власти: алчные, двуличные, порочные. Власть лишь обнажает пороки человека, а честные люди не рвутся к власти и не попадают в ряды вершителей судеб".

Ведущий 2. В тоже время произведение показывает «топор» в человеческом характере, в отношениях между ними. Природа человека, его психология меняется очень медленно, а самое главное – этот процесс не виден нам, и управлять этим процессом трудновато издалека. А. Гилязов поэтому и говорит и подводит итог: «В мире самое трудное – это вынести себе приговор». Топор, который висит над людьми, это – безработица; закрывает дорогу на будущее, и человека оставляет без средств, говоря, что «ты не нужен».

У татар говорят так, у кого на груди топор висит у того душа болит. Когда читаешь роман, осознаешь, что нельзя оставлять себя в таком состоянии, в каком оказался Назип. Оказывается, некоторые «топоры» находятся в наших руках, с которыми мы можем управлять и «не рубить» все наши желания и возможности.

Җәлилова Миләүшә Ринат кызы,
Азнакай шәһәренең 1 нче урта гомуми белем мәктәбе

## А.Гыйләҗевның “Җомга көн кич белән...” әсәрен йомгаклау

9 нчы сыйныф татар төркемендә әдәбияттан технологик карта

| **Дәреснең темасы** | А.Гыйләҗевның “Җомга көн кич белән...” әсәрен йомгаклау. |
|---|---|
| **Көтелгән нәтиҗәләр** | 1.Әсәр буенча укучыларның белемнәрен тикшерү һәм гомумиләштерү.<br>2.Әсәргә, аналарга, гореф- гадәтләргә мәхәббәт тәрбияләү.<br>3. Укучыларда туган җиргә, ихтирам һәм горурлык хисе тәрбияләү. |
| **Дәрес планы** | I. Оештыру.<br>II. Актуальләштерү.<br>- А.Гыйләҗевның “Җомга көн кич белән” әсәрен кабатлау. Дәреснең исемен ачыклау.<br>III. Яңа белем һәм күнекмәләр формалаштыру.<br>1. Командаларга бүлү.<br>2. Биремнәргә җаваплар эзләү.<br>3. Яңа сүзләрне истә калдыру.<br>IV. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту.<br>1. Сорауларга җавап бирү.<br>2. КВН уены.<br>V. Йомгаклау.<br>1. Сорауларга җавап.<br>VI. Өй эше. Билгеләр кую. |
| **Укыту методлары** | Әңгәмә<br>Дәреслек белән эш |
| **Укыту эшчәнлеген оештыру формалары** | Презентация<br>Төркемдә эш |
| **Укытучы эшчәнлеге алымнары** | Укытучы сүзе<br>Сорауларга җавап бирү |
| **Танып-белү биремнәре** | **Төркемнәргә бирелгән бирем үрнәге. Мәкальне дәвам итәргә.**<br>1. Кеше булу кыен түгел,------------ (кешенеке булу кыен)<br>2. Картлык------------------------ (шатлык түгел)<br>3. Картларга юл куй,------------(үзең дә картаерсың)<br>4. Бала чакта олылардан курыксаң, олгайгач---------- (балалардан куркырсың) |

**Укучылар эшчәнлеген оештыру**

Сорау- җавап

Төркемнәрдә эш

Уен – КВН.

**Слайд 2** Кроссворд

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | б | а | л | ы | к | | |
| | к | у | я | н | | | | |
| | к | ө | з | г | е | | | |
| | | | г | а | р | м | у | н |
| д | а | в | ы | л | | | | |
| | к | а | й | т | а | в | а | з |
| | ш | а | л | к | а | н | | |
| | | б | ә | р | ә | ң | г | е |
| | к | ә | җ | ә | | | | |
| | с | ы | е | р | | | | |
| | к | а | в | ы | н | | | |

**Слайд 3- 13:**

1.Канаты бар очалмый,
Күккә таба карамый,
Йолдызларны санамый,
Коры җирдә торалмый.(Балык)

2. Җәен соры, кышын ак,
Аңа шулай яхшырак. (Куян)

3. Карыйм да күрәм,
Борылам да күләм. (Көзге)

4.Сырлы, сырлы, сырлы ул,
Безнең белән җырлый ул. (Гармун)

5. Тиле- тиле, тилергән
Сарай башын җимергән. (Давыл)

6. “Ә” дисәм, “ә”, ди,
“Мә” дисәм, “мә”, ди.
Үзе бирми, бирсәм- алмый,
Сүзгә җавап кайтармый. (Кайтаваз)

7. Җир астында картыгыз,
Сакалыннан тартыгыз. (Шалкан)

8. Чәчәге агачында,
Алмасы тамырында.(Бәрәңге)

9. Сакалы бар- акылы юк.(Кәҗә)

10. Үлән ашый, май ташый. (Сыер)

11. Тышы сары, эче баллы, үзе җылы якта үсә. (Кавын)

- Нинди сүз килеп чыкты?
- Ул кем?Сез аның турында ниләр беләсез? (1 укучының рефераты белән танышу)
- Нинди әсәрләре белән таныш?
- КВН ыбызны башлыйбыз!

**Слайд 15. I тур “Картлык”**

Мин ике командага видео- фрагмент күрсәтәм.(DVD дискта. Аннары сораулар бирәм)

1. Бибинур үзендә картлык галәмәтен ничек сизә?
2. “Картаюны төрле кеше төрлечә каршылый” дигән җөмләне сез ничек аңлыйсыз?

**Слайд 16. II тур “Мин- сиңа, син- миңа”**

Һәр команда әсәргә кагылышлы сораулар төзи һәм беренче команда икенче командага , аннары алмашып , бер- берсенә бирәләр.

**Слайд 17. III тур “Үги балалар”**

**Слайд 18. (Бәяләр куелган таблица)**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **100** | **200** | **300** | **400** | **500** | **600** |

- Мин сезгә бәяләр куелган таблица тәкъдим итәм. Сез кул күтәреп кенә үз суммагызны әйтәсез. Ә мин аңа караган сорауны бирермен. Шушы суммага карап,

| | |
|---|---|
| | сезнең балларыгыз куелачак.<br>**Слайд 19 - 24.**<br>**100.** Бибинур кемнәрне тәрбияли?<br>**200.** Бибинур аларга ничек ярдәм итә?<br>**300.** Үги балаларның мөнәсәбәте әбигә карата ничек күрсәтелә?<br>**400.** Авыл халкы бу балаларга карата нинди мөнәсәбәттә?<br>**500.** Балалар үз әниләренең каберен беләләрме?<br>**600.** Габдуллаҗан белән Гайшә кемнәр алар?<br>**Слайд 25. (Тормыштан алынган ятим карчыкларның рәсемнәре)**<br>/ Чыннан да, дөньяда мондый балалар бар. Үз әти- әнисеннән туйган, карыйсы килмәгән балалар бик күп. Әти- әнисе алар өчен дип, бөтен әйберләрен бирергә әзер. Өс- башлары бөтен, тамаклары тук булсын өчен күпме тир түгәләр. Ләкин кайбер бала моңа яманлык белән кайтара, сез үз ташламагыз!/<br>*Бер укучының "Әнием" дигән мәкаләсе белән танышу.*(Индивидуаль эш)<br>**Слайд 26. IV тур " Сүзләр сүтәм"**<br>**Слайд 27. Тәгаен----------** төгәл, ачык, анык<br>**Җәберсенү---------** *үпкәләү, кимсенү, рәнҗү*<br>**Бимазалау---------** *тынычсызлау, борчу*<br>**Әҗәл----------------** *үлем*<br>**Чәркәләр------------** *савытлар*<br>**Йолып алу----------** *коткару*<br>-Мин сезгә әсәргә кагылышлы сүзләр бирәм, ә сез аңа аңлатма бирергә тиеш.<br>**Слайд 28. V тур "Җомга көн..."**<br>-Һәр команда менә бу капчыктан сораулар ала, уйлыйлар һәм җавап бирәләр.<br>1. Бибинур карчык ни өчен көн дә почтага килә?<br>2. Миңлегөл аңа нинди хәбәр җиткерә?<br>3. Бибинур нинди кеше ул?<br>4. Күршеләре Бибинурны хөрмәт итәләрме?<br>5. Ни өчен Бибинурның корреспондентны китерәсе килми?<br>6. Ни өчен әсәр "Җомга көн кич белән" диелгән?<br>(*Җыр тыңлау. З. Сәхәбиева башкаруында мөнәҗәт тыңлау)*<br>**Слайд 29. VI тур "Мәкаль әйтәм- тыңла!"**<br>- Башын үзем , ә ахырын сез әйтерсез.<br>5. Кеше булу кыен түгел,------------ (кешенеке булу кыен)<br>6. Картлык----------------------- (шатлык түгел)<br>7. Картларга юл куй,------------(үзең дә картаерсың)<br>8. Бала чакта олылардан курыксаң, олгайгач---------- (балалардан куркырсың) |
| **Төп төшенчә , исем һәм терминнар** | **Тәгаен----------** төгәл, ачык, анык<br>**Җәберсенү---------** *үпкәләү, кимсенү, рәнҗү*<br>**Бимазалау---------** *тынычсызлау, борчу*<br>**Әҗәл----------------** *үлем*<br>**Чәркәләр------------** *савытлар*<br>**Йолып алу----------** *коткару* |
| **Белем чыганагы** | **1.Дәреслек** З.Н.Хәбибуллина "Әдәбият": рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 9 сыйныф өчен дәреслек, Мәгариф, 2005<br>2. Интерактив такта.<br>3. Кино фрагменты (DVD дискта)<br>4. Компьютер.<br>5. Презентация. |
| **Өй эше** | Миниатюр сочинение язарга "Картлык – шатлык түгел". |
| **Бәяләү** | Укучылар үзләренең дәрестә катнашуларын бәялиләр. (смайликлар ярдәмендә).<br> |

Нуртдинова Раушания Равил кызы, Кәлимуллина Әлфия Нәҗиб кызы,
А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш мәктәбе, Сарман районы

**“Мәхәббәт һәм нәфрәт җырчысы” (дәрестән тыш чара эшкәртмәсе)**

1 нче алып баручы. Сарман халкы — ачык, киң күңелле, талантлы, җырга-моңга оста, ярдәмчел һәм эшчән халык. Һәр районның үзенә генә хас, кабатланмас, истәлекле урыннары, горурланырлык күренекле шәхесләре бар. Язучы Хәниф Гыйздулла улы Хәйруллин ; Татар дәүләт академия театры артисткасы Фәридә Мирхафизан кызы Сафина; Татарстанның халык артисткасы Зөһрә Шәрифуллина; Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Илһам Гыйльметдин улы Шакиров; язучы, журналист, һәвәскәр археограф Дамир Хәйрулла улы Гарифуллин; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева һәм башка тагын бик күп күренекле шәхесләре бар туган төбәгебезнең.

2 нче алып баручы. Бүгенге чарабызны якташыбыз, ТАССРның, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык язучысы, Габдулла Тукай, М.Горький исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты Аяз Мирсәет улы Гыйләҗевкә багышларбыз. Аяз Гыйләҗев – татарның әдәби мирасына зур өлеш керткән язучы. 17 нчы гыйнварда аңа 90 яшь тулган булыр иде. (Китапханәче, презентация кулланып, Аяз Гыйләҗевнең биографиясе белән таныштырып үтә)

1нче алып баручы. Аяз Гыйләҗев әдәбиятка аяк баскан еллар – каршылыклы фикерләрнең нык чәкәләшкән еллары булды. Әмма шундый фикер төрлелеге камалышында булган хәлдә дә Аяз Гыйләҗев үз сүзен кистереп әйтеп килә белде. Мондый адымнар ясарга аны үзенең асылында тоткан юлының дөрес булуына ышанганлык кына этәрә алгандыр. Бу дөрестән дә шулай : “Өч аршын җир” ен алыргамы яисә “Җомга көн, кич белән...”, “Язгы кәрваннар”, “Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят”, “Урамнар артында яшел болын”, “Яра”, “Йөгез, бер дога!” һ.б. әсәрләре – һәрберсе милләт, ил язмышына битараф булмаган оста каләм иясе кулы белән язылган хәзинәләребез. Аның публицистик язмалары, фәлсәфи фикерләре беркайчан да үз кыйммәтләрен югалтмаслар.

2 нче алып баручы. Ркаил Зәйдулланың “Аяз Гыйләҗевкә” шигырен 1 нче укучы башкара.

Акрын гына карлар төшә өскә,
Офыккача тоташ япан кар...
Учак шәүләләре сикерешә,
Бер кыз көлеп куя кайдадыр.

Ә аксакал карлар хозурында,
Алмаштырып булмый холыкны.
Азатлыкны тою мөмкинмени,
Татымасаң әгәр коллыкны?

Янәшәдә мәш киләләр эшләр,
Кем ул мылтык төзи киеккә?
Балта таушы...
Тигезлиләр тагын –
Үскән кемдер бер баш биеккә.

Татар имән сыман беркатлы ул:
Тамырларга балта тигәндә,

Горурланып аваз бирә кәүсә:
Сабы безнеке, - дип, - имәннән.
Акрын гына карлар төшә өскә,
Офыккача тоташ япан кыр.
Монда Тукай ауган, монда – Гаяз
Буран ярып алга баргандыр.
Шагыйрьләрне
Болгар бабайлар ук
Хөрмәт иткән, кулга нан биргән.
“Аның урыны Тәңре янында”, - дип,
Муенына элмәк кидергән.
Офыккача тоташ аклык бүген,
Ирексездән җаннарга йога.
Аксакалның эзләренә карыйм,
Һәм кабатлыйм, йәгез, бер дога!..
Тып – тын кала тирә – юнем шулчак,
Күздән тамган яшем ник ачы?
Иренемдә юкса ясин түгел,
Исән үтәсе юл догасы.

1нче алып баручы. Аяз Гыйләҗевнең иҗатын игътибар белән күздән кичерсәң, аның барлык әсәрләренә – хикәя-повестьларына да, пьесаларына да, публицистикасына да нигез итеп кагылган баганалар – Мәхәббәт һәм Нәфрәт. Сөйгәнеңә, гаиләңә, иптәшләреңә, илеңә мәхәббәт, табигатькә, барлык тереклек дөньясына, изге күңелле кешеләргә булган мәхәббәт.

“Берәү”, “Дүртәү”, ”Урталыкта”, “Кызлар хатлары”, ”Күзгә - күз”, ”Язгы кәрваннар” повестьлары, ниһаять, турыдан- туры шул хисне әсәрнең исеменә үк чыгарып куйган "Мәхәббәт һәм Нәфрәт турында хикәят" повесте – болар барысы да яхшы белән яманны, изгелек белән явызлыкны, ак белән караны төрле ситуацияләрдә, төрле коллизияләрдә, тормыш тәҗрибәләре һәм белемнәре төрлечә булган кешеләр язмышы аша сурәтләп бирәләр.

2 нче алып баручы. “Язгы кәрваннар” повесте “Казан утлары” журналында басылгач, Сибгат Хәким “Язгы кәрваннар” шигырен яза (2 нче укучы башкара)

Сугыштан соң икенче яз, моңсу
Язы иде кырык алтының.
Без чанада икәү, бездән башка
Эзе дә юк кырда атлының.
Абый белән икәү, озата мине,
Аты ябык, арык ат иде,
Минем күңелем кебек экрен – экрен
Эреп барган йомшак март иде.
Сугыштан соң күренеп китү өчен
Кайткан идем, юлым Арчага.
Тик без генә атлы, сугыштан соң
Калган бары бер ат, бер чана.
Безнең атның курка – өркәсе юк,
Дилбегәне абый буш тоткан.

Икенче бер, бүтән дөньядан,
Ак кар дөньясыннан, бушлыктан,
Кинәт кенә пәйда булды алар:
Ни икәнен сөеп назлауның
Онытып күптән, авыр чана тартып,
Төркеме күк киек казларның,
Хатын – кызлар килә иде тезелеп,
Кычкырдылар: ал, дип, атыңны...
Юк, сукмады абый, эйтерсең ат
Оятыннан читкә атылды.
Оятымнан мин чанадан төштем,
Йөрәгемне арыш тырнады;
Алар тартып кайткан чаналарда
Йоклый иде арыш кырлары.
Йоклый иде бодай басулары,
Йоклый иде яшел дулкыннар...
Чәчми калсаң әгәр, шушы кырлар
Гомер буе , беләм, сулкылдар.
Атны абый өйгә таба борды,
Атка җиңел хәзер, ат чаба.
Үземә дә җиңел иде минем,
Мин җәяүләп киттем Арчага.
Горур йөзләр, күзләр, ул карашар
Күңелемдә язылып калганнар.
Зәңгәр күктә горур башны чөеп,
Бара юлдан язгы кәрваннар.
10 нчы гыйнвар, 1978.

1 нче алып баручы. Бая әйткән мәхәббәт һәм нәфрәтне берләштергән “Көзге ачы җилләрдә ” драмасын халык бик яратып кабул итте. Режиссер Габдулла Юсупов аның тирәнлегенә төшә алды, буыннар язмышын, аларның күчешен һәм шул күчештәге авырлыкларны сәхнә чаралары белән тамашачыга күрсәтә алды.

2 нче алып баручы. “Көзге ачы җилләрдә” драмасыннан “Көзге ачы җилләрдә” җыры: (Ришат Төхфәтуллин башкаруында тыңлау)

Без утырган паровозның
Тоткалары җиз генә,
Бер илләрдән чыгып киткәч,
Кайтып булмый тиз генә.
Йөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып җитәрдәй булам,
Көзге ачы җилләрдә лә,
Туган-үскән илләргә.
Чәчәк идем илләремдә,
Чәчелдем чит җирләрдә.
Тагы да чәчәк булыр идем,
Кайтсам туган илләргә.
Йөгереп китәрдәй булам ла,

Кайтып җитәрдәй булам,
Көге ачы җилләрдә лә,
Туган-үскән илләргә...

1нче алып баручы. Аяз Гыйләҗевнең кодрәтле таланты татар әдәбиятына бик күп үзенчәлекле әсәрләр бирде. Ул кырыклап пьеса авторы. Аның драматургиясе – акыллы, тирән мәгънәле фикерләр драматургиясе ул. Татар дәүләт академия театрында аның байтак әсәре куелды.

2нче алып баручы. "Әгәр бик сагынсаң..."драмасыннан Фәүзия җырын 3 нче укучы башкара.

Ал яулыгым, ал яулыгым
Давылларда, җилләрдә;
Күңелләремә керден син
Мәңгелеккә, тирәнгә.
Ал яулыгым җилләрдә...
Ал яулыгым, ал яулыгым –
Таңның ал нуры төсле.
Сандугач җырын тыңласаң,
Шул минем моңым төсе.
Ал яулыгым, ал яулыгым!..
Ал яулыгым, ал яулыгым!
Казаннарда юк ише.
Үзем таптым, үзем сөйдем,
Гаҗәпләнә күп кеше.
Мәхәббәтнең юк ише...

1 нче алып баручы. "Аяз Гыйләҗевнең "Өч аршын җир", "Язгы кәрваннар", "Әтәч менгән читәнгә", "Йәгез, бер дога!", "Балта кем кулында?", "Яра", "Мостафа" кебек роман – повестьларын укып кемнәр генә тетрәнмәгәндер. Никадәр күңелләрне гыйбрәтле язмышлар үрнәге аша тәрбияләнергә мәҗбүр иткән язучы ич ул – Аяз Гыйләҗев. Аяз Гыйләҗевнең "Мостафа" повестен укыгач, мин тетрәндем. Шигырь үзеннән –үзе минем күңелемдә туды, - дип яза Мөхәммәт Мирза. Хәзер аның шигыре белән таныштырып китәрбез ( 3 нче укучы башкара)

Һәр төбәкнең Муллины
утызынчы елларда
ярлы – гидай һәр мужик:
- Мин җирле, - дип торганда,
өмет сабын сындырып,
кылыч бирде кулларга:
- Туганыңны чак, - диде,
- Туганыңны чап, - диде...
Төгәл – кырыс кулланма...
Һәр төбәкнең Мостафасы
утызынчы елларда
халыкның каш – күз арасын
ядрә белән ерганда,
юылды уелган җаннар,
чи ит белән буталып,

сузылды утлы еландай
оешкан кан тутыгы,
Черек күлне тутырып...
Мостафаның, Муллинның
оныклары туганда,
бабалары кулланмасын
өлге итеп куйганда,
оешкан кан тутыгына
күбәләкләр кунганда,
Черек күлнең аръягында
кызарып  Ай тулганда,
сискәнеп тартылды ХӘТЕР...

2 нче алып баручы. Халык шагыйре Г.Афзал Аяз Гыйләҗевнең иҗатындагы төп пафосны шактый дөрес тотып алды:

Син бик усал, ач арыслан кебек,
Усаллыгың җитәр йөз елга.
Юаш кына малай идең элек,
Усаллата икән бу дөнья.

1 нче алып баручы. Г.Афзал үз каләмдәшен “усал” дип кенә калмый, бу сыйфатның аңарда ни өчен барлыкка килүен дә аңлатып җибәрә: “усаллата икән бу дөнья”. А.Гыйләҗевтә җәмгыятькә карата “усаллык” барлыкка килүнең сәбәпләрен чын – чынлап бары тик аның “Йәгез, бер дога!” әсәре басылып чыккач кына аңлашылды күпләргә. Ул Казан – Свердловск – Петропавел – Карабас – Актас – Волынка – Маукудук – Чиләбе – Казан маршрутын, тоткын буларак, рәшәткәле вагоннарда, кысан машиналарда, урыны – урыны белән җәяүләп тә узган икән. Ни өчен? Бары тик сталинчыл режимны, халыкны изүнең бу рәвешен мактамаганы, шуны ныгытуга өлеш кертмәгәне өчен. Егерме ике яшьлек егет, шул рәвешле яманаты чыккан 58 нче маддә буенча гаепләнеп, илнең каймагы булган меңнәрчә – меңнәрчә шәхесләр арасында, чыннан да, хакимиятнең тоткан юлына аңлы рәвештә каршы булган кешегә әверелә. Аның: “Акылны төрмә кебек баета торган мәктәп юк,” – диюе шуңа ишарә.

2 нче алып баручы. “Шомырт чәчәк атканда” пьесасыннан Әндәрҗан җыры: (4 нче укучы башкара)

Кыр казлары үтте,санамадым.
Яз кайтырлар эле. Санармын.
Истәлеккә биргән кулъяулыгың
Ядкарь итеп көн дә карармын.
Кыр казлары кебек син дә киттең.
Көннәр, айлар үтте. Санадым.
Кайтырсың да аңларсың ла, җаным,
Ялгыз яшәүләрнең газабын.
Кыр казлары кайта, сәлам биреп,
Җилпи – җилпи канат кагынып.
Син генә юк, тагын ничә язлар
Яшәрмен мин сине сагынып.

1 нче алып баручы. Аяз Гыйләҗевнең мәхәббәт тарихына тукталып китәсе килә. Менә ул нәрсәләр язып калдырган: “Әнкәсенә карап кызын ал!” дип акыл беркеткән

безнең бабайлар. Яшь аермабыз шактый булса да (тугыз ел!), Нәкыягә күз салуымның сәбәпләре шулардыр дип уйлыйм: Зөләйха әбиемнәрнең изге нигезе, мохит, җылы күңелле ихлас татар дөньясы, бишек тирәсендәге соклангыч гамәлләр, әнкәсенең уңганлыгы, чисталыгы, авылча аш – суга осталыгы. Һәм көннәрдән бер көнне ачыктан – ачык, туп – турыдан мәхәббәт аңлату: ”Күп чыркылдап йөрмә, кайтырмын да өйләнермен!”

Фәрештәләрнең дәррәү “Амин!” дигән чагына туры килдеме, яшьлегемдәге дуамал хыялларымның күпчелеге тормышка ашты. Мин Нәкыягә өйләнеп, без уртак тормыш корып җибәрдек. Ләкин аңа кадәр эле...”

2 нче алып баручы. “Черек күл төрмәсенең беренче катындагы “одиночка”да мин Нәкыяне искә төшердем һәм энем Алмаз белән күрешкәч тә: “Ул кыз кайда? Кияүдәме?” – дип сорадым.

Кияүгә чыкмаган икән, Аллага шөкер! Унынчы классны тәмамлап, медицина институтына имтиханнар биреп караган да үтә алмаган, хәзер Иске Әлмәт мәктәбендә укыта икән...

Ике айдан артык Казан төрмәләрендә ятканнан соң, мине үзем чыгып киткән лагерьга кайтардылар. Анда кайтуымның икенче көнендә үк, 1954 нче елның 22 ноябрендә, Нәкыягә хат язып салдым. Ике арада хатлар йөри башлады. Менә аларның берсе:

“Сагынасыңмы?” – диләр,
Хисләр өчен
Бу сүз, дуслар, бик – бик кечкенә.
Мин: “Сагынам!” – дисәм,
Бу авазда
Җир тетрәгән тавыш ишетелә...
Нәкыя!

Хатыңны алдым. Озак, бик озак көттем мин синнән хатны. Ниһаять, ниһаять... Менә ул хат. Синең җитди, кечкенә рәсемеңнән зурларча таләпчән, җиткән кыз – бөтенләй ят, таныш түгел кыз карый. Мин озаклап синең рәсемеңә карап торам да үткәндәге кечкенә Нәкыяне күз алдына китерергә тырышам. Рәхмәт сиңа, сеңлем, зур рәхмәт” – дип язган Аяз Гыйләҗев.

1нче алып баручы. “Аяз абый лагерьдан кайткач, беренче күрүдә мин аны тамчы да ошатмадым. Тәбәнәк кенә, күзлекле, кырыс кына икән мин “риза” дип язган егет. Аяз абыйның хатлары кайнар өермә булып мине уратып алдылар да яңа давыллы хисләр дөньясында яшәтә башладылар. Тора – бара егетемнең күзлеге дә, тәбәнәк буе да онытылды. Минем янымда әйткән сүзендә нык торучы, эшләгәндә ару-талуны белмәгән, ата – анасына игътибарлы, көчле рухлы, талантлы егет калды. Аны ничек яратмыйсың! Тормышта гел генә баллы яңгыр яумый. Беренче чорда Аязны кагып-сугып рәнҗетеп йөрттеләр. Ул елларда мин аңа ышанычлы дус, терәк булырга тырыштым. Хәзер без балалар – оныклар белән бергә җыелабыз да, гомеребез бушка-заяга узмады, дип сөенешәбез. Олыгайган саен, хатыннарның дәрәҗәсе арта икән, Аяз мине элеккедән дә ныграк ярата дип уйлыйм”, - дип язды Нәкыя Гыйләҗева “Таһир - Зөһрә” газетасында. (1999, № 2 (14)

2 нче алып баручы. “Әнисе, матурым, исәнме! Әнисе, кадерлем минем! Әнисе, кадерлем! Әнисе, исәнме! Минем кадерле карчыгым! Әнисе, кадерле карчыгым! Әнисе, сөекле карчыгым! Минем матур улларым Искәндәр, Мансур, Рәшат! Улларымны һәм сине

кат – кат үбеп калам. Сагынып, үбеп калучы картың Аяз. Барыгызны да кайнар үбеп калам. Әбигә күп итеп сәлам юллыйм. Һәрбарчагызга сагынычлы сәламнәремне озатып калып, Аяз.” Бу – А.Гыйләҗевнең хатыны Нәкыя Гыйләҗевага язган хатлардан өзекләр.

1нче алып баручы. 1967 нче ел, 19 нчы декабрь, Кисловодсктан язган хаты: “Әнисе, кадерлем! Мин чыннан да рәхәтлекне тоеп ял итсен өчен, синнән хат алу кирәк булган икән. Хатыңны алгач, шулай рәхәт, күңелле һәм җиңел булып китте, әйтеп бетергесез. Җылы өйне, өстәл башына тезелеп утырган улларымны күз алдыма китердем... Нигәдер балалар хат язмый эле. Искәндәргә иртәгә хат язам дип торам. Үзе дә язсын. Өйне, сезне бик сагынам. Әбинең ураза бәйрәмен бәйрәмен әйбәтләп уздырыгыз инде. Хат көтеп калам. Сезне сагынып, үбеп, Аяз.”

2 нче алып баручы. 1968 нче ел, 6 нчы март, Ялта шәһәреннән хаты: “Әнисе, кадерле карчыгым! Сагынам. Сагынам.. Сине сагынам, улларымны сагынам, өйне сагынам. Менә малайларымны тезеп утыртам да уйланам, уйланам. Бәхетләре булсын улларымның, еллар тыныч булсын, алар һәм без сау булыйк.”

1 нче алып баручы. Бу хатларны укыгач, Аяз Гыйләҗев һәм хатыны Нәкыя Гыйләҗеваның мәхәббәтләренә сокланасың. Аның тәмле теле җанны эретерлек.

Язучы буларак та, гаилә башлыгы буларак та Аяз ага бәхетле иде. Алар Нәкыя апа белән өч гөрнәдир егет үстерделәр. Аларның берсе – галим Искәндәр Гыйләҗев, икенчесе – драматург Мансур Гыйләҗев, өченчесе – малтабар Рәшат Гыйләҗев. Өчесе дә саф татарча сөйләшә, татарча укый торган милләтебез угланнары. “Милләткә эшчән, булдыклы, һәркайсы җәмгыятьтә үз урынын тапкан өч ир – егет бүләк иткән башка татар язучысы юк”, - дип язды Тәлгат Галиуллин. “Милләтнең йөзен саклап калыр өчен иң беренче үз гаиләңдә татарча тәртип урнаштырырга кирәк!” - дия торган иде мәрхүм. Аның бу фикере сүздә генә калмады, әдип моны үз гаиләсендә үрнәк рәвештә исбат итте.

2 нче алып баручы. “Китмәгез, тургайлар!”драматик повестеннан Наза җыры: ( 5 нче укучы башкара)

Җилгә тапшырдым серемне,
Таң җиленә.
Барып җитәр дип уйладым
Күңеленә.
Уянмады җаның синең,
Уйланмады.
Офыкларым алсу төскә буялмады.
Кире кайтарды таң җиле
Бар серләрем!
Яраланды яшь йөрәгем,
Син белмәдең!

1 нче алып баручы. А.Гыйләҗев – әдәбиятыбызда татар милли характерын булдыруга зур көч куйган әдип. Без белгән Мирвәли, Шәмсегаян, Әдилә, Сабирәттәй, Бибинур, Галикәй, Хәйретдин агайлар – бары тик татар дөньясында гына була алган, шул дөньяның үзенә генә хас үзенчәлекләрен туплаган бөек шәхесләр. Аларның батырлыгы, кешелеклеге язучыга якты маяк булып торган, җанына мәңге сүнмәс җылылык биргән.

2 нче алып баручы. Язучы үткәндәге һәм бүгенге көн милләт хадимнәренең тулы җыелмасын тудыруны да максат итә: “Аерым кешенең хәтере ялгыз агач ул, аны үтмәс балта белән дә кисеп ташлап була. Халык хәтере мәгърур карурман шикелле, кисеп чыксаң – орлыктан шытачак, яндырып узсаң – тамырдан калкачак. Урманның гомерен

йөзәр яшьлек имәннәр ныгыткан кебек, халык хәтерен ныгыта, оештыра торган уртак хәзинәләр кирәк. Сәйдәшләр, Тукайлар, Мусалар”.

1 нче алып баручы. Әдәбиятыбызның классигы халкыбызның көйгә салынган көндәлек тормышын да данлый. Сабантуй, Җыен, Ураза, Корбан бәйрәме, җомга, орлык чыгару һәм башка шундый йола – гадәтләрнең тыныч – бәхетле тормышның нигезе булуын раслый.

2 нче алып баручы. ХХ йөзнең икенче яртысы – татар әдәбияты үсешендә иң әһәмиятле дәверләрнең берсе, тормыш – яшәешнең һәр өлкәсендә барган бөек үзгәрешләр вакыты. Шул вакытта А.Гыйләҗев кебек киң кырлы шәхесләр, әлеге чорның иҗтимагый – мәдәни тормышында яңа дәвер хасил итеп, милләтнең намусы һәм пакъ йөзе булдылар.

1 нче алып баручы. Тоталитар режимның иң авыр, цензураның рәхимсез котырынган елларында да Аяз Гыйләҗев халыкка туры сүз, хакыйкать сүзен алып килде, дөреслекне яклады. Шуңа да аның әсәрләре эле бик озак яшәр, автор үзе дә әдәбиятыбызда якты эз калдырган әдип буларак хөрмәт ителер.

2 нче алып баручы. “Әгәр бик сагынсаң...” дилогиясенең 2 нче пьесасы «Әткәй җырлый да... җылый да» драмасыннан Фәүзия җыры: ( 6 нчы укучы башкара)

1 нче җыр:
Күңелкәем, күбәләк кенәм,
Талпынасың нигә?
Ул кайтыр.
Күзләремә карап елмаер да
Ярсу йөрәгемне юатыр.
Күңелкәем, язгы ташудай
Чайкаласың нигә?
Ул кайтыр.
Кайнар учларына кулым кысып
Янган йөрәгемне юатыр.
2 нче җыр:
Түбәләргә тия язып, түбәләргә,
Киек казлар гына үтteләр
Һәй, киек казлар!
Һәй, киек казлар!
Сезсез булмыйдыр язлар!
Күңелләргә тия язып, күңелләргә,
Сагышларын җиргә сиптеләр.
Һәй, киек казлар!
Һәй, киек казлар!
Сезсез кайтмыйдыр язлар!

Китапханәче А.Гыйләҗевнең әсәрләреннән, аның турында язылган чыганаклардан төзелгән китап күргәзмәсе белән таныштыра.

Мусина Гузель Фаритовна,  Юнусова Резеда Фадитовна
«Джалильская СОШ №2», Сармановский район

**Тема урока: A.M.Gilyazov. “On Friday evening”**
**(А.М.Гилязов «В пятницу вечером»)**

**Класс: 10**

**Цели деятельности учителя:**

Организовать деятельность учащихся по поиску и обработке информации; обобщению способов действия; постановке цели урока, расширить знания учеников за счет включения новых определений и описаний.

**Тип урока:** урок открытия новых знаний

**Планируемые образовательные результаты:**

*Предметные:*

**Ученик научится:**

- работать с адаптированным текстом литературного произведения;

- использовать языковые средства текста в устной монологической и диалогической речи;

- группировать полученные сведения по изученному тексту.

**Ученик получит возможность научиться**: делать литературный перевод на основе прочитанного.

*Личностные:* умение вести диалог на основе взаимного уважения и принятия другой стороны; умение осмыслить ошибки и устранить ошибки, объяснять самостоятельно - изученные грамматические правила и подбирать конкретные примеры.

*Метапредметные:*

-*Регулятивные УУД:* Определение и прогнозирование трудностей при работе с текстовой информацией, способность осуществлять самокоррекцию и самопроверку устного сообщения; умение продуктивно общаться и взаимодействоватьв процессе совместной деятельности, учитывать позиции других участников деятельности, эффективно разрешать конфликты, адекватно самостоятельно оценивать правильность выполнения действия и вносить необходимые коррективы.

-*Коммуникативные УУД*: умение читать и понимать адаптированный текст; читать с пониманием основной идеи и с извлечением специальной информации; логично строить развернутое высказывание; подбирать синонимы, заменять слова; умение соблюдать формат устного высказывания; умение осознанно строить речевое высказывание в устной форме в соответствии со стилем общения и нормами языка; умение слушать собеседника и проявлять уважительное отношение к нему, работать в сотрудничестве, уметь литературно переводить текст.

-*Познавательные УУД:* умение строить логическое рассуждение (учебно-познавательная компетенция); умение работать с печатным текстом; умение выделять необходимую информацию; использовать приобретенные знания в практической деятельности;

| Этап урока | Действия учителя | Действия учеников |
|---|---|---|
| 1) Организационный момент | Приветствие. | Приветствие. |
| 2) Постановка цели и задач урока. Мотивация учебной деятельности учащихся. | Прием «кластер»:<br>На доске написано слово *literature*.<br>- Учитель просит учащихся назвать как можно | Предлагают свои |

| | | |
|---|---|---|
| | больше слов по данной тематике и записывает примеры на доске (схема).<br>(предлагает решить кроссворд (прил.3) и подводит учащихся к формулированию темы урока)<br>*T: Have a look at the crossword and answer the questions to fill it (работа с интерактивной доской)*<br>*1. The most famous russian poet. (Pushkin)*<br>*2. Who is the author of the fairy tale “Shurale”? (Tukay)*<br>*3. The author of “Romeo & Juliet” (Shakespeare)*<br>*4. The author of the play “Three sisters” (Chekhov).*<br>(Фамилия Гилязова выделена посередине).<br>*What we are going to talk about?*<br>*The theme of our lesson is A.M.Gilyazov “On Friday evening”.*<br>Учитель задает вопрос учащимся:<br>*Think of three questions you would like to ask about A.M.Gilyazov. Then listen to the biography and see if you can answer them.*<br>Организует прослушивание информации по биографии писателя.<br><br>Учитель подводит учащихся к постановке целей урока применяя вопросно-ответную работу. *What do you expect to learn at this lesson?* | варианты: *poet, writer, novel, story etc.*<br><br>Работают в группах и заполняют кроссворд на листочках, кто первый сделает.<br>Заполняют кроссворд фамилиями известных писателей и формулируют тему урока.<br><br>Записывают три вопроса в тетради.<br><br>1 ученик выступает с подготовленным сообщением о биографии Гилязова (прил.1)<br>*I want to know about his works.*<br>*I would like to get more information about his family.* |
| 3) Открытие новых знаний. | Учитель просит прочитать текст (прил.2) Настраивает учащихся на работу с текстом задавая вопрос и побуждая к высказыванию своего мнения:<br>*What do you think about Bibinur`s attitude to nature?*<br><br>Учитель дает задание на заполнение пропусков в тексте фразами, подходящи-ми по смыслу:<br>Read again and complete the gaps with the phrases below.<br>*A. were not felt so sharply (3)*<br>*B. was in need of Bibinur (5)*<br>*C. but one day she felt great changes in herself (1)*<br>*D. to overcome difficulties and resist sorrow (6)*<br>*E. the most valuable memories of her lifestyle (2)*<br>F. *watching the leaves fall down from trees (4)*<br>Дает задание на поиск в тексте слов-синонимов.<br>*Match the words in bold to their meanings. Use each one in a sentence of your own.*<br>*1. Enjoy (like, be fond of)*<br>*2. Pass by (go by)*<br>*3. Important (mean)*<br>*4. Flowering (to be in blossom)*<br>*5. The evidence (proof, argument)*<br>*6. The sign (mark, feature)*<br>*7. Delights (beauty)*<br>*8. Affinity (closeness)* | Ученики читают отрывок, отвечают на вопросы учителя и предлагают свои варианты:<br>*- She loved nature.*<br>*- I suppose she considered nature to be her friend.*<br>Заполняют пропуски и объясняют свой выбор<br><br>Находят в тексте слова синонимы и составляют письменно свои предложения с ними |
| 4) Первичная проверка | Организуется беседа по уточнению и | Высказывают свои |

| | | |
|---|---|---|
| понимания и первичное закрепление. | конкретизации первичных знаний.<br>*Work in groups. Translate the extract into Russian, give a literary translation.* | предположения в группах и делают литературный перевод выделенного отрывка |
| 5) Закрепление изученных способов действия | Выдвигает проблему и напоминает обучающимся о необходимости применения изученных лексических единиц, контролирует выполнение работы.<br>Учитель просит учеников найти себе пару из другого ряда и сесть рядом (данное упражнение направлено на формирование пар и зарядки для тела).<br>*Find the pair from the next row.*<br>*Imagine that you are Bibinur and you are talking about nature with your neighbour. Write a short dialogue and act it out.* | Работают в парах и составляют диалог на основе прочитанного текста.<br>*B: Hello, my dear. How are you?*<br>*N: Hello Bibinur! I am fine. The air is so fresh today.*<br>*B: Yes, I agree. I enjoy every season greatly. I think we should love nature.*<br>*N: Look the birds are coming back from warm countries. Spring is coming!*<br>*B: Exactly so! I am waiting for summer with an impatience because I want to clean the house before Sabantui!*<br>*N: That`s true! You always keep your home clean and tidy.*<br>*B: Thank you. etc.* |
| 6) Рефлексия (подведение итогов занятия) | Подводит обучающихся к выводу о главной идее текста.<br>*What are the main themes in Gilayzov`s works?*<br><br>Учитель организует работу учащихся с целью контроля и выявления степени усвоения учебного материала (метод синквейна)<br>-Существительное<br>-2 прилагательных<br>-3 глагола<br>-Фраза из 4 слов<br>-Синоним<br>Учитель проводит рефлексию деятельности на уроке (прием «Продолжи фразу»):<br>1. *It was interesting for me ….*<br>2. *Today we have discussed …*<br>3. *I have understood that…*<br>4. *It was difficult for me …* | Высказывают свое мнение<br>*I think he wrote about connection of a person with nature.*<br>*I suppose he showed the attitude to the native land.*<br>Излагают содержание учебного материала на тему изученного отрывка<br>*Nature*<br>*Beautiful, flowering*<br>*Enjoy, pay attention, feel*<br>*We must save nature*<br>*Environment*<br>Формулируют свое отношение к результатам урока<br>*It was interesting for me to make up a dialogue/ to make a literary translation/ to learn Gilyazov`s biography…*<br>*Today we have discussed the beauty of nature/ the author`s feelings …* |

| | | |
|---|---|---|
| | | *I have understood that nature is very fragile and we should take care of it…* |
| 7) Объяснение домашнего задания | Объясняет дифференцированное домашнее задание:<br>*Your hometask is to write about the environment in your native place.*<br>*If you want to get "5" you should write 90-100 words.*<br>*"4" you should write 75-89 words.*<br>*"3" you should write 55 -74words.* | Задают вопросы, если есть непонятные моменты |

Приложение 1

Биография Гилязова А.М. (The biography of *A.M.Gilyazov* (1928-2002)

Prominent Tatar prose writer and playwright Ayaz Mirzaitovich Gilyazov was born on January 17, 1928 in the village of Chukmarly Sarmanovsky district of the Republic of Tatarstan, in the family of a teacher.

His first novel "There were four of them" was written in 1958. His famous books are "Three arshins of earth" (1962), "The Pearl of the Hare" (1963), "In the middle" (1969), "The Spring Caravans" (1972), "The Story of Love and Hatred" (1973), "Friday Evening" (1979), "The Cock Rid the Fence" (1979-1980). All these works give us the right to call him the leading prose writer of the republic.

In the writer's works live full-blooded images. Each of his heroes bears not only the prints of his era, but it is revealed as a bright, unique personality with his character, habits, and an interesting fate. A. Gilyazov paid particular attention to the national traditions. The national spirit permeates everything in his works: language, everyday life, the melody of the phrase, as if showing that the personality finds himself not only through national culture and the past, but also power, a sense of security, a full spiritual life.

After the death of the writer, there were many unpublished letters, both personal and professional.

Приложение 2

**Перевод отрывка из произведения «В пятницу вечером»**

**(The translation of the extract from "Friday evening")**

Every person meets his old age and endures it differently. It seemed that this age **passed** Bibinur **by** 1) … . Her eyesight and ears were good. Still she reacted to the changes in nature very sensitively. A new calendar was bought every year and Bibinur put down all the **important** events on it. She wrote in a short and simple manner. All the notices were not meaningless. It was **the evidence** of Bibinur`s close connection with her daily life, 2) … . She retired early as soon as she reached the age. She wouldn`t have left the work so easy but there was no place for her. She didn`t consider her retirement as **the sign** of the old age. Though after several years her long-time relationships with not only everyday life in Aksirgak, collective farm affairs but also the seasons and changes in nature 3) … .

In early spring she used to run out of the house to meet warm winds and birds. During summer time she cleaned her house before Sabantui and everything sparkled in the sun. Dull autumn months also attracted her greatly. She spent time 4) … . Winter had its own **delights**. She **enjoyed** white snow and cold frosty air.

It didn`t matter wether Bibinur was necessary herself to the **flowering** meadows, spring storms, winter snows, dull clouds but everything was important for her. She annually revived with springs and summers. At the same time every year of her life was disappearing together

with nature. In fact every season 5) … ! Wasn`t it the nature who created a human being with a great purpose? Wasn`t he born to understand and feel the nature?

Exactly her strong **affinity** with nature helped Bibinur 6) … . It helped her to forget about loneliness. But one day everything changed!

Приложение 3

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | **4** |
| | **1** | | | | | | **C** |
| | **P** | | **2** | | | | **H** |
| | **U** | | **T** | | | | **E** |
| | **S** | | **U** | **3** | | | **K** |
| | **H** | | **K** | **S** | | | **H** |
| | **K** | | **A** | **H** | | | **O** |
| **G** | **I** | **L** | **Y** | **A** | **Z** | **O** | **V** |
| | **N** | | | **K** | | | |
| | | | | **E** | | | |
| | | | | **S** | | | |
| | | | | **P** | | | |
| | | | | **E** | | | |
| | | | | **A** | | | |
| | | | | **R** | | | |
| | | | | **E** | | | |

Александрова Әлфинур Әбүзәр кызы,
Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Якташыбыз - Аяз Гыйлаҗев (дәрестән тыш чара)**

**Максат:** татар теленә хөрмәт тәрбияләү.

**Бурычлар:** Сарман төбәгенең күренекле шәхесләрен барлау, Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлын өйрәнү, әдипнең татар халкына мөрәҗәгате белән танышу.

Дәрестән тыш чара барышы

1. Оештыру өлеше. Мотивлаштыру этабы.

(Аудиоязмада балалалар башкаруында "Хәерле көн" җыры куела,укучылар кушылып җырлый.)

Йокыдан уянуга мин
Беләм нишләргә кирәк
Елмаям эти-әнигә
Хәерле көннәр теләп.
Яратам мин,яратам шул
Матур теләк теләргә.

Онытты дип уйламагыз,
Хәерле көн сезгә дә.
Хәерле көн күршеләргә,
Дуслар туганнарга.
Теләктән читтә калмасын
Таныш булмаганнар да.

Хәерле көн, укучылар!

- Әйдәгез, барыбыз да матур итеп басып, кулга-кул тотышыйк, бер-беребезгә елмайыйк. Куллардан-кулларга җылылык, күңелдән-күңелгә рәхәтлек йөгерде, йөзләргә якты нур булып елмаю сирпелде. Менә шушы җылылык, рәхәтлек, елмаю безгә көн буена җитәрлек көч бирсен.

-Бүгенге иртәдә сезнең кәефләрегез ничек икән, билгелик әле. Үзегезнең кәефегезгә туры килгән смайликны сайлап алыгыз. Тәрбия сәгате ахырына сезнең кәефләрегез үзгәрерме, юкмы, монысын соңрак күрербез.

2. Уку мәсьәләсен кую

Татар халык җыры “Сарман” көе яңгырый.

Төркемнәрдә тикшерү өчен сораулар:

- Бу җыр сезгә ошадымы?
- Әйе, ошады.
- Кайсы ягы белән?
- Сүзләре дә, көе дә йөрәккә якын.
- Ни өчен дип уйлыйсыз?
- Чөнки ул безнең Сарманыбыз турында.
- Димәк, бүгенге дәрестә сүз нәрсә турында барачак?

Үз-үзеңү бәя кую.

3. Уку мәсьәләсен чишү.

1 төркем. Сарман ягы җырчыларын барлый.

2 төркем. Сарманның язучыларын барлый.

3 төркем. Күренекле урыннарын искә төшерә.

Төркемнәр чыгышларын тыңлау. Үз-үзеңә бәя кую.

4. Туган ягыбызда яшәүче никадәр күренекле шәхесләребез бар! Алар һәр төбәкнең үзенеке генә. Сарман төбәгендә дә алар бик күп. Сандугачларга тиң җырчы – Илһам ага Шакировны белмәгән кеше юктыр. Сарман ягын бөтен Рәсәйгә таныткан кеше ул. Татар җыр сәнгатен аннан башка күз алдына китерү кыен. Күренекле кешеләре: Нияз Акмал, Клара Булатова, Әзһәр Габиди, Дамир Гарифуллин, Рафис Гыйззәтуллин, Аяз Гыйләҗев, Гөлшат Зәйнәшева, Марсель Зарипов, Мәдинә Маликова, Сөббух Рәфыйков, Адлер Тимергалин, Ямаш Игәнәйләр. Буген Аяз Гыйләҗев иҗаты белән якыннан танышып китәрбез.

Аяз Гыйләҗев – искиткеч талантлы һәм гаять үзенчәлекле әдипләребезнең берсе. Аның тормыш юлы бик гыйбрәтле. 1928 елның 17 гыйнварында Сарман районындагы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. (2 слайд)

Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районы Югары Баграж авылында уза. Шул авыл мәктәбенең тугыз классын һәм Сарман урта мәктәбенең унынчы классын тәмамлый. Ул 1948-1950 елларда В.И.Ульянов – Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында укый. “Чаян”, Азат Хатын”, ”Казан утлары журналлары редакцияләрендә эшли. 1962 елдан Язучылар берлеге әгъзасе. (3 слайд).

Аяз Гыйләҗевнең тормыш иптәше Нәкыя ханым да мәктәптә эшләгән, укучыларга татар теленең нечкәлекләрен өйрәткән. (Аның туганы Фәния апа безнең мәктәптә күп еллар эшләде.) (4слайд). Алар 3 ул тәрбияләп үстергәннәр (Рашат, Мансур, Искәндәр) (5слайд).

Искәндәр Гыйләҗев – тарих фәннәре докторы, профессор. (6 слайд). Драматург Мансур Гыйләҗев – әтисенең эшен дәвам итүче язучы.

“Бүгенге көндә әтинең тәрбияләү принциплары, аның киңәшләре бик актуаль булыр иде. Чөнки хәзер дөнья, бигрәк тә балалар, яшьләр Интернет дөньясына кереп китте, тормыш кыйммәтләре онытыла башлады. Ә әти безне тормыш гүзәллекләрен күрергә өйрәтә иде. Авыл, табигать төшенчәләрен белеп үстек. Ул безгә гел урманга йөртә иде. Бергәләп гөмбә җыябыз, күлдә балык тота идек. Ә хәзер бит балага андый мөнәсәбәт онытыла башлады. Кайберәүләр туган җиренең кайда икәнен дә белми. Әти гомер буе кешелек кыйммәтләрен алга сөрде. Безне дә шулай тәрбияләде”, - ди Мансур Гыйләҗев. (7,8слайд)

Аяз Гыйләҗевнең әдәби мирасы бик зур. Ул үзен драма әсәрләре язып та таныта. Аның “Шикәрем син, балым син”, “Яланаяклы кыз”, “Көзге ачы җилләрдә”, “Киек каз юлы” пьесалары буенча куелган спектакльләрен халык бик яратып Татарстан театрлары сәхнәләрендә куела. (9,10,11,12,13слайд)

Балалар өчен язылган “Алсу, Илдус һәм сандугач” хикәяләр җыентыгы бар. (14 слайд) Укучылар белән өйдә укып килгән “Муйнак” хикәясе турында фикер алышу үткәрелә.

Татар әдәбияты классигы Аяз Гыйләҗев иҗаты еллар үтү белән дә татар укучысы өчен генә түгел,башка халык вәкилләренә дә кызыклы. Аның әсәрләре башка телләргә тәрҗемә ителә. Авторның “Йәгез, бер дога!” романы венгр телендә яңгыраш тапкан. (15.16 слайд)

Быел 17 гыйнварда аның юбилее билгеләп үтелде.

- Аяз Гыйләҗевнең татар халкына мөрәҗәгате бүген дә актуаль яңгырый. Шуларның берничәсен тыңлап китик әле. (17 слайд) Иң беренче: үз телеңне камил бел! Аңа зур хөрмәт белән кара, башкаларны шуңа өйрәт. Онытма: Синең Телең дөньядагы иң камил, иң бөек ундүрт телнең берсе. Теленнән йөз чөергәннең – теле көяр! Җиде буын бабаларыңның исемен бел, шәҗәрәсен сакла. Атаң-анаң сүзеннән чыкма, аларны санла һәм шәфкатьле бул. Картайган коннәрендә ярдәм ит. Гомрең буе үз милләтеңнең йолаларын сакла, гореф-гадәтләрен үтә. Үз халкыңның үткәнен бел, аның чын тарихы белән кызыксын. Өйрән һәм башкаларга да сөйлә. Үткәне юкның – киләчәге дә юк! Милли хисең турында кычкырып йөрмә, эчеңдә тот. Татар булуың белән мактанма. Әмма Горурлан!!!

Йомгаклау.

Милләт өчен, гади халык өчен янып-көеп яшәгән әдипнең иҗатын онытмау, бу бөек шәхесне зурлау бездән тора.

Күренекле әдип, Татарстанның халык язучысы, Тукай һәм Исхакый исемендәге дәүләт бүләкләре иясе Аяз Гыйләҗевнең иҗаты әдәбиятыбызның кыйммәтле бер өлеше. Аның бай иҗаты киләчәк буыннарга да хезмәт итәр, якты истәлеге халкыбыз күңелендә мәңге сакланыр. (18 слайд)

5. Көтелгән план үрнәге:

1) Сарман ягы күренекле шәхесләрен белергә.

2)Үз төбәгең тудырган бөек шәхесләрнең тормыш юлын, иҗатын, мирасын өйрәнергә.

3)Үз милләтеңнең ышанычын яулау өчен тырышырга.

6. Рефлексия

Бүгенге сыйныф сәгатендә сүз нәрсә турында барды?

Ни өчен кеше үз туган илен яратырга тиеш?

Бу чарадан үзегезгә нинди сабаклар алдыгыз?

Үз-үзеңә бәя кую. Дәрестән тыш чара ахырына сезнең кәефләрегез ничек? Смайликлар белән күрсәтегез.

Кирилова Алсу Мансур кызы,
Минзәлә шәһәренең 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе

**Мәктәптә, инновацион технологияләр кулланып, Аяз Гыйләҗев иҗатын өйрәнү**
**(**фәнни-методик эшкәртмә)

Аяз Гыйләҗев-татар әдәбиятының мәңгелек сүнмәс уты!

Татар халкы язучысы, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты.

А. Гыйләҗев – татар әдәбиятының күренекле бер шәхесе. Ул – татар милләтенең талантлы, көчле рухлы икәнлеген бөтен дөньяга раслаучыларның берсе.Аның иҗаты тематикасы, проблема үткенлеге,идея-эстетик үзенчәлеге белән хәзерге татар әдәбиятында аерым урын алып тора.Аяз Гыйләҗев – әдәбиятыбызның төрле тармакларында ут уйнаткан кеше. Ул күренекле прозаик, үзенчәлекле драматург, үткен каләмле публицист һәм очеркист, ниһаять, «усал телле тәнкыйьтче».Әдип хезмәтләренең тәрбияви кыйммәте әйтеп бетергесез зур. Беренчедән, алар – милләтебезнең рухи байлыгы, милли үзенчәлекләре турында чорыбыз вакыйгаларына бәйләп язылган әдәби әсәрләр. Икенчедән, язучы сәнгатьчә сурәтләү чараларының бик күп төрләрен кулланып, татар теленең киң мөмкинлекләреннән оста файдалану үрнәген бирә. Ләкин шунысын әйтеп үтәргә кирәк, А. Гыйләҗев – әлегә чын-чынлап, тирәнтен өйрәнелмәгән, әзер кысаларга, кабул ителгән атамаларга сыешып бетми торган зур иҗат мирасы калдырган әдип. Аның проза, драматургия, публицистика, әдәби тәнкыйть өлкәләренә керткән яңалыгын бәяләү, аңлау һәм аңлату хәзерге әдәбият фәне алдында торган изге бурычларның берсе.

Аяз Гыйләҗевнең башлангыч иҗат тәҗрибәләре студентлык чорына карый. Ләкин аның актив иҗат эшчәнлеге 1956 елдан башлана дияргә була.

Беренче әсәрләрендә үк анык сиземләнгән язу манерасы – кырыс реализм, халыкчан образларга бай җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары, кайсы чор турында һәм нинди темага язса да, кеше шәхесенең катлаулы рухи дөньясын, эш-гамәлләрен анализлау – А.Гыйләҗев иҗат эшчәнлегенең төп асылын, идея-эстетик юнәлешен тәшкил иткән сыйфатлар.

"Өч аршин җир" (1962 ел), "Зәй энҗеләре" (1963 ел), "Урталыкта"(1969 ел), "Язгы кәрваннар"(1972 ел), "Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят" (1973 ел), "Җомга көн кич белән" (1979 ел), "Өтәч менгән читәнгә" (1979-1980 ел) әсәрләре белән Аяз Гыйләҗев үзен повестьлар остасы итеп танытты.

Тематик яктан А.Гыйләҗевның күпчелек повестьлары авыл тормышына багышланган. Аларда кичәге һәм бүгегенге авыл, аның гади кешеләре гәүдәләндерелә. Аяз Гыйләҗев – ике дистәдән артык драма әсәре авторы да. Аларның күбесе республика театрлары репертуарына кертелгән.

Соңгы елларда А.Гыйләҗев роман жанрында иҗат итүгә күп көч куйды. Аның бер-бер артлы "Балта кем кулында" (роман), "Йәгез, бер дога!" (роман-хатирә) кебек зур күләмле әсәрләре дөнья күрде.

"Җомга көн кич белән" һәм "Өтәч менгән читәнгә" повестьлары өчен А.Гыйләҗев 1983 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Әдәбиятны һәм театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен аңа 1978 елда Татарстанның, ә 1985 елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә. Ул – М.Горький исемендәге премия лауреаты да.

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен 1993 елда, Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Аяз Гыйләҗевкә Татарстан Республикасының халык язучысы дигән мактаулы исем бирелде.

Хәзерге көндә кеше мәгълүматлар чолганышында яши, яңа мәгълүмати технологияләрдән башка ул аларны үзләштерә дә, җәмгыять үсеше өчен файдалана да алмый. Тормышыбызга компьютер һәм шуның белән бергә мәгълүмати технологияләр нык үтеп керде. Алар укучыга гына түгел, хәтта укытучының үзенә дә үсәргә киң мөмкинлекләр бирә. Белем бирү процессын компьютерлаштыру – мәгариф үсешендә өстенлекле юнәлешләрнең берсе.

Яңа мәгълүмати белем бирү мохитенә күчү шушы мохиткә хас педагогик мөмкинлекләрне, методларны, формаларны, җиһазларны һәм шулай ук укучылар өчен көтелгән нәтиҗәләрне тәэмин итәрлек төрле белем бирү эшчәнлекләрен өйрәнү һәм анализлауны күзаллый.

А.Гыйләҗев иҗатын өйрәнүгә программада рус мәктәбенең 9 нчы сыйныфларның рус һәм татар төркемнәрендә “Җомга көн кич белән”, 11 нче сыйныфның татар, 10 сыйныфның рус төркемендә “Йәгез, бер дога”, 7 нче сыйныфның рус төркемендә “Өч аршын җир” әсәрләре бирелгән.

Аның иҗаты белән тулырак танышу, тәрбияви әһәмиятен укучыларга тирәнрәк аңлату максатыннан чыгып, өй эше итеп АГыйләҗевнең биографиясен һәм “Җомга көн кич белән” әсәрен укырга кушам. Дәрескә килгәндә, укучылар аның тормыш юлы һәм иҗаты, әсәрнең эчтәлеге белән хәбәрдар булалар. Дәресне кызыклырак, үзенчәлеклерәк итү өчен тәнкыйди фикерләү технологиясенең метод һәм алымнарын, ассоциацияләр методын кулланып эшлим.

Укучыларга түбәндәге **“идеяләр кәрзине”**н тутырырга тәкъдим итәм.



Сыналу Көч Бүләк

Укучыларга мондый сорау бирәм: Аяз Гыйләҗевнң тормыш һәм иҗаты буенча сез бу кәрзиннәргә нинди идеяләр салырсыз? **“Сыналу”** га нәрсәләр керә? (Укучылардан көтелгән җаваплар: Аяз Гыйләҗевнең башлангыч иҗат тәҗрибәләре студентлык чорына карый. Ләкин аның актив иҗат эшчәнлеге 1956 елдан башлана дияргә була).

**«Көч»** кә нәрсәләр керә? (Аңа да шәхес культының газапларын татырга туры килә. 1950 елның мартыннан башлап 1955 елның августына кадәр Казакъстанда тоткынлыкта була).

Аяз Гыйләҗев кайсы “**бүләк”кә** лаек? (Татар халкы язучысы, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты. Әдәбиятыбызның имән баганасы).

Тормыш сынауларын үткәндә, сыгылмыйча, теләсә нинди шартларда да (тормыш сиңа власть, акча, авырлык бирә) син кеше булып калсаң, үзеңне-үзең югалтмасаң, язмыш сине бүләкли.

Талантлы шагыйрьнең иҗатын ничә еллар буе өйрәнү – ул бит бездән бүләк. Үлгәннән соң да яшәү үзе бүләк түгелме?

**1. Чакыру. Кызыксындыру уяту.**

“Җомга көн кич белән” повесте.(Өй эше итеп, алдан укып килергә кушылган иде)

Экрандагы рәсемнәргә карагыз әле, рәсемнәр буенча теманы табарга тырышыгыз. (Әйе, темабыз “Ялгызлык, картлык”).

Булган белемнәрне активлаштыру. Дәреснең беренче этабында кулланыла. Укучылардан күбрәк идеяләр әйттерү өчен уңайлы. Ничек уйлыйсың? - Барысы да уйлый, фикер әйтә.

Картлык шатлык түгел, диләр. Үзең картаеп, аның ачысын тойгач кына бу сүзләрнең дөреслегенә инанасың. Ә бит яшь чакта бер дә картаймассың шикелле. Тик җырдагыча: “Картлык беркемне дә урап узмый”.

Ә бит безнең барыбызның да бәхетле җылы картлыкны каршы аласы килә.

**“Бәхетле картлык” формуласын төзибез.**

**Бәхетле картлык**
**Бәхетсез картлык** } Нинди ассоциацияләр тудыра ?

(Укучылар төркемнәрдә ассоциацияләр чылбырын язалар).

Мин сезгә үз җавапларыгызны “Идеяләр кәрзине” ысулы аша әйтергә тәкъдим итәм.



**Бәхетле картлык**
Картлык тынычлыгы мич башы
җылысыннан түгел,
үз юлыңнан кадерле кеше барганын
күргәндә генә килә бит!



**Бәхетсез картлык**
Ялгыз картлар үзләрен беркемгә дә
кирәк түгелләр икәнлеген сизеп
яшиләр.

Картлык тынычлыгы, янәшәңдә сине кайгырткан балалар һәм оныклар булуда.

Бу ысул, гадәттә, дәреснең беренче этабында кулланыла. Ул идеяләрне, төшенчәләрне, фактларны тупларга һәм алар арасында бәйләнеш тудырырга ярдәм итә. Иң әһәмиятлесе: ул язма сөйләмне камилләштерү һәм укучыларның шәхси, парлап һәм төркемнәрдә эшләүләрен оештыру мөмкинлеген бирә. Ул дәрестә балаларның белемнәрен активлаштыру вакытында кулланыла.

**2 . Аңлау (төшенү)**

А.Гыйләҗевнең“Җомга көн кич белән” повесте белән тагышуны дәвам итәбез.

1.**“Сүзләр болыты”** алымын куллану. Һәр группага эш бирелә. “Сүзләр болытын”да нинди мәгънә һәм исем яшеренгән?










Видеоязманы кушу.Сорауга җавап эзләү. Әсәрнең төп героен табу.

2. Бибинур – әсәрнең төп герое. Аңа характеристиканы **ассоциатив символлаштыру алымы** ярдәмендә бирү.



Ялгыз, шәфкатьле, балалар бәхетен мәхәббәттән өстенрәк күрә, игелекле, балаларны үз итә, сабыр, Гайшә алдында җаваплылык сизә **- Ялгыз, карт ана.**

3**.”Зигзаг” алымын куллану.**

Һәр группага эш бирелә. Группадагы һәр укучыга бер тулы бер текстның бер өлеше бирелә. Шул өлештән укучы иң кирәклесен генә эзли. Я схема, я таблица төзи. Группадагы укучылар үзләрнең парларын табалар (кемгә №1, я №2 текстның өлеше эләккән). Эксперт группалары эшли башлый, бергә җавап эзлиләр. Иң яхшы җавапны эзлиләр.

Балалар – ярдәмче геройлар. Аларга характеристиканы **ассоциатив символлаштыру алымы** ярдәмендә бирү.



Игелексезләр, кешелексезләр, мәрхәмәтсезләр – **Балалары**

**Әсәрнең үзәгендә  нинди мәсьәләләр тора?**

(Конкрет мисалда ата-аналар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәт, өлкәннәргә ярдәм итү, өлкән кешеләр язмышы, буыннар арасындагы бәйләнешнең өзелүе, кеше күңеленең рухи байлыгы, әхлак мәсьәләсе)

**Алга таба нәрсә булыр?**

Хәзерге көндә дә үз әти-әнисен рәнҗеткән, олыгайган көннәрендә тәрбияләмәгән, картлар йортында яшәткән кешеләр бар. Аларны аналары, төн йокыларын калдырып, үстергән, укыткан, кеше итәргә тырышкан. Шул балалар картлык көннәрендә ярдәм итмиләр. Алар иртәме-соңмы үзләре дә картаячаклар. Алар үзләренең балаларына нинди үрнәк күрсәтәчәкләр? Юкка гына татар халкы “Олыласаң олыны – олылар үзеңне” дигән мәкальне  уйлап тапмагандыр. Шуңа күрә ата-ананы, өлкәннәрне хөрмәт итәргә, ярдәм итәргә, карарга кирәк. Син әти-әниеңне ничек карасаң, киләчәктә балаларың да сине шулай тәрбияләр.

**3.Рефлексия.**

**Ни өчен повесть “Җомгакөн кич белән” дип атала?**

Сабантуй атнасы. Җомга көн кич белән. Авылга Сабантуйга бик күп кеше кайта. Бибинур әби генә ялгыз. Аның янына беркем дә кайтмый. Ул берүзе утырып кала, һаман балаларын көтә. Шуңа күрә дә әсәр “Җомга көн кич белән...”дип атала.

**“Җомгакөн кич белән”**

**“Мәсьәләләрне чишү таблицасы”** н тәзергә

**“Бәхетле картлык” формуласы”**

**Йомгак**

А.Гыйләҗев “Җомга көн кич белән...” повестында кеше җанының иң тирән почмагына кадәр үтеп керүгә ирешә. Рәхимсез балалары тарафыннан онытылган Бибинур карчыкның, беренче карашка физик яктан шактый зәгыйфь тоелган әбинең көчле рухы, кешеләргә карата чиксез мәхәббәт белән сугарылган олы җаны, әрнүле һәм фаҗигале эчке дөньясы тирән ачыла.

А.Гыйләҗев “Җомга көн кич белән...” әсәре белән зур һәм актуаль проблеманы күтәреп гыйбрәтле кешеләр язмышы һәм тормышындагы чынбарлыкны тасвирлап бирә.

А.Гыйләҗев үткән, бик борынгы мәҗүси чорларда яшәгән кешеләр арасындагы яшәеш кануннары һәм киләчәктә тууы мөмкин булган мөнәсәбәтләрне үзенең хыялы белән берләштереп, шуларның синтезы итеп, татар прозасының иң уңай каһарманнарыннан берсен – Акъәбине, Бибинурны, иҗат иткән.

А.Гыйләҗев иҗаты үлмәс, мәңгелек иҗат. Аның турында яңадан-яңа фикерләр туа, нәшрият битләрендә аның турында язылган мәкаләләр көннән көн арта.

Афзалова Луиза Әкрам кызы,Шәйдуллина Ландыш Камил кызы,
икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

## Хаталар кабатланмасын!

| | |
|---|---|
| **Дәреснең темасы** | Хаталар кабатланмасын! |
| **Дәреснең тибы** | 30 нчы октябрь – сәяси репрессия корбаннарын искә алу көне уңаеннан уздырылган татар әдәбиятыннан математика белән берләштерелгән сыйныфтан тыш уку дәресе |
| **Сыйныфы** | 9 нчы сыйныф, татар төркеме |
| **Дәреснең максаты** | Кулланылган мәсьәлә текстлары, укылган әсәрләрне барлау аша шәхес культының тирән фаҗигасен тоемлауга ирешү, укучыларның сөйләм телен, фикерләү сәләтләрен үстерү, бер–берсенең чыгышларын тыңларга, бәяләргә өйрәтү, нахакка җәберләнгән шәхесләргә карата ихтирам хисләре тәрбияләү. |
| **Җиһазлау** | Репрессияләнгән татар язучылары турында презентация, А.Гыйләҗев әсәрләре күргәзмәсе, дәрестәге эшчәнлекне бәяләү таблицасы, “Процент исәпләү” темасына биремнәр, “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”, Татарстанның Хәтер китабы, өч тәгәрмәчле арба сүрәтләнгән А3 форматы. |

| Дәреснең барышы | | |
|---|---|---|
| **Этаплар** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучылар эшчәнлеге** |
| Мотивлаштыру<br><br>Максат: уңай психологик халәт тудыру.<br><br>Укучыларны уку эшчәнлегенә тарту. | -Исәнләшү.<br>Тактадагы язмаларга, дәреснең эпиграфына мөрәҗәгать иттерү | “30 нчы октябрь – сәяси репрессия корбаннарын искә алу көне”,<br>“Акланырга сәбәп тә бар<br>Чоры шундый, чоры –<br>Һәр гаиләнең тәнендә –<br>Сталин ярчыгы” (М. Әгъләмов) язмаларын уку һәм шулар буенча дәреснең темасын ачу. |
| | Дәреснең интеграль булуын әйтү, мәсьәләләр чишү, аларның процентны исәпләүгә корылуын хәбәр итү. | Шәхси эшчәнлек: ике фәннән дә эш дәфтәрләрен барлау, датаны, темаларны язып кую. |
| | Дәрестәге эшчәнлекне бәяләү таблицасы белән таныштыру | Дәрестә төркемнәрдә эшләү кагыйдәләрен искә төшерәләр: башкаларны тыңла, үз фикереңне ачык әйт, игътибарлы бул, бәяләү таблицасына билгеләр куеп баруны онытма. |
| Актуальләштерү<br><br>Максат: яңа белем алуга әзерлекне тикшерү | Төркемнәр алдына сораулар кую. (Слайдларда ачыла)<br>Аңлатмалы сүзлекләр белән эшләү:<br>1 төркем - репрессия,<br>2 төркем – культ,<br>3төркем –шәхес культы сүзләренә аңлатма бирә. | 1.Сез репрессия сүзен ничек аңлыйсыз?<br>2. Шәхес культы нәрсә дигән сүз?<br>3. Сүз ничәнче еллар турында бара? сорауларына җавап бирү.<br>Аңлатмалы сүзлекләрдән безне кызыксындырган сүзләрнең аңлатмасын табу. (Репрессия – җәза бирү, кысу чарасы, җәзалау эше; культ – кемгә яки нәрсәгә дә булса табыну; шәхес культы – җәмгыятьтә аерым шәхесләрне идеаллаштыру, аңа табыну). Дәфтәрләргә язып кую. |
| | Кире дәресебезнең эпиграфына әйләнеп кайтып, шигъри юлларны аңлату. Чорга характеристика бирәбез. Кайсы еллар турында сүз бара?<br>Нәтиҗә ясау: бөтен көчне хәрби һәм эре индустриягә багышлаган чорда Сталинның шәхси хөкемдарлыгына юл ачыла һәм репрессияләр башлана. | Укучылар 30 нчы елларда булган вакыйгаларны барлыйлар: илне коллективлаштыру, индустриализацияләү, шәһәрләр төзү, күпләп завод-фабрикалар төзелү, удар бишьеллыклар игълан ителә.<br><br>Җавап бирүче укучыларны билгеләп кую. |
| Уку мәсьәләсен чишү | Процент исәпләүгә мәсьәләләр чишү (слайдларда күрсәтү) | 1.*Татарстанның Хәтер китабы (китап күрсәтелә) мәгълүматлары буенча, Татарстанда 1937 нче елга - 7375 беренчел, 917 кабат кулга алу туры килә. 1937 нче елда барлыгы 8292 кеше репрессияләнә. 3056 кеше иң каты җәзага - үлемгә хөкем ителә. Үлемгә хөкем ителүчеләрнең процентын табыгыз. Килеп чыккан санны йөзгә кадәр түгәрәкләгез.*<br>*2. 8292 репрессияләнгән кешенең 2382се хөкем ителә, 185е аклана, 983 кешенең эшен тикшерү туктатыла, 9ын мәҗбүри рәвештә дәвалануга җибәрәләр. Репрессиягә эләккән кешеләрнең аклану дәрәҗәсе нинди? Килеп чыккан санны түгәрәкләгез.*<br>*3. Репрессияләнгән кешеләрнең сыйныф катлавын өйрәнсәң, мондый нәтиҗә ясап* |

| | | |
|---|---|---|
| | Үзбәя, бәяләү | *була: иң күп репрессияләнүчеләр– крестьяннар. Ә бит алар сәясәттән ерак, белем ягыннан да түбән, күбесе укый-яза да белми. Алардан соң – эшчеләр. Болары революция тарафдарлары булган. Таблицаны карагыз һәм репрессияләнүчеләрнең санын табыгыз.* (Кушымтада бирелә)<br>*4. Диаграммада репрессиягә дучар булучыларның милләтләре буенча бүленеше күрсәтелгән. Кайсы милләт вәкилләре күбрәк булуын ачыклагыз.* (Кушымтада бирелә)<br>Җавап бирүче укучыларны билгеләп кую. |
| Уку мәсьәләсен чишүне дәвам итү<br><br>Үз фикереңне әйтү өчен, төрле дәлилләр сайлый белү, аларны раслау | Төркем алдына сорау кую, аңа җавап эзләү. - *Репрессия елларында социаль катлау булган муллалар, аларның гаиләләре, гаиләләре белән сәүдәгәрләр, предприятие хуҗалары, кулаклар сөрелә. Укучылар, ә кулаклар дип кемнәрне атаганнар соң?* | Булган белемнәрдән чыгып, фикерне формалаштыру. Фикереңне кыска һәм матур итеп әйтү.<br><br>Җавап бирүче укучыларны билгеләп кую. |
| | Мәсьәләләр чишүне дәвам итү (слайдларда күрсәтү) | 5. *Хезмәт сөюче крестьяннар, без аларны кулаклар дип атарга мәҗбүрбез, һәм колхозлар уңышны 7:1 нисбәтендә үстерәләр. Барлыгы 10,4 млн тонна икмәк үстерелгән. Кулаклар өлешенә туры килгәнен табыгыз.* (Җавап 9,1 млн. тонна)<br>6. *Алдагы диаграмманы карагыз да нәтиҗә ясыйбыз. Кайсы социаль катлау аеруча җәфа чигә?* (Кушымтада бирелә) |
| Ял моменты | | |
| Уку мәсьәләсен чишүне дәвам итү | Төркем алдына сорау кую, аңа җавап эзләү.<br>-*Укучылар, җәмгыятьтә булган үзгәрешләр, вакыйгалар әдәби әсәрләрдә чагылыш тапмый калмый. Әдәбиятны без һәрвакыт теге яки бу чорга бәйләп өйрәнәбез, чөнки язучы яшәгән яисә әдәби әсәрдә чагылдырган елларны, ул вакытта булган тарихи вакыйгаларны белми торып, без әдәби әсәрне тулысынча аңлап, бөтен йөрәгебез белән кабул итә алмыйбыз. Узган уку елында без Гариф Ахуновның “Идел кызы” әсәрен укыдык. Исегезгә төшерегез әле, әсәрдә кайсы катлам кешесе кыерсытуларга дучар булды?* | Гариф Ахуновның “Идел кызы” әсәрендәге вакыйгаларны барлау. Габбас мулланың фаҗигасенең сәбәпләрен искә төшереп сөйләү.<br><br>Җавап бирүче укучыларны билгеләп кую. |

| | | |
|---|---|---|
| | *-Репрессияләнүчеләр арасында татар язучылары да шактый. Сталинның канлы балтасы татар әдәбиятының муенына иң үткен вакытта төшә. Г.Ибраһимов, М.Галәү, Җ.Валиди, Ф.Сәйфи-Казанлы кебек өлкән буын язучылар белән беррәттән яшьрәк язучылар Ф.Бурнаш, Г.Толымбай, Л.Гыйльми, Ш.Усманов, К.Тинчурин бер гаепсезгә үтерелә. Х.Туфан, И.Салахов һәм башкалар сөргенгә җибәрелә.*<br>Төркем алдына сорау кую, аңа җавап эзләү.<br>*-Репрессияләнгәннәргә “Халык дошманы” тамгасы сугылган. Бу тамга гаиләнең барлык әгъзаларына кагылган.* | Экранда күрсәтелгән фоторәсемнәр белән танышып бару.<br><br>Х.Туфанның тормыш иптәше Луиза Салигаскәрова язмышын искә төшереп сөйләү. Җавап бирүче укучыларны билгеләп кую. |
| Мәсьәләләр чишүне дәвам итү (слайдларда күрсәтү) | *-Андыйлар миллионнар булган. Архив документлары буенча 1921-1953 елларда репрессияләр вакытында СССРда барлыгы 6 млннан артык кеше зыян күргән дип санала. Тик аларның саны хатыннары, балалары, туганнары, дуслары дучар булган төрле мыскыллау-кыерсытуны исәпләсәң, дистәләрчә миллионга да туладыр. Документлар буенча әлеге 6 млн кешенең 4 млннан артыгы төрлечә җәзаланган, 800 мең кеше үлемгә хөкем ителгән. Зыян күрүчеләрнең 2,6 млн тирәсе милләтчелектә гаепләнгән.* | 7. *ДнепроГЭС, Идел-Дон каналы, Метрополитен кебек бөек төзелешләр, яла ягып, нахакка кулга алынган кешеләрне җәзалау, “төзәтү” корылмаларына әверелә. Репрессияләнгән кешеләрнең күбесе Магнитогорск шәһәре төзелешенә килеп эләгә. Аларның саны якынча 42, 5 мең кешене тәшкил итә. Барлык репрессияләнгән кешеләрнең өчтән ике өлешен Татарстан кешеләре тәшкил итә. Аларның саны ничә? Җавабыгызны бөтенгә кадәр түгәрәкләгез.* (Җавап 28 мең кеше).<br><br>Җавап бирүче укучыларны билгеләп кую. |
| “Өч тәгәрмәчле арба” хикәясе буенча фикер алышуны оештыру | Төркем алдына сорау кую, аңа җавап эзләү.<br>*-Якташыбыз Аяз Гыйләҗев студент вакытта шушы мәхшәрне үткән кеше. Аның “Ягез, бер дога” әсәре - шул елларның канлы хатирәсе. Бу уку елында без бу автор иҗаты белән ныклап танышырбыз әле. Бүген без сез укып килгән “Өч тәгәрмәчле арба” хикәясе турында сөйләшербез.* | Дәрескә Аяз аганың шушы хикәясен сайлап алуның сәбәпләрен аңлату.<br><br>Җавап бирүче укучыларны билгеләп кую. |

| | | |
|---|---|---|
| Мөстәкыйль эш | Төркемнәрнең мөстәкыйль эшен оештыру.<br>- *Сезнең алда менә шундый макет. Аның үзәгендә өч тәгәрмәчле арба. Нәрсә символы ул, укучылар?* | Куелган сорауга җавапны А3 форматлы битләрдә белдереп, схемалар ясау.<br>Төркемнәрнең үз эшләрен яклавы.<br><br>Җавап бирүче укучыларны билгеләп кую. Үзбәя. |
| Йомгаклау<br><br><br>Үз фикереңне әйтү өчен, төрле дәлилләр сайлый белү, аларны раслау | - *Укучылар, 1991 елның 18 октябрендә РСФСР Югары Советының 30 октябрь көнен сәяси репрессия корбаннарын искә алу көне буларак билгеләп үтү турындагы карары пәйда була.* | Әсәр герое Рашат Сәләев кебекләрнең җиңел сулап куя алуларының сәбәбен аңлату. |
| Рефлексия, өй эше бирү. | Темага бәйле рәвештә дәрескә нинди нәтиҗә ясап була?<br>Бәяләү таблицасын җыю. | *Хатирәләр онытылырлык түгел. Хәзер инде бер генә теләк: мондый хәлләр кабат кабатланмасын, мондый вәхшилекләргә юл куелмасын иде.*<br><br>Өйдә “Репрессия еллары - безнең гаилә тарихында" яисә “Өч тәгәрмәчле арба” хикәясе героеның алдагы тормышын ничек күзаллыйсың?" темасына чыгыш әзерләргә. |

## Кушымта

3 нче мәсьәлә

| Социаль катлаулар | Халык саны |
|---|---|
| колхозчылар | 7397 |
| крестьяннар (кулаклар, колхозга керергә теләмәүчеләр) | 22207 |
| эшчеләр | 9334 |
| хәрбиләр | 2766 |
| хезмәткәрләр | 7005 |
| төрле җитәкчеләр | 3584 |
| студентлар | 534 |
| Ислам дине әһелләре | 1065 |
| Православие дине әһелләре | 1663 |

4 нче мәсьәлә



6 нчы мәсьәлә




Шәйхелисламова Лилия, Бариева Фәнүсә,
икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Аяз Гыйләҗевның тормышы һәм иҗаты**
**(Сыйныфтан тыш уку дәресе)**

Максат: Якташ язучыбыз Аяз Гыйләҗевнең тормышы һәм иҗаты белән таныштыру.

Көтелгән нәтиҗәләр:

*Предмет нәтиҗәләре:* укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү; укылган текстның планын төзү.

*Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:* үз фикереңне әйтә белү; төркемнәрдә килешеп эшли белү; фикереңне дәллили белү.

*Регулятив универсаль уку гамәлләре:* уку бурычларын кую.

*Танып – белү универсаль уку гамәлләре :* укыганны анализлау.

*Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:* башкаларның сөйләмен ишетү һәм тыңлау; башкаларга аңлаешлы сөйләм төзү.

Материал, җиһазлау: Аяз Гыйләҗев китаплары, аерым битләргә бастырылган кроссвордлар, Аяз Гыйләҗевның электрон фотосурәте, проектор, экран.

Дәрес барышы.

I. Оештыру.

- Исәнмесез!

II. Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.

-Балалар, без сезнең белән якташ язучыларыбызны өйрәнүне дәвам итәбез.

- Бүген кем турында сөйләшәчәкбез икән? Аны белер өчен сезгә кроссворд чишәргә кирәк. (Группаларга кроссвордлар бирелә.)




1. Безнең районыбызның үзәге булган авыл.(Сарман)
2. Бистәбез шагыйрәсе, 1 нче санлы Җәлил гомуми урта белем бирү мәктәбендә укыткан Хезмәт ветераны һәм Татарстан язучылар берлеге әгъзасының исеме. (Рухия Ахунҗанова)
3. Чукмарлы авылында яшәп иҗат иткән язучы. Күп еллар укытучы булып эшләгән. (Әзһәр Габиди)
4. “Кикринур”, “Бакакак” китапларын иҗат иткән районыбызның шагыйрь-язучысы, тарихчы-галиме.(Дамир Гарифуллин)
5. Җәлил бистәсендә яшәүчеләр нинди? (тырыш)
6. Сарман районы Урта Кәшер авылында туган «Очучы буласым килә», «Көтелмәгән сорау», һ.б. китаплар авторының исеме. (Рафис Гыйззәтуллин)
7. Әзһәр Габиди туган һәм яшәгән авыл. (Чукмарлы)
8. Безнең якташ җәлилче Зиннәт Хәсәновның туган авылы.(Кәшер)
9. Герой-шагыйрь исеме бирелгән бистә.(Җәлил)
10. Сарман районында урнашкан урыс авылы.(Александровка)
11. Сарман районы Чураш авылында гомер кичерүче, 36 ел мәктәптә укытып атказанган укытучы исеменә лаек булган балалар язучысының исеме. (Вәсимә Хәйруллина)

Хәзер бергәләп тикшерик инде. (Экрандагы интерактив кроссворд тутырыла)

- Килеп чыккан исемне укыгыз.

- Балалар, сез кроссвордны дөрес чиштегез. Хәзер инде дәреснең темасын һәм максатларын әйтеп карагыз.(Аяз Гыйләҗевнең тормышы һәм иҗаты турында сөйләшү)

III. Яңа материал. (Экранда Аяз Гыйләҗевнең фотосурәте)

Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. Авыл мәктәбенең тугызынчы сыйныфын тәмамлагач, унынчы сыйныфны Сарман урта мәктәбендә укый.

1948 – 1950 елларда ул – Казан дәүләт университеты студенты. Аңа да шәхес культының газапларын татырга туры килә. 1950 елның мартыннан башлап 1955 елның августына кадәр Казахстанда тоткынлыкта була. Казанга кайткач, университетта укуын дәвам итә.

1957 елның мартыннан 1961 елның августына кадәр А.Гыйләҗев матбугат эшендә: «Чаян» һәм «Азат хатын» (хәзер «Сөембикә») журналлары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, «Совет әдәбияты» ("Казан утлары") журналында проза бүлеге мөхәррире вазифаларын үти.

1961-1963 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укып кайтканнан бирле Аяз Гыйләҗев, язучы-профессионал сыйфатында, әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә.

Аяз Гыйләҗев 2002 елның 13 мартында вафат булды.

"Җомга көн кич белән" һәм "Әтәч менгән читәнгә" повестьлары өчен А.Гыйләҗев 1983 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Әдәбиятны һәм театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен аңа 1978 елда Татарстанның, ә 1985 елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә. Ул – М.Горький исемендәге премия лауреаты да.

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен 1993 елда, Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Аяз Гыйләҗевкә Татарстан Республикасының халык язучысы дигән мактаулы исем бирелде.

IV. Группаларда эшләү.

-Сез өйдә Аяз Гыйләҗевның “Алсу, Илдус һәм сандугач” әсәрен укып килдегез.

- Төркемнәргә мондый бирем: “Алсу, Илдус һәм сандугач” әсәренә план төзергә. Бирем аңлашылдымы? Башладык. (Төркемнәрдә эшләү)

- Төркемнәрнең эшләрен тикшерәбез. (Укучыларның планнарына нигезләнеп гомуми план төзелә һәм тактага языла).

- Без хикәя эчтәлеген искә төшердек. Алдагы бирем мондый. Укучылар, сез ничек уйлыйсыз, Алсу һәм Илдус белән алга таба нинди вакыйгалар булырга мөмкин? Төркемнәрдә шушы сорауларга җавап эзләп карагыз әле. (Төркемнәрдә эшләү).
Укучылырның җавапларын тыңлау. Фикер алышу.

V. Рефлексия.

- Балалар, сезнең каршыгызда берничә җөмлә. Теләгән җөмләләрне тәмамлап, бүгенге дәрестән алган кичерешләрегезне әйтегез.

Мин бүген ... белдем.

Миңа ... кызык булды.

Миңа ... авыр булды.

Миңа ... аңлашылмады.

VI . Өй эше. Аяз Гыйләҗевнең “Муйнак” әсәрен укырга.

VII. Йомгаклау.

Салихова Гөлнара Атлас кызы
Яңа Кәшер санатор интернат-мәктәбе, Әлмәт районы

**Татар әдәбиятының алтын баганасы**

Дәрескә аннотация

Бәйге өчен әзерләнгән әдәбият дәресем, «Татар әдәбиятының алтын баганасы» һәм Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән» әсәре буенча төшерелгән «Бибинур» фильмына күзәтү экскурсия-дәрес рәвешендә алынды.

Дәреснең тибы: бәйләнешле сөйләм теле үстерү

Эш төрләре (алымнар): сорау-җавап, карточкалар белән эш.

Дәреснең төзелеше:

1.Оештыру өлеше.

2.Белемнәрне актуальләштерү

Максат: бүгенге темага нигез булырлык итеп, Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән» әсәре буенча сораулар биреп, төгәл җавап алуга ирешү.

3.Уку мәсьәләсе кую

Максат: укучылар белән берлектә дәрес-экскурсиягә бәйләнешле сүзне табу.

4.Төп өлеш. Төп өлеш заллардан тора. **I зал. «Кино - китаптан башлана». II зал. Кино - күмәк хезмәт. Кемнәр кино төшерә? IIIзал. Видеозал.**

Физпауза

5. **Рефлексия.**

Бәяләү.

Өй эше: **IV зал - иҗади эшләр залы.**

Дәреснең темасы программада, А.Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән» повестен укыгач, әсәрне кино сәнгате белән бәйләп, бәйләнешле сөйләм теле үстерү дәресе тибында бирелде. Тема 1 дәрес (сәгать) итеп өйрәнелә.

Дәрес-экскурсияне укучыларның яшь үзенчәлекләрен, белемнәрен, тормыш белән бәйләнешен исәпкә алып төзедем.

Әлеге дәрестә укытуның төрле алымнарын кулландым: сорау-җавап, карточкалар белән эш, эзләнү.

Белем һәм тәрбия бирүгә якын килеп, дәресемдә балаларның тәрбиялелеген күтәрү өстендә дә эшләргә тырыштым.

Дәресемә түбәндәге максатларны куйдым: Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән» әсәре буенча төшерелгән «Бибинур» фильмы белән өстәмә материаллар аша танышу; кино сәнгате турында сөйләшү; тема белән бәйләп укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү; сүз байлыгын арттыру; логик фикерләү сәләтен үстерү; уен элементлары кулланып, укучыларда татар теле һәм әдәбияты дәресләренә кызыксыну уяту; мөстәкыйльлелек, игътибарлылык, оешканлылык сыйфатлары тәрбияләү; укучыларның үз фикерләрен әйтә алулары белән үзләрен күркәм холыклы шәхес итеп тоярга мөмкинчелек тудыру; тормыш белән бәйләнешне күздә тотып, яшәешкә дөрес караш тәрбияләү; укылган повесть һәм каралган кино аша укучыларда ата-анага, якын кешеләргә карата мәрхәмәтлелек хисе тәрбияләү; мин-минлек, эгоистлык сыйфатларының начар булуына төшендерү.

Өй эше итеп, **IV залны үзебез иҗади оештырырга** тәкъдим ителде.

Куелган максатымнан чыгып, дәресемне Р.Фәхреддин сүзе белән йомгаклыйсым килә. «Шәкертләрне гыйлем белән тәрбияләү, изге шәригатьтә аңлатылган күркәм холыклар белән таныштыру һәм гадәтләндерү – укытучының беренче эше булыр».

Дәрес темасы: А.Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән»әсәренә нигезләнеп төшерелгән “Бибинур” фильмына күзәтү.

Сыйныф: 9нчы сыйныф

Дәрес тибы: бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

Планлаштырылган нәтиҗәләр:

Шәхескә кагылышлы: Россия гражданинына хас сыйфатлар тәрбияләү: укучыларда татар халкының талант иясләренә хөрмәт хисе, аларның иҗатын өйрәнү теләге уяту;татар халкының һәм Татарстанда яшәүче башка халыкларның тарихына, теленә, мәдәниятенә ихтирам хисләре булдыру; укучыларның үзлегеннән белем алуга, танып белүгә әзер булуы, аңлы рәвештә һөнәр сайлауга килүе; Татарстан, Россия һәм бөтендөнья халыкларының сәнгати һәм мәдәни мирасын үзләштерү аша матурлык сыйфатларын үстерү.

Метапредмет: татар әдәбиятының үсешен кино сәнгате белән бәйләп өйрәнү;

Предмет-уен элементлары кулланып, Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән» әсәре буенча куелган «Бибинур» фильмы турында өстәмә материаллар аша танышу; кино сәнгате турында сөйләшү.

Материал: кино итеп төшерелгән китаплар күргәзмәсе: А.Гыйләҗев «Җомга көн, кич белән», Г.Әпсәләмов «Ак чәчәкләр»; Айдар Хәлим «Өч аяклы ат»; Гадел Кутуй. «Тапшырылмаган хатлар»; Хәбир Ибраһим «Ялгыз тәкәрлек»; Халисә Ширмән «Еректагы йолдызым».

Җиһазлау: Мультимедиа проекторы, презентация

**Дәрес барышы**

**1.Оештыру өлеше.Уңай психологик халәт тудыру.**

Балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру. Бүгенге эш өчен кирәкле сыйфатларны билгеләү. Моның өчен һәр укучыга җәмәгать урыннарында үз-үзен тоту кагыйдәләре язылган карточкалар таратыла.

1. Театрга, киногa пөхтә һәм бәйрәмчә киенеп кил.

2. Спектакльгә һәм кинофильмга соңга калма.

3. Театрда өс киемеңне сал, күлмәгеңне төзәткәлә, чәчеңне тара. Ә кинотеатрда, гадәттә, чишенмиләр, ләкин ир балалар баш киемен салырга тиеш.

4. Рәт арасыннан узганда, урындыкта утыручыларга алдың белән карап кер.

5. Театрга һәм клубка кергәч, билетта күрсәтелгән урынга утыр.

6. Тамаша залында тирә-юньдәгеләргә комачаулама, утыргычны шыгырдатма, кәгазь кыштырдатма, сызгырма, сөйләшмә.

7. Кинотеатр залында тыйнак, тәртипле бул: идәнне чүпләмә, спектакль, кино барганда ашап утырма.

2.Белемнәрне актуальләштерү

Максат: бүгенге темага нигез булырлык итеп, Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән» әсәре буенча сораулар биреп, төгәл җавап алуга ирешү.

3.Уку мәсьәләсе кую

Максат: укучылар белән берлектә дәрес-экскурсиягә бәйләнешле сүзне табу. Табышмаклар ярдәмендә ФИЛЬМ сүзен чыгарырга.

1. Йөртәләр аны һәрвакыт
Каты-каты типкәләп,
Җан-фәрманга йөгерә ул,
Тормый бер дә үпкәләп.(футбол тубы)

2. Кара да , ак та, каты да, йомшак та
Иске дә, яңа да, тәмле дә, баллы да,
Махсус завод пешерә, бик тә кирәк кешегә.
Ул нәрсә? (икмәк)

3. Озын, юка, төп-төз ул,
Билгели ул иң төз юл;
Юллары озынлыгын
Беләм санап сызыгын.(линейка)

4.Нокталар урынында нинди хәреф язарга.
Кәгаз.....- дәр.....я,
Каләм- көймә. ( Ь)

5.Аяз Гыйләҗевнең этисенең исеме. (Мирсәет)

- Нинди жанрдагы кинолар беләсез? Сугыш (боевик) турында, тарихи, драма, триллер, комедия, әкияти, фантастика

4.Төп өлеш.

- Экскурсиянең объекты - кинотеатр һәм без читтән торып кинотеатр залларына экскурсия ясарбыз. («Экскурсия» слайдлар ярдәмендә башкарыла)

**I зал. «Кино - китаптан башлана». Кино сәнгате белән таныштыру өчен сүз «Тарихчы»га бирелә.**

- Фильм сүзенә аңлатма биреп китик әле. Фильм- исем, инглиз теленнән кергән сүз. 1. Кино төшерү өчен яктылыкка сизгер катламнан торган юка целлулоид пленка тасма; 2) Шул тасмага төшерелгән сурәт, кинокартина. Нәфис фильм.

Кино сәнгате – заманча сәнгать төре, әсәрләр хәрәкәтләнүче рәсемнәр ярдәмендә иҗат ителә, кино сәнәгате – кинофильмнар төшерүче, аларны төшерер өчен махсус эффектлар, мультипликацияләр эшләүче икътисад тармагы. Кино сәнгате әсәрләре кинотехника ярдәмендә иҗат ителә.

Россия президенты В.В. Путин тарафыннан 2016 ел – Россиядә кино елы дип игълан ителгән иде.

Кинофильмнар, сериаллар кешелек тарафыннан иң яратып кабул ителгән ял итү чараларының берседер, мөгаен. Бу төрдәге сәнгать кече яшьтәге сабыйдан алып олы кешеләргә кадәр бик яхшы таныш. Өйдә телевизор артында карыйсыңмы, әллә кинотеатрларга барып карыйсыңмы, без бер генә мизгелгә дә кинодан аерылып тормыйбыз. Һәм безнең яшәешебезне аннан башка күз алдына китерүе дә кыен.

Фильмнарны без төрле форматларда карый алабыз. Әмма дә ләкин һәрнәрсәнең башлангычы булган кебек кино сәнгатенең дә тарихы бар. Россиядә беренче фильмның премьерасы 1908 елда булган. Әлеге кинолента режиссер Владимир Ромашковныкы булган. Әлеге фильм 7 минут кына барган. Ә төсле фильм экраннарга 1925 елда чыккан. Танылган «Броненосец Потемкин» дип исемләнгән киноны Сергей Эйзенштейн төшергән.

Иң беренче татарча кино 1927 нче елда төшерелгән. Татар крестьяннарының Пугачев хәрәкәтендә катнашулары турындагы бу фильм «Булат-Батыр» дип атала. Фильмны 30 дан артык илдә күрсәткәннәр.

Сезнең каршыгызда «Кино – китаптан башлана» дигән исемдә китап күргәзмәсе. Бу күргәзмәдә **махсус бүләкләр алган әсәрләр (кушымта №1) һәм** бөтен татар дөньясын шаулаткан «Бибинур» фильмына нигез итеп алынган Аяз ага Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән» китабы да бар.

**Укытучы сүзе.** 2010 нчы елның 19 нчы июнендә режиссер Юрий Фетинг төшергән «Бибинур» фильмы (сценариын драматург Мансур Гыйләҗев язган) VI халыкара мөселман киносы фестивалендә ике бүләккә лаек булды. Ул «Иң яхшы тулы метражлы нәфис фильм» номинациясендә җиңү яулады. Шулай ук «Тулы метражлы нәфис фильмда иң яхшы хатын-кыз роле өчен» номинациясендә фильмда төп герой Бибинурны уйнаган Г.Камал исемендәге академия театры артисткасы Фирдәвес Әхтәмова бүләкләнде.

Татар матбугат чаралары «Бибинур» фильмы турында күп язды. Алар татарның хәзер «Бибинур» фильмы белән теләсә кайсы дөнья киңлеген иңли торган, теләсә нинди фестивальдә катнашырлык кинобыз бар дип авыз тутырып әйтә алуын билгеләп үтте. «Фәлсәфи тирәнлек, фильмның башы һәм ахыры тәңгәл килү, мистик вакыйгалар белән әсәрнең эчтәлеген ача белү – болар барысы да режиссерның табышы, таланты турында сөйли. Рус телле режиссер Юрий Фетингның татар мохитен шулкадәр нечкә тоемлавы,

милли хисләрне күңеле белән аңлый белүе барыбызны да сокландырды», - диләр матбугатчылар.

«Бибинур» фильмының сюжет сызыгы болайрак корылган: инде өлкән яшьтә булган Бибинур төш күрә. Ул тиз арада җомга көнне бу дөнья белән саубуллашырга тиеш икән. Бибинур, үлгәнче, бурычларын биреп бетерергә һәм Мәңгелек белән очрашуга әзерләнергә тиеш. Әмма көтмәгәндә аның авылында криминал белән шөгыльләнүче эшкуарлар һәм җир биләүчеләр пәйда була. Алар иске зират урнашкан җирне табыш китерерлек итеп сатып җибәрмәкче була. Аларның берсе – Җиһангир исемлесе озак еллар чит илдә яшәп кайткан һәм мул тормышка ияләнгән кеше була.

«Бибинур»фильмының продюсеры Светлана Бохараева сүзләренчә, фильмны төшерү җиңел булмаган. «Бу сәхнәдә бу фильмны эшләүдә катнашкан ике йөзләп кеше басып торырга тиеш. Бу – безнең уртак приз, - диде ул, фестиваль бүләген өскә күтәреп. – Әлеге фильм татар авылы, аерым бер татар әбисе турында гына түгел. Ул – безнең бу тормышны ничек яшәвебез хакында». Светалана Бохараева «Бибинур» фильмының халыкара мөселман киносы фестивалендә җиңүен яхшыга юрады һәм әлеге фильмны дөнья тамашачысына танытуда этәргеч булуын билгеләп үтте.

Фильмның режиссеры Юрий Фетинг, үз чиратында, РФ һәм ТР Мәдәният министрлыкларына рәхмәтен җиткерде. Казанда барысының да яхшы булуын, әмма тулы көченә эшләүче киностудиянең булмавын әйтте. Шул ук вакытта Татарстанда бу мәсьәлә белән шөгыльләнүчеләрнең барлыкка килүенә канәгатьлек хисләрен белдерде.

Бибинур ролен уйнап, фестивальнең «Тулы метражлы нәфис фильмда иң яхшы хатын-кыз роле өчен» номинациясендә төп бүләкне алган Фирдәвес Әхтәмова, сәхнәгә чыккач, дулкынланудан берникадәр вакыт сүзен дә әйтә алмый торган. Сүзен бисмиллә белән башлап җибәргән Фирдәвес ханым: «Миңа бөтен әйбер көтмәгәндә килә. Монысы да шулай булды», - дигән .

**II зал. Кино - күмәк хезмәт. Кемнәр кино төшерә?**

Бу залга кергәнче түбәндәге биремне үтәргә кирәк. Бу биремне Сезгә кино куючылар тәкъдим итә

| **№** | **Нокталар урынына тиешле сүзләрне куегыз.(Бирем парларда, төркемнәрдә эшләнергә мөмкин)** | **Ярдәмче сүзләр** |
|---|---|---|
| **1** | **....** (грекча) — хәрәкәт иткән рәсемнәрне берләштергән кеше эшчәнлеге төре. Кайсы бер вакытларда синемато́граф дип атала (фр.*cinématographe*). .... XIX гасырда барлыкка килде. | Актер |
| **2** | Театр сәхнәсендә һәм киноларда рольләр башкаручы артист яки.... | Кинематограф |
| **3** | Экранда күрсәтелә торган кинематографик әсәр-...... Художественный фильм-нәфис фильм. | Монтажер(монтажчы)- |
| **4** | Кинога төшерү яисә телевидениедә сурәт тапшыру эшләрен башкаручы белгеч- ... | Режиссер |
| **5** | ... фильмның, әдәби яки музыкаль әсәрнең аерым кисәкләреннән эчтәлеге һәм художество эшләнеше ягыннан бер бөтен әсәр булдыручы. Мәсәлән, кеше 100м. сикерә алмый, кешене шул биеклектән сикертүне ... эшли. | Оператор |
| **6** | ... -спектакль һәм кинофильмнарны сәхнәгә куярга әзерләүче | Композитор |
| **7** | ...- музыкаль әсәрләр, композицияләр иҗат итүче. Баштагы вакытларда композиторлар кино барышында тере тавыш белән уйнаганнар. | Кино(кинофильм)- |
| **8** | Сәхнә, кадр, дубль санын әйтеп баручы .... | Сценарист |
| **9** | ... -кинофильм иҗат итү өчен махсус рәвештә әсәр язучы | Продюсер |
| **10** | Кинофильм ул зур проект эшчәнлеге. Аны төшерү, эшләү зур чыгымнар сорый. Һәм шуның өчен ... кирәк. Аларның бурычлары кино төшерүчеләргә яхшы уңайлыклар тудыру | Режиссер ярдәмчесе |

**«Кино куючы».** Аяз Гыйләҗевнең «Бибинур» фильмын куючылар һәм татар киносы сәнгатен үстерүчеләрбелән таныштыра. (Кушымта №2)

Продюсер Светлана Бухараева. Күпсерияле телевизион фильмны куючы режиссер Юрий Фетинг. Оператор Максим Дроздов. Фильмның сценарий авторлары Мансур Гыйләҗев, Юрий Фетинг. Рәссам Булат Гыйльфанов. Тавыш режиссеры Игорь Сиденко. Композитор Радик Салимов. Фильмда халык җырлары яңгырый. «Бибинур» фильмы «Сабантуй», «Татаркино» киностудияләрендә Рәсәй Федерациясенең Мәдәният министрлыгы ярдәме белән төшерелә. Драма Мамадыш районы Алгай авылында төшерелгән.

**Шзал. Видеозал.**

**1 нче «Актер». Бу зал да Аяз Гыйләҗевнең** «Бибинур» фильмында катнашучы төп рольләрне башкаручылар белән таныша аласыз.

**Бибинур** – Фирдәвес Каюм кызы Әхтәмова (21 июль 1939 ел — 22 февраль 2012 ел) — татар артисткасы, 1996 еланТатарстанның халык артисты.

**Җиһангир** – Эрнест Әнвәр улы Тимерханов – Русия кино һәм театр артисты һәм режиссёр.

**Зәмирә түти** – Хәлимә Шакир кызы Искәндәрова, (19.05.1940) — драма актеры, Камал исемендәге Татар дәүләт академия драма театры артисты,Татарстанның атказанган артисты.

**Яшь Бибинур -** Резидә Һадиуллина. Актриса. Казахстанда Евразия халыкара кино фестивалендә "Кино сәнгатендә яңа исем" номинациясендә җиңү яулый. Шушы ук фильм Германиядә үткән Халыкара фестивальдә дә катнаша.

**Вәли бабай** – Нәсих Фазлырахманов. Мамадыш районының абруйлы мәчет карты

**Габдуллаҗан** – Т. Миңнуллин исемендәге татар дәүләт драма театры җитәкчесе, баш режиссеры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, М. Сәлимҗанов исемендәге республика премиясе лауреаты, Россия театр әһелләре берлеге әгъзасы Рөстәм Галиев

**Мансур** – актер Руслан Мостафин

**2нче актер Татарстаннан бәйгедә катнашкан нәфис фильмнар белән таныштыра. (кушымта №3)**

**5. Рефлексия.**

**Рефлексив кабатлау**

Укытучы. Сезнең алдыгызда кәгазь битләре бар. Анда җөмләләр язылган.Үзегезгә охшаганны алып, җөмләләрне дәвам итегез.

Бүген мин .... белдем.

Миңа .... ошады.

Мин биремне ..... эшләдем

Мин ..... аңладым.

Мин .... өйрәндем.

Мин ... эшләп карыйм.

2. Бәяләү. 1. Укучылар үзбәя куялар. 2.Укучыларга, дәрестә катнашканнары бәяләнеп, билгеләр куела.

3.Өй эше: **IV залны үзебез иҗади оештырырбыз. Бу залда сезнең тарафтан әзерләнгән төрле рәсемнәр, открыткалар, иҗади эшләр урын алып торыр.**

Кушымта №1 **Махсус бүләкләр алган әсәрләр**

2011 елда Илдар Ягъфәровның «**Югалту»** картинасын «Милли гореф-гадәтләрне һәм татар телен саклап калуга керткән өлеше өчен» дигән махсус бүләк белән билгеләп уздылар.

2013 елда Мәскәү режиссеры Максим Швачконың **"Уен ахыры"** дип аталган фильмы Татарстан президентының махсус бүләгенә лаек булды. Картина татар авылында төшерелгән, анда татарча репликалар яңгырый. Фильмның икенче режиссеры һәм сценарий авторы – татар драматургы Илгиз Зәйниев.

2014 елгы фестивальдә Ильдар Матуровның «**Туфан Туфан инде»** дип аталган документаль эшен җюри махсус искә алып узды.

2015 елда Салават Юзиевнең «**Ишекне шапылдатып яптым да киттем»** дигән фильмы кыска метражлы нәфис фильмнар арасында иң яхшысы дип табылды, ә баш рольне уйнаган Илдус Габдрахманов иң яхшы ир-ат роле өчен призга лаек булды. Иң яхшы тулы метражлы документаль фильм номинациясендә исә татарлар турындагы фильм җиңеп чыкты. **"Кичерелмәгәннәр сугышы"** дип аталган фильмны Мәскәү режиссеры Денис Красильников төшергән. Казан мэрының махсус призын ул елны Степан Беловның «**Ярату билгесе астында. Композитор София Гөбәйдуллина Казанда»** дип аталган картинасына бирделәр.

2015 елда ТЮРКСОЙ да үзенең бүләген булдырган иде. Бүләк «**Рудольф Нуриев. Рудик»** фильмы өчен Фәрит Дәүләтшинга бирелде. «Татар әдәбиятын экранлаштыруга керткән өлеше өчен» махсус приз «**Ак чәчәкләр»** режиссеры Ренат Әюповка тапшырылды.

Милләттәшләр һәм башка илләрдән режиссерлар дини һәм милли тамырларны эзләүгә багышланган документальленталар белән әлеге фестивальдә актив катнаша. Мисал өчен, 2012 елда Беларус татарлары турында Сергей Лукьянчиков төшергән «**Беларус күгендә азан яңгырый»** дип аталган фильм Русия Мөфтиләр шурасының махсус бүләгенә лаек булды.

2014 елда Германиядән килгән татар фильмы игътибарга лаек булды. Нәсүр Юрушбаевның **«Әтиемнең тавышы»** дип исемләнгән фильмда Германиядә әсирлектә булган Ибраһим Хәлимов тавышының күп еллардан соң Татарстанга, аның 90 яшендә булган кызына килеп ирешүе тасвирлана.

Кушымта №2

**Фото күргәзмә. (слайдлар ярдәмендә күрсәтелә)**

Татар киносы сәнгатен үстерүчеләр: Татарстан Кинематографлар берлеге рәисе, режиссер **Илдар Ягъфәров,** драматург **Мансур Гыйләҗев, фильмнарга сценарий язучылар: Мансур Гыйләҗев,** Нурания Җамали, Данил Салихов, Ркаил Зәйдулла, Әмир Камалиев, Илгиз Зәйниев, яшь режиссер **Илшат Рәхимбай,**Татарстанның халык артисты **Әсхәт Хисмәтов,**Татарстанның атказанган артисты **Рәмзия Закирҗанова,** «Татаркино» дәүләт оешмасының «Мир» кинотеатрында директор ярдәмчесе Наилә Гәрәева.

**Кушымта №3 Татарстаннан бәйгедә катнашкан нәфис фильмнар.**

**2005 ел.** Илдар Ягъфәровның «**Күктау»** нәфис фильмы «Алтын минбәр»дә («Алтын минбәр» – фестивальнең әвәлге исеме) катнашып «Иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә җиңде. Баш рольне уйнаган Фәрит Бикчәнтәев бүләк алды.

**2008 ел.** Нурания Җамалиеваның «**Өч аяклы ат»** дип аталган нәфис фильмы бәйгедә катнашса да, бүләк ала алмады. Татарстаннан тагын бер документаль әсәр

катнашты – илаһиятче, публицист Муса Бигиев турында **«Һәм ай ярылды»** дип аталган фильм.

**2009 ел. «Бөркетләр»** фильмы «Иң яхшы ир-ат роле» өчен бүләккә лаек булды. Мактаулы исемне Камал театры артистлары Әзһәр Шакиров, Ринат Таҗетдинов һәм Равил Шәрәфи алды.

**2010 ел.** Режиссер Юрий Фетинг төшергән **«Бибинур»** фильмы фестивальнең баш бүләген отты. Моннан тыш, Татарстанның халык артисты Фирдәвес Әхтәмова «Иң яхшы хатын-кыз роле»ндә җиңеп чыкты. **Фильмның казанышлары:**Казан халыкара мөселман киносы фестивалендә Гран-при - 2010 нчы елның иң яхшы фильмы.

Актриса Фирдәвес Әхтәмовага - иң яхшы хатын-кыз роле өчен бүләк (Бибинур роле).

Халыкара Евразия кинофестивалендә (2010 ел) – иң яхшы хатын-кыз роле өчен актриса Резеда Хадиуллинага бүләк (яшь Бибинур роле).

Иң яхшы режиссер хезмәте өчен бүләк (Франция, Онфлер, 2010 ел).

Иң яхшы сценарий өчен бүләк (Франция, Онфлер, 2010 ел)

**2014 ел.** Илдар Юзеевның яшь татар язучысы Илдар Әбүзәров әсәре буенча төшергән «**Корбан-роман. Корбан белән бәйле тарих»** фильмы. Фильм берьюлы ике приз алды: Даниил Шигапов «Иң яхшы ир-ат роле» өчен бүләкләнсә, фильм авторларына Казан шәһәре башлыгының махсус бүләге тапшырылды.

Гайсина Гөлүсә Рифхат кызы,
19 нчы урта мәктәп, Яр Чаллы шәһәре

**Татар әдәбиятының алтын баганасы**

Аяз Гыйләҗев - татар прозасының тәҗрибәле язучыларыннан. Аяз ага ерактагы якын йолдыз кебек. Ул үзенең иҗат дәверендә төрледән-төрле әдәби геройлар, бай образлар дөньясын бирде, аларда заман кешеләренең катлаулы язмышларын, каршылыклы характерын күрсәтә алды. Аяз Гыйләҗев турында уйланганда, әсәрләрен укыганда, ул бәгырьләрне тетрәндерерлек дәрәҗәдә якын булып күз алдына баса. Шул ук вакытта ул буй һәм хыял җитмәс еракта, биеклектә торгандай. Ачык төнне күктәге йолдызлар шулай күренә, кулыңны суз да үзеңә ошаганын тартып ал. Булмый шул, адәм баласы күпме омтылса да, әкиятләрендә, җырларында, ягъни сәнгать әсәрләрендә, хыялый метафорада гына күк җисемнәренә барып җитә алган. Мин бу хисне ике сүз белән - Рухи Камиллек дип атар идем. Ошбу каршылыклы тойгылар, күрәсең, аның тормышчан гадилегеннән, үз чорын тирәннән сөреп, аңлап, киләчәкне тоемлап, иҗатында шуның чаткыларын чагылдырып кала алу сәләтеннән килә торгандыр.

Хәятнең күпьяклы күренешләрен, социаль-әхлакый конфликтларның нәкъ үз чорын характерлый торганнарын сайлап, шул көрәшләр эчендә сурәтләнгән геройларның язмышы үткәннең һәм бүгенгенең фаҗигасе булып та күз алдына килә: Мирвәли - язучының нәкъ шундый үткәннән килә торган герое («Өч аршын җир», 1963). Әсәрдәге киеренке конфликт, аның үстерелеше, гомумән чынбарлыкның катлаулы яклары геройның эчке дөньясы аша чагылыш таба. Мондый сурәтләү формасы язучы стиленең отышлы ягы, ул язучының кеше характерын ачу осталыгын да күрсәтә. Мирвәли кичерешләре аркылы утызынчы елларның сыйнфый көрәшләре, Шәмсегаян белән эчкерсез мәхәббәте, яшьлек дәрте белән төзеп җибәргән гаилә бәхете, комсыз кулак ата белән талашлары киеренке гәүдәләнә. Рухи дөнья процессын алып баруда икенче

персонаж - Шәмсегаянның роле зур. Туган җирен сагынып яшәүче бу күбәләк җан, Мирвәлинең антиподы булып, кичерешләрнең дәвамын һәм уйлар йомгагының очын очка ялгап, алга табан әйди, әйтерсең ул Мирвәлинең киләчәк яшәешен билгеләп куя. Мирвәлинең җинаяте - туган җиргә, авылдашларына кизәнүендә, мәңгелек яра калдыруында. Ул - аларның әллә никадәр ашлыкларын агулап чыгып качкан кеше. Геройның үкенү хисләрендә туган җир хакының кыйммәте тагын да зурая төшә. Шунысы мөһим: монда халык күңеленең хөрлеге, гафу итә белә торган кешелекле табигате ачык күренә. Өч аршын җирне Мирвәли фәкать туган авылында гына таба. Язучы геройның эчке хәрәкәтенә үзе катнашмый, аның уй-хис агышын табигый юнәлешкә сала һәм шуның белән укучы күңелен биләп ала да.

Шундый ук юнәлештә эчке тавыш белән бирелгән икенче герой - Сәгыйть («Урталыкта», 1972) - Гыйләҗевнең иҗат осталыгын билгели торган образ. Кайчандыр яхшы әсәрләр бирә алган драматург хәзер торгынлыкта яши, урталыкта калган, үзенә ярдәм итеп килгән остазы Баязит картка да ул хыянәт иткән икән. Бу - вөҗдан тартышына әйләнгән психологик конфликт геройның кичерешләрен көчәйтә. Сәнгатьтәге каршылыклар Гали Кадыйров кебек интриган типлар белән катлауланып китә, күңел бәхәсләре арта, иҗатчы йөрәгенә үтеп кергән хәтәр торгынлык күз алдына баса. Туры табигатьле Баязит карт һаман урталыкта калганнарны кузгату өчен кирәк. Нәкъ менә карт галимнең булышлыгы аркасында, Сәгыйтьнең иҗат эзләнүләре кузгалып киткәндәй була. Һәрхәлдә, кешеләр арасындагы уңай мөнәсәбәтләрнең яшәүчәнлеге инандыра сыман. Аяз Гыйләҗев үзенең геройларын кат- кат эшләргә ярата.

«Берәү» (1978) повестеның үзәк герое Исхак сурәтләнешенә күз салсак та, язучының киеренке эзләнүенә юлыгасың. Соңгы басмада персонажның эчке үсешен аңлатырга теләү үз логикасына таянуын сурәтләү күзәтелә. Конфликтның тормышчанлыгы Исхак язмышында төп рольне уйный. Авыл тормышына кул селтәгән егет, күп михнәтле юл үтеп, шул ук туган җиренә, туган якларына кайтып ямь таба. Күпме эзләнүләренең каршылыклы агышы, шәһәр белән авылның контраст тормышы, сугыштан соң авылларны төзекләндерү өчен барган тартышлар һәм андагы яшәү газаплары Исхакның драматик язмышын тудыра. Әлбәттә, агроном егетнең читтән бәхет эзләве ничектер аның идеалларын кимсетә, хәрәкәт сферасын тоткарлый шикелле. Авылның үзгәреше, ярдәмгә юмарт холкы аны ымсындыра, күңел кылларына кагыла. Тагын шуңа күптән эзләгән мәхәббәтнең авылда табылуы өстәлеп, егетнең күрү офыклары киңәеп китә. Ашкынучан егеткә яшәүнең тирән мәгънәсе ачыла. Шуңадыр, күрәсең, Исхак олы тормыш юлында үзен таба алган шәхес булып хәтердә кала.

А. Гыйләҗевнең геройлары – бүгенге көннең гадәти яшьләре, тормышның четерекле якларыннан читләшмичә, катлаулы хәрәкәттә баручы тынгысыз шәхесләр. Шул яклары белән алар – җәлеп итүчән, эзләнү һәм өмет, югалту һәм табышлар нәтиҗәсендә генә кеше булып яшәүче драматик типлар. Алар бер-берсенә каршы куелган персонажлар түгел, бәлки бер үк хакыйкать өчен көрәшүче төрледән-төрле геройлар төркемен тәшкил итә. Әхәт белән Идрис – нәкъ шундый типларның ачык үрнәге, «Урамнар артында яшел болын» (1980) романының төп персонажлары, журналист егетләр. Язучының геройлары шушы позициядән чыгып уйланылган. Әхәт тә, Идрис тә - конфликт сызыгында, икесе ике төрле характер иясе. Алар – үзләренең киеренке хәрәкәте, эчке драматизмы белән социаль-әхлакый конфликтны әйдәп баручы геройлар. Әсәр жанр ягыннан роман дип аталса да, кеше язмышларын сурәтләүдә киеренкелек һәм тирәнлек җитми шикелле. Шул сәбәпле, тыгыз башланып киткән сюжет сызыкларын ачу өчен, язучы, иң кыен

проблеманы алып, шул хисапка жанр киңлеген алып барырга тырыша. Алты яшьлек Айдарның көйсез яшәве, унөч яшьлек Мөзәкирнең олылар тарафыннан гамьсез кыйналуы хәзерге тормышта мораль конфликтларның кискенлеген, рәхимсезлекнең еш очравын искәртә. Мөзәкир каты кыйналудан түгел, бәлки гаделсезлеккә нәфрәтләнеп, асылынып үлә. Вакыт-вакыт өлкәннәрдәге рәхимсезлек һәм ваемсызлык малайның бөтен омтылышларын кисеп ташлый, аптырау хәленә куя. Ашкынып яшәүче Мөзәкир тормыштан бизә, олылар дөньясына тик нәфрәт белән генә карый. Алты яшьлек Айдар исә «Өлкәннәр һаман алдыйлар» дип кабатлый һәм, монда рәхимсезлек турында уйланырга мөмкинлек бик зур. Идрис журналист кына түгел, Айдар кебек тере ятимнәрнең, риясыз сабыйларның бәхете өчен көрәшүче интеллектуаль зат, хәзерге заман яшьләренең омтылышлы натурасы, хисләргә бай герой булып хәтердә кала.

Язучының Бибинур образын («Җомга көн, кич белән...», 1982) озак эзләнүләрнең уңышлы нәтиҗәсе дип карарга кирәк тә. Бибинур – гади хезмәт кешесе, сәнгатьчә төгәллеккә җиткән гуманистик образ. Геройның бөтен тормыш юлы – сабый һәм үсмер еллары, яшьлек юмартлыгы һәм толлык газаплары тулысынча кичереш агышы булып сурәтләнә. Автор чынбарлыкка персонажның рухи дөньясы аша карый, ул яшәешне чагылдыра торган телескоп ролен үти. Герой үзенең күңел дөньясында башка персонажлар белән диалог кора, кирәксә бәхәсләшә, билгеле бер күренешләргә бәя бирә, нәтиҗәләр ясый. Объектив вакыт әсәрдә зур түгел – бер атна тирәсе генә. Бөтен булган фаҗига – җомга көн, кич белән... Үзе тәрбияләгән өч ятимнән рәнҗетелгән шикелле, Бибинур үзендә икмәк ашаган Карабайдан да талана. Балаларын хурлыктан коткару өчен талпынуы да аның үлеме белән бетә. Авторның мондый персонажлар арасында үткәргән параллельләре юкка гына түгел. Бу кадәр рәхимсезлек алдында Бибинурның кешелекле табигате зураеп күренә, бала җанлы карчыкның мәшәкатьле тормышы ихтирам гына түгел, кызгану, әрнү хисләрен дә көчәйтә. Аяз Гыйләҗевнең осталыгы геройның эчке дөньясында икенче, өченче нәфислек дөньясын төзүдән гыйбарәт. Ягъни ул геройның фикер, хис катламнарын төрле агышта табигый сурәтләүгә корып җибәрә ала. Бибинур үз эчендә катлы-катлы хис дөньясына күмелә: Ул – өч ятимгә, Хәтимәгә, Сабирга һәм төпчеге Нәҗипкә булган эчкерсез мәхәббәте, аларга карата үзенең генә үпкә-сагышлары, рәнҗү-борчулары белән кала. Бу очракта геройның эчке дөньясы һаман тирәнәя, ниһаять, каршылыклы диалог өлгерә. Балалар өчесе дә хәрәкәт сферасында күренми, алар тик карчыкның уйларында гына укучыга барып ирешә. Ана белән балалар арасындагы мөнәсәбәт һәр предмет, һәр деталь ярдәмендә ачыла.

Әдәби геройларны сурәтләүдә тагын язучының осталыгы итеп кыскалыкка ирешүен әйтергә кирәк. Кыскалык – осталыкның үрнәге. Автор геройны я кыска гына характерланган бер өзектә, я бер деталь белән, яки геройның индивидуаль сөйләме аша сурәтләп, аның иң мөһим сыйфатларын күз алдына китерүгә ярдәм итә. Лейтенант Хөсәен («Берәү» повесте) фронттан кайткач авыл кызына өйләнә. Монда портрет детальләре мул сибелгән. Деталь бербөтенне күз алдына китерү өчен нинди әһәмиятле роль башкара. Фәрихәнең тышкы кыяфәте егетнең элекке сөйгәне нәфис кыз Сания белән чагыштырып характерлау өчен бик кирәк. Моңлы җыры белән күңелгә кереп калган Санияне өзелеп сөйсә дә, егет, нигәдер, тәбәнәк Фәрихәне үзенә яр иткән.

«Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» исемле әсәрендә язучы бер-берсенә капма-каршы ике геройны истә калырлык итеп бик төгәл күрсәтүгә ирешә.

Биктимер бу өзектә юмор аралаш характерлана, хатын-кыз эшенә тыгылганга күрә, аны «бичара катынша» дип тә йөртәләр, әмма халык бу «юаш кеше»не кызганып сөйли,

шуларның барысы өстенә «катынша Биктимер» — фронтта кыю җанлы көрәшче дә, Мәүлихага бөтенләй контраст образ. Мәүлиха – Биктимернең хатыны. Ул җыелыш саен сөйләмичә калмый, телчән хатын булып истә кала. Бу өзектә бөтенләе белән Мәүлиха үзе. Шуның өстәвенә аны тагын бер деталь ныграк ачып бирә, ире кан коеп алган «Батырлык өчен» медаленә «жалуния» алып ятарга чамалый. Әсәрнең исемендә үк әйтелгән нәфрәт сүзе шушы Мәүлихага ук барып бәрелә бит.

Аяз Гыйләҗев әсәрләреннән күңелдә моң кала, эзләнү һәм өмет чаткылары уяна, еш кына аларда сагыш эченнән туып килә торган яктылыкны күрәсең. Тартышка, бәрелешкә корылган тормышның бай күренешенә юлыгасың. 1971 елда басылып чыккан «Кызлар хатлары» повесте язучының төрледән-төрле характерлары белән бик җәлеп итүчән. Шунлыктан ул, еллар үткән саен, укучының яратып укыла торган әсәре булуында дәвам итә. Раушания – үз күңел дөньясына күмелеп яшәүче кыз – повестьның төп героинясы. Яшьлек кыз өчен гамьсез хыял дөньясы гына түгел, бәлки аның да уйландыра, борчый торган яклары бар икән. Кызның шик-шөбһәләре, яшьлек әрнүләре - тормыш үзе куйган сораулар. Өреккән болан баласыдай, ул чынбарлыкка сагаеп карый, һәрбер хаттан аерым шәхесне күрергә тели. Менә ничек күз алдына килә Лариса: эстрада кызның яраткан өлкәсе, шуның өстенә ул чит ил артистлары эшчәнлеге белән дә мавыгучан, спорт секциясе дә аныкы. Тик әдәбият түгәрәгенә вакыты юк, әмма барысына өлгерүне максат итеп куймый икән. Сабыр табигатьле Лариса Раушаниягә салкын булып тоелса, Курган кызы Лена кайнап торган табигате, ашкынучан характеры белән хәйран итә. Аның яшьлеге абыну-сөртенүләр белән тулы. Ялгышуының сәбәпләре кызның хатында беркадәр ачылгандай була булуын, ул һәркемне уйландырырлык үзе бер гыйбрәтле хәл. Әлбәттә, һәр геройның язмышы төрле ассоциация тудыра. Ник? Нигә? сораулары ирексездән күңелне кытыклап тора. Бибинур, Мөзәкир һәм тагын төрледән-төрле кызлар язмышы нәкъ менә укучыда каршылыклы диалог төзүгә китерә. Бу уңайдан шуны әйтергә кирәк, һәр язучы үзенә якын проблеманы ала, аны үзенең иҗтимагый тәҗрибәсеннән чыгып анализлап бирә, фикер тудыра һәм билгеле бер нәтиҗәгә килә. Әмма язучының уйланулары һәр җәһәттә дә катгый була алмый. Ул эчке диалогларны тәмамламый да калдыра, үзен борчыган мәсьәләне укучы хөкеменә куя, нәтиҗәдә бу хәл төрле ассоциация тудыру өчен фикер дәвамы булып кала.

Гыйләҗев үз әсәрләрендә кеше язмышы мәсьәләсенә кагыла. Кеше язмышы үзенең билгесезлеге белән катлаулы һәм шуңа күрә әсәрдә ихлас кызыксыну уята. Язучы безнең игътибарны нәкъ шундый язмышларга юнәлтә, уйлар кочагына ташлый. Аның «Язгы кәрваннар» (1974) повестенда Әдилә, Ибраһим, Дамир ятим балалыктан яңа гына чыгып килүче илленче еллар яшьләре, сугышны кичергән үсмерләр булып истә кала. Әдиләнең караңгы төн эченнән ишетелгән җыры күңелгә үтеп керә. Өч ятимне багучы бу моңлы кызга битараф калып булмый. Аның белән киләчәктә ни булыр? Ул да, Бибинур кебек, яшьлеген ятимнәргә биреп, үзе ярык тагаракта калмасмы? Әмма шунысы бәхәссез, яшьлек, сугыш китергән яраларга карамастан, үзенә яшәү дәрте даулый, яшәүгә омтыла. Киләчәк көннәргә ышанып карауда яшьлек оптимизмы чагыла. Бу яшьләр, чабата белән кар суын ерып, 30-40 километрдан чәчү орлыгы ташый икән, ул орлыклар халыкның таянычы һәм киләчәк өмете булып шыта.

Гыйләҗев иҗатында сугыш темасы да чагылмый калмый. Сугыш чорына туры килгән яшьлекнең сагышы һәм моңы да, дәртле җилкенүе дә «Язгы кәрваннар» әсәрендә реаль сурәтләнә. Ул язмышлар уртаклыгы белән язучының «Дүртәү» повестена аваздаш.

Һәр ике әсәр сугыш аркасында иртә чыныккан яшьлекне чагылдыруы белән бер-берсенә бик якын.

Аяз Гыйләҗевнең әдәби тәҗрибәсе хезмәт кешеләренең сәнгатьчә эшләнгән типлары белән байый бара. Хезмәтнең ямен, тәмен тойдырырлык итеп сурәтләүдә язучының халыкчан фикерләве, иҗтимагый карашларының шактый тирән булуы сизелә. Хәйретдин - нәкъ шундый халыкчан характер. Ул – «Өтәч менгән читәнгә» (1982) повестеның герое, үзенең уңганлыгы, эчке җылылыгы белән яраттыра. Ул үзенең килеш-торышы, тормыш тәҗрибәсенең муллыгы, гадәт-холкының күркәмлеге белән халыкның яшәү образын, аның гасырлар буе тупланып килгән матур сыйфатларын хәтергә төшерә. Язучының чынбарлыкка уйлы мөнәсәбәтен күрсәтү ягыннан Хәйретдин, Бибинур, Нурлыгаян, Идрис образларының идея-эстетик кыйммәте зур. Алар төрледән-төрле характер геройлары булулары белән кызыклы һәм, шуның белән бергә, тормышның күпьяклы хәрәкәтен сиздереп торучы реалистик типлар. Хәйретдин, Бибинурлар янында Мирфатих белән Сәлахетдиннең гарип сыйфатлары бигрәк тә шыксыз булып күренә. Сәләхетдин һәм Мирфатих образлары күбрәк хикәяләү юлы белән ачыла.

Аяз Гыйләҗевнең дә образ-характер иҗат итүе аерым тоткарлыклар, эзләнүләр белән бара. Автор эзләнүенең бер үрнәген Әскәр Моратов образында күрергә мөмкин. Ул – «Мең чакрым юл» (1978) романының үзәк герое. Димәк, зур эпик жанрның героен сурәтләү язучының иҗтимагый колачын, фәлсәфи тирәнлекне, психологик нечкәлекне таләп итә. Әскәр - кызыклы уйланылган персонаж. Фән өлкәсендә карьерист, әхлакый сыйфаты белән бозык, рухи дөньясы белән ярлы булган Моратов укучы нәфрәтеннән читтә калмый, аның һәр адымы, хәрәкәт сферасы, уй-кичерешләре укучы анализына күчә, әмма геройның конфликттан читләшкән саен рухи бөтенлеге һәм дөньяга карашлары да тоныкланып кала. Аның бөтен эш-фигылен, эчке һәм тышкы хәрәкәтен тасвирлау автор иркенә күчү сәбәпле, геройның үз логикасы югала, тормышчанлыгы бетә. Язучының әдәби практикасы өчен мондый эзләнүләрнең әһәмияте бар-барын. Тормышчан чынлыкка, сәнгатьчә бөтенлеккә ирешүдә әдәби геройлар дөньясы һәрчак диярлек язучы иҗатының үзәген тәшкил итә. Әсәрдәге бөтен күренеш һәм хәлләр, аерым детальләр кеше образын ачуга юнәлгән. Автор табигатьне чиксез киңлекләре белән иңләүгә бармый, киресенчә, ул табигатьнең аерым кисәген, аерым детальләрен генә алып, геройның күңел дөньясын, уй-хисләр агышын җыйнап бирүгә ирешә. Табигать авылга гына хас күренеше белән геройның уй- хисләрендә укучыга җитә. Бередә эстетик сиземләү белән бергә, танып белүгә басым ясала. Гөлбикәне шушындый авыл табигатеннән башка күз алдына китерүе кыен булыр иде, чөнки Гөлбикә – үзе авыл кешесе, ул авылның яшәеше, авылның табигате белән генә бербөтен образ булып күз алдына килә. Кеше белән табигатьнең гармониясе бик матур тәэсир калдыра. Кеше натурасының оптимизмын, актылыкка омтылышын язучы табигатькә мөнәсәбәт аша тулырак һәм колоритлырак ачуга ирешә.

Аяз Гыйләҗев – татар прозасында бай психологик типлар иҗат итә алган язучы. Аның эчке диалогка корылган әдәби геройлары һәрвакыт укучыны уйлануларга, рухи кичерешләргә этәрә. Язучы әсәрләрендәге төрле язмышлар яшәү мәгънәсен, тормышның каршылыкларга бай үсешен, чынбарлыкның киеренке хәрәкәтен аңларга ярдәм итә.

Гаскәрова Ләйсән Минифәвис кызы,
икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Тема:А.Гыйләҗевнең “Матур” хикәясе**

Дәреснең технологик картасы

| | |
|---|---|
| Дәрес темасы | А.Гыйләҗевнең “Матур” хикәясе |
| Дәрес тибы | Яңа теманы өйрәнү, беренчел ныгыту дәресе |
| Максат | **Дидактик:** А.Гыйләҗевнең “Матур” хикәясенең эчтәлеге белән танышу;<br>**Үстерешле:** материалны үзләштерү өчен уңай шартлар тудыру; парларда , төркемнәрдә эшләүне камилләштерү.<br>**Тәрбияви:** -Укучылар арасындагы үзара мөнәсәбәтләрдә дуслыкның иң мөһим сыйфатларның берсе булуына ышаныч тәрбияләү; |
| Планлаштырылган нәтиҗәләр | *Предмет буенча нәтиҗәләр :*дуслык, дусларча мөнәсәбәт төшенчәләрен аңлау, дусларга яхшы ярдәмчел мөнәсәбәттә булу. |
| | *Метапредмет нәтиҗәләре:*<br>*РУУГ :*уку мәсьәләсен кабул итү, планлаштыру, истә калдыру; акыл эшчәнлеген көчәйтү; уку эшчәнлеген бәяләү;<br>ТБУУГ: китап белән эшли белү, кирәкле мәгълүматны таба, гомумиләштерә белү, төшенчәләрне чагыштыра, анализлый белү;<br>КУУГ: күршең белән хезмәттәшлек итү,бердәм эшчәнлектә уртак кызыксынулар табып, уртак фикергә килү. |
| | *ШУУГ*: үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру, дәрестә үз фикереңне башкаларга җиткерә белү; |
| Эш методлары һәм алымнары | фронталь, индивидуаль. |
| Төп төшенчәләр: | Дуслык,ярдәмчеллек, бердәмлек, тырышлык |
| Чыганаклар: | А.Гыйләҗев “Матур” хикәясе, б.11-15 |

| Дәреснең этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| **1. Оештыру.** | **-Уңай психологик халәт тудыру**<br>**Хәерле көн, ...**<br>**Хәерле көн, ...**<br>**Хәерле көн, ...**<br>**Хәерле көн,...**<br>**Хәерле көн, ...**<br>**Хәерле көн, ...**<br>**Менә шундый изге теләкләр белән дәресебезне башлыйбыз.** | <br>**алсу таңнарга!**<br>**сайрар кошларга!**<br>**зәңгәр күкләргә!**<br>**якын дусларга!**<br>**матур кызларга!**<br>**батыр малайларга!** |
| 2. Актуальләштерү. Теманы ачыклау | (Уку мәсьәләсен кую). Бик биек тауда көтүче яшәгән. Бервакыт яңгырлы бер төндә өч кеше аның ишеген шакыган. - Минем өем бик бәләкәй, берегез генә керегез. Сез кемнәр соң? – дип сораган көтүче. - Без, Дуслык, Бәхет, Байлык. Иң башлап кайсыбыз керүен үзең хәл ит. - Укучылар сез ничек уйлыйсыз? Көтүче кемне кертер?<br>Ни өчен?<br><br>-Дуслык – дөньядагы иң кирәкле мөнәсәбәтләрнең берсе. Дуслары булган | -Дуслыкны<br>-Чөнки дуслык керү белән өйгә бәхет тулган, байлык килгән.<br>Балаларның фикерләрен тыңлау |

| | | |
|---|---|---|
| | кешеләр генә бәхетле буладыр, минемчә. Ә сезнеңчә ничек икән? Сезнең фикерләрегезне ишетеп китәсе килә.<br>-Әйтегез әле, балалар, кем ул дус?<br><br>-Дуслык сүзе аңлатмалы сүзлектә ничек бирелә икән? Әйдәгез карап китик әле?<br><br><br>-Ә сезнең дусларыгыз бармы?<br>-Әйе, балалар, һәркемнең дә дусты булырга тиеш, шулай булганда гына яшәве күңелле, рәхәт була. Дуслык – ул бик кыйммәтле язмыш бүләге. Дуслык безгә укырга, эшләргә, яшәргә ярдәм итә. Ул безне әйбәтрәк, яхшырак, көчлерәк итә. Кешегә дусларсыз яшәү мөмкин түгел. Дустың булу – зур байлык.<br>-Дуслык турында бик күп әкиятләрдә, хикәя-шигырьләрдә дә языла. Әйдәгез, искә төшереп китик әле, сез дуслык турында нинди әсәрләр беләсез?<br>Проблемалы сорау бирәм.<br>-Сез тагын да дуслык турында яңа әсәрләр белән танышырга телисезме?<br>А.Гыйләҗевнең “Матур” хикәясен укыганыгыз бармы?<br>Дәрескә нинди максатлар куябыз | <br><br><br><br>-ярдәм итүче, бергә уйнаучы, дәрес әзерләргә булышучы,...<br>Дуслык – ихтыяҗларның, карашларның, фикерләрнең уртаклыгына үзара рухи якынлык, бер-береңне ихтирам итү һ.б. ш. нигезләнгән мөнәсәбәт (97 бит)<br>- бар<br><br><br><br><br><br><br><br><br>-“Чукмар белән Тукмар”,<br>Х.Халиков “Мыекбай”<br><br><br><br>- телибез<br><br>юк<br>-А.Гыйләҗевнең “Матур” хикәясен укыйбыз;<br>- яңа сүзләр белән танышабыз;<br>-хикәянең төп геройларын табабыз, аларга характеристика бирәбез;<br>- хикәянең нәрсә турында булуын ачыклыйбыз; |
| 3.Яңа материалны аңлату (уку мәсьәләсен өлешләп чишү) | А.Гыйләҗевнең “Матур” хикәясен уку<br>**Сүзлек өстендә эш**. Аңлашылмаган сүзләрне кайдан табарга була?<br>-авызын турсайтып<br>-чуар яулык<br>-гарьлек<br>-мәзәк<br>-йөдәтеп бетте<br>- болдыр<br><br>А.Гыйләҗевнең “Матур” хикәясен укытучы укый<br><br><br>Сорауларга җавап бирү<br>Сезнеңчә, хикәянең төп геройлары кемнәр?<br><br>Разыя нинди кыз? | Яңа сүзләр белән танышалар<br>Аңлатмалы сүзлекләрдән, тәрҗемә сүзлекләреннән, укытучы аркылы, интернеттан.<br><br><br><br><br><br><br><br>укучылар тыңлыйлар<br>А.Гыйләҗевнең “Матур” хикәясен укучылар чылбыр буенча укыйлар<br><br><br>Искәндәр, Разыя , Разыяның әнисе, Галия, Искәндәрнең әбисе, Матур<br>Акыллы, ярдәмчел, тәрбияле кыз<br>Тәртипсез, саран кыз |

| | | |
|---|---|---|
| | Галия нинди кыз?<br><br>Хикәянең төп темасы нинди ?<br>Кемнәр арасында дуслыкны күрәсез?<br>Аларның дуслыгын нәрсәдә күрергә була?<br><br>-Әйе, дөрес.Искәндәр белән Галия чын дуслар.<br>-Әйе, сез бик дөрес фикер йөртәсез.Булдырдыгыз!<br><br>-Укучылар, сез бу хикәяне өлешләргә бүлеп, һәр өлешкә исем куеп карый аласызмы? Парларда эшлибез.<br><br>Хикәяне өлешләргә бүлеп , исемнәр куйганда авырлыклар тудымы?<br>-Сез ничек уйлыйсыз, ни өчен сезнең алда кыенлыклар туды?<br>-Ә кемгә бирем буенча кыенлыклар тумады?<br>Булдырдыгыз, укучылар! | Дуслык турында.<br>Искәндәр белән Разыя арасында.<br>Разыяга Искәндәрсез урамда уйнавы бик күңелсез.Авырып киткән иптәшен күрәсе,аны өчпочмак белән сыйлыйсы, хәлен беләсе, сөйләшәсе килә. Алар- чын дуслар.<br><br>-Разыя урамга чыгып китте.<br>-Разыя урамда Галияне очратты.<br>-Разыя Искәндәрләр тәрәзәсе янында.<br>-Разыя бүрәнә башына менә башлады.<br>- Искәндәрнең әбисе калтырый башлаган Разыяны җиргә төшереп бастырды.<br>- Матур һәм өчпочмак.<br>-Разыяның үксеп елавы.<br>-Искәндәрнең әбисе Разыяны өчпочмак белән сыйлый.<br><br>Укучылар үз фикерләрен әйтәләр<br>Әйе ( юк) |
| Белемнәрне беренчел ныгыту | -Әйтегез әле, сез, дәрестә алган яңа белемне кайда куллана аласыз? Безгә бу тема бик кирәкме?<br><br>- Укучылар, сез, бу хикәяне дәвам итә алыр идегезме?<br><br>- Төркемнәрдә эшлибез. Һәр төркем хикәяне дәвам итеп карый һәм үзенең хикәясен укып күрсәтәчәк | Тормышта, чын дус булып калу өчен кирәк.<br><br>Әйе, дәвам итә алыр идек.<br><br>Төркемнәрдә эшлиләр |
| Ял минуты | “Түбәтәй” уены. | ял итәләр |
| Белемнәрне гомумиләштерү | -Дуслык турында татар халкы үз фикерен мәкальләр<br>аша бик үтемле итеп җиткерә. Ә сез аларны беләсезме икән? Тикшереп карыйк әле? Мин сезгә мәкальләрнең башын әйтәм, ә сезгә дәвам итеп бетерергә кирәк:<br>-Кош канаты белән, ...<br>-Дустың булмаса – эзлә, тапсаң - ...<br>-Иптәшең үзеңнән ...<br>-100 сум акчаң булганчы, ... | <br><br><br><br><br><br><br>-кеше дуслары белән көчле<br>-югалтма<br>-яхшырак булсын<br>-100 дустың булсын |

| | | |
|---|---|---|
| | -Дуслыкның нинди төрләрен беләсез?<br><br>- Төрле миллә кешеләре үзара дус була аламы?<br>-Әйе,укучылар, халыклар дуслыгы Татарстанның иң зур байлыгы.Безнең Татарстанда 115 милләт яши. Сан буенча 1нче урында – татарлар,2нче урында руслар, 3нче урында чувашлар. Бу милләтләр узара дус һәм тату яшиләр. | -Кызлар дуслыгы, малайлар дуслыгы, халыклар дуслыгы, туганнар дуслыгы, профессиональ дуслык, табигать белән дуслык, китап белән дуслык һ.б.<br><br>-Әйе |
| Уку эшчәнлеге буенча рефлексия. | - Без бүген дәрестә нинди яңа белем үзләштердек?<br>- Без дәрескә куйган максатыбызга ирештекме?<br>- Безнең кыенлык нәрсәдә иде?<br><br>- Сез бу хикәя буенча үзегезгә берәр файдалы киңәш ала алдыгызмы? | Аяз Гыйләҗевнең ”Матур” хикәясе белән таныштык<br>Әйе, без үзебез куйган максатларга ирештек.<br>А.Гыйләҗевнең “Матур” хикәясе турында бернәрсәдә белми идек.<br>Әйе, без бу хикәя аркылы чын дуслыкның кадерен белергә кирәклеген белдек<br>Дустыңны бәладә ташлап калдырма.<br>Дустыңа һәр нәрсәдә булыш.<br>Дуслыкка таләпчән бул. |
| Өй эше. | 1.Мәҗбүри.Тексны укырга. 11-15 нче битләр. 2.Хикәя язарга”Чын дустым”<br>3.Иң ошаган өлешенә рәсем ясарга.<br>Үзбәя. Билгеләр куйдыру. Һәр укучы үзенә билге куя. | Өй эшен язу<br><br>Билгеләр куялар |
| Йомгаклау. | Укучылар, сез барыгызда бик актив булдыгыз, дәрестә катнашып утырдыгыз. Сез барыгыз да булдырдыгыз! Дәрес өчен бик зур рәхмәт. Сау булыгыз! | Сау булыгыз |

Умнова Лилия Иван кызы,
Мәләкәс урта мәктәбе, Тукай районы

**Метапредмет дәрес. А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» әсәренә мифопоэтик анализ**

Аннотация.

Бу дәрес 11 класста А. Гыйләҗев иҗатын өйрәнгәндә бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе кысаларында үткәрелә. Әдәби әсәр белән укучылар өйдә таныша.

Әдәбиятны метапредмет технологиясе белән укыту баланың дөньяны кузаллавын формалаштыра. Нинди кыйммәтләрне сайларга. Кемгә ышанырга – боларның барысы алдында югалып кала. Әсәр зенчәлекләрен традицион анализлау гына әлеге проблемаларны чишми. Метапредмет технология ярдәмендә укучы әсәргә анализ

барышында төп төшенчәләрне: ярату, яшәү мәгънәсе, намус төшенчәләрен аерып чыгаралар. Мәсәлән А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» әсәрендә дә укучылар мифопоэтик образлар турында гына сөйләшмиләр, ә барыннан да элек гомумкешелек кыйммәтләрен дә аерып чыгаралар.

Укучы эшчәнлеге аңа белем бирүгә генә нигезләнми, ә алган белемнәрне куллану юлларын күрсәтүгә корыла.

Дәреснең структур элементлары:

- Мобилизацияләүче этап: актив акыл эшчәнлеген кузгата
- Максат кую: укучылар тарафыннан максатны билгеләү: (искә төшерү – яңаны белү – куллана белү (вспомнить – узнать – уметь.)
- Коммуникация.
- Үзара тикшерү һәм рефлексия

Метапредмет дәресләрдә алган белемнәр – универсаль. Алар теория категориясеннән практикага күчәләр. А. Гыйләҗевнең «Өч аршы җир» әсәреннә мифопоэтик анализ ясау барышында предметара бәйләнеш кенә килеп чыкмый, ә балалар яшәеш кануннарына да төшенәләр: туган җир, намус вөҗдан, җаваплылык һ.б. кебек изге әйберләрне детальләп чагыштыралар.

Бу дәресне метапредмет дәресләргә нигезләнеп укытуның максаты – әдәби әсәрне анализ ярдәмендә тикшереп, аның мәгънәсен тулы аңлау сәләте формалаштыру гына түгел, ә баланы уйларга, үз фикерен дәлилләргә өйрәтеп, туган нәтиҗәне үз тормыш тәҗрибәсе итеп алуда да. Аналитик эш ярдәмендә укучыга әдәби әсрне тикшерү юлларын күрсәтү, әдәби әсәр мәгънәсенең чикләрен тоярга ярдәм итү – бүгенге көн таләбе. Дәрес укучыга әдәбият белеменең төп юнәленшләренең берсе – мифопоэтик анализ хакында мәгълүмат бирә һәм әдәби текст белән эшләгәндә бу методны файдалану мөмкинлекләрен күрсәтә.

Китерелгән дәрес ике өлештән тора. Беренче өлештә укучылар теоретик материал белән танышалар. Икенче өлештә беренче өлештәге алгортм нигезендә А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» әсәреннән мифопоэтик моментларны табып, аларны анализлыйлар. Тапкан мифопоэтик катламнарны берләштереп, аларның үзенчәлекләрен ачалар.

Дәрес барышында укучылар анализ-синтез, гомумиләштерү, абстракция алымнарын файдаланалар. Фикерләрен аргументлаштырып, нәтиҗәләр чыгаралар.

Дәрес алгоритмы: 1өлеш – теоретик өлеш. Мифопоэтиканың нигезе һәм архетиплар белән танышу. Мифопоэтик анализ үзенчәлекләре:

- Әсәрдәге мифологик катламны барлау;
- Авторның шәхси күзаллавын ачыклау.

2 нче өлеш – практик өлеш. Мифопоэтик үзенчәлекләрне А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» әсәренә нигезләреп карау.

**1. Әсәрнең сюжет элементларын билгеләү.** Андагы мифопоэтик катламнарны табу;

**2. Автор позициясен ачу**

Йомгак.

**Тема: А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» әсәренә мифопоэтик анализ**

Бу дәрес 11 класста, А. Гыйләҗев иҗатын өйрәнгәндә, бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе кысаларында үткәрелә. Әдәби әсәр белән укучылар өйдә таныша.

**Дәреснең максаты:** Сөйләм теле компетенциясен формалаштыру

1 **Танып белү эшчәнлеге:** әсәр өстендә эшләргә өйрәтү; мифопоэтик анализ үзенчәлекләрен аңлату; төп төшенчәләр: архетип, мифопоэтик катлам, хронотоп; лексик сүз байлыгын арттыру.

2 **Практик әһәмияте:** укучыларга әсәрнең яшерен катламнарын таптыру; әсәрнең структурасын күрсәтү; әсәргә мифопоэтик анализ ясарга өйрәтү.

**Предмет өсте белемнәрен формалаштыру:**

Информацион: мифопоэтик анализга нигез салучыларны белдерү. Бу төр анализ үзенчәлекләрен әсәр анализында кулланырга өйрәтү;А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» әсәренә мифопоэтик анализ ясату.

Коммуникатив:А.Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» әсәренә мифопоэтик анализ ясау; игътибарларын һәм логик фикерләүләрен үстерү, чагыштыру алымына һәм нәтиҗә чыгарырга өйрәтү, үз фикерләрен дәлилләргә нигезләп әйтергә өйрәтү; янәшәдәгеләрне тыңларга һәм ишетергә күнектерү.

Социаль компетенцияләр: коллективта эшләргә өйрәтү, эш нәтиҗәсен алдан күзаллап, хаталарны адекват кабул итәргә, нәтиҗәләр чыгара белергә өйрәтү.

**3.Тәрбияви максат:** Тарих җилләренең кай якка исүенә карамастан, туган җирнең изге төшенчә икәнлеген төшендерү; җаваплылык хисе тәрбияләү.

**Җиһаз**: DVD проектор, интерактив такта. Дәрес барышында презентация рәвешендә слайдлар күрсәтелә

**Дәрес барышы.**

Уңай психологик халәт тудыру

Элек-электән үк борынгы бабаларыбыз балаларын яхшы гамәлләр генә кыларга, өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәткән. Алар бер-берсенә күңел җылысын кызганмыйча, үзара ярдәмләшеп, тату гомер иткәннәр. Әйдәгез әле, без дә бер-берегезгә күңел җылысы – елмаю бүләк итик.

Укучылар, без бүгенге дәрестә, А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир » әсәренә таянып, мифопоэтик анализ үзенчәлекләрен карарбыз.

**1. Мобилизацияләүче этап: актив акыл эшчәнлеген кузгата.**

Әдәби әсәргә һәр укучының үз шәхси- субъектив карашы туу табигый. Һәр әсәрне укыгач, анализ ярдәмендә тикшерү бурычы куела.

Әдәбият фәне үсеше дәвамында төрле гыйльми юнәлешләр һәм мәктәпләр барлыкка килгән, алар әдәбиятны һәм әдәби әсәрне билгеле бер теоретик караш ноктасыннан тикшергәннәр. Әлеге әдәби әсәр анализы алымнарыннан без мифопоэтик анализ методына тукталырбыз.

Сез дәрестә түбәндәгеләрне истә калдырырга тиеш:

1. Нәрсә ул мифопоэтика, хронотоп, архетип.
2. А. Гыйләҗевнең «Өч аршын » әсәрендәге мифопоэтик чараларны билгеләргә.
3. Мифопоэтик чаралар аша авторның шәхси күзаллавын табарга.
4. Автор кузаллавын үзегезнеке белән чагыштырырга.

Көнбатыш әдәбият белемендә 20 гасырның икенче яртысында формалашкан фәнни юнәлешнең – мифопоэтиканың нигезендә әһәмиятле күренеш дип мифны санау ята. Алман романтиклары хезмәтләрендә миф уйлап табылган әкият кенә түгел, ә борынгы кешенең тормышка бөтенлекле карашын белдерә.

Россиядә мифологик мәктәп барлыкка килү һәм үсү татар фольклорын өйрәнүгә уңай йогынты ясый. Ш. Мәрҗәнинең татар риваятьләренә игътибар итүе мәгълүм. Шулай ук бу эштә К. Насыйри да активлык күрсәтә.

Аерым алганда мифопоэтиканың, теоретик нигезен К.Г. Юнгның архетиплар теориясе тәшкил итә.

- архетиплар- әдәбиятта кабатланып торучы образлар. Галимнәр фикеренчә, мондый образлар борынгы кешеләрнең психологик тәҗрибәсе нәтиҗәсе булган кеше моделен тергезәләр.

Архетип образлар белән без тагын кайсы язучылар иҗатында очраштык? (Н. Гыйматдинова «Ак торна каргышы» – Сара, «Сәвилә» – Сәвилә, «Китәм димә» – Камилла, «Каракош»; Зифа Кадырова «Сагынырсың мин булмам» – Сөмбел, «Язмыш сынавы» – Әлфия, «Көтеп узган гомер»; Фоат Садриев «Таң җиле» –Нуриәсма; Һ Такташ «Җир уллары», «Газраиллар»; Михаил Булгаков «Мастер и Маргарита»; Куприн «Олеся», «Гранатовый браслет» һ.б.)

**2. Максат кую – укучылар тарафыннан максатны билгеләү: (искә төшерү- яңаны белү- куллана белү (вспомнить – узнать – уметь)**

Хәзер без сезнең белән дәресебезнең максатын билгеләп китик әле. Без бу дәрестә А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» әсәренең мифопоэтик катламнарын барлап чыккач, нәтиҗәне тормыш тәҗрибәсе итеп алырга тиеш.

Мифопоэтика әсәрдәге мифологик катламны барлый. Бу катламнар автор ихтыярыннан башка хасил була һәм әсәрне шәхси, социаль- типик, эпохаль чикләрдән алып чыга.

Мифопоэтик анализ әсәрдәге мифологик катламны барлый, авторның шәхси күзаллавын, кеше аңының универсаль, һәрчак хәрәкәттәге үзенчәлекләрен беренче планга чыгуын ачыклый. Мифопоэтик анализ барышында хронотоп мөһим.

Хронотоп – (грек. Chronos-вакыт, topos-урын) - урын һәм вакыт бергәлеге.

Дәреснең 1нче өлешен йомгаклап үтик:

**1. Мифопоэтик анализга кем нигез сала?(** К. Юнг сала).

**2 . Мифопоэтик анализ барышында төп момент? (**Мөһим момент - миф, аның **нигезендә архетиплар хронотоп һәм символлар ята).**

Димәк, мифопоэтик анализ вакытында без төп игътибарны нәрсәгә юнәлтергә тиеш? (Хронотоп, архетиплар, пейзаж һәм тылсым аша әсәрнең төп идеясенә килү).

Хронотопны (дөньяның урын-вакыт образын) нәрсәләр барлыкка китерә соң?

1.Сюжет – вакыйгалар агышы; 2. Кертелгән эпизодлар – вакыйгага бәйле искә төшерелгән хәлләр; 3. Вакыт һәм урын тәңгәллеге; 4. Пейзаж – геройны әйләндереп алган физик дөнья чагылышы; 5.Мифопоэтик образлар; 6. Эчке мәгънә.

**3. Коммуникация.**

Дәреснең 2 нче өлеше

А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» әсәренә мифопоэтик анализ

**I. Әсәр язылуга алшартларны барлап чыгу:**

а) А. Гыйләҗевнең үзенең дә сталинизм чорында рухи кимсетүләр кичерүе;

б) Тарихта кулаклар дип аталган халык катламының байлыгын тартып алу вакыйгалары;

в) Шәхеснең физик һәм әхлак ягыннан мәсхәрләнүе.

- Әсәр парадокслыкка корылган. (Парадокслык – А. Гыйләҗев иҗатына хас нәрсә – кеше күз алдына китерә алмаслык хәлләр).

- Повестьның сюжет нигезен нәрсә тәшкил итә? (Сюжет нигезен әйләнеп кайту ситуациясе хасил итә. Ике көн эчендә барган вакыйгалар поездда туган якларына кайтып килүче хатынның хәле начарлану, аны станциядә төшереп калдыру, хатынның больницада

вафат булуы һәм, аның васыятен үтәп, ирнең мәетне туган авылына кайтарып җирләве кебек бара).
- Повестьның сюжеты гадәтиме? (Юк).
- Ни өчен? (Әсәрдә төп сюжет сызыгы бу түгел. Төп сызык искә төшерү рәвешендә үткәнгә , яшьлегендә тарихи вакыйгалар аркасында хата ясаган кешенең хатасын тануы – үзгәрүе – гафу соравы –тәүбә итеп, яңа тормыш башлавы төсен ала. Әмма геройның дөрес юлга басуы хатыны – Шәмсегаянның тормышы хисабыннан була. (Бер укучы Мирвәлинең үткәне турында сөйли)

Әсәрнең сюжет элементларын билгеләү. (Төенләнеш: Авыр хәлдәге Шәмсегаян ире белән бергә поезддан төшеп, ат арбасында больницага юнәләләр. Озак та үтми, Шәмсегаян үлә. Вакыйгалар үстерелеше: арбада кайткандагы сөйләшү, узган гомер. Кульминацион нокта: Мирвәли өч аршын җир сорый. Чишелеш: авылдашларының ризалыгы. Кадерле ул туган җир).
- Вакыйгалар кайда бара? (Юл мотивы тирәсендә җыела. Мирвәли Шәмсегаянның васыятен үтәр өчен 58 км юл уза).
- Хикәяләү ничек бара? (Бу өлештә хикәяләү геройның эчке монологы төсендә бирелә. Ул үткәннәрне хәтергә төшерү, бәяләү кебек үрелеп бара).
- Кайсы күбрәк? Автор бу турыда ни ди? (136 бит) (58 чакрымны, шәп барганда, бер төндә үтеп булыр….

58 чакрым… Менә шулай артыңа борылып карамыйча да башыңны күтәрмичә дә үтеп була инде аны. ..

58 ел, нигә, Мирвәли 58 еллык гомерен дә артына борылып карамыйча үткәрә алды ич. Нигә борылып карамады икән ул. 58 тулуын да нигә менә шушы япан кырда исенә төшерде. Нигә борылып карарга курка? Кем сагалый аны? Кайдан башланды бу курку?)
- Мирвәли нидән курка? (Ул үткәненнән курка).
- Ә ни өчен курка? (Кемдер алдында гына түгел, вөҗданы алдында гаебе зур. Чөнки ул 30 ел буе начарлык кына эшләп йөри).
- Автор Мирвәлинең куркуын нинди мифопоэтик мотивлар аша күрсәтә. (Җен-пәриләр мотивы. Әсәрдә берничә урында күренә. (Бу өлешләр укып үтелә). Курку (кайтудан, үз-үзеннән, үткән гомереннән-күләгәсеннән).

... Йөрәк кагып яшим дип үзен-үзе сабыйларча юаткан Мирвәли, артына, гомеренең үзе кичкән ягына борылып карауга куркып, имәнеп китте. Үзе белән беренче тапкыр очрашу куркытты аны! Үткән гомере караңгы әрем сабаклары артына посып торган шөкәтсез өрәк, бүкәй кебек нурсыз, куркыныч, шыксыз булып күренде.
- Әсәрдә кешелеклелек төшенчәсе кайда җыела? (Бу төшенчә күбрәк Мирвәлинең Карачурага кайтып барган вакытта калкып чыга. Ул башкаларга явызлык эшләргә ярамый дигән канун тирәсенә җыела. Малларына зыян салып, Мирвәли кешелеклелек чиген атлап чыга. Шуңа күрә намус хөкемен тоеп яши).
- Мирвәли җырлары нәрсәгә ишарәли?Аларның Мирвәли язмышына ни кагылышы бар? ( Кара гынай урман, караңгы төн…

Яхшы атлар кирәк үтәргә -

Мирвәли тормышына һәм гомумән кеше тормышына, язмышына ишарә ясый, төп идея белән кисешә. Туган җиргә, якыннарыңа нәселеңә таянып, тормыш авырлыкларын, сынауларын кичеп чыгарга була, дип белдерә.

Югалттым мин сәгать чылбырым

Тапмадыңмы, сары былбылым..

Ә икенче җырында Мирвәлинең шәхси хата-югалтуларына ишарә ясый. Бу җыры белән ирнең үзе өчен иң кадерле нәрсәләрен югалтуы, бәхетсез гомер кичерүен тагын бер кат искәртә).

- Мирвәли тормышында байлыкка омтылдымы? (Юк, ул үзе белән санашуларын гына тели. “Аның үзе белән ачыктан-ачык сөйләшергә кирәк дип тә тапмаганнар. Ничек бары да хуҗадан башка хәл иткәннәр. Аның башында усал уйлар кайнады: киңәшмичә, сорашмыйча эшләгәннәр. Кеше түгелме әллә Мирвәли?!)

- Мирвәлигә нәрсә кирәк соң? (Мирвәлигә авылдашлары кичерүе генә түгел, ә үзе алдында йөзе аклану, намусы чистару , үзен-үзе кичерү дә кирәк. Адашы Мирвәли белән сөйләшүдән соң Мирвәли үзенең гаебен аңлый. Автор моны Мирвәли авызыннан: «Гаебе зур Мирвәлинең, моннан китү ул гаепне тагын да зурайту, үстерү генә булачак…», - дип белдерә).

- Ә нинди гаебе бар соң Мирвәлинең, беренче булып аның 11 яшьтән бил бөгеп тапкан мөлкәтен тартып алмакчылар иде. (Укучыларның җаваплары)

- Мирвәли нәрсә алдына куела? (Сайлау алдына куела).

Мифопоэтик традициядә язылган текстларда геройның билгесез, серле көчләргә каршы тору, «китәр юлны» сайлау вакытында тылсым әсәрдә кинәт кенә пәйда була.

Табигать стихиясе. (Җир һәм су, әйтерсең лә, геройга үз күләгәсен җиңәргә ярдәм итәләр. Мирвәли Шәмсегаянның васыятен үтәргә кирәк дигән карарга килә.)

Гафу сорау мотивы – кара яктан котылу буларак кабул ителә. (Гафу сорау, тәүбә итү герой күңелендә булган барлык караңгы, кара яктан котылу кебек аңланыла. Күләгәсен тулысынча җиңү өчен авылдашларының кичерүе кирәк аңа.)

- Менә шушы үтә кырыс кыяфәтле авылдашлары белән аны бәйли торган берәр нәрсә калганмы соң? (Мирвәли башта нигезен күз алдыннан кичерә «Бүген ул үзе туып-үскән нигез янышнан үтеп китте. Нигез буш», авылны, аның үткәнен, нәселен (Монда аның ерак бабалары туган. Авылның нигезен салган Карачура үзе дә аның ерак бабасыдыр әле…. Бу зиратта аның әтисе ята, әнкәсе…) якыннары – кавемдәшләре («Тирә-якта кешеләр нинди күп. Үзара алар нинди якыннар: туганнар, абыйлар, апалар, җизниләр, сңелләр, балдызлар, кодалар, кодачалар, … Я булмаса иптәшләр, кардәшләр, яшьтәшләр, аркадашлар, Нинди җылы җепләр бәйләр бәйли адәми затларны якты дөньяда.»).

- Мирвәли аңындагы изге урыннар? (Нигезе, өч кое, авыл зираты).

- Читләшүнең иң югары ноктасы нидә күренә? (Мирвәлине балалык дусты адашы – Мирвәлинең хөкем итүе очраклы түгел. Ул гади авылдаш кына түгел, ул – Мирвәлинең намусы, вөҗданы. Мирвәли – адашы аңа («Еллар буе кара тир түгеп эшләп берни алмаган чакларыбызда безне кимсетмәделәрме? Әрнемәдекме?.. Тик туган җиребезне каһәрләп мөртәткә әйләнеп чыгып качмадык!»,- дип белдерә).

- Әлеге сөйләшүдә ике караш ноктасы бәрелә. Нинди ул? (Төп геройның караш ноктасы «Өч аршын җир» гыйбарәсенә таяна. Ул кешенең җир тормышы чикләнгәнлеккә, адәм баласы кем генә булмасын, үз гомерендә ни генә кылмасын, соңгы сыеныр урыны җир икәнлеккә ишарә бирә. Илдә нинди генә җилләр иссә дә, кешенең туган җирен каһәрләргә хакы юк икәнлеген белдерә).

- Әсәрдә ачкыч сүз кайда? (Качып яшәп, бер ел үткәч, ирен авылга озатканда, автор Шәмсегаян авызыннан: «Туган җиреңнән олы була алмассың» - дип әйттерә. Һәм бу сүзләр әсәрнең ачкыч сүзе булып тора да инде.

- Без мифопоэтик анализ язучының дөньяны шәхси күзаллавын ассызыклый дидек. Автор кем позициясе нидә соң? Эчке мәгънә нидә күренә? (Авторның герой адашы – Мирвәли позициясендә торуы ачык күренә. Кешенең җир тормышы, эш-гамәлләре аша аның өч аршын җиргә хокукы, бармы-юкмы икәнлеге тәгаенләнә).

- Төп тема? (Яшәү фәлсәфәсе).

- Повестьта төп идея? (Туган җирнең һәр кеше өчен изге урын булуы).

- Төп идея тагын кайда көчле позициягә чыгарыла? (Әсәрнең исемендә. Авылда калырга карар кылган Мирвәли авылдашларыннан өч аршын җир сорый).

- Автор укучыга үз фикерен нинди мифопоэтик образлар аша җиткерә? (Автор укучыга үзенең фикерләрен архетип образлар аша күрсәтә: ата-ана каргышы; күләгә архетибы Мирвәлинең яшерен якларын күрсәтә. Мирвәли Карачурага җиткәнче узган 58 км геройның үз күләгәсе белән көрәшен чагылдыра. Мирвәли эчендә ике як бар. Берсе гаҗәеп ялгызлыгын тоя һәм ялгызлыкның җәза икәнен аңлый. Икенчесе – үч алуны сорый. Шәмсегаян – хатын – татар хатын-кызларының корбанчылык архетибы. Мирвәли – көчле, горур, буйсынмас ир архетибы)

- Ритуальлелек нәрсәдә күренә? (Үткән белән бүгенгенең бер ноктада кисешүе. Шәмсегаянның үлеме герой аңында үзенчәлекле борылыш ясый).

- Моңа бәйле рәвештә вакыт һәм пространство, ягъни хронотоп барлыкка килә. Вакыт һәм пространство бәйләнеше (Хронотоп) кайда күренә?

Больница белән Карачура арасы 58 км; Шәмсегаянга 58 яшь; Мирвәлигә 58 яшь.

Көннәре, минутлары, 58 яшь (ел) – 58 км.;
1 көн – 58 еллык гомерне искә төшерә кайтканда;
30 еллык читтәге гомер – бәгырен өзгәли.

- Юл нәрсә ул? (Юл - кеше гомере ул. (метафорик мәгънә)

- Символика кайда күренә? (Ут символикасы (тәмугъ уты төсендә) – герой туган авылын яндыру теләге белән кайта. Шәл – күңел җылысы символы (Алар авылдан качкан төнне Шәмсегаянның Мирвәлигә шәлен салып бирүе, салкын вокзалда җылы биргән бу шәл әсәрдә күңел җылысына янәшәлек бирелә.) Ак пәрдә (Мирвәли ак пәрдәне ерта….) Дәү наратка, сыенып үскән каен ….)

- Кертелгән эпизодлар – вакыйгага бәйле искә төшерелгән хәлләр? (Әсәр буеннан буена искә төшерү, Мирвәлинең үз эчендә казынуы буларак бара. Геройларның һәрберсе фәлсәфи-психологик бәйләнеш барлыкка китерәләр. Мирвәлинең эчке каршылыгын ачыкларга булышалар).

- Ә Мирвәли Шәмсегаянга тормыш буе бирәр нәрсә бирәме? Аның үткән юлы нәрсәгә тәңгәлләшә? (Геройның пространстводагы хәрәкәтенә, юлына рухи юл тәңгәл килә. Хатасын тануы – үзгәрүе – гафу соравы – тәүбә итеп, яңа тормыш башлавы – әлеге үзгәрешләрне Мирвәлидәге эче каршылык хәрәкәткә китерә: Карачурадагы авылдашларын гаепле санаудан – үзенең хатасын тануга алып килә).

- Финалның төп мотивлары? (Тәүбәгә килү. Гафу итү).

- Сюжет схемасының архетиплыгы нидә чагыла? (Нәтиҗәдә авылдашлары Мирвәлине гафу итә. Мирвәли образы Изге китаплардагы адашкан егет хакындагы сюжет белән тәңгәллегенә ишарә ясый).

**3. Үзара тикшеру һәм рефлексия**

- Әсәрне йомгаклап ни әйтәбез? (А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» әсәре кешегә сикәлтәле сынаулы тормыш юлында туган җир, нәсел, аның тарихы, кавем-кардәшләр кебек гомумкешелек кыйммәтләре генә кешегә дөрес юл күрсәтә ала. Автор кеше

иҗтимагый хәлләргә карап түгел, ә кешелек кануннарына буйсынып яшәргә тиеш дигән фикерне ассызыклый.

- Әсәр сезгә ошадымы, ул бүгенге көндә дә актуальме? Ошаса да, ошамаса да ни өчен? (Ул чорга бүгенге көн күзлегеннән бәя бирергә мөмкинлек бирә. Дөрес яшибезме, уйландыра. Туган җирнең олы икәнлеген төшендерә. Изге төшенчәләрне кадерләргә өйрәтә. һ.б.)

Әдәби әсәрне өйрәнү вакытында бер методны куллану башкаларына мөрәҗәгать итәргә ярамый дигән сүз түгел. Текстны берничә караш ноктасыннан тикшерү аның мәгънәви мөмкинлекләрен ачыклауга, аерым методларның көчле һәм йомшак яклары хакында уйлануга китерә.

Вакыт калса, Ф Яруллинның «Туган ягы кирәк кешегә» шигыре укыла

Өйгә эш бирү һәм билгеләр кую

Умнова Лилия Иван кызы,
Тукай районы Мәләкәс гомуми урта белем бирү мәктәбе

**Сынмаганнар, сыгылмаганнар...**
**(Татар мәктәбенең 8 нче классында А. Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәрен өйрәнү)**

Аннотация

Дәрес эшкәртмәсе ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының сайтында китерелгән үрнәк программага нигезләнеп эшләнде (Төзүче-авторлары: Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова, 2013 ел). Дәреслек - 8 кл. Ганиева Ф. Ә., Рамзаева Ч.Р., 2006, Казан, “Мәгариф” татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 8 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия.

А. Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» әсәре татар мәктәпләре өчен 8 класста үзләштерелә. Программада әлеге әсәр өчен 3 сәгать вакыт бирелә. Бу йомгаклау дәрес.

Дәрес коллектив фикер йөртү технологиясе (технология коллективной мыслительной деятельности – КМД) буенча оештырылды (проблема ситуациясенә кертү – группаларда эш – фикер алышу – рефлексия). Әлеге дәрес әсәрнең мәгънәви эчтәлеген ачып, укучыларга тормыш тәҗрибәсе бирүгә нигезләнә.

Дәрес, ФДББС таләбе буенча, гомуми метадологик дәрес структурасы буенча оештырылды. Үзмаксат (укучыларны мотивацияләү җыр аша башкарылды) – кыенлык (ачкыч сүз) - уку мәсьәләсе (сугыш яшүсмерләре чор авылыкларын нәрсә хисабына җиңгәннәр?) - эш стратегиясе билгеләү - эш барышы (соңыннан эталон буенча тикшерү), мөстәкыйль эш (темпераментларны билгеләү, аларны әсәр геройлары белән бәйләп дәлилләү) - рефлексия (күркәм холык моделе төзү)

ФДББС дәресе буларак: өйрәнелә торган материал баланың тормыш тәҗрибәсе белән бәйләнештә, проблемалы сораулар куела, эзләнү эшчәнлеге: искә төшер, мисал китер, дәлиллә, аңлат форматында бара. Дәрестә укучыларның эешчәнлеге 70%; аралашуның диалогик формасы кулланыла, кеше темпераментлары белән әсәр геройларын бәйләү ярдәмендә стандарт булмаган ситуация тудырыла. Дәрестә балалар индивидуаль һәм группада эшлиләр. Кире бәйләнеш җаваплар һәм эш карталары ярдәмендә башкарыла. Үзбәя һәм үз контроль бәяләү кәгазьләре ярдәмендә дәреснең һәр этабында үтәлә һәм азактан, һәр группа гомуми нәтиҗә чыгарып, аны дәлилли.

Әлеге дәрес барышында укучылар тормышны хисси-эмоциональ тәэсир чаралары ярдәмендә кеше холкы сурәтен, моделен төзү һәм шуңа карата мөнәсәбәт формалаштыру

сәләтенә ия булалар. А. Гыйләҗев фикере аша гомумкешелек кыйммәтләрен, күркәм холыкның мөһимлегенә төшенәләр. Тормышчан проблемаларга әсәрдән аргументлар китереп, үз фикерләрен дәлиллиләр. Кеше темпераментлары белән укучылар хәбардар. (7 нче класс, җәмгыять белеме) Бу дәрестә укучылар кеше темпераментлары аша, геройларны характерлап, үзләренә киләчәккә ориентир билгелиләр.

**Дәреснең максаты:** Коммуникатив һәм танып белү универсаль уку күнекмәләрен булдыру.

**Өйрәтү максаты:** А. Гыйләҗевнең "Язгы кәрваннар" әсәре геройларына характеристиканы кеше темпераментлары аша бирергә өйрәтү; монологик, диалогик сөйләм күнекмәләрен үстертү.

**Белем үстерү максаты:** тормыш тәҗрибәсе бирү, кеше танырга өйрәтү, үз фикерләрен дөрес, матур итеп әйтә белергә өйрәтү.

**Тәрбияви максат:** киләчәк бүгенге яшүсмерләр кулында, шуңа күрә аларда матур холык , эшләгән эшләре өчен җаваплылык хисе һәм бердәмлек тәрбияләү.

**Метапредмет белемнәр-** темперамент, текст һәм модель белән эш.

**Көтелгән нәтиҗә: УУГ-универсаль уку гамәлләре**

**Шәхси:** -индивидуаль эшчәнлек стилен формалаштыру;

-кешенең башкаларны кабул итүләрен, аңлауларын, фикерләрен җиткерә алу сәләтләрен үстерү.

Патриотик һәм кешелеклелек тәрбиясенә юнәлеш бирү. Үткәннәргә хөрмәт һәм сак караш тәрбияләү

**Регулятив:** бәйләнешле сөйләм,үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белүләрен үстерү;

**Коммуникатив:** ишетә һәм тыңлый белү күнекмәләре формалаштыру, фикерләү сәләтен үстерү;

**Танып-белү:** үзләренең белем системасында ориентлаша белергә өйрәтү; яңа белемнәр табу, үткәндә өйрәнгәнне укытучы ярдәмендә яңасыннан аера белү; яңа белемнәр табу, дәрестә алган информациядән файдаланып сорауларга җавап бирү.

Предметара бәйләнешләр: психология, җәмгыять белеме

Төп ресурслар: А. Гыйләҗевнең "Язгы кәрваннар" повесте, аңламалы сүзлек, интернет. Өстәмә ресурслар: презентация, интерактив такта, карточкалар, рәсемнәр, ноутбук, экран, эш кәгазьләре

Эш формалары: Фронталь эш, төркемнәрдә эш.

**Дәрес барышы**

Кереш әңгәмә

- Укучылар, минем сезгә бер бик мәгънәле җыр тыңлатасым килә. Әлеге җырны тыңлаганда, ачкыч сүзләрне табарга тәкъдим итәм. (Укучыларга Фәридә – Алсу дуэтының «Борма юллар» җырының бер өзеге тәкъдим ителә. Укучылар тыңлаганнан соң, өзекнең ачкыч сүзләрен табалар. Һәр группа үз вариантын тәкъдим итә, группаларда киңәшләшү өчен вакыт бирелә)

- Әлеге җырда ачкыч сүзләр? Җаваплар тыңланыла (Көтелгән җавап: гомер юлы һәм адәм баласы)

- Адәм баласы гомер юлын үткәндә, аның белән янәшә, нәрсә бара соң? Җаваплар тыңланыла (Көтелгән җавап: холык)

- Димәк, без бу дәрестә ни турында сөйләшербез? Җаваплар тыңланыла (Көтелгән җавап: холык турында сөйләшербез)

- Нәрсә соң ул – холык? Слайд №1 (кешенең табигате, характеры.) (Миллият сүзлеге/ Казан «Мәгариф» нәшрияты, 2007)

- Холык, укучылар, нәрсәгә нигезләнеп формалаша соң? (Көтелгән җавап-темпераментка нигезләнеп формалаша.)

- Әйе, сез моны 7 нче класста җәмгыять белеменнән үзләштердегез инде. Укучылар, сезнең алда эш кәгазьләре, биредә сез сыйфатларыннан чыгып, темперамент төрләрен язарга тиешсез. Эш барышында сүзлек, интернет, 7 нче класс өчен җәмгыять белеме дәреслеге файдаланырга мөмкин (Группаларда киңәшләшү өчен вакыт бирелә. Һәр группа үз вариантын тәкъдим итә) (эш кәгазе №1)

Слайд №2




Слайд №3 группалар, чиратлап, темпераментларны әйтә баралар һәм слайдтан тикшерә баралар (эталон буенча тикшерү ),




(Һәр группа членнары гомуми бәя кәгазенә дәреснең бу этабына бәя куя)

- Укучылар,без бүген кайсы әсәр геройларының темпераментларын карарбыз икән соң? (Көтелгән җавап: узган дәрестә А. Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар » әсәрен өйрәндек. Шуңа күрә, әлеге әсәр өстендә эшләрбез дип уйлыйм)

- Әсәр темасы турында нәрсә әйтә аласыз? (Көтелгән җаваплар: Бу әсәр сугыш чорыдагы авыл кешеләре турында. Әсәрдә төп вакыйгалар Сарман районы Кәсле глубинкасы һәм Зәй районы Югары Баграж авыллары арасындагы юлда бара. Вакыйгалар да Югары Баграж кешеләре белән бәйле. Әлеге чор кешеләре бик катлаулы юл үткәннәр. Әлеге юлны һәр кеше үзе булдыра алганча үткән.

- Әсәр  сездә нинди хисләр уятты? (Ул миндә ниндидер яктылык хисе уятты. «Язгы кәрваннар» повестенда А. Гыйләҗев геройларның язмышын күбрәк кырыс буяулар белән тасвирласа да, әсәрдән эчке бер җылылык бөркелеп тора.

Әсәр миндә кызгану хисе уятты, ә гаделсезлеккә ачуым килде. Сугыш чоры авырлыкларын фаҗигагә әйләндергән төп сәбәп – Сарман районы Чокырлы авылы (Кәсле авылының күршесе) кешеләрен Зәй районы Сарсаз глубинкасына, ә Зәй районы Югары Баграж (Сарсазның күршесе) кешеләрен Сарман районы Кәсле глубинкасына солы семенасына җибәрүләрендә. Хәкимҗан абый: «Чокырлы кешеләрен очратуыгызны бүтәннәргә сөйләмәгез инде... Ишеттем мин аны! Нишлисең, кушканны үтәмичән ярамый. Көне буе районда шуны даулап йөрдем» (85 нче бит),- ди. Кешеләр кызганыч.

Мин геройларга карап сокландым да, аларны кызгандым да. Алар 75 чана тезелеп 65 чакрым ераклыктагы Кәсле авылына җәяү чана тартып чыгып китәләр. Иң аянычы шунда: әлеге семенаны күрше авылдан гына да алырга булган. Ә Чокырлы кешеләрен, киресенчә, Сарсаз Багражга җибәрәләр.

Алар өчен горурландым. Әсәрдә вакыйгалар  сугышның соңгы язын тасвирлый. ( Хәкимҗан абзый болай ди: “Инде  быелгы читен яз соңгысы булсын! Тезләнсәк тә, егылыр өчен түгел, сикереп торып йөгерп китәр өчен тезләнәбез” (68-69 нчы бит)).

*Укучыларга картада  Югары Баграж һәм Кәсле авылы аралары күрсәтелә.*

**Проблемага кертеп җибәрү** (Слайд №4)

Уку мәсьәләсен кую. Әсәр кемнәр турында? (Җаваплар тыңланыла: көтелгән җавап: яшүсмерләр турында; сугыш чорында авыл халкы турында; шушы кешеләрнең гомер юллары турында)

- Аларның гомер юллары җиңел булганмы? (Җаваплар тыңланыла. Көтелгән җавап:  аларның гомер юллары бик авыр булган.  Бу яшүсмерләрнең гомер юллары авыр сугыш елларына туры килгән. Аларның гомер юллары авыр булуына Баграж–  Кәсле арасындагы юлда  күргән авырлыклардан сизенәбез. Бу аларның бөтен гомер юлларын күрсәтә кебек.

- Үзеннән  үзе нинди сорау туа? (Көтелгән җавап: сугыш чоры яшүсмерләре гомер юлларындагы авырлыкларны нәрсә хисабына җиңеп чыга алганнар?

Без  дәрес азагында нәкъ менә шушы сорауга җавпны  табарга тиеш тә инде.

**2. Уку мәсьәләсен чишүнең беренче этабы- индивидуаль эш.** Слайд №4

- Ә хәзер, әйдәгез әле әсәрнең эчтәлеге белән танышлыгыгызны тикшереп үтик

Һәр укучы алдында әсәр турында тезизлар таблицасы.  Укучылар мөстәкыйль рәвештә эшлиләр. Эшләп бетергәннән соң эталон бенча тикшерәләр, һәр дөрес җавапка 1 балл куялар. Слайд №5

| тезис | әйе | юк |
|---|---|---|
| Әсәрдә символлар: кәрван, җыр, бүреләр, җил | + | |
| Дамир, Әдилә, Ибраһим- ярдәмче геройлар | | - |
| Элеваторга 7  атта, 7  кеше бара | + | |
| Кәслекгә 75 чана кузгала | + | |
| Ибраһим белән Әдилә эт улаганын ишетәләр | | - |
| Гыймай фатихының кызы Гөлбәдәр табынга арыш ипие куя | | - |
| Кәследән семена алып кайтышлый  алар Чокырлы кешеләрен очраталар | + | |
| Иң авыр вакыйга кайтканда, завод тавында, Сабираттәй язмышы белән бәйле | + | |
| Әдилә чана бавын, шәлен рәтләгәндә, Дамирга тоттыра | | - |

- Төп вакыйгалар кайда бара? (Көтелгән җавап: төп вакыйгалар Баграж белән Кәсле авыллары арасындагы юлда бара).

- Ә менә шул юл әлеге геройларның нәрсәсенә ишарәли соң? (Көтелгән җавап: әлеге юл геройларның авыр, сикәлтәле гомер юлларына ишарәли һ.б.)

- Әсәр үзәгендә яшүсмерләр, дидек. Ә кемнәр соң алар? Һәр группа үзенә бер геройны сайлап ала һәм аңа характеристика бирә. (Группаларда киңәшләшү өчен вакыт бирелә)

Ибраһим – җитез, үткен, максатына ирешүчән, тракторчылар курсында укып кайткан. Ярдәмчел, арыган хатыннарның, хәле авырайган Сабираттәйне, Дамирның чанасына утыртып, заводка кадәр тартып алып бара, тәвәккәл (Әдиләгә мәхәббәтен аңлата ала). Әдилә – моңлы, матур итеп җырлый белә, ярдәмчел (юлда барганда, өлкән апаларга булыша), яхшы күңелле (бу аның җырыннан күренә: Алтын булып тамаем, Көмеш булып агаем). ике кыш апасының 4 баласын карый, бер эштән дә тартынмый. Инициативалы, башкалар өчен җаваплылыкны үз өстенә ала. (Кәслегә җитәрәк, ул берничә кызны ияртеп, алгарак китеп, Кәсле идарәсенә бара. Анда фатирлар белешеп, кешеләрне өйләргә бүлгәләп тә куя, Сабирәттәйнең хәле авырайгач, төп җаваплылыкны үзенә ала). Дамир – кәрле аяклы кара чутыр малай. Әтисе сугышка кадәр конюх булган, хәзер үзе атлар карый. Бераз астыртын. (Тиктомалдан, Әдиләне яманлый башлый). Дальтоник, колакка катырак, үпкәчән. (Ибраһимның саңгылау түгел лә мин, дигән сүзенә үпкәли). Армиягә яраксыз, әмма максатына ирешү өчен тырыша. (Мунчада биергә өйрәнә, ат өендә гармун кычкыртып маташа, Кәслегә дә күтәрәмгә калган атларга солы бирүләренә өметләнеп юлга кузгала).

(Һәр группа членнары гомуми бәя кәгазенә дәреснең бу этабына бәя куя)

Уку мәсьәләсе чишүнең икенче этабы - группада эш

- Укучылар, без дәрес башында темперамент турында сөйләштек, яңа гына геройларга характеристика бирдек. Ә хәзер нишләрбез? (Көтелгән җавап: Ә хәзер төп геройларның темпераментларын билгеләп үтәрбез)

- Әйе, укучылар группаларда киңәшләшеп, геройларның темпераментларын билгеләрбез. Моның өчен эш кәгазьләрендә эше дәвам итәбез. (Группаларда киңәшләшү өчен вакыт бирелә)

Һәр группа үзе фикерен әйтә һәм дәлилли. (Эш кәгазе №1). Үзбәя кую (Һәр группа членнары гомуми бәя кәгазенә дәреснең бу этабына бәя куя)




**3.Фикер алышу** Слайд №7

- Темперамент сыйфатлары нинди булуга карамастан, аларны төп сыйфаты? (Көтелгән җавап: темперамент сыйфатлары төрле булуга карамастан, алар кешелекле, киң күңелле, җаваплы. Алар барысы да оптимистлар булганнар. Ягъни киләчәккә ышанганнар, әле ышанып кына калмаганнар аны якынайту өчен мөмкин булганны да, мөмкин

булмаганны да эшләгәннәр. Алар кешелекле һәм бердәм булганнар. (Кәсле авылында да Сәрвәр апа кәрванчыларны, үзләрендә дә санаулы гына калган, бәрәңге белән сыйлый. Җитмәсә, күршеләренә кунарга кергән юлчыларны да ашарга алып чыга. Чөнки күршеләре алардан да авыррак торалар).

- Әйе, характер сыйфатлары, темпераментлары нинди булуга карамастан, алар бер-берсенә терәк, ярдәмче, мәрхәмәтле. Алар күркәм холыклы: бар булганнары белән бүлешә белгәннәр (Габбас абый йортына кунарга кергәч тә, бәрәңге ашаганда һәркем үз күршесенә бәрәңгенең тәмлерәген куярга тырыша; Сабирәттәйне дә берсе дә ярдәмсез калдырмый)

Әдилә җыры да шуңа ишарәли.

Алтын булып агаемла…

Көмеш булып тамаем…(60 нчы бит)

- Әсәрнең төп идеясе. (Көтелгән җаваплар: Өлкән буын үзенең гомере, сәламәтлеге хакына сугышның ахырын – язны якынайта. Сабирәттәй үлеме дә шушы корбаннарның берсе. Инде дилбегә «Язгы кәрваннар» – яшьләр – кулына күчә. ( Кәслегә барганда буран чыккач, яшьләрне кәрванның алдына куялар). Бу символик мәгънәгә ия, димәк, сугыштан соңгы тыныч тормыш төзү нәкъ менә шушы яшүсмерләр кулында булачагына ишарәләнә. Кәрван алдындагы кешеләр эз салып бара, алар кая барса кәрван да шул якка бара бит. Хәкимҗан абый Ибраһимга: «Даула син, үскәнем, даула. Әгәренки дауламасак, эшебез җайга китәчәк түгел безнең. Тракторын да, машинасын да – барын да даула». (64 нче бит) Илне сугыш ялангачлыгыннан явызлыгыннан, тотолитар система алып килгән афәтләрдән тыныч, җылы, гадел тормышка бары тик алар гына алып чыга алганын искәртә автор. Хәкимҗан абзый аша, **автор позициясе** чагыла. Ул яшьләрне актив булырга чакыра.

**4. Рефлексия**

- Ә хәзер дәрескә куелган уку мәсьәләсенә әйләнеп кайтыйк әле. Бу авырлыкларны алар нәрсә хисабына җиңеп чыга алганнар соң? (Җаваплар тыңланыла. Көтелгән җавап: күркәм холык һәм бердәмлек)

- Әлеге яшүсмерләр нинди холыклы булганнар соң? (Җаваплар тыңланыла). Слайд № 8 Әйдәгез әле, без дә беренче номерлы эш кәгазенә нигезләнеп, күркәм холык моделен ясап карыйк. (Һәр төркем үз күркәм холык моделен төзи һәм аны яклый)




**3 нче этап** (Слайд №9)

- Укучылар, сез бүген бик уңышлы эшләдегез, әйдәгез әле, дәрес дәвамында үзбәя кәгазьләрендәге билгеләрне гомумиләштирик һәм группаларда эшебезне бәялик, куйган билгебезне дәлиллик. (киңәшләшү өчен вакыт бирелә). Сез яшьләр! Сез – бүгенге заман яшүсмерләре! Димәк, киләчәк дилбегәсе кем кулында? Кайчандыр Ибраһим, Әдилә,

Дамирлар «кәрван» алдына баскан кебек, тиздән безнең кәрван алдына кемнәр басарга тиеш соң? Шулай булгач, безнең картлыгыбызның, сезнең киләчәгегезнең нинди булуы кемнән тора? Безнең «кәрваныбыз» сикәлтәле гомер юлыннан көчле, шәп барсын дисәк, сезгә нинди булырга кирәк соң? Ә моның өчен эшне каян башлыйк?

Өй эше. Слайд №10.1. Әдилә, Ибраһим, Дамирның холыкларын,темпераментларын күз алдында тотып, аларның алдагы тормышлары турында эссе яз (1 бит). 2. Бөек Ватан сугышы чоры яшүсмерләренең рух ныклыгын сурәтләп, 2038 елдагы яшьтәшеңә хат яз. 3. Киләчәк бүгеннән башлана дигән фикерне дәлилләп, реклама яз.

Кушымта №1 (һәр группага тарату өчен )

**Эш кәгазе №1**




**Эш кәгазе №2**




Кушымта №2 (Һәр укучыга бирелә)

| тезис | әйе | юк |
|---|---|---|
| Әсәрдә символлар: кәрван, җыр, бүреләр, җил | + | |
| Дамир, Әдилә, Ибраһим- ярдәмче геройлар | | - |
| Элеваторга 7 атта, 7 кеше бара | + | |
| Кәслекгә 75 чана кузгала | + | |
| Ибраһим белән Әдилә эт улаганын ишетәләр | | - |
| Гыймай Фатихының кызы Гөлбәдәр табынга арыш ипие куя | | - |
| Кәследән семена алып кайтышлый, алар Чокырлы кешеләрен очраталар | + | |
| Иң авыр вакыйга кайтканда, завод тавында, Сабираттәй язмышы белән бәйле | + | |
| Әдилә чана бавын, шәлен рәтләгәндә, Дамирга тоттыра | | - |

Бәяләү кәгазьләре (Һәр группага бирелә)

| Эш төре | 1 нче укучы | 2 нче укучы | 3 нче укучы | 4нче укучы | Гомуми нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|
| Темпераментларны билгеләү:<br>Эш кәгазе №1 (1 нче өлеш) | | | | | |
| Индивидуаль эш: әсәрнең эчтәлеген белү | | | | | |
| Группаларда эш: геройларга характеристика<br>Эш кәгазе №1(2 нче өлеш) | | | | | |
| Рефлексия:<br>күркәм холык моделен ясау (кушымта №2) | | | | | |
| Гомуми нәтиҗә | | | | | |

Баһавиева Лилия Данис кызы,
43 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе

## Аяз Гыйләҗев “Өч аршин җир” әсәре

| Предмет | Татар әдәбияты |
|---|---|
| Тема | Аяз Гыйләҗев “Өч аршин җир” әсәре. |
| Дәреснең максатлары | 1. Аяз Гыйләҗевның тормыш юлы һәм иҗаты, “Өч аршын җир” әсәре белән белән таныштыру, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү;<br>2. Сөйләм телен, фикерләү сәләтен, анализлау күнекмәләрен үстерү;<br>3. Туган якка, туган җиргә карата мәхәббәт тәрбияләү. |
| Планлаштырылган нәтиҗә | **Шәхескә кагылышлы:**<br>-дөрес сөйләм булдыруга омтылыш<br>-үз фикереңне әйтә белү;<br>-төркемнәрдә килешеп эшли белү<br>-иптәшеңә рухи ярдәм күрсәтә белү<br>--фикереңне дәлилли белү<br>**Метапредмет:**<br>*Танып –белү УУГ*<br>-аңлап уку.<br>-тиешле мәгълүматны табу һәм аерып алу;<br>-төрле рәвештә бирелгән мәгълүматны кабул итү һәм аңлау;<br>-текстны кабул итү.<br>-укыганны анализлау;<br>*Коммуникатив УУГ:*<br>-башкаларның сөйләмен ишетү һәм тыңлау;<br>-үз фикереңә ышандыра белү;<br>-башкаларга аңлаешлы сөйләм төзү.<br>*Регулятив УУГ:*<br>-уку бурычларын кую<br>-эшчәнлеккә бәя бирү.<br>-үз фикереңне төгәл җиткерү<br>-дөрестән дөрес түгелне аеру<br>-таныш арасыннан таныш булмаганны билгели белү<br>-нәтиҗәләр формалаштыру |

| | |
|---|---|
| | **Предмет буенча:**<br>А.Гыйләҗевның тормыш юлы Һәм иҗаты белән таныштыру. “Өч аршин җир” әсәрен уку һәм анализ ясау. Туган якка, туган җиргә карата мәхәббәт тәрбияләү.Туган як темасына диалог һәм монолог төзи белү. |
| Дәреснең тибы | Яңа белем бирү. |
| Төп төшенчәләр | Туган илне сагыну,юксыну. |
| Предметара бәйләнеш | Тарих , татар теле |
| Эшне оештыру | Төркемдә,парларда,индивидуаль. |
| Чыганаклар | Татар әдәбияты Мотыйгуллина Ә.Р. Ханнанов Р.Г. Мулласалихова Г.Г. 7 класс(1 кисәк) |

## Класс: 7

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре(УУГ) |
|---|---|---|---|
| **Оештыру**<br>Максат: белем алуны мотивлаштыру | Укучыларны уку эшчәнлегенә мотивлаштыру. Көтелгән нәтиҗә: дәрескә уңай психологик халәт булдыру(“Туган ил”темасына презентатция күрсәтү) | Сыйныф эшкә әзерләнә (укытучыны сәламлиләр, сорауларга җавап бирәләр,сөйләм эшчәнлегенә кушылалар) | Укытучыга һәм сыйныфташларга карата хөрмәт.Укытучы,сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү.Дәреснең темасын,максатын ачыклау. Эш урынын әзерләү. |
| **Актуальләштерү**<br>Максат: алдагы дәрестә алган белемнәрне искә төшерү | Фронталь эш оештыра. Үткән дәресне ныгыту өчен укучыларга сораулар бирә. | Өстәмә уку өчен бирелгән әсәрне уку, биремнәрне эшләү. | Регулятив (укучылар тарафыннан белгән күнекмәләрне үзара бәйләү). |
| **Уку мәсьәләсен кую**<br>**Максат:** Аяз Гыйләҗевның тормыш юлы һәм иҗаты, **таныш булмаган яңа сүзләрне истә калдыру** “Өч аршын җир” әсәре белән белән таныштыру, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү | Аяз Гыйләҗев биографиясе белән таныштыра (презентатция күрсәтә), әсәрне сәнгатьле укый, тәрҗемә эше, сүзлек өстендә эш оештыра. | Аяз Гыйләҗевның биогра-фиясе буенча сорауларга җавап бирәләр. Сүзләрне укыйлар, тәрҗемә итәләр, сүзтезмәләр, җөмләләр төзиләр Әсәрне сәнгатьле итеп укыйлар, сорауларга җавап бирәләр, сүзлек белән эшлиләр. Фикер алышалар. | Шәхси: Туган илеңне ярату, кадерен белү;<br>Танып-белү:универсаль-логик гамәлләрне аерып күрсәтә белү;<br>Предмет: кыска сөйләм берәмлекләре төзү.<br>Коммуникатив: фикерне төгәл итеп җиткерә белү. |
| **4. Физкульминутка**<br>Максат: укучыларны ял иттерү | Ял итәргә тәкъдим итә | Укучылар укытучы кушканны башкаралар | Шәхси:күнегүләр ясау. |
| **Уку мәсьәләсен чишү.**<br>**Максат: уку һәм сөйләм күнекмәләрен үстерүне формалаштыру** | Укучыларга белемнәрне ныгыту биремнәрен аңлата. Схемалар ярдәмендә эшләүне өештыра.Текстка карата сораулар бирә. Вакыйга кайда бара? Пассажирлар нинди хәбәр ишетәләр? Авыру янына кем килә? Авыру хатын кем ул? Аның кемнәре бар? Ни өчен поездны туктатырга булалар?Шәмсегаянны нәрсә борчый? | Алган белемнәрен кулланып,биремнәр үтиләр;терәк сүзләр ярдәмендә схемалар төзиләр.Сорауларга җавапны табып уку. | Шәхси:Туган илнең бер булуын аңлау.<br>Танып-белү: Әсәрне аңлап уку. Соруларга җавапны тексттан таба белү.<br>Коммуникатив: нинди юнәлештә камилләшү мөмкинлеген күрсәтү; проблеманы бергә хәл итә белү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Мирвәли, басу буйлап барганда, нәрсәгә ътибар итә? Мирвәлинең теләге нинди? Шәмсегаян нинди васыять әйтә? Мирвәли нәрсәдән курка? Автор бу әсәре белән нәрсә әйтергә тели? Бу әсәр ошадымы? Бүгенге көндә актуальме? | | |
| **Уку эшчәнлеген йомгаклау. Рефлекция Максат: алган белемнәргә нәтиҗә ясау. Билгеләр кую.** | Дәрестә туган авырлыклар турында сорый.<br>Дәрес барышында нинди авырлыклар туды? Ни өчен дип уйлыйсыз?<br>Укучыларның җавабын тыңлый. | Үз фикерләрен әйтәләр. | Коммуникатив: үз фикереңне дәлилле итеп коллективта аңлата белү. |
| **Өй эше.** | Балаларның белем дәрәҗәләренә карап, сайлый торган өй эше тәкъдим итә.<br>1) Әсәрдән үзеңә ошаган бүлекне сәнгатле укырга, тәрҗемәсен белергә<br>2) Туган як турында хикәя язу.<br>3) Туган илнең матурлыгын рәсемдә күрсәтеп ясарга.<br>Өй эшен аңлата. | Өй эшен сайлап алалар. | Шәхси: үз мөмкинлегеннән чыгып өй эше сайлау. |

Гыйниятуллина Раилә Хәбибулла кызы,
43 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе

## Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” әсәре

| | |
|---|---|
| **Дәреснең темасы:** | **Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” әсәре** |
| **Дәреснең максаты:** | Татар халкының танылган язучысы Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлын һәм иҗатын искә төшерү, аның “Җомга көн кич белән” әсәре белән танышу |
| **Дәреснең төп бурычлары:** | **өйрәтү:** татар халкының танылган язучысы Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу, “Җомга көн кич белән” әсәреннән бирелгән өзекләрне уку;<br>**үстерү:** “Җомга көн кич белән” әсәреннән бирелгән өзекләрне анализлау;<br>**тәрбияви:** шәхеснең рухи-әхлакый сыйфатларын камилләштерү, әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү. |
| **Дәреснең тибы:** | «яңа белем ачу» |
| **Көтелгән нәтиҗә** | *Фән буенча УУГ:* әсәрне уку, төп герой Бибинурның катлаулы рухи дөньясын һәм эш-гамәлләрен анализлау;<br>*Танып белүнең УУГ:* “Бибинур” фильмын караганнан соң, әсәр белән уртак һәм аермалы якларын табып, анализ ясый белү, план төзү;<br>*Шәхси УУГ:* мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәнү, өлкән яшьтәгеләргә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү;<br>*Регулятив УУГ:* дәреснең максатын мөстәкыйль таба белү, укучыларның нәрсә аңлауларын белү, тагынниләр үзләштерергә |

| | |
|---|---|
| | тиешлеген аңлату;<br>*Коммуникатив УУГ*: дөрес сөйләм нормаларын саклаган хәлдә, үзләренең фикерләрен ачык, төгәл, тексттан өземтәләр китереп дәлилли белү, укытучы һәм яшьтәшләр арасында хезмәттәшлекне планлаштыру. |
| **Предметара бәйләнеш** | татар теле, кино сәнгате, әйләнә-тирә дөнья. |
| **Чыганаклар :**<br>**- төп**<br><br><br><br>**- өстәмә** | 1. Хәсәнова Ф. Ф., Сафиуллина Г. М., Гарифуллина М. Я. “Татар әдәбияты”: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүчеләр өчен). 9 нчы сыйныф, Ике кисәктә. 2 нче кисәк – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2016. – 191 бит: рәс. б-н.<br>1. Электрон дәреслек, 2. “Бибинур” фильмы 3. Презентация, 4. Газета-журнал материаллары 5. Үзбәя бирү өчен таблица |
| **Эшне оештыру төрләре** | Фронталь, индивидуаль, парлап эшләү |
| **Төп төшенчәләр** | Кешелеклелек, әхлак нормалары |

Бәдриева Фәридә Рәис кызы,
икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

## А. Гыйләҗевнең “Матур” хикәясендә дуслык темасы

| | | |
|---|---|---|
| **Тема** | А. Гыйләҗевнең “Матур” хикәясендә дуслык темасы | |
| **Сыйныф** | 3 нче сыйныф, татар төркеме | |
| **Дәреснең тибы** | Якташ язучылар иҗатын өйрәнү буенча әдәби укудан сыйныфтан тыш уку дәресе | |
| **Максат** | 1. А. Гыйләҗев иҗаты белән таныштыру.<br>2. Укучыларның татар халык ашлары турында белемнәрен ныгыту. Песиләрнең үзенчәлекләре, аларның яраткан азыклары турында әңгәмә алып бару.<br>3. Татар телендәге әсәрләрне укуга кызыксыну уяту, дуслык, татулык, ярдәмчеллек кебек уңай сыйфатлар тәрбияләү. | |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | 1. Предмет нәтиҗәләре: өзекнең темасын аңлау, тулысынча укып чыгу теләген уяту.<br>2. Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр: Разыяның Искәндәргә булган җылы мөнәсәбәте аша дуслык хисе булдыру.<br>3. Метапредмет нәтиҗәләр:<br>- регулятив: дуслык турында хикәяне уку<br>- танып-белү: әдәби әсәрне мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру<br>- коммуникатив: үз фикерен белдерергә, уртак фикергә килергә өйрәнү. | |
| Предметара бәйләнешләр | Татар теле, музыка, әйләнә-тирә дөнья | |
| Җиһазлау | Аяз Гыйләҗев “Алсу, Илдус һәм сандугач”, 2008 ел, Аяз Гыйләҗев портреты , китаплар күргәзмәсе, ноутбук, өчпочмак песи рәсеме, слайдлар күрсәтү өчен проектор, экран, фонохрестоматиядән Сарман көе,татар халык бию көе, әдәби әсәрләргә иллюстрацияләр. | |
| Эшне оештыру | Фронталь эшләү. | |
| Педагогик технологияләр | Өлешчә тикшеренүгә корылган әңгәмә | |
| **Дәреснең барышы** | | |
| Дәрес этаплары | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучылар эшчәнлеге** |
| | | |
| Оештыру этабы | Уңай психологик халәт урнаштыру.<br>Исәнмесез, хәерле иртәләр, укучылар!Дәресебез кызыклы файдалы узсын өчен без тырыш, белемле, кызыксынучан, тәртипле булыйк. | Исәнләшү, елмаю, изге теләкләр теләү, куелган сорауга җавап бирү |

| | | |
|---|---|---|
| Темага килү | -Күңелләребез тагын да күтәренке булсын өчен көй тыңлап үтик. Бу "Сарман" көе. Әйтә алмассыз микән, ни өчен бу көйне тыңлап уздык? | "Сарман" көе тыңлау, шушы яктан чыккан күренекле шәхесләрне атау. |
| Белемнәрне актуальләш-терү | - Укучылар, без бүген якташларыбыз турында сөйләшүне дәвам итәбез.<br>- Әйе, бүген безне Аяз Гыйләҗев һәм аның "Матур" дигән әсәре белән танышу көтә.Ул Сарман районы Чукмарлы авылында туган. | Язучының портретын, китаплар күргәзмәсен карау, дәреснең темасын, хикәянең исемен әйтү. |
| | Әсәр ничек атала? Ни өчен монда песи рәсеме эленеп тора? Менә шушы сорауларга без сезнең белән җавап бирербез. | Өзекне чылбыр буенча уку, әсәрнең геройларын атау. Разыя белән Галияне чагыштыру. |
| Белемнәрне актуальләштерүне дәвам итү | Игътибарны рәсемнәргә юнәлтү. Сораулар бирү. Татар халык ашлары, песиләрнең яшәү шартлары, нәрсә белән тукланулары турында әңгәмә.<br>Өзекнең темасын билгеләү | Рәсемнәргә карап, өзекләрне уку. Сорауларга җавап бирү.<br>Өчпочмакны ничек әзерләүне, нинди ингредиентлардан торуын, песиләрнең итле ашамлыклар яратуын әйтү.<br>Дуслык- зур байлык. |
| Ял моменты Физкультпауза | Татар халык бию көе куела, туктатып, җавабы сан булган сораулар бирелә.<br>Песинең ничә аягы бар? Кеше ничә бияләй кия? Өчпочмакның ничә почмагы бар? | Бию, көй туктау белән парлашу(өчәү, дүртәү) басу.<br><br>Парсыз калучыларның уеннан чыгуы. |
| Беренчел ныгыту | Сөйләгәннәрдән чыгып, проблемалы сорау куела: "өнәп бетерми", " томалаган мич" юлларын сез ничек аңлыйсыз? | Җавап бирү, үз фикерләрен әйтү. Җөмләләр төзү. |
| | Ни өчен Разиянең әнисе Искәндәрләргә керергә рөхсәт бирми? | Җавап бирү, үз фикерләреңне әйтү |
| Икенчел ныгыту. | Өчпочмак ашап утырганда, Разыяның башына нинди уй килә? | Җавап бирү, үз фикерләреңне әйтү. |
| Мөстәкыйль эш | Өзекне укыту, тактага план яздыру. | Укыган өзек буенча план төзү, кыскача сөйләү. |
| Белемнәрне системага салу | Сорауга җавап эзләүне оештыру.<br>Экранда:"...Кыш килгәндә, һавада эре-эре кар бөртекләре бөтерелгәндә, ничек инде берүзең генә уйнап булсын?!"<br>“...Разыяның иптәшенә булган якынлыгы аның күңелен нечкәртте..." | Төркемнәрдә киңәшләшү, үз фикерләреңне әйтү.<br><br>Дуслык турында сөйләшү. |
| Рефлексия. Өй эше бирү. | Барлык эш процессын күздән кичереп, төп нәтиҗәне чыгару:<br>Чын дус булу - нинди зур бәхет ул,<br>Дусларыгызның кадерен белегез! | Төп нәтиҗә: Дуслык ул – иң матур, иң күркәм хис. Ул хисне бервакытта да югалтырга ярамый. |

| | | |
|---|---|---|
| | Кеше янында яхшы булып кыланып,<br>Көнчеләрдән ерак йөрегез!<br>**Өй эше**: Сез Разыя белән Искәндәр турындагы әсәрне азагына хәтле укырга теләр идегезме? Мин әсәрнең принтердан чыгарылган нөхсәсен таратам, ә сез өйдә укып бетереп килегез, хикәя эчтәлеге буенча рәсем ясагыз. | |
| Дәресне йомгаклау | Билгеләр кую. | Эшчәнлеккә үзбәя. |

Нәҗметдинова Чулпан Мөнир кызы,
Сарман аграр көллияте, Сарман районы

## Аяз Гыйләҗев иҗатында Туган җирем сукмаклары (2нче курс укучылары өчен дәрес)

Җәмгыять үсеше белән бергә, мәктәп тормышында яшәп килгән тәрбия системасы да бик еш үзгәртеп корыла. Һәрнәрсәнең ике ягы булган кебек, бу үзгәрешләр дә уңай нәтиҗә генә бирми. Иң аянычы - балаларыбызның туң йөрәкле, үз мәнфәгатьләрен бөтен нәрсәдән өстен куючы затлар булып үсүе ихтимал. Яшьләрнең рухи яктан зәгыйфләнә баруы күренә башлады. Бу хәл уку-укыту эшендә дә үзен сиздерә. Хәзерге балаларга совет чоры әсәрләрен, бигрәк тә сугыштан соңгы еллар турында язылганнарын аңлау кыенлашты. Ләкин җәмгыять ничек кенә үзгәрмәсен, кеше яхшы белән начарны, ак белән караны, бөеклек белән түбәнлекне аерырга, үз туган иленә карата булган мәхәббәтнең зурлыгын аңлап үсәргә тиеш. Чөнки бәхетле тормышны безгә үзебезгә төзергә туры киләчәк.

Көллиятебездә татар әдәбияты дәресендә Аяз Гыйләҗев иҗаты белән танышу эш программасына кертелгән. Әлеге теманы үткәндә, мин студентларыма Туган як, туган җиргә карата булган хис, аның кеше тормышындагы әһәмиятен аңлатырга тырышам.

Әдипнең күп әсәрләрендә туган як, туган җир, туган авыл, аның гаделлеккә нигезләнгән тәртипләре, гореф-гадәтләре, әхлакый кануннары – шуларга тугрылыклы булып кала белү мәсьәләләре күтәрелә, геройларның кем икәнлекләре дә ахыр чиктә шул кануннар, шул кагыйдәләр белән үлчәнә. Дөрес, бу хәл татар әдәбияты өчен бигүк яңа күренеш түгел. Әмма мәсьәләнең куелышы-чишелеше һәм геройлар язмышының як-тыртылышы А.Гыйләҗев әсәрләрендә беркадәр башкача.

Аның әсәрләрен укыганда күңелгә бер рәхәтлек бирә торган хис уяна. Якташ язучылар әсәрләрендә генә, узеңңнең йөргән җирләрне, Сарманыңны күз алдына китереп укып була. Үзең дә аның геройлары кебек шул сукмаклардан атлыйсың, шул юлларны үтәсең кебек тоела.

Язучы иҗатын өйрәнү дәресен мин **"Аяз Гыйләҗев иҗатында Туган җирем сукмаклары"** дип атадым.

Электрон белем бирү ресурслары: ноутбук, проектор, экран, слайдлар

**Дәрес тибы:** Язучы иҗатын өйрәнү дәресе

**Дәрес максаты:** Укучыларны язучының иҗаты һәм тормыш юлы белән таныштыру; аның якташыбыз булуына басым ясау. Якташыбызның татар халкы

күңелендә зур урын алуы, әсәрләренең тәрбияви кыйммәтенең зурлыгы, аның беркемне дә кабатламаган кодрәтле таланты; туган җир темасына бәйле рәвештә укучыларны логик фикерләү аша иҗади фикерләүгә алып чыгу; Әсәрләрендә булган туган як, туган җир, туган авыл, аның гаделлеккә нигезләнгән тәртипләре, гореф-гадәтләре, әхлакый кануннары — шуларга тугрылыклы булып кала белү мәсьәләләре; Үз туган ягына битараф булмау, укучыларда туган илне саклый белү сыйфатлары тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Шәхси: активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә, акыл эшчәнлегенә һәм рухи эшчәнлеккә өйрәтү.

Метапредмет: укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү.

Танып-белү: әдәби әсәр буенча һәм тормыштан алган күренешләргә, хис-кичерешләргә нигезләнеп, сорауларга җавап бирү.

Коммуникатив: үз фикерләрен телдән җиткерә белү.

Регулятив: үз фикерләреңне мөстәкыйль дәлилләү.

**Предметара бәйләнеш:** тарих, әйләнә-тирәне танып белү.

**Җиһазлау:** интерактив такта, компьютер, фоторәсемнәр, А. Гыйләҗев тормышыннан истәлекле фотолар, китапларыннан күргәзмә.

**Дәреснең технологик картасы**

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Универсаль уку гамәлләре (УУГ)** |
|---|---|---|---|
| **<u>Мотивлаштыру</u>**<br>2 мин.<br>Максат: уңай психологик халәт тудыру. | Укучыларны уку эшчәнлегенә тарту.<br>- Кәефләрегез яхшымы? Бик яшы. Яхшы кәеф белән дәресебезне башлап җибәрик.<br>(1,2 слайдлар) | Дәрестә эшләү кагыйдәләрен искә төшерәләр: башкаларны тыңла, хөрмәт итәргә, үз фикереңне ачык әйтергә, игътибарлы булырга | **Шәхси:** әдәп-әхлак кагыйдәләрен искә төшерү, бер-берсенә уңышлар теләү. |
| **<u>Актуальләштерү</u>**<br>4 мин.<br><br>Максат: дәрескә әзерлекне тикшерү, аның темасын формалаштыру. | 1. интерактив тактадагы фотосүрәтләргә игътибар иттерү<br>2. аларның барысын да нәрсә бәйли соравына җавап эзләү (3 слайд) | Һәр укучы уйлап үз фикерен, дөрес җавапны җиткерә (бу безнең Туган ягыбыз – Ватаныбыз) | Регулятив: үзләштерелгән белән таныш булмаганны чагыштырып, хәл ителергә тиешле уку бурычын кую. |
| **Аңлау өчен авыр тоелган сорауны ачыклау өчен сынап карау этабы** 4мин.<br>Максат: <u>укучының нинди авырлык белән очрашуын билгеләү</u> | Проблема тудыра. Дәрестә нинди тема күтәреләчәк, шул сорауга җавап әзерләү, укучылардан әйттерү.<br>Туган як, туган җир темасы | Фикер алышу. Дөрес җавапны табу. | **Коммуникатив:** информацияне эзләү һәм туплауда инициативалы хезмәттәшлек**.** |
| **<u>Кыенлыктан чыгу планы.</u>** (яңа белемнәрне куллану).5 мин.<br>Максат: кыенлыктан чыгу юлларын ачыклау | Шушы сүзгә бәйләп җавапны тулыландыру өчен сораулар бирә.<br>Сарманыбызда туып үскән, иҗат иткән, танылган шәхесләрне ачыклау. (4 слайд) | Җавапны тулыландырып бирү. | **Коммуникатив:** проблеманы ачыклау, тәңгәлләштерү, аны хәл итүнең юлларын эзләү. |
| **<u>Планны тормышка ашыру</u>**/<u>өйрәнеләчәк темага</u> | Язучының тормышы турында фикерләр. Тумышы | Язучының “Балачак | **Коммуникатив:** эчтәлеге буенча фикер |

| | | | |
|---|---|---|---|
| кереп китү<br>6 мин.<br>Максат: аңлау, әсәрләрен санап үтү. | белән кайдан? Кайда яшәгән? (5-7слайдлар) | сукмаклары” хатирәләреннән өзек уку | алышу, аңлашылмаган җирләрендә туктап бер-берсенә аңлату. |
| **Беренчел ныгыту** 6 мин.<br>Максат: белемнәрне куллану/тышкы сөйләмдә әйтеп күрсәтү | Язучының гаиләсе турында бераз искә төшерү өчен сораулар бирү.<br>(8- 10 слайдлар) | Гаиләсе турында фотосурәтләр белән танышу | **Танып белү:**<br>Презентациядәге фотосурәтләрне карау, танышу |
| **Үз-үзеңне тикшерү** 6 мин.<br>Максат: үзләштерелгән белемнәр буенча нәтиҗә ясау. | Класстан тыш укырга бирелгән “Дүртәү”, “Язгы кәрваннар” хикәяләреннән чыгып сораулар бирү. Аның төп геройлары кемнәр? Нинди темаларга иҗат иткән? (11слайд) | Хикәяләре буенча эш. Тематикасын ачыклау. Туган ил төшенчәсен ачуны дәвам итү. | **Танып белү:**<br>уй-фикерне сөйләмдә аңлап һәм ирекле оештыру. |
| **Белемнәрне системага** салу. 6 мин.<br>Максат: алган белемнәрне куллану һәм ныгыту. | -Дәреснең темасы нинди иде?<br>- Сез бүгенге дәрестә якташыбыз А. Гыйләҗевнең томыш юлы һәм иҗаты турында нинди яңалыклар белдегез?<br>-Туган як һәм аның иҗаты арасында нинди бәйләнеш барлыгын сиздегез? | Сорауларга җавап бирү. | **Регулятив:**<br>үзләштерелгән һәм үзләштереләсе белемнәрне аера белү һәм төшенү, үзләштерелгәннең сыйфатын һәм белү дәрәҗәсен аңлау. |
| Рефлексия 6 мин.<br>Максат: үз эшчәнлегеңә кире кайтып бәя бирү | Үз эшеңне бәяләүгә юнәлтелгән сораулар куела. Укытучы укучылар белән берлектә эшкә йомгак ясый. Өй эше бирү һәм аңлату.<br>(12,13 слайдлар) | Укучыларның фикерләре тыңлана. Нәтиҗәләр ясала. | **Танып белү**: эш – хәрәкәтләрнең алымнарын һәм шартларын , эшчәнлекнең барышын һәм нәтиҗәләрен тикшереп бару һәм бәяләү. |

**Дәрес барышы:**

Оештыру. Уңай психологик халәт тудыру.

Эпиграф:

Урман-күлләр, елга үзәнлекләр,
Кош сайравын җиргә тарата.
Кая гына китеп яшәсә дә,
Туган җирен һәркем ярата.

**Укытучы сүзе:** Тактадагы фотосурәтләрне игътибар белән карагыз әле. Аларны нәрсә бәйли? Берләштерә? (3 слайд - *интерактив тактада Казан шәһәре, Татарстан флагы, Сарман)* **Укучылар җавабы.**

**Укытучы:** Дөрес, укучылар. Бу безнең туган ягыбыз, Ватаныбыз - Татарстан. Ә сез ничек аңлыйсыз Туган як сүзен? Сез аны ничек күз алдына китерәсез? Сез Туган илне яратасызмы? **Укучылар җавабы.**

**Укытучы:** Әйе, Туган җиребез һәрберебез өчен дә кадерле, күңелгә якын җир. Кая гына китеп яшәсәк тә, Туган якны сагынабыз. Ә безнең Туган җиребез – Сарман районы. Болын-кырлары, чишмәләре, күлләре белән сокландырып, үзенә тартып торучы яшел бишегебез ул безнең. Сарманыбыздан бик күп танылган кешеләр, язучылар, җырчылар чыкканын без барыбыз да беләбез. Шуларны санап үтик әле. **Укучылар җавабы.**

**Укытучы:** Әйе, алар арасында сез әйтеп үткән Аяз Гыйләҗев тә бар. Аның нинди әсәрләрен беләсез? (4 слайд – *Аяз Гыйләҗев портреты*) **Укучылар җавабы.**

**Укытучы:** Язучыбызның әсәрләрендә үзебезнең Сарманыбыз турында язылган урыннарны очратканыгыз бармы? **Укучылар җавабы.**

**Укытучы:** Әйе, туган җиребез сукмакларын аның күп кенә хикәяләрендә, хатирәләрендә очратырга була. Аларны укыганда үзең дә шул юллардан узган кебек буласың. Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 нче елның 15 гыйнварында Сарман районы Чукмарлы авылында туган. Ләкин аның балачагы Югары Баграж авылында уза. Әнисе Әхмәт авылыннан, Әтисе Сарманнан булганга күрә бик еш, бигрәк тә җәйләрен Сабантуйларына, җыеннарга кайта торган булалар. Бу турыда ул үзенең "Балачак сукмаклары" хатирәләрендә яза.

Язучының "Балачак сукмаклары" хатирәләреннән өзек уку. (5 *слайд*)

**Укытучы:** Әтисе Мирсәет, әнисе Мөгаттәрә укытучылар булалар. Алар өч бала тәрбияләп үстерәләр: Алмаз, Аяз һәм Азат*(6 слайд )*.А.Гыйләҗевнең башлангыч иҗат тәҗрибәләре студентлык елларында ук башлана – «Ян, учагым, ян!» исемле лирик рухтагы беренче хикәясе 1948 елда дөнья күрә. Шулай да аның актив иҗат эшчәнлеге беркадәр соңрак – 1956 елда башлана. Илленче еллар ахырында ул күп санлы хикәяләр, публицистик мәкаләләр иҗат итә.

Тик Аяз аганың сукмаклары такыр гына булмый. Ул университетны ташлап яңадан авылына кайта. Моның төп сәбәбе: ачлык, ялангачлык.

Аяз аганың тормышында иң аянычлы чор ул 1950-1955 еллар. Бу елларны язучы Казахстан далаларында, Сталин концлагерьларында уздырырга мәҗбүр була. Мәктәптә өйрәнелгәннәрдән, әсәрләреннән чыгып ни өчен икәнен әйтә аласызмы? **Укучылар җавабы.**

**Укытучы:** Әйе, бары тик әсәрләрендә чагылган, шул чор режимына бик үк туры килеп бетмәгән үткен фикерләре өчен. (*7слайд)* Язучы азат булып туган якларына кайткач, Нәкыя исемле кызга өйләнә. Бер-бер артлы өч уллары туа. (*8 - 10 слайд - гаилә фотоларын күрсәтү)*

Искәндәр – профессор. Мансур – язучы, драматург. Рәшат – табиб, эшмәкәр

**Укытучы:** Язучы илленче елларда әдәбиятта үз сукмагын табып, беркемне дә кабатламыйча, рухи азатлык җырчысы буларак юл яр ды. Аның төп теләге – хакыйкатьне яклау, гаделлеккә омтылу иде. Класстан тыш укырга бирелгән "Дүртәү", "Язгы кәрваннар" хикәяләреннән күренгәнчә аның төп геройлары кемнәр? Нинди темаларга иҗат иткән? *(11 слайд)* **Укучылар җавабы.**

**Укытучы:** Әйе, язучыбыз авыл кешесен, аның авыр тормышын тасвирлый. Әдипнең күп әсәрләрендә туган як, туган җир, туган авыл, аның гаделлеккә нигезләнгән тәртипләре, гореф-гадәтләре, әхлакый кануннары – шуларга тугрылыклы булып кала белү мәсьәләләре күтәрелә, геройларның кем икәнлекләре дә ахыр чиктә шул кануннар, шул кагыйдәләр белән үлчәнә. Дөрес, бу хәл татар әдәбияты өчен бигүк яңа күренеш түгел иде. Әмма мәсьәләнең куелышы-чишелеше һәм геройлар язмышының яктыртылышы А.Гыйләҗев әсәрләрендә беркадәр башкача. Укучылар, ул бары тик хикәяләр генә язганмы сон? Яисә бутән жанр өлкәсендә дә каләмен сынап караганмы? **Укучылар җавабы**.

**Укытучы:** Бик дөрес. Киң колачлы талант иясе ул. Проза өлкәсендә, драматургия өлкәсендә дә зур уңышларга ирешкән язучы. Аның кайсы гына әсәрен алсаң да, алар халык өчен, ил өчен борчылган олы әдипнең алыштырмас хәзинәләре. "Өч аршын

жир",  "Язгы кәрваннар", "Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят", "Җомга көн кич белән", "Әтәч менгән читәнгә" әсәрләре белән Аяз Гыйләҗев үзен повестьлар остасы итеп танытты. Ә драма әсәрләре, төрле театр сәхнәләрендә уйнала. Аның пьесалары белән танышкач укучы уйлана, дөнья гаме белән яши башлый. Күп кенә әсәрләре рус һәм төрек телләренә дә тәрҗемә ителгән. *(12 слайд)*

**Йомгаклау.**

Димәк, сез бүгенге дәрестә якташыбыз А. Гыйләҗевнең томыш юлы һәм иҗаты турында нинди яңалыклар белдегез? *(13 слайд)*

Туган як һәм аның иҗаты арасында нинди бәйләнеш барлыгын сиздегез?

Якташыбыз үз иҗатында иң кирәкле мәсьәләләрне күтәргән. Аның әсәрләре озын гомерле. Язучының халык тәҗрибәсенә нигезләнгән иҗтимагый–фәлсәфи карашлары безне яхшыны яманнан, дөреслекне ялганнан аерырга өйрәтә. Аяз Гыйләҗев әсәрләренең тәрбияви кыйммәте әйтеп бетергесез зур. Моның шулай булуына, аның иҗаты белән якыннанрак танышкач тагын бер кат инанырбыз.

**Өй эше:** А. Гыйләҗевнең “Өч аршын җир” әсәрен укып килергә.

Гимадиева Гөлнар Фоат кызы,
Яр Чаллы шәһәренең 1 нче урта мәктәбе

## Мәктәптә Аяз Гыйләҗев иҗатын өйрәнүнең куелышы
## (Методик тәҗрибә)

### Кереш

Мәктәп программасы нигезендә әдәбият дәресләрендә өйрәнү өчен язучыларның халык күңелендә лаеклы урын алган мөһим эчтәлекле, сәнгатьчә дип табылган әсәрләре сайлап алына.

Аяз Гыйләҗев – татар прозасының тәҗрибәле язучыларыннан. Моны аның каләмдәшләре, әдәбият галимнәре дә раслый: «Аяз Гыйләҗев – татар әдәбиятына бик күп үзенчәлекле әсәрләр биргән шәхесләрнең берсе. Аяз Гыйләҗев иҗаты – көрәшче иҗат», ди Гариф Ахунов. «Аяз Гыйләҗев – күренекле прозаик, үзенчәлекле драматург, үткен каләмле публицист һәм очеркист, ниһаять, усал телле тәнкыйтьче» дип бәяли Фәрваз Миңнуллин.

Бу бәяләмәләрдән аңлашылганча, язучы Аяз Гыйләҗевнең тормыш һәм иҗат юлы мәктәптә һичшиксез өйрәнелергә хаклы.

Методик тәҗрибә эшендә Аяз Гыйләҗев иҗаты **өйрәнү объекты**, язучының «Язгы кәрваннар» әсәрләре **тикшеренү предметы** итеп алынды.

**Максатыбыз** – Аяз Гыйләҗевнең мәктәптә проза әсәрләрен өйрәнү үзенчәлекләрен барлау һәм күрсәтү.

Максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычлар** куелды:

– Аяз Гыйләҗев иҗатын күздән кичерү, программада бирелгән әсәрләрен барлау;

– Аяз Гыйләҗев иҗатын мәктәптә өйрәнү методикасы буенча фәнни-методик әдәбият белән танышу;

– мәктәптә Аяз Гыйләҗев иҗатын өйрәнүнең торышы һәм куелышын билгеләү;

– VIII сыйныфта Аяз Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» әсәрен өйрәнү методикасын эшләү;

– тупланган материалны язмача теркәү.

**Тикшеренүнең фәнни-теоретик һәм методологик нигезен** Тәлгат Галиуллин,

Фәрваз Миңнуллин, Рафаэль Мостафин, Рифат Сверигин, Мәдинә Җәләлиева кебек әдәбият галимнәрнең хезмәтләре тәшкил итте.

**Тикшеренү методикасы.** Әдәби әсәрләргә анализ бирү һәм әдәби әсәрне методик яктан тикшерү күздә тотыла.

**Хезмәтнең фәнни-гамәли кыйммәте.** Күзәтү-тикшеренүләр һәм аларның нәтиҗәләре мәктәп һәм югары уку йортларында Аяз Гыйләҗев иҗатын һәм әсәрләрен өйрәнү барышында файдаланыла ала.

Хезмәт кереш, ике бүлек, йомгак өлеше, файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора.

**Мәктәптә Аяз Гыйләҗев иҗатын өйрәнүнең торышы**

Мәктәп программасында Аяз Гыйләҗевнең халык күңелендә лаеклы урын алган «Язгы кәрваннар» – VIII сыйныф, «Әтәч менгән читәнгә» – XI сыйныф, «Җомга көн, кич белән» әсәрләре – XI сыйныф, альтернатив дәреслекләр буенча сайлап алынган.

Программа нигезендә Аяз Гыйләҗев әсәрләрен өч төргә бүлеп өйрәнү мөмкин: 1) текстны җентекләп тикшерү (уку һәм анализлау); 2) гомумирәк тикшерү (укып фикер алышу); 3) мөстәкыйль үзләштерү (сыйныфтан тыш уку).

Беренче юл белән әсәрләр башлыча укытучы җитәкчелегендә анализлана. Икенче юл белән тикшерүдә укучылар мөстәкыйльлек ягыннан активрак катнаша. Өченчесендә укучылар тулаем мөстәкыйль үзләштерәләр. Әмма һәр өч төркемдә дә игътибар текстны укуга юнәлдерелә. Болар – чын мәгънәсендә әдәби уку дәресләре. Әдәби әсәрне укып төшенү – рухи баю, күңелгә яңа хәзинә өстәү дигән сүз ул.

Программада Аяз Гыйләҗевнең кече күләмле әсәрләре белән («Язгы кәрваннар») беррәттән, зур повестьлары да («Әтәч менгән читәнгә», «Җомга көн, кич белән») тәкъдим ителгән. «Үги ана яфраклары» хикәясе белән дәрестә дә танышырга була. Әмма зур күләмле әсәргә күчкәч, дәрестә уку белән өйдә укуны аралаштырырга туры килә, кайбер бүлекләрне өстәмә рәвештә аерым укучылардан сөйләтергә дә мөмкин. Дәрестә туган кызыксынуга нигезләнеп, бөтен әсәрне укып чыгарга киңәш итәргә кирәк була. Әгәр дә дәрес укучыда язучының башка әсәрләрен, бөтен иҗатын белү теләген кузгатса, бу хәл укытучы эшчәнлегенең нәтиҗәле булуы турында да сөйли.

Әсәрне, бигрәк тә өйдә укылганнарны, әдип сүзләре белән мөмкин кадәр төгәл сөйләп чыгу да укучыга күп нәрсә бирә. Чөнки бу очракта ул иң күркәм, мәгънәле, образлы, җанлы тел белән, кайчак лирик, юмористик, музыкаль аһәңле сөйләм белән, кыскасы, оста теле белән очраша. Образлы фикерләү үрнәкләренә язучы булмаган башка бөек шәхесләр дә еш мөрәҗәгать иткәннәр. Автор язганны сөйләп чыгу укучы теленең баюына, егәрен ныгытуга булыша.

Әдәбият программасы Аяз Гыйләҗев иҗаты турында тулы белешмә бирүне күздә тотмый. Укытучы тиешле тапса, язучы турында өстәмә материаллардан файдалана, махсус дәресләр, өстәмә чаралар уздыра ала.

Аяз Гыйләҗев иҗаты киңрәк иңләү нияте белән, программа нигезендә, кайбер әсәрләр һәм иҗаты вариант тәртибендә тәкъдим ителә ала. Берничә әсәрдән кайсысына тукталу укытучы һәм укучылар ирегенә калдырыла, ягъни дәрестә укучы күңеленә хуш килгән әсәрләр өйрәнелә, калганнарын белү мәҗбүри итеп куелмый. Әлбәттә, аларны уку чикләнми. Сайлап алу эшенә укучыларны катнаштыру, фикерләрен исәпкә алу, аларның активлыгын кузгату бик мөһим. Имтиханда укучыга үзе белгән, үзе өйрәнгән иҗат яки әсәр турында сөйләү хокукын бирергә кирәк була.

Хәзерге көндә әдәби әсәрләрне А.Яхин методикасы буенча анализлау өстенлек ала.

Бу методиканың нигезендә укучыга матурлыкны күрсәтү, хис дәрәҗәсен арттыру, әхлак тәрбиясе бирү ята. Ләкин аеруча әһәмиятлесе – ул әдәбият дәресләрендә мөстәкыйль фикер йөртергә күнегә, чөнки эчтәлек табу өчен дәрес саен диярлек әсәрләргә анализ ясый, әдипләрнең сәнгатьчә фикерләү нәтиҗәләрен фәнни фикер алымнары белән өйрәнә. Аяз Гыйләҗев әсәрләрен дә дәрестә А.Яхин методикасы буенча анализлау мөмкинлеге бар. Программада «Җомга көн, кич белән» әсәрен өйрәнү һәм аны структур яктан анализлау бирелгән.

Шулай итеп, мәктәптә Аяз Гыйләҗев иҗатын өйрәнү шактый күләмле итеп куелган. Язучы әсәрләрен традицион методикага нигезләнеп тә, альтернатив дәреслекләргә нигезләнеп тә өйрәнү мөмкин. Монда язучының «Язгы кәрваннар» – VIII сыйныф, «Әтәч менгән читәнгә» – XI сыйныф, «Җомга көн, кич белән» әсәрләре – XI сыйныф, альтернатив дәреслекләр буенча өйрәнү каралган. Беренче әсәр традицион методикага нигезләнеп үзләштерелсә, соңгы ике әсәрен структур яктан анализлау юлы белән өйрәнү мөмкинлеге бар.

**Аяз Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» әсәренә анализ ясау дәресләрен оештыру**

Урта мәктәптә Аяз Гыйләҗевнең 1972 нче елда иҗат ителгән «Язгы кәрваннар» исемле повесте программа нигезендә VIII сыйныфта өйрәнелә. Укып фикер алышу өчен 3 сәгать вакыт бирелгән. Дәресләрне кереш, анализ дәресе һәм йомгаклау (гомумиләштерү) дәресе итеп оештырырга мөмкин.

Кереш дәресне Аяз Гыйләҗев тормышы һәм иҗаты турында укучыларның исендә калырлык итеп оештыру аеруча мөһим. Язучы тормыш юлына һәм иҗатына хас үзенчәлекләр шактый җыела: нахакка гаепләнү, әдәби тәнкыйтьче булу һ.б. Укытучы бу дәрестә истәлекләрдән, өстәмә материаллардан файдалана.

Аяз Гыйләҗев иҗаты буенча кереш дәрес – «әдәби әсәргә карата билгеле бер караш тудыру, шул караш яктылыгыннан әдәби әсәргә үтеп керүне күздә тоткан кереш дәресләр» итеп оештырыла. Әлеге дәрестә укытучы сугыш чоры вакыйгаларына басым ясап анализлауны күздә тотып эш итә. Әдәби әсәр кереш дәрескә кадәр үк укылган була. Укытучының кереш сүзендә Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә сугыш чоры проблемаларының эзлекле, язучының башка әсәрләре белән бәйләнеш уздырыла. Аннан соң, укучыларга анализның алдан максат иткән юнәлешен күздә тоткан сораулар һәм биремнәр тәкъдим ителә. Укучылар әсәрне кабаттан укыйлар, аны беренчел укыганда игътибарга алмаган якларны күрәләр.

Икенче дәрес – анализ дәресе. Анализ дәресе өчен «Язгы кәрваннар» әсәренең тексты «Сайланма әсәрләр» дән алына. Повестенең эчтәлеген, ягъни хикәяләү дәрәҗәсен ачыклау авыр түгел. Повесть, сугышның ахырында көздән язга кадәр вакыт аралыгын иңләп, көз көне җыелган ашлыкны Чаллы элеваторына илтү һәм яз көне чәчүлек орлыкны ерак Кәсле глубинкасыннан алып кайту турында.

Сурәтләү дәрәҗәсендә образларның – сугыш чорында эшне җигелеп тарткан өлкәннәр: Хәкимҗан абзый, Сабирәттәй һәм үсеп килүче, ләкин шулай ук тормыш арбасына җигелгән яшьләр: Ибраһим, Әдилә, Дамир образларының, төрле хәл-вакыйгаларга төрлечә караучы итеп, үзенчәлекле бирелеше игътибарга алына. Авыл кешеләре күп кенә гаделсезлекләр белән очрашалар: көз көне кырып-себереп, ашарга да, чәчәргә дә калдырмыйча, ашлыкны җыялар, атлар күтәрмәдә, инде язын, якында гына солы була торып, 65 чакрымнан кире алып кайтырга кирәк. Яшьләр моның хата, ялгыш булуын кычкырып әйтсәләр, Хәкимҗан абзый башкаларга канәгатьсезлегеңне ишеттерергә ярамаганлыкны аңлый. Ул бер пичәтле кәгазьдәге фәрманны юкка чыгара

торган икенче пичәтле кәгазь алу өчен генә даулаша ала.

Моннан тыш, әсәр шулай ук сурәтләү дәрәҗәсендә күзәтелә торган символларга бай. Чорның шыксыз, ач-ялангач, салкын, рәхимсез булуын белдерүче җил символы, куркыныч көч, явызлыкның янәшәдә генә икәнлеген сөйли торган бүре символы бар. Җыр символы исә шуларга каршы куелган яшьлек-матурлык, изгелек рәвешендә аңлашыла. Җыр беренче тапкыр көзен солы илтүгә бәйле ярдәмче сюжет сызыгында яңгырый, һәм җил басыла, кешеләр турая, күңелләре яктыра. Икенче кат җыр Ибраһим тракторчылар курсына укырга бару турында сөйләгән ярдәмче сюжет сызыгында искә төшә. Ул авылдан, әнкәйдән аерылу сагышын җиңә. Өченче тапкыр Кәслегә бару хакындагы сюжет сызыгында Габбаслар гаиләсенең кешелеклелеген, миһербанлылыгын сөйләгән вакытта телгә алына. Бу урында автор, беренче очрактагы кебек үк, җырның мәгънәсе – башкаларга ярдәм күрсәтү, аларның бәхетле итү омтылышы булуын үзе әйтә. Дүртенче тапкыр Ибраһим сүзләрендә явызлыкка каршы куела: «Син җырлап җибәрсәң, җил дә тынар, бүреләр дә туктар». Шунда ук Әдилә сүзләре аркылы, җырның, язгы су кебек, үз вакытын белеп кузгалуын, һәм җырларга вакыт җиткәнлеге искәртелә. Шушы сурәтләү үзенчәлекләре авторның мөнәсәбәтенә кушылып китә, аны ачып җибәрә. Чорга бәя тәнкыйди: замана җилле, суык, ач, анда гаделсезлек, бүреләр куркытып тора. Ләкин кешеләрнең бер-берсенә терәк, ярдәмче булуы, мәрхәмәтлелеге авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә. Автор геройлары авызыннан шушы язның әһәмиятле, тыныч тормышка бусага икәнен әйттерә.

Өлкән буын үзенең гомере, сәламәтлеге хакына сугышның ахырын – язны якынайткан. Сабирәттәйнең үлеме дә – шушы корбаннарның берсе. Инде дилбегә «Язгы кәрваннар» – яшьләр кулына күчә. Алар – теләсә нинди гаделсезлеккә сизгер, кыю һәм акыллы (автор берничә тапкыр өлкәннәрнең дә яшьләр сүзенә колак салуына игътибар иттерә), эшли һәм үз сүзен әйтә алучы, сөю һәм хыял белән яшәүче буын. Илне сугыш ялангачлыгыннан-явызлыгыннан тыныч, җылы, гадел тормышка бары тик алар гына алып чыга ала, ди автор.

Шулай итеп, әсәрнең идеясен ачыклау, аны анализлау өчен аны бәяләү дәрәҗәсенә төшеп җитәргә туры килә. Ә инде әсәрнең эш барышында табылган сыйфатлары: сугыш темасына яңача – заман үзгәреше ноктасыннан якын килү; җәмгыятьтәге гаделсезлекләрне фаш итү, заманга бәя бирү омтылышы; геройларны бер үк ситуациядә бәяләү-ачу; символларга мөрәҗәгать итү; әсәр исемен эчке һәм тышкы мәгънәгә ия итеп кую; автор фикерен туплаган урыннарны, образларны лирик чигенешләр, язучы уйланулары төсендә кабатлау һ.б. нәтиҗәләр ясарга ярдәм итә. Аяз Гыйләҗевнең сурәтләү осталыгы турында сөйли һәм иҗат стиленең үзенчәлекләре дә булып тора.

Әлеге анализ дәресен проблемалы анализ ясау алымын кулланып та оештырырга мөмкин. Бу дәресләр укучыларда мөстәкыйль танып белү ихтыяҗын арттыра, аларны эзләнүгә этәрә, иҗади эшчәнлекне активлаштыра. Аның асылы шуннан гыйбарәт: проблеманы дөрес сайлап куйган очракта, укучылар тикшерелә торган предмет һәм объектны билгели, гипотезалар китерә, дерес җавап вариантларын сайлап алып гомумиләштерә һем үзләре үк нәтиҗә дә чыгара. Проблемалы анализның тагын бер ягы әһәмиятле: ул, беренчедән, әдәби әсәрне тирәнрәк аңлау һәм бәяләү мөмкинлеге бирә; икенчедән, укучы һәм укытучы арасында хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре урнаштыра, укучының мөстәкыйль эшченлеген үстерә. Әсәрдәге проблемалы анализлау укучыларда өйрәнелә торган чор, андагы вакыйгалар, геройлар һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләр белән зур кызыксыну уята. Бу дәресне уздыру үрнәге беренче кушымтада бирелә.

Өченче дәрес – йомгаклау (гомумиләштерү) дәресе. Бу дәрестә әсәрне анализлаганда туган күзәтүләрне барысын да җыйнау һәм алар арасында эчке бәйләнешләр үткәреп, өйрәнелгән әсәрнең, әйтелгән фикерләрнең бербөтен системасын булдыру тормышка ашырыла. Бу дәрестә укучылардан актив һәм киеренке акыл эшчәнлеген (фикерләүнең конкрет төшенчә һәм образлы элементлары) таләп итәрдәй мәсьәләләр күтәртергә кирәк. Шунлыктан әлеге дәресне гомумиләштерү төрендәге язма эш итеп оештырырга мөмкин. Укучыларга «Сезнең тормыш − үзе батырлык» темасына инша язуны тәкъдим ителә.

Күренекле язучыбыз Аяз Гыйләҗев «Язгы кәрваннар» повестенда тылдагы кешеләрнең күңел матурлыкларын, олы җанлы, киң күңелле булуларын, үзләренең хәле хәл булса да, башкалар турында кайгыртып яшәргә омтылуларын Сабирәттәй, Хәкимҗан абый, Сәрвәр апа, Габбас абыйлар аша сурәтләсә, сугыш та җиңә алмаган яшь җаннарның күңел матурлыгын, мәхәббәтнең, дуслыкның олылыгын Ибраһим, Әдилә, Дамир образлары аркылы безгә җиткерә. Өмет, теләк көчле булганда, яшәү дә матур булачак. Аларның һәркайсының тормышы – үзенә күрә батырлык».

Шулай итеп, VIII сыйныфта Аяз Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» әсәренә анализ ясау дәресләрен 3 сәгать эчендә оештыру мөмкинлеге бар. Кереш дәрестә язучы иҗатына кычкача бәя бирелә, әсәрне укырга җирлек әзерләнә. Икенче – анализ дәресе ике төрле итеп үткәрелә ала: әсәрнең идеясен, сюжетын ачыклау һәм проблемалы анализ ясау юлы аша. Йомгаклау яисә гомумиләштерү дәресендә иҗади эш – инша язу күздә тотыла.

**Йомгак**

Мәктәптә халык күңелендә лаеклы урын алган мөһим эчтәлекле, сәнгатьчә дип табылган әсәрләр өйрәнелә, анализлана.  Классик әдипләр исемлегендә Аяз Гыйләҗев иҗаты һәм әсәрләре дә урын алып тора.

Мәктәптә Аяз Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар», «Әтәч менгән читәнгә», «Җомга көн, кич белән» кебек әсәрләре анализлау өчен бирелә. Укучыларга өйрәнү һәм анализлау өчен материал шактый зур.

Традицион укыту программасында Аяз Гыйләҗев әсәрләрен өйрәнү тарихи-эстетик принципка нигезләнеп сайланган.

Аяз Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» әсәренә анализ VIII сыйныфта ясала. Моның өчен 3 сәгать бирелгән. Әлеге өч сәгатьне кереш, анализ, йомгаклау дәресе итеп оештыру мөмкин. Кереш дәрестә язучы иҗатына кычкача бәя бирелә, әсәрне анализларга әзерлек башлана. Икенче дәрес – анализ дәресе ике яссылыкта үткәрелә.  Беренче юл – әсәрнең идеясен, сюжетын ачыклау. Икенче юлы – проблемалы анализ ясау. Йомгаклау яисә гомумиләштерү дәресендә иҗади эш – «Сезнең тормыш − үзе батырлык» темасына инша яздырыла.

Гыйлемханова Сиринә Мөрсәлим кызы,
Балык Бистәсенең 2нче урта мәктәбе, Балык Бистәсе районы

**Әдәбиятның алтын баганасы**

Син бик усал,ач арыслан кебек,
Усаллыгың җитәр йөз елга
Юаш кына малай идең элек,
Усаллата икән бу дөнья.

**Г.Афзал**

Эшемнең максаты: Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗаты турындагы алган белемнәрне тулыландыру. “Татар әдәбиятының алтын баганасы “– дигән төшенчәгә җавап бирү. Аяз Гыйләҗевнең кодрәтле таланты татар әдәбиятына бик күп үзенчәлекле әсәрләр биргән. Аның иҗаты – көрәшче иҗат. Ул беркайчан такыр юлдан бармаган. Тематик яктан Аяз Гыйләҗевның күпчелек повестьлары авыл тормышына багышланган. Аларда кичәге һәм бүгенге авыл, аның гади кешеләре гәүдәләндерелә.

Аяз Гыйләҗев турында Флүс Латыйфи болай дип яза: ”Аяз Гыйләҗев безнең өчен – зур әдәбиятка чагыштырмача соңрак килгән буын өчен – кул җитмәс биеклек, әдәбият Олимпында борынгы грек аллаларыныкы шикелле үз урыны, үз сүзе булган изге бер зат кебек тоела иде. Әйе, ул елларда әле үзе исән чагында ук әдәбиятыбызның алтын баганаларына – классикларга әверелгән әдипләребез, сәнгатъкәрләребез байтак иде. Без аларның фидаилегенә, фидакарьлегенә, гыйлем вә тормыш дөньясында киң колачлылыкларына, хәтер сандыкларының байлык-муллыгына сокланып, эшчәнлекләренең күпкырлылыгына сокланып карый идек. Соңгы ун-унбиш ел эчендә Нәкый Исәнбәт, Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, БакыйУрманче, Гариф Ахунов кебек бөекләребез фани дөньяны калдырып бакыйга күчкәч, әдәбият-сәнгатьнең тәхет залы бушап калды. Укучыларын бик еш таң калдырырга, көтмәгәндә-уйламаганда яңа әсәре белән шаккатырырга яраткан Аяз Гыйләҗев әнә шул мөбарәк тәсбихның соңгы мәрҗәне булды бугай”.

Минем уйлавымча, Аяз Гыйләҗев “Җомга көн кич белән“ дигән повестен гына язса да, татар әдәбиятына зур өлеш керткән булыр иде. Чөнки Бибинур образы ул чорда бераз гына сәеррәк, бик якты, яңа һәм кабатланмас образ.

Кем соң ул ”татар әдәбиятының алтын баганасы”? ТАССРның, РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык язучысы, Габдулла Тукай, М.Горький исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты – Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев.

Прозаик һәм драматург Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 нче елның 17 нче гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында туа. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. Урта мәктәпне Сарманда тәмамлый.

1948-1950 нче елларда ул – Казан дәүләт университеты студенты. Аңа да шәхес культының газапларын татырга туры килә.Ул 1950 нче елның мартыннан башлап 1955 нче елның августына кадәр Казахстанда тоткынлыкта була. Бары тик 1955 нче елда гына кайтып, университетны тәмамлый.

1957 нче елның мартыннан 1961 елның августына кадәр Аяз Гыйләҗев матбугат эшендә : ”Чаян” һәм “Азат хатын”(хәзер –“Сөембикә”) журналлары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр,”Совет әдәбияты”(хәзер – “Казан утлары”) журналында проза бүлеге мөхәррире вазифаларын үти.

1961-1963 нче елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укып кайтканнан бирле Аяз Гыйләҗев, язучы-профессионал сыйфатында, әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә. Аяз Гыйләҗевның башлангыч иҗат тәҗрибәләре студентлык чорына карый. Ләкин аның актив иҗат эшчәнлеге 1956 нчы елдан башлана дияргә була.

“Алтын багана“ – ул минем уйлавымча да, (бу очракта татар әдәбиятында) бик күркәм, затлы, мәртәбәле урын тоткан шәхес. Аның әсәрләре татар әдәбиятына яңа сулыш өрде. Моңа кадәр бер тапталган юлдан язылган әсәрләрнең, никадәр тормыштан аерылган, идеальләштерелгән икәнен аңлаган укучы , язучының әсәрләрен көтеп алынган бүләк кебек кабул итте. Суга сусагандай йотлыгып укыды аларны татар. Укып кына

түгел, уйланырга, чагыштырырга, хыялланырга мәҗбүр итте язучы. Гыйләҗевның тормыштан алынган геройлары, безнең кебек үк гөнаһлы җир кешеләре. Әсәрнең беренче битен укыгач та, геройларны үз итәсең, аларның тормышы белән яши башлыйсың. Андагы образлар белән үзең дә сизмәстән, вакыйгалар өермәсенә килеп керәсен. Читтән караганда күренә бит: геройларны хата ясаудан, усал сүзләрдән саклыйсы килә. ”Мин булсам бүтәнчә эшләр идем“, - дип хыялланып та аласың әле. Әкияттәге шикелле, сарык та исән, бүре дә тук була алмый шул. Тормыш булгач, югалтулар да, кайгы-хәсрәтләр дә була. Һәм нәкъ шулай яза да Аяз Гыйләҗев, нәкъ тормыштагыча, үзебезчә.

Яшь чагында дөньяны бик аңлап җиткермисең бит әле. Кайсы гамәлнең дөрес, кайсысы ялган икәнен дә белмисең. Безгә олылыр әйтә торган иде: ”Күкәй эчендәге сары бит әле сез”, - дип. Менә шул “сары”ларга дөнья күтәргә каласы бит. Ул вакытларда Партия Үзәк комитеты җитәкчеләре кушканча язган язучыларның әсәрләрендә тормыштагы вакыйгалар тулысы белән яктыртылмый иде. Ниндидер бездән аерылган тормышта яши иде ул әсәрләрдәге геройлар. Безне менә шушы геройлар образына тиң булыгыз дип өйрәтәләр иде. Мәсәлән, Павлик Морозов образы. Ул үзенең атасын советларга саткан малай. Яшьләргә үрнәк булырлык кыю, уңай образ. Мин үзем шулай уйлый идем. Менә шулай тәрбияләнгән яшьләргә Гыйләҗевнең китабы яңа ачыш булды. Геройлар безнең шикелле гади, вакыйгалар безнең авылдагы кебек, кешеләре чын тормыш белән яшиләр.

**Бибинур образы**

Мин аның “Җомга көн кич белән” әсәре белән 9-10 классларда укыган вакытларда таныштым. Китапның чыккан вакытында ук. Моңа кадәр татар телендә шундый тормышчан, яңача эчтәлекле китап укыганым булмаганга күрә, повесть минем күңелдә эз калдырды.

Әсәрдәге Бибинур образы бөтенләе белән мине әсир итте. Олы яшьтәге хатын-кызга мәхәббәт бик соңарып килә.”Соң булса да, уң булсын“, - дигәндәй, унсигез яшьтәге кызларга әйләнә, бер карауда гашыйк булган Бибинур. Хәер, әүлия шикелле кешегә мәхәббәт килмәсә, бик аяныч булыр иде. Ул гомер буе кеше өчен яшәгән, үзенә авыр булса да,тешен кысып түзгән. Үлгәнче дөньяда бурычым калмасын дип яшәгән әби, ни өчен килгәнен дә белә бугай. Бибинур – дөньяга бәхет өләшер өчен туган җан. Авылдагы хатыннар сыман гайбәт сөйләмәгән, кеше бәхетеннән көнләшмәгән, өч ятимә бала тәрбияләп, бала рәхәте күрмәсә дә, рәнҗи белмәгән кешене әүлия дими ни дисең!? Яшь кыз бала өч баланы үзенеке дип кабул итә, аларга җил-яңгыр тидерми үстерә, кеше итә.Тик балалары аны хөрмәтләү урынына елга бер тапкыр да Аналары янына кайтып, хәлен белмиләр. Бик ояла алар өчен Бибинур, ләкин кешедән балалары турында начар сүз әйттерми. Аларга авырлык килмәсен дип йөреп, гомере дә өзелә.

Бу очракта укучы автор белән килешмәскә дә мөмкин, ни өчен яхшылык җиңелә? Беркайчан да начарлыкка начарлык белән җавап кайтармаган Бибинур ни өчен этләргә талана? Мин бу кешегә андый үлем теләмәс идем. Акылга “утырган” балалары кулында җан тәслим кылсын иде әби. Дөньяда барыбер начарлыкны яхшылык җиңә дип әйтер идек. Ләкин барысы да автор кулында, әсәрнең отышы да бәлки шул аянычлы үлемдәдер. Авылдашлары барыбер Бибинурны онытмаслар, аны хөрмәт белән искә алырлар. Нарат башындагы яулык та, Бибинур йөрәге шикелле ялкынланып, әллә кайдан янып торыр. Авыл халкы кызыл комач яулыкны Бибинурның төсе итеп шунда калдырыр дип телисе

кала. “Җомга көн кич белән” повесте өчен Аяз Гыйләҗев 1983 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Аяз Гыйләҗев 74 яшендә дөнья куя. Сиксәнне тутырган булса да, матур, тормышчан әсәрләр иҗат иткән булыр иде дип уйлыйм. Иртәрәк киткән икән шул олпат язучыбыз. Аның үзе турында язган шундый сүзләре бар: “Хәзер дә тормыш белән бәйләнешне ычкындырмаска тырышам. Ел саен диярлек үз авылыбызга кайтам, башка төбәкләргә чыгам, йөрим.Тормыш агышыннан ычкынып төшеп калмаска кирәк. Барыбыз да шуңа омтылабыз. Тормыштан артта калмас өчен, аның хәрәкәтен генә түгел, үзгәрмәс кыйбласын да яхшы белергә кирәк! Тормыш шартлары, яшәү күренешләре көнләп-сәгатьләп үзгәреп торса да, бу бөек төшенчәләр –мәңгелек, һәм шушы мәңгелеккә тугры кешеләр генә үзгәрешләрне халык белән бергә сиземли алалар”.

Менә ни өчен аның әсәрләре халыкчан, кыйбласы халык кыйбласыннан аерылмый. Иртәме соңмы тотолитар режим бетеп, язучы чын мәгънәсендә ирекле кеше булыр дип ышанган остазыбыз.

Гыйльфанова Ильмира Альберт кызы,
Сарман гимназиясе, Сарман районы

**Нәниләрнең хыялы. (А.Гыйләҗев “Суык” хикәясе)**
**3 класста әдәби уку дәресе эшкәртмәсе**

**Тема**: Нәниләрнең хыялы. (А.Гыйләҗев “Суык” хикәясе)

**Максат**: А.Гыйләҗевнең “Суык” хикәясенең эчтәлеге белән таныштыру; күп белергә омтылыш тәрбияләү.

**Универсаль уку гамәлләре (УУГ)**

**Танып белү (**ТБУУГ): анализлау, чагыштыру, классификацияләү, гомумиләштерү.

**Регулятив (**РУУГ): үз эшеңә бәя бирә белү.

**Коммуникатив (**КУУГ): тормыш тәҗрибәсен куллану.

**Шәхси** ( ШУУГ): эш гамәлләрне бәяләү, кызыксындырулы бәяләүне аңлату

**Бурычлар:** Нәниләрнең хыяллары ни өчен өлкәннәрнекеннән аермалы булуының сәбәпләрен аңлату; хикәя һәм экиятләрдә уйлап чыгарылган вагыйгаларның төрле максатларда кулланылганын ачыклый алу күнекмәсен ныгыту; үзләреннән кечерәкләргә ярдәмчел, игътибарлы булуларына ирешү.

**Материал:**дәреслек 1нче кисәк (89-96 нчы битләр)

**Җиһазлау**: А.Гыйләҗев портреты, термометр, презентация.

**Предметара бәйләнеш**: әйләнә-тирә дөнья

**Эш формалары**: эзләнүле, фронталь, индивидуаль,парларда.

**Дәрес барышы**

**I. Дәресне оештыру. Мотивация.**

- Исәнмесез,- диеп башлыйм әле,

Дәресебез шулай башлана.

Сезнең белән очрашканга, дуслар,

Күңлем минем чиксез шатлана.

- Хәерле көн, укучылар! Серле һәм мавыктыргыч дөнья- хыял дөньясына сәяхәт итәргә сез әзерме?

**II. Актуальләштерү.**

- Укучылар, карагыз әле тәрәзәгә, урамда елның кайсы вакыты? *(Урамда кыш)*

- Дөрес әйтәсез, урамда салкын кыш. Ләкин шуңа да карамастан, без сезнең белән боекмыйбыз, ә эссе кояшлы җәйне искә төшерербез.Әйдәгез әле, өй эшенә бирелгән хикәяләрнең берничәсен тыңлап китик (Балалар “Җиләк җыйганда” дигән хикәяләрен укыйлар).

- Молодцы, балалар! Бик матур һәм эчтәлекле хикәяләр язгансыз.

**III. Уку мәсәләсен куюю ситуциясе тудыру.**

- Укучылар, без бүген сезнең белән нәрсә турында сөйләшербез микән? Мин сезгә табышмаклар әйтәм, ә сез уйлап карагыз әле.

1. Аягы юк, кулы юк, үзе сүрәт төшерә. (суык)
2. Кулсыз, күзсез, буяусыз ясый ул төрле бизәк

Беркем өйрәтми аны,ул үзе шундый зирәк. (суык)

**IV. Уку мәсьәләсен чишү.**

- Әйе, дөрес, бу суык. Дәреслекләрнең 89нчы битен ачыгыз һәм без укыйсы хикәянең исемен укыгыз.

- Бүген без сезнең белән Аяз Гыйләҗевнең “Суык”дигән хикәясе белән танышабыз. Кем соң ул, Аяз Гыйләҗев? Танышып китик әле. (А.Гыйләҗев биографиясе һәм иҗаты белән презентация ярдәмендә таныштыру).

- Балалар, Аяз Гыйләҗев турында үзегезгә нинди яңа мәгълүматлар белдегез? (ул Сарман районында туган, шунда укыган).

- Дөрес, балалар. Кире хикәягә әйләнеп кайтыйк, хикәянең исеменнән сүз нәрсә турында барганын аңлап буламы? (Суык турында)

- Чыннан да суык турында бара микән сүз? Без шушы сорауга хәзер сезнең белән җавап эзләрбез.

**V. Яңа материалны аңлату.**

1. Чылбыр буенча хикәянең беренче өлешен уку
2. Сораулар буенча эш: Хикәянең беренче өлешен укыгач, сүз суык турында бара дип әйтә алабызмы? Ни өчен? Хикәядә сүз кем турында бара? Искәндәргә ничә яшь дип уйлыйсыз? Аның бик бәләкәй малай икәнен кайсы юллардан аңлап була? Шул юлларны табып укыгыз.

Термометр Искәндәрне нәрсәсе белән кызыктыра? Малай термометрны нәрсә белән чагыштыра? Бу бүлектә ничә герой катнаша?

“Әйләнә-тирә дөнья” дәресендә термометр турында алган мәгълүматларны искә төшерү. Термометрны ватарга ярыймы? Ялгыш ватылган очракта нишләргә кирәк?

Хикәянең икенче һәм өченче өлешен чылбыр буенча уку.

**VI. Ял минуты**

Матур сүзләр уйладык
Ял итәргә туктадык.
Җилкәләрне турайттык,
Тирән итеп суладык,
Башны як-якка бордык,
Чүгәләдек һәм тордык,

Бер урында йөгердек,
Аннары соң сикердек.
Сузылдык –киерелдек.
Югарыга үрелдек.
Соңыннан тынычланып
Шөгыльне дәвам итик.

**VII. Белемнәрне беренчел тикшерү**

1.Парларда эш

“Искәндәр-бик бәләкәй малай” темасына парларда сөйләшү (берничә укучының фикерен тыңлау)

2. Хикәядә ничә герой катнашуын ачыклау.

- Сез ничек уйлыйсыз, бу хикәядә ничә герой бар? Алар кемнәр? Тискәре геройлар бармы? Искәндәрнең әбисе нинди холыклы?

**VIII. Өйрәнгәннәрне ныгыту күнегүләре.**

1. Укыган өзекләргә исем кую.
2. 90 нчы биттәге рәсем буенча әңгәмә оештыру
3. Дәреслектәге рәсем хикәягә туры киләме?
4. Рәсемдә кем сүрәтләнгән?
5. Сез Искәндәр турында ниләр әйтә аласыз? Аны мәрхәмәтле бала дип әйтеп буламы? Шуны дәлилләгән юлларны табып укыгыз.
6. Искәндәр нинди хата ясаган?

Дару үләннәрен җыю кагыйдәләрен искә төшерү

7. Искәндәр авыргач әбисе аны нәрсә белән дәвалый?
8. Мәтрүшкә үләне турында сез нәрсәләр беләсез? Тагын нинди дару үләннәрен беләсез?
9. Дару үләннәрен җыю кагыйдәләрен искә төшерик әле. (слайдлар)

**IX. Дәрескә йомгак. Рефлексия.**

Хикәя сезгә ошадымы? Хикәяне укыгач, үзегезгә нинди сабак алдыгыз?

Дәрестә биргән җавапларыгыз белән сез канәгатьме? Үзегезнең эшчәнлекне “Светофор” билгеләре белән билгеләгез (кызыл, сары, яшел төстәге түгәрәкләр беркетү).

**X. Өй эше.**

Өй эше 3 дәрәҗәдә тәкъдим ителә: Хикәянең үзеңә ошаган өлешенең эчтәлеген сөйләү. Хикәягә рәсем ясау. “Минем белән булган кызыклы хәл” темасына кечкенә хикәя язу.

Садриева Гөлнара Миңнулла кызы,
Баек төп гомуми белем бирү мәктәбе, Мөслим районы

## Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән”әсәрендә автор позициясе һәм повестьның сәнгати үзенчәлекләре
## (Дәреснең технологик картасы)

| | |
|---|---|
| **Укытучы** | Садриева Гөлнара Миңнулла кызы |
| **Предмет** | Әдәбият |
| **Тема** | Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” әсәрендә автор позициясе һәм повестьның сәнгати үзенчәлекләре. |
| **Сыйныф** | 9 нчы сыйныф, татар төркеме |
| **Дәреснең тибы** | Катнаш дәрес |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | **Предмет**- әсәрнең сюжет- композиция үзенчәлеген ачыклый белү, тулы эчтәлеген аңлау.<br>**Метапредмет** – анализ ясау күнекмәләрен камилләштер, сәбәп- нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру, гомумиләштерүләр ясый белү.<br>**Регулятив**-әсәрнең төзелешен ачыклау,геройның эш-гамәлләрен бәяләгәндә, үзеңнең, башкаларның фикерен белү,төп нәтиҗәне чыгарганда активлык күрсәтү.<br>**Танып белү**- белемнәргә таянып, әсәрдәге төшенчәләргә кагылышлы мәгълүмат табу, анализлау аша аны бәяләү, гомуми нәтиҗә чыгару.<br>**Коммуникатив**- башкаларның җавапларын тыңлау, үз фикереңне дәлилли белү.<br>**Шәхескә караган**- әсәрдәге вакыйгалардан үрнәк яисә гыйбрәт алу. |
| **Предметара бәйләнешләр** | Татар теле, тарих |

| | |
|---|---|
| **Чыганаклар** | Уку Әсбабы: Әдәбият.9сыйныф:татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен.2 кисәктә /Ә.М.Закирҗанов,Г.М.Фәхретдинова. - Казан: Татар.кит.нәшр.2015 |
| **Эшне оештыру** | Фронталь,төркемдә, парларда, индивидуаль |
| **Төп төшенчәләр** | Парадокс,символик образлар, конфликт, композиция, сюжет |
| **Педагогик технология** | Өлешчә тикшеренүгә корылган проблемалы укыту |

**Дәреснең барышы**

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучылар эшчәнлеге** |
|---|---|---|
| **Мотивлаштыру-ориенлаш-**<br><br>**тыру.Уңай психологик халәт һәм эш атмосферасы тудыру** | Укучыларны уку эшчәнлегенә тарту.<br>Исәнмесез.Укучылар, экрандагы язуга игътибар итик әле.<br>“Ана алдындагы иң изге бурычны оныту ул - кешелексезлек” Әлеге сүзләрне сез ничек аңлыйсыз?<br>1.Әлеге әсәр белән бу сүзләрнең уртаклыгы нәрсәдә? | Җаваплар:<br>1.Кешегә бәя ата –анасына карата булган мөнәсәбәттә күренә.<br><br>2.Бибинурның үстергән балалары аны онытาлар.<br>4. Әсәр белән әлеге сүзләрнең уртаклыгы - Бибинурга карата кешелексезлек күрсәтәләр, картайган көнендә оныталар дип уйлыйм мин. |
| **Белемнәрне актуальләш-терү.Алдагы дәреснең уку мәсьәләсен искә төшерү,**<br>**Өй эшләрен тикшерү** | Укучыларның белем дәрәҗәләрен, өй эшененең катлаулы урыннарын ачыклау.<br>1.Вакыйгалар кайда бара?<br>2. Әсәрнең төп герое кем?<br>3.Бибинур карчык образы сездә нинди хисләр уятты?<br><br>4. Бу әсәрдә автор позиөтясе. | "Сарман" көе тыңлау, шушы яктан чыккан күренекле шәхесләрне атау.<br><br>1.Әсәрдә вакыйгалар Аксыргак авылында бара.<br>2. Бибинур карчык.<br>1.Бибинур гап-гади авыл хатыны. Күңел дөньясы, кешеләргә мөнәсәбәте белән башкалардан аерылып тора.<br>2. Кеше турында кайгырта, үзен оныта.<br>3.Габдуллаҗан балаларын тиккә үстергәнен аңласа да күңеле белән кабул итми. Матур кеше<br>4.Туганы Зөһрәбануга да начар мөнәсәбәттә түгел.Кичерә дә белә, ачу саклау да юк.Әхлагы да ныклы.Безгә өлге булырлык.<br>5.Кеше күңелен аңлый.Үзенә ясаган яхшылыкны онытмый.<br>Җиһангирның ялгыз күңеле Бибинур карчык күңеле белән тәңгәлләшә. Бибинур моны бик яхшы аңлый |
| **Проблемалы ситуация булдыру.**<br>**Уку мәсьәләсен кую һәм чишү** | Укучыларны белемнәрен активлаштыра, проблемалы ситуация тудыра, нәрсәне белмәгәнне ачыкларга ярдәм итә, өстәмә мәгълүмат бирә.<br>1.Әсәрнең сюжетына салынган вакыйгаларны кыска гына сөйләп чыгыгыз.<br>2. Автор нинди проблемалар күтәрә?<br><br><br><br><br><br><br>Ни өчен балалар ата-аналарга карата каты күңелле?<br><br>Китап укучы белән автор нәрсә турында сөйләшәләр<br>Төп идеяне ничек билгеләр идегез? | Укучылар.<br><br><br><br><br>Укучылар.<br><br>1. Бибинур искмле гап-гади бер авыл хатыны турында.<br>2. Ил тарихы турында.<br>3. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр турында.<br>Дәреснең темасын формалаштыралар<br>Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән”әсәрендә автор позициясе.Повестьның сәгати үзенчәлекләре.<br>Балалар һәм ата-аналарҖәмгыятьтә гаилә мөнәсәбәтләренең үзгәрә баруы<br><br>Балаларның каты күңелле булып үсүләре.Кешеләрнең битарафлыгы.<br>Әхлак кагыйдәләре бозылу һәрвакыт олы фаҗигагә китерә, ди язучы.<br>Геройлар язмышы аша кешене тәрбияли.Яшәргә өйрәтә, тормыш авырлыклары |

| | | |
|---|---|---|
| | Автор позициясен аңлатыгыз<br>3.Сюжетны ни өчен тармакландыра?<br>Парадокс – күпчелек тарафыннан кабул ителгән, күзаллауларга кискен рәвештә каршы булган, кеше ышанмаслык булып тоелган фикер яки күзаллау.<br>Повестьның сәнгати эшләнеш үзенчәлекләрен билгеләгез . | алдында куркып калмаска өнди.<br>Үзеңне яратырга, кеше турында гына уйламаска өйрәтә.<br>Кешелексезлек, битарафлык кебек күренешләрнең тормышта еш очравын искәртә<br><br>Язучы стиленең бер үзенчәлеге.<br>“Ни өчен шулай булды?”<br><br>Бибинур тормышына метафора булып тора. |
| **Уку мәсьәләсен өлешләп чишү** | 1. Буа тавышы нәрсәгә хезмәт итә?<br><br><br><br>2.Образларны тулырак ачу өчен нинди алымнар кулланыла?<br><br>3.Язучы вакыйгаларны төрле геройлар тарафыннан сөйләтә, ни өчен?<br><br>4.Бибинур образы сезгә кемне хәтерләтте, тормышта мондый кешеләрне очратканыгыз бармы? | Тормышы тыныч булса, тавыш ишетелми.Бибинур күңел тынычлыгын җуйганда ишетә.Иркен аккан елга хәзер буылып куелган.Җиһангир образы белән дә бәйләп әйтеп була<br><br>1.Әсәрдә психологизм көчле.<br>2.Бибинурның күңел халәте.<br>3.Шатлыклы һәм хәсрәтле чагы.<br>1.Күпме кеше, шуның кадәр фикер дигән, әйтем бар.Бу очракта да шулай.<br>2.Автор персонажга әйләнеп, әсәрдә барган вакыйгаларга бәя бирә башлый.<br>3.Язучы хикәяләү аша, укучысын тәрбияли башлый. |
| **Ял моменты** | Татар халык бию көе куела, туктатып, җавабы сан булган сораулар бирелә.<br>Песинең ничә аягы бар? Кеше ничә бияләй кия? Өчпочмакның ничә почмагы бар? | Бию, көй туктау белән парлашу(өчәү, дүртәү) басу.<br><br>Парсыз калучыларның уеннан чыгуы. |
| **Мөстәкыйль эш.**<br><br>**Эш –гамәлләрнең дөреслеген беренчел тикшерү** | А.Гыйләҗевнең сурәтләү үзенчәлекләрен гомумиләштереп бәяләгез. | Кырыс реализм методы белән яза, әсәрләре халыкчан образларга, сурәтләү алымнарына бай.Кайсы чор турында һәм нинди темага язса да, кешенең катлаулы рухи дөньясын, эш гамәлләрен анализлый. |
| **Рефлексия,дәрес-нең нәтиҗәләре, бәяләү,үзбәя** | Нинди уку максаты куелды,максатыбызга ирештекме? | Үзләренең эшләренә бәя бирәләр |
| **Өй эше** | Повестьның пейзажны билгеләгән урыннарны табып укырга.Аяз Гыйләҗев стиле нәрсә ул? | |

Тимергалиева Илсөя Рифкать кызы,
Яр Чаллы шәһәренең 54 нче гимназиясе

**Аяз Гыйлажевнең 90 еллыгына багышланган класстан тыш чара**

**Максат:** Балаларны язучы Аяз Гыйлаҗевның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру.Укучыларның сәнгатьле укуларын оештыру.Укучыларда туган телгә карата ихтирам, мәхәббәт хисе тәрбияләү.

Планлаштырылган УУД: **Шәхескә кагылышлы:** үз төбәгеңнең атаклы шәхесләренең иҗатын өйрәнү теләге формалаштыру.

**Танып-белү УУГ:** Укытучының сорауларына тулы һәм дөрес җавап бирү.

**Регулятив универсаль уку эшчәнлеге**: Укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү.

**Коммуникатив УУГ:** -Башкаларның сөйләвен аңлап тыңлау. Дәрестә һәм тормышның төрле чакларында әңгәмә кора белү. Сөйләм этикасын үтәү: исәнләшү, саубуллашу, рәхмәт әйтү.

**Җиһазлау:** Язучының портреты, әсәрләреннән китап күргәзмәсе, презентация .

Дәрестән тыш чараның планы

I.Оештыру.

Исәнләшү, укучыларны барлау.

II. Төп этапта булачак актив эшчәнлеккә әзерлек.

1. Тактадагы сүзләргә игътибар иттерү.
2. “Кем ул Аяз Гыйләҗев?”соравына җавап табу.

III. Төп өлеш.

1. Укучыларга максатны җиткерү.
2. Язучы Аяз Гыйлаҗевның тормыш юлы турында информация бирү.
3. Презентация күрсәтү.
4. Язучының иҗаты турында мәгълүмат бирү.
5. Аяз Гыйлаҗевның татарлар өчен язылган киңәшләрен уку, анализлау.

IV. Йомгаклау һәм кире информация .

1. Сораулар бирү.
2. Нәтиҗә ясау, йомгаклау.

Чара барышы

I.Оештыру.

- Исәнмесез, укучылар. Утырыгыз.

II. Төп этапта булачак актив эшчәнлеккә әзерлек

Укытучы: Укучылар, әйдәгез игътибарны тактага юнәлтик. Берегез теманы укыгыз әле. Кем ул Аяз Гыйләҗев? (Көтелгән җавап: язучы )

-Димәк, безнең бугенге тема кемгә багышланачак? (Көтелгән җавап: язучы Аяз Гыйләҗевкә)

Укытучы. Тагын бер тактага игътибар итегез әле? Бу даталар турында сез нәрсә әйтә аласыз? (Көтелгән җавап: бу язучының туган көне).

Укытучы.Укучылар, әгәр дә Аяз ага исән булса, аңа быел ничә яшь булыр иде? (Көтелгән җавап: 90).

Укытучы. Әйе, быел Аяз Гыйләҗевнең тууына 90 ел.

III. Төп өлеш.

Укытучы. Сез язучы турынданиләр белергә теләр идегез? (Көтелгән җавап: язучының кайда, кайчан тууы, кайда яшәве, нинди әсәрләрләр язуы).

Укытучы. Күренекле прозаик, драматург, халык язучысы ул –Аяз Гыйләҗев.Кем соң ул драматург? (Көтелгән җавап: спектакль, театр өчен әсәрләр язучы. Прозаик сүзенә аңлатма бирү).

Укытучы. Мирсәет улы Аяз Гыйләҗев 1928 нче елның 15 гыйнварында Сарман районы Чукмарлы авылында туа. (1нче слайд). Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. Шул авыл мәктәбенең тугыз классын һәм Сарман урта мәктәбендә ун класс тәмамлый. Әтисе Мирсәет, әнисе Мөгәттәрә укытучылар булалар. Алар өч бала тәрбияләп үстерәләр: Алмаз, Аяз һәм Азат. (2нче слайд). Тик Аяз аганың тормыш юлы җиңел генә булмый. 1948 нче елда ул Казан

университетына укырга керә. Тик озакламый университетны ташлап яңадан авылына кайта. Моның төп сәбәбе: ачлык, ялангачлык.

Аяз аганың тормышында иң авыр чор ул –1950-1955 еллар. Бу елларны язучы Казахстан далаларында, Сталин концлагерьларында уздырырга мәҗбүр була. Ни өчен? Бары тик әсәрләрендә чагылган, шул чор режимына бик үк туры килеп бетмәгән үткен фикерләре өчен. (3 нче слайд.)

Казакъстанда төзелештә ташчы, бетон коючы, бригадир һәм десятник (сүзгә аңлатма бирелә) профессияләрен үзләштерергә туры килә. Ул бу чорда бик күп кызыклы шәхесләр белән таныша, бик күп гыйбрәтле язмышлар аның күз алдыннан уза, кыскача ул сөргендә вакытта үзенең әсәрләре өчен бик күп материал тупларга өлгерә. Аннары, яңадан Казанга кайтып, университетта укуын дәвам иттерә.

Аяз Гыйлаҗев, азат булып туган якларына кайткач, Нәкыя исемле кыз белән өйләнешәләр. Бер-бер артлы өч уллары туа. (4 нче слайд.)

Искәндәр – профессор, Мансур – язучы, драматург, ә Рәшат – табиб, эшмәкәр. Аяз ага уллары белән бик горурлана.

Аяз ага Гыйләҗев безне һәрчак татар телен, ана телен онытмаска, белергә, үз телеңдә сөйләшергә өнди. “Мин милләттәшләремдә, җирдәшләремдә, замандашларымда ...Туган илгә мәхәббәтне кайтарырга телим...”- дип яза ул. (5 нче слайд)

- Менә ул, язучының безгә җиткерергә теләгән киңәшләре: (Сүз балаларга бирелә).

1нче укучы.Иң беренче – үз телеңне камил бел! Аңа зур хөрмәт белән кара, башкаларны шуңа өйрәт. Онытма: Синең Телең – дөньдагы иң камил, иң бөек үндүрт телнең берсе.

2 нче укучы. Җиде буын бабаларыңның исемен бел, шәҗәрәсен сакла, алга таба балаларыңа һәм оныкларыңа калдыр. Бабасын оныткан – алдагысын оныткан!

3 нче укучы. Атаң – анаң сүзеннән чыкма, аларны санла һәм шәфкатьле бул. Картайган көннәрендә ярдәм ит. Туганнарыңны, якыннарыңны ташлама. Атасын сүккән – аңсыз калган!

4 нче укучы. Күп белергә тырыш, күп укы, югары белемгә омтыл. Һич тә намусыңа тап төшермә, исемең – атың белән рәттән чиста, тәртипле, берсүзле, ышанычлы, белемле, яхшы күңелле, акыллы, тургылыклы, талантлы, иманлы дигән Изге Сүзләрне куярлык булсын.

5нче укучы. Үз халкыңның үткәнен бел, аның чын тарихы белән кызыксын. Өйрән һәм башкаларга да шуны сөйлә. Үткәне юкның – киләчәге дә юк!

6нчы укучы. Башкаларга түбәнсетеп карама. Дөньядагы барлык милләтләрне хөрмәт ит, аларның теленә, культурасына, йолаларына, гореф-гадәтләренә ихтирам белән кара. Булдыра алсаң, берничә чит тел өйрән. Үзен яратканның күзе – көзгедә, башканы яратканның – башкаларның йөзендә!

Укытучы. Иҗатына килгәндә, проза өлкәсендә, драматургия өлкәсендә дә зур уңышларга ирешкән язучы. "Өч аршын җир", "Зәй энҗеләре", "Урталыкта", "Язгы кәрваннар", "Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят", "Җомга көн кич белән", "Әтәч менгән читәнгә" әсәрләре белән Аяз Гыйләҗев үзен повестьлары белән танылган ул. Драма әсәрләре, төрле театр сәхнәләрендә уйналынган.(6 нчы слайд).

Аяз ага бик күп очрашуларда катнашкан, төрле конференцияләрдә чыгыш ясаган, бик күп яшь язучыларга акыллы кирәкле киңәшен әйткән остаз да. Ул хатлар язарга

яраткан. (7 нче слайд: каләмдәшләре, фикердәшләре, чордашларының белән төшкән фотосүрәт).

Укытучы. Әлбәттә инде аның иҗаты үз бәясен ала. “Җомга көн, кич белән”, “Әтәч менгән читәнгә” повестьлары өчен Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә, русча тәрҗемәдә Казанда басылган “При свете зарниц” исемле китабы өчен РСФСРның Максим Горький исемендәге дәүләт бүләгенә лаек була. Мирсәет улы Аяз Гыйләҗев – “Татарстан Республикасының халык язучысы”. Аяз Гыйләҗевнең “Йәгез, бер дога!” автобиографик романы венгр теленә тәрҗемә ителеп бастырылган. Күп кенә китаплары төрле телләргә тәрҗемә ителгән. Аның драма әсәрләре буенча куелган спектакльләр бугенге көндә дә зур театр сәхнәләрендә уйнала.

2002 нче елның 13 нче мартында ул вафат булды. Быел Аяз ага Гыйләҗевнең тууына 90 ел.

IV. Йомгаклау һәм кире информация.

Укытучы. Мин сезгә хәзер сораулар бирәм. Сез җавап бирерсез. Дөрес сораулар өчен жетоннар бирелә. Тест

1. Аяз Гыйләҗевнең әтисенең исеме язылган рәтне күрсәтегез:

а) Мияссәр ә) Мирсәет б) Миңлегали

2. Язучының балачак еллары кайда уза?

а) Зәй районында Югары Баграж авылында ә) Балык Бистәсе районында Котлы Бөкәш авылында б) Минзәлә районында Бикбау авылында

3. А.Гыйләҗев 10 нчы сыйныфны кайда тәмамлый?

а) Сарман районы Сарман урта мәктәбендә ә) Актаныш районы Актаныш урта мәктәбендә б) Арча районы Арча урта мәктәбендә

4. Ул КДУга укырга керә.

а) 1946 нчы елда ә) 1948 нче елда б) 1945 нче елда

5. А.Гыйләҗев ничәнче елларда Казахстан далаларына озатыла?

а) 1949 нчы елда ә) 1950 нче елда б) 1951 нче елда.

Укытучы. Димәк, балалар, кем соң ул Аяз Гыйләҗев? (Көтелгән җаваплар: язучы прозаик, драматург, М.Горький һәм Г.Тукай премияләре лауреаты, халык язучысы).

Укытучы. Без сезнең белән алдагы әдәби уку дәресләрендә Аяз аганың “Суык” әсәре белән танышырбыз. Ә хәзергә чарабыз тәмам. Бер-беребезгә рәхмәт әйтик.

Шәрифуллина Румия Рифгать кызы,
Песәй урта мәктәбе, Менделеев районы

**Аяз Гыйләҗев әсәрләрен продуктив уку технологияләренә таянып өйрәнү**

Безне, укытучыларны, борчыган мәсьәләләрнең берсе – укучыларыбызның әдәби китаплар укуга карата кызыксынулары кимү, татар әдәбиятының күренекле шәхесләрен белмәү, текстны аңлап укымау, аннан тиешле мәгълүматны аерып ала алмау. Бүгенге көндә без иксез-чиксез мәгълүмат дөньясында яшибез. Мәгълүмат дөньясына кереп чумган балага кирәкле фактларны дөрес сайлап алу һәм үз эшчәнлегендә дөрес файдалана белү бик зарур. Сер түгел, күп кенә чыгарылыш сыйныф укучыларыбыз дәүләт йомгаклау аттестациясен узганда да шундый кыенлыкларга очрыйлар: төп фикерне ачыклый белмиләр, язучының тел үзенчәлекләрен күрмиләр, аерым биремнәрне башкара алмыйлар. Сәбәп нидә соң? Бәлки бу безнең укыту методикасына да бәйледер... Шулай булгач, без

сезнең белән нәрсә турында сөйләшербез? (Җаваплар). Без күбебез традицион методикага нигезендә укытабыз. Әйтик, әдәби уку дәресләрен үткәргәндә, түбәндәгечә эш итәбез.

Укучыны текстны үзләштерергә әзерлибез:

а) язучы турында әңгәмә үткәрәбез;

б) сүзлек эше (үзебез кыен дип санаган сүзләрнең мәгънәләрен аңлатабыз);

в) үзебез сәнгатьле итеп укып күрсәтәбез.

Менә шуннан соң гына укучыларга сүз бирәбез. Алар кычкырып укыйлар,

укытучы биргән сорауларга җавап бирәләр. Укучылар өчен бернинди дә кызык юк, алар текст белән эшләүдән канәгатьләнү алмыйлар.

“Кешегә балык бир, ул бер көн тук була, син аны балык тотарга өйрәт – ул көн дә тук була” дигән гыйбарә күбебезгә таныш. Шулай булгач, текст белән эшләүнең яңа методикаларын кулланып карарга кирәк. Шундый отышлы технологияләрнең берсе – продуктив уку технологиясе, Бунеев һәм Бунееваларның текст белән эшләү технологиясе (профессор Н.Н. Светловская методикасы). Әлеге технология текстны дөрес аңлап уку эшчәнлеген оештырырга ярдәм итә. Аның төп максаты – тексттан тиешле мәгълүматны табу. Текст белән эшләү 3 этаптан тора:

I этап. <u>Текстны укыр алдыннан эшне оештыру.</u> Бу этапның максаты: укучыларның *антиципация* сәләтен үстерү, ягъни текстның исеменә, дәреслектәге иллюстрацияләргә карап эчтәлекне фараз итү сәләтен үстерү дигән сүз.

II этап. <u>Уку барышында текст өстендә эшләү.</u> Бу этапның максаты – текстның эчтәлеген аңлауларына ирешү.

1. Укучылар мөстәкыйль рәвештә эчтән текстны, я бер кисәкне, я тәмамланмаган бер фрагментны укыйлар. Аларның инде үз алларына куелган максатлары бар: укый башлаганчы туган фаразлауларны тикшерү.

2. Укучылар текстны аңлатып, җөмләләп яисә абзацлап укыйлар.

3. Шул ук вакытта сүзлек эше дә алып барыла. Чөнки кайсы сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау кирәген укучылар үзләре билгелиләр, контекстта ук аңлатма бирәләр.

Шулай ук һәр кисәген аңлатып уку, укучыларга мөстәкыйль укыганда да текстка якын килеп эшләргә ярдәм итә. Шушы ук этапта текстның эчтәлегенә карата әңгәмә, сайлап уку күнегүләрен кертергә була. Һәм төп сорау: безнең фаразлаулар туры килдеме, кай җирдә без ялгышканбыз икән?

III этап. <u>Текстның эчтәлеген өйрәнгәннән соңгы эшчәнлек.</u>

Аның максаты: текстның төп фикерен ачыклау. Автор әйтәсе килгән фикерне билгеләү.

1. Укытучы бөтен текстка карата проблемалы сорау куя. Бу сорауга җавап эзләгәндә укучылар авторның юллар арасына яшеренгән әйтәсе килгән төп фикерен, уен ачыклыйлар.

2. Укытучының язучы турында сөйләве. Текст белән эшләгәннән соң сөйләү, укучыларга текстның эчтәлеген тагын да ныграк аңларга ярдәм итә.

3. Иллюстрацияләргә яңадан әйләнеп кайту: кайсы фрагмент сурәтләнгән, рәссам һәр детальне төгәл сурәтләп биргәнме?

4. Иҗади биремнәр. Мәсәлән:

а) Һәр укучыга берәр өзеккә, абзацка яки җөмләгә иллюстрация ясарга кушарга, текст сүзләре белән исемләү; аларны тәртип буенча төзү. Бу иллюстрацияләр җыелмасы текстның эчтәлеген ачып бирергә тиеш.

в) геройның портретын ясау, “Кем төгәлрәк?” конкурсы үткәрү.

д) геройлар исеменнән телеграммалар, хатлар язу;

е) авторга ияреп иҗат итү күнегүләре һ. б.

Практик өлеш

- Хөрмәтле коллегалар! Хәзер исә без теорияне практикада ныгытырбыз.

Сез минем укучыларым булырсыз. Продуктив уку технологиясен Аяз Гыйләҗевнең кече яшьтәге балалар өчен язган “Матур” хикәясе мисалында карап үтәрбез. *Максатым* – шушы технологиягә нигезләнеп, Аяз Гыйләҗев әсәрләренә карата кызыксыну уяту, әлеге алымны практик үзләштерүгә ирешү.

| Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге |
|---|---|
| Текстны укыр алдыннан эшне оештыру (антиципация) | |
| - Без бүген дәрестә куренекле татар язучысы А. Гыйләҗевның “Матур” дигән хикәясе белән танышырбыз. Текстның исеме буенча сездә нинди фикерләр бар – әсәр ни турында дип уйлыйсыз? Бәлки иллюстрацияләр сезгә ярдәм итәр.<br>- Сездә авторга карата нинди сораулар туды?<br><br>Уку мәсьәләсен кую:<br>- Димәк, без бүген дәрестә нәрсәләр белербез? Моның өчен нишләргә? | Укучыларның фикерләре:<br>- матур күлмәк;<br>- матур көн;<br>- матур кыз;<br>- матур песи;<br>- матур күңел.<br>1. Нәрсә ул “матур”?<br>2. Автор бу әсәре белән безгә ни әйтергә теләгән?<br>- Куелган сорауларга җавап табарбыз, тексттан кирәкле мәгълүматны эзләрбез. |
| Уку барышында текст өстендә эшләү | |
| - Әсәрнең төп геройларын табыйк эле.<br>-Ә нәрсә микән ул матур?<br>Тексттан шушы сорауга җавап табыйк эле. | Текстның баш өлешен уку. (Искәндәр, Галия, Разыя, Разыяның әнисе)<br>Өзекне укыганнан соң, Матур – песи кушаматы икәнлеге ачыклана. |
| Төркемнәрдә биремнәр башкару | |
| <u>I төркем өчен бирем </u>– ни өчен Разыяның Искәндәрне күрәсе килгән? | Тиешле өзекне укыйлар. Җавап: дусты чирләгәч, аны күрәсе килгән. |
| <u>II төркем өчен бирем </u>– Галия кем? Ул нинди? | Өзекне уку. Җавап: Галия – курше кызы, ул үпкәчел, усал. |
| <u>III төркем өчен бирем </u>- Разыя ник елый? | Өзекне уку. Җавап: Разыяның Искәндәргә дигән өчпочмагын Матур кушаматлы песи ашаган. |
| <u>IV төрке өчен бирем</u> - иллюстрацияне ачыклаучы өзекне укып күрсәтегез әле | Тиешле өзекне уку, комментарий бирү. |
| Эчтәлек буенча әңгәмә | |
| - Разыя белән Искәндәр кемнәр алар?<br>- Ни өчен Разыяның әнисе Искәндәр белән уйнарга рөхсәт бирми?<br>- Разыяның башына нинди уй килгән?<br>- Искәндәрнең әбисенең күңеле ник нечкәреп киткән? | Җаваплар әйтелә, дәлилләр китерелә. |
| Сәнгатьле уку | |
| - Искәндәрнең әбисе белән Разыя арасындагы сөйләшүне укып күрсәтегез әле | Сәнгатьле уку |
| Текстның эчтәлеген өйрәнгәннән соңгы эшчәнлек | |
| Иллюстрацияләрне тәртип буенча тезегез. | Иллюстрацияләрне тәртипкә тезү |
| - - Шулай итеп, ни өчен әсәр “Матур” дип атала? Автор безгә ни әйтергә теләгән?<br>- Тагын нинди сыйфатларны матур дип санарга була? Ә сез иптәшегез чирләсә, аның хәлен беләсезме?<br>-Автор турында ниләр беләсез?<br>(Аяз Гыйләҗев турында белешмә бирү) | Автор Разыяның эчке матурлыгын күрсәтергә теләгән.<br>Укучыларның җаваплары.<br><br><br><br>Презентация карау. |
| Өйгә эш | |
| 1. Әсәрның ахырын ничек дәвам итәргә була, шул турыда сөйләргә.<br>2. Кешенең матур сыйфатларына карата мәкальләр язарга. | Өйгә бирелгән эшне язып кую. |

Йомгаклау

Шулай итеп, хөрмәтле коллегалар, без сезнең белән продуктив уку технологиясен әдәби уку дәресендә ничек кулланып булуын сынап карадык. Ә хәзер бу технологияне ничек үзләштерүегезне сынап алыйк. Моның өчен мин сезгә *Блум кубигын* тәкъдим итәм (Америка галиме Бенджамин Блум алымы). Кубикның 6 кыры бар, димәк сезгә 6 бирем. (Продуктив уку технологиясенә кагалышлы сүзләр белән аңлатырга тиеш).

1. Тасвирла (текст өстендә эш 3 этаптан тора)
2. Чагыштыр (традицион технологиядән нәрсә белән аерыла?)
3. Ассоцияция (продуктив уку – ул ... )
4. Куллан (бу технологияне А. Гыйләҗевнең тагын нинди әсәрләрен өйрәнгәндә кулланырга уйлыйсыз?)
5. Бәя бир (бу технологиянең уңай яклары нидә?)
6. Тәкъдим ит (ирекле тәкъдимнәр)

- Барыгызга да бик зур рәхмәт! Иҗади уңышлар сезгә!

КУШЫМТА 1











Алтынбаева Светлана Сәгыйдулла кызы,
Азнакай шәһәренең 2 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе

## Ана – бөек исем

**Максат:** Әсәрнең эчтәлегенә төшенү, идеясен ачыклау. Бибинур образына киңрәк тукталу, аңа хас сыйфатларны ачыклау. Укучыларда иҗади фикерләү сәләтен үстерү, үз хисләрен һәм фикерләрен эзлекле, матур, төгәл итеп әйтә, аңлата белүләренә ирешү. Укучыларда ата-анага мәрхәмәт, шәфкатьлелек хисләре тәрбияләү; әхлак тәрбиясе бирү. **Җиһазлау.** А.Гыйләҗев портреты, әсәр буенча презентация, М.Гыйләҗев “Бибинур” фильмының видеоязмасыннан өзек.

**Дәрес барышы.**

**I. Оештыру, уңай психологик халәт тудыру.**

**Укытучы.** “Туган илеңә, халкыңа бирелгәнлек, туган телеңә сүнмәс мәхәббәт – менә ул язучының үзгәрмәс кыйблалары. Тормыш шартлары, яшәү күренешләре көнләп-сәгатьләп үзгәреп торса да, бу бөек төшенчәләр – мәңгелек, һәм шушы мәңгелеккә тугры кешеләр генә үзгәрешләрне халык белән бергә сиземли ала”, - дип яза Аяз Гыйләҗев.

-Укучылар, бүген без сезнең белән Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” әсәре аша Аналарның бөеклеген дәлилләрбез.

**Укытучы.** **Әсәрдән** бирелгән өзек ничек башлана? **(**Картаюны кешеләр төрлечә кичерә: күзләре начар күрә, аяклары йөрмәс була...)

**Укытучы.** Бибинур да шушы ук халәтне кичерәме? (Бибинур картлыкны башка төрле тоя. Ул табигатьнең матурлыгын тоймас була. Кошлар сайравына игътибарсыз, тургайлар килүен сизми, гөрләвекләр тавышы белән хозурланмый.)

**II. Төп өлеш.**

**Укытучы:** Сезнең алдыгызда бирем язылган кейслар. Сез кейслардагы беренче биремне укып фикер алышыгыз әле.

Беренче төркемгә бирем: кешеләрдә яхшылык сыйфатлары кими баруның сәбәпләре нәрсәдә? Көтелгән җавап: (тормыш артыннан куып, туганлык, үзара ярдәмләшү, олыларны олы итү мәрхәмәтлелек, миһербанлылык сыйфатлары югалып бара. Бу сыйфатларның югалуы олы фаҗигаләргә китерә. Бүгенге көндә күпме ата-ананың балалары тарафыннан кимсетелеп, йортларыннан куып чыгарылуы, картлар йортына илтеп ташлаулары турында, ул гына да түгел, хәтта үтерүгә барып җиткән очракларны да көндәлек матбугат битләреннән дә, зәңгәр экраннар аша да күреп-ишетеп торабыз.

-Икенче төркемгә бирем: бу күренеш заманга бәйлеме? Көтелгән җавап: әлбәттә заманга бәйле, кешеләр байлык, дәрәҗә артыннан куып, ата-анасын, туганнарын оныта бара, көнчелек, тупаслык, дорфалык сыйфатлары алга сөрә. Элек гаиләләр әби - бабай бергә яшәгән, хәзер аерым. Әти-әниләр эштән кайтып кермиләр, тормыш куалар, ә балалар күпчелек вакытларын интернет артында үткәрәләр. Артык иркәләү, балаларга эш кушмау - җаваплылык хисен юкка чыгара.

**Укытучы.**Тактадагы язмага караыйбыз. (Сүзләр чыга).

“Вальпараиса, Галлапогос, Титикака, Куала-Лумпур – шәп яңгырый торган исемнәр, беләм! Әмма минем өчен Аксыргак авылы, Ташлыяр елгасы тагын да шәбрәк яңгырый! Кадерле булганга күрә шәбрәк яңгырый!” (Авторның үз сүзләре)

“Бу тарихны ишеткәч, мин ул әбинең болдырына утырып озак кына җыладым... Тәрәзәләре такта белән томаланган япа-ялгыз йорт. Ихатада башка корылмалар күптән ишелеп беткән. Көзге үтә шомлы төн иде. Караңгы булса да, череп укмашкан саламны әрсез җил иркенә бирмичә түбә өстенә рәт-рәт тезелешеп яткан каен бастырмалар аер мачык күренеп тора иде. Карчыкның бөек рухы, җимерек йорты белән саубуллашып китә башлагач, борылып карадым: сәҗдәгә чүккән өй дә, аның ак төшкән йомык тәрәзәләре дә юк иде, әнә шул, сабый бала беләге юанлыгы, иртә киселгән ап-ак каен кәүсәләре генә караңгылык елгасында мыштым гына, каядыр, серле, без белмәгән мәңгелек елгасына таба йөзәләр төсле тоелды”.Габдулла абый Юсупов сүзләре.

«Уф, йөрәгем!..» димәс идем, янулары басылса.Татар халкының яраткан җыры

**Укытучы.** Төп герой Бибинурның характер үзенчәлекләрен, холкын ачуда мөһим роль уйнаган сюжет сызыкларына тукталыйк. Беренче сюжет сызыгы: Бибинурның мәхәббәте. (Укучылар Бибинурның яшьлеге, аның Мирзаһидка, Габдуллаҗанга, Җиһангирга карата булган мөнәсәбәтләре турында сөйлиләр)

**Укытучы.** Дөресен әйткәндә, Бибинур яшь чагында берәүгә дә гашыйк булмыйча кала. Мирзаһитны үзен хөрмәт иткәнгә якын күрә. “Кирәк, яшь үтеп бара”, - дип аулак өйләргә бара. Габдуллаҗанны ул яратырга өлгерми, өч баласы булмаса, ул аның барлыгын да белмичә яшәр иде. Бу сюжет сызыгы аша, Бибинур нинди кеше булып күз алдына килә? (Гади, мәрхәмәтле, тыйнак, кеше бәхете өчен үз бәхетен дә кызганмый).

**Укытучы.** Бибинур һәм авылдашлары, туганы Зөһрәбану белән мөнәсәбәтләре турында сөйләшик әле. Бу очракта сез аның нинди сыйфатларын күрәсез? (Ул кешелекле, эшчән, кешеләргә ачык йөзле).

**Укытучы.** Ә ни өчен соң, Бибинур өенә кунак чакырмый? Алай гына да түгел, кешенең өенә кергәнен яратмый? (Чөнки авылдагы бердәнбер салам түбәле йорт Бибинурныкы. Кайчандыр хәлле генә булган йортның эчендәге барлык әйберләрне балалары алып китеп бетергән. Чәй куеп эчерерлек чәйнеге дә калмаган әбинең. Бу аның кунак, яратмавыннан түгел, ә оялуыннан).

**Укытучы.** Бибинур һәм аларның балалары турында нәрсә әйтә аласыз? Бибинурны әлеге балаларның әнисе дип әйтеп буламы? (Әйе, без аны балаларның әнисе дип әйтә алабыз, чөнки ул аларны шундый авыр елларда үстергән, тәрбия биргән. Татар халкында шундый мәкаль бар: “Тапкан ана түгел, баккан ана”).

**Укытучы.** Димәк, бу сюжет сызыгыннан күренгәнчә, Бибинур балаларын яратучы, алар өчен бөтенесен эшләргә әзер торучы чын әни кеше буларак күз алдына килә. Балаларына авылдашларыннан да тел-теш тидертми. Ә сез ничек уйлыйсыз, автор үз героен яратамы? Ни өчен? (Ярата. Ул аны җылы хисләр белән яратып иҗат иткән. Автор аның белән бергә шатлана да кайгыра да кебек).

**Укытучы.** Укучылар, сезгә 2 нче бирем язылган кейслар. 1нче төркемгә Бибинурның матур сыйфатларын санарга. (Бибинур татар хатын-кызларына хас иң яхшы сыйфатларны үзенә җыеп алган. Ул – эш ярату, авырлыкка түзә белү; кимсетсәләр, гафу итә белү; сер саклый белү. Бибинур – дөнья каршысында да, Алла каршысында да изге җан. Ул барлык кешегә яхшылык кына эшли).

2 нче төркемгә каршылык тудырган сыйфатларын санарга. (Татарларда шундый мәкаль бар: чирен яшергән – үлгән. Бибинур балаларына дөрес тәрбия бирми. Балаларын һәрвакыт яклый. Аларның юньсез, игелексез булуларын танымый. Балалар авырлыкларны әниләре белән бергә бүлешергә, авыр минутларында әниләренең иң беренче ярдәмчеләре булырга тиешләр. Балаларына дөрес тәрбия бирмәгәнгә күрә, яхшылык явызлык булып кайта)

**Укытучы.** Димәк, укучылар, Бибинурның матур сыйфатлары бик күп, эзләгәч, кимчелекләрен дә табып була икән. Нәтиҗә ясыйбыз. (Киемнең уң ягы һәм сул ягы булган кебек, кешеләр дә төрле сыйфатларга ия, тормыш та авырлыклар һәм шатлыклы вакыйгалар белән алмашынып бара. Бәлки шушы тискәре сыйфатлар булмаса, матурлык күзгә күренмәс тә иде, кадере дә булмас иде).

**IV. Ныгыту.**

**Укытучы.** Укучылар, хәзер Бибинурның почтальон кыз Миңнегөл белән очрашу өзеген карап китик. Алга таба сезгә өзекнең эчтәлеген үзгәртергә кирәк булачак.(Өзек карау)

**Укытучы.** Кейста 3нче бирем язылган. Матур булмаган өзекне узегезчә үзгәртеп, матурлап язып карагаз. Әсәр ничек үзгәрер микән?

1.Почтальон кыз сөенечле хәбәр алып килгән: “ Балаларың Сабан туйга кайталар,” - ди

2. “Сине һәм балаларыңны мактап язарга журналистлар килә,” - ди Миңнегөл. (Укучыларның җавабын тыңлау, рольләргә бүлеп уку)

**Укытучы.** Бик яхшы. Рәхмәт укучылар.

**II. Йомгаклау өлеше.**

**III.** Ә хәзер теория буенча тест эшләп, белемнәребезне тирәнәйтик. Дәрескә тест.

1. “Җомга көн кич белән ..” повесте кайсы әдәби төргә карый.

а) лирик; ә) **эпик;** б) драма.

2. Бибинурның ялгызлыгына ишарә итүче символик образны билгеләгез.

а) хат; ә) **яшел чирәм**; б) зират.

3. “ Ул балаларын **олы дөньяга чыгарып җибәрде**” җөмләсендә кулланылган тропны билгеләгез.

а) **фразеологизм;** ә) чагыштыру; б) эпитет.

4. Әсәрдә геройларның үзара аралашуын ачыклый торган сөйләм формасын атагыз.

а) реплика; ә) ремарка; б) **диалог.**

5. Әсәрдәге **саран бакалар** тел- сурәтләү чарасын атагыз .

а) эпитет; ә)**метафора**; в)чагыштыру.

**Укытучы.** Әсәрдә Бибинурның язмышы ничек төгәлләнә соң? (Бибинурның гомере бик аянычлы өзелә. Аны үзе караган эте үтерә)

**Укытучы.** Аяз Гыйләҗев әсәрдә эт образын ни өчен керткән дип уйлыйсыз? (Автор эт белән Бибинур тәрбияләп үстергән балаларны чагыштыра. Бибинурның эте белән балалары арасында ниндидер охшашлык бар. Алар үзләренә яхшылык эшләгән кешене онытканнар. Аны гына да түгел, балалар үзләренең туган җирләрен, туган туфракларын да онытканнар).

**Укытучы.** Укучылар, бүгенге тема сездә нинди хисләр калдырды? **(**Балалар әти-әниләргә, өлкәннәргә мәрхәмәтле булсыннар иде, аларга булышсыннар, авыр сүзләр әйтмәсеннәр, рәнҗетмәсеннәр иде. Без, балалар, нинди генә уңышларга ирешсәк тә, бар булганыбыз белән әти-әниләребезгә бурычлы. Әти-әниләребез безнең рәхмәтебезне тоеп, безнең өчен сөенеп яшәсеннәр иде.)

1. Өй эше: “Бибинурның үстергән балаларына әйтер сүзем бар” / “Ә мин әти-әниемә игътибарлымы?” темасына кечкенә хикәя язарга язарга
2. Билгеләр кую

Хайруллина Әлфия Камил кызы,
Хосусый белем бирү оешмасы №23 Менеджер урта мәктәбе, Әлмәт районы

## Аяз Гыйләҗевнең “Әтәч менгән читәнгә” әсәрендә рухи матурлык һәм ярлылык темасы буенча дәрес эшкәртмәсе

**Предмет :** татар әдәбияты, 9 нчы сыйныф

**Тема:** Аяз Гыйләҗевнең “Әтәч менгән читәнгә” әсәрендә рухи матурлык һәм ярлылык темасы буенча класстан тыш уку дәресе

**Максат:** Рухи матурлык, рухи ярлылык төшенчәләре буенча белемнәрен тирәнәйтү. Аяз Гыйләҗев иҗатына кызыксыну уяту. Әсәрдәге образларны, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне анализлау аша әсәрнең проблемасын табу. Укучыларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.

**Дәрес тибы:** класстан тыш уку дәресе

**Технология:** эшчәнлекле метод технологиясе, критик фикерләү һәм проблемалы укыту технологияләре.

**Күрсәтмә һәм таратма материаллар:** презентация, биремле карточкалар, таблицалар, эталоннар, тема һәм максатлар язган битләр

**I.Мотивация.**

- Хәерле көн, укучылар! Дәресебезне Ренат Харисның “Кеше кайчан матур?” шигыре белән башлыйсым килә. (Экранда презентация күрсәтелә бара).**Шигырь укыла.**

- Бу шигырь нәрсә турында? (Кешенең матур сыйфатлары, кеше матурлыгы)

- Әйе, шагыйрь рухи матурлыкның төрле мизгелләрен сурәтләгән.

**II.Актуальләштерү.**

- Ә хәзер рухи матурлык төшенчәсен менә бу кластерга билгеләп китик әле.




(тышкы матурлык, күңел матурлыгы, табигать матурлыгы, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр матурлыгы һ.б.)

- Димәк, нәрсә ул рухи матурлык? (Матурлык – бик тирән мәгънәле төшенчә ул. Рухи матурлыкны да һәркем үзенчә аңлый. Аны күрә, тоя белергә генә кирәк. Бөек рус язучысы А.П.Чехов та: “Кешенең бөтен нәрсәсе дә матур булырга тиеш: киеме дә, йөзе дә, күңеле дә, фикере дә”, - дип язган бит.

- Ә тормышта һәрвакытта да шулаймы икән? Бу сорауга җавап бирер өчен, әйдәгез әле тагын бер төшенчәгә аңлатма биреп китик.




-Димәк, нәрсә ул рухи ярлылык? (Әхлаксызлык, кешелексезлек, битарафлык...)

-Укучылар, без ни өчен рухи матурлык, рухи ярлылык төшенчәләрен кабатладык икән? (Бу төшенчәләр безгә яңа белемнәр ачарга ярдәм итәчәк)

**III.Уку мәсьәләсен кую.**

- Өй эше итеп сезгә Аяз Гыйләҗевнең “Әтәч менгән читәнгә” әсәрен укып килергә бирелгән иде. Димәк, бу төшенчәләрне дә без шушы әсәр белән бәйләп карарбыз.

- Дәресебезнең темасын әйтә аласызмы?

- Дәресебезгә нинди максатлар куярбыз?***(Тема һәм максатлар тактада ачыла)***

Әсәрдәге образларны билгеләү

Аяз Гыйләҗевнең “Өтәч менгән читәнгә” әсәрендә рухи матурлык һәм ярлылык темасы

Әсәрнең төп проблемасын ачыклау

Алар арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыклау

**IV.Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

**<u>1 бирем.</u> Әсәрдәге образларны билгеләү һәм аларга кыскача характеристика бирү.**

**<u>Сәләхетдиннар гаиләсе:</u>**

Гаилә башлыгы *Сәләхетдин* – Ватан сугышында катнаша, яралана.

Хатыны *Гөлбикә* – кешеләрнең тышкы кыяфәтенә бик нык игътибар бирә. Кешеләргә бәя бирергә ярата, гайбәтче.

*Зәйтүн* – тырпаеп торган чәчле, тар маңгайлы. Начар укый. Өтәчне читәннән бәреп төшерүче образ.

*Фирүзә* – Зәйтүннең сигезенчедә укып йөрүче апасы, очлырак иякле, килешле биек муен, яңаклары алланып, янып тора. Битендә чыккан кызыл төрткеләргә бик борчыла. Үткен телле.

*Вәзилә* – бәләкәйдән үк шәһәрдә торырга хыялланып яши. Моның аркасында ул начар укый башлый. Җәмилнең сөйгәне. Җәмилнең футболчы булуына бик шатлана, алар акчаны күп алалар һәм күбесенчә шәһәрдә яшиләр. Ул Җәмилне ничек булсада шәһәргә китәргә күндерергә тели. Ләкин Җәмил үз сүзендә тора, шуңа күрә Вәзилә төрле мәкерле планнар кора, ләкин аның усал ниятләре тормышка ашмый. Ул бары тик киләчәге турында гына уйлана. Эгоист. Әти-әнисенә карата да бер ихтирам хисе юк. Ул аларның кырыйларына, больницага, барырга ояла. Анда ул олы су буйлап төшә. Җәмилне дә ул яратмый, бары тик үзен аның хуҗасы итеп тоя, әйбергә караган кебек карый, көнчелеге дә шуннан.

*Зөфәр* – тыныч холыклы, Җәмил абыйсын ярата, хөрмәт итә. Хәйретдин агай белән дус. Аны байлык кызыктырмый, Хәйретдин агай кебек ул да юмарт.

Хәйдәр – мәктәптә бик начар укый, шуңа күрә мәктәптән этеп-төртеп дигәндәй чыгаралар. Чистай авыл хуҗалыгы техникумында укый. Механизатор. Әти-әнисе янында яши. Эчәргә ярата.

**<u>Мирфатыйхлар гаиләсе:</u>**

*Мирфатыйх* – Ватан сугышында катнаша, яралана.

*Гөлмәрьям* –Мирфатыйхның хатыны, көнчел.

*Әнәс* – Мирфатыйхның кече улы. Мәктәптә яхшы укый.

*Җәмил* - мәктәптә укыганда география һәм физкультура дәресләрен ярата. Ярышларда күп катнаша, район чемпионы исеме белән армиягә китә, укытучы, футболчы. Авыл тормышын ярата.

*Мидхәт.* Чистай авыл хуҗалыгы техникумында укый. Механизатор. Әти-әнисе янында яши. Эчәргә ярата.

**<u>2 бирем.</u>Образлар арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыклау**.

- Нинди образларны чагыштырып карап була?

*Сәләхетдин – Мирфатыйх*

*Гөлбикә - Гөлмәрьям*

- Бу ике гаилә арасында бик матур чаклар була. Бер-берсенә йомышка, мунчага, туган көнәргә йөрешәләр. Ике йорт арасында уртак эшләр башкарыла. Бернинди яшерен сер, гайбәт, көнчелек булмый. Гаилә башлыклары ике җан дус, туганнар. Заманында Гөлбикә белән Гөлмәрьям дә ахирәт дуслар булалар. Мирфатыйх та, Сәләхетдин дә Ватан сугышында катнашалар, икесе дә яраланып кайта. Бер вакытта диярлек өйләнәләр. ***(444 – 445 биттән өзекләр укып китәләр)***

- Ләкин бер заман Сәләхетдин районнан мотоцикл алып кайта һәм шуннан ике гаилә арасында дуслык бетә. “Көнчелек дигән сүз кергән арага тиз арада дошманлык та кереп оялый”. (Берсеннән-берсе арттырып әйбер алу, йорт җирләрен яхшырту вакыйгаларын искә төшерү)

Зәйтүн – Әнәс

- Дус булырга телиләр, ата-аналары йогынтысында дуслаша алмыйлар. (Малайларның бәхәсләшү һәм сугышу вакыйгасы искә төшерелә)

Хәйдәр – Мидхәт

-Ике дошман нигезендә үскән егетләр чит урында – Чистайда бергә туры киләләр. Көлкедән котылу өчен, янәшә түзеп яшәргә, дошманлыкны онытып торырга туры килә. Ләкин авылга кайткач, эти-әниләре тәэсирендә яңадан дошманнарга әвереләләр. (Практика вакытында булган хәлне, машиналар белән узышу вакыйгалары искә төшерелә)

**<u>3 бирем.</u> Әсәрнең төп проблемасын ачыклау**.

- Ә хәзер без сезнең белән төркемнәрдә эшләп алырбыз. (Ике төркемгә бүленәләр)

-Образлар арасында нинди мәсьәләләр күтәрелә? (Төркемнәрдә 5 мин фикер алышу)

**1 төркем.** Зәйтүн белән Әнәс мөнәсәбәтендә (Балалар дус була алырлар иде, гаилә комачаулый. Гаилә тәрбиясенең мөһимлеге)

Хәйдәр белән Мидхәт мөнәсәбәтендә (Эчкечелекнең авыл кешеләре арасына кереп тамыр җәя баруы)

**2 төркем.** Гөлбикә белән Гөлмәрьям мөнәсәбәтләре (көнчелек, байлык артыннан кууының нәтиҗәсе – гаиләдәге балаларны әхлаксыз итеп тәрбияләүгә китерүе. Хатын-кыз тыйнаклыгының югала баруы).

Сәләхетдин белән Мирфатыйх ( Алар да хатыннары кебек үк).

- Ә гаиләдәге ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр берәр мәсьәләгә ишарә ясамыйммы? (Бала – ата-ана көзгесе. “Бала күңеле уңдырышлы кыр – ни чәчсәң, шуны урырсың!”- ди автор. Балаларның дус-тату, әхлаклы булып үсүендә аларның мөнәсәбәте әһәмиятле роль уйный).

- Ничек уйлыйсыз, матур елга Олы су турында язып, автор нинди мәсьәләне күтәреп чыга икән? (Үткәннәргә хөрмәт хисенең югалуы. Зиратларга кадерсезлек.)

- Ә ни өчен автор Хәйретдин агай образын керткән? (Чөнки бу образ башка образларга мәгънәви төсмерләр өсти. Ул бөтен образлар белән дә мөнәсәбәткә керә)

- Хәйретдин агайның башка образларга мөнәсәбәтендә нинди мәсьәлә күтәрелә? (Кешеләрне, хезмәтне, дөньяны яратырга кирәклекне күрсәтә. Ул әсәрдә олысына да, кечесенә дә үрнәк. “Үлемсез ил агасы – мәңгелек булып тоела”)

- Әсәрдә күтәрелгән проблемаларның бөтенесен бергә җыеп, авторның нинди төп проблеманы күтәрүен билгеләп карыйк әле. (Укучылар төркемнәрдә фикер алышалар)

- Шулай итеп, автор нинди төп проблеманы күтәрә? ( Кешенең эчке дөньясы, рухи үсмәве).

**V.Мөстәкыйль эш.**

***Бирем.*** Әсәрдә рухи матурлык һәм рухи ярлылык төшенчәләре ничек ачыла, таблицага язарга.

| **Рухи матурлык** | **Рухи ярлылык** |
|---|---|
| | |

**VI.Белемнәрне гомумиләштерү.**

1) Мөстәкыйль эшләр эталоннар буенча чагыштырыла һәм фикер алышу үткәрелә (***эталоннар таратыла).*** Билгеләр куела.

2) Г.Камал театрында "Әтәч менгән читәнгә" әсәре буенча куелган спектклььдән видеоролик карау.

**VII.Рефлексия.**

**Өй эше.** Рухи матурлык, рухи ярлылык темаларына синквэйн язарга.

- Дәреснең темасы нинди иде?

- Дәрескә нинди максатлар куелды? Без максатларга ирештекме?

- Дәлилләгез. Нинди алымнар кулландык? **Үзбәя.**

Шакирова Суфия Шамил кызы,
Хосусый белем бирү оешмасы №23 Менеджер урта мәктәбе, Әлмәт районы

**Аяз Гыйләҗевнең тууына 90 ел**

( 9 - 11 нче сыйныфлар өчен кичә)

Кичә буласы зал алдан бизәлә, язучының портреты эленә.

Аяз Гыйләҗевнең тууына 90 ел

1928 – 2018 - сүзләре

Һәм эпиграф языла: *"Үз халкыңның үткәнен бел, аның чын тарихы белән кызыксын. Өйрән һәм башкаларга да шуны сөйлә. Үткәне юкның – киләчәге дә юк!" А. Гыйләҗев*

**Максат:** күренекле язучы Аяз Гыйләҗевка укучылар күңелендә ихтирам тәрбияләү; язучы мирасы белән мөмкин кадәр тулысынча таныштыру; татар халкының танылган язучысы, драматургы Аяз Гыйләҗев мирасына кызыксыну тәрбияләү; язучының әсәрләреннән рухи азык алу; А. Гыйләҗев әсәрләре үрнәгендә тормышка әзер кешеләр тәрбияләү; укучыларга А. Гыйләҗев әсәрләре аша милли рух сеңдерү, милли тәрбия бирү;

**Җиһазлау:** Аяз Гыйләҗев портреты, компьютер презентациясе, экран, видеоматериаллар (*А. Гыйләҗев әти – әнисе турында, "Өч аршын җир", "Әтәч менгән читәнгә")*

**1нче укучы.**

"Яшә җирдә – исемең калсын,
Исемең үлемсез булсын.
Синең калган буыннарга
Янучы маяк булсын" ,

- дип җырлыйлар бер җырда. Халкымның маяк булып янып торучы эзләр калдырып киткән шәхесләре бик күп. Алар Г. Тукай, Г. Исхакый, М. Җәлил, М. Сыртланова, Ә. Афзалова һәм башкалар, һәм башкалар. Без бүген шундый кешеләрнең берсе, һәр татар кешесенең күңелендә тирән эз калдыра алганы, Татарстан Республикасы халык язучысы, Г. Тукай, М. Горький исемендәге премияләр лауреаты, РСФСРның

атказанган сәнгать эшлеклесе Аяз Гыйләҗевнең тууына 90 ел булуны билгеләп үтү кичәсенә җыелдык. **(2 нче слайд)**

**2 нче укучы.** Аяз Гыйләҗев – прозаик, драматург. 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. Авыл мәктәбенең тугызынчы сыйныфын тәмамлагач, унынчы сыйныфны Сарман урта мәктәбендә укый. (**3 нче слайд)**

***Җыр. "Туган ил" (Н. Исәнбәт сүзләре, татар халык көе. 10 нчы сыйныф Ләйсән, Алина, Дамир)***

*https://www.youtube.com/watch?v=qWiJK9yg3_Q – видео А. Гыйләҗев әти – әнисе турында*

**1нче укучы.** 1948 – 1950 елларда ул – Казан дәүләт университеты студенты. Монда ул, уку программасындагы фәннәрне яхшы үзләштерү белән бергә, беренче курстан ук бик мавыгып университет каршындагы әдәби түгәрәккә йөри, анда үзенең язган беренче иҗат тәҗрибәләре белән уртаклаша, фикер алышуларга, диспут- бәхәсләргә актив катнаша.

**2 нче укучы.** Ләкин сугыштан соңгы бу еллар – тоталитар совет режимының идарәдә янәдән бик нык репрессив ысуллар куллана башлаган чоры. Репрессияләр шаукымы иҗади студент яшьләрне дә читләтеп үтми: 1950 ел башында Казан югары уку йортларында укучы бер төркем татар студентларын, шул җөмләдән А.Гыйләҗевне, «советка каршы коткы таратуда һәм милләтчелектә гаепләп», кулга алалар.

**1 нче укучы.** 1950 елның декабрендә совет мәхкәмәсенең ябык утырышы А.Гыйләҗевне җиде елга ирегеннән мәхрүм итеп, хезмәт колониясенә җибәрергә дигән хөкем карары чыгара.**(4 нче слайд).** Югары белем алып, язучы булырга хыялланган егерме ике яшьлек егет әнә шулай Казакъстандагы совет концлагерьларында биш елга якын җәфа чигәргә мәҗбүр була.

***Шигырь."Агыла да болыт, агыла"( Х. Туфан) 9 нчы сыйныф Газинур***

**2 нче укучы.** Аяз Гыйләҗев Гулаг мәхшәрләрен узган, соңгы сулышына кадәр "туган илем" дип яшәгән, сокландыргыч әсәрләр иҗат иткән.

**1 нче укучы.** Сталин вафатыннан соң гына аны ирекка чыгаралар һәм Казан университетында өзелгән укуын дәвам итәргә мөмкинлек бирәләр.

**2 нче укучы.** Университетны тәмамлагач, А.Гыйләҗев берничә ел көндәлек матбугат редакцияләрендә эшли, аннары, Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы икееллык Югары әдәби курсларда укып кайтканнан соң, 1963 елдан башлап профессионал - язучылык хезмәтенә күчә.

**1нче укучы.** А.Гыйләҗевнең иҗаты күпкырлы һәм мул уңдырышлы. Язучы кайсы чор турында һәм нинди темага язса да, кеше шәхесенең катлаулы рухи дөньясын, милли, тарихи-иҗтимагый тормыш барышындагы катлаулы һәм каршылыклы мәсьәләләр, әхлакый проблемалар белән тыгыз бәйләнештә гәүдәләндерергә омтыла.

**2 нче укучы. (чиратлашып)** "Дүртәү" повесте, "Язгы кәрваннар" повесте, "Оч аршын җир" повесте, "Җомга көн кич белән" повесте, "Әтәч менгән читәнгә" повесте, "Балта кем кулында?" романы, "Йәгез бер дога" романы (**5 нче слайд).**

**1 нче укучы.** «Җомга көн, кич белән...» һәм «Әтәч менгән читәнгә» повестьлары өчен А.Гыйләҗев 1983 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә, ә 1987 елда русча тәрҗемәдә Казанда басылган «При свете зарниц» исемле китабы өчен РСФСРның М.Горький исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

**2 нче укучы.** А.Гыйләҗев иҗатында җир образы үзәккә куелган әсәрләр шактый. Укучысын үзенең "Өч аршын җир" әсәре белән "кеше өчен иң кадерле – туган җир, нәсел-нәсеп, аның тарихы, кавемдәшләр икән" дигән фикергә китерә язучы.

**1 нче укучы.** "Өч аршын җир" повесте герое Шәмсегаян гомере буе туган җирен сагынып яши, аны төшләрендә күреп саташа, үлер алдыннан иренә әйткән васыяте дә шул турыда була. **(6 нчы слайд)**

*"Өч аршын җир" спектакленнән өзек карау. Мирвәли белән Шәмсегаян диалогы.*

https://www.youtube.com/watch?v=Jy1SU3o8vgc – туган җирне сагыну.

**Фәнис Яруллин."Туган ягы кирәк кешегә" шигыре (9 нчы сыйныф – Әмирхан)**

**2 нче укучы.** Ни өчен соң повестен "Өч аршын җир" дип атаган язучы? Өч аршын җир ул – үлгән кешенең соңгы урыны. Аңа бүтән, тагын да зуррак урын кирәк түгел. Мирвәли һәм Шәмсегаян өчен өч аршын җирнең кыйммәте – туган җирдә булуында. Туган җирләренә кайта алмыйча, чит җирләрдә бик күп еллар гомер итеп, авыргач кына булса да, туган җиреңә әйләнеп кайту, шул газиз җирдә үлеп, аның өч кенә аршынына ия булу да Мирвәли һәм Шәмсегаян кебек каңгырап, тилмереп яшәгән меңәрләгән күмәкләшү чоры корбаннары өчен бер бәхет икәнен әйтергә теләгән автор.**(7 нче слайд)**

***Сусау. Җыр. Сибгат Хәким сүзләре, Сара Садыйкова көе (Ләйсән Әкъдасовна)***

**1 нче укучы.** А.Гыйләҗевне бер баскычка югары күтәргән "Җомга көн кич белән..." повесте – укучыларның иң яратып укыган әсәрләреннән берсе. Әсәрдә рәхимсез балалары тарафыннан онытылган Бибинур карчыкның, физик яктан шактый зәгыйфь тоелган әбинең көчле рухы, чиксез мәхәббәт белән сугарылган олы җаны, әрнүле һәм фаҗигале эчке дөньясы укучыны тирән тетрәндерде.

**2 нче укучы.** А.Гыйләҗевның "Җомга көн кич белән..." әсәренең төп герое Бибинур карчык. Бибинур кечкенәдән үк итагатьле, намуслы, эшчән, саф күңелле булып үсә. Үзенә җан аткан егет тә табыла. Ләкин Мирзаһит белән Бибинур бергә бәхетле булырга, матур итеп гаилә корырга гына җыенганда аларның мәхәббәтенә киртә корыла – Гайшәнең вакытсыз үлеме Бибинурның хыялларын чәлпәрәмә китерә. Ул үз гомерендә мәхәббәтнең ни икәнлегендә татый алмаган килеш, үзенең яшьлеген ятим балалар хакына корбан итә. Ни кыяфәте, ни тазалыгы булмаган Габдуллаҗанга кияүгә чыга.

**1 нче укучы.** Бөтен көчен куеп, тырышып-тырмашып дигәндәй, балаларның тамагы тук, өсләре бөтен булсын өчен кулыннан килгәннең барын да эшли. Ләкин шунысы аянычлы – туган якларына, туган җиргә, ата-баба туфрагына күңелләре суына балаларның. Туган авылда ике күзен алмый үзләрен көтеп торган Бибинур барын, әни дип үскән якын кешеләре – ата-ананы алыштырган изге җанлы кеше барын оныталар.

**"Җомга көн кич белән" повестеннан Бибинур монологы** ( Алина – 10 нчы сыйныф)

**Ф.Яруллин. "Яхшылык эшләргә ашыгыйк" шигыре укыла.**

**1 нче укучы.** Бибинур татар хатын-кызларына хас иң яхшы сыйфатларны үзенә җыеп алган. Ул – эш ярату, авырлыкка түзә белү; кимсетсәләр, гафу итә белү; сер саклый белү. Бибинур - дөнья каршысында да, Алла каршысында да изге җан. Ул барлык кешегә яхшылык кына эшли. Бибинур – бөтен гомерен өч ятим баланы бәхетле итүгә багышлаган ана. Бибинур кебек әниләр турында матур сүзләр генә әйтәсе, матур җырлар гына җырлыйсы килә.

***Җыр "Әнкәем" (10 нчы сыйныф кызлары җырлый)***

**2 нче укучы.** Аяз Гыйләҗев туган республикасының, милләтенең туган теленең бүгенгесе һәм киләчәге турында кайгырып, борчылып яши. " ... Мин милләттәшләремдә, җирдәшләремдә, замандашларымда әле сүнеп бетмәгән, заманның явыз тизлеге белән капланып өлгермәгән Туган илгә мәхәббәтне кайтарырга телим..." , - дип яза ул. (**8 нче слайд**).

**1 нче укучы.** Бүген туган телебезнең язмышы күбебезне борчый. Аяз Гыйләҗев укчыларына туган телне саклау, кадерләү, ярату турында бик акыллы киңәшләр бирә. Менә аларның кайберләре:

**2 нче укучы. "**Иң беренче үз телеңне камил бел! Аңа зур хөрмәт белән кара, башкаларны шуңа өйрәт. Онытма: синең телең дөньядагы иң камил, иң бөек ундүрттелнең берсе. Теленнән йөз чөергәннең – теле көяр! "

**1 нче укучы. "**Үз халкыңның үткәнен бел, аның чын тарихы белән кызыксын. Өйрән һәм башкаларга да шуны сөйлә. Үткәне юкның – киләчәге дә юк!"

**2 нче укучы.** "Татар халкы олуг әдәбиятлы, зур мәдәниятле милләт. Аның әдәбият-сәнгатен үзләштер, даими кызыксынып бар, өйрән һәм башкаларга да шуны сөйлә, өйрәт! Үзенекен кире каккан – үзен кире каккан!»

**Хәсән Туфан. “Туган тел турында җырлар” шигыре. Укый 9 нчы сыйныф укучысы Суянов Әмир.**

**1 нче укучы.** Татар әдәбияты классигы Аяз Гыйләҗев иҗаты еллар үтү белән дә татар укучысы өчен генә түгел, башка халык вәкилләренә дә кызыклы. Аның әсәрләре башка телләргә дә тәрҗемә ителеп, чит илләрдә таралыш ала, меңләгән тираж белән сатыла һәм фикерләр барлыкка килүгә этәрә, бәхәсләр уята. (**9 нчы слайд**

**2 нче укучы.** Хәзерге вакытта Аяз Гыйләҗев әсәрләре төрек, рус һәм венгр телләренә тәрҗемә ителгән. Татар язучысына бу телләрдә “сөйләшә” башларга, чит илләрдә дә үз укучысын табарга ярдәм иткән, бу эшкә үз гомерләренең соңгы елларын багышлаган белгечләр - Арпад Галгоци, Фатих Котлу, Наил Ишмөхәммәтов бер-берсе белән Казанда очрашты. (**10 нчы слайд)**

**1 нче укучы.** Татарстан һәм Россия театрлары Аяз Гыйләҗевнең күп әсәрләрен сәхнәләштерделәр, ягъни театр сәхнәләрендә язучының күп геройлары меңләгән тамашачы белән сөйләштеләр.

**2 нче укучы.** Бу «Өч аршын җир» «Кар астында кайнар чишмә» «Ефәк баулы былбыл кош» «Югалган көн» «Оҗмах капкасы» («Җомга көн, кич белән» әсәре буенча), «Яра», «Әтәч менгән читәнгә» әсәрләре (**11 нче слайд)**

*Чаллы театры һәм Г. Камал исемендәге татар академия театры куйган спектакльләр турында репортаж карау*

**https://www.youtube.com/watch?v=d_CNsBCdzLs**

**https://www.youtube.com/watch?time_continue=5&v=uxXGo8OhFpo**

**https://www.youtube.com/watch?time_continue=5&v=uxXGo8OhFpo**

**1 нче укучы.** Аяз Гыйләҗевнең әсәрләре кино сәнгатендә дә урын тапты. 2010 нчы елда “Җомга көн кич белән” әсәре буенча төшерелгән “Бибинур” драмасы зур казанышларга ирешә. Казан халыкара мөселман киносы фестивалендә Гран-при - 2010 нчы елның иң яхшы фильмы исеменә лаек була.

**2 нче укучы.** Фильмның сюжеты: Бибинур исемле ялгыз татар карчыгы бер көнне сәер төш күрә. Имеш, аның 5 яшьлек вакыты. Ул сукмак буйлап килә. Караса, каршындагы биек агач башына аның бөтен үлгән туганнары менеп утырган – “Бибинур, Бибинур, сиңа безнең янга килер вакыт җитте!” - диләр алар. Йокысыннан уянып киткәч, карчык үзенең 5 көн гомере калганлыгын аңлый. Фильмда шушы көннәр эчендә булган вакыйгалар сурәтләнә. (**11 нче слайд)**

**1 нче укучы.** Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай премиясе лауреаты Аяз Гыйләҗев исән булса, 17 нче гыйнварда аңа 90 яшь тулыр иде. Язучының вафат булуына инде 16 ел.

**2 нче укучы.** Тагын бик күп еллар үтәр, тормыш алга барыр. Ләкин халкымның күңеленә үзенең танылган әсәрләре белән кереп калган Аяз Гыйләҗевнең исеме мәңге яшәр!

**1 нче укучы.** Кичәбезнең ахырында Аяз Гыйләҗевнең сүзләрен искә төшерәсе килә килә: “Үз халкыңның үткәнен бел, аның чын тарихы белән кызыксын. Өйрән һәм башкаларга да шуны сөйлә. Үткәне юкның – киләчәге дә юк!”

*Җыр. “Туган тел” ( Г. Тукай сүзләре, халык көе) яки “Мин яратам сине, Татарстан!” ( Р. Рәкыйпов сүзләре, Р. Андреев көе)*

**1 нче укучы.** Игътибарыгыз өчен бик зур рәхмәт. Киләсе очрашуларга кадәр сау булыгыз!

Гильфанова Фәнүсә Мәгсүмҗан кызы, Кызрачева Нурзия Мәрвәр кызы,
А. Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомумбелем бирү мәктәбе,
Сарман районы

**Бердәмлектә көч. А.Гыйләҗевнең “Дүртәү”әсәре**

**Максат:** укучыларны язучының тормышы, иҗаты һәм “Дүртәү” әсәре белән таныштыру; эзләнү һәм чагыштыру ярдәмендә укучыларның фикерләү сәләтен үстерү.

**Универсаль уку гамәлләре:**

- танып белү УУГ: әсәрнең авторы турында мәгълүмат туплау; әсәрнең әһәмиятен һәм кыйммәтен ачыклау; дәресне тормыш белән бәйләү; дәреслектә ориентлаша, сорау куя, нәтиҗә ясый, әсәр геройларына характеристика бирә белү; тексттан бирелгән өзекне табу; үз фикерләрен дөрес һәм матур итеп әйтүләренә ирешү; текст өстендә биремнәр башкару;

- регулятив УУГ: үз эшчәнлегеңне контрольгә алу; акыллы өлкәннәр киңәшенә колак салу; гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;

- коммуникатив УУГ: әсәрнең авторы турында мәгълүмат туплау; башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык, кеше кадерен белү, үзара дуслык мөнәсәбәтләре формалашу; күршең белән хезмәттәшлек итү; ачыклый торган сораулар бирә белү, эчтән һәм кычкырып аңлап уку; төрле фикерләрне исәпкә алу һәм үз позицияңне нигезләү;

- шәхескә кагылышлы УУГ: геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү; үз мөмкинлекләреңне бәяләү; үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру; әсәр геройларының фикерләрен тыңлау, алар белән килешү яки килешмәү, үз фикереңне әйтә белү, аны тексттан өзекләр китереп дәлилләү.

**Җиһазлау:** А.Гыйләҗев портреты һәм әсәрләре күргәзмәсе, 4 нче сыйныф өчен дәреслек, компьютер, проектор, газета-журнал материаллары, тәҗрибә-уен өчен агач чыбыклар.

**Дәрес тибы:** яңа материалны өйрәнү дәресе.

**Дәрес барышы.**

**I. Мотивлаштыру. Уңай психологик халәт тудыру.**

-Хәерле көн,укучылар. Утырыгыз.

Хәерле көн телим һәр бөҗәккә,
Хәерле көн телим гөлләргә.
Сөйкемлелек телим яшь кызларга
Һәм сабырлык телим ирләргә.

Хәерле көн телим юлчыларга,
Чәчәкләргә карап елмаям.
Җиргә якты, җылы нурын сипкән
Кояшыма карап куанам.

-Укучылар, бүгенге дәресебезне Ф.Зыятдинованың “Хәерле көн телим” дигән шигыре белән башлап җибәрдек. Сезнең барчагызга да исәнлек-саулык бәхет телим.

“Бердәмлектә көч” дигән девиз астында бер-беребезгә карап елмаеп, уңышлар теләп, дәресебезне башлап җибәрик.

**II. Актуальләштерү**

1) - Укучылар, без сезнең белән бик күп язучыларның әсәрләре белән таныштык. Алар арасында якташларыбыз да бар. Әйдәгез, бераз искә төшереп китик. (Адлер Тимергалин, Вәсимә Хайруллина, Клара Булатова, Дамир Гарифуллин, Диләрә Зөбәерова, Әзһәр Габиди)

2) Төркемнәрдә эш. Һәр төркем өйгә бирелгән эш буенча бер язучы турында мәгълүмат бирә. (Хәзер үзегезнең эшләрегезгә билгеләр куегыз)

**III.Уку мәсьәләсен кую**

Ә бүген дәрестә танышачак язучыбызнын исемен шушы башваткычны чишеп табарбыз.

ОАОЯОЗО ОГОЫЙОЛОӘОҖОЕОВО

- Аяз Гыйләҗев.

**IV.Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1)Укытучының кереш сүзе. Әдәбиятыбыз күркәм, кодрәтле сүзияләренә бай. Бүген үзенчәлекле, берәүне дә кабатламый торган, дөреслекне ярып салучы язучы

А.Гыйләҗевнең тормыш юлы, иҗаты белән танышырбыз. (Язучының тормыш юлы, иҗаты турында презентация күрсәтү. Слайдлар буенча аңлатма биреп бару.)

Прозаик, драматург Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. Авыл мәктәбенең тугызынчы сыйныфын тәмамлагач, унынчы сыйныфны Сарман урта мәктәбендә укый.

1948 – 1950 нче елларда ул – Казан дәүләт университеты студенты. 1950 нче елның мартыннан башлап 1955 нче елның августына кадәр Казахстанда тоткынлыкта була. Казанга кайткач, университетта укуын дәвам итә.

1957 нче елның мартыннан 1961 нче елның августына кадәр А.Гыйләҗев матбугат эшендә: «Чаян» һәм «Азат хатын» (хәзер «Сөембикә») журналлары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, «Совет әдәбияты» ("Казан утлары") журналында проза бүлеге мөхәррире вазифаларын үти.

1961-1963нче елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укып кайтканнан бирле Аяз Гыйләҗев, язучы-профессионал сыйфатында, әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә.

Аяз Гыйләҗев 2002 нче елның 13 нче мартында вафат булды.

Иҗатына килгәндә, ” Өч аршин җир", "Зәй энҗеләре" , "Урталыкта", "Язгы кәрваннар", "Җомга көн кич белән", "Әтәч менгән читәнгә", “Дүртәү” әсәрләре белән Аяз Гыйләҗев үзен повестьлар остасы итеп танытты.

Тематик яктан А.Гыйләҗевнең күпчелек повестьлары авыл тормышына багышланган. Аларда кичәге һәм бүгегенге авыл, аның гади кешеләре гәүдәләндерелә. Шуларның берсе - “Дүртәү” әсәре – дәресебезнең темасы.

2) Дәреслек белән эш. Аяз Гыйләҗевнең “Дүртәү ”хикәясе

Әсәрнең 1 нче бүлеге өстендә эш.

- сүзлек өстендә эш: гыйбрәтле, алып батыр, сукыр черкидән дә әрсезрәк;
- хикәяне “чылбырлап” укыту (үзбәя)

3)Төркемнәрдә эш: сорауларга җавапны әсәрдән эзләп табу.

1 нче төркемгә сорау. Ни өчен Хафиз бабай гыйбрәтле хәл турында сөйләргә тели?

2нче төркемгә сорау. Тексттагы вакыйгаларның кайсысын гыйбрәтле дип атап була?

Нәтиҗә ясау. Көтелгән җаваплар.

- Бердәмлек дошманнарны җиңәргә ярдәм иткән. Яше-карты барысы да арысландай көрәшкәннәр, туган йортларына яуны җибәрмәгәннәр. Алда торган кышның салкыннарына каршы торуда да бердәмлекнең өлеше зур булган һ.б. (Төркемнәрдә эшләгән эшләренә, үзләре билгеләр кую)

4) Карточкалар белән эш. “Мәкальләрне дәвам ит”

Кош канаты белән, (кеше дуслары белән көчле).

Дуслыкта, бердәмлектә (көч).

Дуслык тау (күчерә).

- Бик әйбәт, укучылар. Димәк, дуслык - ул кешеләр арасындагы нинди сыйфатлар, уңаймы, әллә тискәреме? (Фикерләр тыңлана, үзбәя куйдырыла)

5) Кеше холкына хас уңай һәм тискәре сыйфатлар искә төшерелә. Беренче төркем уңай сыйфатларны, икенче төркем тискәре сыйфатларны яза. Укучыларның лексик сүз байлыгы тикшерелә.

| Уңай сыйфатлар | Тискәре сыйфатлар |
|---|---|
| Яхшы | начар |
| Намуслы | усал |
| Акыллы | ялкау |
| Сабыр | саран |
| Сәләтле | тупас |
| Игътибарлы | кире |

(Төркемнәрдә эшләгән эшләренә, үзләре билгеләр кую)

Физминутка

**V. Әсәрнең 2 нче бүлеге өстендә эш.**

1) - Укучылар, әсәребезнең беренче бүлегендә тылсымлы уен коралы турында әйтелеп кителде. Ул ишек төбендә тешен шыгырдаткан ачлыкның тавышын ишетмәскә булышкан, сабыйлар шул көйгә изрәп йоклаганнар, өлкәннәр дә сабырланганнар.

- Нинди уен коралы турында сүз бара? (Җавапларны тыңлау)

- Авырлыкларны җиңәргә булышкан скрипканы халык зурлап, хәтфәдән ясалган махсус савытка салып, мәрмәр таш өстенә урнаштырганнар. Халык ел сан шушы йортка килеп, батырларын искә ала икән.

- Укучылар, бәлки сезнең скрипка күргәнегез яки уйнап караганыгыз бардыр? ( Скрипканы тотып яки презентациядән карау)

- Ә көй анда ничек чыга соң?(Кыллар ярдәмендә)

- Әйе, укучылар, шушы дүрт кыл берләшеп, искиткеч матур көй чыгаралар. Без юкка гына бу уен коралы турында сөйләшеп китмәдек, димәк, безнең алдагы бүлегебез нәрсә турында булыр? (Скрипка)

“Дүртәү” әсәренең дәвамы нәкъ менә шул скрипка һәм аның дүрт кылы турында бара да инде.

2)Әсәрне ярымтавыш белән укып чыгарга тәкъдим итү.

3)Түбәндәге сораулар буенча фикер алышулар:

1) Скрипка кешеләргә табигатьнең нинди авазларын җиткерә ала?

2) Аерым кылларда гүзәл авазлар нәрсәгә әверелгән? (Җавапларга үзбәя бирелә ).

**VI.Чыбыклар белән уен-тәҗрибә.**

1 нче төркемгә 10 чыбыкны бергә җыеп бәйләргә һәм сындырып карарга кушу.

2 нче төркемгә 10 чыбыкның һәрберсен аерым-аерым сындырып карарга кушу.

- Балалар, нинди фикергә килдегез? (Фикерләр тыңлау. Әсәр белән бәйләү. Нәтиҗә ясау).
- Бүгенге дәресебезне “Бердәмлектә көч “дигән девиз белән башлап җибәргән идек. Әсәрнең эчтәлегеннән һәм чыбыклар белән ясалган тәҗрибәдән без моның шулай булуына тагын бер кат инандык.

**VII. Рефлексия**

- Хафиз бабай сөйләгән гыйбрәтле хәл нәрсә турында уйланырга мәҗбүр итә?
- Әкмәл Хафиз бабай сөйләгәнне нәрсә дип атый? Синеңчә, кем хаклы: Әкмәлме, Хафиз бабаймы?
- Аяз Гыйләҗев бу әсәре аша безгә нәрсә әйтергә теләгән?
- Бүгенге дәрестә алган белемнәребез киләчәктә кирәк булырмы?

-Әсәр ни өчен “Дүртәү “дип атала?

**VIII. Үзбәя.**

“Белем баскычы”на фишкалар кую, һәр укучының нәтиҗәне аңлатуына ирешү.

Өй эше. 1в.Әсәрнең эчтәлеген сөйләргә.

2в. А.Гыйләҗев иҗаты һәм тормышына презентация ясарга.

3 в. “Бердәмлектә көч” дигән темага хикәя яз.

Шәйдуллина Чулпан Камил кызы, Ихсанова Римма Ильяс кызы,
икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Бара юлдан язгы кәрваннар**

( Тыл ветераннары, сугыш чоры балалары белән очрашу кичәсе)

**Экранда Җиңү көне тантанасыннан язма күрсәтелә.**

**Укытучы.** Авыр сугыш еллары артта калды. Май ае саен без Бөек Җиңүнең тагын бер еллыгын билгеләп үтәбез. Сугыш кырларында башларын салган батырларны искә алабыз. Ул көнне һәйкәлләр чәчәкләргә күмелә. Әйе, батырлар һәрчак безнең арада. Аларның якты истәлекләре халык күңелендә яши. Аларны онытырга безнең хакыбыз юк. Бары халык хәтере яшәгәндә генә батырлар даны югалмаячак.

**Бер укучы Р.Газизовның “Кыр казлары” шигырен укый.**

Укытучы. Укучылар, Бөек Ватан сугышы елларында тиңдәшсез батырлыклар күрсәткән каһарманнардан кемнәрне беләсез? Аларның батырлыкларын атап, сөйләп бирегез әле.

1 нче укучы. Мин Муса Җәлил белән горурланам. Ул 1942 нче елда Волхов фронтында фашистлар кулына эләгә. Бер төрмәдән икенчесенә күчереп йөртәләр аларны. Бик авыр вакытларда да шагыйрь куркып калмый, каләмен кулыннан төшерми. Ул үлемсез шигырьләрен туплаган “Моабит дәфтәрләре”н нәкъ менә фашистларның өнендә иҗат итә. Никадәр көч, сабырлык, җиңүгә ышаныч кирәк моның өчен. Алар үлгәндә дә елмаеп үлгәннәр. Бүген аның исемен мин яшәгән бистә йөртә. Без герой исеменә лаек булырга тиеш.

**(Укучы сөйләгәндә экранда М. Җәлилнең биографиясе белән бәйле слайдлар күрсәтелә. Х.Якуповның “Хөкем алдыннан” картинасы бирелә).**

2 нче укучы. Минем Газинур Гафиятуллин турында сөйлисем килә. Бу егет үзенең күкрәге белән дошман амбразурасына ташлана. Таулы урында урнашкан дзот безнең солдатларга алга барырга ирек бирмәгән була. Алай гына түгел, аның аркасында шулкадәр күп сугышчы һәлак була. Менә шул вакытта Газинурның: ”Ватан өчен!” дигән тавышы яңгырый. Ул һәлак була, ә сугышчылар фашистларны тар-мар итәләр, бу калкулыкны алалар, авылны азат итәләр.

**(Слайдлар аша Г.Гафиятуллинның батырлыгы тасвирланган рәсемнәр күрсәтелә).**

3 нче укучы. Минем Советлар Союзы Герое Александр Казаков турында сөйлисем килә. Бу герой – безнең якташыбыз. Ул Сарман районы Александровка авылында туып-үскән. Хәзер бу авылда аңа һәйкәл куелган, мәктәптә аның истәлегенә багышланган Хәтер почмагы эшли. Александр Казаков сугыштан исән-сау кайткан, тик сугыштан соң юл һәләкатенә очрап һәлак булган. Аның кабере дә авыл зыяратында.

**(Слайдлар аша авылдагы каһарман белән бәйле урыннар күрсәтелә).**

4 нче укучы. Минем әбием белән бабам Әлмәт районы Урсалабаш авылында яшиләр. Бу авылда да Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган Мотыйк Әхмәдуллинга һәйкәл бар. Мотыйк Әхмәтҗан улы Әхмәдуллин Карелия фронтында сугыша. Сугышның башыннан ахырына кадәр сапер була. Сержант

Әхмәдуллин Днепр елгасын, Украинаны, Молдавияне азат итү сугышларында катнаша. Сугыштагы батырлыклары өчен Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. Туган якларына исән-сау әйләнеп кайткач, иленә тырышып хезмәт итә, гаилә кора, балалар үстерә. Бу геройны туган авылында хәзер дә хөрмәтләп искә алалар, үзәк урамнарның берсе аның исемен йөртә. Һәйкәле Мәдәният йорты каршында.

**(Слайдларда аның белән бәйле документлар, фотолар, мәктәп музее материаллары күрсәтелә).**

Укытучы. Әйе, укучылар, каһарманнар турында сөйли башласак, безгә бик озак вакыт кирәк булыр иде. Аларның саны меңнәр белән исәпләнә. Сугыш үткән һәр карыш җир батырлар каны белән сугарылган.

Ләкин безнең җиребез кан белән генә түгел, тир белән дә сугарылган. Сугыш бит ул безнең халкыбыз җилкәсенә күтәрә алмаслык авырлыклар алып килгән. Ир-егетләр фронтка киткән. Бөтен эш хатын-кызлар, балалар, әби-бабайларга калган. Алар завод-фабрикаларда эшлиләр, иген үстерәләр, фронтны кием-салым, икмәк, корал белән тәэмин итәләр. Сугыштан соңгы җимерекне дә алар төзәтә, һаман ипи үстерә.

**Бер укучы Ш.Галиевнең “Әткәйгә хатлар” поэмасыннан өзек укый.**

Укытучы. Укучылар, экранга карагыз әле. (Экранда А.Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” повесте буенча төшерелгән рәсемнәр күрсәтелә) Менә бу рәсемнәр – А.Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәренә булган иллюстрацияләр. Кәрван дип йөк төялгән атлар, дөяләр рәтен атыйлар. Монда да йөк төялгән чаналар, тик аны атлар түгел, ә балалар, апалар тартып бара. Аларга бер дә җиңел түгел. Күрәсезме, башлары аска иелгән аларның, арганлыклары төсләренә, гәүдәләренә чыккан. Тик туктарга ярамый, ял итәргә вакыт юк. Аларны өйдә ач балалары көтә. Салкын өйләрдә, ялгыз утыралар ул балалар. Әниләре – колхоз эшендә, әтиләрнең күбесе фронттан кайтмаган...

**Әсәрдән өзекләр укыла. Алар слайд итеп презентациягә куелганнар.**

1 нче укучы. Бүгенге көн өчен вакыйгалар артык күп булса да, бер җепкә тезгәч, алар бары тик бер мәгънә алалар иде: әйе, яшәү җиңел булмаячак. Әмма яшәргә, тырышырга кирәк!. Әйе, авыр, җәфалы, бөлдергеч сугыш беткәнгә кайчан гына бит әле! Күкрәкләр тыныч сулый башлаганга күпме вакыт узды... Әйе, безнең буын бәхетлерәк... без күкрәкләргә салкын мылтык түтәсе түгел, кызлар кыса алабыз...

2 нче укучы. Җитмеш биш чана дигәч, бер дә исем китмәгән иде, бик күп була икән ул! Көн артык җылы да, салкын да түгел, сирәк кар ява. Яз ае булса да, март тотрыксыз ул, кәефе кырылып буранлаган чагы да еш була.

3 нче укучы. Куллар табынга үрелде... Юлда, ындырда, җилдә киселеп, яргаланып беткән, бирчәйгән бармаклы, эре, калын тырнаклы куллар... Тупырдап бала сөясе урында җыерчыклы күз тирәләреннән күз яше сөртеп өйрәнгән куллар...

Гомер-гомергә иннек-май күрмәгән иреннәр шау кайнар чәйле кружкаларга тиде, кояш нурында төссезләнгән сирәк керфекле күзләр рәхәтләнеп кысылды, тартылган яңак сөякләре шытырдап китте...

4нче укучы. Бу мәшәкатьләр, кадерле кунакны каршылаган кебек каршылау, егермегә якын кешегә әзерләгән сыйлы табын, өченче көн генә кунып чыккан унике кеше – үз яхшылыгыннан тыш аның өчен дә – Габбас абый өчен эшләнә! Аның исән кайту куанычы шул тиклем зур, сөенече шулкадәр мул – Сәрвәр апа бу сөенечне тел белән генә гомердә дә әйтеп бетерәчәк түгел!..

5 нче укучы. Хатыннар Сабира апаның чанасы тирәсенә җыйналгач, мин үзебезнең өс-башыбызның нинди таланган, йолкынган иске-москы булуына игътибар иттем. Ябык идек без, ямьсез идек…

**1 укучы С.Хәкимнең "Язгы кәрваннар" шигырен укый.**

Укытучы. Укучылар, безнең арада шушы авыр елларны үз күзләре белән күргән, үзләрендә кичергән апалар бар. Бүген без аларны сөйләшүгә чакырдык. Алар безгә балачаклары турында сөйләргә килделәр.

**(Сугыш чоры балалары чыгышы)**

Укытучы. Бүген бөтен кешенең теләге бер: сугыш булмасын, мондый авырлыкларны күрергә туры килмәсен. Язгы кәрваннар булып йөрергә язмасын иде.

**Чара "Матур булсын" дигән җыр белән тәмамлана.**

Вахитова Ләйсән Асаф кызы,
Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

## Ялгышулар кыйммәткә төшә
## (IX сыйныфта Аяз Гыйләҗевнең "Күзгә-күз" повестен дәрестән тыш өйрәнү)

Максат: укучыларның фикер алыша, вакыйгаларны анализлый, үз карашларын дәлилли белү күнекмәләрен үстерү; яшүсмерләрдә ихтыяр көче, рухи ныклык, шәфкатьлелек кебек сыйфатлар, дустанә хисләр тәрбияләү.

Җиһазлау: Аяз Гыйләҗевның портреты; китапларыннан күргәзмә, язучы турында истәлекләр.

Тибы: диспут-дәрес.

Дәрес барышы:

Укытучы. Хәерле көн, укучылар!Без бүген якташ язучыбыз Аяз Гыйләҗевның иҗатын өйрәнүне дәвам итеп, аның "Күзгә-күз әсәре"н укып килергә тиеш идек.

Әсәр менә ничек башланып китә: Быел яз алар Наза белән өчәүләшеп Гафур Кәрамовның каберенә өч агач утырттылар.

Ак каен – Назадан...

Чыршы – Җәүдәттән...

Имән – Нәгыймнән...

Ак каен – мәңге якты булсын өчен!

Чыршы – мәңге яшел булсын өчен!

Имән – мәңге нык булсын өчен!..

Агачлар үзләрен утыртучы геройларны кайсы яктан ачалар? Без бу турыда бераз соңрак җавап табарбыз.

– Вакыйга кайда бара? Төп герой – кем ул?

– Шәһәрдә. Әсәрнең төп герое – Җәүдәт.

– Җәүдәтләрнең гаиләсе турынданиләр белдегез?

– Җәүдәт әти-әнисе белән шәһәр фатирында яшиләр. Әтисе Хәкимҗан Вәлитов – 50 яшендә, депода слесарь, сабантуйларның батыр көрәшчесе, яман гадәтләре юк. Улының музыка белән мавыгуын хупламый, спорт белән шөгыльләнүен тели. Хатыны Зөһрә апаның малайны артык иркәләвен өнәми, тавыш шуның өчен генә булгалый.

Җәүдәт исә ябык, озын буйлы. Балыкка йөрергә ярата, күптән магнитофонлы булырга кызыга. ГПТУда яхшы укый. Тимер юлда машинист булырга тели. Локомотив йөртү буенча аларна депоның атаклы машинисты Гафур Кәрамов укыта.

– Наза – кем ул?

– Наза – Гафур Кәрамовның кызы. Алар Җәүдәтләр белән бер йортта яшиләр. Яшьләр еш очрашалар. Дуслар. Наза – өлкән сыйныф укучысы. Җәйге ялында лагерьда эшли. Җәүдәтнең начар егетләр белән аралашуын сизә. Аның тайгак юлга кереп китүдән саклый, һәрчак ярдәмгә килә.

– Җәүдәт нинди егетләр белән аралаша соң?

– Алик белән Морат егетне йомшак итеп катыга утырталар. Башта, Наза алдында коймадан сикерттерәләр. Янәсе, куркак түгел. Соңрак үзләренең балык тотрага йөрүләре белән Җәүдәтне кызыктыралар. Балыкка йөрергә яраткан Җәүдәт аларга иярә. Аларга тагын Саша, Нәгыйм ияреп ике көймә белән елгага чыгалар. Ул кармак белән биш-алты балык тота. Башкалар ятьмә белән сөзеп, ике чиләк тоталар. Нәгыйм ун килоны базарда аткарып, эчемлекләр алып килә. Уха. Шәраб. Җәүдәтнең башына китә. Шәһәрдән узасы карбыз вагоннарын таларга сүз куешалар. Айныгач, үкенә. Тегеләргә каршы килә. Кыйнала. Әти-әнисе хәсрәттә.

– Гафур абыйсы аңа болай ди: “Аракының ике койрыгы булу – берсе ялган, икенчесе караклык. Күзгә күренми үсәләр. Итәгеңне караштырып йөр”. Шуннан соң Җәүдәт дөньяга Гафур Кәрамов күзләре белән карый башлый: эш, хезмәт, авырлыкны җиңү чыннан да юкка гына яшәмәвеңне раслау бит! Җәүдәт моннан соң тыныч кына яши аламы?

– Юк. Аңа бик кыенга туры килә. Аны төрле җирләрдә сагалап торалар, кыйныйлар. Алик аңа үзендә хәнҗәр булуын сиздерә: “Бу хәнҗәрнең очында кемнеңдер җаны бар, Жан” (Җәүдәтне алар шулай дип атыйлар).

Җәүдәт буталчык дуслыкның акрын-акрын үз муенына элмәк булып уралуын тоя. Вәгъдә биреп ташланган шул. Бер-ике карбыз урланганнан берни дә булмас, дип тә уйлый. Икеләнә. Бармаса? Алар күбәү, кансыз. Җәүдәт – юаш. Пычак очына куелган җанын саклар өчен ул төнге эшкә бара. Ләкин, станциядә ул рельсның бер башы ярылган икәнен күреп ала, поездга каршы йөгереп, аны туктата, авариядән саклап кала. Аның батырлыгы турында газетага язалар. 50 сум акча белән бүләклиләр. Тик Аликлар төркеме шул арада ярты вагон карбызны урлый. Җәүдәткә дә өлеш акчасы китерәләр, магнитофон алырсың, диләр. Ул акчаларны өйгә алмый, түбәдән төшүче су торбасына тыга. Аларны иртән яңгыр юып төшерә. Кешеләр акча җыя.

– Зөһрә апа да унбиш сум тотып керә. Ире ташларга куша. Андый җиңел акча кирәк түгел аларга. Әнисенә тәрәзә пәрдәләрен яңартырга Җәүдәт үзенең илле сум бүләк акчасын бирә. Җәүдәтнең Аликлар белән мөнәсәбәте ничек дәвам итә?

– Алик аны Моратларга китерттереп, группадашы Валерийның ачкычын урларга куша. Бай егетләрнең фатирын чистартырга өметләнәләр. Җәүдәт баш тарта, аны тагын кыйныйлар., урамга чыгарып аталар. Әнисе милициягә бара. Кыйналуы турында врач белешмә бирә. Ләкин егет Нәгыймне күрсә дә, берсен дә танымадым, ди.

– Соңыннан Җәүдәт Нәгыйм белән дуслаша. Ничек була соң ул?

– Терелгәч, Җәүдәт Нәгыймнәргә бара. Укырга чакыра. Аликның күрсәтмәләрен үтәмәскә киңәш итә. Берне үтерү җиңел, икене булдыра алмас, ди. Көн саен диярлек Нәгыймгә килә, КВНга чакыра, туган көненә Наза белән бүләк бирәләр. Мондый җылы мөнәсәбәтне күреп, Назыйм да үзгәрә.

– Назага да бандитлардан хат килә. Нәрсә турында була ул?

– Назага: “Җәүдәтең акылга утырмаса, кыслаларга ризык итәбез гәүдәсен”, дип язалар. Кыз аны әтисенә укыта. Гафур абыйсы егетне барысы турында да сөйләргә мәҗбүр итә. Депо директоры белән сөйләшеп, үзенә ярдәмче итеп алдыра. Озакламый, алар юлга чыгып китәләр. Наза озатып кала. Йөкне кирәкле урында калдырып, яңа состав тагып кайтырга чыгалар. Алик Нәгыймне эчертә, Җәүдәт шәһәргә кайтырга тиеш түгел, ди. Нәгыйм каршы килгәч, аны бикләп калдыралар. Блокпосттагы деңур Санияне бәйләп, бандитлар урамга ыргыталар. Үзләре поездны туктаталар. Моратта мылтык. Ата. “Ул түгел, ул түгел!” – дип чинап кычкырганы ишетелә.  Гафур үз урынына сынап карарга дип, Җәүдәтне утырткан була... Җәүдәт поездны үзе генә алып кайта.

– Байтак вакыт үткәннән соң, Нәгыйм Җәүдәтнең ярдәмчесе булып йөри башлый. Гафур каберенә алар өчәү, Наза, Җәүдәт, Нәгыйм өч агач утырталар. Җәүдәтләрнең тепловозына “Гафур Кәрамов” исеме бирелә.

– Укучылар, эчтәлек һәм персонажлар белән таныштык. Әсәрне искә төшердек. Әсәр нәрсә турында?

– Әсәр яшьләрнең, тормыш юлына аяк басканда, авырлыклар белән очрашуы турында. Җәүдәтнең беркатлы булуыннан файдаланып, бандит егетләр аның йомшак якларыннан файдаланып, үзләренә буйсындырдылар. Бик тиз аңласа да, егеткә алар тозагыннан чыгу җиңел булмады. Тозак аны, төпсез сазлыкка суыргандай, һаман үзенә батырды. Әти-әнисе, Наза, Гафур абыйсы ярдәме белән ул чын кеше булып кала алды. Корбансыз да булмады. Кадерле кешесе Назаның әтисе һәлак булды.

– Ул бүгенге көндә дә актуальме?

– Әйе. Хезмәт сөймәгән, җиңел тормыш белән яшисе килгән, башкаларны рәнҗетүдән курыкмаган яшьләр бүгенге тормышта да очрый. Алар Алик кебекләргә тиз ияручән була.

– Җәүдәтне дә шул категориягә кертәбезме?

– Юк, ул эшне ярата. Магнитофон алырга күптән кызыга. Ләкин әти-әнисенең мөмкинлеге булмый. Балык тотарга ияпә. Үзенең дә кармакка эләгүен сизми кала.

– Бу күңелсез хәлләр килеп чыкмасын өчен нишләргә кирәк иде соң?

– Танышлыгы чамалы кешеләр белән аралашмаска, балыкка бармаска, исерткеч эчемлек эчмәскә иде.

– Гафур Кәрамов каберенә утыртылган агачларга әйләнеп кайтыйк. Алар турында нәрсә өстәп әйтеп була?

– Наза ак каен утырта. Әтисе аны ак күңеле итеп тәрбияләгән. Тормышы да гел якты туслардән торсын.

– Җәүдәт чыршы утырта. Аның исәнлеге өчен корбан булган Гатуф абыйсын ул һәрчак истә тотар.

– Назыйм имән утырта. Ул Гатуф Кәрамов, Наза, Җәүдәт кебек дуслары ярдәме белән бөтенләй икенче кешегә – көчле ихтыярлы кешегә әйләнде.

– Язучылар, гадәттә, авылда туалар, шәһәрдә яшиләр. Яңа темаларга җирлек кайда да бар. Аяз Гыйләҗев “Күзгә-күз” повесте белән шәһәр даирәсенә дә кыю үтеп керә алуын бәхәссез раслады. Балалар турында ул шундый фикер белдергән иде: “Хәзерге балаларны инде без читтәнрәк торып, әмма тәҗрибәле күз белән күзәтәбез. Бүгенге балаларга карап кайчагында сокланабыз,  кайчагында мактанабыз, горурланабыз да! Мәгәр күңелләрдән бер шик гел китеп тормый: балалар хәзер иркә, аларның күпчелеге кара эштән чирканучы булып үсә, алар алдагы тормышларын ал да гөл итеп кенә күз алдына китерәләр, ансат

яшәргә, җиңел яшәргә омтылалар, үзләрен мул, рәхәт көннәргә генә әзерлиләр. Ә җир шарында беркайда да оҗмах юк, авырлыклар, кыенлыклар алда да булыр, тормышның авырлыгын бүтәннәргә калдырып, алга узарга тырышкан, ансат яшәргә хыялланган балалар хәзер күпчелек, менә шушы уй миңа бер дә тынгылык бирми. Һаман борчып килә. Һәм әйтергә кирәк, бу борчылулар кимү түгел, арта гына тора. Мин бер буын балаларын икенчесенә каршы куярга тырышмыйм, мәгәр хәзерге балалар арасында эгоистлар, шәфкать-мәрхәмәтне аңламаган, яшьтән үк куркыныч юлга баскан балалар күбрәк дип уйлыйм".

Димәк, безгә дә уйланырга сәбәп бар. Шушы урында без дәрес-диспутыбызны тәмамлыйбыз.

Дәрестә катнашучыларга билгеләр куела.

Өй эше: Җәүдәткә хат язарга.

Шәйхулова Миләүшә Фәгыйль кызы,
Җиңү бистәсе урта гомуми белем бирү мәктәбе, Азнакай районы

**Аяз Гыйләҗев иҗатына багышланган дәреснең (технологик картасы)**

| | |
|---|---|
| **Фән** | Татар әдәбияты |
| **Дәрес** | 1 |
| **Класс** | Рус мәктәбенең татар төркеме. 9 нчы сыйныф. |
| **Укытучы** | Шәйхулова Миләүшә Фәгыйль кызы |
| **Тема** | Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗаты. |
| **Максат** | Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру.<br>Прозаик һәм драматург А.Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү; Язучы эшчәнлегенең асылын ачыклау. А.Гыйләҗев иҗатына карата кызыксыну уяту. |
| **Көтелгән нәтиҗә** | Предмет буенча нәтиҗәләр: А.Гыйләҗевнең тормыш юлын, иҗатын белү; Шәхескә кагылышлы: А.Гыйләҗев шәхесенә хөрмәтле булу, иҗаты белән кызыксыну; Метапредмет нәтиҗәләре: моңа кадәр белгән һәм белмәгән белемнәрне, күнекмәләрне үзара бәйли, үз фикереңне дөрес итеп әйтеп бирә белү. |
| **Предметара бәйләнешләр** | Татар теле, тарих |
| **Җиһазлау** | А.Гыйләҗевнең портреты, А.Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗатын чагылдырган презентация, язучының әсәрләреннән күргәзмә, "Аяз Гыйләҗев. Истәлекләр". (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2006), "Сөембикә", "Мирас" журналлары."Азат хатын" ( "Сөембикә"), "Чаян", "Совет әдәбияты" ( "Казан утлары") журналларының элекке һәм хәзерге басмалары, видеоязмалар. |
| **Уку эшчәнлеге формалары** | Фронталь эш, индивидуаль, төркемнәрдә эш |

| **Дәреснең барышы** | | |
|---|---|---|
| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучылар эшчәнлеге** |
| **Мотивлаштыру-ориентлаштыру.** | Уңай психологик халәт тудыру.<br>- Исәнмесез, укучылар,<br>Хәерле көннәр сезгә.<br>Белем һәм тел ачкычларын<br>Телимен һәммәгезгә. | Укучыларның сәламләве. Актив эшчәнлеккә әзерләнү. |
| **Белемнәрне актуальләштерү.** | 1.Үтелгәннәрне кабатлау. Кроссворд чишү. (Кушымта1)<br><br>2. "Дөрес һәм дөрес булмаган фикерләр" (Эй Ар Гайд структурасы буенча эш. Дәрес башында һәм | Кроссвордны чишү ( вертикаль буенча Аяз Гыйләҗев дип языла), җавапларын экран буенча тикшерү. Үзбәя.<br>Дәреснең темасын билгеләү. Дәфтәргә числоны, дәрес темасын язу.<br>Таблицаны тутыру. |

| | | |
|---|---|---|
| | ахырында тутырыла. ( Кушымта 2) | |
| **Уку мәсьәләсен кую.** | 1. - “... Язучы -үз халкының рух сакчысы, намусы. Мин шулай була алдыммы? Белмим. Бу дөньяда иң авыры – үз-үзеңә хөкем чыгару... ”, - дигән А.Гыйләҗев. Без бүген сезнең белән шуны ачыкларбыз. | А.Гыйләҗев сүзләре белән танышу. Бер укучының тактадан укуы. Эш дәфтәренә А.Гыйләҗев сүзләрен язып кую. |
| **Уку мәсьәләсен өлешләп чишү** | Презентация буенча А.Гыйләҗевнең тормыш юлы, иҗаты белән таныштыру. | 1.Презентация белән танышу. Әңгәмәдә катнашу.<br>2.А.Гыйләҗев чыгышын тыңлау. “Әти-әнием турында” |
| | А.Гыйләҗев әсәрләре белән таныштыру.Кыскача мәгълүмат бирү.<br>А.Гыйләҗев – прозаик. (“Язгы кәрваннар” әсәреннән өзек уку.)<br>А.Гыйләҗев әсәрләре – сәхнәдә.(“Өч аршын җир” спектакленнән өзек күрсәтү.)<br>“Бибинур” фильмы турында мәгълүмат бирү. | А.Гыйләҗев әсәрләре буенча төзелгән күргәзмә буенча әңгәмәдә катнашу.<br><br>“Бибинур” фильмы турында фикер алышу. |
| | А.Гыйләҗев әсәрләрен тәрҗемә иткән шәхесләр турында видеоязма күрсәтү. | А.Гыйләҗев әсәрләрен тәрҗемә иткән шәхесләр турында видеоязма карау, тәрҗемәләре турында сөйләшү. |
| **Ял моменты** | Татар халык бию көе куела, туктатып, җавабы сан булган сораулар бирелә.<br>Песинең ничә аягы бар? Кеше ничә бияләй кия? Өчпочмакның ничә почмагы бар? | Бию, көй туктау белән парлашу(өчәү, дүртәү) басу.<br><br>Парсыз калучыларның уеннан чыгуы. |
| **Материалны беренчел ныгыту.** | А.Гыйләҗев турында ниләр белүләрен ачыклау. | Тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйләү. |
| **Дәреслек өстендә эш** | 1. А.Гыйләҗев турында дәреслектә бирелгән материал белән танышырга, хронологик таблица төзергә бирем бирү.<br>2. Сорау- җавап.<br>А.Гыйләҗевнең 90 еллык юбилеен республика күләмендә зурлап үткәрүне сорап, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына мөрәҗәгать белән чыгарга кирәк. (Төркемнәргә “тәрҗемәчеләр”, “прозаиклар”, “драматурглар”, “режиссерлар” дип язылган карточкалар таратыла). Һәр төркем А.Гыйләҗевнең шул өлкәдәге хезмәтен дәлилләп чыгыш ясарга тиеш. | А.Гыйләҗев турында дәреслектә бирелгән материал белән танышу, хронологик таблица төзү.<br><br>Сорауларга җавап бирү, сайлап уку.<br><br>Һәр төркемнән бер укучының җавабын тыңлау |
| **Кабатлау һәм ныгыту күнегүләре**. | 1. “Дөрес һәс дөрес булмаган фикерләр” (Эй Ар Гайд структурасы буенча эш. Кушымта1) | Берничә укучының чыгышын тыңлау.(Мин ничек уйлый идем, хәзер нәрсә белдем) |
| | 2. А.Гыйләҗев турында күренекле кешеләрнең фикерләре белән таныштыру. | Экраннан А.Гыйләҗев турында күренекле кешеләрнең фикерләре белән танышу. |
| **Рефлексия, дәреснең нәтиҗәләре, бәяләү, үзбәя** | - Ничек уйлыйсыз: дәрес башында куелган сорауга без уңай җавап бирә алабызмы? Сез А.Гыйләҗевкә нинди җавап бирер идегез? | Үзләренең эшләренә бәя бирәләр |
| **Өй эше** | Өй эше бирү.<br>1)А.Гыйләҗевнең әсәрләре исемлеген төзергә.<br>2) “Җомга көн, кич белән” әсәрен тулысынча укырга. | |

| | | |
|---|---|---|
| | 3)“Җомга көн, кич белән” әсәре буенча буктрейлер ясарга (төркемнәрдә эш). | |

## Аяз Гыйләҗев иҗатына багышланган дәреснең (технологик картасы)

| | | |
|---|---|---|
| **Фән** | Татар әдәбияты | |
| **Дәрес** | 2 | |
| **Класс** | Рус мәктәбенең татар төркеме. 9 нчы сыйныф. | |
| **Укытучы** | Шәйхулова Миләүшә Фәгыйль кызы | |
| **Тема** | Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн, кич белән...” повестенда Бибинурның кешелеклелек сыйфатлары. | |
| **Максат** | 1.Әсәр белән танышу, анализлау.<br>2. Укучыларда кешелек җәмгыяте турында күзаллау булдыру;<br>3. Бибинурның рухи дөньясын, эш-гамәлләрен анализлау;<br>4. Укучыларда мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек хисләре тәрбияләү; | |
| **Көтелгән нәтиҗә** | Предмет буенча нәтиҗәләр: Әдәби әсәрне анализлый белү, фразеологизмнарны билгели белү;<br>Метапредмет нәтиҗәләре: проблеманы куя һәм чишә, анализлый һәм нәтиҗә чыгара белү;<br>Шәхескә кагылышлы: гомуми кешелеклелек сыйфатларына ия булырга омтылу. | |
| **Предметара бәйләнешләр** | Татар теле, халык авыз иҗаты, рус әдәбияты | |
| **Җиһазлау** | А.Гыйләҗевнең портреты, Тест, “Тасма”, видеофильм, дәреслек, экран. Солженицынның “Матренин двор” әсәре. Дәреснең эпиграфы язылган плакат:<br>“Көчлелегең белән горурланма,<br>Кешелегең белән горурлан.”(М.Җәлил) | |
| **Уку эшчәнлеге формалары** | Фронталь эш, индивидуаль, төркемнәрдә эш | |
| **Дәреснең барышы** | | |
| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучылар эшчәнлеге** |
| **Мотивлаштыру-ориентлаштыру.** | Уңай психологик халәт тудыру.<br>- Исәнмесез, укучылар,<br>Хәерле көннәр сезгә.<br>Белем һәм тел ачкычларын<br>Телимен һәммәгезгә. | Укучыларның сәламләве. Актив эшчәнлеккә әзерләнү. |
| **Белемнәрне актуальләш-терү. Өй эшен тикшерү.** | Һәр төркемнән 3 кешегә тест эшләргә, 1 кешегә кластер тутырырга кушыла.<br>1.Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗаты буенча тест үткәрү. (Тестлар экран буенча тикшерелә)<br>2. А.Гыйләҗевнең прозаик һәм драматург икәнен дәлилләү. | 1.Тестларны үтәү.<br><br>Үзбәя.<br><br>2.А.Гыйләҗевнең проза һәм драма әсәрләрен барлау. Кластер тутыру. |
| **Уку мәсьәләсен кую.** | Тасма.(тасмадагы сүз мәгънәле кисәкләргә бүленеп язылган, шул урыннан бөкләнгән.)<br>кеше лек ле лек | Сүз төзелеше ягыннан тикшерү. |
| | – Сез ничек уйлыйсыз, без бүген нәрсә турында сүз алып барачакбыз? | Дәреснең темасын билгеләү. Числоны, теманы язу. Дәреснең эпиграфын язып кую. |
| **Уку мәсьәләсен өлешләп чишү** | 1.Ф.Яруллинның “Сорау һәм җавап” шигырен уку.<br>2.Әңгәмә.<br>- Кешелеклелекне сез ничек аңлыйсыз?<br>- Кешелекле дип без нинди сыйфатка ия кешеләр турында әйтәбез?<br>- Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>- Кешелеклелек турында тагын нинди | Әңгәмәдә катнашу.<br><br>Мәкальләрне дәфтәргә язу. Мәгънәләрен |

| | | |
|---|---|---|
| | мәкальләр беләсез? | аңлату. |
| | А.Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” әсәре турында мәгълүмат бирү. | Әсәр буенча эшләп килгән буктрейлерлары белән таныштыру (төркемнән 1 кеше чыгышы).<br>Әсәрнең эчтәлеген кыскача сөйләп чыгуы. |
| | Сүзлек эше | Өзектә булган таныш түгел сүзләрнең мәгънәсен ачыклау. |
| | Актер укуында әсәрдән өзек тыңлату. Укыган өлеш буенча әңгәмә үткәрү. | Актер укуында әсәрдән өзек тыңлау. Повестьтан өзек уку. Укыган өлешнең эчтәлеге буенча әңгәмәдә катнашу. |
| | -Язучының тел байлыгы ничек чагыла? (фразеологизмнарны табу) | Дәреслектәге өзектән фразеологизмнарны табу. Шул урыннарны сайлап уку. Мәгънәләрен ачыклау. |
| **Ял моменты** | Татар халык бию көе куела, туктатып, җавабы сан булган сораулар бирелә. Песинең ничә аягы бар? Кеше ничә бияләй кия? Өчпочмакның ничә почмагы бар? | Бию, көй туктау белән парлашу(өчәү, дүртәү) басу.<br><br>Парсыз калучыларның уеннан чыгуы. |
| | “Бибинур” фильмы турында мәгълүмат бирү. Фильмнан өзек күрсәтү. | Фильмнан өзек карау. |
| **Материалны беренчел ныгыту.** | - Бибинур кем ул?<br>- Бибинур Гайшә кабере янына ни өчен килгән?<br>- Бибинурда булган кешелеклелек сыйфатларын табыгыз.<br>- Балаларның әниләренә мөнәсәбәте ничек?<br>- Тормышта мондый хәлләр булырга мөмкинме?<br>- Кайсы рус язучының нинди әсәре “Җомга көн кич белән” повестена аваздаш? | Әңгәмәдә катнашу. Сорауларга җавап бирү.<br><br>Әсәрдән шул урыннарны табып уку. |
| **Кабатлау һәм ныгыту күнегүләре.** | -Кешелекле дип без нинди сыйфатларга ия булган кешеләргә әйтәбез?<br>- Әсәрдәге кайсы образларда бу сыйфатларның киресен күзәтәбез?<br>Бу шакмакларда шул сыйфатларның кайсылары яшерелгән икән. Табып карыйк әле. (Кушымта 2)<br>“Блума” кубигын тутыру. (Кушымта 3)Парларда эш. Төсле тасмалар таратыла. Укучылар җавап биргәч, тасмалар тактага беркетелеп бара. | Кешелеклелекне аңлатучы характер сыйфатларын барлау.<br>Әсәрне тулысынча укыган укучыларның җавабын тыңлау.<br>Таблицада яшерелгән сүзләрне табу.<br><br>Һәр парның үзенә бирелгән тасмаларга сораулар язуы. Җавап бирү. |
| **Рефлексия.** | 1. -Кешелеклелек турында әдәбияттан нинди мисаллар китерә аласыз? | Җавап бирү, мисаллар китерү |
| **Өй эше** | 1.Әсәрдән тел-сурәтләү чараларын табарга.<br>2.Бибинур турында хикәя төзеп сөйләргә. | Үзбәя |
| Билгеләр кую. | Укучыларның белемнәрен бәяләү, билгеләр кую. | Үзбәя |
| Дәрескә нәтиҗә ясау. | Дәресебезне Ф.Яруллинның “Сорау һәм җавап” шигыренең соңгы строфасы белән тәмамлыйсым килә.<br>Һич яхшылык эшли алмасаң син,<br>Кешеләргә бик-бик теләп тә,<br>Яхшы теләк телә,<br>Ул да кайчак | |

| | | |
|---|---|---|
| | Зур көч өстәп куя йөрәккә.- Бу юлларны барыбыз да хәтеребездә саклербыз дип өметләнәм. | |

Кушымта 1.

Ф.Яруллинның “Сорау һәм җавап” шигыре

Кабатлыйм мин бер сорауны
Өнемдә һәм төшемдә
“Кеше булып яшәргә
Нәрсә кирәк кешегә? “
Диңгез әйтә: Тирәнлек.
Урман әйтә: Бердәмлек.
Таулар әйтә: Горурлык.
Юллар әйтә: Турылык.
Җир эндәшә: Юмартлык.
Чык суы әйтә: Сафлык.
Яшен әйтә: Кыюлык.
Ипи әйтә: Олылык.
- Гүзәллек,- диләр Гөлләр.

- Иреклек, - диләр Җилләр
- Нык канат, - ди бөркетләр
- Биеклек, - диләр Күкләр.
Һәм шушылар өстенә
Кирәк тагын иң элек,
Кешене кеше иткән
Бер нәрсә – кеше-лек-ле-лек!
Һич яхшылык эшли алмасаң син
Кешеләргә бик-бик теләп тә,
Яхшы теләк телә,
Ул да кайчак
Зур көч өстәп куя йөрәккә.

Кушымта 2

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| И | Г | Ш | Ә | Ф | Т | Ь | Л |
| Я | Е | Л | Е | К | А | Л | Е |
| Р | Д | Е | К | Я | Г | Ы | М |
| Ш | Ә | К | | К | М | Ы | Л |
| Л | М | Л | Е | Е | Ә | Т | Р |
| Е | Ч | Е | Л | Е | Р | Х | А |
| Ә | Д | Ә | П | Л | Е | Ә | М |
| Г | И | Е | Л | Т | Ә | М | Ю |
| Ъ | Т | И | Б | А | Р | Л | Ы |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| И | Г | Ш | Ә | Ф | Т | Ь | Л |
| Я | Е | Л | Е | К | А | Л | Е |
| Р | Д | Е | К | Я | Г | Ы | М |
| Ш | Ә | К | | К | М | Ы | Л |
| Л | М | Л | Е | Е | Ә | Т | Р |
| Е | Ч | Е | Л | Е | Р | Х | А |
| Ә | Д | Ә | П | Л | Е | Ә | М |
| Г | И | Е | Л | Т | Ә | М | Ю |
| Ъ | Т | И | Б | А | Р | Л | Ы |

Кушымта 3

| | |
|---|---|
| Гади сорау | - Әсәр ни өчен шулай аталган?<br>- Бибинур гомерен кемнәргә багышлаган?<br>- Әсәрдәге вакыйгалар кайсы көнне бара?<br>- Әсәрнең төп герое кем? |
| Ачыклаучы сораулар | - Әгәр мин дөрес аңласам, Бибинурның балаларының шундый булуында аның да гаебе бар дип саныйсыз?<br>- Ялгышмасам, сез Миңлегөлнең корреспондент чакыруын хупламадыгыз?.... |
| Интерпретацион (аныклаучы) сорау | - Ни өчен Бибинур тәрбияләгән балалар шундый булып чыккан?<br>- Зәкиянең улы ни өчен Бибинурга бүләк алып кайта? |
| Иҗади сорау | - - Ничек уйлыйсыз, вакыйгалар алга таба ничек дәвам итәр?<br>- Бибинур бу балаларга үги булмаса, хәл үзгәрер идеме?<br>- Авылга корреспондент килеп киткәч, үзгәреш булырмы?<br>- Газетада нинди эчтәлектәге язма чыгар дип уйлыйсыз? |
| Гамәли сорау | - Бибинур урынында булсагыз сез нишләр идегез?<br>- Тормышта сезнең мондый хәлләрне күзәткәнегез бармы?<br>- Сез Бибинурга нинди киңәш бирер идегез? |
| Бәяләүче сорау | - Бибинурның кылган гамәлләренә сезнең мөнәсәбәтегез?<br>- Күршедә яшәп, бергә уйнап үскән ике гаилә балаларының әниләренә мөнәсәбәте нәрсә белән аерыла? Ни өчен дип уйлыйсыз? |

Юнысова Әлфия Вәдүт кызы,
Әлмәт төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**А.Гыйләҗев “Дүртәү”**
**(4 нче сыйныфта әдәби укудан дәрес эшкәртмәсе)**

**Дәреснең максатлары:** күренекле язучы А.Гыйләҗевның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирү; ”Дүртәү” әсәренең мәгънәсенә төшендерү, автор әйтергә теләгән фикерне табу; йөгерек уку күнекмәләрен үстерү; әсәр ярдәмендә укучыларда кешелеклелек, әхлак сыйфатлары тәрбияләү, дуслыкның кадерен белергә өйрәтү, бердәм, тату булганда гына барысына да ирешеп булуын аңлату.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Шәхескә кагылышлы:** Укучыларны тормышта ярдәмләшеп яшәү кирәклегенә, хезмәткә хөрмәт, дуслыкның кадере хисләренә төшендерү.

**Метапредмет: Танып-белү УУГ:** логик фикерләү күнекмәсенә ия булу; тиешле мәгълүматны куллана белү; дәреслек белән эш итә белү.

**Коммуникатив УУГ:** укытучының сорауларына җавап бирү; укытучы һәм сыйныфташларыңны тыңлый белү, дәрестә актив катнашу; парлап эшләү.

**Регулятив УУГ:** укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү; теманы аңлау дәрәҗәсен билгеләү; эш сыйфатына бәя бирә белү.

**Предмет буенча:** әсәр геройларына бәя бирә белү.

**Җиһазлау:** А.Гыйләҗевнең портреты, язучының төрле елларда басылган китаплары, дәреслек, презентация, скрипка рәсеме, Р.Фәхретдиннең “Балаларга үгет-нәсыйхәт” китабы.

**Дәрес төре**: әдәби әсәрне өйрәнү дәресе.

**Кулланылган методлар:** 1)өлешчә эзләнү; 2)иҗади уку.

**Алымнар:** 1)сорау-җавап; 2)әңгәмә.

**Принциплар:** 1)оптимальлек; 2)укыту-тәрбия берлеге.

**Дәрес планы.**

**I.Оештыру этабы**(2 мин):

1)исәнләшү;

2)дәрес алып бару өчен уңай психологик халәт тудыру.

**II.Актуальләштерү этабы**(6 мин)

1) дуслык турында мәкальләр уку;

2)”Нәрсә ул дуслык?” соравына җавап бирү.

**III.Уку мәсьәләсен кую**(3 мин)

1)Ш.Галиевнең “Дуслык балы” шигырен уку;

2)Дәрес темасын ачыклау, максат кую.

**IV.Уку мәсьәләсен чишү**(24 мин):

1) А.Гыйләҗевнең тормыш юлы турында мәгълүмат бирү;

2) А.Гыйләҗевнең “Дүртәү”әсәрен (повестьтән өзек)уку;

3) Сорау-җавап алымы ярдәмендә хикәянең геройларын барлау, вакыйганың вакытын һәм урынын билгеләү, авторның төп фикерен ачыклау;

4) Әсәрнең төп идеясен табу ярдәмендә балаларга кешеләрнең бердәм булганда гына зур көчкә ия булуларын төшендерү, ихтыяр көче тәрбияләү.

**V.Ныгыту этабы** (6 мин):

1) логик мәсьәлә уку, аның ярдәмендә “Дуслык-иң зур байлык һәм бәхет” дигән фикер үткәрү;

2)”Дуслык” төшенчәсенә билгеләмә бирү, дуслыкның төрләрен ачыклау.

**VI.Йомгаклау этабы.Рефлексия**( 3 мин):

1)нәтиҗә чыгару;

2)белемнәрне бәяләү;

3)өй эше бирү.

**Дәрес барышы**

**I.Оештыру этабы**(2 мин):

1)Исәнләшү:

-Хәерле көн, укучылар! Менә без тагын “Әдәби уку” дәресен башлап җибәрәбез.Эшлекле дәрес, күңелле дәрес булсын ул.

2)Шаулап уку:

а)тактада язылган шигырьне пышылдап уку;

б)шигырьне бергәләшеп кычкырып(хор белән) уку.

Зәңгәр күк-кояш белән дус,
Иген кыр белән.
Җәйләр-җылы яңгыр белән,
Чишмә җыр белән.

Күлләр аккошлар белән дус,
Май-сирень белән.
Төн якты йолдызлар белән,
Мин синең белән.

*Р.Вәлиева*

**II.Актуальләштерү этабы**(6 мин):

*Укытучы*: Ә хәзер тактага күз салыгыз әле укучылар.Анда нәрсә дип язылган?Яле, Мөслим, укып күрсәт әле!

*Укучы:* Йөз сум акчаң булганчы – йөз дустың булсын.

Дус беленер авырлыкта, ир беленер батырлыкта.

Дусың булмаса – эзлә, тапсаң – югалтма!

*Укытучы:* Балалар, бу сүзләр ничек атала әле? (Алар “Мәкальләр” дип атала).

*Укытучы:*Бик дөрес.Ә нәрсә соң ул дуслык? Ничек уйлыйсыз, бердәмлек сүзе дуслык сүзенең синонимы була аламы? (Укучыларның җаваплары тыңлана).

**III.Уку мәсьәләсен кую** (3 мин):

*Укытучы:* Балалар, сезнең дуслык турында нинди шигырьләр, хикәяләр укыганыгыз бар? (Укучыларның җаваплары).

*Укытучы:* Мин сезгә хәзер Ш.Галиевнең “Дуслык балы” дигән шигырен укып китмәкче булам, тыңлагыз әле.

*Укытучы:* Шигырьдә ике кеше дуслыгы гына чагыламы? (Юк, милләтләр дуслыгы күрсәтелгән).

*Укытучы:* Дөрес.Димәк, балалар, без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшәчәкбез икән?Дәрес темасыннан чыгып нинди максатлар куярсыз? (Укучыларның җаваплары*)*

**IV.Уку мәсьәләсен чишү** (24 мин)

*Укытучы:* Бүген без якташ язучыбыз Аяз Гыйләҗев иҗаты турында сөйләшербез.

Прозаик һәм драматург Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. Авыл мәктәбенең тугызынчы сыйныфын тәмамлагач, унынчы сыйныфны Сарман урта мәктәбендә укый. Белем алуын Казанда университетта дәвам итә. Аяз Гыйләҗевнең башлангыч иҗат тәҗрибәләре студентлык чорына карый. Тематик яктан А.Гыйләҗевнең

күпчелек повестьлары авыл тормышына багышланган. Аларда кичәге һәм бүгенге авыл, аның гади кешеләре гәүдәләндерелә. Аяз Гыйләҗев – ике дистәдән артык драма әсәре авторы да. Аларның күбесе республика театрлары репертуарына кертелгән.

Аяз абый авылыбызда еш кунак була иде. Мәктәбебез укучылары белән дә еш очрашып торды. Рухи азык туплап, бик матур романнар язды.

Аяз абый Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә ия, аңа Татарстан Республикасының халык язучысы дигән мактаулы исем бирелгән. Аяз абый Гыйләҗев 2002 елның 13 мартында вафат булды. Быел мәшһүр язучыбызның тууына 90 ел тулды.

*Ял минутын уздыру (1 мин)*

*Укытучы:* Бүген без А.Гыйләҗевнең “Дүртәү” повестеннән өзек укырбыз.*(*Тактада “ымсыну”, “гыйбрәтле”, “утлап”, “чорма” сүзләре языла һәм аларның мәгънәләре аңлатыла.Башта укытучының үрнәк укуы тыңлана, аннан хикәяне балалар чылбырлап укыйлар.)

*Укытучы:* Укучылар, ни өчен бу әсәр “Дүртәү” дип аталган?*Фикерләр тыңлана.*

*Укытучы:* Геройларны барлап алыйк әле.Кемнәр алар? Әсәрдә кемнәр катнаша? (Дүрт малай, Хафиз бабай, әкияттә дүрт скрипка кылы).

*Укытучы:* Малайлар кая килгәннәр? (Атлар сакларга).

*Укытучы:* Алар арасындагы сөйләшүдән чыгып, нәрсәне ачыкладыгыз? (Алар үзара тату түгел, бер-берсе белән ызгышалар).

*Укытучы:* Ни өчен Хафиз бабай гыйбрәтле хәл турында сөйләргә тели? (Ул малайларның дус, бердәм булуларын тели).

*Укытучы:* ”Аерылганны – аю ашар, бүленгәнне бүре ашар” дигән татар халык мәкален әсәрдә нәрсәләргә карата мисал итеп китереп була? (Скрипка кылларына, алар аерым килеш куркыныч тавышлар гына чыгарганнар, гүзәл авазлар юкка чыккан).

*Укытучы:* Әйе, бик дөрес.Чыннан да, автор безгә дуслыкның кадерен белергә, бердәм, тату булырга кирәклеген әсәр эчтәлеге аша үзенчәлекле итеп җиткерә алган.

**V.Ныгыту этабы**( 6 мин):

*Парлап эшләү өчен бирем.*

*Укытучы:* Ә хәзер бүгенге дәресебезгә кагылышлы бер хикәя – башваткыч укыйм. ”Бер биек тау башында кечкенә генә йортта көтүче яшәгән. Яңгырлы бер төндә өч кеше аның ишеген шакыганнар.

- Сез кемнәр? Минем өем бик кечкенә, берегезне генә кундыра алам, - дигән көтүче.

- Без –Дуслык, Бәхет һәм Байлык.Иң башлап кайсыбыз керүен үзең хәл ит...”

*Укытучы:* Ничек уйлыйсыз, көтүче кемне сайлаган һәм ни өчен?Әйдәгез әле, парларда үзегезнең җавапларыгызны әзерләгез. (Дуслыкны).

*Укытучы:* Ни өчен? (Чөнки Дуслык керү белән, өйгә Бәхет тулган, Байлык килгән).

*Укытучы:* Әйе, бик дөрес.Димәк, хикәягә нәтиҗә ясап, сез нәрсә әйтә аласыз? (Дуслык – иң зур байлык һәм бәхет!)

*Укытучы:*Афәрин, балалар!Әйтегез әле миңа, дуслыкны нинди төрләргә бүлеп карарга була? (Кыз-малай дуслыгы, хайваннар, кошлар белән дуслык, милләтләр, илләр дуслыгы һ.б.)

**VI.Йомгаклау этабы.Рефлексия**(3 мин ):

*Укытучы:*Дәресебезнең ахырында безгә таныш булган Р.Фәхретдиннең “Дуслык әдәпләре” белән дә танышып алыйк.Без аның “Балаларга үгет-нәсыйхәтләр”ен узган темаларда да уңышлы кулландык.Әйдәгез әле, аларны бергәләп укый.

*Укучылар:*1.Дусларны яхшы кешеләр арасыннан эзләгез.

2.Дуслык сүздә түгел, эштә күренер.

3.Дуслар ярдәмче булсыннар өчен кирәк.

*Укытучы:* Бүгенге дәрестә без сезнең белән нинди хикәя укыдык?Аны кем язган? (А.Гыйләҗевнең "Дүртәү" әсәрен).

*Укытучы:* Автор әсәрдә нинди фикер әйтергә теләгән? (Һәрвакыт дус, бердәм булырга, дуслыкның кадерен белергә кирәк).

*Укытучы:* Бүген барыгыз да актив булдыгыз.Рәхмәт, балалар! Әйдәгез дәресебезне "Тугры дус" җыры белән тәмамлыйк әле!

*Өй эше бирелә, билгеләр куела.*

Харисова Илзирә Алмаз кызы,
Иске Кәшер урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**"Матур" хикәясендә кем матур?**

**(А.Гыйләҗевнең "Матур" хикәясе буенча сыйныф сәгате)**

Сыйныф: 3 нче сыйныф

Максат: укучыларны хикәя эчтәле буенча нәтиҗә ясап, изге гамәлләр кылу турында уйландыру.

Бурычлар: аңлап уку, укыганны аңлата белү, укылганны рәсемдә күрсәтә белү күнекмәләрен үстерү, ныгыту. Әйләнә- тирәдәгеләрнең һәм үзләренең эшләренә дөрес бәя бирергә өйрәтү, матур, дөрес сөйләм культурасы үстерү өстендә эшләүне дәвам итү;

Әйләнә-тирәдәгеләргә игелекле мөнәсәбәт, яхшы эшләр эшләргә омтылыш тәрбияләүне дәвам итү.

Җиһазлар: копьютер, экран, магнитлы такта, проектор, А.Гыйләҗевнең тормыш юлына багышланган презентация, әдипнең әсәрләре күргәзмәсе,"Татар халык мәкальләре" җыентыгы

Сыйныф сәгатенә әзерлек.

1. Укучыларның А.Гыйләҗевнең "Матур" хикәясе белән танышуын тәэмин итү: укучылар санынча ишәйтеп тарату һәм мөстәкыйль укуларына ирешү.
2. Әңгәмә аша аларның хикәяне аңлау дәрәҗәсен тикшерү.
3. Хикәя эчтәлеге буенча иллюстрацияләр ясату.
4. Изге эшләр турында мәкальләр туплау.

**Сыйныф сәгатенең барышы**

I. Оештыру моменты. Уңай психологик халәт урнаштыру.

- Укучылар, хәерле иртә. Бер-беребезнең хәлен сорашып, елмаеп алабыз да урыннарыбызга утырышабыз. Сыйныф сәгатен башлап җибәрәбез.

II. Төп өлеш. Укылган хикәя буенча әңгәмә.

- Сез укып, матур рәсемнәр ясап килгән хикәя ничек дип атала?
- Аның авторы кем? (А.Гыйләҗев турында берничә слайдтан торган презентация күрсәтелә, аның безнең якташыбыз икәненә басым ясала).
- Әсәрнең геройлары кемнәр?
- Искәндәр турында без нәрсәләр белдек? Кайсыгыз авырып ятучы Искәндәрне рәсемгә төшерде? Рәсемне күрсәтеп кенә калмыйбыз, укучылар, нәрсә тасвирлаганыгызны сөйлибез, ягъни рәсемебезне яклыйбыз.

- Разыя нинди кыз? Аның турында нәрсәләр белдек? Кемнәр аны рәсемгә төшерде? Рәсемегезне яклагыз.

- Укучылар, ә ник хикәя "Матур" дип атала? Кем песине төшерде? Хикәядә песи нишли?

- Менә бу рәсемдә өчпочмаклар төшерелгән. Аларны кем пешерде икән?

- Әсәрнең исеме песи белән генә бәйлеме? Автор матурлык турында язганда песине генә күз алдында тотты микән? Бу турыда ял итеп алгач сөйләшербез.

III. Ял моменты.

IV. Белемнәрне системага салу.

- Укучылар, "Матурлык" төшенчәсен сез ничек аңлыйсыз?

- Килешәм, безнең табигать искиткеч матур. Слайдларга игътибар итик әле, анда шундый матур күренешләр бирелгән. (Табигать күренешләре тасвирланган рәсемнәр күрсәтелә).

- Ә матур эшләр буламы, укучылар? Санап карыйк әле, кеше нинди матур эшләр эшли ала? Сез әйтә барыгыз, мин аларны тактада терки барам. (Укучыларның җаваплары языла).

- Матур эшләрне тагын ничек атап булыр иде? (Игелекле, изге эшләр)

Нәтиҗә ясау. Шулар арасыннан балалар да башкара ала торганнарын аерып алу.

- Разыя матур эш эшлиме? Сезнең нинди изге гамәлләр кылганыгыз бар? (Балаларның җавапларын тыңлау).

- Ә песине ачуланабызмы? Җавабыгызны дәлилләгез.

- Кемнең песие бар? Ул ниләр эшли белә? (Җаваплар тыңлана).

V. Мәкальләр китабы белән эшләү.

Изгелек турында мәкальләр табу, аларның мәгънәләрен аңлату.

Һәр көн игелекле гамәлләр кыл, изге эшләр башкар. Изгелек ит тә – суга сал, балык белмәсә халык белер. Игелекле эшнең иртәсе-киче юк. Яхшылык барысын да җиңәчәк. Кылган эшләрең белән мактанып йөрмә. Изгелек эшен озакка сузарга ярамый. Изгелек иткән юлда калмас. Изгелек итә алмасаң, яманлык кылма.

VI.Рефлексия. Укучылар, якташыбыз А.Гыйләҗевнең "Матур" хикәясе бик тирән мәгънәле булып чыкты. Язучы абый безне нинди булырга чакыра? Кеше нинди эшләр башкарырга тиеш? Шундый эшләр башкарса, ул нинди була? Нәтиҗә ясыйбыз: изге эшләр эшләсәң, матур буласың.

Без дә бүген авырып яткан сыйныфташыбыз Илдарның хәлен белергә барырбыз, килештекме? Сыйныф сәгатебез тәмам.

Хәбибуллина Сөмбел Габдулла кызы,
Әтәс төп гомуми белем бирү мәктәбе, Актаныш районы

**Аяз Гыйләҗев "Язгы кәрваннар" әсәре буенча сценарий**

Укытучы – күпкырлы шәхес. Үз фәнебезне тирәнтен белү белән беррәттән, класстан тыш чараларда укучыларның төрле яклап сәләт-талантларын ачу да безгә бурыч итеп куела. Җиңү бәйрәменә карата оештырылган сәхнә күренешләре бәйгесендә VIII сыйныф укучылары, А.Гыйләҗевнең "Язгы кәрваннар" әсәрен сәхнәләштереп, мәктәптә уңышлы чыгыш ясадылар. Әлеге сценарийны Сезгә дә тәкъдим итәбез.

**Язгы кәрваннар**

(1 пәрдә, 4 күренеш)

Катнашалар:

Х ә к и м җ а н – колхоз рәисе

И б р а һ и м – үсмер егет

Д а м и р – үсмер егет

Ә д и л ә – яшь кыз

С а б и р а т т ә й – олы яшьтәге апа

*Вакыйга Бөек Ватан сугышы елларында гади татар авылында бара.*

Беренче күренеш.

*Моңлы музыка тавышы. Кәнсә бүлмәсе. Бүлмәдә председатель Хәкимҗан абзый утыра. Алдындагы кәгазьләргә текәлгән. Ишек шакып, Ибраһим керә.*

**Ибраһим.** Исәнме, Хәкимҗан абзый. Менә, укып бетереп кайттым.Чаллыдан. Тракторчы дигән кәгазь бирделәр.

**Хәкимҗан** (*карамыйча*). Ярар, энем, булдыргансың.

**Ибраһим.** Сөенмәдең, ахры, Хәкимҗан абзый.

**Хәкимҗан.** Сөенәм, үскәнем, бик шатланам.

**Ибраһим.** Кул кысып котламадың. Документымдагы билгеләргә дә күз салмадың.

**Хәкимҗан.** Күңелем белән бик котладым, үскәнем. Тик күңел бит, әллә ничегрәк дип әйтимме, икегә бүленгән. Яртысы, олы яртысы елый аның, үскәнем, синнән яшерене юк. Күзгә кырып салырлык та бөртек юк. Атлар барысы да – өрлектә. МТС машиналарына өмет бар, мәгәр чират кайчан җитәр?

**Ибраһим.** Трактор бирәчәкләрме соң?

**Хәкимҗан.** Аннан ни файда? Инеш буеннан вак таш җыеп чәчәрсеңме? Менә бүген нәрәт килде. Сарман ягыннан, Кәсле дигән глубинкадан 300 ц солы симәнәсе язганнар. Иртәгәдән шуны ташый башларга кирәк. Кәслегә, иртәгәдән дә калмый, ишетәсеңме, җитмеш биш чана чыгарырга кирәк. Ә ул 75 не әфсен укып җыясыңмы? Шүтке түгел, 65 чакрым диләр аны! Ә җибәрмәсәң – бәла! Атна-ун көннән юл өзеләчәк. Өзеләчәк, көт тә тор, син ашыкканда гел шулай була ул, үскәнем. Ярты авыл – карт-коры, яртысы – аксак та туксак. Менә син чана тартып барасыңмы? Кесәңдә дукамент, син дә трактор дауларга килгәнсең.

**Ибраһим.** Дауламыйм, Хәкимҗан абый. Мин бары кайтуымны әйтергә дип кенә килгән идем.

**Хәкимҗан** *(Ибраһимның иңенә кулын сала).*Даула син, үскәнем, даула. Әгәренки даулашмасак, эшебез җайга китәчәк түгел безнең. Дауларга кирәк. Тракторын да, машинасын да – барын да даула. Булачак ул трактор, бирәчәкләр аны. Тик менә журна дигәне чәчне агарта! Солы - Кәследә. Алтмыш биш чакрым! Солыны атна арасында ташып бетерергә кирәк, пример әйтик, җитмеш биш чана чыгарсак... чана саен өчәр пот салсак...

**Ибраһим.** Ир-ат дүрт потны да тарта ала, Хәкимҗан абый.

**Хәкимҗан.** Ашыкмыйк, үскәнем, өчәрләп чамалап карыйк... *(алдында яткан чут төймәләрендә саный).* Ике йөз дә егерме биш пот була. Тик менә җитмеш биш чананы каян табарга? Олы мәшәкать бу, бик олы...

*Шулчак ишек ачыла, ап-ак мамык шәлгә уранган, ак пирчәткә кигән Әдилә килеп керә.*

**Әдилә.** Исәнме, Хәкимҗан абый. Ибраһим да кайткан икән, исәнме.

**Ибраһим.** Мин кайтырга киткән. Менә син ничегрәк?

**Әдилә.** Мин дә менә... җизнине өйләндереп кайттым.

**Хәкимҗан.** Ниндирәк кеше алды инде?

**Әдилә.** Күршеләрендә кодача тиешле бер апа бар иде. Ире сугыштан кайтмаган, бер малае белән тора. Шул ике тол бергәләп оя кордылар.

**Хәкимҗан.** Гомерле булсын!

**Ибраһим** (*шатланып*). Әдилә, алайса, бөтенләйгә кайттың инде?!

**Әдилә.** Әйе, шулай дип торам.

**Хәкимҗан.** Кайтуың яраган, Әдилә. Менә солы симәнәсе ташырга керешәбез. Син дә барырсың.

**Әдилә.** Кая?

**Хәкимҗан.** Кәслегә.

**Әдилә** (*көлеп*). Бик якын икән. Күрше-тирәдән, әйтик шул ук Сарсаз глубинкасыннан симәнә алып булмыймыни? Анда да бардыр ич солы. Әллә Кәследә мөгезлесеме?

**Хәкимҗан** (*җитдиләнеп*). Ә-ә, үскәнем. Кыз бала шул син, җиңел уйлыйсың. Һе, хатын-кызның шул... Кайсы глубинкада нәрсә бар, анысы инде аның дәүләт сере. Сугыш сере белән бер анысы. Безнең катнаш юк анда. Менә Чаллыдан килгән нәрәт. Пичәт басылган, кулы куелган. Кәследән диелгән и бетте-китте. Барасыңмы?

**Әдилә.** Ярар, Хәкимҗан абый, мин болай гына әйттем. Барырмын.

**Ибраһим** (*сөенеп*). Мин дә барам.

**Хәкимҗан.** Рәхмәт яугырлары, менә тагын ике чана табылды. Ярар, иртәгә кәнсә алдына килерсез. Матри, озатышып йөреп, соңга каласы түгел. *(Яшьләр чыгып китә)*

II күренеш

*Март ае иртәсе. Кәнсәләр алды. Чаналар тарткан хатын-кызлар, яшүсмерләр төркеме. Кәнсәдән Хәкимҗан абый чыга.*

**Хәкимҗан.** Җыелдыгызмы, туганнар? Рәхмәт сезгә, авыр юлдан куркып калмаганыгыз өчен. Инде исән-имин йөреп, симәнә белән кайтырга язсын. Юлда бер-берегезне ташламагыз. Быелгы читен яз соңгысы булсын. Тезләнсәк тә, егылыр өчен түгел, сикереп торып, йөгереп китәр өчен тезләнербез. Быел яз бирешмәскә кирәк, туганнар. Ягез, ипләп кенә юлга кузгалыгыз, юлларыгыз уң булсын.

**Сабирәттәй.** Хәкимҗан, минем оланнарыма күз-колак булырга Бәдәрне булса да җибәрерсең инде. Юлыбыз озын һәм озак. Балалар үзләре генә калды. Ягез, туганнар, утырып бер дога кылыйк, эшләребез уң булсын!

III күренеш.

*Ибраһим, Әдилә, Дамир, Сабирәттәй сәхнәдә.*

**Ибраһим.** Тизрәк завод тавына җитсәк, хәл алыр идек инде.

**Әдилә.** Сабирәттәй, хәлең начарландымы әллә? Түз инде, завод күренеп кенә тора. Анда инде врач бардыр, каралып чыгарсың. (*Сабирәттәй эндәшми, үз чанасындагы капчыклар өстенә ава*)

**Әдилә.** Егетләр, тиз булыгыз, ни дә булса эшләгез. Күрмисезмени, Сабирәттәйнең хәле авырайды бит.

**Дамир.** Ибраһим, минем капчыкларны үз чанаңа сал. Сабирәттәйне минем чанага утыртыйк. (*Ашыгып, Сабирәттәйне утырталар. Әдилә белән Ибраһим авылга юнәләләр.)*

*Музыка. Ул югалту, аерылу хакында. Башларын түбән игән Әдилә, Ибраһим, Дамир керәләр.*

**Ибраһим.** Я, нишлибез инде хәзер? Сабирәттәйнең үле гәүдәсен дә, орлыкларны да алып кайтырга безнең көчебез җитмәячәк. Орлыкны да һич калдырырга ярамый. Әле кайтасы юл озак.

**Дамир.** Сабирәттәйгә хәзер ашыгуның кирәге юк. Тик менә әниләренең кайтуын дүрт күз белән көткән балаларына ничек күренербез дә ничек кенә бу ачы хәбәрне җиткерербез икән?!

**Әдилә.** Мескен, бәхетсез сабыйлар икән. Әтиләренең дә үлем хәбәрен алганга әле күп тә үтмәгән иде бит. Инде әнисез дә калдылар. Тулы ятим булып яшәүләрне ходай күрсәтмәсен, үземнән чыгып әйтәм. Ләгънәт яусын бу сугышка! Күпме кешене ятим калдырды, кан-яшь түктерде.

**Ибраһим.** Әйдәгез, кузгалыйк булмаса. Сабираттәйне яңадан килеп алырбыз (*китәләр*). *Музыка.*

IV күренеш.

*Авыл. Кайтучыларны Хәкимҗан абый каршылый.*

**Хәкимҗан.** Кайттыгызмы, үскәннәрем? Сабирәттәй күренми, кая ул?

**Дамир.** Без кайттык. Менә Сабирәттәй генә...

**Әдилә.** Үлеп калды.

**Ибраһим.** Сабирәттәйне берәр ат белән барып аласы иде. Исән чагында күргән михнәтләре өчен булса да бер яхшылык булыр иде.

**Хәкимҗан.** Ярар, үскәннәрем, ничек тә шулай итәрбез. Тик менә балаларына кем генә әйтер инде? Аларны кая куярбыз? Их, бу сугыш, башы беткере немец! Сезнең дә балалыкны, яшьлекне урлады бит.

Үскәннәрем, сезгә иртәгә тагын юлга җыенырга туры килер инде. Бу юлы еракка түгел, Сарсазга гына. Түзегез инде, үскәннәрем, түзегез. Дөньялар гел болай булмас, бер рәтләнми калмас. Сез дә язгы кәрваннар булудан туктарсыз.

*“Сарман” көе яңгырый.*

*Пәрдә.*

Сабирҗанова Җәмилә Фаткылгаен кызы,
Казан шәһәре, Яңа Савин районының
91 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе

## Федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыру шартларында Аяз Гыйләҗев иҗатын өйрәнү. А.Гыйләҗевнең “Өч аршын җир” повесте

| | |
|---|---|
| **Укытучы** | Сабирҗанова Җәмилә Фаткелгаен кызы |
| **Предмет** | Әдәбият |
| **Тема** | Федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыру шартларында Аяз Гыйләҗев иҗатын өйрәнү.А.Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» повесте. |
| **Сыйныф** | 7 нче сыйныф, татар төркеме |
| **Дәреснең төре** | Яңа белемнәрне ачу дәресе |
| **Педагогик технологияләр** | Шәхескә юнәлдерелгән технологияләр |
| **Максат** | 1.А.Гыйләҗевнен тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирү.<br>2.Уку күнекмәләрен формалаштыру өстендә эшләү; эчтәлек буенча анализ ясап нәтиҗә чыгарырга, геройларга характеристика бирергә өйрәнү; коммуникатив аралашуны, сөйләмне үстерү максатыннан чыгып төркемнәрдә эшләргә өйрәтү.<br>3.Укучыларның логик фикерләү сәләтен, мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын һәм танып-белүне үстерүгә ярдәм итү.<br>4.Повесть аша укучыларда кешелеклелек, хезмәт кешесенә хөрмәт, туган як белән |

| | |
|---|---|
| | горурлану, аны ярату хисләре тәрбияләү<br>5. Әсәргә анализ барышында язучының стилен билгеләү һәмтәнкыйди фикер йөртү аша вакыйгага заман күзлегеннән бәя бирү.<br>6. Геройларның яшәү кыйбласы аша нәтиҗәләр ясау һәм рухи сәламәтлек тәрбияләү. |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | **Предмет**- әсәрнең сюжет- композиция үзенчәлеген ачыклый белү, тулы эчтәлеген аңлау.<br>**Метапредмет** – анализ ясау күнекмәләрен камилләштер, сәбәп- нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру, гомумиләштерүләр ясый белү.<br>**Регулятив** - әсәрнең төзелешен ачыклау,геройның эш-гамәлләрен бәяләгәндә, үзеңнең, башкаларның фикерен белү,төп нәтиҗәне чыгарганда активлык күрсәтү.<br>**Танып белү** - белемнәргә таянып, әсәрдәге төшенчәләргә кагылышлы мәгълүмат табу, анализлау аша аны бәяләү, гомуми нәтиҗә чыгару.<br>**Коммуникатив -** башкаларның җавапларын тыңлау, үз фикереңне дәлилли белү.<br>**Шәхескә караган** - әсәрдәге вакыйгалардан үрнәк яисә гыйбрәт алу. |
| Эш формалары | фронталь эш, төркемнәрдә һәм парларда эш, индивидуаль эш |
| **Предметара бәйләнешләр** | Татар теле, тарих |
| **Ресурслар** | Куллану өчен әдәбият: Аяз Гыйләҗев “Сайланма әсәрләр” , 2004<br>Казан.Татарстан китап нәшрияты, 2012. Техник чаралар: компьютер, презентация, мультимедиа. |

**Дәреснең барышы**

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучылар эшчәнлеге** |
|---|---|---|
| **Мотивлаштыру-ориенлаш-тыру.** | -Исәнмесез укучылар! Хәерле иртәләр сезгә,утырыгыз .Сез бүген бик матур!<br>Бу атнада Казанда нинди яңалыклар булып үтте? | Исәнмесез! Хәерле көннәр!<br><br>Укучылар санап үтәләр. |
| **Белемнәрне актуальләш-терү.** | -Укучылар,сезгә өй эше итеп кем иҗаты белән танышып килергә бирелгән иде? Әйдәгез әле искә төшерик, аның турында кем нәрсә белә?<br>-Әйе,укучылар, бик дөрес. А.Гыйләҗевнең бик күп повесть, хикәяләре бар. “Дүртәү", "Язгы кәрваннар", "Өч аршын җир", "Җомга кон, кич белән", "Әтәч менгән читәнгә"повестьлары һәм башка хикәяәре.Аның китаплары бик күп, мин аларны киләчәктә укырсыз дип ышанып калам. | Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. Авыл мәктәбенең тугызынчы сыйныфын тәмамлагач, унынчы сыйныфны Сарман урта мәктәбендә укый.<br>1948 – 1950 елларында ул – Казан дәүләт университеты студенты була.Бер укучы презентация ярдәмендә биографиясен дәвам итә. |
| **Өй эшен тикшерү** | Әйдәгез әле А.Гыйләевнең "Өч аршын җир" повестен укыганлыгыгызны тикшереп карыйк (слайд белән эшләү)<br>Бирем: бирелгән җөмләләрне әсәр эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз.Ә хәзер эшләрегезне бер-берегез белән алмашып тикшерегез. | Укучылар бер-берсе белән алмашып тикшерәләр. |
| **Проблемалы ситуация булдыру.** | - Балалар безнең дәреснең максаты нинди булыр? Без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшербез икән?<br>- Рәхмәт, утыр. | - Бүгенге дәресебездә без А.Гыйләҗевнең "Өч аршын җир"повестен анализларбыз, образларга характеристика бирербез һәм әсәрдә әйтелгән фикернең мәгънәсенә төшенергә тырышырбыз. |

| | | |
|---|---|---|
| **Уку мәсьәләсен куюу һәм чишү** | Тактада язылган җөмләгә игътибар итегез әле,укучылар.Бергә укыйк әле. "Кешегә бәхетле булу өчен нәрсә кирәк?"<br>- Сез бу сорауны ничек аңлыйсыз? Дәрес ахырына сез бу сорауга тулырак җавап бирерсез дип ышанам. | Укучылар бәхет төшенчәсенең асылын аңлатып крыйлар,сорауларга җавап бирәләр. Ләкин төп фикерне әйтеп бирә алмыйлар.<br>Көтелгән җаваплар -Бик үк аңлап бетермибез, чөнки без әле бу турыда сөйләшмәдек |
| **Уку мәсьәләсен өлешләп чишү** | **...**Кеше яши, һәм аны соңгы сулышына кадәр гаделлеккә ышаныч озатып бара. Кешелек дөньясы яратылганнан бирле, күпме заманалар үзгәрде. Кешелексез шартларда калып, олы әхлакый югалтулар кичергәндә, чын кеше булу миссиясен адәм баласы үтиме? Бер-берсенең исән чагында кадерен беләме? Кайчагында гомереңнең бер саплам җеп кебек кыска калганын сизәсең... Ул шулкадәр кыска...<br>Аяз Гыйләҗев иҗат иткән герой – гыйбрәтле,кырыс<br>Укучылар түбәндәге сорауларга җавап биреп карыйк әле:<br>1. Адашы Мирвәлинең бәгыренә тиярлек гамәлләрен сез ничек бәялисез? Авылда, син киткәннән бирле ,Мирвәли исемен кушмыйлар – ди ул.<br>2. Мирвәлинең кулак малае булып тууына кем гаепле?<br>3. Усаллык, золым белән корымланган җанны ничек дәваларга?<br>4. Үземә булмады, этләргә дә булмасын, дип барлык калган әйберләрне тураклап, юкка чыгарып дөрес эшлиме?<br>Ә ни өчен соң фаҗига килеп чыга? Фаҗиганең иң куркынычы – Мирвәлигә җәмгыять хыянәт итә, аны кешелек сыйфатларыннан биздереп, рухын изә. Совет идеологиясенең кеше аңына сеңдергән кануннары шундыйлардан була. | Мирвәли туып-үскән җирдән аерылу ачысын кичерә, буталчыклык, югалтулар, төзәтү мөмкин булмаган олы хата, кешеләргә булган ышанычын югалта, мәкер, усаллык, нәфрәт белән гомер уздыра.<br><br>Кулаклар дип аталган халык катламының көчләп күмәкләштерү чорында тир түгеп табылган байлыгын – шәхси милекне тартып алу чорындагы каршылыкларга түзә алмый Шәхразыйның улы. |
| **Ял моменты** | Мин сезгә төрле эшләр кушам, ә сез аларның киресен эшлисез.<br>Кулларны төшерәбез.Артка таба ике адым атлыйбыз.Алга таба ике адым атлыйбыз.Сулга бер адым атлыйбыз.Рәхмәт сезгә.Сез бик тә игтибарлы икәнсез. | Кулларны төшерәләр.Алга таба ике адым атлыйлар. Артка таба ике адым атлыйлар.Уңга бер адым атлыйлар. |
| **Яңа белем һәм күнекмәләрне куллану** | Образларга характеристика биреп карыйк әле.<br>Әйдәгез әле Финкин Мэпс алымын кулланып аларның характерына хас сыйфатларны билгелик.Карта-шар ясыйк әле.<br>-Балалар, без һәр образның характер сыйфатларын билгеләргә тырыштык.Хәзер аларга тулырак характеристика бирик .Нәрсә соң ул | Мирвәли – хезмәт кешесе. Тир түгеп табылган мал газиз һәм кадерле. Хакимияткә хезмәт иткән кешеләрнең дә тартып алырга хакы юк. Ул тавыш күтәрә. Аның эшләгән эшләре үзенә һәм гаиләсенә зыян сала.Хәзерге күзлектән караганда дорес тә бит. Ләкин ул чорда дөреслекне ярып салырга ярамаган.<br>Җирсеп, гомере буе бәгырен телгәләгән туган туфрагын сагыну хәсрәтеннән үлем |

| | | |
|---|---|---|
| | характеристика?(һәр образга тулы характеристика бирелә) | түшәгенә егылган хатыны - Шәмсегаян үлә. - Мирвәли, хатынының мәете белән сөйләшеп, тормышын күздән кичерә.<br>Шәмсегаянның васыятен табып укыйлар... Ничек уйлыйсыз, Мирвәли аны үтәрме?<br>Әйе, үти. (тактада эшләнә,һәр бала чыгып үзенең фикерен яза<br>Дәфтәрдән укыйлар |
| **Яңа белем һәм күнекмәләрне куллану** | -Укучылар образларны бер-берсеннән аерып торган сыйфатларны да табыйк әле.Бу эшне без парларда эшләрбез.Моның өчен плейсмэт консенсус алымын кулланырбыз.Бик яхшы укучылар.<br>-Уйлап карыйк әле балалар... бу образларны төсләр белән күрсәтергә теләсәк алар нинди булырлар икән?Һәр геройга нинди төстәге киемнәр кидерер идегез?<br><br>(Укучылар һәр образны үзләре теләгән төсләр белән күрергә теләүләре турында фикерләрен әйтәләр.<br><br>Укытучы төрле төстәге түгәрәкләр тарата, һәрбер укучы үзләренә ошаган төсне ала.<br>Төп образларны ни өчен, нинди төстә "киендерүләрен" әйтәләр, санап чыгалар.) | Уртак бер фикер әйтелә<br><br>(Һәр геройны нинди төс белән күрергә теләүләре әйтелә)<br>Малайның әнисенә ак төсне сайлыйлар, ак төстәге яулык, ак чәчәкле күлмәктән күрергә телиләр.Чөнки әниләрнең күңелләре ак, теләкләре ак.<br><br>Шәйхразыйга яшел төстәге күлмәк, башына яшелле - каралы түбәтәй кулайрак булыр, диләр. Ул бит гомер буе туган җирендә яши.<br>Ә Шәмсегаянга сары кулмәккә яшел яфраклар төшерелгән күлмәк бик килешер иде, чөнки ул җирне яратып, табигатькә гашыйк булып,туган авылын, туган ягын сагынып яши.. Ә сары төс - сагыш билгесе ул.<br>Ләкин теләге кабул була – Карачурада мәңгелеккә кала, җир куены аны үзенә кабул итә.<br>Мирвәлигә акка кара сызыклар төшкән күлмәк кидертергә була.<br>Ни өчен кара сызыклар төшкән күлмәк?Чөнки ул тормыш корып җибәргәндә бер ялгышлык ясый.<br>.Мирвәлинең яшьтән үк үз юлы – әтисе сызган юлга буйсынмый ул. Шәйхразый аны сайлау алдына куйгач та, Шәмсегаянны җитәкләп, төп йорттан, яхшы шартлардан аерылып, фәкыйрь Таифә карчыкка яшәргә китә<br>Ата-ана фатыйхасын алмыйча, читкә чыгып китүе тормыш иткәндә кыенлыклар тудыра,балалары да булмый, эти – әни ризалыгы кешене гомер буена баш очында озата бара диләр бит. Мирвәли дөньяда яшәү кыйбласын югалта. Шул чор системасы аның рухына нык йогынты ясый.<br>Рухи кыерсытуларга түзә алмыйча, кеше<br>башына сыймаслык адымнар ясый,ләкин гомеренең ахырына кадәр вөҗдан газабы кичереп яши.<br>Кисен Мирвәли ак күлмәген, аның куңеле бит начарлыкта булмый,ул үзенә үзе кайта, сон булса да ялгышлыкларын аңлап, тәүбәгә кайта.<br>Ак күлмәккә төшерелгән кара сызыклар да юкка чыгар,чөнки ул бәхетенең |

| | | |
|---|---|---|
| | | нәрсәдә булуын аңлады.<br>Авылдашларыннан бары өч аршын җир бирүләрен сорады.Ә авылдашлары аны гафу иттеләр. Мирвәли исә шул җиргә – өч аршын җиргә тезләнеп кала...<br>Чыннан да кешене өч аршын җир бәхетле итә. |
| **Рефлексия. Дәреснең нәтиҗәләре, бәяләү,үзбәя** | Укучылар без бүген нәрсә турында сөйләштек?<br>Сез туган җирегезне яратасызмы?<br>Чит җирләргә китәр идегезме?<br>Ни өчен?<br>Бу әсәр сезне нәрсәгә өйрәтә?<br>Дәресебезне Аяз Гыйләҗевнең якташы Р.Кәраминең сүзләре белән тәмамлыйсы килә:<br>“... Юкка гына әйтмәгәннәр: малын җуйган җиде ел елар, иленнән аерылган – гомер буе. Дөнья киң. Адәм баласы йөремсәк. Ул кай тарафка гына барып чыкмый. Әмма ул һәрчак кендек каны тамган җирен – изге туган ягын сагынып кайта. Чөнки аның бәхете – туган илендә, туган җирендә.”<br>Сораулар кую юлы белән дәреснең һәр этабына укучыларның анализ ясауларын оештыра. Уку мәсьәләсе чишелешенә, дәрестәге эшчәнлекләренә укучыларның игътибарын юнәтә. Укучыларның үзбәя куюларын оештыра<br>Укытучы.Без сезнең белән бүген нинди максат куйган идек?<br>Укытучы.Куйган максатка ирештекме?<br>Укытучы.Нинди юл белән ирештек?<br>Укытучы.Нинди нәтиҗәгә ирештек?<br>Укытучы.Бу сүзләрне кайда кулланабыз?<br>Укытучы.Нәрсәне яхшы эшләдек?<br>Укытучы.Нәрсә кыен булды?<br>Дәрестәге эшчәнлеккә бәя бирү.<br>Бәяләү һәм үзбәя куюны оештыру.<br>- Укучылар, дәрес сезгә ошадымы?<br>- Кем дә кем үзен бүгенге дәресне аңладым һәм башкаларга да аңлата алам дип саный, торып басыгыз!<br>"5"ле билгесе куела.<br>- Кем дә кем үзен бүгенге дәресне аңладым , ләкин башкаларга аңлата алмыйм дип саный, торып басыгыз!<br>"4"ле билгесе куела.<br>-Кем дә кем әле миңа активлыкны тагын да арттырасы бар дип уйлый, алар торып баса.<br>"3"ле билгесе куела.<br>Миңа да сезнең белән бик күңелле булды, булдырдыгыз! | Укучылар туган як турында үзләре белгән шигырьләрне укып күрсәтәләр.<br>“Иленнән аерылган – канаты каерылган”мәкаленең дөреслегенә тагын бер кат ышаналар.<br>Г.Афзалның "Туган җиреңнән китмә" шигырен укыйлар һәм анализлыйлар (кемгә туры килгәнен әйтәләр)<br><br>Җавап бирәләр. |
| **Өй эше** | 3 дәрәҗәдә өй эше тәкъдим итә.<br>1.Повестьның эчтәлеген сөйләргә.<br>2."Туган ягым" темасына презентация ясарга.<br>3."Туган ягым - яшел бишек"темасына | |

| | | |
|---|---|---|
| | сочинение язарга. (2-3нче биремнәрне эшләүдә сайлау мөмкинлеге бирелә)<br>Сау булыгыз. | |

Ганиуллина Римма Ясир кызы,
Сарман гимназиясе, Сарман районы

**Нәрсә ул бәхет?**

(8 сыйныфта Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәре белән танышканнан соң үткәрү өчен сыйныф сәгате эшкәртмәсе)

**Максат:** укучыларны “Нәрсә ул бәхет?” дигән темага уйланырга мәҗбүр итеп тормышта үз урыннарын табарга ярдәм итү; балаларның үз фикерләрен ачык, матур итеп башкаларга җиткерә, дәлилләп күрсәтә белүләренә ирешү; укучыларда рухи-әхлакый сыйфатлар тәрбияләү. Эзләнү һәм чагыштыру ярдәмендә укучыларның фикерләү сәләтен үстерү; укучыларда халкыбыздагы күркәм әхлак сыйфатларын үзеңдә булдырырга омтылыш уяту.

**Җиһазлау:** А.Гыйләҗев портреты һәм әсәрләре, 8 нче сыйныф өчен дәреслек, компьютер, проектор, газета-журнал материаллары

***Чара барышы:***

**Оештыру.Уңай психологик халәт тудыру.**

-Хәерле көн,укучылар.Утырыгыз.

Хәерле көн телим һәр бөҗәккә,
Хәерле көн телим гөлләргә.
Сөйкемлелек телим яшь кызларга
Һәм сабырлык телим ирләргә.

Хәерле көн телим юлчыларга,
Чәчәкләргә карап елмаям.
Җиргә якты, җылы нурын сипкән
Кояшыма карап куанам.

-Укучылар, бүгенге сыйныф сәгатебезне мин Ф.Зыятдинованың “Хәерле көн телим” дигән шигыре белән башлап җибәрдем. Бүгенге чарабызда минем үз фикерләрегезне дә ишетәсем килә.Мондый очракта үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен дә искә төшереп үтик:

- Бер-береңә ихтибарлы бул һәм бере-береңне хөрмәт ит;
- Үз фикерләреңне кычкырып һәм аңлашылырлык итеп әйтергә оялма;
- Кеше фикерен кире какма, ә үзеңнекен дәлилли бел;
- Иптәшеңне бүлдермә, азагына кадәр тыңла.

Мин сезнең барчагызга да исәнлек-саулык, бәхет телим.

**II. Кереш сүз**

**Укытучы:** *Нәрсә соң ул бәхет? Кайда соң ул? Ничек аны эзләп табарга?*

Укучылар! Без бик еш бер-беребезгә бәхет телибез. Безнең барчабыз да бәхетле булырга тели, без моңа омтылып яшибез, шуның өчен көрәшәбез. Бәхет турында күренекле кешеләр кызыклы гына фикерләрен әйтәләр, шагыйрьләр шигырьләр язалар, композиторлар аларга көй чыгаралар, җырчылар аларны башкаралар, ә без исә аларны яратып тыңлыйбыз. Бәхет турындагы бүгенге әңгәмә беркемне дә битараф калдырмас дип уйлыйм. Чөнки барыбызның да бәхетле буласы килә. Ә нәрсә соң ул бәхет, укучылар? Бәхет сүзен сез ничек аңлыйсыз?

Бәхет – тулы канәгатьләнү халәте һәм хисе дип язылган сүзлектә. Бәхет төшенчәсе булдыклы, сабыр, түземле, тәрбияле кешеләргә күбрәк елмая кебек. Мин сезгә берничә сорау бирәм, сез җавап бирерсез. Күзләрегезне йомдык...

Бәхет нинди төстә?

Җөмләне дәвам итегез: Бәхет – ул янәшәңдә ..

Бәхет нинди зурлыкта?

Бәхеткә кагылсагыз, сез нәрсә тоясыз?

Бәхетнең тәме нинди? (җаваплар тыңлана) Рәхмәт, күзләрне ачтык.

Җаваплар бик күп төрле, чөнки бу сорауларга җавапларны һәркем үзенчә күзаллый.

*Бәхет нәрсә ул?- дисезме,*
*Ул бит гаҗәп төшенчә.*
*Җаваплар булыр күп төрле-*
*Һәркем аңлый үзенчә...*

Бәхет турында мәкальләр дә күп:

Бәхет пыяла кебек, сакламасаң - уала. Акыллы кеше бәхетне көтеп ятмый. Үз-үзенә ышанган кеше бәхетле була. Бәхет җирдән чыкмас, тирдән чыгар.Ызгышкан җирдән бәхет качар.

Соңгысына игътибар итсәгез иде. Дус, тату гаиләгә дан җырлый ул мәкаль.

Күркәм, кодрәтле сүз иясе, үзенчәлекле, берәүне дә кабатламый торган, дөреслекне ярып салучы язучы якташыбыз, күптән түгел генә укыган "Язгы кәрваннар" повесте авторы А.Гыйләҗев "Кеше яши икән,бәхет татыр өчен яши ", - дип яза.Ул үзен бик бәхетле кеше дип санаган. Чөнки аның яраткан хатыны Нәкыя ханым, уллары – Искәндәр, Мансур, Рәшат һәм оныклары аңа иҗат итү өчен көч, дәрт биреп торганнар.

Ә үзе кебек бәхетле булу кәгыйдәсен гади генә итеп "Язгы кәрваннар повестенда аңлатып бирә.

Сезнең алда повестьтән бер өзек бирелгән. Тагын бер кат укып эчтәлекне искә төшерик. (Мәктәп китапханәсе сериясе, 26 нчы том, 122-125 нче битләр, өзек-өзек өлешләр)

Әңгәмә өчен сораулар:

Гаиләдә кемнәр яши?

Сәрвәр апа ире чукрак Габбас абыйдан тагы җиде кешене ашарга алып кайтырга рөхсәт соравы нәрсә турында сөйли?

Ни өчен бу гаиләне автор бәхетле дип атый?

Сөенечне кешеләр белән уртаклашуны сез ничек аңлыйсыз?

Шушы өзектә авторның әйтергә теләгән фикере нинди?

Әсәрдән өзекне кычкырып уку:

"Кешеләрне Габбас абыегыз гозерен үтәп кертәм, - диде Сәрвәр апа соңыннан... Мөгаен, ансы да хактыр. Юк, бу teләкләре уртак аларның, алар өй эчләре белән чиксез **бәхет** тоеп, сөенешеп яшиләр, үз бәхетләре белән кешеләрне дә шатландырыга телиләр.

Яшәүнең бөек максаты, кешенең иң гади сыйфаты шул түгелмени?"

Бәхет ул – тулы гаиләдә бер-береңне хөрмәт итеп яшәү икән бит. Өйдәге өлкән кешенең түрдә намаз укып утыруы да бу гаиләдә өлкәннәргә хөрмәт турында сөйли. Шушындый бәхетле гаиләдә яшәгән кеше башкаларны да сөендерергә ашыга.

Сугыштан соңгы елларда 20 кешене, аннан алдагы төндә генә 12 кешене ашатып чыгарулары – аларның нинди киң күңелле кешеләр булулары турында сөйли.

**Исеңдә тот!**

**Бәхетнең вакыт сынавын узган үз формуласы бар – ул уңайлы йорт, дус гаилә һәм яраткан эш.**

Һәркем кояшлы көнгә шат, күңеле күтәренке була. Шуңа да экранда кояш рәсеме. Аның һәр нуры бәхеткә илтә торган юл булсын.

1. Иң кадерле кешеләреңне ярату,алар белән бергә булу.

2. Бер мизгеллек *бәхет*

Ачыгу + ризык = бәхет

Сусау+ су = бәхет

Юксыну + очрашу = бәхет

3.Тынычлык, җир шарында сугышсыз тормыш

4. Хыялларыңның тормышка ашуы

5. Сәламәт булу

6. Игелекле эшләр эшләү

Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” повестендә шушы бәхет кояшының барлык нурлары да чагылыш таба. Хәтта безнең алда яткан кечкенә генә өзектән дә җавап табып була.

Укучылар белән барлык пунктларына да аңлатма эзләү һәм җавапларны аңлату.

1. Сәрвәр апа һәм Габбас абый гаиләсе
2. Кәрванчыларның ерак юлдан соң сыйланулары
3. Әсәр тулысы белән сугышның кайгы-хәсрәт булуын ача
4. Ибраһим һәм Адилә мөнәсәбәте
5. Габбас абыйның гарипләнүе
6. Сәрвәр апаның киң күңеллелеге мисалларында күреп була.

- Хәзер, балалар, сүзне сезгә бирәм. (Бәхет турында үз фикерләрен әйтәләр)
- Бүгенге әңгәмәбезне бер риваять яки гыйбрәтле хикәят белән тәмамлар идем.

Көннәрдән беркөнне өч бертуган чокырда утырган Бәхетне күрделәр. Агайларның берсе чокыр янына килеп, Бәхеттән акча сорады. Бәхет аңа, әлбәттә, бик күп итеп акча бирде. Агай нык сөенеп өйгә кайтып китте. Икенче туган үз чиратында Бәхеттән матур хатын сорады. Аның да теләген кәнагатьләндерде Бәхет.Агай хатыны белән тиздән күздән югалды. Өченче туган чокырга иелде. “Сиңа нәрсә кирәк?”- дип сорады аннан Бәхет. “Ә сиңа нәрсә кирәк?”- дип кабатлады агай. “Мине бу тирән чокырдан чыгарсаң иде”, - дип җавап бирде Бәхет. Агай кулын сузды да, Бәхетне чокырдан тартып алды. Аннары борылды да,барыр юлын дәвам итте. Ә Бәхет аның артыннан иярде...

Балалар, бәхет ул һәрчак янәшә, шуны онытмасак иде. Бәхетле булу өчен сәламәтлек тә, ярату да, матди яктан тәэмин ителеш тә, рухи байлык, дуслык, гаилә тормышы – барысы да кирәк. Алар бер-берсе белән тоташып бәхет чылбыры тәшкил итәләр.

”БӘХЕТ УЛ... Бәхет нәрсә ул? - дисезме? Төгәл әйтмәс берәү дә. Бәхет ул – бу җиһанда КЕШЕ булып яшәүдә.

Галимова Гүзәлия Рамис кызы,
Буа шәһәренең лицей-интернаты (сәләтле балалар мәктәбе)

**Бибинур – рухи матурлык символы**

УМК: Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы (татар балалары өчен): 1-11 нче сыйныфлар. – Казан: Мәгариф, 2010. – 111 б.Дәреслек, электрон белем бирү ресурслары, ноутбук, проектор, экран, слайдлар)

**Класс: 9 нчы сыйныф**

| Тема | **“Бибинур – рухи матурлык символы”**<br>**Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн, кич белән...” әсәрендә Бибинур язмышы** |
|---|---|
| Дәреснең максаты | Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн, кич белән...” әсәрен анализлау |
| Дәреснең бурычлары | **1.Белем бирү максаты**: укучыларның А.Гыйләҗев турындагы белемнәрен тирәнәйтү, “Җомга көн, кич белән...” әсәрендә чагылыш тапкан төп фактик мәгълүматлар белән таныштыру;<br>**2.Фикерләү сәләтен үстерү максаты**: үз тарихыңны белергә, яратырга,өйрәнергә,үткәннәрдән сабак, күргәннәрдән гыйбрәт алырга өйрәтү<br>**3.Тәрбия бирү максаты**: укучыларда игелеклелек, шәфкатьлек; ата-анага, өлкән буын кешеләренә мәхәббәт хисе тәрбияләү, дус.татау яшәргә теләк уяту |
| Планлаштырылган нәтиҗәләр | Предмет нәтиҗәләре:<br>**танып белү өлкәсендә**: әдәби әсәрне анализлау, аның билгеле бер жанрга каравын, теманы аңлау һәм формалаштыру, идеясен тотып ала белү.<br>**әхлакый кыйммәтләр юнәлеше өлкәсендә**: автор карашын, мөнәсәбәтен аңлау.<br>**коммуникатив өлкәдә**: әсәрне ишетеп кабул итү, аңлаешлы уку, эчтәлекне дөрес аңлау.<br>**эстетик өлкәдә**: сүзнең эстетик вазифасын, әдәби образларның сурәтләү көчен аңлау. |
| Дәрес тибы | яңа белемнәр ачу, рефлексия дәресе (дәрес-диалог) |
| Предметара бәйләнешләр | музыка, рәсем сәнгате, татар теле |
| Ресурслар:<br>төп<br>өстәмә | Төп: татар әдәбияты (рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен дәреслек), 2016<br>Өстәмә: слайдлар күрсәтү өчен проектор, экран, ноутбук, әсәрнең тулы варианты |
| Эшне оештыру | индивидуаль һәм төркемнәрдә эшләү |
| Төп төшенчәләр | тема, проблема, идея, анализ, нәтиҗә, чагыштыру |
| Педагогик технологияләр | өлешчә тикшеренү |

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Эшкә этәргеч бирүче сораулар һәм тәкъдимнәр** |
|---|---|---|---|
| **<u>Мотивлаш-тыру</u>**<br><u>2 мин</u><br>Максат: Уңай психологик халәт тудыру | Укучыларны уку эшчәнлегенә тарту | Дәрестә эшләү кагыйдәләрен искә төшерәләр:<br>кеше сөйләгәнне игътибар белән тыңла;<br>үз фикереңне ачык итеп әйт;<br>иптәшеңне урынсызга бүлдермә | Аудиоязмадан бәхет турында шигырь тыңлау.<br>***Бәхет***<br>*Нәрсә соң ул бәхет? Кайда соң ул?*<br>*Ничек аны эзләп табарга?*<br>*Тормышыңда берни уйламыйча,*<br>*Сөю утларында янарга.*<br>*Бәхетле булу нәрсә икән соң ул?*<br>*Тыныч һәм кайгысыз көннәрме?*<br>*Бу җирдәге һәрбер кешене*<br>*Язмышлар бәхетле итәрме?*<br>Дәресебез бер сулышта үтсен өчен нишлибез? |
| **<u>Актуальләшт ерү</u>**<br>6 мин<br>Максат: алган белемнәрне гомумиләштер ү, дәреснең темасын | Белем алуга эчке ихтыяҗ булдыру өчен шартлар тудыру<br>**Искәрмә:** балалар алдан ук “Бибинур” кинофильмын | Узган дәрестә А.Гыйләҗевнең “Җомга көн, кич белән” әсәре, аның төп герое Бибинур белән таныштык.<br>Бибинур сөйгән егете Мирзаһитны рәнҗетте, Зөһрәбануның каргышын алды. | Төп герйның ярдәмче геройлар белән мөнәсәбәте нинди? |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ачыклау | карыйлар. Әсәр тулысы белән өйдә укыла. Шуңа нигезләнеп, әсәрне йомгаклауга әзерлек эше алып барыла | | |
| | Әсәрнең кыскача эчтәлеге сөйләнелә, төп фикерләр әйтелә. Слайдлар күрсәтелә | Укучылар әсәрне төп дүрт өлешкә бүлүләре турында әйтәләр. | Әсәрне ничә өлешкә бүлдегез? Ярдәмче геройлар кемнәр? |
| | **Слайд №1.** Авыл йорты. Ятим калган балалар | 1 нче өлеш: Бибинурның соңга кадәр балалар бакчасында калган Нәҗипне өенә озатуы.<br>Бибинур - балаларын ярату һәм аларның миһербансызлыгын танып, бәргәләнүче герой. Бөтен яшьлеген, мәхәббәтен, бәхетен балалар хакына корбан итә. | Бибинур кем ул? Бибинур ни өчен Габдуллаҗанга кияүгә чыга? Балаларны ничек тәрбияли? Гбдуллаҗанга кияүгә чыгып, Бибинур дөрес эшләдеме? |
| | **Слайд №2**. Ишелергә торган йорт күренеше. Яшел чирәм баскан ишегалды | 2 нче өлеш:  Бибинурның бар малын сатып, булган акчасын җыеп, балаларына квартир, дача, машина алып биреп ялгыз калуы. Тапкан гына ана түгел, үстергән дә ана. Бибинур исә аларга ана гына түгел, ата да булды. Баларының шундый мәрхәмәтсез булып үсүләре, авыл халкы өчен генә түгел, Бибинурның үзе өчен дә сер. | Балаларның үсеп, кеше булгач, әниләренә мөнәсәбәтләре нинди? Бибинурны гаепле дип саныйсызмы? Бибинур карчык бу балаларга үги булмаса, хәл үзгәрер идеме?  Гомере буе кешеләргә яхшылык эшләгән Бибинур “бәхет” сүзен ничек аңлый? |
| | **Слайд №3.** Урманда учак күренеше | 3 нче өлеш: Тегәрҗеп авылы кешесе Җиһангирның Аксыргак авылына килүе. Бибинурның мәхәббәте.  Җиһангирның вакытсыз үлеме.<br>Җиһангир Аксыргак авылы рәисе. Олы йөрәкле Бибинурны чын күңеленнән кызгана, аңа ярдәм итә. | Җиһангир кем ул? Нигә Бибинур аны хөрмәт итә? Ничек уйлыйсыз ут, буа тавышы нинди образлар? |
| | **Слайд №4:** Сабантуй күренеше | 4 нче өлеш: Кунакларның Аксыргак авылы сабан туена кайтуы. Корреспондент килә дигән хәбәр таралу. Бибинурның Тегәрҗеп авылына сәяхәте.<br>Авыл кешеләре Бибинурны аңламыйлар. Һәрберсе үз көнен күреп яши. Зәкия дә әбинең җирен улына карап куйган, шуңа анның хәлен белгәли.<br>**“Бибинур – рухи матурлык символы”** | Аксыргак авылы сабан туена кемнәр кайта? Әби нинди тавыш ишетә? Авыл кешеләре әбине яратамы? Зәкиянең олы улы ни өчен Бибинурга мәк чәчәге төшерелгән кулмәклек бүләк итә? Ничек уйлыйсыз: бүгенге дәреснең темасы ничек яңгырар? |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **<u>Аңлау өчен авыр тоелган сорауны ачыклау өчен сынап карау этабы</u>**<br>4 мин.<br>Максат: Укучыларда килеп туган авырлыкны билгеләү | Укучылар алдына проблемалы сорау куя, проблемалы ситуациятудыра. Укучыга үз фикерен әйтер өчен юнәлеш бирә | Аерым-аерым да, төркемнәрдә дә җавап бирелә. Сорауларга җавапларның төрле вариантларын табалар. “Бәхәс” дискуциясе оештыралар. | Кемнәр алар маңкортлар? Бибинурның балаларын маңкортлар дип әйтеп буламы? Карабай нинди символ? |
| **<u>Физминутка</u>**<br>Максат: укучыларны ял иттерү | Җаваплы укучыны билгеләү | Күнегүләр ясыйлар | |
| **<u>Кыенлыктан чыгу этабы</u>**<br>4 мин<br>Максат: кыенлыктан чыгу юлларын билгеләү | Җавапка этәрүче сораулар бирә | Бибинурның балаларын Карабай белән тиңләү. Карабай- символ, ул – Бибинурның балаларын сурәтләп бирә торган явыз җаннарның берсе. Балалары – кешене кеше итеп бизи торган иң гүзәл сыйфатларны югалткан кешеләр. Күренми торган маңкортлар. | Ни өчен Бибинурның балалары аналарын ташлыйлар? Моңа кем гаепле? |
| **<u>Яңа алган белемнәрне практик куллану</u>**<br>6 мин.<br>Максат: Бибинурның сүзле портретын ясау | Сораулар бирә, эшнең эзлеклелеген тәэмин итә. Укучыларга эпиграф тәкъдим итә.<br>**Слайд №5.** “Изгелеккә явызлык белән җавап кайтару кешенең рухын җимерә” А.Гыйләҗев.<br>**Слайд №6**. Эпиграф. Бәхете булган кешенең улы ипле, кызы күрекле булыр. Татар халык мәкале | Индивидуаль фикерләр тыңлана, төркемнәрдә тикшерелеп, нәтиҗә чыгарыла: хәзерге заман- каты күңеллеләр заманы. Кеше байлык артыннан куып, туган җирен, нигезен, үстергән якын кешесен оныта. Бибинурның балалары да шушы төркемгә карый. Бибинур- искиткеч гүзәл герой. Барлык тереклекне тоеп, якын итеп, тормышны барлык нечкәлекләре белән кабул итә алган герой. Карабай да урманда бозылырга өлгергән. Корсагын туйдыру өчен һәркемне ботарлап атарга әзер.<br>Бибинурның бәхете – кешеләргә яхшылык эшләүдә, изгелек кылуда | Бибинурның изгелеге, шәфкатьлелеге нәрсәләрдә чагыла?<br><br>Әсәрдә бәхетле кешеләр бармы? Бибинурны бәхетле дип әйтә алабызмы? |
| | Әсәрне автор ике заманга аерып куйган: сугыш алды һәм сугыш чоры Бибинурның яшь вакыты); хәзерге заман (70 нче еллар) | Язучы игътибарны “хәзерге” гә юнәлтә. Повестьның буеннан-буена чорга бәя бирелеп бара. Авыллар бушап калган, җирләр эшкәртелмәгән. Менә яңа рәис килә. Авыл халкы аны башта килмешәк буларак кабул итсә дә, изге гамәлләре өчен, үз итә. | Әсәрдә автор төп игътибарны кайсысына юнәлтә? |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Слайд № 7**. Буа һәм юл рәсемнәре | Буа, ут, юл, кызыл тукыма<br>Буа тавышы Бибинурның күңелендә яшеренеп яткан Җиһангирга карата сөю хисен, туган җирне сагыну тойгысын, балаларына рәнҗүен чагылдыра. Буа туган җир, туган туфрак тавышы. Ул Бибинурны каядыр чакыра кебек, ләкин Бибинур карарларны үзе чыгара. Шәфкатьлелеге, изгелеге мәхәббәттән өстен чыга. Ул ятим балаларны сайлый.<br>Ут - яшәеш чыганагы, юл – Бибинурның күңел кичерешләре, тормыш юлы. | Автор әсәрдә нинди шартлы-метафорик образ сурәтләр куллана? |
| **<u>Материалны беренчел ныгыту</u>**<br>6 мин<br>Максат: Яңа алган белемнәрне практик куллана белү; үз фикереңне төзек һәм матур итеп әйтү. | Тормышта Бибинур язмышлы кешеләр турында әңгәмә кору | Әңгәмә кору, сорауларга җавап бирү.<br>Балаларның шәфкатьсезлеге, аналарның бәхетсезлеге.<br>Әниләрне генә түгел, туган илне, туган телне оныту. Илсез, телсез калган куркыныч кешеләр туу. | Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн, кич белән...” әсәрендә нинди проблемалар күтәрелә? Алар хәзерге заманда актуальме? |
| | | Әсәрнең исеме Бибинур һәлак булган көн белән бәйле. Татарларда “җомга көн үлгән кеше – изге дигән” ышану бар. Автор төп геройны изгеләр рәтенә бастыра. Бу фикер әсәр азагында да урын ала. | Автор әсәрен ни өчен шулай атаган? Җомга сүзе нәрсәне аңлата? |
| **<u>Мөстәкыйль эш</u>** 6 мин<br>Максат: үзләштерелгән белемнәр буенча нәтиҗә ясау | Мөстәкыйль эшләрне күзәтү | Әсәрдә фәлсәфи яссылыктагы яшәү – үлем каршылыгы бар. Автор Гайшә, Җиһангир, Бибинур үлемнәренә туктала. Асылда бу үлемнәр кешене мәңгеләштерә | Әсәрдә фәлсәфи яссылыктагы нинди каршылыклар бар? |
| **<u>Кабатлау һәм ныгыту күнегүләре</u>**<br>8 мин<br>Максат: алган белемнәрне гомумиләш-терү | Әсәрнең асылын аңлауга ярдәм итүче сораулар бирү.<br>Фикерләрне дөрес нәтиҗә ясауга юнәлтү. | Сюжет сызыгында үзәк каршылык Бибинур һәм Миңлегөл арасында чыга. Редакциягә хат язып, Миңлегөл авыл халкының фикерен җиткерә. Бу каршылык ярдәмне “читтән” көтү, якын кешеләрнең кеше проблемасына битараф булу проблемасын китереп чыгара.<br>Авыл кешеләре олы кешене кайгыртмый, алар бары тик балаларын гына оялтмакчы. Бибинурның эчке дөньясына төкереп карыйлар. Бу каршылыктан икенче проблема килеп туа: авыл халкы Бибинурның балалар хакына үз бәхетен корбан итүен аңлый алмый. Автор милли кыйммәтләр юкка чыга барганга борчыла. Әгәрдә без аларны яңадан | Бибинур гәҗиттә язылачак мәкаләне ничек күзаллый?<br>Сюжетта үзәк каршылык кемнәр арасында чыга? Илдә бу чорда урнашкан идеологик кануннар нәрсә китереп чыгарды? |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | тергезсәк, кешелекне дә саклап кала алыр идек. Бибинур белән Җиһангир – татар авылының җаны йөрәге. | |
| **<u>Рефлексия, өй эше</u>** 2-3 мин. Максат: үзеңнең, иптәшеңнең эшен бәяләү, билгеләр кую | Дәресне йомгаклау. Эшчәнлеккә нәтиҗә ясау. | 1. Кинофильмдагы Бибинурны әсәрдәге Бибинур белән чагыштырырга.<br>2. "Бибинур – рухи матурлык символы" исемле сочинение язарга. | Җөмләләрне язып бетер: "Бүген мин дәрестә ...... белдем. Миңа ...... кызганыч тоелды. Үземә ..... алдым. Укучылар, үзбәяләрегезне чыгарыгыз һәм билгеләрегезне куегыз.<br>Дәрес тәмам |

Салихова Айгөл Роберт кызы,
икенче санлы Җәлил урта гомум белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Аяз Гыйләҗевнең "Йәгез, бер дога" исемле роман-хатирәсендә репрессия елларының чагылышы (тарих укытучыларына дәрестә куллану өчен өстәмә материал)**

Күңелләрне шомландырып,йөрәкләргә мәңге җуелмас яра салган, сагыш-моңнарга уралган көннәр бар. Шуларның берсе – 30 октябрь. Бу көн XX гасырның 30-50 нче елларында Россиядә сәяси репрессиядән гөнаһсызга корбан булган һәм җәберләнгән ватандашларыбызны искә төшертә.

1930 нчы еллардагы вакыйгалар, колхозлашу еллары, гаепсез корбаннар, репрессия…

Сталин репрессияләренең иң хәтәр чоры булган 1918, 1924, 1930, 1937 елларда башланган террор гамәлләре һәр авылга, шәһәрдәге һәр урамга килеп җиткән. Төнге урамнарда кара машиналарда тужуркалы җәлладлар килеп бер гаепсез кешеләрнең өйләрен тентеп, үзләрен НКВД зинданнарына ташыган. Кулга алынганнарның күпчелеге дистә еллар буе төрмәдә, каторгада газапланган, һәлак булганнары чит җирләрдә торып калган: Магаданда, Колымада, НКВД ихатасында, ГУЛАГ лагерьларында.

Гаепләнүчеләрнең күпчелеген крестьяннар тәшкил иткән. Тарихтан билгеле булганча, репрессияләрнең иң югары ноктасы 1937 нчы елга туры килә. Өлкән кешеләрнең истә калганнары буенча, авыл кешеләренең күбесен Сталин исеменә каршы сүз әйткән дип кулга алганнар. Репрессия Аяз Гыйлэжевнең гаиләсен дә читләтеп үтмәгән.

"Йәгез, бер дога" исемле роман-хатирәсенә күз салыйк: "Әтием – Сарман тумасы, иң фәкыйрь "Ак ыштаннар мәхәлләсенең" имамы, 30 нчы еллар башында Алабуга тормәсендә үтерелгән Сәхәбетдин хәзрәт улы Мирсәет – Югары Баграж дигән авылга бара да топләнеп кала. Нигә туган тоягеннән ерак-тарак, чит-ят керәшеннәр арасында калырга булганын мин соңгы елларда гына аңладым. Мулла малае булуыннан курыккандыр, ахрысы! Намуслы, эчкерсез, сабыйлык матурлыгы бер чакта да уңып бетми торган керәшеннәр яшь укытучыны зурлап каршылаганнар. Күрә эти: монда гадел, тырыш халык яши. Кулакларны куганда да Югары авыллар үз араларыннан таза тормышлы крестьяннарны читкә сөрергә ирек бирмәгәннәр. Иң эшлекле, таза тормышлы кешеләрнең йорт-җирләрен алып мәктәп салганнар, авыл советы, колхоз идарәсе төзегәннәр... Кулак хуҗаларны үз ихаталарында калдырганнар, я таш амбарга, я мунчага күчергәннәр. Югары Баграж тирә-якта атаклы, тозек һәм нык авыл булган. 30 нчы елларда ШКМ (Яшь коммунистлар мәктәбе) ачканнар, аннары урта мәктәп. ... Баграж – сугыш алды елларының бер мәдәни үзәге иде. Мәктәптәге әдәбият түгәрәгенә генә 30-40 кеше даими йөри, күпләр шигырь яза... Кыскасы, Югары авыл үзе бер дәүләт булып яши иде".

Сәяси репрессия чорында нахакка гаепләнүчеләрнең, тоталитар режимнан зыян күргәннәрнең саны бүгенгәчә төгәл билгеле дә түгел.

Кечкенә Аяз өлкән класс укучыларының сәяси әңгәмәләрендә катнаша, "яшьтән үк җитди, сүзнең кадерен югалтмаска иярләнгән, урысчаны су кебек эчкән" Хәбир Зәйнуллинны аерып ихтирам итә: "Сүз, бәхәсләр асылда илдәге гаделсезлекләр турында бара иде – авыл кешеләре ач, фәкыйрьләр һаман бөлә бара, өй саен дүрт-биш бала, күбесе мәктәпкә йори алмый... Инде укыган өчен дә салым түләргә кирәк. Сүздән сүз чыгып, Хәбир егетләре кайбер адәмнәрнең авыллардан кинәт кенә югалуларына хәйран калалар иде... Иң гаҗәбе шул: егетләр бөтенесе бер нәрсәгә ышаналар – юлбашчыбыз Сталин бу хәлләрне белми икән. Болар һәммәсе дә минем яшьтән алган сәяси сабакларым иде".

...Соңрак, Сталин төрмәләрендә, ул бик күп үзе кебек нахакка рәнҗетелгән зыялылар, гади халык белән сәяси әңгәмәләр корыр, аларны һәр иҗат җимешенә – дистәләгән повесть-романнарына, пьесаларына, публицистик язмаларына, каләмдәшләренә, якыннарына юллаган күпсанлы хатларына теркәп калдырыр.

Сталин репрессияләре беренче чиратта зыялы катламны юк итә. Дистәләрчә татар язучылары нахакка гаепләнеп атып үтерелә, хезмәт лагерьларына, сөргенгә озатыла.

"Атаклы 1948-49 еллар бу! Илдә кешеләр аңын чираттагы "чистарту" бара... Шушы бер мәкалә үзе генә дә мине Черек күлгә илтеп ябарга азык була иде". 1950 елның 22 мартында 58 нче номерлы маддә буенча ("контрреволюцион агитация һәм пропаганда өчен") А.Гыйләҗев кулга алына. Җизказган, Киңгир, Балхаш, Актас, Волынка – лагерьлар, бакыр рудниклары, шахталар. ... Соңрак, хаклыкны язу мөмкинлеге тугач, А.Гыйләҗев "Йәгез, бер дога!" романында "шөкер кылачак": "Черек күлдә, тимер ишекләр артында саклана торган "Тикшерү дело"сында шактый кызыклы фикерләрем, беркетмәләргә сыланган сүзләрем калган минем... Бүген йөзем ачык: кыю вә хак фикерләр әйтә алганмын ич!" Әдип татарлар гына түгел, "большевизм камаган бәхетсезләр" – "урыслар, яһүдләр, японнар, немецлар, балкарлар"га дога кылачак: "Мин сезгә, һәрбарчагызга искиткеч рәхмәтлемен: минем рухым ботенлеген сез саклап калдыгыз, җанымның Аллаһы Тәгалә биргән бөтенлеген ваттырмадыгыз".

Әйе, Россия тарихында «кара таплар» җитәрлек. Ә менә Сталин хакимияте тудырган золым, халыклар төрмәсе иң хурлыклысыдыр, мөгаен. Мондый таплар Аяз Гыйләҗевнең генә түгел, ә тулаем алганда, милләтемнең нинди авыр язмыш сынаулары аша үтүен күрсәтә. Зур корбаннар бәрабәренә килгән шатлыклы да, кайтарып ала алмаслык югалтуларның ачы үкенечен дә аңларга ярдәм итә.

Шафигуллина Алия Фәрид кызы,
гомуми үсеш төрендәге 4 нче "Сандугач" балалар бакчасы, Сарман районы

**Аяз Гыйләҗевнең "Суык" хикәясе өстендә эш**
**Мәктәпкә әзерлек төркеме өчен шөгыль конспекты:**

Максат. Балаларны матур әдәбият әсәрләре белән кызыксындыру, әсәрнең эчтәлегенә карата тәрбияче биргән сорауларга төгәл җавап кайтарырга өйрәтү, үзлектән фикерләү сәләтен үстерү.

**Әзерлек эшләре:** авазлар өстендә эш, дидактик уеннар уйнау.

**Методик алымнар:** хикәяне уку, әңгәмә уздыру.

**Җиһазлау:** хикәягә иллюстрацияләр, хәрефләр.

**Кулланма әдәбият:** Аяз Гыйләҗевнең “ Суык” хикәясе (“Алсу, Илдус һәм сандугач” китабы)

**Эшчәнлек барышы:**

Кыш турында Г.Тукайның табышмак –шигыре “Бу кайчак була?”

Һәр җир карланган,
Сулар бозланган;
Уйный җил-буран,—
Бу кайчак, туган? *(Кыш көне)*

Кыш турында кем тизрәк сүз әйтә?

А) Сүздә “а” авазы ишетелсен,

Б) Сүздә “к” авазы булсын.

*Хикәянең беренче өлешен уку.*

Сорауларга җавап бирү:

Хикәя кем турында?

Малайның этисе нәрсә алып кайткан?

Нәрсә ул термометр?

Әбисе термометрны нәрсә өчен кирәк дип аңлаткан Искәндәргә?

*Физминутка.*

*Икенче өлешне уку.*

Искәндәр әбисенә ничек булыша?

Искәндәр нинди төш күрә?

Балаларга хикәяне дәвам итәргә тәкъдим итү. “Ничек уйлыйсыз, әбисе күмәч кибетенә киткәч, Искәндәр нишләде икән?”

Суыкны тотып буламы?

Искәндәр ни өчен авырган?

Кыш көне авырмас өчен нишләргә кирәк?

*Термометр , аның төзелеше белән таныштыру (слайдлар ярдәмендә)*

*Йомгаклау.*

Без бүген нинди әсәр укыдык?

Сезгә “Суык” хикәясе ошадымы?

Гарифуллина Альфинур Флеровна, Садыкова Ильмира Зуфаровна,
«Джалильская СОШ№2», Сармановский район

## Литературный сценарий «Давайте помолимся!»
## Карлаганская страница Аяза Гилязова

**Цель:** Познакомить детей с романом-воспоминанием «Давайте помолимся!», изданным на татарском языке в 1997 году, ставшем своего рода исповедью – завершающим произведением писателя Аяза Гилязова.

**Задачи:**

1. Сформировать представление о советском периоде через произведения А.Гилязова.
2. Помочь найти пути сохранения человеческого достоинства в кризисных жизненных ситуациях по произведениям писателя.

3. Доказать что автору удалось сохранить свою живую душу, не осквернить ее подлостью, ложью, доносительством и прочими «свинцовыми мерзостями» лагерного бытия.

**Оборудование:** выставка, посвященная теме ГУЛАГа; презентация, фото материалы.

**Выходят два чтеца.**

**1 чтец**: Они мирно жили и честно трудились,
Но в одночасье все изменилось.
Сломаны судьбы, надломлены души,
Стенанья родных. Как можно их слушать?

**2 чтец**: Сегодня, в день памяти этих несчастных
Мы вспомним, как все это было ужасно.
Стыдливо потупив глаза от родных,
Мы тихо попросим: «Простите за них!»

**1 чтец**: XX век. Жестокий, сильный, кровавый. По-своему, век людей исполинов. И не мудрено, ведь только такие смогли в нем жить и выжить.

**2 чтец:** Страшные тайны и разоблачения, чудовищные ошибки и искупления, люди-монстры и люди, избранные спасти планету от скверны, – вот его печать. Наверное, потому поиск смысла жизни и своего предназначения, выбор единственно верного пути стали мерилом столетия.

**1 чтец:** Идти вперёд - и не сбиться с курса, упасть - и подняться, продолжать путь - и не Идти вперёд - и не сбиться с курса, упасть - и подняться, продолжать путь - и не наследить, пройти ад - но остаться человеком.

**2 чтец:** Эту дорогу “осилили” не все “идущие” по ней. Не согнуться под напором бурь и ураганов - удел особой личности, избранной на страдания и подвиги, гонения и признания.

**1 чтец:** Один из таких людей стал знаком эпохи. Его имя – Аяз Гилязев, полновесное, звучное, прочное, словно одетое в гранит. (Слайд 1)

**2 чтец:** Подстать имени и его носитель, мудрый, прошедший испытание временем и славой, - писатель с большой буквы, человек, которого ненавидели так же сильно, как и любили.

**Выходят ведущие**.

**1ведущий:** 17 января 2018 г. А.М. Гилязову (1928-2002) исполнилось бы 90 лет. Это один из тех татарских писателей, чье творчество ознаменовало собой целый этап в истории татарской литературы. Народный писатель Татарстана, лауреат Государственной премии ТАССР им. Г. Тукая и Государственной премии РСФСР им. М. Горького, литературных премий Союза писателей Татарстана им. Г. Исхаки и С. Рафикова, Заслуженный деятель искусств ТАССР и РСФСР А. Гилязов по праву может считаться одним из самых талантливых и самобытных представителей татарской культуры XX-XXI веков.

**2 ведущий:** Он вошел в литературу сложившейся личностью, человеком со своей выстраданной общественной позицией, со своими выношенными творческими принципами. За плечами у него, кроме филологического факультета Казанского университета, учебы на Высших литературных курсах в Москве, еще университеты коллективизации, когда в стране ломался вековой крестьянский уклад; Отечественной войны, в горниле которой погибли отцы и старшие братья многих его ровесников; шесть

лет тюрем и лагерей, сделавших, по его собственному признанию, из него писателя. Это во многом определило специфику творчества А. Гилязова. Судьба писателя могла бы стать учебным пособием по истории татарского

**1 ведущий:** Писателя Аяза Гилязова называют татарским Солженицыным. Школой жизни для него стали сталинские лагеря. Годам, проведенным в ГУЛАГе, он посвятил свой роман «Давайте помолимся!». По замыслу автора, это повествование, ориентированное на текст Корана, должно вылиться в текст-молитву. (Слайд 2)

**2 ведущий:** В 1990-х, прежде чем начать роман «Давайте помолимся!», Аяз Гилязов побывал на месте Карлага в Казахстане, по местам своего заключения и был шокирован увиденным. Лагерь будто стёрли не только с лица земли, но и из памяти местных жителей. А ведь в 1940-х он занимал около 1,8 млн гектаров. На месте «вчерашних» лагерей были построены рабочие поселки, и жители этих поселков знать не знали о том, какая страшная жизнь и земля под их домами и огородами. Это поразило писателя. Так родилась главная мысль его романа: люди должны сохранить память-молитву, даже если стёрта вещественная память. (Слайд 3)

**1 ведущий:** Когда он добрался до карьера, а добирался он мучительно, потому что ни один водитель автобуса, ни один водитель такси не мог вспомнить о существовании этого карьера (государство старательно подчистило память об этих лагерях). И когда Гилязов нашел этот карьер, он был потрясен увиденным. На месте карьера ныне находилось озеро... озеро, на котором люди просто отдыхают... смеются на месте, где похоронены сотни заключенных... Их лишили даже могилы... И тогда он обратился с этой могилы и дал себе слово, что люди, которые канули в вечность «под номерами» в его книги обретут лица и имена...

**3 чтец:**

Всё, что видел и пережил, вошло в эту книгу.

Первый год я писал её чернилами - но чернила закончились.

Второй год - слезами, но и слёзы высохли.

Третий год - кровью, но и её не хватило

**2 ведущий:** На русский язык эту книгу о судьбах заключённых ГУЛАГа, среди которых было много иностранцев, перевели лишь спустя 20 лет после выхода в свет - в конце прошлого года. (Слайд 4)

**1 ведущий:** Зато перевод на венгерский только в прошлом году выдержал три (!) переиздания. Ведь среди героев романа – друг писателя по лагерному бараку, а ныне известный в Венгрии **переводчик Арпад Галгоци**. (Слайд 5)

**1 ведущий:** Историю своей жизни Аяз Гилязов долго не рассказывал даже семье. Только в 1990-х сыновья узнали детали, из которых, как пазл, начала складываться картина его судьбы.

**2 ведущий:** Его роман-воспоминание «Давайте помолимся!», изданный на татарском языке в 1997 году, стал своего рода исповедью – завершающим произведением писателя. По форме книга напоминает «Один день Ивана Денисовича» Александра Солженицына. В ней отразился весь лагерный маршрут писателя, а также истории и мысли людей, которые встречались на его пути, - сокамерников, товарищей по бараку. (Слайд 6)

**3 чтец:** До 30 лет я не знал, за что отец попал в лагерь. Не подозревал, что отец и дед моей матери погибли не на фронте, а в сталинских тюрьмах. Эта тема была в нашей семье секретной. Мама боялась вольнодумства так, что за неправильные фразы могла и по

губам нам шлёпнуть. Оказалось, что за подобные суждения в своё время и пострадал наш отец.

**3 ведущий:** Так воспоминает сын писателя, сценарист Мансур Гилязов. (Слайд 7)

**4 ведущий:** В архивах КГБ хранится тетрадь, исписанная женским почерком, - донос на 22-летнего Аяза. Его арестовали в 1950 году по 58-й статье и сослали в карагандинский лагерь – один из крупнейших исправительно-трудовых лагерей ГУЛАГа. Вчерашний студент попал на каменоломню. В бараках было по 30 человек. Сидели без разбору: пленные со всего мира, убийцы, экономические и политические преступники. (Слайд 8)

**3 чтец:** Отец с интересом наблюдал за заключёнными разных национальностей. Видел, как тяжело переносили голод немцы и китайцы. Только они съедали даже рыбные кости, тогда как остальные их выбрасывали. Китайцы ели кости сразу, а немцы сушили их, перемалывали между камнями и этой мукой посыпали хлеб. Даже в таких деталях проявлялся характер нации.

**3 ведущий:** Аяз Гилязов часто говорил: «Если бы Муса Джалиль сидел в Карлаге, он бы не сохранил «Моабитскую тетрадь». Всё время обыски, проверки. Нелегко было и интеллигентам, попавшим в бараки с уголовниками. Приходилось выкручиваться. Одну из таких историй Аяз Гилязов позже привёл в своей книге «Давайте помолимся!»

**4 чтец:** «Когда я спросил: «Какой способ вы нашли, чтобы выжить?» - Кулешов рассмеялся. «Гюго с Бальзаком спасли меня, - ответил он. - Я смолоду занимался в самодеятельном театре. Сначала работал суфлёром. Сорок три пьесы наизусть знаю! У воров есть странная особенность, они любят, когда им книги вслух читают или пересказывают по памяти. Вот я и взялся им каждый вечер романы «читать»! На самом интересном месте останавливаюсь, как Шахерезада, на следующий вечер опять продолжаю… Если истории кончаются, свои придумываю!»

**3 чтец:** В лагере были свои высшие и низшие сословия - «шестёрки», «паханы». «Отец рассказывал, что после смерти Сталина эта иерархия начала меняться. Когда жёнам заключённых разрешили приезжать в Карлаг, соседи по баракам увидели их и вдруг переоценили, кто чего стоит. То есть даже в лагере авторитет мужчины во многом зависел от красоты его жены. Одни женщины смогли возвеличить своих мужчин, другие, наоборот, принизить. (Слайд 9)

**1 ведущий:** За пять лет Карлаг расширил кругозор деревенского парня, научил его мыслить масштабно. По ночам в бараке вели интересные беседы. Разговоры по душам быстро сближали товарищей по несчастью. Гилязов сдружился с венгром Арпадом Галгоци.

**2 ведущий:** Этот юноша рассказал, как советские солдаты при нём изнасиловали его мать, и та покончила с собой, не выдержав позора. Гимназистом Арпад вступил в антисоветскую подпольную организацию молодёжи, которая существовала в 1948-1952 годах. Вскоре его поймали, осудили по политической статье и отправили в Карлаг.

**1 ведущий:** На память от Арпада Аязу остались два чудом сохранившихся портрета. На одном был реальный Аяз - заключённый в ушанке и телогрейке, а на втором он в костюме, с хорошей причёской. Смысл данной композиции был в том, чтобы сказать: вот, Аяз, твое настоящее, а вот, Аяз, твое будущее. Сейчас ты должен был бы быть в этом костюме и учиться, а не работать в лагере. Разве друзья могли знать, что их судьбы ещё пересекутся?

**2 ведущий:** Вскоре после освобождения из лагеря Аяз Гилязов стал известным писателем. Он всю жизнь помнил о своём друге, но считал его погибшим. Ведь он был уверен, что Арпад с его характером участвовал в Венгерской революции 1956 года и не мог остаться в живых. Пытался искать, но неправильно запомнил фамилию - по фамилии Голгоци никого не нашлось. Память о друге Гилязов решил увековечить в своём романе-воспоминании. Причём Арпад стал прототипом сразу двух героев - бывшего белогвардейца Мерзлякова и художника Голгоци.

**1 ведущий:** Судьбы товарищей по бараку снова сплелись, когда в 2015 году Арпада Галгоци разыскала литературовед Милеуша Хабутдинова, изучающая творчество Аяза Гилязова. От неё Арпад узнал, что друг посвятил ему часть своего романа. С тех пор переводчик уже трижды был в Казани. Жаль, что встретиться с товарищем он уже не смог, Аяз Мирсаидович скончался в 2002 году. Но зато Арпад познакомился с его большой семьёй - вдовой, тремя сыновьями, внуками. (Слайд 10)

**1 ведущий:** Во время своих визитов в Казань по приглашению Казанского федерального университета Арпад Галгоци рассказал о дружбе с татарским писателем, которого в лагере величали все Алексеем, Арпад – ханом Батыем. Многое их объединяло. Они были ровесниками. Арестовали их в стенах учебных заведений. Арпад Галгоци сдавал экзамен за курс гимназии, а Аяз Гилязов учился в университете.

**2 ведущий:** Во время ночных разговоров они говорили о тоталитарном режиме, литературе, истории. Хотя А.Гилязов был бригадиром, но ему разрешалось брать из библиотеки лишь одну книгу в месяц. Арпад Галгоци был художником, поэтому всегда имел доступ в библиотеку. Он приносил другу книги каждый день.

**1 ведущий:** Рисунки Арпада помогали бригаде сделать жизнь более сносной. Они приносили «живые деньги», давая возможность отовариваться в лагерном ларьке. Арпад и Аяз абый встретились в период, когда сталинские лагеря себя изжили экономически: заключенные получили послабления в режиме. Как признается Арпад, жизнь стала более-менее сносной, если ее сравнивать с первыми годами заключения. По приговору оба писателя должны были провести в лагерях по 25 лет.

**2 ведущий:** Стараниями Галгоци на венгерский язык роман «Давайте помолимся!» перевели даже раньше, чем на русский. В предисловии к русскому переводу, который издали прошлой осенью, Арпад Галгоци пишет автору и другу: «Ты оставил этот мир, но перехитрил судьбу и через 65 лет обращаешься ко мне, и сейчас я пишу предисловие к новому изданию Твоих произведений… А какие вечные разговоры предстоит нам с Тобой вести! …жди меня, и я обещаю, что непременно найду Тебя».

**1 ведущий:** В лагере важно выжить «любой ценой», но, все же, не ценой утраты души, или духовного омертвления. Поэтому многим осужденным и прежде всего самому автору удалось сохранить свою живую душу, не осквернить ее подлостью, ложью, доносительством и прочими «свинцовыми мерзостями» лагерного бытия. «Душа и колючая проволока». И в этом величие души человека за колючей проволокой! В этом моральная победа зека-одиночки над всесильным тоталитарным режимом

**2 ведущий:** Аяз Гилязов зашагал по миру, завоевывая сердца все новых и новых читателей! Его книги формируют представление не только о советской эпохе, в них воссоздан портрет татарского народа, указаны пути сохранения человеческого достоинства в кризисных жизненных ситуациях. (Слайд 11)

Тазирова Валентина Валериан кызы,
Сарсаз-Баграж гомуми төп белем бирү мәктәбе, Зәй районы

**Аяз Гыйләҗев биографиясендә Баграж ягы**

Туган җир! Туган төбәк! Туган табигать! Һәр кеше өчен нинди газиз, тирән мәгънәле сүзләр!

Туган якның бай тарихы һәм мәдәнияте, табигате һәм көнкүреше – болар барысы да кече яшьтән үк балалар тормышының бер кисәгенә әверелә.

Әдәби туган якны өйрәнү әдәбиятны тирәнрәк аңларга, аның тормыш белән бәйләнешен төшенергә булыша, туган төбәкне танып белергә, патриотик, әхлакый, эстетик тәрбия бирергә ярдәм итә.

Мәктәптә әдәби туган якны өйрәнүнең максат- бурычлары, формалары, ысуллары күптөрле: якташ әдипләрнең тормыш һәм иҗатларын тикшерү, музейлар. әдәби почмаклар ачу, стендлар, альбомнар төзү, фольклор материалларын туплау һәм өйрәнү, истәлекле әйберләр, экспонатлар җыйнау, әдәби кичәләр, очрашулар үткәрү һ.б. Бу зур эштә аларга әдәби, тарихи чыганаклар, җирле һәм гомумән вакытлы матбугат, архив, музей материаллары, мемуар әдәбият, төрле хатлар, кулъязмалар, өйрәнелә торган әдипләрне якыннан белгән кешеләр дә һәм үзләре әдипләр дә ярдәмгә килә.

Зәйлеләр төбәктә туып үскән күренкле җәмәгать эшлеклеләре, әдәбият, сәнгать әһелләре белән хаклы рәвештә горурланалар. Кемнәр белән горурланабыз, матур мәгънәсендә кемнәр белән мактана алабыз соң без – Зәй кешеләре?

Әйе, Зәй төбәгендә туфрак бик тә уңдырышлы; анда шагыйрь дә, язучы да, галим - академиклар да, атаклы көрәшчеләр, спортчылар да үсә тора. Якташыбыз шагыйрь Мөдәррис Әгъләм язганча: "Орлыгы да, аңа киткәч, түгел аның Бохарада!"

Әмма Зәйнең ике тугае бар - Зичә һәм Ирнә буе. Шул тугайлардан Зәй төбәгенең күп кенә күренекле шәхесләре дә чыккан. Алар арасында Бигеш авылында туып үскән, Татарстан Фәннәр Акдемиясе Президенты, филология фәннәре докторы, профессор Мансур Хәсәнов; Поручиково авылыннан техник фәннәр докторы, профессор Юрий Гортышев; Бигеш авылыннан Казан медицина академиясе ректоры, академик Марс Михайлов һ.б. бар.

Әдәбият галиме, педагог, филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры ,Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе", "Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт бүләге лауреаты", "Халыкара ел кешесе" һ. б. - бу дәрәҗәләрнең һәм исемнәрнең барысы да бер үк затка - Хатыйп Миңнегуловка карый. Ул да Зәй төбәгенең Апач авылында туып үскән. Х.Миңнегуловның татар әдәбияты тарихы буенча язылган һәм бәһаләп бетергесез хезмәтләре бар. Тарих төпкелләренә төшәр өчен без якташыбыз, 1838 елда вафат булып, Зәй төбәгенең Имәнлебаш авылында җирләнгән Таҗетдин Ялчыгол исемле бөек галим калдырган тарихи китапларга тотынырга тиеш булачакбыз. Ул калдырган бихисап фәнни әсәрләр арасында исемнәре иң алда йөри торган "Рисаләи Газизә" белән "Тәварихы Болгария" исемле китаплар бәһаләп бетергесез кыйммәтле әсәрләрдән санала.

Зәйдән башка бер генә язучы чыкмаган булса да, бушлыкны шагыйрь Мөдәррис Әгъләм тутыра алган булыр иде. Ул Биш Субашы авылыннан. Мәктәптә укыган чакта ук аның шигырьләре зур матбугат битләрендә еш басылып торган. Беренче шигырьләреннән үк аны Хәсән Туфан белән Сибгат Хәкимнәр, шагыйрь буларак үз араларына кабул иттеләр, якладылар, күтәрделәр.

Сөббух Рафиков та, Аяз Гыйләҗев кебек үк нахакка гаепләнеп, ватаныннан аерылып 20 ел кырыс котыпта яшәргә мәҗбүр ителгән шәхес иде. Ул туган якларына кайткач, Зәй шәһәрендә яши.

Гурий Тавлин. Баграҗ авылыннан чыккан бу кеше сугышын да, төрмәсен дә күрде, сатлыкларны да күрде. Ләкин һаман сабыр булды. Исемнәр сорамады, ярдәм сорап түрәләр янында бөтерелмәде, юкса бит ул – бөтен татар милләтенең олы язучысы. Аның репрессия заманы энциклопедиясенә торырлык соңгы "Афәт" романы гына да ни тора! Гурий Тавлинның архивында әле басылмаган биш романы калган. Керәшеннәр турында яза башлаган әсәре дә тәмамланмаган. Хакимият башлыгы карары белән Зәй шәһәренең бер урамы һәм бер мәктәбе аның исемен йөртә. Кеше китте, эзе калды, күңелләрдә якты образы, моңы калды. Татар әдәбиятына Гурий Тавлин дигән моңсу бер сәхифә язылды.

Өлгер, җитез, тырыш, һәр эшкә һәвәс кеше хакында, гадәттә, "И - и - и, аның җитешмәгән җире юк!" диләр. Бу сүзләрне һичбер икеләнүсез, Түбән Олыҗы авылында туган Рабит Батуллага да әйтеп булыр иде. Ул язучы, драматург, әкиятче, режиссер, артист, театр училищесында - укытучы, пародист, мәзәкче һ. б. Болар – аның һөнәр-шөгыльләре.

Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисты Наил Дунаев – безнең төбәктән. Ул Әхмәт авылында дөньяга килгән. Ул атасы кебек умартачы булып та киткән булыр иде, ләкин аны театр сәхнәсе бөтереп үзенә алды. Хәзер инде ул – татарның яраткан актеры Наил Дунаев.

Дөньякүләм танылган якташыбыз, атаклы чаңгычы, дөнья чемпионы, Баграждан чыккан керәшен егете Федор Симашевны без аеруча искә алып узарга тиешбез. Ул зәйлеләрнең генә горурлыгы түгел, бөтен татар халкының милли горурлыгы.

Сарман төбәгендә туса да, без Аяз Гыйләҗев белән дә горурланабыз. Якташыбызның мактаулы исемнәрен, алган бүләкләрен язсаң, язып, санасаң – санап бетереп булмас: Габдулла Тукай исемендәг Дәүләт бүләге, Татарстанның һәм Русиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Горький исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык язучысы һәм башкалар.

Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районындагы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. “Тәңремә рәхмәтлемен: ул мине туганда ук шигъри күңелле иткән”, - дип яза әдип “Үзем турында үзем” истәлекләренең “Балачак сукмаклары” исемле бүлегендә. “Минем әтием тумышы белән Сарман кешесе, әнием Мөгаттәрә дә шул төбәк кызы, Сарманга терәлеп үк торган Югары Әхмәт авылында туып үскән. Әтине эшкә Чукмарлы авылына җибәрәләр, әни бер-бер артлы өч малай табып өйдә утыра. Яшь мөгаллим дип, әтине район читендәге Югары Баграж авылына җибәргәннән соң, безнең гаилә Багражда калган. Әти урта мәктәптә химия-биология укыта, иртә-кич бакчада казынырга бик ярата иде. Метри елгасы ярында яшелчә бакчасы ясады. Яфракларыннан татлы ис таратып утыручы юаш карлыган куаклары шунда тезелде. Кыяр, кишер, чөгендер, помидор янәшәсендә кавын-карбызлар тәгәрәп үсте. Әнием оста “җөйче” иде. Безнең авылда балалар бакчасы ачкач, әнине тәрбияче иттеләр

Минем балачагым, яшьлегем әнә шул авылда – юмарт күңелле, кунакчыл, гади, үтә кешелекле, риясыз-хәйләсез керәшеннәр арасында үтте. Олысы-кечесе безне хөрмәт итә иде”.

“Халык язмышын бербөтен итеп күрә алу сәләте – табигать тарафыннан бик сирәк

кешеләргә эләккән бүләк”, - дип яза әдип. Аяз Гыйләҗев тормышы – XX гасырда яшәгән татар язмышы хроникасы ул. “Йәгез, бер дога” исемле роман-хатирәсенә күз салыйк: “Әтием – Сарман тумасы, иң фәкыйрь “Ак ыштаннар мәхәлләсенең” имамы, 30 нчы еллар башында Алабуга төрмәсендә үтерелгән Сәхәбетдин хәзрәт улы Мирсәет – Югары Баграж дигән авылга бара да төпләнеп кала. Нигә туган төбәгеннән ерак-тарак, чит-ят керәшеннәр арасында калырга булганын мин соңгы елларда гына аңладым. Мулла малае булуыннан курыккандыр, ахрысы! Намуслы, эчкерсез, сабыйлык матурлыгы бер чакта да уңып бетми торган керәшеннәр яшь укытучыны зурлап каршылаганнар. Күрә әти: монда гадел, тырыш халык яши. Кулакларны куганда да Югары авыллар үз араларыннан таза тормышлы крестьяннарны читкә сөрергә ирек бирмәгәннәр. Иң эшлекле, таза тормышлы кешеләрнең йорт-җирләрен алып мәктәп салганнар, авыл советы, колхоз идарәсе төзегәннәр... Кулак хуҗаларны үз ихаталарында калдырганнар, я таш амбарга, я мунчага күчергәннәр. Югары Баграж тирә-якта атаклы, төзек һәм нык авыл булган. 30 нчы елларда ШКМ (Яшь коммунистлар мәктәбе) ачканнар, аннары урта мәктәп. ... Баграж – сугыш алды елларының бер мәдәни үзәге иде. Мәктәптәге әдәбият түгәрәгенә генә 30-40 кеше даими йөри, күпләр шигырь яза... Кыскасы, Югары авыл үзе бер дәүләт булып яши иде”.

Өченче класста кечкенә Аяз беренче шигырен яза: “Чыгарган беренче такмагым – шигъри юлларым хәтердә калмаган, соңгы юлы гына исемдә...” Дүртенче класстан шигырь-поэмалар яза башлап, бишенчедә “Ул үскәндә” повестен “әмәлләргә тотына”, күп санлы нәни пьесалар яза. ...Соңрак бөек татар язучысы, драматург Аяз Гыйләҗев язганнарын пөхтәләп, кадерләп аерым киштәләрдә саклаячак, мирас итеп сөекле тормыш иптәше мөгаллимә Нәкыя ханыма, уллары – татарның тарихчы галиме, академик Искәндәр Гыйләҗевкә, татарны дөньякүләм таныту буенча күп гамәлләр кылучы драматург Мансур Гыйләҗевкә, табиб, эшмәкәр Рәшат Гыйләҗевкә калдырачак.

Аяз Гыйләҗевнең бала чагы һәм мәктәп еллары күршедәге Зәй районының Югары Баграҗ исемле керәшен татарлары авылында уза. Шул авыл мәктәбенең тугыз сыйныфын һәм Сарман урта мәктәбендә унынчыны тәмамлаганнан соң (1945), берникадәр вакыт колхозда эшли, аннары ике елга якын комсомолның Зәй район комитетында бүлек мөдире хезмәтендә була. 1948 елда Казанга килеп, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә

Университетны тәмамлагач, А.Гыйләҗев берничә ел (1957-1961) көндәлек матбугат редакцияләрендә эшли, аннары, Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы икееллык Югары әдәби курсларда укып кайтканнан соң, 1963 елдан башлап бөтенләе белән профессионал-язучылык хезмәтенә күчә.Ул үзен бигрәк тә озын хикәя-повесть остасы итеп таныта. «Дүртәү», «Өч аршын җир», «Зәй энҗеләре», «Берәү» (язылуы 1960 еллар башы, басылуы 1966), «Урталыкта», «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Мең чакрым юл», «Җомга көн, кич белән…», «Әтәч менгән читәнгә», үзгәртеп кору елларында язылган «Балта кем кулында?», «Яра» повестьлары – шуның матур мисаллары. Тематик яктан әдипнең күпчелек повестьлары авыл тормышына багышланган. Аларда сугыш чоры һәм сугыштан соңгы еллардагы татар авылы, аның гади, эшчән, әмма авыр сынауларга дучар ителгән кешеләре сурәтләнә, әхлак, тәрбия мәсьәләләре, мәхәббәт, гаилә, намус-вөҗдан каршында җаваплылык, яшәү максаты, яхшы белән яманның, изгелек белән явызлыкның кеше күңелендә һәм чынбарлыкта барган мәңгелек көрәше, гыйбрәтле язмышлар, тирән конфликтлы, драматик агышлы вакыйгалар аша сәнгатьчә яктыртыла. Автор гади кешенең шәхес буларак рухи бөеклегенә дан җырлый, повестьларында торгынлык чорында киң таралыш алган эгоизм, кешелексезлек,

бюрократлык, ваемсызлык, карьеризм кебек яман сыйфатларны сарказмлы, усал көлү белән фаш итә. «Җомга көн, кич белән…» һәм «Әтәч менгән читәнгә» повестьлары өчен А.Гыйләҗев 1983 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә, ә 1987 елда русча тәрҗемәдә Казанда басылган «При свете зарниц» исемле китабы өчен РСФСРның М.Горький исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. А.Гыйләҗевнең иҗат эшчәнлегендә драматургия жанры да зур урын били. Аның каләме белән кырыктан артык исемдә күп актлы комедия, трагедия һәм драмалар языла. Аларның күпчелеге Казанның Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры сәхнәләрендә, Татарстанның Әлмәт, Минзәлә, Чаллы шәһәрләрендәге театрларда куела, кайберләре, башка телләргә тәрҗемә ителеп, үз вакытында башкорт, авар, чуаш милли театрлары, рус театры сәхнәләрендә дә уңыш белән бара. А.Гыйләҗевнең киң колачлы әдәби эшчәнлеге күп гасырлык татар мәдәнияте хәзинәсен яңа кыйммәтләр белән баетты. Шуларны күздә тотып, аңа 1993 елда Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев Указы нигезендә «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән шәрәфле исем бирелә. Ул шулай ук Татарстанның (1978) һәм Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе (1985) дигән мактаулы исемнәр йөртә. Аяз Гыйләҗев 2002 елның 13 мартында Казанда вафат була һәм шәһәрнең Яңа бистә зиратына җирләнә.

2015 нче елның 25 августында Зәй районы Урта Баграж авылында Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевның әти-әнисе яшәгән йортка мемориаль такта кую тантанасы үтте. Аңа язучының тормыш иптәше Нәкыя ханым, уллары Искәндәр һәм Мансур Гыйләҗевлар, туганнары, оныклары, республиканың төрле шәһәр, районнарыннан татар әдәбиятын сөючеләр килгән иде. Мөхтәрәм кунакларны уртабагражлылар ипи-тоз, дәртле керәшен җырлары белән каршы алды. Мемориаль тактаны ачу хокукы Нәкыя Гыйләҗевага һәм район җитәкчесе Разиф Кәримовка тапшырылды. “Безнең төп йортыбызны саклап торучы кадерле кешеләр, дип дәшәм мин бүген барчагызга. Сагынып, ашкынып кайттык бу нигезгә. 1955 елда – Аязым төрмәдән кайтканда, әти белән әни мәктәп ихатасындагы йортта яши иде. Ул әтисе белән әнисенә үз йортларын булдырырга ярдәм итүне үзенә максат итеп куйды.1960 елда без шушы йортны тергездек. Аның өчен әти белән әнинең куануларына чик-чама булмады, моңа кадәр шәхсән үз йортлары булмаган кешеләргә (совет чорында укытучыларны бер җирдән икенче җиргә күчереп йөртәләр иде) бу төп нигез булды. Зәй төбәге, биредә яшәүче керәшен халкы безнең якын кешеләребезгә әйләнде. Аяз гел әйтә иде керәшен халкы – изге халык, алар кешелекле булулары белән аерылып тора дип. Урта Баграж авылы халкы теләге белән 1994 елда Зәйнең элекке җитәкчесе Рәшит Хәмәдиев бу йортны без – Гыйләҗевларга төзекләндереп, рәсмиләштереп бирде, шуның нәтиҗәсендә без җәйге вакытларны Аязым, балалар белән биредә үткәрә алдык. Хәзер менә яңадан Разиф Кәримов күрсәтмәсе белән йортыбыз кабат балкып тора, рәхмәт аңа бу изге эше өчен. Без моны татар язучысына хөрмәт, татар әдәбиятын зурлау буларак кабул итәбез. Кешеләрен, тарихын зурлаган төбәкнең киләчәге дә якты», - диде Нәкыя ханым. Кунаклар Аяз Гыйләҗевнең әти-әниләре истәлегенә, ташлар куелган чишмәгә төшеп, шифалы судан да авыз итте. Соңыннан авыл мәдәният йортында язучының иҗатына багышланган әдәби кичә үтте.

“Мин үзем күргән, тормышлары, яшәешләре, кылган гамәлләре белән мине баеткан бик күп кешеләр алдында зур бурычлы әле. Мин унҗиде яшемә хәтле авылда

яшәдем. Сугыш еллары һәм аннан соңгы еллар иде бу. Шул елларның истәлеге минем өчен аерата газиз һәм кадерле. «Берәү», «Дүртәү» повестьларында мин бу истәлекләрнең бер өлешен язарга тырышып та карадым. 1972 елда «Язгы кәрваннар» һәм «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» исемле кечкенәрәк күләмдә ике повесть яздым. Бу минем үземнең авылдашларыма, якты шәхесләргә, Югары Баграж кешеләренә, Зәй буйларына бурычымны кайтаруым гына. Әсәрләргә геройлар тормыштагы үз исемнәре белән кермәсәләр дә, географик һәм биографик дөреслеккә ябышып ятмасам да, бу әсәрләре минем янәшәмдә яшәгән гүзәл авылдашларым турында", - дип яза Аяз Гыйләҗев үзенең "Балачак сукмаклары" истәлекләрендә.

Укучыларыбыз Аяз Гыйләҗев әсәрләрен бик теләп өйрәнәләр, бигрәк тә үзебезгә таныш, якташ язучы булганга күрә 8 сыйныфта "Язгы кәрваннар" әсәрен үткәндә зур кызыксыну белән укыйлар,Сарсаз авылында, яки безнең авылда булган тормыш турында язылган"- дип.

Хәзерге вакытта мәктәп музеенда якташ язучыларыбызга әдәби почмак булдырылган. Анда Аяз Гыйләҗев исеме күренекле урын алган.Урта Багражда эти-әнисе яшәгән йорт бүгенге көндә дә караулы, авылга якты истәлек булып тора.

Туган төбәгебезгә булган якын хисләрне тәрбияләүдә якташ язучыларыбызның да өлеше бәяләп бетермәслек дәрәҗәдә зур. Алар матур әдәбият үрнәкләре аша туган җиребезне тагы да яратырга, аның башка төбәкләрдән аермалы булган үзенчәлекле якларын ачарга ярдәм итә. Ә шәхес булыр өчен, беренче чиратта, туып-үскән җирең турында, мәдәнияты, тарих буенча хәбәрдар булырга кирәк.

Шакирҗанова Гүзәлия Зиннур кызы, Мөхәммәдиева Дамира Заһит кызы,
Кече Урыссу төп гомуми белем бирү мәктәбе, Ютазы районы

## Аяз Гыйләҗевнең "Суык"хикәясе
## (укудан дәрес эшкәртмәсе, 3 нче сыйныф)

**Тема:** Аяз Гыйләҗев."Суык" хикәясе.

**Максат:** Аяз Гыйләҗевнең иҗаты белән таныштыру. "Суык" хикәясен укуга кызыксындыру уяту.

**Бурычлар:** Нәниләрнең хыяллары ни өчен өлкәннәрнекеннән үзгә булуының сәбәпләрен аңлату. Хикәя һәм экиятләрдә уйлап чыгарылган вакыйгаларның төрле максатларда кулланылганын ачыклый алу күнекмәсен ныгыту. Үзләреннән кечерәкләргә ярдәмчел,игътибарлы булуларына ирешү.

**Җиһазлау:** проектор, презентация, дәреслек, карандаш, күргәзмәгә куелган китаплар, термометр,

**Дәрес барышы:**

**1.Мотивлаштыру. ( 1мин)**

- Елмаеп карагыз дөньяга,
Рәхәт бит яшәве, шулаймы?!
Елмаеп яшәсәң көн саен,
Укырга, уйларга бик җайлы.

Бер-беребезгә яхшы кәеф, күңел күтәренкелеге теләп, әдәби уку дәресен башлап җибәрик.

**2. Өй эшен тикшерү. (5мин)**

“Җиләк җыйганда” исемле кечкенә хикәя язарга бирелгән иде.(Тыңлау һәм анализлау)

**3. Яңа теманы ачуга әзерлек .** (10мин)

- Дәрескә максат кую, укучыларда белем алуга омтылыш тәрбияләү

(Саннар күрсәткән хәрефләр буенча язучының исемен фамилиясен төзиләр)

| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | А | Ә | Б | В | Г | Д | Е |
| 2 | Ж | Җ | З | И | Й | К | Л |
| 3 | М | Н | Ң | О | Ө | П | Р |
| 4 | С | Т | У | Ү | Ф | Х | Һ |
| 5 | Ц | Ч | Ш | Щ | Ы | Ю | Я |

**1**.1-5 (**Г**), 5-5(**ы**), 2-5(**й**), 2-7(**л**), 1-2(**ә**), 2-2(**ж**), 1-7(**е**), 1-4 (**в**)

2. 1-1(**А**), 5-7 (**я**),2-3 (**з**)

3. 3-1 (**М**), 2-4 (**и**), 3-7 (**р**),4-1(**с**), 1-2 (**ә**), 1-7(**е**) , 4-2(**т**) 4-3 (**у**),2-7(**л**), 5-5 (**ы**)

- Ә хәзер укучылар бүгенге дәрестә өйрәнәсе язучының тормыш юлы һәм иҗаты белән танышып китәрбез. (Презентация күрсәтү)

Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 нче елның 15 гыйнварында Сарман районы Чукмарлы авылында туган. Ләкин аның балачагы Зәй районы Югары Баграж авылында уза. Әтисе Мирсәет, әнисе Мөгәттәрә укытучылар булалар. Алар өч бала тәрбияләп үстерәләр: Алмаз, Аяз һәм Азат. Аяз Гыйләҗев хатыны Нәкыя белән 3 ул тәрбияләп үстерәләр (Гаилә фотоларын күрсәтү). Искәндәр – профессор, Мансур – язучы, драматург, Рәшат – табиб, эшмәкәр.

- Аяз ага уллары белән бик горурлана. “Мин татар дөньясына өч татар үстереп бирдем. Киленнәрем дә татарлар, оныкларым да татар булыр” дип әйткән сүзләре дә бар. Язучы үзенең хезмәтләре өчен бик зур бүләкләргә лаек була.

**4.Аяз Гыйләҗевнең китаплары белән танышу. (Аяз Гыйләҗев китапларыннан күргәзмә)**

**5.Уку мәсьәләсен өлешләп чишү. (20 мин)**

-Әгәр дә табышмакның җавабын тапсагыз бүген без укаячак хикәянең исеме килеп чыгачак.

Кулсыз, күзсез, буяусыз ясый ул төрле бизәк.

Беркем аны өйрәтми, ул үзе шундый зирәк. **(Суык)**

**6.“Суык “ хикәясен чиратлап уку.**

**7. Сүзлек өстендә эш.**

Термометр сүзенә аңлатма бирү – температураны үлчи торган прибор.

Терекөмеш – гадәти шартларда сыек булган ак авыр металл.

- Термометр турында белемнәрне искә төшерү (Әйләнә-тирә дөнья дәресе белән бәйләү)

8**. Дару үләннәрен җыю кагыйдәләрен искә төшерү.**

РЕЛЛИ ТЭЙБЛ СТРУКТУРАСЫ

- Мәтрүшкә турында белгәннәрен чиратлашып бер бит кәгазьгә язалар һәм слайдтан тикшерәләр

**9. Белемнәрне беренчел ныгыту. (5мин)**

- Хикәя буенча рәсемнәр күрсәтелә һәм укучылардан кыскача фикерләр тыңлана.

- Хикәянең исеме әсәрдә нәрсә турында сүз баруын аңларга ярдәм итәме?

- Ни өчен шулай уйлыйсың?
- Хикәяне укыгач үзенә кем нинди сабак алды?

**10. Мөстәкыйль эш.**

Модель Фрейер. Кәгазьләр таратыла укучылар модельны ясыйлар. Искәндәргә характеристика бирәләр.

**11.Рефлексия.**

- Хикәядәге Искәндәр сиңа ошадымы?
- Ул суыкны ничек күз алдына китерә?
- Дәрестә биргән җавапларыңнан син канәгатьме?

**“Уңыш болыны”н чәчәкләр белән бизәү** (үз-үзеңә билге кую)

**12. Өй эше бирү.**

1) Хикәянең үзеңә ошаган бүлегенең эчтәлеген сөйләү.
2) Термометр турында белгәннәрне искә төшерү.
3) “Минем белән булган кызыклы хәл” темасына кечкенә хикәя язу.

**13. Йомгаклау**.

Антонова Гөлзада Александр кызы, Ләке төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**А. Гыйләҗев. Күктау...**

| | |
|---|---|
| Тема | **А. Гыйләҗев. Күктау...** |
| Максат | Әсәрне аңлап уку, катнашучыларны табу, аларга характеристика бирү, автор теләген таба белергә , танып-белү УУГ өйрәтү. |
| Планлаштырылган нәтиҗә | Әсәрне сәнгатьле һәм йөгерек укуга ирешү, автор әйтергә теләгән фикерне табу |
| Төп төшенчәләр | -катнашучы,-идея, -автор теләге |
| Фәнара бәйләнеш | Сынлы сәнгать, әйләнә-тирәбездәге дөнья, музыка |
| Ресурслар: төп<br>-өстәмә | Уку китабы. Ягъфәрова Р. Х., 1 кисәк, Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2013<br>Портрет, иллюстрацияләр, Аяз Гыйләҗев әсәрләреннән китаплар күргәзмәсе, презентация |
| Эшне оештыру | Фронталь, индивидуаль, парларда, төркемнәрдә эшләү |

| Дәрес этабы | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | УУГ |
|---|---|---|---|
| **I. Оештыру. Эшкә кызыксыну тудыру**<br>Максат: дәрес эшчәнлегенә керешеп китү ихтыяҗы булдыру өчен шартлар тудыру | -Хәерле көн, укучылар!<br>Шук кызлар һәм малайлар!<br>Дәресебез бик җитди,<br>Аңлар бары сабырлар.<br>- Шушы кояшлы, матур көндә сезне кабат күрүемә мин бик шатмын. Сезнең барыгызга да күңел күтәренкелеге, уңышлар, сәламәтлек телим.Дәресебезне шат күңел белән башлап җибәрик.<br>Укучылар, дәрестә | Укучыларның җаваплары.<br>Игътибар белән тыңларга,<br>бер-береңне бүлдермәскә,<br>тулы җавап бирергә,<br>үз фикереңне әйтергә. | КУУГ: классташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү<br>ШУУГ: үзмаксат кую |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | нинди булырга, нәрсәләргә игътибар итәргә кирәк. | | |
| **II. Актуальләштерү. Яңа материалны үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру**<br>Максат: элек үзләштергән белемнәрне мөстәкыйль рәвештә искә төшерү мөмкинлеге булдыру | Өй эшен тикшерү<br><br>Бүген без теманы өйрәнүне дәвам итәбез. | – Укучыларның җаваплары<br>Үткән дәрестә без Габдулла Тукайның "Туган авыл" шигырен укыдык. Шигырне яттан сөйләү | ТБУУГ: төп билгеләрне аерып күрсәтү<br>РУУГ: кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу<br>КУУГ: тыңлый белү, диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу |
| **III. Уку мәсьәләсен кую.**<br>Максат: яңа белемнәр кабул итүне оештыру һәм үзләштерүгә юнәлеш бирү; килеп туган уку мәсьәләсен анализлау; дәреснең темасын, максатын билгели белү | Балалар ,сезнең алда бүген дәрестә тикшереләчәк әсәр авторының портреты тора . Кем ул?<br>Күргәзмәгә куелган китаплар авторны белергә ярдәм итәр.<br>Аяз Гыйләҗев әсәрләреннән төзелгән китап күргәзмәсе белән танышу.<br>Нинди максат куярсыз үзегезгә ?<br>Әдәби уку дәресләренең максаты нинди?<br>Без әле бүген туган якның табигате, атамалары турында күбрәк белергә тырышырбыз | Укучыларның җаваплары<br><br>– Аяз Гыйләҗев<br>– Без бүген Аяз Гыйләҗев иҗаты белән танышабыз.<br>Туган якка багышланган әдәби әсәрләр укыйбыз<br>– Аңлап, сәнгатьле укыргаөйрәнергә, укыган буенча үз фикереңне әйтә белергә, иптәшләрнең фикерләрен тыңлый белергә, | ТБУУГ: танып белү мәсьәләсен мөстәкыйль ачыклау һәм максат кую<br>РУУГ: кагыйдә, инструкцияләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу<br>КУУГ: коллектив фикер алышуда катнашу |
| **IV.Танып-белү эшчәнлеге. Уку мәсьәләсен чишү.**<br>Максат: күзаллау булдыруда ярдәм итү;<br>мисаллар китереп раслый белү<br><br>**Ял вакыты.** | Презентация буенча Аяз Гыйләҗевның биографиясе белән танышу<br>Нәтиҗә ясау.<br>Әдәби әсәрне беренчел кабул итү.<br>Ничек уйлыйсыз ул нәрсә турында?<br>Рәсем буенча әңгәмә<br>Укытучының үрнәк укуы.<br>Өзек сездә нинди тәэсирләр калдырды? Ни өчен?<br>Әсәрдәге төп катнашучы кем?.<br>Әсәрдә аңлашылмаган | Биографиядән кирәкле мәгълүматларны дәфтәргә язалар<br><br>Дәреслекнең 5 битен ачалар.<br>Күтелгән җаваплар.<br>-Рәсемдә авыл күренеше күрәбез. Кыз белән малай чишмә буенда көймә агызып уйныйлар. Текст авыл турында дип уйлыйбыз.<br>Укучыларның җаваплары. | ТБУУГ: уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү, төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру<br>КУУГ: үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү<br>РУУГ: үз эшчәнлегеңне контрольгә алубуенча |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сүзләрне табыгыз<br>Сүзлек эше | – Уңай тәэсирләр калдырды<br>– Хөсәен туган авылын ярата<br>– Хөсәен<br>-Меридиан, экватор, котып | |
| **V. Яңа белемнәрне ныгыту, мөстәкыйль куллану**<br>Максат:<br>яңа белемнәрне дәреслек һәм өстәмә әдәбият кулланып камилләштерү; өстәмә әдәбият белән эшли белү; укучыларның хисси һәм эстетик тәҗрибәләрен практик кулланырга мөмкинлек тудыру | Сәнгатьле укуга хәзерлек<br><br>Сәнгатьле уку<br>Әсәрдән рәсемгә туры килгән юлларны табып укыгыз.<br><br>Нәрсә ул әдәби әсәрнең темасы?<br><br>Өзекнең төп мәгънәсе кайсы юлларда чагыла?<br>Соңгы юлларны укып күрсәтегез әле. Бу юллар нәрсәне аңларга ярдәм итә?<br>Нәтиҗә ясау.<br>Мәкальләрне укып анализлау<br>Туган илем – туган анаң.<br>Туган илем – туган өем.<br>Үз илем – алтын бишек.<br>Илеңдә яшисең икән – үз илеңә хезмәт ит.<br>Туган авыл темасына синквейн төзү | Укучылар пышылдап укыйлар, сәнгатьле укырга әзерләнәләр.<br>Өзекне укыйлар<br>-Чишмәсе дә – тишек улактан агып яткан гади чишмә... Кыяр тавында чәнечкеле үләннәр үсә дә зур күзле яшел чикеркәләр сикергәли...<br>– Әдәби әсәрдә нәрсә яки кем турында да булса хәбәр итү<br><br>– Соңгы строфада.<br><br>Укучыларның җаваплары<br>Төркемнәрдә мәкальләрне укып анализлыйлар.<br><br>Парларда эш. Синквейн төзиләр.<br>Көтелгән җавап.<br>Мәсәлән,<br>Туган авыл.<br>Кадерле, якын.<br>Яратам, сагынам, тартылам.<br>Хәтеремдә мәңге калыр.<br>Ватаным. | РУУГ: үзконтроль, биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү<br>ШУУГ: күршеңә ярдәм итүдә танып белү инициативасы күрсәтү<br>ТБУУГ: яңа мәгълүмат туплауда өстәмә әдәбият куллану<br>КУУГ: мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү, иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү |
| **VIII. Рефлексия.**<br>Максат: дәрестәге эшчәнлекне анализлау, белемнәрне бәяләү | Дәрес сезгә ошадымы?<br>Аеруча да нәрсә кызыклы булды?<br><br>Нинди яңалык белдегез?<br>Матур җавапларыгыз, төпле фикерләрегез өчен рәхмәт. | Укучыларның җаваплары | ШУУГ: үз уңышларың / уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү<br>РУУГ: үз эшчәнлегеңне контрольгә алу |
| **IX. Өй эше**<br>Максат: өй эшен хәбәр итү, аны башкару ысулын | Өй эше 3 вариантта бирелә<br>- Аяз Гыйләҗевның биографиясен өйрәнергә | Укучылар өй эшен сайлап алалар. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| аңлату | - Өзекнең эчтәлеген сөйләргә<br>- Авылдагы тыкрык, урам, тау, чишмә, күпер, басу исемнәрен һәм аларның ни өчен шулай аталганын өлкәннәрдән сорап килергә | | |

Садыкова Алсу Наил кызы,
Менделеевск шәһәренең 1 нче гомуми белем биру мәктәбе

**Ана хакын хакламаучыларны аклап буламы?**
**(Хөкем итү дәресе)**

Бу дөньяда һәркем үз гамәлләре өчен җаваплы. Җаваплылыкуы мин укучыларда тәрбияләнергә тиешле иң күркәм, мөһим сыйфатлар рәтендә күрәм. Җаваплы кеше эшен вакытында, сыйфатлы итеп башкара, җаваплы кеше якыннары, дусларының авыр хәлгә куймый. Җаваплы кеше табигатькә сакчыл карашлы була. Әдәбиятта җаваплылык хисен тәрбияләү еш кына "гамәл вә җәза" мотивы аша тормышка ашырыла. Әмма әлеге кагыйдәдән чыгарма булган әсәрләр дә бар. Алар күңелдә аеруча тирән эз калдыралар. Мондый әсәрләрне укыганда укучы ихтыярсыздан автор белән диалогка керә, аның белән бәхәсләшә, әсәрнең дәвамын икенче төрле итеп фаразлап карый. А.Гыйләҗевнең "Җомга көн, кич белән" әсәре – шундыйлардан. Гомерен балаларга багышлаган Бибинурның балалары тарафыннан караусыз калуы, яхшы тормыш итүче балаларның үзләрен карап үстергән Бибинурга рәхмәт йөзеннән кош теле кадәр хат та язмаулары каршылыклы хисләр уята, моның сәбәбен ачыклыйсы, балаларны табып, хаталарын аңлатасы, җаваплылыкка тартасы килә. Шуны истә тотып, 9 нчы сыйныф укучылары белән мин А.Гыйләҗевнең "Җомга көн, кич белән" повестен өйрәнү өчен каралган дәресләрнең берсен дәрес-суд формасында оештырырга тәкъдим итәм. Мондый дәреснең тәрбияви потенциалы шактый зур булган кебек, укучыларның танып белү активлыгын үстерүдә дә әһәмияте зур. Гаепләүчеләр дә, аклаучылар да әсәр геройларының язмышын, һәр гамәлен, аларның шәхес буларак формалашуына йогынты ясаган һәр фактор-шартны яхшы белергә тиешләр. Мин тәкъдим иткән эшкәртмәне укытучыар үз эшләрендә үзгәртеп куллана алалар. Бәлки Бибинурны балаларын аклаучылар табылыр, ә гаепләнүче балалар гафу үтенерләр? Мин мөмкин булган вариантларның берсен генә тәкъдим итәм. Әлбәттә, суд-дәрес алдан ныклы әзерлекне дә, соңыннан рефлексия үткәрелүне таләп итә. Мин бары суд-дәрес барышын тәкъдим итәм.

Дәреснең темасы: А.Гыйләҗевнең "Җомга көн, кич белән" повестендә Бибинурның балаларына суд – хөкем итү оештыру.

Дәрес тибы: гомуметодологик юнәлештәге дәрес

Дәрес формасы: дәрес-суд

Дәреснең максаты: А.Гыйләҗевнең "Җомга көн, кич белән" повестен өйрәнү аша укучыларда әхлакый кыйммәтләр формалаштыру

Дәреснең бурычлары: танып белү бурычы: А.Гыйләҗевнең "Җомга көн, кич белән" повестендәге геройларга бәяләмә бирергә өйрәнү; үстерешле бурыч: мәгълүматны

мөстәкыйль рәвештә табып, эшкәртеп куллана белү, монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү; тәрбияви бурыч: аналарга тирән ихтирам тәрбияләү.

Әзерлек эше: А.Гыйләҗев, Бибинур, Бибинурның балалары, Галикәй, корреспондент кыз (шаһит), судья, адвокат, прокурор рольләренә укучыларны әзерләү.Секретарь ролен укытучы башкара ала.

Җиһазлау: Бибинур өенең фотосы, тегү машинасы, самовар фотолары.

Дәрес барышы

Секретарь: Басыгыз. Суд килә.

Судья: Бүген Бибинур исемле татар карчыгының балаларына Галикәй карт гаризасы нигезендә кузгатылган эш карала. Галикәй бабай, сезгә сүз.

Галикәй: Без Бибинур белән күптәннән таныш. Аның гомере минем күз алдымда үтте. Яшьтән үк тырыш, чибәр, уңган кызның язмышын мин бөтенләй башкача күз алдыма килә иде. Яшь чакта мин аңа күз атмадым, яшьли сөйгән егете Мирзаһит бар иде, аның белән гөрләшеп туй ясарлар, бер көтү бала-чага үстереп, бәхетле гомер итәрләр, дип уйлаган идем.

Судья: Бибинур әби, сез бу сөйләгәннәр белән килешәсезме?

Бибинур: Дөрес, ләкин мин тормышым бәхетсез үтте дип санамыйм. Мирзаһитка кияүгә чыгып бәзетле гаилә корып яшәсәм дә, Габдуллаҗанның әнисез калган, берсеннән-берсе кечкенә өч сабыйның наз күрмичә, җылы аш күрмичә үсүләрен күреп әрнер идем.

Прокурор: Хөрмәтле судья. Авыл Советыннан Габдуллаҗан турында белешмә алынды. Белешмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә: Габдуллаҗан Абдуллин кулаклар куылган йортларны сүтеп, мәктәп оештыруда катнашучы иң актив кешеләрнең берсе була. Ул хатыны Гайшә Абдуллина һәм өч баласы белән авылда уртача дәрәҗәдәге тормыш алып баралар. Көзге явымлы көннәрнең берсендә Гайшә иренең ике шинелен, бүреген киеп, ишегалдына чыга. Кемнәрдер аның артына тимер кендек белән китереп суга. Гайшә егылып җан бирә. Өйдә булган Габдуллаҗан "Ул түгел, ул түгел" дип кычкырган тавышны ишетеп, балта тотып ишегалдына чыкканда үтерүчеләр киткән була, Гайшә дә инде үлгән була.

Бибинур. Әйе, нәкъ шулай булды. Авылдагы бу хәл барыбызны да тетрәтте. Икенче көнне "Плащадка"га төпчек малае Нәҗипне Габдуллаҗан абый үзе алып килә. Мин Нәҗипне күкрәгемә кочып яраттым, шунда Габдуллаҗан абый белән күзләребез очрашты. Шул кичне мин Мирзаһит янына кичке уенга чыкмадым. Таң белән Габдуллаҗан абыйларның өенә үзем киттем, Нәҗипне үзем алып бардым балалар бакчасына. Аларның хәле тагын шуның өчен дә кыенлаша иде: берничә көннән "Плащадка"ны ябырга тиешләр. Балаларга, бигрәк тә төпчек Нәҗипкә нишләргә кала?

Судья: Сүз Нәҗипкә бирелә. Бибинур әби сезнең өйгә күчкәч, тормышыгызда нинди үзгәрешләр барлыкка килде? Ул сезгә карата усал булмадымы? Үги балалар дип кыерсытмадымы?

Нәҗип: Үги булса да, мин әни турында начар сүз әйтә алмыйм. Дөрес, без аңа бик тиз ияләшә алмадык. Чит кешегә әни дип әйтү авыр икән ул. Мин, бәләкәй булсам да, аның безнең өйдәге беренче көнен хәтерлим. Ул бәрәңге пешерде. Бәрәңге артык тозлы иде. Мин аны кабып карау белән, кашыгымны атып бәрдем дә "тәмсез" дип кычкырдым. Шул вакытта әтинең гамәлләре миндә гаҗәпләнү тойгысы калдырды: ул шыр тоз булган бәрәңгене кабып карады да, тәмле, тозы гына җитми дия-дия, шуңа тагын тоз өстәп, ашый башлады. Әтидән күреп, мин дә, башкалар да бәрәңгегә үрелдек. "Әни" дип әйтергә дә әти

өйрәтте, бик озак ул сүзне әйтә алмый интектек. Тора-бара Бибинур әнине яраттык, бергә-бергә биш җанлы гаилә булып яши башладык.

Судья: Сез, Бибинур тарафыннан кадер-назда үстерелгән өч бала, хәзерге вакытта өчегез дә яхшы урында эшлисез, бай дип әйтмәсәм дә, акчагыз җитәрлек. Ни өчен үсеп таралышкач, әниегезгә карашыгыз үзгәрде, кадер-хөрмәт дигән нәрсә кая китте? Үзегезне баглап үстергән әниегезне картлык көнендә ялгызын авылның иң фәкыйрь өендә яшәтү әхлак кануннары буенча да, юридик законнар буенча да – җинаять. Җавап бирегез.

Бибинурның олы кызы: Хөрмәтле судья, тормыш безне төрле җиргә ташлады. Һәркемнең үз мәшәкате, эштән бушый алмыйбыз. Бераз буш вакыт булса, әлбәттә, әни янына кайтыр идек.

Адвокат: Хөрмәтле судья, хәзер бит заманы да шундый: балалар әниләрен, әтиләрен артык күрәләр. Бу – Бибинурлар гаиләсенә генә түгел, гомумән, бөтен ил буенча сизелә торган тенденция.

Судья: Хөрмәтле адвокат, без гомуми эшләр белән түгел, конкрет очраклар белән шөгыльләнәбез.

Адвокат: Сез Бибинурның балаларын гына гаеплисез, ә бит конкрет итеп алсак, Галикәй бабайның балаларына да гаеп тагарлык. Алар да әтиләре белән бер өйгә сыя алмыйлар. Я әтиләр артый чапылдатып ашый, я авызын зур итеп ачкан шикелле тоела.

Галикәй бабай: Адвокатка шуны әйтер идем, яшьләрнеке яшьләрчә. Аталар һәм балалар арасында конфликт булган, бар һәм булачак. Әмма алар мине өйдән кумады, минем өемдәге әйберләрне алып чыгып китмәде, минем балаларыма кагылмаска сорыйм.

Судья: Хөрмәтле адвокат, Галикәй бабайның сүзләрен истә тотуыгызны сорыйм. Әлеге вакытта аларның эше каралмый, Бибинурның балалары турында сүз бара. Сүземне шаһитләргә бирәм.

Шаһит (корреспондент кыз): Мин Бибинурның кызының сүзләрен ялган дип саныйм. Аларның кайтырга вакыты булмаса, хат язарга мөмкинлеге бар. Бибинур шуңа да бик сөенер иде. Вакыт юк дигәнне дә сылтау дип кенә саныйм. Тегү машинасын, самоварны алып китәргә кайтып җиттеләр алар, яхшы гына йорттан алмаган әйберләре калмады, нәтиҗәдә Бибинур гомеренең картлык чорын хөрмәттә, җылы, йомшак урынлы өйдә, тәмле җылы ашлар ашап уздырырр урынына авылның иң фәкыйрь йортларның берсендә яши күңеле теләп кәнфит алган очракта соңрак үзен акча әрәм итүдә гаепли.

Судья: Рәхмәт, шаһит, сүзләрегез кабул ителде. Прокурор, сезгә сүз.

Прокурор: Бибинур кечкенә өч баланы үз теләге, тырышлыгы белән аякка бастырды. Әмма хәзер дә ул аларны яклый, аклый, гәрчә алар аклауга лаек түгелләр. Мин сезгә кайчандыр яхшы гына, җитеш кенә йорттан калган сурәтне күрсәтергә телим. Өйдә элек тегү машинасы (фотоны күрсәтә), самовар (фотоны күрсәтә) бар иде. Балалар аларны да алып китә. Бибинур балаларына оят булсын дип, әлеге хәлне ишеткән корреспондентлар газетада фельетон язарга булдылар. Моны белгәч, Бибинур курыкмыйча икенче авылга юлга чыгарга җыена. Җиһангирны соңгы юлга озата барганда, ул аларның йортында үзләренеке шикелле ялтырап торган самовар күргән була. Казаннан корреспондент килгәч, шул самовар, башка чүпрәк-чапракларга күрсәтеп, “балалар ярдәмнән ташламыйлар” дип әйтергә ниятли. Әмма кичке юл фаҗига белән тәмамлана, кыргый этләр, шул исәптән, кайчандыр Бибинур өендә яшәгән, ашаган Карабай да аңа ташланалар. Бибинур, ут ягып, аларны куркытса да, күпне күргән әбинең йөрәге түзми, ул шунда мәңгелек йокыга тала. Хөрмәтле судья, мин Бибинурның шушы хәлгә җитүендә

балаларының да гаебе зур, дип уйлыйм. Аларны гаепле дип табарга, бала, кеше дип йөртергә хокуклары юк дип аталуларын сорыйм.

Судья: Минем бу хакта җәмәгатьчелек фикерен дә ишетәсем килә. Секретарь, һәркемгә карточкалар таратуыгызны үтенәм. (Укучыларга карточкалар таратыла, һәркем гаепләргә яисә акларга дигән урынга тамга сала, фикерен дәлилләрлек аргументлар китерә).

Судья: Суд фикер алышырга тиеш. 10 минутлык тәнәфес игълан итәм. (Суд әгъзалары карточкаларны өйрәнгән арада, калганнар "Бибинур" фильмыннан өзек карыйлар).

Судья: Без, карточкаларны тикшереп, шундый фикергә килдек. Унбиш укучы балаларны гаепле дип табарга тиешлекне дәлилли. Кире очракта җәмгыятьтәге башка әгъзаларга җавапсызлык, анага карата битарафлылык үрнәге булып калачак. Алты кеше акларга мөмкин дигән фикерне җиткерде. Алар уйлавынча, балалар үз ялгышларын аңлаганнар. Суд мондый фикергә килде: хөкем залында Бибинурның балалары үзләрен акларга омтылсалар да, ялгышларны тану, гафу үтенү сүзләре яңгырамады. Бибинурның балаларын битарафлылыкта, җавапсызлыкта, ана хакын хакламауда гаепле дип табарга. Аларның Кеше дигән олы исемне йөртергә хокуклары юк дип табарга. Хөкем тәмам.

Вәлиәхмәтова Гөлшат Шәмгун кызы, Яңа Кәшер санатор интернат-мәктәбе
Әлмәт районы

## Тема: Аяз Гыйләҗевның тормыш юлына һәм иҗатына багышланган "Могҗизалар кыры" интеллектуаль уены

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Метапредмет:** укучыларда эстетик, рухи-әхлакый зәвык тәрбияләү.

**Предмет:**А.Гыйләҗевның тормыш юлын һәм иҗатын барлау.

**Шәхескә кагылышлы:** балаларда татар халкының әдәбиятына, бөек шәхесләренә карата кызыксыну уяту.

**Уенга катнашучы:** 5-9 нчы сыйныфлар

**Кулланылган материал һәм җиһазлар:** сорулар, магнитофон, компьютер, экран,презентация, интрактив такта, мультимедиа проекторы

**Үткәрү шарты.**

«Уен-баланың тормышка әзерләнү күнекмәсе ул. Уеннар балага зур файда китерәләр, алар ярдәмендә ул үзенең характерына нигез ташы булып урнашып кала торган гадәтләргә, күнекмәләргә өйрәнә, моның өстенә бу уеннар балада, гадәттә, зур канәгатьләнү хисе уяталар», − дип язган профессор П.Ф.Лесгафт. Дөрестән дә, уеннар, бер яктан, физик тәрбия чарасы булса, икенчедән, күп кенә уеннар эстетик тойгылар тәрбияләүгә зур ярдәм итә. Уен вакытында туган шатлыклы кичерешләр уенны көчле тәрбия чарасына әверелдерә. Танылган шәхесләребезнең берсе – Ризаэддин Фәхреддин балаларга язган үгет-нәсыйхәтендә: «Балаларның тәрбиялесе илә тәрбиясезе уйнаган вакытларында бик ачык беленер. Аның өчен уйнаган чакларында балалар бик каты ихтыярлы булырлар, зурлардан курку кеби нәрсәләр күңелләреннән чыгып та китәр», - дигән. Чыннан да, тәрбияче өчен уен – балаларны яхшырак аңлау, аларга тагын да ныграк якынаю чарасы да. Чөнки, нәкъ менә уен вакытларында, тәрбияче һәр баланың нәрсәгә сәләтле булуын, аның оештыру мөмкинлекләрен яхшырак күрә ала, холкын, гадәтләрен күбрәк аңлый. Уен ярдәмендә оялчан, үз эченә бикләнгән балаларны да «уятырга» мөмкин. Уендагы текстка, җырга кушылып, аның кагыйдәләрен үтәп, йә булмаса, нindидер роль башкарып, бала үз көченә ышанырга, эшләгән эшенә бәя бирергә өйрәнә, анда башкаларның хәленә керә белү, ярдәмләшү, игътибарлылык кебек матур сыйфатлар тәрбияләнә. Әдәп-тәртип кагыйдәләрен үтәү гадәте дә уенда камилләшә.

Төп игътибар баланың зирәклегенә, логик фикер йөртә алуына, фараз итүенә юнәлтелә, чөнки кешенең мәгърифәтлелеге белем күләмендә генә түгел, ә аны төрле хәлләрдә куллана алу мөмкинлегендә дә чагылырга тиеш.

Уйнау шартларына, укучыларның яшенә, кызыксынуына, хәтта кәефенә карап, уен кагыйдәләре, эчтәлеге дә үзгәртелә. Уеннар балаларда игътибарлылык, үзара ярдәм итешү, коллективизм кебек уңай сыйфатлар тәрбияләргә ярдәм итә.

Әлеге «Могҗизалар кыры» интеллектуаль уены туган тел һәм әдәбияты дәресләрендә һәм сыйныфтан тыш чараларда кулланырга мөмкин.

1 нче сайлау турында теләгән бөтен укучы да катнаша ала. Алар сорауга яки табышмакларга җаваплар бирергә тиешләр. Кем беренче җавап бирә, шул укучы уенда катнашучы исемен ала.

Икенче, өченче турга сайлаганда катнашмаучы укучылар җавап бирергә тиешләр.

Уен 3 турдан, финалдан һәм суперфиналдан тора.

Һәр уенда 3әр уенчы катнаша. Уенның максаты: аерым-аерым хәрефләрне атап, бирелгән темага сүзне табу. Әгәрдә хәрефне дөрес атамасалар яки ул атаган хәреф ул сүздә булмаса, уенны икенче уенчы дәвам итә. Уенчы хәрефне дөрес атаса, ул икенче хәрефне дә әйтә ала. Уен сүзне эзләп тапканчы дәвам ителә. Һәр турның җиңүчесе финалга чыга.

Финал җиңүчесе суперфиналга чыгып, уенның төп сүзен табып, җиңүчесе була ала.

Кызыклы, күңелле, уңай кичерешләр тудыра ала торган уен.

**Уен барышы**

**Алып баручы**

Исәнмесез, саумысыз,
Һәрберегез, барчагыз,
Бездән сезгә кайнар сәлам
Кабул итеп алыгыз.

Хөрмәтле укытучылар,тәрбиячеләр һәм укучылар бүген без бу залга V – IX сыйныф укучыларының белемнәрен, зирәклеген, тапкырлыгын сынау өчен “Могъҗизалар кыры” уенына җыйналдык.

Бүгенге уеныбыз бөек язучыбыз, якташыбыз Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлына һәм иҗатына багышлана. (Биремнәр слайдларда күрсәтелеп бара)

**I турга сайлап алу өчен сораулар.**

Нинди язучыларны беләсез?

(М Җәлил, Г. Тукай, А.Гыйләҗев, Х Туфан)

**I тур биреме**

Аяз Гыйләҗевның әтисенең исеме?(Мирсәет)

Тәнәфес *(Концерт номеры)* Бу чыгышыбыз 1 нче турда уйнаучыларыбызга рәхмәтебез булсын.

**II турга сайлап алу өчен сораулар.**

1.Аяз Гыйләҗев кайда һәм кайчан елда туган?

Сарман районы,Чукмарлы авылында, 1928 нче елның 17 нче гыйнварында

2. Бу рәсем нинди әсәрдән? (Киек каз юлы).

3. “Өтәч менгән читәнгә” әсәренең төп герое нәрсә? (Өтәч)

**Алып баручы.**Уенчыларның урыннарына чыгып басуларын сорыйбыз.

Менә алар: *(2 нче турга чыгучы уенчылар белән таныштыру)*

1 нче уенчы _______________ .
2 нче уенчы _______________ .
3 нче уенчы _______________

**II тур биреме.**

Әдәплелеге**,** акчага, малга кызыкмавы, чисталыгы – пөхтәлеге, кешеләргә эшләгән яхшылыклары белән аерылып торган Хәйретдин агай кайсы әсәрдә тирән мәгънәле роль уйный. **(Өтәч менгән читәнгә).**

**Алып баручы.** 2 нче турның җиңүчесе _____________. Котлыйбыз. Музыкаль сәламебез сезгә.

**III турга сайлап алу өчен сораулар**

1. "Җомга көн, кич белән" әсәренең төп герое **(Бибинур)**

2. "Әтәч менгән читәнгә" повестен Аяз Гыйләҗев ничәнче елда язган? (**1979 – 1980)**

3.Аяз Гыйләҗев туган район. **(Сарман)**

**Алып баручы.** Уенчыларның урыннарына чыгып басуларын сорыйбыз.

*(3 нче турга чыгучы уенчылар белән таныштыру)*

1 нче уенчы _______________ .

2 нче уенчы _______________ .

3 нче уенчы _______________ .

**III тур биреме**

Әдилә, Ибраһим, Дамир яңа гына ятим балалыктан чыгып килүче, сугыш чоры авырлыкларын кичергән 50 нче ел яшьләре. Авыр тормыш,ачлык ялангач, юл сынауы. Ашлык ташу авырлыклары Аяз Гыйләҗевның кайсы повестында күрсәтелә? **(Язгы кәрваннәр)**

**Алып баручы.** Җиңүчене котлыйбыз. 3 нче тур уенчыларына музыкаль сәлам.

**Алып баручы.** Уеныбызны дәвам итәбез. 3 турда да җиңүчеләребезне чакырабыз. Рәхим итегез.

1 турдан җиңүчебез _______________ .

2 турдан җиңүчебез _______________ .

3 турдан җиңүчебез _______________ .

**Финал.**

Бу әсәрнең кайсысын Аяз Гыйләҗев язмаган?

**а)"Кәҗүл читек"**

б) "Өч аршын җир"

в) "Җомга көн кич белән"

**Алып баручы.** Бу финалда җиңүчебез булып ___________ калды. Афәрин.

**Алып баручы.** Без җиңүчебезгә супер-уен тәкъдим итәбез. Каршы килмәссез дип уйлыйбыз.

**Супер-уен биреме:**

Аяз Гыйләҗевка Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән өчен 1993 елда Татарстан Республикасының ....... язучысы дигән мактаулы исем бирелә. Нокталар урынындагы тиешле сүз: халык, атказанган, эшлекле.

**Татарстан Республикасының *халык* язучысы**

**Алып баручы.** Җиңүчебезне котлыйбыз. Безнең уенда катнашканыгыз өчен сезгә үзебезнең рәхмәтләребезне җиткерәбез.

**Алып баручы**

Кичәбез ахрына якынлашты.
Сау булыгыз, дуслар шат яшәгез
Ямьләндереп бөек Ватанны.
Зур уңышлар белән каршылагыз
Туган илдә аткан һәр таңны.

Миякссәрова Ләйлә Кәбир кызы, Шәнгәрәева Нәзифә Наил кызы,
икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

## А.Гыйләҗевнең "Матур" хикәясендә кунакта

(башлангыч сыйныф укучылары өчен әдәбият белеме бәйгенамәсе).

**Максат:** коммуникатив һәм танып – белү универсаль уку күнекмәләрен булдыру.

**Бурычлар:** А.Гыйләҗевнең "Матур" хикәясе аша балаларны иҗади сәләтле, рухи яктан бай, бүгенге заманга яраклы шәхес итеп тормышка әзерләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Метапредмет:** укыган текстны аңлап, аңа күзәтү ясый белү.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:** укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү; анализлый белү.

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:** тиешле мәгълүматны табу, билгеләү; сөйләм берәмлекләрен логик эзлеклелеккә салу; чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен формалаштыру.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:** фикерне төгәл итеп җиткерү; әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү; мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару.

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:** балаларда белемгә омтылыш тәрбияләү.

**Әзерлек эше:** А Гыйләҗевнең "Матур" хикәясен уку. Кичәдә катнашу өчен 2 төркем әзерләү.

**Бәйгенең барышы**

Сарман ягы – күренекле шәхесләре белән бөтен Татарстанга гына түгел, тирә-як өлкәләргә дә билгеле як. Туган ягыбызда яшәүче никадәр күренекле шәхесләребез бар! Алар һәр төбәкнең үзенеке генә. Сарман төбәгендә дә алар бик күп.

Сез кемнәрне әйтеп китә аласыз? (Илһам Шакиров, Нияз Акмал, Клара Булатова, Әзһәр Габиди, Дамир Гарифуллин, Рафис Гыйззәтуллин, Аяз Гыйләҗев, Гөлшат Зәйнәшева, Марсель Зарипов, Мәдинә Маликова, Сөббух Рәфыйков, Адлер Тимергалин).

- Шушы кадәр әдипләре булган төбәк турында нәрсә дип әйтергә кала соң? Афәрин! генә дия алам. Без бүген якташыбыз Аяз Гыйләҗевнең "Матур" хикәясен яратучылар, яхшы белүчеләр өчен "Матур" хикәясендә кунакта" исемле әдәбият белеме бәйгенамәсе үткәрербез.

Бүгенге бәйгедә ике төркем катнашыр.(Төркемнәр белән танышу).

Һәрбер бәйгедә, гадәттәгечә, хөкемдарлар да була. Әйдәгез әле алар белән якыннан танышып китик (Хөкемдарлар белән танышу).

**1нче бирем. "Игътибарлы укучы" (**рәсемнәр кушымтада)

Рәсемнәрне хикәянең эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз.

(Һәр төркемгә сюжетлы рәсемнәр бирелә. Аларны А-4 форматындагы кәгазьгә эчтәлек тәртибендә урнаштырырга кирәк).

**2нче бирем. "Табышмаклар аланы"**

Тартмада табышмаклар язылган карточкалар. Төркем вәкилләре берәр табышмакны алып укыйлар, җавапны әйтәләр. Җавап дөрес булмаса, икенче төркем хаталы җавапны дөресли ала. Әлбәттә, очко аларга бүләк ителәчәк.

1.Тәңкә карлар сибелгән
Җир ап-акка күмелгән.
Чыршы, каен, имән
Кардан чикмән кигән.
Бу кайчак? (Кыш)

2.Ак ашъяулык таптык,
Җир өстенә яптык. (Кар.)

3.Йомырка белән онны
Бутап камыр басканнар.
Бәрәңге, ит, тоз салып,
Почмаклар ясаганнар. (Өчпочмак)

4.Тәмле ашлар пешерә, матур гөлләр үстерә.
Өебезнең нуры ул, барыбыздан олы ул. (Әби)
5.Нинди аучы коралсыз
Җәнлек саклый төн буе,
Аннан мыегын селкетеп
Йоклап ята көн буе? (Песи)
6. Мин аны бик сагындым, күңелем әрни, уйлый әллә ни.
Кем соң аны белми? Ул бит минем (Әни).

**Җанатарлар өчен сорау.**

Табышмакларның җаваплары турында хикәядән нәрсәләр белдегез?
“Матур” хикәясенең геройлары кемнәр?

**3 нче бирем. “Бу кем?”**

Карточкаларда герой исемнәрен аларга гына хас сыйфатлар, билгеләр белән тоташтырыгыз.

| | |
|---|---|
| Бер нәрсә булды исә, ул үпкәләргә яисә сугышырга тора. | Матур |
| Ярдәмчел, юата белә, кунакчыл, тәмле ризыклар пешерә. | Разыя |
| Уйнарга чыгырга ярамый аңа. | Әби |
| Дустын күрәсе килә, өчпочмак белән сыйларга тели. | Галия |
| Аның муенына өчпочмакны бәйләп куйдылар, хәйләкәр. | Искәндәр |

Хикәядә нинди ел фасылы сурәтләнә? Нинди кыш билгеләрен беләсез? Ә сез кыш көне урамда уйнарга яратасызмы?

**4 нче бирем. “Кем күбрәк?”**

Кышкы уен төрләрен языгыз. Кем күбрәк?(Төркемнәргә 1 минут вакыт бирелә).

**5нче бирем. “Сүз эчендә сүз “уены.**

**ӨЧПОЧМАКЛАРНЫ**

(өч, почмак, алан, чолан, ана, камыр, кар, чорма, чык, колын)

**6нчы бирем. “Мәкальләр утравы”.**

Кайсы мәкаль укыган хикәянең эчтәлегенә туры килә. Җавабыгызны дәлилләгез.

1) Өйнең яме ана белән.
2) Күп укыган күп белер.
3) Балык сусыз торалмый, кеше дуссыз торалмый.
4) Иле барның теле бар.
5) Йөз сумың булганчы, йөз дустың булсын.
6) Китап — тормыш көзгесе.
7) Кош канаты белән, кеше дуслык белән көчле.

**7нче бирем. “Дустыма хат”**

Сезнең дә иң якын дустыгыз авырып китте, ди. Сезне аның янына кертмиләр. “Хат язып бирсәң, тапшырбыз”, - диләр. Сез 2 минут эчендә авыру дустыгызга хат язарга тиеш буласыз.

Уенның нәтиҗәләрен ясау. Катнашучы төркемнәрне бүләкләү.

- Укучылар, бәйгедә катнашуыгыз өчен рәхмәт! Күренекле әдип, Татарстанның халык язучысы, Тукай һәм Исхакый исемендәге дәүләт бүләкләре иясе Аяз Гыйләҗевнең иҗаты әдәбиятыбызның кыйммәтле бер өлеше. Аның бай иҗаты киләчәк буыннарга да хезмәт итәр, якты истәлеге халкыбыз күңелендә мәңге сакланыр.

Низамиева Нурфия Гарәпша кызы,
Казан шәһәре, 37нче гимназия

**А.Гыйләҗевнең 90 еллыгына багышланган кичә**

**Максат:** А.Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру. Әдип иҗатына кызыксыну уяту. Сәнгати зәвык, шәхестә милли үзаң, үз халкың белән горурлану хисе, милли әдәбиятка, мәдәниятка, телебезгә мәхәббәт тәрбияләү.

**Зал бизәлеше**: А. Гыйләҗев портреты, әдәби бюллетень, әсәрләре буенча ясалган рәсемнәр, әдипнең әсәрләреннән күргәзмә, телевизор макеты.

**Кичә барышы**

Сәхнәдә 2 алып баручы һәм укучылар.

**"Сарман буйларында.."** җыры яңгырый (1куплет)

**Алып баручы:**Кеше туа җиргә... Аваз сала
Әзер булып җирдә барына.
Утыра да тормыш арбасына,
Кереп китә гомер юлына.

**Алып баручы:** Хәерле көн, хөрмәтле телевизор караучы тамашачылар, кадерле дуслар! Эфирда "Әдәби хәзинә" тапшыруы. Бүген студиябездә кунакта – 10-11 нче сыйныф укучылары. Бүгенге тапшыруыбыз татар сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән язучы, драматург Аяз Гыйләҗевның 90 еллыгына багышлана.

**Алып баручы:** Язучы гомере үзе яшәгән еллар белән генә чикләнми. Алар һәрвакыт халык күңелендә әсәрләре белән яшиләр.

**Алып баручы:** Татарстанның халык язучысы, Татарстанның Г. Тукай һәм РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт бүләкләре иясе, Татарстанның, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Аяз Гыйләҗевнең иҗади мирасы XX-XI гасыр татар әдәбиятының иң кыйммәтле хәзинәсе булып санала.

**Алып баручы:** Кеше гомере тыгыз бер йомгак,
Барлык юллар шунда уралган.
Сүтә-сүтә генә беләсең,
Кемгә нинди язмыш юралган, -

дип язган Фәнис Яруллин. Әйдәгез, Аяз Гыйләҗевның тормыш йомгагын сүтик.

**Алып баручы:** Әдипләргә илһам бирерлек гүзәл табигате, җырларда мактап җырларлык уңган халкы, бишек җырыдай моңлы челтерәгән чишмәләре, шаулап утырган алтын башаклы басулары белән дан тоткан Сарман ягы! Ул – безгә прозаик һәм драматург Аяз Мирсәет улы Гыйләҗевны бүләк иткән төбәк. Аяз Гыйләҗев 1928 елның 17 нче гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районында уза. Авыл мәктәбенең тугызынчы сыйныфын тәмамлагач, унынчы сыйныфны Сарман урта мәктәбендә укый. Ә хәзер, әйдәгез, Аяз абыйның әти-әнисе турында сөйләвен тыңлап үтик. **(Видеоязма)**

**Алып баручы:** Аяз Гыйләҗевнең иҗаты гаҗәеп киң кырлы.

Берничә дистә еллар дәвамында тудырылган бай эчтәлекле, төрле жанрдагы әдәби иҗаты – «Өч аршын җир», «Җомга көн кич белән...», «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят»,«Урамнар артында яшел болын», «Яра», «Йәгез, бер дога!» һ. б. әсәрләре – һәрберсе милләт, ил язмышына битараф булмаган оста каләм иясе кулы белән язылган әсәрләр.

**Алып баручы:** "Ана күңеле балада, бала күңеле далада", - ди халык. "Җомга көн кич белән" әсәре безне һәрвакыт әниләребезгә карата игътибарлы, мәрхәмәтле булырга чакыра.

**1нче укучы:** (Әсәрдән өзек укый). "Берәүләр: "Их, бу дөнья миннән кала", - дип офтаналар. Бибинур киресен уйлады: "Шөкер, әле дә ярый, мин китеп барсам да, алар калачак! - дип сөенде. - Мин калып, алар югала торган булса, нинди күңелсез һәм мәгънәсез булыр иде бу дөнья! - дип юанды". Әйдәгез, әсәрдән бер өзек карап үтик.

**"Җомга көн, кич белән" әсәреннән өзек күрсәтелә. (10 нчы класс)**

**Алып баручы:** Әйе, Бибинур татар хатын- кызларына хас иң яхшы сыйфатларны үзенә җыеп алган.Ул – изге җан. Бибинур өчен бәхет ул – игелек, яхшылык кылу. Без дә кешеләргә карата яхшылыклар гына эшлик!

**2нче укучы:** "Өч аршын җир". Бу әсәрне ул 1962 нче елда яза. Әсәр Аяз Гыйләҗевны көчле язучы итеп таныта.

**Алып баручы:** Тормыш Аяз абыйны сыный. "Өч аршын җир"әсәре өчен ул кулга алына. А.Гыйләҗевнең хатыны Нәкыягә төрмәдән язган хаты белән танышыйк.

"...Изолятор, конвой, подъем, марш! Стой! Быргы тавышы йокыдан уята, аннан иртәнге аш, юл, эш...

Бу авыр еллар мине тормышны танырга, аның катлаулы сәхифәләрен укырга өйрәтте. Бу авыр еллар миннән җитди кеше ясады. Тузанлы заводларда, кысан тынчу вагоннарда, кечкенә, ярымкараңгы төрмә камераларында кемнәр белән генә бер сынык икмәкне бүлешмәдем мин! Тормыш никадәр кыен булса, аның саен яшисе килә. Язлар килеп, дала өстендә җылы җилләр уйнаганда, үзеңнең кемлегеңне онытып ерак офыкка озаклап-озаклап карап торасың... Үткән көннәр хакындагы җылы истәлекләр акрын гына уяналар да, кайтасы килә, кайтасы...

Аяз. 27 февраль, 1955 ел".

**"Кайту"** җыры яңгырый.

**Алып баручы:** Әйдәгез, "Өч аршын җир" спетакленнән өзек карап үтик.

**"Өч аршын җир" спетакленнән өзек карау.**

**Алып баручы:** Туган җир, туган нигез һәркем өчен кадерле,газиз! Туган җирдән аерылып, бәхет табып булмый.

**3нче укучы:** Фәнис Яруллин "Туган ягы кирәк кешегә".

**Алып баручы:** Әйе, туган җирнең гүзәл табигате кешегә яшәү өчен бетмәс көч, дәрт бирә.

**4 нче укучы:** «Ниһаять, әтәч тәвәккәлләде: ишегалдын иңләп канатларын җилпеде, мәгърур башын кыегайтып күккә карады һәм, мә сиңа, читән казыгына очып та кунды. Өстән караганда дөнья бик киң һәм тавыклар бик вак булып күренделәр. Югарыга карады, кояш та тары бөртегеннән әллә ни зур түгел иде...» Аяз Гыйләҗевнең "Әтәч менгән читәнгә" әсәре шулай башлана.

**5 нче укучы:** Бу повесть 1979-1980 нче елларда язылa. Әсәрнең темасы – кешеләрнең яшәеш рәвеше, кешеләрнең үзара тормышы.

**"Әтәч менгән читәнгә" әсәреннән өзек (11 нче класс)**

**Алып баручы:** Бәхетне кеше тырыш хезмәте белән эшләп табарга тиеш. Аяз Гыйләҗев "Җомга көн кич белән..."(1979) һәм "Әтәч менгән читәнгә"(1980) повестьлары өчен 1983 елда Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

**"Бәхет"** җыры яңгырый. (Алмаз Монасыйпов көе, Әнгәм Атнабаев сүзләре )

**Алып баручы:** “Йәгез,бер дога”.Бу Аяз Гыйләҗевнең сәяси тоткынлыкта үткәргән алты елга якын гомеренә багышланган автобиографик әсәре. Роман 90нчы еллар башында языла. Беренче тапкыр “Казан утлары ” журналында басылып чыга.

**6 нчы укучы:** “...Менә мин «Йәгез, бер дога!» дигән әсәремне төгәлләдем. Анда сүз кырык ел элек булган вакыйгалар турында бара. Әсәрдә телгә алынган һәр кеше – чын, һәр вакыйга үз башымнан үткән! Үткәнемә һәм тарихка хилафлык кылмыйча, үзем кабул иткән дөреслекне сурәтләргә омтылдым. Чөнки кеше зурмы-кечкенәме, аның тарихка үз мөнәсәбәте, үз аршыны бар. Миңа бу хатирәләрдән котылырга кирәк иде”, - дип яза Аяз абый.

**7 нче укучы:** Шигырь «Йәгез,бер дога.»

**8 нче укучы:** Татар әдәбияты классигы Аяз Гыйләҗев иҗаты еллар үтү белән дә татар укучысы өчен генә түгел, башка халык вәкилләренә дә кызыклы. Аның әсәрләре башка телләргә дә тәрҗемә ителеп, чит илләрдә таралыш ала, меңләгән тираж белән сатыла һәм фикерләр барлыкка килүгә этәрә, бәхәсләр уята.

**9 нчы күнегү:** Хәзерге вакытта Аяз Гыйләҗев әсәрләре төрек, рус һәм венгр телләренә тәрҗемә ителгән. Татар язучысына бу телләрдә “сөйләшә” башларга, чит илләрдә дә үз укучысын табарга ярдәм иткән, бу эшкә үз гомерләренең соңгы елларын багышлаган белгечләр - Арпад Галгоци, Фатих Котлу, Наил Ишмөхәммәтов.

**Алып баручы:** Күренекле әдип, Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай һәм М. Горький исемендәге дәүләт бүләкләре иясе Аяз Гыйләҗевнең иҗаты – әдәбиятыбызның кыйммәтле бер өлеше. Аның бай иҗаты киләчәк буыннарга да хезмәт итәр, якты истәлеге халкыбыз күңелендә мәңге сакланыр. Тапшыруыбызны җыр белән тәмамлыйбыз.

Җыр **” Шушы яктан, шушы туфрактан без...”**

Мәхмүтова Резедә Рафаэль кызы,
Казан шәһәренең 14 нче номерлы урта гомумбелем бирү рус-татар мәктәбе

## Аяз Гыйләҗев тормышы һәм иҗатына багышланган “Тамчы шоу” интеллектуаль тапшыруы (уены)

**Максатлар:** Аяз Гыйләҗев тормышы һәм иҗаты буенча алган белемнәрне ныгыту; язучының әсәрләренә кызыксыну уяту; балаларның сөйләм телен камилләштерү. Балаларның фикерләү сәләтен үстерү. Аяз Гыйләҗев әсәрләренә карата соклану хисләре тәрбияләү.

Кирәкле җиһазлар: проектор, такта, ноутбук, өстәлләр, ак битләр, каләмнәр, карандашлар, Аяз Гыйләҗев портреты, китаплары.

Алдан эшләнгән эш: А.Гыйләҗев тормышы, иҗаты һәм әсәрләре белән балаларны таныштыру.

**Уен барышы:**

Алып баручы: Хәерле көн! Исәнмесез, укытучылар һәм укучылар! Аяз Гыйләҗев – әдәбиятыбызның төрле тармакларында ут уйнаткан кеше. Ул күренекле прозаик та, үзенчәлекле драматург та, үткен каләмле публцист та, очеркист та һәм үткен каләмле тәнкыйтьче дә. Аяз Гыйләҗевка, исән булса, быел 17 нче гыйнварда 90 яшь тулган булыр иде. Шул уңайдан әдипне искә алып, без бүген Аяз Гыйләҗев иҗатына багышланган “Тамчы шоу” интеллектуаль тапшыруы үткәрергә җыелдык. Бу уенда 7 нче А сыйныф укучылары үзләренең белемнәре буенча көч сынаячаклар. Әйдәгез әле, сезнең алкышлар

белән уенчыларны бирегә чакырыйк. "Өмәт энҗеләре" һәм "Тырыш егетләр" командалары рәхим итегез. (3 кыз, 3 малай ) чыга

Алып баручы: Безнең шулай ук командаларны бәяләп баручы жюриларыбыз да бар. (Жюрилар белән таныштырыла)

Алып баручы: Әйдәгез, командаларга сүз бирик.

Алып баручы: Беренче тур. Сорауларга җавап бирү. Сезгә Аяз Гыйләҗев тормышы һәм иҗаты буенча сораулар бирелә. Сез шул сорауларга җавапны өстәлләрдәге ак битләргә язарга тиеш буласыз. Аннан язган җавапны берәмләп укыйсыз. (Сорауларга җавапны һәр ике команда ак биткә язалар һәм берәм-берәм язганнарын укыйлар.)

1.А. Гыйләҗев кайчан һәм кайда туа? (1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында туа)

2. 1948-50 елларда ул кем? (КДУ студенты)

3. Аяз Гыйләҗев кайта тоткынлыкта була? (Казакъстанда)

4. Аяз Гыйләҗев эшләгән журналлар ? (“Чаян”, “Азат хатын” (“Сөембикә”), “Совет әдәбияты” (“Казан утлары”)

5. Язучының хатынының исеме ничек? (Нәкыя)

6. 1963 нче елдан башлап әдип нинди эшкә күчә? (Профессиональ язучылык эшенә)

7. 1993 нче елда Татарстан Президенты М.М. Шәймиев указы нигезендә нинди исем бирелә? (Татарстан Республикасының халык язучысы)

8.Аяз Гыйләҗевнең күп телләргә тәрҗемә ителгән повесте? (“Өч аршын җир”)

9. “Язгы кәрваннәр” әсәрендә кайсы чор балалары тасвирлана? (Сугыш чоры)

10. “Камыр”, “Тамыр” кемгә әйтелгән кушамат? (Дамир)

Алып баручы: Безнең беренче турыбыз тәмам. Сүз жюрига бирелә.

Алып баручы: Алга таба барабыз. Икенче тур. Сезгә бер видеоязма тәгъдим ителә. Игътибар белән тыңлагыз. Аннан сорау булыр. (Тинчурин театры артистлары тарафыннан Аяз Гыйләҗевнең «Ефәк баулы былбыл кош» спектакленнән өзек күрсәтелә. Сорау: Әлеге спектакль кайсы театрда уйнала?

Алып баручы. Өченче тур. Хаталарны тикшерү.

“Терәзәләр» (“ТӘрәзәләр»)

«Уналты яш» («Уналты яшЬ»)

«Мәхәбәт хәм нәфрәт турында хикәят” («МәхәбБәт Һәм нәфрәт турында хикәят”)

“Көзгө ачы җиләрдә” (“КөзгЕ ачы җилЛәрдә”)

“Жомга көн кич белән” (“Җомга көн кич белән”)

“Әтәч меңгән читәнгә” (“Әтәч меҢгән читәнгә”)

«Әгәр бик сагынсан» (“Әгәр бик сагынсаҢ”)

“Яланайаклы кыз” (“ЯланаЯклы кыз”)

Алып баручы: Ә хәзер сонгы сүздәге хәрефләрдән яңа сүзләр төзергә тиеш буласыз. Сезгә бер минут вакыт.

Алып баручы: Вакыт бетте. Ә хәзер кара-каршы берәмләп төзелгән сүзләрне әйтә барабыз. (Алан, кан, ял, лак, акыл, наз, аяк, каз һ.б. Сүзләр әйтелә, жюри нәтиҗә чыгара)

Алып баручы: 4 нче тур. Капитаннар конкурсы. Һәр команданың капитанына 9 ар сорау бирелә. Әйе яисә юк дип җавап бирергә тиешсез.

1 нче команда

1. Аяз Гыйләҗев Сарман районында туган. (әйе)
2. Язучының 2 улы булган (юк)
3. Аяз сүзендә 3 иҗек бар. (юк)

4. 10 нчы сыйныфны Сарман мәктәбендә укый (әйе)
5. Аяз Гыйләҗев 4 ел тоткынлыкта була (юк)
6. Язучы 2002 нче елда вафат була. (әйе)
7. “Язгы кәрваннар” ул хикәя (юк)
8. А. Гыйләҗевнең күпчелек повестьлары авыл тормышына багышланган (әйе)
9. А. Гыйләҗев Г.Тукай исемендәге премия лауреаты (әйе)

2 нче команда

1. Аяз Гыйләҗев Арча районында туган. (юк)
2. Язучының 3 улы булган (әйе)
3. Гыйләҗев сүзендә 3 иҗек бар (әйе)
4. 10 нчы сыйныфны Казанда укый (юк)
5. Аяз Гыйләҗев 5 ел тоткынлыкта була (әйе)
6. Язучы 2003 нче елда вафат була. (юк)
7. “Язгы кәрваннар” – ул повесть (әйе)
8. А. Гыйләҗевнең күпчелек повестьлары шәһәр тормышына багышланган (юк)
9. А. Гыйләҗев – Г.Тукай исемендәге премия лауреаты (әйе)

Алып баручы: Уен турлары тәмам. Нәтиҗәне чыгарыр өчен сүз жюрига бирелә.

Кичәбезне Рафаэль Мостафин сүзләре белән тәмамлыйсы килә: ”Аяз Гыйләҗев – әдәбиятыбызның имән баганасы**.** Татарстанның әдәби җәмәгатьчелеге Аяз Гыйләҗевне талантлы һәм үзенчәлекле прозаик, хөр фикерле, кыю каләмле әдип, кызыклы драматург, кыскасы, зур язучы дип таныды. Бу әдипнең исеме Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Мөхәммәт Мәһдиев кебек классикларыбыз белән бер рәттә торырга лаеклы”.

Тажетдинова Рүзилә Илгизәр кызы, Сарман гимназиясе
Сарман районы

## Аяз Гыйләҗев. "Алсу, Илдус һәм сандугач"

**Максат:** укучыларны Аяз Гыйлэжевнен ижаты белэн таныштыру, анын эсәрләренә кызыксыну уяту. Туган илгә,анын табигатенә сакчыл караш тәрбияләү, хезмәткә мәхәббәт уяту. Сөйләм телен үстерү.

**Җиһазлау**: Аяз Гыйләжевнең портреты, анын әсәрләреннән кургәзмә, презентация

Дәрес барышы.

1. Оештыру өлеше. Уңай психологик халәт тудыру.

Әкрен генә талгын халык көе уйнатыла.

- Туган як! Туган җир! Туган туфрак! Туган табигать! Һәрбер кеше өчен нинди газиз,тирән мәгънәле сүзләр! Безнең Сарман ягы турында сүз кузгалганда беренче булып аның җырларга кергән тугайлары, тугаенда сайраучы пар сандугачлары, шул сандугачлардан калышмаучы мәшһүр җырчылары күз алдына килеп баса. Алар турында бар дөньяга бәян итүче шагыйрьләребез, язучыларыбыз да байтак.

2.Яңа тема.

- Бүген без, укучылар, сезнен белән шул данлыклы кешеләребезнен берсе, Сарман районының Чукмарлы авылында 1928 нче елның 17 нче гыйнварында укытучы гаиләсендә туып үскән язучы Аяз Гыйләҗевнең иҗаты белән танышып үтәрбез. Аның бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районында уза. Бу елгы хатирәләре турында ул "Балачак сукмаклары"

исемле хикәясендә сүрәтли. Авыл мәктәбенең 9 нчы сыйныфын тәмамлагач, Сарман урта мәктәбендә укый. 1948-1950 нче елларда Казан Дәүләт Университетында белем ала. Сугыш елларында әсирлектә булып, ачлык, ялангачлык фаҗигасен татый. Ләкин туган җиренә, туган халкына мәхәббәтен җуймый, туган илен сатмый. Бу хисләр аның язучы буларак, куп кенә әсәрләрендә чагыла.

3. Белемнәрне актуальләштерү.

- Без сезнең белән буген Аяз Гыйләҗевнең балалар өчен язылган "Алсу, Илдус һәм сандугач" хикәясе белән танышып китәрбез.

1) Хикәяне уку.

2) Сүзлек өстендә эш. Шәфәкъ – офыкта кояш баегач һәм кояш чыкканда чагылып ала торган нурлар балкышы.

3) Әсәрнең эчтәлеге буеча эш.

- Укучылар, хикәя нэрсэ турында, автор бу әсәрендә нәрсә турында әйтергә теләгән?. (Хикәя туган як табигатенә сакчыл караш кирәклеге турында).

- Әсәрнең төп геройлары кемнәр? Аларны автор ничек тасвирлый? ( Төп геройлар Алсу белән Илдус бакчаларында сандугач сайравын ишетәләр,иптәшләренә мактаналар. Ләкин узен күрә алмыйлар, чөнки бакчаны чүп үлән басып киткән була. Шуңа ул бакчаны сандугач та үз итми, ташлап очып китә. Иптәшләре Алсу белән Илдустан "ялганчы", "мактанчык" дип көләләр.)

- Алсу белән Илдусны нәрсә үзгәртә? (Алсу белән Илдус бакчаны чүп-чардан чистарталар, кычыткан, әрем, билчәннән дә курыкмыйлар. Аларны казып алып, чокырга күмәләр. Шулай итеп аларны хезмәт үзгәртә.)

- Хикәядә нинди табигать күренешләре сурәтләнә? (Бакчага ямь керә, тирә як матурлана, киңәеп китә. Өскәрәк үрләгән сирень ботакларында күз явын алырлык матур тәлгәшләр асылынып кала. Иртәнге якта тәрәзәдән нур бөркелә, ачык ишектән салкынча һава ургылып керә һәм баш очында гына өздереп-өздереп бер кош сайрый. Сайрый-сайрый да сызгырып җибәрә. Илдус тәрәзәдән карауга бакчаны танымый. Табигать шул хәтле матурлыкка төренгән була).

4. Алган белемне ныгыту.

- Авторның әйтергә теләгән фикере? ( Хезмәт кешене матурлый, эшләгән эшеннән ямь табарга өйрәтә. Сандугач та шул килүеннән китмәде. Илдус оя ясады, сандугач шунда бала чыгарды. Бик яратты ул Илдусларның бакчасын).

- Сандугач нинди кош ул? ( Сандугач – таң җырчысы, матурлык, нәзакәтлелек билгесе, сәю,мәхәббәткә тугрылыклы җанлы табигать иясе)

- Әсәрдә Алсуның әтисе сандугач турында нәрсә, ди? ("Бәхетле, тырыш кеше бакчасына гына оялый торган асыл кош ул", - ди.)

- Бу әсәргә карата нинди татар мәкальләре әйтер идегез? (Хезмәт төбе – хөрмәт. Тырышкан табар – ташка кадак кагар. Агач җимеше белән, кеше хезмәте белән матур)

5. Дәрескә йомгак. Рефлексия.

- Нәрсәләргә өйрәндек? (Якташыбыз Аяз Гыйләҗевнең иҗаты белән таныштык. Хезмәтнең нәтиҗәсен аңларга өйрәндек. Табигатьне сакларга, якларга кирәк икәненә төшендек)

Хәмәтҗанова Фәнүзә Сәгыйрь кызы,
Сарман урта мәктәбе, Сарман районы

## “Исем” темасы буенча якташ язучы Аяз Гыйләҗев әсәрләрен файдаланып эшләнгән күнегүләр

Укучыларыбызда төбәгебездән чыккан язучылар һәм аларның әсәрләре белән кызыксыну уяту йөзеннән шул шул әсәрләрдән алынган текстлар, җөмләләрне, язучылар, шагыйрьләр турындагы мәкаләләрне дәрестә файдалану - отышлы алым. Әзерләнгән ул күнегүләрне дидактик материал буларак кулланырга мөмкин.

Күренеклеякташларыбыз турында язылган текстлар танып- белү эшчәнлегенә ярдәм итә.

### Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр

**Бирем.** Ялгызлык исемнәрен билгеләгез.Аларның нәрсә белдергәннәрен, язылышларын аңлатыгыз.

1. Рәшит тау күкрәгендәге ташлар, диңгез төбендәге мәрҗәннәр, Каф тау артындагы алтын кантарлары хакында дәртләнеп-дәртләнеп сөйләргә керешсә дә, Разыя аны тыңламый иде. Авылда әле унынчы класста укыган чаклары һәм “Галиябану”ны куюлары исенә төште Разыяның.*(А.Гыйләҗев. “Егет белән кыз”)*
2. Салих эре хәрефләр белән конверт тышына “Казан, “Чаян” журналына” дип сырлады да тыныч күңел белән йокларга ятты. (*А.Гыйләҗев.”Уйлап табучы”)*
3. Бүген, таң яралмас борын ук, “Зәңгәр сәдәф” исемле тегүчеләр әртиле тынычлыгы бозылган кырмыска оясына охшап калды. (*А.Гыйләҗев.”Җинаять һәм җәза”)*
4. Каратау станциясендә аларга Кыңгыраулы ягыннан килүче поезд очрады. Саҗидә дә, Мәснәви дә бу поездның нәкъ өченче вагонында бер кочак бүләк төягән, шатлыклы һәм бәхетле Әзәл белән Асиянең баруын белми дә калдылар... (*А.Гыйләҗев.”Үбү”)*
5. Моннан ярты гасырлар чамасы элек Үзбәкстанның Коканд шәһәреннән Габсаттар Ходжаев исемле бер үзбәк Казан якларына килеп чыга. *( А.Гыйләҗев.”Олы урам күләгәсендә”)*
6. Муйнакны бәйгә куярга кирәк, Галимҗан. Бик әшәкеләнгән. Берәрсен тешләп, бәлале булырсың. (*А.Гыйләҗев.”Муйнак”)*
7. Соңгы елларда Зәйдә ГРЭС салдылар – ул тирә-як авыллардан байтак чуар йөрәкләрне җыйды. Аннары Түбән Кама, Чаллы – гигант төзелешләр чоры башланды, заводлар моңарчы йөрүне артык яратмаган, үз авылыннан кыз алып, үз авылына кыз биреп яшәгән Аксыргактан да бик күпләрне үзенә суырып алды, авыл уртасындагы дәрәҗәле урыннарда да буш ихаталар ешайды. (*А.Гыйләҗев.”Җомга көн кич белән...”)*

### Исемнәрнең килеш белән төрләнеше

**Бирем.** Исемнәргә сораулар куеп, килешләрен билгеләгез.

1. Аяз Гыйләҗевнең исеме киң катлау укучыларына яхшы таныш. Ул Чукмарлы авылында туган. Балачагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. *(“Сарман” газетасы)*
2. Аяз Гыйләҗевнең беренче китабы 1960 нчы елны чыкты.Ул – “Яшьлек елларында” дип аталган юка гына бер китап иде. *(“Сарман” газетасы)*
3. А.Гыйләҗевнең әсәрләрендә без күбрәк тормышның ямьсез күренешләре, фаҗигале хәлләре, тупас бәндәләре белән очрашабыз. (*Ф.Миңнуллин)*

4. Аяз Гыйләҗев – әдәбиятыбызның төрле тармакларында ут уйнаткан кеше. (*Ф.Миңнуллин)*

5. Аяз Гыйләҗевне язучы итеп таныткан әсәре, миңа калса, “Үги ана яфраклары” дигән егерме генә битлек хикәясе булды. *(Х.Сарьян)*

6. Сүз Аяз Гыйләҗев турында барганда, шикләнми әйтергә була. Ул – чынлап та безнең әдәбиятны үзгәрткән әдип. (*Ф.Миңнуллин)*

**Исемнәрнең тартым белән төрләнеше**

**Бирем.** Тартым белән төрләнгән исемнәрне табыгыз, аларның килешләрен табыгыз, мәгънәләрен аңлатыгыз.

1. Һай, биек тә соң Сәләхетдиннәрнең читәне! (*А.Гыйләҗев.”Әтәч менгән читәнгә”)*

2. Әтәч тә җүләр түгел, тәҗрибәсе һәм куәте бар, ишле кәзинәкләренең ни көткәнен күз карашларыннан сизде, тавыклар, аның дәрт-дәрманын көчәйтеп кырлый-кырлый, читән күләгәсендә сырпаландылар. (*А.Гыйләҗев.”Әтәч менгән читәнгә”)*

3. Әтиемнең Сарман тумасы икәнен әйткән идем инде. *(А.Гыйләҗев. “Балачак сукмаклары”)*

4. Авыл малаеның балачак хатирәләре кыяр-шалканнан башлана икән, моңа һич гаҗәпләнергә кирәкми. *(А.Гыйләҗев. “Балачак сукмаклары”)*

5. Дүрт яшемдә идеме, әллә якты кояш астында бишенче җәемне үткәрә идемме, безнең авылда балалар бакчасы ачтылар. *(А.Гыйләҗев.“Балачак сукмаклары”)*

6. Көзге кыр эшләре башлану белән үк бозылган һаваның рәтсезлеге бик озакка тартылды. *(А.Гыйләҗев. “Дүртәү”)*

**Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше**

**Бирем.** Тартымлы исемнәрне табып, асларына сызыгыз. Күп нокталар урынына тиешле тартым һәм килеш кушымчаларын куеп, җөмләләрне күчереп языгыз.

1. Урман авыл малае...никадәр кадерле ул! *(А.Гыйләҗев. “Дүртәү”)*

2. Мин атлар... карап килдем, бөрлегән эзләдем, ләкин таба алмадым. *(А.Гыйләҗев “Дүртәү”)*

3. Буа тавыш... аермачык ишетте Бибинур карчык. ( *А.Гыйләҗев.”Җомга көн кич белән...”)*

4. Бибинурның күз... тагын куе яшь килеп тыгылды. ( *А.Гыйләҗев.”Җомга көн кич белән...”)*

5. Җәмил абый... мактаулы кызга әнә шулай диде. ( *А.Гыйләҗев.”Әтәч менгән читәнгә”)*

6. Бару-бармау мәсьәлә... хәл итүдә ул ирекле диярлек иде. Әнә шул ирекне тою аны юлга ныграк этәрә, тик күңел... кайсы чирегендәдер туган икеләнү божра... тиз-тиз өзеп ташлый алмау гына аны сәерсендерә иде.( *А.Гыйләҗев. “Үги ана яфраклары”)*

7. Әнәснең юрганы идәнгә савылып төшкән, ул, тезләр... чәнчеп бөгәрләнеп яткан, иреннәр... чәпелди, иреннәр... елмая, ул төш... чабып баручы ат көтү... күрә! (*А.Гыйләҗев.”Әтәч менгән читәнгә”)*

**“Исем” темасы буенча контроль диктант**

**Бирем.** Исемнәрнең асларына сызарга, килешләрен билгеләргә.

**Искәрмә.** Авыр язылышлы сүзләрне тактага язып куярга, мәгънәләрен аңлатырга.

Аяз Гыйләҗев – проза һәм драматургия өлкәсендә үз урынын тапкан, иҗат буындашлары арасында тизрәк өлгергән, үзенчәлекле язу стиленә ия булган һәм үзенең популярлыгы белән дә аерылып торган бәхетле язучыларның берсе.

А.Гыйләҗевнең тормыш тәҗрибәсе арткан саен, аның иҗат офыклары тагын да ныграк ачыла. Авторның сугыш алды һәм сугыш чоры, аннан соңгы совет авылы тормышын сурәтләгән “Берәү”, “Өч аршын җир”, “Язгы кәрваннар”, “Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят”, “Мең чакрым юл”, эшчеләр темасын күтәргән “Зәй энҗеләре”, сәнгать кешеләре тормышына багышланган “Урталыкта”, “Җомга көн кич белән”, “Әтәч менгән читәнгә” повестьлары, журналистлар тормышын һәм хезмәтен чагылдырган “Урамнар артында яшел болын”, “Җиз кыңгырау” пьесалары китап сөюче укучыларыбыз тарафыннан яратып укыла.

Язучының соңгы әсәре – роман-хатирә “Йөгез, бер дога”. Бу роман аның иҗатын аңлауга тулаем ачкыч булып тора. Аны укымый һәм андагы һәрбер фикер турында тулаем аңламый торып, А.Гыйләҗевне һәм шәхес, һәм әдип буларак тулысы белән аңлый алмас идек. *(“Сарман” газетасы)*

Нигматуллина Флүзә Әсгать кызы
Яңа Кәшер санатор мәктәп- интернаты, Әлмәт районы

## Без белергә тиеш

**Максат** : Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнү.

**Бурычлар:** Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлын һәм әсәрләрен белүләре, тормыш итү дәвамында, тирә-юньдәге кешеләрнең эчке дөньялары, үзара мөнәсәбәтләренең әһәмиятен күрсәтү, язучының иҗатына кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Аяз Гыйләҗевнең биографиясенә презентация, портреты, китапларына күргәзмә, әсәрләренә иллюстрацияләр.

### Кичә барышы

**Укытучы.** Хәерле көн, хөрмәтле тамашачылар, кадерле кунаклар! Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗатына багышланган “Без белергә тиеш” дип исемләнгән әдәби кичәбезне башлап җибәрик.(Слайд №1)

**Укучы.**

Дөньяны күрәм тик беренчесен,
Тудым да менә нәкъ шуның өчен.
Шушы дөньяда эзем калсын дип,
Ялкын йөрәгем гомер янсын дип.

“Кеше яши икән, бәхет татыр өчен яши“, - дип яза А.Гыйләҗев.Ул үзен бик бәхетле кеше дип санаган. Чөнки аның яраткан хатыны Нәкыя ханым, уллары – Искәндәр, Мансур, Рәшат һәм оныклары аңа иҗат итү өчен көч, дәрт биреп торганнар.

**Укучы.** Татарстанның халык язучысы, драматург, публицист Аяз Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында хәзерге Татарстан Республикасының Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган.

Укытучыларны элек бер авылдан – икенчесенә, бер мәктәптән өченчесенә күчереп йөрткәннәр. Урта Баграждагы бу йорт – алар беренче үз нигезләре. Язучы булып, беренче әсәрләре басыла башлауга, Аяз ага әти-әнисенә йортларын яңартырга булышкан. Улларының балачагы да шушында – әбиләре белән бабайлары янында узган.

**Укучы.** Аяз Гыйләҗев Урта Баграж авылын халкына – керәшеннәргә гомер буе рәхмәтле булган. Бу аның әсәрләрендә ачык күренә. Шушы авыл кешеләрен, мондагы сукмакларны, чишмәләрне, тауны язучының китапларыннан җиңел таныйсың.

**Укучы.** Авыл мәктәбенең тугыз сыйныфын һәм Сарман урта мәктәбендә унынчыны тәмамлаганнан соң, берникадәр вакыт колхозда эшләгән. 1948 елда Казан университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый башлый. Илдәге репрессияләр шаукымы иҗади студент яшьләрне дә читләтеп үтми. Казан университетында өзелгән укуын дәвам итәргә соңрак мөмкинлек ала. (Слайд №2)

**Укучы.** Университетны тәмамлагач, А.Гыйләҗев берничә ел (1957-1961) көндәлек матбугат редакцияләрендә эшли, аннары, Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы икееллык Югары әдәби курсларда укып кайтканнан соң, 1963 елдан башлап бөтенләе белән профессионал-язучылык хезмәтенә күчә.Ул үзен бигрәк тә озын хикәя-повесть остасы итеп таныта. “Дүртәү”, “Өч аршын җир”, “Зәй энҗеләре”, “Берәү”, “Урталыкта”, “Язгы кәрваннар”, “Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят”, “Мең чакрым юл”, “Җомга көн, кич белән…”, “Әтәч менгән читәнгә”, үзгәртеп кору елларында язылган “Балта кем кулында?”, “Яра” повестьлары – шуның матур мисаллары.

**Укучы.** Аның хезмәтләре арасыннан “Җомга көн, кич белән…” һәм “Әтәч менгән читәнгә” повестьлары1983 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә, ә 1987 елда русча тәрҗемәдә Казанда басылган “При свете зарниц” исемле китабы өчен РСФСРның М.Горький исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

**Укытучы.**

Син яшәмә җирдә файдасыз бер
Түмгәк булып тигез урында.
Янып калсын гомрең, маяк булып
Үзеңнән соң килгән буынга.
Эзе калсын керсез намусыңның,
Ни үтсә дә синең кулыңнан.
Көчлелегең белән горурланма!
Кешелегең белән горурлан!

Мин Муса Җәлилнең әлеге шигъри юллары белән кешегә хас булган кешелеклелек сыйфатын әйтергә телдәдем. Безгә таныш булган “Җомга көн кич белән...” повестенда Бибинур образы шушы сыйфатның бер үрнәге булып тора. Повесть үзәгенә, бигрәк тә балалары тарафыннан онытылган Бибинур карчыкның олы җанлы булуы куелган.Бибинур – бәләкәй генә гәүдәле, ябык аркалы, авылдашлары күзенә дә алай артык чалынмаган, тыныч холыклы, йомшак тавышлы, этисе төсле зәп-зәңгәр күзле, ярдәмчел, оста, җитез, чиста, сабыр татар әбисе.

**Укытучы.** Аяз Гыйләҗев әсәрләренең тәрбияви кыйммәте әйтеп бетергесез зур. Алар – безнең милләтебезнең рухи байлыгы, милли үзенчәлекләре турында чорыбыз вакыйгаларына бәйләп язылган әдәби әсәрләр.

Бүгенге көндә дә язучы турында яңадан-яңа фикерләр туа, нәшрият битләрендә аның турында язылган мәкаләләр арта.А.Гыйләҗев иҗаты – үлмәс, мәңгелек иҗат.

Бүгенге сыйныфтан тыш чараны Р.Фәйзуллинның “Кеше кайчан матур була?” дигән шигырендәге юллар белән тәмамлыйсым килә.(Слайд №3)

Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шулвакыт —
Иле өчен, халкы өчен
Яшәгәндә җан атып;
Замананың авырлыгын
Җилкәсенә алганда;

Олы данга ирешеп тә,
Кече булып калганда.

Халиуллина Роза Барый кызы, Яңа Кәшер санатор мәктәп-интернаты,
Әлмәт районы

## Аяз Гыйләҗев безнең күңелләрдә
## Чара эшкәртмәсе

**Максат:** Укучыларда А.Гыйләҗев иҗаты белән кызыксынуны үстерү һәм фәнни – практик яктан эзләнүне булдыруга омтылыш уяту.

**Җиһазлау:** язучының рәсеме, язучының китапларыннан күргәзмә.

**Укытучы**. Хәерле көн, хөрмәтле укучылар, укытучылар һәм килгән кунаклар! Бүген бездә бәйрәм, матур бәйрәм. Без бүген олы йөрәкле, гаҗәеп тә талантлы, киң күңелле татар халык язучысы, ТАССРның, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык язучысы, Габдулла Тукай, М.Горький исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты Аяз Мирсәет улы Гыйләҗевне искә алу кичәсенә җыелдык. Әлеге бөек шәхесне искә алу кичәсен башлап җибәрергә рөхсәт итегез.

**Укучы:** Әйе, безнең республикабыз талантлы шәхесләргә бик бай. Кемнәр генә юк алар арасында? Әдәбият һәм сәнгатьнең, фән һәм мәдәниятнең, хезмәт һәм батырлыкның кайсы гына тармаган алсаң да, тарихта үз исемен зур хәрефләр белән язып калдырган шәхеслеребез күп безнең. Татар халкының күренекле шәхесләрен дөньяның төрле почмакларында очратырга мөмкин. Шуларның берсе – Аяз Гыйләҗев. Ул күренекле прозаик, үзенчәлекле драматург, үткен каләмле публицист һәм очеркист, ниһаять, “усал телле тәнкыйтьче”.

**Укучы:**
Нихәл итик, бүген Сез торасыз
Безнең иркен күңел түрендә.
Иҗатыгыз аша сикәлтәле,
Олы тормыш юлы күренә.

**Укучы:**
Моңсу, чөнки безнең арабызда
Юк шул бүген газиз язучы.
Әле генә менә бергә идек,
Шул көннәргә, әйдә, кайтыйкчы?

**Укучы:**
Бүген мин тудым, сез беләсезме?
Минем тавышны ишетәсезме?
Карагыз миңа, я, күрәсезме?
Нинди кечкенә, дип көләсезме?

**Укучы:** Прозаик һәм драматург Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында узган. Авыл мәктәбенең тугызынчы сыйныфын тәмамлагач, унынчы сыйныфны Сарман урта мәктәбендә укыган. Сарман урта мәктәбендә унынчыны тәмамлаганнан соң, бу була 1945 ел, берникадәр вакыт колхозда эшләгән.

**Укучы:** 1948 елда Казанга килеп, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергән. Монда ул, уку программасындагы фәннәрне яхшы үзләштерү белән бергә, беренче курстан ук бик мавыгып университет каршындагы әдәби түгәрәккә йөри, анда үзенең язган беренче иҗат тәҗрибәләре белән уртаклаша, фикер алышуларга, диспут-бәхәсләргә актив катнаша.

**Укучы:** Илдәге репрессияләр шаукымы иҗади студент яшьләрне дә читләтеп үтми: 1950 ел башында Казан югары уку йортларында укучы бер төркем татар студентларын, шул исәптән А.Гыйләҗевне, «советка каршы коткы таратуда һәм милләтчелектә гаепләп», кулга алганнар.

**Укучы:** А.Гыйләҗевне җиде елга ирегеннән мәхрүм итеп, хезмәт колониясенә җибәрергә дигән хөкем карары чыгарганнар. Югары белем алып, язучы булырга хыялланган егерме ике яшьлек егет әнә шулай Казакъстандагы совет концлагерьларында биш елга якын җәфа чигәргә мәҗбүр булган. Фәкать Сталин вафатыннан соң гына аны иреккә чыгаралар һәм Казан университетында өзелгән укуын дәвам итәргә мөмкинлек бирәләр.

**Укучы:**

Казан, Казан! Сиңа багышлап
Инде күпме җырлар язганнар.
Күпме яшьләр синдә белем алып,
Чын мәгънәдә кеше булганнар.

**Укучы:** Университетны тәмамлагач, А.Гыйләҗев берничә ел, 1957-1961 елларда көндәлек матбугат редакцияләрендә эшли, аннары, Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы икееллык Югары әдәби курсларда укып кайтканнан соң, 1963 елдан башлап бөтенләе белән профессионал-язучылык хезмәтенә күчә.

**Укучы:** Аның иҗат эшчәнлегендә драматургия жанры зур урын били. Ул бик күп комедия, трагедия һәм драмалар язган. Аларның күпчелеге Казанның Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры сәхнәләрендә, Татарстанның Әлмәт, Минзәлә, Чаллы шәһәрләрендәге театрларда куела, кайберләре, башка телләргә тәрҗемә ителеп, үз вакытында башкорт, чуаш милли театрлары, рус театры сәхнәләрендә дә уңыш белән бара.

**Укучы:** Аның “Шикәрем син, балым син”, “Яланаяклы кыз”, “Көзге ачы җилләрдә”, “Киек каз юлы” пьесалары буенча куелган спектакльләрен халык бик яратып карый.

**Укучы:** Аяз Гыйләҗев проза өлкәсендә зур казанышларга ирешкән. Аның “Язгы кәрваннар” һәм “Җомга көн кич белән” повестьларын бигрәк тә яратып укыйлар. Әдипнең күп әсәрләрендә туган як, туган җир, туган авыл, аның гаделлеккә нигезләнгән тәртипләре, гореф-гадәтләре, әхлакый кануннары – шуларга тугрылыклы булып кала белү мәсьәләләре күтәрелә.

**Укучы:** Аның әсәрләрен укыганда күз алдына сугыш чорында авылда үскән намуслы, тыйнак, саф күңелле кешеләр килеп баса. “Язгы кәрваннарда” гы Ибраһим, Дамир, Әдиләләрнең эчкерсезлеге, авырлыклардан курыкмаулары, шундый авыр тормыш шартларында да мәхәббәт дигән изге хискә тугры калулары. Дамирның Әдиләгә карата булган ихтирам катыш сөюе сокландыра. Ибраһимның да Әдиләгә карата хисләре чын, ләкин ул бу ике йөрәк арасындагы изге хискә каршы килә алмый. Бу әсәрдә кешелеклелек беренче урында тора, әсәр укучыны рухи-әхлакый яктан тәрбияли.

**Укучы:** Ә “Җомга көн кич белән” әсәрендә төп образ – Бибинур. Аяз Гыйләҗев Бибинур карчыкның шәхесе аша кешеләрне борчыган иң җитди мәсьәләне – балаларның ата-анага карата каты күңелле булуын күтәрә. Ни өчен гомерен кеше бәхете өчен корбан иткән кешеләр, гадәттә, үзләре бәхетсез булалар? Язмышның усал шаяруымы бу? Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр ничек тәэсир итә бу өлкәгә? Бу сорауларга җавапны өздереп кенә әйтеп булмый. Ләкин Бибинур карчыкның хакыйкатьтән куркуы, үзен аямыйча яшәве фаҗигагә китерә.

**Укучы:** Аяз Гыйләҗев үзенең әсәрләре аша кешене тәрбияли, яшәргә өйрәтә, тормышта килеп туган авырлыклардан куркып калмаска, үзеңне яратырга, гел кеше турында гына уйламаска өйрәтә. Әхлаксыз адәмнәрнең дөньяда күп булуын, алардан үзеңне саклый белергә кирәклеген аңлата.

**Укытучы:** Нәтиҗә ясап шуны әйтәсем килә: Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең иҗаты халык күңеленә бик якын. Ул – кыю каләмле язучы. Милләт өчен, гади халык өчен янып-көеп яшәгән әдипнең иҗатын онытмау, бу бөек шәхесне зурлау бездән тора.

Күренекле әдип,Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай, М.Горький исемендәге Дәүләт бүләкләре иясе Аяз Гыйләҗевнең иҗаты – әдәбиятыбызның кыйммәтле бер өлеше. Аның бай иҗаты киләчәк буыннарга да хезмәт итәр, якты истәлеге халкыбыз күңелендә мәңге сакланыр.

Ситдыйкова Чулпан Индус кызы, Ситдыйкова Эльвера Дамир кызы,
Мөслим лицее, Мөслим районы

**Кейс методы аша Аяз Гыйләҗевнең “Тәрәзәләр” хикәясен анализлау (Мастер-класс)**

Бүгенге көндә яңа нәтиҗәле укыту технологияләрнең берсе – кейс методын куллану. Бу метод безнең илдә дә актив кулланылышка кереп бара һәм актуаль мәсьәләләрдән санала, чөнки мәктәпләр алдына куелган бурычлар белем бирүгә яңача караш, интерактив алымнар куллануны таләп итә. Кейс методы нигезендә уку-укыту процессын нәтиҗәле оештыру өчен яхшы кейслар һәм аларны дөрес куллану методикасы таләп ителә. Кейс методы чит илдә киң кулланылышта, беренче тапкыр Гарвард университетының (1920 елда) бизнес мәктәбендә кертелә башлый.

Кейс инглиз теленнән алынган, case “очрак, хәл, ситуация” мәгънәсендә, “кейс” төшенчәсе “кәгазьләр, документлар салып куя торган кечкенә чемодан” мәгънәсендә. Кейс – дәресләрдә тормыштан алынган хәлләргә нигезләнгән проблемалы ситуацияләрне анализлау. Анализ вакытында укучылар төркемнәрдә эшләргә, нәтиҗә чыгарырга, дөрес карар кабул итәргә өйрәнәләр. Методик яктан дөрес төзелгән, мәгълүмати характердагы кейс-биремнәр укучыларның мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерә, интерактив метод буларак укучыларда укуга уңай караш тәрбияли, укыту процессында тормыш белән бәйләнеш тудыра.

Кейс методы укытучыга да яңача фикер йөртергә ярдәм итә, иҗади эшчәнлекне тәэмин итә.

Кейсның төрләре:

1) гамәли кейслар 2) өйрәтү характерындагы кейслар 3) фәнни-тикшеренү кейслары

Кейс методы куллану дәресләрен оештыруның якынча планы:

1. Әзерлек этабы. Укытучы проблемалы ситуацияләр, өстәмә материал әзерли. Дәреснең урынын, бурычларын билгели.

2. Таныштыру этабы. Бу этапта укучыларны ситуация белән таныштырыла (ситуация, өстәмә материал, глоссарий)

3. Төп этап. Укытучының кереш сүзе, укучыларны төркемнәргә бүлү, төркемнәрнең эшләрен оештыру (укучыларның укылган материалны төркемдә сөйләүләре, материал буенча фикер алышу, проблемаларны билгеләү, доклад ясаучыларны билгеләү).

4 Дискуссия оештыру этабы

1.Төркемнәрдә дискуссия оештыру, проблемаларны тикшерү, чишү юлларын эзләү.

2. Гомуми дискуссия. Анализ нәтиҗәләре белән таныштыру, чишелешне билгеләү.

5. Йомгаклау этабы. Анализланган проблема нәтиҗәләрен презентацияләү. Берничә юл (чишелеш) булырга мөмкин.

**Укытучы һәм укучылар арасында эшчәнлекнең бүленеше:**

| Эш фазасы | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| Дәрескә кадәр | 1. Кейс сайлый<br>2. Өстәмә материал әзерли<br>3. Дәрес барышын планлаштыра. | 1. Кейс һәм өстәмә әдәбият ала.<br>2. Дәрескә мөстәкыйль әзерләнә. |
| Дәрес вакытында | 1. Кейс буенча фикер алышуны оештыра.<br>2. Группаларга бүлә.<br>3. Укучыларны өстәмә материал белән тәэмин итә, группалардагы фикер алышу белән идарә итә. | 1. Кейсның эчтәлеген тирәнрәк аңлар өчен сораулар бирә<br>2. Укучылар укылган материалны төркемдә сөйли, материал буенча фикер алыша. |
| Дәрестән соң | 1.Укучыларның эшчәнлеген тикшерә.<br>2. Эшләрне бәяли һәм нәтиҗә чыгара. | Бирелгән үрнәк буенча дәрес турында язмача отчет әзерли. |

Кейс методын мөстәкыйль эшчәнлеккә әзер укучылар белән эшләгәндә генә кулланырга мөмкин. Укуга мотивация булмау кейсларны өстән генә карап чыгу белән чикләнергә мөмкин. Кейс методы башка методлар белән чиратлашып алып барыла. Кейсларны төрле формада бирергә мөмкин: видео-кейс, мультимедиа-кейс, язма кейс. Күләме ягыннан да кейслар төрлечә булырга мөмкин: бер бит язма материалдан алып берничә язма биткә кадәр. Ләкин зур күләмле кейслар укучыларга кабул итү өчен авыррак. Кейс методы белән эшләгәндә әзерләнгән кейслар белән бергә аларны куллану буенча методик тәкъдимнәр дә булырга тиеш.

**Практик өлеш**

**Тема: Кейс методы аша Аяз Гыйләҗевның “Тәрәзәләр” хикәясен өйрәнү**

Сыйныф: 8 нче сыйныф

Укучылар хикәя белән алдан танышалар.

Укытучы. Аяз Гыйләҗевның “Тәрәзәләр ”хикәясе эчтәлеге буенча фикер алышырбыз.

- Автор әлеге әсәре белән нәрсә әйтергә тели? Хикәя нәрсә турында?

**Төркемнәрдә эш.** Сезнең алда конвертлар. Конвертлар эчендәге сорауларны укып, фикер алышыгыз.

**1)”Яз” төркеменә**

1) Автор хикәясен ни өчен “Тәрәзәләр” дип атады икән?

2) Әсәрне өлешләргә бүлегез, һәрберсенең эчтәлеген табыгыз

3) Һади һәм Һашим образларын автор әсәренә ни өчен кертте микән?

**2) “Кояш” төркеменә сораулар**

1) “Тәрәзәдә нур бар икән, тормыш бар, тереклек бар“ юллары аша шагыйрь ни әйтергә теләде икән?

2)Хикәя сездә нинди хисләр уятты?

3) Сез автор фикере белән килешәсезме?

**2 бирем**

**Түбәндәге мәкальләр арасыннан хикәяне төрле яклап ачканын сайлагыз**

Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез – көн күрмәс

Бер яхшы эш мең яхшы сүздән артык

Гомер кыска – уткәрмә бушка.

Кеше яраткан эшен яхшы эшли

Кошның матурлыгы төсенә карап,

Кешенең матурлыгы эшенә карап.

Эше барның көче бар.

**3 бирем**

**Кейс эчендә текстлар тәкъдим ителгән, бүген өйрәнгән хикәя эчтәлегенә сезнең карашка иң туры килгәннәрен табып укыгыз**

1.Илгә кирәкле булу,

Яхшы теләкле булу,

Илдә һөнәрле булу —

Ак бәхетләр түгелме? (М.Садри)

2.Һөнәрләрнең барысы да

Тигез кеше каршында.

Күңел тарткан бер һөнәр

Сайла, сине кешеләр

“Алтын куллы” дисеннәр. (М.Садри)

3.Бер хәким балаларга шундый хикәят сөйләде.”Әй җаннарым, угланнарым, хикәятемне ишетегез – һөнәр өйрәнегез. Дөньяның байлыгына ышанырга ярамый. Алтын-көмешләр кеше өчен хәтәрдер. Йорт-җире булган кеше өчен аның тагын бер хәтәр ягы бар: аны я карак алып китә, я утта янып бетә. Әмма һөнәр бер агымсудыр, ышанычлы дәүләттер. Һөнәр иясе байлыгын югалтса да кайгырмас. Әй угыл, син дә шулай һөнәр өйрән, тәрбияле бул, белем ал..” (Каюм Насыйри “Тәрбият китабы)

**Йомгаклау.** Аяз Гыйләҗев үз әсәрләрендә кузгаткан фикерләре белән безнең татар халкына аеруча якын. Язучының прозасы фикергә, фәлсәфи уйлануларга бай. Әсәрләрен укыганда, без уйлана һәм уйландыра белүче геройлардан тыш, дөньяның агышы, гомернең мәгънәсе турында күп фәлсәфи фикерләргә юлыгабыз.

Күренекле язучы А.Гыйләҗевнең “Тәрәзәләр” хикәясендә бүгенге көннең бик җитди проблемалары күтәрелә дияргә мөмкин. Мәрхәмәтлелек, миһербанлылыкның кешеләр күңеленнән югалмавын сурәтләгән, хезмәткә хөрмәт тәрбияләүче бу әсәр аеруча игътибарга лаек. Үсмер Һадиның күңеленә игелек орлыклары чәчүче пыялачы Фәхриев образы соклану хисләре уята. Мондый геройлар явызлык, гаделсезлек дөньясында якты нур булып, укучылар күңелендә өмет чаткысы кабызып, тормышка ышаныч уятып торалар.

Михайлова Эльвира Илгиз кызы,
Әгерҗе шәһәре 2 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе,
Әгерҗе районы

**Аяз Гыйләҗевнең "Үги ана яфраклары" хикәясе буенча дәрестән тыш чара**

**Максат:** А.Гыйләҗев иҗаты белән танышу, "Үги ана яфраклары" хикәясен уку. Автор иҗатында "Табигать һәм мәхаббәт" темасын ачыклау. Бер-береңә карата игътибарлы булу, кеше хезмәтенә хөрмәт белән карау кебек уңай сыйфатлар тәрбияләү. Китап укуга кызыксыну уяту.

**Катнашучылар:** 8-9 сыйныф укучылары.

**Укучыларның төп эшчәнлек төрләре:** тулы һәм матур җөмләләр кулланып сөйләшә белү, бәйләнешле сөйләм төзү, рәсем буенча әңгәмә, сорауларга җавап бирү, сөйләү, үрнәк буенча парлап эшләү, чагыштыру, тыңлау, сүзлек белән эш, гомуми нәтиҗә чыгару.

**Җиһазлау:** компьютер, презентация, интерактив такта, укучылар рәсемнәре, китап киштәсе.

**Китапханәче.** Исәнмесез, укучылар ! Хәерле көннәр сезгә! Без бүгенге дәрестән тыш чарада А.Гыйләҗев иҗаты белән танышып китәрбез. (А.Гыйләҗев турында кыскача биографик белешмә белән таныштыра) А. Гыйләҗев – ике дистәдән артык драма әсәре авторы.

**А.Гыйләҗев иҗаты буенча китап киштәсе белән танышу "Үзен үзе җиңгән шәхес ..."**

Әңгәмә кору.

**Китапханәче:** Сезгә өйдә А.Гыйләҗевнең "Үги ана яфраклары" хикәясе белән танышырга һәм шул хикәя буенча рәсем ясарга кирәк иде. Шушы рәсемнәрне менә бу күргәзмәдә таный аласыз.

Бүгенге класстан тыш чарада сыйныф 2 төркемгә бүленә. Һәр төркемгә сорау бирелә. Җавап булмаса, сорауга җавапны икенче төркем бирә.

Алдагы соравым бөтен сыйныф укучылары өчен:

Бу әсәр нәрсә турында? (җавап: *мәхәббәт һәм табигать турында, кеше - табигать баласы).* Әйе, унтугыз битлек әлеге хикәя мәхәббәт турында поэма булып яңгырый.

Хикәянең төп каһарманы кем? (җавап: ***Галимҗан,*** *Сөмәя)*

***1төркем***

1. Галимҗан нинди егет? (Җавап: Галимҗан тәртипле, намуслы, акыллы, олы кешеләргә начар сүз әйтми, туган авылын ярата. Галимҗанның кыяфәте, үз үзен тотышы, уйлары, сөйләшүе, аның нинди икәнен безгә аңлата).

***2 төркем***

2.Сөмәя нинди кыз? (Җавап: тыйнак,оялчан,тәртипле...)

***1төркем***

3. Галимҗан кайда эшли? Очрашу көнне ул нинди кием киеп чыккан? (Җавап: комбайнчы, ак күлмәк).

4. Ни өчен Галимҗан эшкә ап-ак күлмәк кигән? (Тексттан җавап табу. Җавап: чөнки ул Сөмәя белән очрашып аңлашырга җыена. Шуңа күрә ул комбаиннан ашлык ташу кебек тузанлы эшкә дә ап-ак күлмәк киеп чыккан).

***2 төркем***

5. Ә Сөмәянең очрашу көнне күлмәге нинди төстә? *(Җавап:Сөмәянең күлмәге ак төстә).*
6. Галимҗан нинди хисләргә бай? (Галимҗан шагыйрәнә матурлык күрә, чөнки ул Сөмәяне күрүен тели һәм ярату хисен әйтергә тели. Галимҗан матурлыкны күрә, аңлый).

***Һәр төркемгә сорау***

7. Галимҗанга капма-каршы итеп кем образы куелган? Ни өчен?(Җавап: Хәнәфи образы. Матурлыкны күрми).

Галимҗан белән Хәнәфинең сөйләшүләре. Күзлүт уләне турында әйткән сүзләрен тексттан табып уку. (492 - 493 битләр. Йөкче мәзәк кенә пырхылдады:..)

***Һәр төркемгә сорау***

8. Галимҗан Хәнәфигә нинди үлән турында сөйли? (Җавап: күзлүт үләне турында).
9. Күзлүт уләне нинди үлән ул? (*Текст белән эш.* А.Гыйләҗев Сайланма әсәрләр. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияте (ТаРИХ), 2004.- 511б. китабыннан 492 бит).
Сүзлек белән эш итү.(Татарско-русский словарь 205 бит: Күзлүт *бот.* жабрей, жабрица, пикульник).

***Һәр төркемгә сорау***

10. Ни өчен А.Гыйләҗев хикәягә “Үги ана яфраклары” дигән исем биргән? Һәр укучы үз фикерен әйтә.

Текст белән эш, сүзлек белән эш итү.(Татарско-русский словарь 449 бит.) (Җавап: мать-и-мачеха, Галимҗан белән Сөмәянең сөйләшүләре 504-505 битләр). Хәнәфи – үги, Галимҗан - ана да дип була.

11.Галимҗан белән Сөмәя бергә булачакмы?(Әйе, чөнки алар бер берсен аңлыйлар, хөрмәт итәләр...)

Нәтиҗә ясау. Йомгаклау. Буктрейлер күрсәтү.

Китапханәче: Галимҗан кешеләрне ярата, аның уйлары да ак. Ул табигатьне ярата, күп укый, ул бәхетле кеше. Сөмәя дә табигатьне ярата, тәрбияле, яхшы холыклы. Галимҗан белән Сөмәя – икесе дә ак күлмәктән, ак күңелле кешеләр.

Кеше – табигать баласы. Язучының бу хикәясе укучыларга табигать белемен арттырырга да ярдәм итә.Үзебез моңа кадәр җитәрлек игътибар итмәгән бик күп яңа серләренә, беренче карауга күзгә чалынмый торган гаҗәеп нечкә үзенчәлекләренә төшенәбез. Гади генә чүп үләне дип уйлаган кеше күзлүт үләне, үги ана яфрагы үләннәре бик тә кызык тарихлы һәм файдалы булып чыгуы безгә, укучыларга, күңелгә күп уйланулар кертте.

Шулай ук, Галимҗан белән Сөмәя дә – гади авыл кешеләре булса да, күпме белем, ярату хисе бар аларда. Галимҗан – әсәрнең төп каһарманы, ул үз авылын ташлап китүен уйламый, белеме булса да, ул үз җирен яратып үскән егет. Галимҗан белән Сөмәя – авылның якты киләчәге.

Кадерле укучылар, шушы дәрестән тыш чара сезгә яңа уйлар, хисләр, белемнәр керткән булса, бу дәрес нәтиҗәле булды дип уйлыйм.

Игътибарыгызга рәхмәт. Киләсе очрашуларга кадәр!

Китап сезгә юлдаш булсын!

Ясәвиева Гөлфинә Минирасит кызы,
Песәй урта гомуми белем бирү мәктәбе, Менделеев районы

**Ян, учагым, ян!**
**«Тамчы - шоу» интеллектуаль уены**

**Максат:** укучыларда укуга, татар әдәбияты фәненә карата аңлы караш тәрбияләү; укучыларның сөйләм телен, дөньяны танып - белү, күзаллауларын арттыру, баету; укучыларга үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру, сәләтләрен үстерү өчен өстәмә мөмкинлекләр тудыру;

**Җиһазлау:** портретлар, компьютер, проектор, презентация. Чара презентация ярдәмендә бара.

Укытучы: Без татар халкының йөзек кашы, яраткан әдибе Аяз ага Гыйлаҗевнең туган көне уңаеннан, “Тамчы-шоу” уенын карарга җыйналдык. Кеше яши һәм аны соңгы сулышына кадәр гаделлеккә ышаныч озатып бара. Кешелек дөньясы яратылганнан бирле, күпме заманалар үзгәрде. Кешелексез шартларда калып, олы әхлакый югалтулар кичергәндә, чын кеше булу миссиясен адәм баласы үтиме? Бер-берсенең исән чагында кадерен беләме? Кайчагында гомереңнең бер саплам җеп кебек кыска калганын сизәсең... Ул шулкадәр кыска...

Гомер-мизгел,тормыш үзәненнән
Үтүләре ай-һай тиз икән.
Үтеп киткәч, сагынып сөйләр өчен,
Түмгәгенә кадәр үз икән.

Чыннан да, гомернең һәр мизгелен тоеп калырга омтылган, авыл халкының яшәү рәвешен әсәрләрендә чагылдырган бөек әдибебез иҗаты белән һәркем горурлана ала. Менә без дә бүген шушы олпат шәхесебезнең иҗат мирасын барлау максаты белән әлеге кичәгә җыйналдык. Иң элек уеныбызның барышына һәм укучыларның чыгышларына бәя бирүче жюри әгъзалары белән таныштырып китәм.

Шулай итеп, башлыйбыз!

Хәзер сүзне үзләре белән якыннанрак таныштырыр өчен мин укучыларга бирәм.

*Укучылар үзләре белән таныштыралар. Исем, девиз әйтелә.*

Шулай итеп, беренче турны башлап җибәрәбез.

***1 нче тур. “Син Аяз Гыйлаҗевның биографиясен беләсеңме? дип атала***

1. Аяз Гыйлаҗев туган урын?
2. Аяз Гыйлаҗев туган ел?
3. Язучының балачагы кайда уза?
4. Кайчан һәм ни өчен кулга алына?
5.Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе бүләге кайчан бирелә?
6. Язучы биографиясендәге “кара шәһәр”?
7. Тормыш иптәшенең исеме, һөнәре?
8. Балалары: исемнәре, һөнәрләре?
9. Аяз Гыйлаҗев эшләгән журналлар?
10. Язу манерасы?
11. Әти-әнисенең исемнәре?
12 Аяз Гыйлаҗевнең үлгән елы?

***2 нче тур "Театр сөючеләр " конкурсы.***

*Укучылар әсәрләрдән өзекләрне сәхнәләштерәләр.”Бибинур” фильмыннан өзек күрсәтелә (Катнашучылар әлеге әсәрләрнең исемен атарга тиеш)*

**3 нче тур "Аяз Гыйлаҗев әсәрләрендә кунакта"**

**Аяз Гыйлаҗев әсәрләреннән өзекләр укыла. Исемен искә төшерегез.**

1. 58 ел, нигә, Мирвәли 58 еллык гомерен дә артына борылып карамыйча үткәрә алды ич. Нигә борылып карамады икән ул. 58 тулуын да нигә менә шушы япан кырда исенә төшерде. Нигә борылып карарга курка? Кем сагалый аны? Кайдан башланды бу курку?

2. Минем әтием тумышы белән Сарман кешесе, үз-үземне белә башлаганда без Югары Баграж дигән гүзәл керәшен авылында Әндрияң дәдәйләр өендә яши идек.

3.1944 елның көзе иде.

Көзге кыр эшләре башлану белән үк бозылган һаваның рәтсезлеге бик озакка тартылды. Атна буе пыскаклап яуган яңгырлар, әрле-бирле үтеп торган атлылар безнең кечкенә генә авыл урамын чупырдаган әшәке сазлыкка әйләндерделәр.

4.- Ибраһим, әй ишеттеңме? – дип сорады.

- Саңгырау түгел лә, - дидем мин, атымның аркалыгын тикшереп.

5. Шәмсегаянны зур кадер-хөрмәт белән авыл зиратына, үзе теләгән почмакка, каен белән нарат кочаклашып үскән урынга күмделәр.

6.Зөһрәбануның үз планы бар иде, Бибинур үлә-нитә калса, арзанга гына булса да өен сатып җибәрермен дип уйлый иде.

**4 нче тур Капитаннар ярышы. "Дөрес җавап" уены**

"Әйе", "юк" дип җавап бирергә тиеш булалар.

**1 команда капитанына сораулар:**

- 58 саны “Җомга көн кич белән” әсәрендә өч тапкыр кулланыла
- Аяз Гыйлаҗевнең “Өч аршин җир” әсәренә “нәшер итмәскә” мөһере сугыла.
- “Балта кем кулында?”- хикәя
- 2 дистәдән артык драма әсәре иҗат итә
- Язучы “Мәгариф” журналында эшли
- Тормыш иптәшенең исеме – Нәкыя
- Башлангыч иҗаты мәктәп елларына туры килә
- “Җомга көн кич белән “ әсәренең төп герое – Бибинур

**2 команда капитанына сораулар:**

- “Өч аршин җир” әсәренең төп герое – Шәмсегаян
- Казахстанда 3 ел төрмәдә утыра
- Мәхәббәт өчпочмагы “Дүртәү” әсәрендә сурәтләнә
- “Дүртәү” әсәрендә Аяз ага үз язмышын сурәтли
- Аяз Гыйлаҗев 1930 нчы елда туа
- 1950 нче елда кулга алына
- Мансур – Аяз Гыйлаҗев улы
- 1994 нче елда Татарстанның халык язучысы исеме бирелә

**5 нче тур “Портретны таны” дип атала.**

5 портрет бирелә, арада А.Гыйләҗев портреты да бар.

Укучылар бирелгән портретларны танырга тиеш.

- Әйе, укучылар, Аяз аганың иҗаты бәяләп бетергесез. Илфак Ибраһимов әдипне “Әдәбиятыбызның имән баганасы “, дип атый. Шушы “имән баганабыз” һәрдаим безгә

юл күрсәтеп, яктыртып торсын. Кичәбезне Г.Афзалның Аяз ага Гыйлажевкә багышланган шигырь юллары белән тәмамлыйсым килә (Укытучының шигырь сөйләве).

- Укучылар, шуның белән безнең уеныбыз тәмам. Үзегез өчен күп кенә кызыклы мәгълүматлар алгансыздыр дип ышанып калабыз. Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт.

Гатин Рафис Исмәгыйль улы, Нуртдинова Гөлнар Салихҗан кызы,
икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Аяз Гыйләҗев иҗаты веб-биттә**
**(Интеграль дәрес эшкәрмәсе)**

**Дәреснең максатлары:**

1. **Белем бирү максаты -** Аяз Гыйләҗевнең биографиясен, иҗатын камилләштерү; аның тормышын искә төшерү, белемнәребезне тирәнәйтү.

2**. Фикер сәләтен үстерү максаты** - Укучыларның логик фикерләү сәләтен, блок системасы аша веб-биттә материал урнаштыру мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын һәм танып-белүне үстерүгә ярдәм итү.

3**. Тәрбияви максат** – Туган җир һәм аның геройлары белән горурлану. Якташ язучыбыз - Аяз Гыйләҗевкә һәм аның иҗатына карата хөрмәт хисе уяту.

**Җиһазлау:** компьютер, проектор, экран, әдәбият дәреслеге

**Дәрес барышы**

1. **Оештыру моменты.**

Укучыларда уңай психологик халәт булдыру. Исәнләшү.

**Татар теле укытучысы**. Бүген без сезнең белән XX гасыр әдәбиятына сәяхәт ясарбыз. Нинди истәлекле вакыйгалар булганлыгын искә төшерербез. Шул вакытның үзенә хас үзенчәлеген күрербез. Моңа Аяз Гыйләҗевнең биографик фактлары булышыр. **(**Аяз Гыйләҗевкә багышланган интернет материаллар белән танышу)

**Һәр укучы бер кызыклы вакыйганы укый**

**1 нче укучы.** Аяз Гыйләҗевне хатыны Нәкыя белән кардәшлек җепләре бәйли. Аның әнисенең энесенең хатыны – Нәкыянең апасы. Апасына бала карарга булышкан, аш-суга оста, чибәр, зифа буйлы Нәкыяне егет кечкенәдән күреп, күзәтеп үсә.

**2 нче укучы** Аяз белән Нәкыяның яшь аермасы - 9 ел. Алар 1957 елның мартында өч көн гөрләтеп туй итәләр. Туйга акчаны язучының коллегасы Галимҗан Сәгыйдуллин биреп тора. Табынга кәләш күп итеп койка кайната, туй күлмәген дә үзе тегеп кия.

**3 нче укучы.** Аяз Гыйләҗев хатынына гел: “Минем улларым музыканы үзләштерергә һәм чит телләрдә сөйләшергә тиеш», - дия торган булган. Музыка дәресләрен балалар теләп үзләштермәсәләр дә, немец телен тырышып өйрәнгәннәр. “Хезмәт хакым немец теленнән репетитор яллауга китеп бара иде”, - дип искә ала Нәкыя ханым. Аяз Гыйләҗев үзе немец телен тоткынлыкта өйрәнгән.

**4 нче укучы** Иреккә чыккач та озак еллар Аяз Гыйләҗевкә кимсетүле карашларны тоярга туры килгән. Язмаларын беркайда бастырмаганнар. Чарасызлыктан язучының кайбер хикәяләре хатыны Нәкыя Гыймадиева исеме белән дөнья күргән.

**5 нче укучы.** Нәкыя ханым Аяз Гыйләҗевнең төрмәдән язган хатларына “бисмилла” әйтеп кенә кагыла. Әлеге кадерле истәлекләрне үзе исән чагында музейга, архивка да тапшырырга җыенмый. “Бу Аязымнан аерылу кебек булыр иде”, - ди.

**6 нчы укучы.** Аяз Гыйләҗевнең язу өстәле беркайчан да булмаган. Ул һәрчак, шкафның күтәртелмәле ишеген төшереп, аны өстәл урынына кулланган. Ишек сыгылмасын өчен астан башына чүпрәк бәйләнгән таяк терәтә торган булган.

**7 нче укучы.** Гыйләҗевлар гаиләсендә иң кыйммәтле бүләк булып китап бастыру машинкасы саналган. Язучы әсәрләрен берсен дә диярлек кулдан язмаган, машинкада бастыра торган булган. Улларының да һәрберсенә: Мансур, Искәндәр, Рашатка 16 яшь тулгач, машинка бүләк иткәннәр.

**8 нче укучы** Нәкыя Гыйләҗеваның шкафында бүген дә ире 1960 елда Мәскәүдән алып кайткан француз хушбуе саклана. Дөрес, хәзер флаконы гына калган, шулай да исе әле дә килә. "Бу хушбуйның бәясен белгәч, исләрем китте. Ул бәягә бер машина алырга була иде ул чакта", - дип искә ала Нәкыя Гыйләҗева.

**9 нчы укучы** Аяз Гыйләҗев балыкка йөрергә, су коенырга яраткан. Хатынына исән чагында гел: "Әбисе, син ничек шулай тәмле пешерәсең икән соң?" - дигән. Ә иң яратып ашый торган ризыгы - Нәкыя апа үзе әзерләгән эремчек булган.

**Татар теле укытучысы.** Укучылар, ә хәзер җылынып алыйк әле. Мин сезгә сораулар бирәм, ә сез сорауга җавапны "әйе" дип санасагыз басасыз, "юк" дип санасагыз утырасыз.

Аяз Гыйләҗев 1928 нче елда туган. – әйе

Аяз Гыйләҗев Арча районы Кушлавыч авылында туа. – юк

Аяз Гыйләҗев Сарман районы Чукмарлы авылында туа . – әйе

Аяз Гыйләҗев Франциядә яши. – юк

Аяз Гыйләҗев Зәй районының Югары Баграж исемле керәшен татарлары авылында яши. – әйе

Аяз Гыйләҗев гражданнар сугышында катнаша. – юк

1948 елда Казанга килеп, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. – әйе

Аяз Гыйләҗев сугышта катнашамы? – юк

**Информатика укытучысы.** Ученики. Давайте сейчас откроем на рабочем столе папку Аяз Гилязев. В ней найдите и откройте файл "Аяз Гилязев" и выполним практическую работу "Блочная верстка".

В этой работе вы освоите трёхколоночную верстку.

- Откройте на рабочем столе компьютера папку **Gilazev.** Откройте файл **gilazev.htm** в текстовом редакторе. Ваша задача – оформить веб-страницу так, как показано на образце (см. в конце страницы). Для этого нужно использовать рисунки из подкаталога **images** и стилевой файл.

Добавьте заголовок страницы (**TITLE**), укажите название: **Аяз Гыйләҗев биографиясе.**

Создайте стилевой файл **gilazev.css** и подключите его к веб-странице. Установите для всех элементов страницы (они обозначаются знаком *****) нулевые внутренние и внешние отступы: *** { margin:0px; padding:0px; }**

Добавьте в блок с идентификатором **header** заголовок документа «**Аяз Гыйләҗев**». В стилевом файле установите для этого блока высоту 80 пикселей и фоновый рисунок **header.jpg** из каталога **images** (без повторения). Добавьте для заголовка отступы слева и сверху (как на образце).

Добавьте в блок **photoleft** четыре фотографии с именами **gilazev1.jpg**, **gilazev2.jpg**, **gilazev3.jpg**, **gilazev4.jpg** из подкаталога **images**.

Добавьте в блок **photoright** семь фотографий с именами **gilazev5.jpg**, **gilazev6.jpg**, **gilazev7.jpg**, **gilazev8.jpg, gilazev9.jpg, gilazev10.jpg, gilazev11.jpg** из подкаталога **images**.

Добавьте в блок **content** текст, записанный в файле **textgilazev.docx**. Оформите абзацы с помощью тэга **p**. В стилевом файле для тэгов **p** установите отступы со всех сторон 5 пикселей и абзацный отступ (красную строку) 20 пикселей.

Добавьте в конец текста абзац со словами *Источник материала:Татар әдәбияты онлайн*.

Выровняйте абзац по правой границе и выделите этот текст с помощью тэга **em**.

Слово «Татар әдәбияты онлайн» должно быть ссылкой на страницу посвящённую Аязу Гилязову.

Добавьте в блок footer текст, содержащий вашу фамилию, имя, например, *Работу выполнил: Иванов П.И.*

Посмотрите, как выглядит страница в браузере. Теперь остается с помощью стилей оформить блоки так, чтобы они заняли правильное место на странице.

В стилевом файле для блока **photoleft** установите ширину 160 пикселей, отступ слева 10 пикселей и обтекание слева (**float:left;**). Посмотрите, как теперь выглядит страница.

В стилевом файле для блока **photoright** установите ширину 220 пикселей, отступ слева 10 пикселей и обтекание справа (**float:right;**). Посмотрите, как теперь выглядит страница.

Теперь сделаем так, чтобы центральная колонка (блок **content**) не залезала на левую и правую. В стилевом файле для блока **content** установите отступ слева 150 пикселей и отступ справа 220 пикселей. Посмотрите, как теперь выглядит страница.

Остается оформить нижний блок («подвал»). В стилевом файле установите для блока **footer** цвет фона **#CCCCCC**, внутренние отступы – сверху 5 пикселей, снизу – 10 пикселей, выравнивание текста по центру. Для того, чтобы этот блок не обтекался другими ни слева, ни справа, добавьте свойство **clear:both;**

Посмотрите на окончательный результат в браузере. (Кушымта №1 )

**Татар теле укытучысы**. Укучылар, ә хәзер без сезнең белән Аяз Гыйләҗевнең иҗат үзенчәлекләрен карап үтәрбез. Аның иҗатында нинди темалар яктыртыла икән?

Аяз Гыйләҗев – прозаик

| | |
|---|---|
| 1 | А.Гыйләҗев әсәрләрендә туган як, туган җир тематикасы. (“Өч аршин җир” ) |
| 2 | А.Гыйләҗев иҗатында шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәте. (“Яра”) |
| 3 | А.Гыйләҗев әсәрләрендә сәяси-иҗтимагый проблемалар. (“Йәгез, бер дога!”, “Балта кем кулында?”) |
| 4 | А.Гыйләҗевнең төрле тематика яктыртылган әсәрләре. (“Урманнар артында яшел болын”, “Дүртәү”, “Татарстан могҗизасы”, “Язгы кәрваннар”) |

А.Гыйләҗевнең иҗат эшчәнлегендә драматургия жанры да зур урын били. Ул кырыктан артык исемдә күп актлы комедия, трагедия һәм драмалар яза. Аларның күпчелеге Казанның Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры сәхнәләрендә, Татарстанның Әлмәт, Минзәлә, Чаллы шәһәрләрендәге театрларда куела, кайберләре, башка телләргә тәрҗемә ителеп, үз вакытында башкорт, чуаш милли театрлары, рус театры сәхнәләрендә дә уңыш белән бара. Прозасы кебек, әдипнең сәхнә әсәрләре дә югары гуманизм идеяләре, кеше шәхесен олылау хисләре белән сугарылган, алар психологик кичерешләргә бай булган үзенчәлекле

образлары, милли характерлары һәм татар драматургиясендә моңарчы күзәтелмәгән форма төрләре белән аерылып торалар. Язучының драматик әсәрләре «Пьесалар» (1969), «Җиз кыңгырау» (1975), «Кар астында кайнар чишмә» (1979), «Әгәр бик сагынсаң» (1984), «Дус кызым кияүгә чыга» (1988) исемле җыентыкларында урын ала

**Белем һәм күнекмәләрне ныгыту. 3-2-1**

Тактага өч сорау языла, укучылар битләргә җавабын язалар.

**3 – Исемдә калдырган әһәмиятле моментлар...**

**2** – Аяз Гыйләҗев – публицист – **дәлилләгез...**

**3** – Аяз Гыйләҗев **иҗаты турында соравым туды...**

**Йомгаклау. Өй эше.**

Драма әсәрләренә күзәтү. Проза әсәрләренә күзәтү.Ике теманың берсенә блочная верстка ясарга.

Укытучы. Балалар үзегезгә ошаган темаларны сайлагыз.

**Билгеләр кую. Саубуллашу.**

**Кушымта**

1.Окончательный результат в браузере:



**Аяз Гыйләҗев**

Татарстанның халык язучысы, романчы, хикәяче, драматург, публицист Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында хәзерге Татарстан Республикасының Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туа. Бала чагы һәм мәктәп еллары күршемдәге Зәй районының Югары Баграҗ исемле керәшен татарлары авылында уза. Шул авыл мәктәбенең тугыз сыйныфын һәм Сарман урта мәктәбендә унынчыны тәмамлаганнан соң (1945), берникадәр вакыт колхозда эшли, аннары ике елга якын комсомолның Зәй район комитетында бүлек мөдире хезмәтендә була.

1948 елда Казанга килеп, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Монда ул, уку программасындагы фәннәрне яхшы үзләштерү белән бергә, беренче курстан ук бик мавыгып университет каршындагы әдәби түгәрәккә йөри, анда үзенең язган беренче иҗат тәҗрибәләре белән уртаклаша, фикер алышуларга, диспут-бәхәсләргә актив катнаша. Ләкин сугыштан соңгы бу еллар - тоталитар совет режимының идарәдә янәдән бик нык репрессив ысуллар куллана башлаган чоры. Репрессияләр шаукымы иҗади студент яшьләрне дә читләтеп үтми: 1950 ел башында Казан югары уку йортларында укучы бер төркем татар студентларын, шул җөмләдән А.Гыйләҗевне, «советка каршы коткы таратуда һәм милләтчелектә гаепләп», кулга алалар. 1950 елның декабрендә совет мәхкәмәсенең ябык утырышы А.Гыйләҗевне җиде елга ирегеннән мәхрүм итеп, хезмәт колониясенә җибәрергә дигән хөкем карары чыгара. Югары белем алып, язучы булырга хыялланган егерме ике яшьлек егет әнә шулай Казакъстандагы совет концлагерьларында биш елга якын җәфа чигәргә мәҗбүр була.

Фәкать Сталин вафатыннан соң гына аны ирекkә чыгаралар һәм Казан университетында өзелгән укуын дәвам итәргә мөмкинлек бирәләр. Университетны тәмамлагач, А.Гыйләҗев берничә ел (1957-1961) көндәлек матбугат редакцияләрендә эшли, аннары, Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы икееллык Югары әдәби курсларда укып кайтканнан соң, 1963 елдан башлап бөтенләе белән профессионал-язучылык хезмәтенә күчә. А.Гыйләҗевнең иҗаты күпкырлы һәм мул уңдырышлы.

Беренче проза һәм сәхнә әсәрләреннән үк сиземләнгән язу манерасы: кырыс реализм, халыкчан бизәкләргә бай җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары, кайсы чор турында һәм нинди темага язса да, кеше шәхесенең катлаулы рухи дөньясын, эш-гамәлләрен егерменче гасырның гуманистик идея-эстетик карашлары югарылыгыннан торып анализларга, аларны чынбарлыктагы, милли, тарихи-иҗтимагый тормыш барышындагы катлаулы һәм каршылыклы мәсьәләләр, әхлакый проблемалар белән тыгыз бәйләнештә гәүдәләндерергә омтылу һәм, ниһаять, әдәби осталык, форма өлкәсендәге өзлексез эзләнү, камилләшү -менә бу сыйфатлар әдипнең язучы-сәнгатьче буларак бөтен иҗат эшчәнлегенең реалистик асылын, идея-эстетик юнәлешен билгелиләр.

Ул үзен бигрәк тә озын хикәя-повесть остасы итеп таныта. «Дүртәү» (1961), «Өч аршын җир» (1962), «Зәй энҗеләре» (1963), «Берәү» (язылуы 1960 еллар башы, басылуы - 1966), «Урталыкта» (1969), «Язгы кәрваннар» (1972), «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» (1973), «Мең чакрым юл» (1977-1978), «Җомга көн, кич белән...» (1979), «Әтәч менгән читәнгә» (1979-1980), үзгәртеп кору елларында язылган «Балта кем кулында?», «Яра» повестьлары - шуның матур мисаллары.

*Источник материала: Татар әдәбияте онлайн.*

Работу выполнил: Иванов П.И.

Ихсанова Лилия Фаизовна, Евстафьева Людмила Фёдоровна,
«Джалильская СОШ №2», Сармановский район

**Бинарный урок по математике и татарской литературы в 5 классе**

**Тема:** Жизнь и творчество писателя-земляка Аяза Гилязова.

**Тип урока**: Урок систематизации и обобщения знаний и умений.

**Цели урока**:

1. Расширение понятийной базы (предметной и метапредметной)

- ***предметные:*** выполнять вычисления с натуральными числами; уметь находить произведение натуральных чисел; знать и уметь применять распределительный закон умножения для вычисления значений числовых выражений; записывать его с помощью букв.

- ***метапредметные***: познавательные УУД: умение выбирать наиболее эффективные способы решения поставленных задач, сравнивать и анализировать информацию, делать выводы на основе полученной информации; развитие навыков самостоятельной исследовательской деятельности;

регулятивные УУД: умение организовать выполнение заданий согласно инструкциям учителя, анализировать результаты своей работы на уроке, умение контроля и оценки процесса и результатов деятельности;

коммуникативные УУД: умение слушать и вступать в диалог, участвовать в коллективном обсуждении проблем, высказывать и аргументировать свою точку зрения, умение отвечать на вопросы, обсуждать вопросы со сверстниками; развитие навыка работы в группах;

- ***личностные:*** личностные УУД: потребность в справедливом оценивании своей работы и работы одноклассников, применение полученных знаний в практической деятельности. Развитие находчивости, активности при решении математических задач, способности к эмоциональному восприятию математических объектов, задач, решений, рассуждений, привитие любви к творчеству АязаГилязова, развитие патриотических чувств

**Межпредметные связи:** Татарская литература. Татарский язык. Математика.

Формы работы учащихся: фронтальная, групповая, индивидуальная.

Оборудование: раздаточный материал, конверты с заданиями, проектор, ноутбук, плакат, фотографии, смайлики.

Ход урока

| Этап урока | Деятельность учителя | Деятельность ученика |
|---|---|---|
| I.Мотивация к учебной деятельности.<br>Цель этапа: Включение учащихся в учебную деятельность на личностно-значимом уровне. | Учитель М: Добрый день, ребята. Сегодня у нас необычный урок. Урок математики и татарской литературы, а проведем его мы.<br>Учитель Т: - Исәнмесез, укучылар, дәресебезне башлыйбыз<br>Аяклар янәшә,<br>Куллар өстәлдә,<br>Дәреснең башы,<br>Кәефләр яхшы!<br>Учитель М: Работать сегодня мы будем в группах. И чтобы работа прошла успешно, мы должны выполнять правила. Они лежат у вас на столах. | Дәрескә әзерлекне барлыйлар.<br><br>Зачитывают вслух правила работы в группах. |
| II. Постановка цели и задач урока. Мотивация | Учитель М: Работа с конвертом №1. Составление анаграммы<br>"ПРОЩЕНИЕ У ЖЫВАРЕНИЙ" - "упрощение выражений" | Составить анаграмму. Записать в тетрадь число и тему урока. |

| | | |
|---|---|---|
| учебной деятельности учащихся. | <u>Записываем в тетрадь число, классная работа, тему урока.</u><br>- Это новая тема? Что мы с вами сегодня будем делать?<br>- Какие цели ты поставишь себе на урок? Что для себя определяешь? | Определить для себя цели и задачи урока. |
| III. Актуализация знаний. | Работа с конвертом №2. Какие свойства нам помогают упрощать выражения.<br>У каждой группы в конверте дано одно из свойств, вы должны:<br>- определить это свойство;<br>- правильно составить его;<br>-выйти к доске и показать.<br>1) a*(b+c)=a*b+a*c; 2) a*(b-c)=a*b-a*c;<br>3) a*(b*c)=(a*b)*c; 4)a+(b+c)=(a+b)+c; | Определяют свойство, выходят к доске с карточками и встают в ряд так, чтобы на карточках по порядку было записано свойство. |
| IV. Обобщение и систематизация знаний. | Учитель М: Работа с конвертом №3: Работа с учебником №566.<br>Упростите и вычислите: 38a+62a, если a=238 и т.д.<br>**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**<br>Даны варианты ответов – собираем слово.<br>Учитель Т: — Укучылар, ә кем соң ул Аяз Гыйләҗев? (язучы)<br>- Аның турында беләбезме?<br>Әйдәгез, аның тормыш юлы буенча әйләнеп кайтык әле.(видеофильм карау) | Упростить выражения и вычислить при заданной переменной. Выбрать верные ответы и собрать слово.<br>23800-АЯЗ, 48900-ГЫЙ, 9600-ЛӘ, 103400-ҖЕВ. |
| V. Применение знаний и умений в новой ситуации. | 1. Упростить выражение 78x+12x и вычислить, если x=1.<br>Ответ: 90.<br>Учитель Т: -Укучылар, ә 90 саны Аяз Гыйләҗев белән ничек бәйләнгән икән?(аңа быел 90 яшь тулган булыр иде)<br>- Язучы булып формалашканчы нинди юллар үткән Аяз ага?<br>(1 укучы тоткынлыкта үткән еллары турында сөйли)<br><u>Укучы</u>: Аяз Гыйләҗев Сарманда укуын тәмамлагач, Казан дәүләт университетына укырга керә, ләкин озакламый «халык дошманы» дип гаепләнеп кулга алына. Биш ел дәвамында Казакъстанда тоткынлыктабула. Бары тик 1955 нче елда гына кайтып, университетны тәмамлый.<br>2.Решить уравнение 65y+15y=320.<br>Ответ: y= 4.<br>Учитель Т: Дөрес җавап - Югары Баграж. Чыннан да, Аяз Гыйләҗев Сарман районы Чукмарлы авылында туса да, балачагы Югары Баграж авылында үткән.<br>Аның әдәби эшчәнлеге турында да тыңлап китик әле.<br><u>Укучы:</u>Аяз Гыйләҗев «Чаян», «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә»), «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналларында эшли. 1961 — 1963 нче елларда Мәскәүдә югары әдәби курсларда укып кайтканнан соң, ул иҗат эше белән генә шөгыльләнә. | Упростить выражение и вычислить.<br>Сорауларга җавап бирәләр, Аяз Гыйләҗев турында классташларының сүзләрен тыңлыйлар<br><br>Аяз Гыйләҗев тормышыннан кирәкле даталарны аерып әйтәләр, эшчәнлегенә күзәтү ясыйлар.<br><br>Решить уравнение.<br>Выбрать верный ответ. На доске висят плакаты с данными ответами, перевернув получаем фотографии деревень и сел. y=4 (Югары Баграж), y=40 (Чукмарлы), y=6 (Сарман). |
| Физ минутка. | Выполнить физ упражнения | |
| VI.Структура урока контроля знаний и умений. | Учитель Т: Работа с конвертом №6. Портрет Аяза Гилязова<br>-Укучылар, конвертта нәрсә бар әле анда? (А. Гыйләҗев портреты) Без аның тормыш юлы, тоткынлыкта үткәргән еллары, әдәби эшчәнлеген карап чыктык. Ул нинди кеше булды икән? Сез аны ничек күз алдына китерәсез? Әйдәгез, сыйфатлар гына кулланып аны тасвирлап карыйк әле.(Акыллы, көләч, укымышлы һ.б)<br>Самостоятельная работа. Работа с конвертом №7.Решить уравнения: 17x-4x=65;x+x=3856; 3x+x=8008; 2x-x=3896.<br>Блиц-сорау: (на экране)<br>1)Прозаик һәм драматург Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев ничәнче елда туган? (<u>1928 елда)</u><br>2)Ул ничәнче елда Казан дәүләт университетынаукырга керә? (<u>1948</u> елдан ул – Казан дәүләт университеты | Сыйфатлар кулланып, язучының сүзле портретын ясыйлар.<br><br>Мөстәкыйль эшлиләр, сорауларга җавап эзлиләр Самостоятельно решить уравнения. |

<table>
<tr>
<td></td>
<td>студенты)<br>3) Казахстанда тоткынлыкта ничә ел була?(5 ел)<br>4) Аяз Гыйләҗев кайчан вафат булган?(Аяз Гыйләҗев 2002 елның 13 мартында вафат була)<br>Самопроверка, ответы:
<table>
<tr><td>Корень уравнения</td><td>5</td><td>1928</td><td>2002</td><td>1948</td></tr>
<tr><td>Номер вопроса</td><td>3</td><td>1</td><td>4</td><td>2</td></tr>
</table>
</td>
<td>Выбрать вопрос, ответом которого является корень уравнения и записать в таблицу.
<table>
<tr><td>Корень уравнения</td></tr>
<tr><td>Номер вопроса</td></tr>
</table>
Выполнить самопроверку и сдать.</td>
</tr>
<tr>
<td>VII. Рефлексия</td>
<td>Учитель М: Работа с конвертом №8. Домашнее задание:1)Решить №569,570. 2)Составить задачи, используя даты жизни А. Гилязева. 3) Аяз Гыйләҗев тормышы һәм иҗаты турында кечкенә күләмле сочинение язарга.<br>Учитель Т: Работа с конвертом №9.<br>Давайте вспомним цели и задачи, которые вы поставили для себя в начале урока.<br>Определите для себя, справились ли вы со своей задачей.<br>Если "ДА" – берем желтый смайлик<br>Если "НЕТ" – синий.<br>Учитель Т:Шуның белән дәресебез тәмам, сау булыгыз!</td>
<td>Записать домашнее задание, обсудить, если есть вопросы.<br>Выбрать соответствующий смайлик и вывесить на плакат.</td>
</tr>
</table>

Исмәгыйлева Минзирә Рәсим кызы, Садыйкова Гөлсинә Солтан кызы,
Казан шәһәре, Киров районының татар телендә белем бирүче өченче гимназиясе

## Татар әдәбиятының алтын баганасы-Аяз Гыйләҗев
## Сыйныф сәгате эшкәртмәсе

**Максат:** Аяз Гыйләҗев иҗаты белән таныштыру. Күренекле шәхесләр белән горурлану, аларны ихтирам итү хисе тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Аяз Гыйләҗевнең китапларыннан күргәзмә, тест үткәрү өчен карточкалар

**Класс сәгатен үткәрү планы:**

1. Кереш әңгәмә.
2. Аяз Гыйләҗев иҗаты белән таныштыру.
3. Тест чишү.
4. Йомгаклау.

### Сыйныф сәгатенең барышы:

**1. Кереш әңгәмә.**

Без халыкның тирән хөрмәтенә ия булган язучыбыз Аяз Гыйләҗевка класс сәгатен багышлыйбыз. Исән булса, бүген күренекле татар язучысы Аяз ага Гыйләҗевка 90 яшь тулган булыр иде. Ул милләтебез горурлыгы! Татар халкы язучысы, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты А. Гыйләҗев – татар әдәбиятының күренекле бер шәхесе. Ул – татар милләтенең талантлы, көчле рухлы икәнлеген бөтен дөньяга раслаучыларның берсе. Аның иҗаты тематикасы, проблема үткенлеге,идея-эстетик үзенчәлеге белән хәзерге татар әдәбиятында аерым урын алып тора .Аяз Гыйләҗев – әдәбиятыбызның төрле тармакларында ут уйнаткан кеше. Ул күренекле прозаик, үзенчәлекле драматург, үткен каләмле публицист һәм очеркист, ниһаять, "усал телле тәнкыйтьче".

***2. Аяз Гыйләҗев иҗаты белән таныштыру.***

Алып баручы: Прозаик һәм драматург Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. Авыл

мәктәбенең тугызынчы сыйныфын тәмамлагач, унынчы сыйныфны Сарман урта мәктәбендә укый.

1948 – 1950 елларда ул – Казан дәүләт университеты студенты. Аңа да шәхес культының газапларын татырга туры килә. 1950 елның мартыннан башлап 1955 елның августына кадәр Казахстанда тоткынлыкта була. Казанга кайткач, университетта укуын дәвам итә.

1957 елның мартыннан 1961 елның августына кадәр А.Гыйләҗев матбугат эшендә: "Чаян"һәм "Азат хатын" (хәзер "Сөембикә") журналлары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, "Совет әдәбияты" ("Казан утлары") журналында проза бүлеге мөхәррире вазифаларын үти.

1961-1963 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укып кайтканнан бирле Аяз Гыйләҗев, язучы-профессионал сыйфатында, әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә.

Алып баручы: Аяз Гыйләҗевнең башлангыч иҗат тәҗрибәләре студентлык чорына карый. Ләкин аның актив иҗат эшчәнлеге 1956 елдан башлана дияргә була.

Беренче әсәрләрендә үк анык сиземләнгән язу манерасы – кырыс реализм, халыкчан образларга бай җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары, кайсы чор турында һәм нинди темага язса да, кеше шәхесенең катлаулы рухи дөньясын, эш-гамәлләрен анализлау – А.Гыйләҗев иҗат эшчәнлегенең төп асылын, идея-эстетик юнәлешен тәшкил иткән сыйфатлар.

"Өч аршин җир", "Зәй энҗеләре", "Урталыкта", "Язгы кәрваннар", "Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят", "Җомга көн кич белән", "Әтәч менгән читәнгә" әсәрләре белән Аяз Гыйләҗев үзен повестьлар остасы итеп танытты.

Тематик яктан А.Гыйләҗевның күпчелек повестьлары авыл тормышына багышланган. Аларда кичәге һәм бүгегенге авыл, аның гади кешеләре гәүдәләндерелә. Аяз Гыйләҗев – ике дистәдән артык драма әсәре авторы да. Аларның күбесе республика театрлары репертуарына кертелгән.

Соңгы елларда А.Гыйләҗев роман жанрында иҗат итүгә күп көч куйды. Аның бер-бер артлы "Балта кем кулында" (роман), "Йөгез, бер дога!" (роман-хатирә) кебек зур күләмле әсәрләре дөнья күрде. Аяз Гыйләҗев 2002 елның 13 мартында Казанда вафат була һәм шәһәрнең Яңа бистә зиратына җирләнә.

Алып баручы: "Җомга көн кич белән" һәм "Әтәч менгән читәнгә" повестьлары өчен А.Гыйләҗев 1983 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Әдәбиятны һәм театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен аңа 1978 елда Татарстанның, ә 1985 елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә. Ул – М.Горький исемендәге премия лауреаты да.

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен 1993 елда, Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Аяз Гыйләҗевкә Татарстан Республикасының халык язучысы дигән мактаулы исем бирелде.

***3. Тест чишү.***

*1. Аяз Гыйләҗевнең әтисенең исемен күрсәтегез?*

а) Мияссәр ә) Мирсәет б) Миңлегали

*2. Язучының мәктәп еллары кайда уза?*

а) Зәй районында Югары Баграж авылында

ә) Балык Бистәсе районында Котлы Бөкәш авылында

б) Минзәлә районында Бикбау авылында

*3. А.Гыйләҗев 10 нчы сыйныфны кайда тәмамлый?*

а) Сарман районы Сарман урта мәктәбендә ә) Актаныш районы Актаныш урта мәктәбендә б) Арча районы Арча урта мәктәбендә

*4. Ул кайчан КДУга укырга керә?*

а) 1946 нчы елда ә) 1948 нче елда б) 1945 нче елда

*5. А.Гыйләҗев ничәнче елда кулга алына?*

а) 1949 нчы елда ә) 1950 нче елда б) 1951 нче елда

*6. А.Гыйләҗевкә Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе кайчан бирелә?*

а) 1983 нче елда ә) 1987 нче елда б) 1981 нче елда

*7. А.Гыйләҗевкә ничәнче елда халык язучысы исеме бирелә.*

а) 1991нче елда ә) 1994 нче елда б) 1993нче елда

*8. 1979 нчы елда кайсы әсәре басылып чыга.*

а) "Җомга көн кич белән..." ә) "Өтәч менгән читәнгә" б) "Язгы кәрваннар"

***4. Йомгаклау.***

Аяз Гыйләҗев – гомере буе профессионал язучы буларак иҗат иткән шәхес. Үз каләм көченә ышанып гаилә тоту да, бәлки, аңа җиңел булмагандыр. Ничек кенә булмасын: ул күпләргә үрнәк булырлык төпле гаилә башлыгы, проза жанрында да, драматургия өлкәсендә дә оста художник, тирән фикер иясе була.

Язучының әсәрләренең тәрбияви кыйммәте әйтеп бетергесез зур. Алар–безнең милләтебезнең рухи байлыгы, милли үзенчәлекләре турында чорыбыз вакыйгаларына бәйләп язылган әдәби әсәрләр.

Аяз Гыйләҗев минем өчен гыйбрәтле язмышы белән дә, олы иҗаты белән дә буй җитмәслек илаһи шәхес. Аның әсәрләре – совет хакимияте чорының сәнгатьчә тарихы, аның ни өчен җимерелеп төшүенең сәбәпләрен тирән итеп аңларга ярдәм итә торган әдәби елъязма. Килер буыннар бу әсәрләргә еш мөрәҗәгать итәрләр әле. Чөнки аларның кыйммәте бүгенге көн белән генә чикләнми. Аяз Гыйләҗев чәчкән таза орлыкларның безгә һәм бездән соң киләчәк яңа буыннар күңелендә бәрәкәтле үсентеләр бирәсенә минем ышанычым зур.

Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевның мирасын яратып һәм хөрмәт итеп яшәсәк, рухи офыкларыбыз киңәер.

Валеева Ләйсан Мидхәт кызы, Түбән Каманың 9 нчы санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе

## А. Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» әсәрендә пейзажның бирелеше (балаларга экологик тәрбия бирү өчен куллану материалы)

Пейзаж (французча "урын", "ил" мәгънәсендә) – әдәби әсәрләрдә сурәтләнгән табигать, авыл күренешләре. Пейзажда язучының һәм аның геройларының табигатькә мөнәсәбәте, туган илгә мәхәббәте, аның матурлыгына соклануы, теге яки бу ил, өлкә урынга хас яклары ачыла. Татар әдәбиятында пейзажны сурәтләү борынгыдан килә. Мәсәлән: Кол Галинең "Кыйссан Йосыф" әсәрендә Йосыф колыкка сатылып, иленнән аерылыр алдыннан анасы кабере өстендә ятып елаганда, күкне кара болыт каплый, кар катыш яңгыр ява башлый. Бу очракта табигать күренешләре белән кеше кичерешләре тәңгәл китерелгән.

Димәк, матур әдәбиятта пейзаж вакыйгаларны һәм анда катнашучы геройларны ачу өчен кулланыла. Ул геройларның кичерешләренә, эчке дөньясына каршы килергә, яисә янәшә булырга мөмкин. Шул юл белән язучы әсәрдә катнашучыларның эчке сыйфатларын, ничек уйлауларын ачып бирә.

Татар әдәбиятында пейзажны оста сурәтләүче язучыларыбыз Г. Ибраһимов, М. Әмир, Ә. Еники. Аяз Гыйләҗевне дә шушы пейзаж осталары белән бер баскычка куяр идем. Әйткәнебезчә, ул да үз әсәрләрендә табигать күрененешләрен бик оста файдалана. Каян килә соң безнең Аяз агага мондый осталык һәм тапкырлык. Нинди туфрак, нинди як мондый талантны алып килгән?!

А. Гыйләҗев җырлы-моңлы, сихри Сарман ягында туса да, язмыш аны үзенең табигате, кешеләре үзенчәлекле, ярдәмчел, сабыр булган Зәй якларына алып килгән. А. Гыйләҗевләр гаиләләре белән Зәй районының Югары Баграж авылына күченеп, шунда яши башлыйлар. Бу вакытта Аяз агага ике яшьләр чамасы гына булса кирәк. Шушы Баграж авылы аның күңелен сабый чактан ук сихерли күрәсең.

Нинди генә агачның да күләгәсе булган кебек һәр авылның да үз тарихы бар. Халык арасында Югары Багражны гадиләштереп – Югары авыл дип йөртәләр.

Югары Баграж авылы табигатьнең иң матур сихри бер почмагына урнашкан. Ул замана сулышын тоеп яши. Авылны өч яктан гаскәр кебек агачлар урап, саклап тора. Урманы да аның бик бай. Моның шулай булуын

А. Гыйләҗев та үзенең “Балачак сукмаклары” дигән язмасында матур итеп әйтеп бирә. Болай дип яза ул: “Метери елгасы аръягында искиткеч матур, аллы-гөлле чәчәкләр капланган бәләкәй генә болын бар иде. Иртә яздан кара көзгәчә чәчәкләр бер-бер артлы ачылалар да җәйнең һәр аенда чәчәк исе була торган иде. Беркем кисәтмәсә дә, болынга аяк баскан кеше кинәт үзгәрә, чәчәкләрне өзмәскә, үләннәрне таптамаска тырыша. Кай яктан җилләр иссә дә, алар тыгыз һавалы бу үзәнгә төшеп җитә алмыйлар, көн туса без шул оҗмахта күбәләк җыябыз, качышлы уйныйбыз. Еш кына болынга эштән бушаганда эти дә төшә, безне түгәрәкләп тирә-ягына утырта, үләннәрнең исемен атап, берәм-берәм күрсәтә башлый. “Безнең якларда ашарга яраклы йөзләп үлән бар”, - дия иде.Ниләр генә җыеп ашамый идек без Баграж болын-урманнарыннан, җиләк-җимешне, гөмбәләрне әйтеп тә тормыйм, язга чыгып кар китүгә, кояшка караган ермак ярларына сап-сары булып бакыр тәңкәләр сибелә. Аланнарда кузгалак үсә, кыр какысы, урман какысы котырып уңа... Төрле якларга җир бәрәңгесе, карабаш, балтырган җыярга йөрибез”, дип соклануын яшерми әдип.

Бу авыл кечкенә генә Баграж инешенә сыенган. Инеш аркылы матур итеп күпер салып куйганнар. Күперне чыгып бераз баргач, биек-биек “таулар” калкып тора. Тауларның хәтта исемнәре дә бар. Мәсәлән, “Дуңгыз сырты”, “Сарык тавы”. Тирән булмаса да елгалары да бар: “Метери елгасы”, “Чүке елгасы”, “Чуал елгасы”; чокырлары да бар: “Тирән чокыр”, “Олы су башы”. Чишмәләргә дә бай авыл ул- Югары Баграж. “Чүке” чишмәсе, “Такта чишмә”, “Аракы” чишмәсе, “Кәҗә башы” чишмәсе. Бу чишмәләрнең күплеге авыл кешеләренең ярдәмчел, кунакчыл керәшен кешеләре, аларның тапкыр сүзле, зирәк кешеләр булуын күрсәтә кебек.

Керәшен кешеләре арасында үзенең балачагын уздырган А. Гыйләҗевнең тормышында бу истәлекләр бер мизгел генә кебек. Ләкин А. Гыйләҗев бик күп әсәрләрендә туган ягының табигатен, аның кешеләрен үтә дә матур, гади итеп сурәтләп биргән.

“Язгы кәрваннар”да җитди, моңсу лирик стиль өстенлек итә. Лирик штрихлар бик чамасын белеп кенә кулланыла, нәкъ әнә шул эчке күңел җылылыгы белән сурәтләнгән лирик хисси күренешләр әсәрнең лирик фонын билгели. Язгы авыл пейзажы ерактан ишетелгән моңлы җыр, герой уйларының салмак, эзлекле чагылышы. Әсәрдә бу турыда менә мондый юллар белән әйтелеп бирелгән: “Көндез алдаучан җылы булып торса да, төш авышуга мә сиңа, зират тавыннан өзлексез җил исә башлады. Зират тавыннан, кояш баешыннан искән җил, гадәттә, үзәнлектә ышыкланып утырган безнең бәләкәй авыл өстенә язын-көзен яңгыр, кышын исә кар-буран алып килә торган иде. Бүген битләрне аяусыз чәнчеп, кием-салымнарны әрсез йолыккалап туктаусыз коры салкын җил иste, суытты, көн ямьсезләнде.

Әсәрдә табигать күренеше белән кешеләрнең уй-кичерешләре тәңгәл китерелеп, берсен-берсе тулыландыралар. Мәсәлән, Ибраһимның Чаллыга укырга баруын гына карыйк: “Имәнле урамыннан чыгуга, әллә нишләп күңелем тулды. Юк, авылдан китү, әнкәйдән аерылу сагышы түгел иде минем күңелдә. Минем күңелне моңарчы тоелмаган, моңарчы бар икәнлеге дә беленмәгән ят сагыш, ят моң биләгән иде. Имәнле урамының ава-түнә утырган иске-москы текмә читәннәренә тикле моңлы-сагышлы иде бүген...”

Шул ук вакытта язучы табигатьтәге үзгәрешләрне дә күрсәтә: “Көн суык. Көн шыксыз. Юл канатлары бозланып каткан”. Язучы үз героеның уй-кичерешләрен табигать белән бергә бәйләп күрсәтеп биргән. Табигать тә кешенең вакытлыча аерылуын, күңелендәге моң-сагышын аңлый кебек.

Әсәрдәге ике яшь йөрәкнең, Әдилә белән Ибраһимның очрашуын искә төшерик: “Язгы төн. Төн айлы. Анда-санда гына юка болытлар ага. Урам яп-якты, инә эзләп табарлык. Урам буп-буш. Анда-санда гына тәрәзәләрдә зәгыйфь утлар җемелди, кеше күләгәләре уйный”. Бу ике яшь йөрәк бер-берсен яратып ошатып йөрсәләр дә, әле бер-берсенә ачылганнары юк. Аларның мәхәббәт күкләре аяз, ләкин аларның мәхәббәт күгендә дә юка болытлар ага. Әмма, аларның киләчәк тормышлары шушы урам кебек яп-якты, матур булыр дип әйтәсе килә. Егет үзенең кызга карата булган хисләрен уйларын әйтә алмый иде. Аның турында уйлап йөрсә дә очраша алмыйлар. Җае туры килеп очрашып сөйләшүләре егет өчен бер олы вакыйга була. Егет кыз белән сөйләшкәч болай ди: “Күз алдым яктырып киткән кебек булды, күтәрелеп карасам, тулган ай болыт астыннан чыгып килә”, - дип герой үзенең уйлануларын табигать белән тәңгәл китерә.

Бу повесть сугыш чорында үскән буынны чагылдырган. Әсәрдәге төп күренеш, вакыйга – ул кешеләрнең ачлы туклы яшәп тә, бик авыр, җаваплы, газаплы һәм шатлыклы юл үтүләре. Язучы кешеләрнең газап-шатлыкларын үзенчәлекле табигать күренешләре белән сурәтләп күрсәтеп бирә.

Табигать күренешләре әсәрдә төп герой авызыннан яңгыратыла. Әсәрдән без өч сөйләмне таба алабыз. Берсе автор сөйләме, икенчесе персонаж сөйләме һәм уртак сөйләм. А. Гыйләҗев бу әсәрдә персонаж сөйләменнән файдалана. Әсәрне ул безгә Ибраһим авызыннан сөйләтә. Ни өчен? Чөнки бу повесть сугыш чорында үскән яшьләрнең өстенә күпме авырлык килгәнен күрсәтергә тели. Ибраһим образы аша шул чор яшьләренең язмышларын күрәбез.

Әсәрдәге образларның характер үзенчәлекләрен, эчке кичерешләрен, кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне ачуда язучы пейзажны бик оста файдаланган. Бу әсәрдә язучы язгы табигать белән кешеләрнең күңел пакьлыгын янәшә куеп безгә җиткерә. Чорның авырлыгын язучы әсәрдә бирелгән пейзаж белән сурәтли. Әсәрнең башыннан алып – ахырына кадәр язгы табигать пейзажы сурәтләнгән.

Аяз Гыйләҗевнең әсәрләрен укыганда шуңа игътибар итәсең: ул тормыш авырлыкларын бик күп кичерсә дә, күңел матурлыгын, юмор хисен югалтмаган. Бу дөньяның гаделсезлеге аны сындыра алмаган. Әдип гаять тирән дәрәҗәдә кеше күңелен аңлый, күрә һәм шуны укучыга җиткерә белә. Аның бу әсәрен укыганда миндә кешеләргә карата чиксез ярату, үз итү, һәр кешенең үзенә генә хас кызыклы сыйфатларын күрә белүгә күзем ачылды. Табигать күренешләрен аның кебек оста һәм кыска тасвирлаучы бик сирәктер ул. Татарстанның халык язучысы А. Гыйләҗев бу фани дөньядан бөтенләйгә китсә дә аның романнары, повестьлары, хикәя-мәкаләләре хәтеребездә гомер буе сакланыр. Бу хезмәтемдә яраткан язучым әсәрендә пейзаж –табигать һәм кеше күңеленең бердәм булуын күрә алуыма чиксез шатландым. Язучы табигатьне үз күңеле аша үткәреп, үзе ничек кабул итә, шулай сурәтли. Ә әдәби герой шул табигать тасвиры нәтиҗәсендә ачыла. Әдәби әсәрдә тасвирлау формалары бик күп. Пейзаж шуның бер төре булып тора, һәм әсәрдә ул тирән мәгънә эчтәлегенә ия. Күргәнебезчә, кешеләр һәм табигать язмышы охшаш, алар бергә үрелеп бара. Бер-берсеннән аерып карап та булмый.

Шайхулова Гөлназ Фаяз кызы,
Яңа Кәшер санатор мәктәп-интернаты, Әлмәт районы

**Гарәп-фарсы алынмаларын кабатлау**
**(А. Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән”, “Өч аршин җир” әсәрләренә бәйләп әзерләнгән дәрес эшкәртмәсе)**

**Максат**: 1. Телебездәге гарәп-фарсы алынмалары турында өйрәнгәннәрне гомумиләштереп кабатлау. 2. Үстерү максаты: иҗади фикерләргә, белемне башкалар белән уртаклашырга өйрәтү, күзәтү, хәтерләү, игътибар итү сәләтен үстерү; А. Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” “Өч аршин җир” әсәрләре белән якыннан танышып, биремнәрне үтәү. 3. Аяз Гыйләҗев иҗатына карата кызыксыну уяту, игътибарлы, әдәпле шәхесләр тәрбияләү.

**Көтелгән нәтиҗә:** Метопредмет. Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; төркемнәрдә эшләү; үз фикереңне төгәл һәм ирекле җиткерә белү.

Предмет. Гарәп-фарсы алынмалары турында белү, гәрап-фарсы алынмаларына караган билгеләрне аерып чыгару.

Шәхескә кагылышлы. Телебезне; А. Гыйләҗев иҗатын өйрәнүгә кызыксыну уяту.

**Дәрес тибы:** гомумиләштереп кабатлау, проеклар яклау.

**Төп төшенчәләр:** гарәп-фарсы алынмалары.

**Предметара бәйләнеш:** гомуми тормыш, матур әдәбият.

**Методлар**: проектларны яклау, әңгәмә, төркем белән эш.

**Кулланылган әдәбият:** М.И.Мәхмүтов, К.З.Хәмзин, Г.Ш.Сәйфуллин тарафыннан төзелгән, 1993 елда Казанда, "ИМАН" нәшриятында чыккан Гарәпчә-Татарча- Русча алынмалар сүзлеге. Г. Ф. Саттаров тарафыннан төзелгән, 1981 елда Казанда “Татарстан китап нәшрияты”нда чыккан Татар исемнәре сүзлеге.

**Җиһазлау:** компьютер презентациясе ”Гарәп-фарсы алынмалары”.

**Дәрес барышы:**

**I. Оештыру, мотивлаштыру.**

Укучыларда уңай психологик халәт булдыру, эшләргә теләк уяту.

Укытучы: Исәнмесез, укучылар. Туган тел дәресебезне башлыйбыз. Безнең бүген гарәп – фарсы алынмалары буенча проектлар яклау дәресе. Сез үзегез әзерләгән проектларны яклаучы, ә мин сезнең фәнни җитәкчегез булырмын.

**II. Уку мәсьәләсен кую.**

- Укучылар, сезгә өй эшенә нинди бирем бирелгән иде? (Аяз Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән", "Өч аршин җир" әсәрләреннән гарәп-фарсы алынмаларын табып, проектлар әзерләргә).
- Әйе, 5 төркемгә 5 тема бирелгән иде. Һәр төркем үзенә бирелгән теманы атап чыксын әле. (Слайд №2)

1 нче төркем: М. Гыйләҗевнең "Бибинур" фильмы турында.

2–3 нче төркемнәр: Әлеге әсәрләрдә кулланылган гарәп-фарсы алынмаларыннан сүзлек төзү.

4 нче төркем: үзебез тапкан гарәп-фарсы сүзләренең сингармонизм законына буйсыну һәм буйсынмавын ачыклау.

5 нче төркем гарәп-фарсы сүзләрен аеру үзенчәлекләре.

- Менә без яклаunion проектларның исемнәрен атап үттек.

**III Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

-Укучылар, экрандагы әлеге сүзләргә игътибар итегез әле. "Дөньядагы барлык милләтләрне хөрмәт ит, аларның теленә, мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә ихтирам белән кара. Булдыра алсаң, берничә чит тел өйрән..." Аяз Гыйләҗев

- Сез язучы сүзләре белән килешәсезме? (Әлбәттә, без олуг әдибебез сүзләре белән килешәбез һәм аны куәтлибез. Тик, кызганычка каршы, телебезнең бүгенге көндәге хәле бик күпләрне борчуга салды. Дәресебезнең әлеге эпиграфын бик күпләргә ишеттерергә теләр идек...)

- Мин сезнең белән килешәм, укучылар. Телебезне тирәнтен өйрәнү, аны яклый белү үзебезнең кулларда. Әлеге максаттан, бүгенге дәрескә нәрсәләр әзерләп килдегез? (Аяз Гыйләҗевнең "Өч аршин җир", "Җомга көн кич белән" әсәрләрен укып, гарәп-фарсы алынмаларын таптык).

- Әйе, сез әлеге әсәрләрне өйдә тагын бер тапкыр укып, һәр төркем үзенә бирелгән биремне үтәргә тиеш иде. Хәзер һәр төркем үзенең эше белән башкаларны таныштырырга тиеш. Уңышлар сезгә, укучылар.

1 **нче төркем "Милләтнең йөзен саклап калыр өчен, иң беренче үз гаиләңдә татарча тәртип урнаштырырга кирәк!"** - дия торган була Аяз Гыйләҗев**.** Аның бу фикере сүздә генә калмый, әдип моны үз гаиләсендә үрнәк рәвештә исбат итә.

"Без бала чактан ук татар театрларындагы бер генә премьераны да калдырмый идек. Жанрына, сыйфатына карамастан, әти безне һәр спектакльгә алып бара иде. Шулай да сиземләү кимәлендә без аларны аңлап карый идек сыман. Табигый, без театрны бик тә ярата идек, аның могҗизасы каршында хәзер дә баш иябез. Мең рәхмәт әтиебезгә!" - дип искә ала Мансур Гыйләҗев. Күргәнегезчә, кечкенәдән салынган бу орлыклар эзсез калмаган, әтиләренең ике олы әсәрен берләштерү нәтиҗәсендә "Бибинур" фильмы дөньяга танылa. Безнең төркемнең эше әлеге фильм хакында.

"Бибинур" нәфис фильмы Казанда узучы VI Халыкара мөселман киносы фестиваленең йөзек кашы була. Фильмны урыс режиссеры Юрий Фетинг төшерә. Сценариен Аяз Гыйләҗевнең "Өч аршин җир", "Җомга көн кич белән" әсәрләре нигезендә язучының улы Мансур Гыйләҗев иҗат иткән. Ә "Бибинур" фильмын төшерүне башлап йөрүче – әсәрнең продюсеры Светлана Бохараева.

Фильмның сценарий авторы Мансур Гыйләҗев сөйләвенчә, Бибинур карчык чыннан да яшәгән. Аяз Гыйләҗевкә аның язмышы турында бер авылда сөйлиләр. Чынбарлыкта Бибинур күрше авылның колхоз рәисе Җиһангирны соңгы юлга озатырга бара. Шуннан кайтканда аны этләр талап үтерә. Ә фильмда әлеге Җиһангир олихарх буларак күрсәтелде.

"Бибинур" фильмында татар милләтенең бүгенге тормышы ничек бар шулай ачып салына. "Без үзебез турында язабыз. Мине бу әсәрдә Бибинур карчык белән Җиһангир мөнәсәбәтләре уйландырды. Мин бит аны башка җирлектә яза алмыйм. Фильмда да кемдер урысча, татарча, инглизчә, кытайча сөйләшә. Тормышта да шулай бит", - ди автор.

Әсәрләрне укып чykканнан соң, әлеге фильмны карау ирексездән уйланырга, фикер йөртергә, чагыштырырга этәрде.

- Ә бүгенге дәрестә безнең алга куелган бурыч, алда атап үтелгән әсәрләрдә кулланылган гәрәп-фарсы алынмаларын аерып алып, аларны туплап, сүзлек төзү. Әгәр дә сораулар булмаса, беренче төркемнең эшен тәмамлап, сүзне 2 нче төркемгә бирик.

2-3нче төркемнәр. Экранда үзләре төзегән сүзлекне тәкъдим итәләр.

Слайд № 3-7

| | | |
|---|---|---|
| **А**. Амин | Шулай булсын! Амин! | Да будет так! Аминь! |
| Ахирәт– гарәп с., исем. | Зыян, бәхетсезлек | беда, несчастье. |
| **Ә**. Әкбәр *с.* | 1) Өлкәнрәк, ик бөек, ин өлкән, ин зур, иң дәү. 2) Алла эпитеты. | *пр. ст.* от кәбир— 1) самый большой. самый великий. 2) Всевышний (эпитет Аллаха). |
| Әрвах гарәп с. | Рух, җан | дух, душа. |
| **Б**. Бәхет гарәп с. | 1)Язмыш. 2)Бәхет, сәгадәт | 1) Судьба. 2) Счастье. |
| Биби ф. ис. | Бикә, ханым; хуҗа хатын. | *п. сущ.* Госпожа, дама; хозяйка. |
| Бисмиллаһ гыйб. дини | Бисмилла (төп мәгънәсе: Алла исеме белән). | *фр. рел.* С именем Бога. |
| Бичара ф. с. | 1) Чарасыз. 2) Ярдәмсез, мескен, бәхетсез, кызганыч. | *п. прил.* Беспомощный; несчастный, жалкий. |
| **В**. Вакыт ис | Чак, заман, чор. | *сущ.* Время, пора, период. |
| Вәгъдә ис. | Вәгъдә, сүз бирү. | *сущ.* Обещание. |
| **Г**. Гомер ис. | 1) Тормыш. 2) Тереклек вакыты, һәркемнең яшәү чоры. 3) Бервакытта да, һичкайчан. | *сущ.* 1) Жизнь. 2) Возраст. 3) Никогда. |
| Гыйбадәтханә гф. ис. | 1) Табына торган урын. 2) Мәчет, чиркәү, потханә. | *ар.-п. сущ.* 1) Место поклонения, храм. 2) Мечеть; церковь; кумирня. |
| **Д**. Дивана ис. | Тиле, юләр, тинтәк. | *п.сущ.* Безумный, умасшедший, юродивый, помешанный. |
| Дога ис. дини | 1) Теләк, теләү, ялынып сорау, үтенү. 2) Келәү итү, дога кылу. | *сущ. рел.* 1) Мольба, просьба, зов. 2) Молитва. |
| Дөнья ис. | 1) Дөнья, галәм. 2) Татар телендә бик күп мәгънәсендә кулланыла. | *сущ.* 1) Мир, свет, вселенная. 2) В тат. рском языке употребляется в значении очень много. |
| Дүшәмбе ф. ис. | Атнаның 2 нче көне. | *п. сущ.* Понедельник. |
| **Җ**. Җәннәт *ис.* | 1) Бакча, 2) *дини* Оҗмах. | *сущ.* 1) Сад. 2) *рел.* Рай. |
| Җиһангир *ф. ис.* | Дөньяны үзенә каратучы, дөньяны яулап алучы. | *п. сущ.* Повелитель вселенной, покоритель мира. |
| Җомга *ис.* | 1) Җыелып укыла торган намаз. 2) Җыелып намаз укый торган көн, атнаның алтынчы көне исеме. 3) Атна. | *сущ.* 1) Молитва, совершаемая вместе, коллективно. 2) День коллективного совершения молитвы, пятница. 3) Неделя. |
| **З**. Зиярәт *ис.* | 1) Зират. 2) Күрергә, күрешергә бару, хәл белә бару. | *сущ.* 1) Кладбище. 2) Посещение, визит. |
| Зөһрәбану *г. ф.* | Зөһрә+Бану | Зухра+Бану |
| **И**. | 1) Фактлар, дәлилләр белән | 1) Подтверждение, удостоверение, |

| | | |
|---|---|---|
| Исбатлау | тулысынча ышандырырлык итеп күрсәтү. 2) Беркетү. | доказывание. 2) Доказательство. 3) Фиксирование. |
| Исем | Исем, ат. | *сущ.* Имя; название. |
| Ихтияр | 1) Ирекле булу, теләгәнең итү. 2) Ирек. 3) Сайлап алу. | 1) Самостоятельность, полномочие. 2) Воля, свобода. 3) Выбор; предпочтение. |
| **К**. Кадәр | Чаклы, хәтле. | Размер, величина (в татарском языке употребляется в значении предлога до. |
| Китаб *ис.* | 1) Китап. 2) Язу. | *сущ.* 1) Книга. 2) Письмо, послание, грамота. |
| Кыйммәт *ис.* | 1) Бәя, бәһа, хак. 2) Кыйбат, югары бәяле. *Зи кыйммәт*— кыйммәт бәяле, кадерле. | *сущ.* 1) Ценность; дена, стоимость. 2) Дорогой, дорогостоящий. |
| **Л**. Лаек | Тиешле, яраклы, килешле, лаек. | Надлежащий, достойный, подходящий, приличный, заслуживающий внимания. |
| **М**. Мансур *г.* | Җиңүче. Өстен чыгучы. | Победитель |
| Мискин *с.* | 1) Ярдәмче кешесе булмаган, бичара, ярлы. | *прил.* 1) Бедняга; бедный неимущий. 2) Убогий, несчастный. |
| **Н**. Нәҗиб *с.* | Тәрбияле нәселдән булган кеше, аксөяк. | *прил.* Благородный, родовитый. |
| Нәсел *ис.* | Токым, бер ата-бабадан таралган токым. | *сущ.* Потомство. |
| **П**. Пәнҗәшәнбә *ис* | Пәнҗешәмбе, кече атна. | *п. сущ.* Четверг. |
| **Р**. Рәхмәт *ис.* | 1) Аяу, кичерү, мәрхәмәт итү. 2) Яхшылыкка җавап итеп әйтелә торган сүз. | *сущ.* 1) Милосердие, сострадание, милость. 2) Благодарность, 3) Спасибо. |
| Ризык *ис.* | Ашамлык, азык. | *сущ.* Продукт, пища, пропитание. |
| **С**. Сишәмбе (сиһшәнбе) ф | Атнаның өченче көне, буш көн | Вторник |
| **Х**. Хәзрәт *ис.* | 1) Мулла, 2) Әфәнде. 3) Зур кешеләрне хөрмәтләү, олылау сүзе. | *сущ.* 1) Мулла, 2) Господнн. 3) Величество, высочество, сиятельство. |
| Хикмәт *ис.* | 1) Хикмәт; фәлсәфә. 2) Мәкаль. 3) Сәер, әкәмәт! 4) Сер. 5) Белем. | *сущ.* 1) Мудрость; философия. 2) Мудрое изречение, поговорка, пословица. 3) Странно! Чудно! 4) Тайна, секрет. 5) Знание; просвещение. |
| **Ш**. Шәҗәрә *ис.* | 1) Бер агач. 2) Нәсел-ырунын кемнән башланып ничек тармакланып килүен күрсәткән схема, нәсел агачы. | *сущ.* 1) Дерево. 2) Родословное дерево. *сущ.* 1) Дерево. 2) Родословное дерево. |

Кыскартулар: гф.- гарәп-фарсы дини - дингә караган ис. с.- исем сыйфат ис.- исем

2-3 нче төркемнәрнең эшләре бик уңышлы чыккан. Хәзер инде сүзне 4нче төркемгә бирик.

**4нче төркем**. Үзебез тапкан гарәп-фарсы сүзләренең сингармонизм законына буйсыну һәм буйсынмавын ачыклау иде. Игътибар экранга. Слайд №8

| Сингармонизм законына буйсынган. | Сингармонизм законына буйсынмаган |
|---|---|
| Әкбәр | Амин |
| Бәхет | Әрвах |
| Биби | Бисмиллаһ |
| Вакыт | Бичара |
| Вәгъдә | Гомер |
| Дога | Гыйбадәтханә |
| Дүшәмбе | Дивана |
| Җәннәт | Дөнья |

| | |
|---|---|
| Җомга | Җиһангир |
| Зиярәт | Зөһрәбану |
| Исбатлау | Ихтияр |
| Исем | Кадәр |
| Лаек | Китаб |
| Мансур | Кадәр |
| Мискин | Кыйммәт |
| Нәҗиб с. | Ризык |
| Нәсел *ис.* | |
| Пәнҗәшәнбә *ф. ис* | |
| Рәхмәт *ис.* | |
| Сишәмбе | |
| Хәзрәт *ис.* | |
| Хикмәт | |
| Шәҗәрә | |

4 нче төркемнәр үз эшләрен уңышлы гына башкарып чыкканнар. 4**нче төркем** гарәп-фарсы сүзләрен аеру үзенчәлекләре белән таныштырды. Слайд №9, 10

Бу телләрдән кергән сүзләр сөйләмебездә зур урын алып торалар. Сораулар булмаса, сүзне 5 нче төркемгә бирик.

**5нче төркем.** Идел-Болгар дәүләте 922 елда Ислам динен кабул иткәннән соң, гарәп җиреннән бик күп укымышлылар, сәүдәгәрләр, сәяхәтчеләр күчеп килгәннәр. Болгарда күпләп мәдрәсә-мәктәпләр, мәчетләр салынган. Халыкны гарәп язуына һәм теленә өйрәткәннәр. 13-14 нче гасырларда Алтын Урда һәм гарәп илләре арасындагы сәүдә мөнәсәбәтләре тагын да көчлерәк үскән бер чорда галимнәр, шагыйрьләр әсәрләре аша гарәп һәм фарсы сүзләре тагын да күбрәк кергән һәм шактый иркен кулланыла башлаган. Алынма сүзләр телебездә шулкадәр киң кулланылган, тора-бара аларның читтән кергән сүзләр икәнлеге беленми дә башлаган. Мәсәлән, **гарәп** теленнән кергән *рәсем, нокта, кер, тәртип; магазин, алгебра, химия* (автор искәрмәсе: бу сүзләрне күпләр рус сүзләре дип уйлыйлар*), хат* сүзләре һәм **фарсы** теленнән кергән *шәһәр, бәхет, начар, рәвеш* һ.б.

Сүзләрнең гарәп һәм фарсынықымы икәнне аеру да шактый кыен, бигрәк тә укучылар өчен. Шулай да гарәп һәм фарсы сүзләрен кайбер билгеләре буенча бер-берсеннән аерырга мөмкин.

**Гарәп сүзләре**

1) **-ат, -әт, -ят** кушымчалары ялганып ясала.

Әдәбият, нәшрият, хөррият (ирек), ахирәт, һәлакәт, сәламәт, әманәт, мәрхәмәт, мәдәният, хакимият, рухият һ.б.

2) **-и, -ый** формалы нисби сыйфатлар.

Әдәби, дини, сыйнфый, иҗади, гамәли, әхлакый, тәнкыйди, шәһәри, сихри, мәгънәви, фәлсәфи, даими.

3) **Әл** артикле ярдәмендә ясалу: әл мәктәбе (мәктәп), әл ислах.

4) **Өч тартык** килү юлы белән ясала:

а) җ м г: **җәмәг**ать, җәмгыять, җомга, җәмигъ;

б) р х м: **рәхм**әт, рәхим, мәрхәмәт;

в) х р м: **хәрәм**, мөхтәрәм, хөрмәт, мәхрүм, мәрхәмәт;

г) к д р: **кадер**, кадәр, микъдар, кадыйр;

д) г л м: **гыйлем**, галәм, галим;

е) х к м: **хаким**, хөкүмәт, хикмәт, хөкем;

ж) к т п: **китап**, котып, сәркатип.

**Аерым кагыйдәләргә туры килмәгән гарәп сүзләре**: ватан, дәүләт, дәрәҗә, гыйшык, зарар, игътибар, илһам, мәкаль, мәсәл, җөмлә, нокта, начар, нәфис, әмма, һәм, әлбәттә, сәгать, һаман, хикәя, шәһәр, җавап, һава, һәйкәл, тамаша, әлифба, шарт һ.б.

**Искәрмә**: гарәп һәм фарсы сүзләре җыелмасы Г.Х. Әхәтовның "Татар теленең лексикасы", Ф.С. Сафиуллина, М.З.Зәкиевнең "Хәзерге татар әдәби теле" китапларында да бирелгән.

**Гарәп сүзләренә кеше исемнәре дә керә. Аларның аерым сүзлеге бар.**

Без укыган әсәрләрдә түбәндәге исемнәр очрады: Мансур, Биби, Зөһрәбану (г. ф), Җиһангир, Нәҗиб.

**Фарсы сүзләре:**

а) **ханә** сүзе кушылып ясала: шифаханә, китапханә, гыйбадәтханә, сырхауханә (шифа, китап, гыйбадәт, сырхау – гарәп сүзләре, ханә – фарсы сүзе);

б) **–кәр, -гәр, -дар, -анә** кушымчалары кушылып ясала:
сәүдә**гәр**, хезмәт**кәр**; хәбәр**дар**, дуст**анә**;

в) **стан** сүзе кушылып ясала: Гарәбстан, Төркестан;

г) **на-, би-** кушылып ясала: **на**хак (хак – дөрес, на – түгел мәгънәсендә йөри, нахак – дөрес түгел); **би**хисап (бик күп, хисапсыз), **би**ниһая (бик зур)

**Физминут**

**Төркемнәр эшенә бәя бирү.**

Карточкалар белән эш. Гарәп-фарсы алынмаларына төшеп калган хәрефләрне куярга. Үзбәя

9 нчы сыйныф. Исемем: _________

| Критерий | билге |
|---|---|
| Биремне хатасыз үти алдым. | "5"ле |
| Биремне үтәгәндә 1-2 хата җибәрдем | "4"ле |
| Биремне 3-4 хата белән эшләдем. | "3"ле |

**IV.Йомгаклау. Рефлексия.**

- Укучылар, дәресебез ахырына якынлаша. Безнең бүгенге дәресебез сезнең өчен нәрсә белән әһәмиятле? Хәзер үзегезнең дәрестәге эшчәнлегегезгә бәя бирегез. (Һәр укучыга үзбәя карточкасы таратыла) Слайд №11. Үзбәя.

9нчы сыйныф. Исемем: ______________

| *Мин бу дәрестә актив катнаштым* | балл |
|---|---|
| *Биремнәрне үтәгәндә үземнән өлеш керттем* | |
| *Мин гарәп-фарсы алынмаларын аера белә́м* | |
| *Сөйләмем дөрес һәм тулы булды* | |
| *Гарәп-фарсы алынмаларын сөйләмдә дөрес итеп куллана беләм* | |

Һәр пунктка берешәр баллдан.

**V. Өй эше.**

1. "Безнең як Бибинуры" исеме астында иҗади эш башкарырга. (Тәрбиягә бала алучы, чит балаларны әти-әниле иткән үрнәк гаиләләр турында)
2. "Аяз Гыйләҗев иҗаты" темасына реклама ясарга.
3. Гарәп-фарсы алынмаларын гына кулланып, 10-12 җөмләдән торган текст төзергә. (мәҗбүри)

- Барыгызга да катнашуыгыз өчен рәхмәт. Сау-сәламәт булыгыз.

Ләйсән Сафина,
Мөслим лицее, Мөслим районы

**А.Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” әсәрендә Бибинур образы**

**Максат:** Әсәрләрнең эчтәлегенә төшенү, идеясен ачыклау.Укучыларның сөйләм телен үстерү, әйтәсе килгән фикерләрен, хисләрен матур, төгәл итеп аңлата алуларына ирешү. Бибинур образындагы кешелеклелек, матурлык сыйфатларын ачу.Укучыларда әти-нигә карата шәфкатьлелек хисләре тәрбияләү; әхлак тәрбиясе бирү.

**Җиһазлау:** әдипнең портреты, “Бибинур” фильмыннан өзек, презентация.

**Метод һәм алымнар:** проблемалы укыту, әңгәмә.

**Дәрес барышы.**

**I. Оештыру**. Уңай психологик халәт тудыру.

**Укытучы.** Укучылар, белгәнебезчә бүгенге тормышта әхлак тәрбиясенә зур урын бирелә, чөнки ул иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Безнең ни дәрәҗәдә тәрбияле булуыбыз кешеләр белән үзара мөнәсәбәттә, эти-әни, әйләнә-тирәдәгеләр белән аралашуыбызда да бик ачык күренә. Ул әби-бабаларыбыздан мирас булып калган. Әхлак мәсьәләсен күтәргән, үзәккә куйган әсәрләр әдәбиятта һаман очрап тора. Шундый әсәрләрнең берсе – Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” әсәре. Бүгенге дәрестә әсәргә йомгак ясарбыз. Дәрескә эпиграф итеп “Ана күңеле – балада, бала күңеле – далада” дигән мәкальне алырбыз. Дәрестә без бу мәкальгә кире әйләнеп кайтырбыз.

**II. Төп өлеш.**

**1. Әсәрнең төп темасы.**

**Укытучы**. Укучылар, әсәрдә нәрсә турында бәян ителүеннән чыгып, тема -сын билгелик әле. (**Көтелгән җавап.** Бу әсәрдә сүз Бибинур исемле карчык турында бара. Ул ятим калган балаларны үз канаты астына сыендыра, гомеренең соңгы сулышына кадәр “балаларым” дип яши. Бибинур аларга ана назы бирә).

**Укытучы.** Бибинурның ятим балаларга карата кылган гамәлләрен нинди сүз белән атап була? (Игелеклелек, шәфкатьлелек, миһербанлылык).

**Укытучы.** Димәк, әсәрнең төп темасы – игелеклелек, шәфкатьлелек. Бу төп тема вакыйгаларда тагын ничек чагыла? (Бибинурның игезәк туганы Зөһрәбану күп еллар буенча аңа начарлык эшләп килә. Ә ул, киресенчә, туганына яхшылык белән җавап кайтара. Моны без Бибинурның Зөһрәбану белән Галикәйне кавыштыруында күрәбез. Тагын бер мисал итеп, Бибинурның хуҗасыз этне өенә алып кайтып, соңгы ризыгын да кызганмыйча бүлешүендә, ашатуында күрәбез. Ләкин шунысы аяныч: соңыннан шул эт үзенә һөҗүм итә).

**2. Әсәрнең сюжеты, төзелеше.**

**Укытучы**. Әсәрнең төп сюжеты итеп нәрсәне билгеләр идегез? (Бибинурның фаҗигале язмышы).

**Укытучы.** Нинди сюжет сызыкларыннан тора? (а) Бибинурның яшьлектәге мәхәббәте. б) Бибинурның картаймыш көнендәге мәхәббәте. в) Игезәк туганы Зөһрәбануга булган мөнәсәбәте. г) Авыл халкы балаларны тәнкыйтьләгәндә дә бичара ананың балаларын яклавы.) Һәрбер сюжет сызыгының эчтәлеге искә төшерелә.

**Укытучы.** Укучылар ни өчен әдип әсәрне “Җомга көн кич белән” дип атаган? (Үзенең соңгы көннәрендә дә балалары өчен янып йөри Бибинур. Алар өчен үзен-үзе куркыныч астына куеп, Казаннан килгән корреспондент алдына балаларының данын төшермәс өчен, самовар, җөй машинасы ише олырак әйберләр һәм башка вак-төякләре

артыннан, Бибинур кичкә табан күрше авылга –Җиһангирның атасы Вәли картларга дип юлга кузгала. Тик урман аша узганда ул кыргый этләр төркеменә очрый һәм шулар арасында, үзе элек ашатып тоткан этен – Карабаен танып ала. Карабай үзенең хуҗасы, ашатып тоткан кешесенә таба һаман да ырылдап килә бара, танымый ул аны. Шул этләр төркеменә тап булган урында Бибинур карчык дөнья да куя. Тик этләр талап үтермиләр аны, карчык үз үлеме белән үлә. Менә аның актык көннәре дә, үзен дөньяда бар дип тә санамаган балалары өчен, юлда, авылдан читтә-урманда өзеләләр, тәмамланалар.Үлгәндә дә ул аларны уйлап, алар өчен борчылып үлә...

Бибинур, иртәгә Сабантуй буласы дигән көнне – җомга көн, кич белән дөнья куя).

**3. Әсәрнең төп персонажы.**

**Укытучы**. Бибинур ничек яши? Кем ул? (Бибинур үзгә итеп тасвирлана. Ул картлыкны да башка төрлечә тоя. Табигатьнең матурлыгын күрми, кошлар сайравына игътибарсыз, тургайлар килүен сизми, гөрләвекләр тавышы белән хозурланмый. Ана назыннан да мәхрүм, хәтта гомере буе үз балаларыдай карап, җил-яңгыр тидермичә тәрбияләп үстергән балаларына да кирәк булмаган бичара, ялгыз ана итеп бирелә).

**Укытучы.** Бибинур татар хатын-кызларына хас нинди сыйфатларны үзенә туплаган? ( Бибинур шул чор кешесе өчен хас сыйфатларга ия: эш ярата, авырлыкка түзә, бирешми; кимсетсәләр, гафу итә белә. Бибинур – дөнья каршысында да, Алла каршысында да изге җан. Ул кешеләргә борчу-хәсрәт китерүдән курка.

**Укытучы.** Тормыш кыенлыкларын җиңең чыгу өчен каян көч таба? (Аңа балаларына булган мәхәббәте кыенлыклырны җиңеп чыгарга көч бирә. Балалар ятимлек ачысын татымасыннар өчен, Бибинур кулыннан килгәннең бөтенесен эшли: укыта, кеше итә. Беркайчан да, беркемнән дә алар турында начар сүз әйттерми. Соңгы елларында Җиһангирга булган мәхәббәте көч бирә. Ул өлкән яшькә җиткәч, үзләренең авылларына колхоз рәисе булып килгән Җиһангир Сәфәргалинга гашыйк була. Ул мәхәббәтен бер кешегә дә әйтми. Бибинур аны ихлас күңеленнән ярата. Картлык көнендә бу мәхәббәт аңа көч, шатлык, яшәү мәгънәсе бирә. Җиһангир фатирда тора. Беркөнне Бибинур аның күлмәкләрен юа. Ул шушы күлмәкләрне юганда, шушы мизгелдә, үзен бик-бик бәхетле сизә. Картлык көнендә бу мәхәббәт аның тормышын бизи).

**Укытучы.** Дәрес эпиграфы итеп, “Ана күңеле – балада, бала күңеле – далада" дигән мәкальне алган идек. Ул Бибинур образына туры киләме? (Әйе, әлеге мәкаль Бибинурның барлык холкын ачарга ярдәм итә. Ул үги балаларны үз баласыдай ярата, алар өчен бер нәрсәне дә кызганмый. Бөтен гомерен шуларга багышлый, булдыра алганча ярдәм итә).

**Укытучы.**Бибинур балаларының аны онытуларына үпкәлиме? Кайтып хәлен дә белмәүләренә рәнҗиме? (Юк, Бибинур бервакытта да зарланмый, балалары турында беркайчан да начар сүз әйтми, кешеләр сөйләгәнне дә яратмый. Ул аларны гел яклап чыга).

**Укытучы**. Ә шулай да Бибинур белән балалар арасында каршылык бармы? ( Әйе, каршылык бар. Моны без балаларның комсыз, мәрхәмәтсез, рәхимсез булуында ачык күрәбез. Алар әниләрен өйне таратып бетерүдә гаеплиләр; укыткан, тәрбия биргән, кеше иткән аналарына түбәнсетеп карыйлар. Ә Бибинур аларны һәрвакыт яклый, гомерен алар өчен корбан итә).

**Укытучы.** Укучылар, сез өйдә “Бибинур” фильмын карап бетереп килдегез, хәзер мин исегезгә төшерү өчен кечкенә генә бер өлешен куеп алам. (Бибинурның Җиһангир белән читтәге баласы турында сөйләшү күренеше)

Җиһангирнең “не родной ребенок” дигән сүзе Бибинурга ничек тәэсир итә? (Бибинурның ачуы чыга, “Как не родной??? Самый, самый родной!” дип өзгәләнә).

**Укытучы.** Хәзер, икенче өзекне карыйк. (Җиһангир Бибинурның чит илдәге малаена шалтырата). Укучылар, ә хәзер нинди нәтиҗә ясап була? (Улы анын белән хәтта телефон аша сөйләшергә теләми, ул анасын бар дип тә белми).

**Укытучы.** Укучылар, әсәр белән фильмның азагын искә төшерик әле! Ике Бибинур арасында аерма бармы? (Әсәрдә гомере буе яхшылык кына эшләп яшәгән Бибинур мәгънәсез үлем белән үлә. Ә фильмда исә Бибинур заманга ярашканрак, буыннар чылбырын саклап калу өчен, үзенең гомере бәрабәренә Җиһангирне коткарып кала).

**Укытучы.** Укучылар, без кечкенәдән үк: “Яхшылык явызлыкны җиңә”, “Кылган яхшы гамәлең үзеңә меңе белән әйләнеп кайта”, - дип әйтеп килә идек. Ни өчен бу әсәрдә яхшылык Бибинурга явызлык булып кайта? (Бибинур гомере буе балалары өчен өзгәләнеп яши, үзе турында уйларга вакыты да булмый. Авыл халкының балалары турында әйткән фикерләренә, киңәшләренә дә колак салмый. Ә балалар аналарының эшләгән изгелекләрен тиеш итеп кабул итәләр. Бибинур артык яратуы аркасында үзе дә сизмәстән аларны боза. Нәтиҗәдә ул балаларга кирәкмәс була. Ана белән балаларны бәйләп торучы җепләр өзелә).

**Укытучы.** Әйе, кызганыч, бүгенгесе көндә тормыш артыннан куып, борынгыдан килгән туганлык, үзара ярдәмләшү, олыларны хөрмәт итү, кешелеклелек, мәрхәмәтлелек кебек күркәм сыйфатлар әкренләп югалып бара. Бу сыйфатларның югалуы олы фаҗигаләргә китерә. Бүгенге көндә радио-телевидение, гәҗит–журнал аша да балалары тарафыннан җәберләнгән, кимсетелгән, кыерсытылган, хәтта акча, байлык өчен ата-анасын, әби-бабасын үтерүгә барып җиткән очраклар турында да ишетеп, күреп беләбез. Димәк, әдип күтәргән проблема бүгенге көндә дә бик актуаль булып кала бирә.

**Укытучы.** Әлеге темага багышланган тагын нинди әсәрләр укыганыгыз яки фильмнар караганыгыз бар? (Ә.Еникинең “Әйтелмәгән васыять” әсәре, Ш.Камалның “Буранда” хикәясе).

**Укытучы.** Әниләр турында тагын нинди мәкальләр беләсез? (Җәннәт - аналарның аяк астында. Тапкан – ана түгел, баккан ана. Ана - шәфкать диңгезе. Өйнең яме ана белән).

**III. Йомгаклау өлеше.**

**Укытучы.** Укучылар, дәрескә йомгак ясап шуны әйтәсе килә: Бибинур язмышы безне үзара ярдәмләшү, туганлык тойгыларын кадерләү, табигый кешелекле бәйләнешләр, кеше ихтыяҗларына игътибарлык кебек гадәти аңлаешлы хакыйкатьләр турында җитди уйланырга чакыра.

Язылу-басылу көненнән башлап бу әсәргә бер татар кешесенең дә битараф калганы юк. Бибинур образы – татар җаны, аның эчке, бик тирән якты дөньясы, тирәлектә үз кирәген таба алмый сыкраган йомшак-нечкә күңеле ул. Гасырлар аша кыю үтеп баручы горурлык хисе, сабырлык, ярату көче ул.

Бибинурны ташлап киткән, ялгыз иткән балалар – милли йөзләрен җуйган мескеннәр – бүгенге чынбарлык ди, А.Гыйләҗев XX йөз ахырында. Гомеренең соңгы елларында А.Гыйләҗев телләрен, диннәрен югалткан яңа буын турында әрнеп яза, татарча укучы табылмас, дип сызлана. Ләкин ике гасыр чигендә Бибинур образының көче мәдәниятләрне берләштерә. Бүгенге дөнья әдәби-мәдәни мохите Бибинурны яңадан “укый”, укыган саен мәгънә ача. Татар халкының бөек әдибе, милләт хадиме Аяз Гыйләҗев исемен XXI йөз дөнья мәдәнияте мәңгеләштерә.

**Укытучы.** Укучылар, дәресебез ахырына якынлашты. Шулай тәэсирләнеп әсәрне укыганыгыз, дәрестә активлык күрсәткәнегез, матур һәм тулы җавапларыгыз өчен бик зур рәхмәт. Бу дәрестән үзегез өчен кирәклесен алгансыздыр дигән ышанычта калам.

Өй эшенә алда санап кителгән мәкальләр белән бәйле темага инша язарга.

Билгеләр кую.

Ризатдинова Эльвира Хәниф кызы, Вахитова Люция Мансур кызы.
икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

## “Хафиз бабай әкияте”нә анализ (А.Гыйләҗевнең “Дүртәү” повестеннан өзек)

| | | |
|---|---|---|
| Тема | “Хафиз бабай әкияте”нә анализ (А.Гыйләҗевнең “Дүртәү” повестеннан өзек) | |
| Сыйныф | 4 нче сыйныф, татар төркеме | |
| Дәреснең тибы | Якташ язучылар иҗатын өйрәнү буенча әдәби укудан сыйныфтан тыш уку дәресе | |
| Максат | Өзекне анализлау өчен шартлар тудыру, язучы әйтергә теләгән идеяне табу. Бердәм булганда гына көчле булырга мөмкин булуны ачыкларга ярдәм итү. Дуслыкның, бердәмлекнең кадерен белергә чакыру, дус, бердәм булырга омтылыш тәрбияләү. | |
| Планлаштырылган нәтиҗәләр | Предмет нәтиҗәләре: өзекнең темасын аңлау һәм формалаштыру, идеясен күрсәтү.<br>Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр: бабай сөйләгән әкият аша бердәмлеккә өйрәнү.<br>Метапредмет нәтиҗәләр:<br>- регулятив: әсәрнең төп проблемасын табу, төп нәтиҗәне чыгару эшчәнлегендә катнашу өчен тырышу.<br>- танып-белү: булган белемнәргә таянып, “бердәмлек” төшенчәсенә кагылышлы мәгълүматны табу һәм анализлау аша аны бәяләү, гомуми нәтиҗәне чыгару.<br>- коммуникатив: бердәмлек турында төп фикергә килгәнче, төрле җавапларны тыңлау; төркемнәрдә эшләгәндә, төрле мисаллар белән үз фикереңне дәлилләү, өзекнең төп фикерен табу һәм формалаштыру. | |
| Предметара бәйләнешләр | Татар теле, музыка | |
| Җиһазлау | Аяз Гыйләҗев “Сайланма әсәрләр”, 2004 ел., слайдлар күрсәтү өчен проектор, экран, ноутбук, фонохрестоматиядән скрипка көйләре, төркемнәргә бүленү өчен төрле төстәге биремле карточклар, әдәби әсәрләргә иллюстрацияләр. | |
| Эшне оештыру | Төркемнәрдә һәм индивидуаль эшләү. | |
| Педагогик технологияләр | Өлешчә тикшеренүгә корылган әңгәмә | |
| **Дәреснең барышы** | | |
| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге |
| Оештыру этабы | Уңай психологик халәт урнаштыру.<br>-Дәресебез уңышлы булсын өчен нишлибез? соравын кую. | Исәнләшү, елмаю, изге теләкләр теләү, куелган сорауга җавап бирү |
| | Классны төркемнәргә бүлү өчен пазл җыю биреме тәкъдим итү | 1 төркем: “Аяз Гыйләҗев – күренекле язучы”, 2 төркем: “Аяз Гыйләҗев – драматург”, 3 төркем: “Аяз Гыйләҗев Сарман районында туган”, 4 төркем: “Хафиз бабай әкияте безгә ошады” язмаларын ачалар һәм урыннарга утыралар. |
| Темага килү | - Укучылар, без бүген кем турында сөйләшүне дәвам итәбез. Нинди хикәя турында сүз барачак?<br>Вакыйгаларны барлау. | Язмалар буенча дәреснең темасын, өзекнең исемен әйтү. Өзекне вакыйгаларга бүлү, тактада язып кую. |

| | | |
|---|---|---|
| Белемнәрне актуальләштерү | Өйдә өзекне укып килгәнгә, һәр төркем әзерләнгән рәсемнәр буенча скрипкачы карт үлеменә кадәрге өлешнең эчтәлеген сөйләргә әзерләнә. | Рәсемнәр буенча әкиятнең эчтәлеген сөйлиләр. Һәр төркем рәсемнәрне тәртип буенча тезә, үзенә туры килгән өлешне дәвам итә. |
| Музыкаль пауза | Скрипка, скрипкачы бабай турында сөйләү, музыка тыңларга тәкъдим итү | Скрипкачы бабай уйнаган көйне тыңлау |
| Белемнәрне актуальләштерүне дәвам итү | Скрипка кыллары сөйләшкән урынны рольләргә бүлеп укыту<br>Скрипканы ташлап киткән кылларның язмышы турында рәсемнәр буенча сөйләтү<br>Өзекнең темасын билгеләү | Рольләргә бүлеп уку.<br><br>Скрипканы ташлап киткән кылларның язмышы турында рәсемнәр буенча сөйләү<br>Бердәмлектә – көч. |
| Ял моменты. Физкультминут | | |
| Беренчел ныгыту | Сөйләгәннәрдән чыгып, проблемалы сорау куела: бердәмлек сүзен сез ничек аңлыйсыз?<br>Аңлатмалы сүзлек белән эшләү<br>Ул нинди сүз белән синоним? | Төркемнәрдә киңәшләшү, үз фикерләреңне әйтү. Аңлатмалы сүзлектән сүзнең мәгънәсен табып уку. Дуслык турында сөйләшү. |
| | Ни өчен скрипка кыллары авыр хәлдә калдылар? Берсе елады, берсен чормага болгап аттылар. | Төркемнәрдә киңәшләшү, үз фикерләреңне әйтү |
| | Рәсемдәге скрипкаларны чагыштыру: кайсы көчлерәк? Ни өчен? | Кыллы һәм кылсыз скрипкаларны чагыштырып, аларга бәяләмә бирү |
| Мөстәкыйль эш | И.Крыловның “Чуртан, Кысла һәм Аккош” мәсәле, “Шалкан” рус халык әкияте буенча рәсемнәр күрсәтелә. Аларның укып килгән әкият белән аваздаш булуын исбатларга. | Төркемнәрдә киңәшләшү, үз фикерләреңне әйтү |
| Белемнәрне системага салу | Скрипка моңын тыңлау. Сорауларга җавап эзләүне оештыру.<br>Экранда: “Кышкы караңгы төннәрдә тешен шыгырдатып ишек төбендә торган ачлыкның тавышын халык ишетмәсен өчен, ул кичтән алып таңгача уйный да уйный икән. Моң астында сабыйлар да изрәп йоклаганнар, өлкәннәр дә сабырланганнар. Бармаклары өшеп, тырнаклары төшеп беткән аның. Моң йортның иң караңгы почмакларына да үтеп кергән...” Моңның көче нәрсәдә?<br>Кешеләр ни өчен скрипкачы картка рәхмәт укыйлар?<br>Кыен булган вакытларда кемнәргә таянырга кирәк?<br>Кешеләр кайчан көчле була? | Төркемнәрдә киңәшләшү, үз фикерләреңне әйтү. |
| Рефлексия. Өй эше бирү. | Барлык эш процессын күздән кичереп, төп нәтиҗәне чыгару.<br>**Өй эше**: “Безнең сыйныф дуслык белән көчле” темасына сочинение язарга, дустың турында сөйләргә әзерләнергә, хикәя эчтәлеге буенча рәсем ясарга | Төп нәтиҗә: кыен вакытта да югалып калмаска кирәк, дусларыңа таян, бервакытта да ялгыз калырга тырышма. |
| Дәрескә йомгак | Билгеләр кую. | Эшчәнлеккә үзбәя. |

Хәсәнҗанова Клара Әхмәт кызы,
Әлмәт шәһәренең 12 нчы урта мәктәбе.

**Аяз Гыйләҗев “Матур” әсәре**
**(3 нче сыйныф укучылары өчен татар әдәбиятыннан дәрес эшкәртмәсе)**

**Максат:** Аяз Гыйләҗевнең туган илгә тугрылык, чынбарлыкны ача белү хисе белән сугарылган хикәяләренең тарихи әһәмиятен ачыклау, аның проза әсәрләренең асылына төшенү. А.Гыйләҗевнең “Матур” әсәрендәге дуслыкның асылына төшенү. Балаларга дуслык, хисләрен үстерү, тәрбияләү. Сөйләм телен үстерү.

**Җиһазлау: Я**зучының портреты, китаплары күргәзмәсе, презентация, Аяз Гыйләҗев “Матур” хикәясе.

Дәрес барышы

**I .Актуальләштерү**

1.Исәнләшү

2. Уңай психологик халәт тудыру

3.Уку мәсьәләсен кую

Укучылар, мин сезгә бер әкият сөйлим. Дәрестә нәрсә турында сөйләшүебезне шуннан аңларсыз.

Борын-борын заманда, биек тауда, гаиләсе белән көтүче яшәгән. Ул бик ярлы булган. Бер төнне аларның ишеген 3 кеше шакыган. Көтүченең өе бик кечкенә икән. Ул аларга : «Берегез генә керегез, өем бик кечкенә минем,-дигән һәм: «Сез кемнәр соң?» - дип сораган.

- Без – Дуслык, Бәхет, Байлык. Син кайсыбызны чакырасың, шул керер, - дигәннәр алар.

Төркемнәрдә киңәшер өчен сорау:

- Көтүче өенә кемне чакырган? (Укучыларның җавабын тыңлау)

- Димәк, бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшербез? (Дуслык турында)

**II. Уку мәсьәләсен кую һәм чишү.**

3 төркемгә бүленеп эшлиләр: Зирәкләр, Тапкырлар, Зыялылар.

Һәр төркемгә дуслык турында сораулар куела:

1. Мәкальләр һәм әйтемнәр белергә
2. Дуслык, матурлык, бәхет турында язучыларның нинди әсәрләрен беләсез?
3. Нәрсә ул дуслык? Һәм аның нинди төрләре бар?

Һәз төркем алдына битләр куела.

Терәк сүзләр тактада һәм карточкаларда язылган. Һәр кем үзенең үз фикерен яза, өстәп язарга башка төркемнәргә дә бирә.

Бер укучы җавапларны җыйнап, баллар куя.

Фикерләрне тыңлап, нәтиҗә чыгарабыз:

Дус – ул сиңа һәрвакытта да ярдәмгә килүче әтиең, әниең, туганнарың.

Дус – ул яраткан китабыбыз, укыган саен укыйсы килү. Дус – ул синең белем иленең серләренә төшендерүче укытучың. Сиңа авыр вакытта зарыңны тыңлаучы яраткан этең – Акбай, кадерле песиең – Матур һәм Бәхетле.

Дуслык ул – бик кыйммәтле язмыш бүләге. Дуслык безгә укырга, эшләргә, яшәргә ярдәм итә. Ул безне тәрбияле, тугрылыклы, әйбәтрәк, көчлерәк итә.

Дуслыкта – зур көч. Кешегә дусларсыз яшәү мөмкин түгел, балачак, яшьлек, гаилә дусларың бар. Дустың булу – зур байлык.

Дустыңның нинди булуы-сиңа авырлык килгәндә сынала.

Дус, дуслык – нинди матур сүз.

Укытучы: Сез язучыларның дуслык турында әсәрләрен атадыгыз. Димәк, дәресебезнең темасын ачыкладык.

Без сезнең белән халык язучысы, "Татар әдәбиятының имән баганасы" дигән зур исемгә лаек Аяз Гыйләҗевнең "Матур" әсәре белән танышырбыз. Әсәрне укыганчы, авторның тормыш юлы һәм иҗаты белән слайдлар аша кыскача белешмә алырбыз.

Эш барышы: Бу танышудан соң төркемнәрдә эшләп, тактадагы сорауларга җавап бирербез.

Тактада аның тормышы, иҗаты турында язма бирелә:

1. Әдипнең туган ягы?
2. Туган елы, туган көне?
3. А.Гыйләҗев кайда укыган?
4. Тормышының сикәлтәле юллары – кайсы елларга туры килә?
5. Кайсы хикәясен укыганыгыз бар? (Укучыларның җаваплары тыңланыла).

- Хәзер без сезнең белән аның "Матур" хикәясен укып китәрбез. Хикәяне укыганнан соң бирелгән сорауларга җавап алына.
- Нәтиҗә ясыйк: "Матур" хикәясенең эчтәлеге нидән гыйбарәт? Җавап бирик әле. (Вакыйга авыл тормышыннан алына. Ишегалдында нәни балалар уйный. Шушы уен барышында кемнең, кемлеге беленә).

Укучылар хикәяне укыйлар, эзләнү эшләре алып баралар, сорауларга җавап эзлиләр.

Укучыларга бирелгән сораулар:

1. Бу хикәядә кемнәр турында сүз бара, хикәянең төп геройларын ата?
2. Елның кайсы фасылы тасвирланган?
3. Разыя нинди кыз?
4. Разыяның әнисе кызына нинди киңәш бирә?
5. Искәндәр кем? Аңа ни булган?
6. Галия нинди кыз? Ни өчен ул усал?
7. Автор әби һәм әни сүзләре белән, балаларны нәрсәгә өнди?
8. Әби: "Дуслыкка ни җитми?" Бу мәкальне сез ничек аңлыйсыз?

III. Рефлексия

Ситуатив биремнәр аша нәтиҗә чыгару.

1. Галия начар сүзләр куллана, дорфа сөйләшә, хәтта сугышырга да күп сорамый икән. Син бу очракта нишлисең?

2. Азат рус теленнән өй эшен эшләмәгән. Күчерергә сорый. Нишлисең?

3. Марат начар укый башлады. Классташларың аның белән уйнамаска өндиләр. Бу очракта син нишләргә тиеш? (Җаваплар тыңланыла).

Төркемнәрдә киңәшеп терәк конспект-модельләрдән файдаланып эшлиләр. Нәтиҗә чыгаралар.

Йомгаклау. Үзбәя

- "Матур" хикәясенең асылы нәрсәдә булуын өйрәндек, максатыбызга ирештек. Сезнең арада Галия кебек кыз бармы? Булса сез аңа, тылсымлы, ягымлы итеп сөйләшергә өйрәтерсезме? (Җаваплар тыңланыла). Рәхмәт, балалар.

Өй эше.

"Мин дуслыкны ничек аңлыйм" темасына кечкенә генә инша язып килергә.

Ханов Разил Зөлфәт улы,
П.Днепров исемендәге Рус Шуган төп гомуми белем бирү мәктәбе,
Мөслим районы

**А. Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” әсәрендә детальләрнең роле**

А. Гыйләҗев үзенең “Җомга көн, кич белән...” повестында уйдырмаларга еш мөрәтәгать итә. Моңа әсәрнең исеме үк беркадәр уйдырмалылык белән аваздаш булу да алшарт ролен үти. Аеруча автор кулланган делальләр зур игътибарга лаек, чөнки шулар ярдәмендә А. Гыйләҗев укучыларны татар халкының язмышы, үткәне, бүгенгесе, киләчәге хакында уйланырга этәрә.

Тикшерү эшебезнең максаты: А. Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” әсәрендә кулланылган детальләргә күзәтү булдыру, аларның әһәмиятен барлау, автор фикерен җиткерүдәге рольләрен ачыклау. Максатка ирешү өчен үзалдыбызга “Җомга көн кич белән” әсәрендәге мөһим детальләрне барлау, әлеге детальләрнең мәгънәсен ачып биргән җөмлә үрнәкләрен язып алу, әсәрдәге вакыйга, күренешләрне бәяләү бурычын куйдык.

Җомга – мөселманнарның җыелу көне булып тора. Шушы көндә кешенең эшләре бәя алганлыктан, әсәрдә дә ниндидер күренешләргә бәя яңгырарга тиешлеге аңлашыла башлый.

Автор уйланулары өлкән буын вәкилләре белән хәзерге буын бәйләнешендә дәвам итә. “Бу тарихны ишеткәч, мин ул әбинең болдырына утырып озак кына җыладым...” дип тасвирланган вакыйганы искә төшерик. Болдыр – ул үз һәм чит аппозициясе. Шул рәвешле тарих аерым кеше тормышы белән бәйләнә. Бу кешенең эчке дөньясы башкалар өчен ябык булуны әсәрдә сурәтләнгән йорт ярдәмендә аңлыйбыз, чөнки аның тәрәзәләр ябык. Бу да мифологизм, ягъни уйдырмалылык белән бәйле мотив. Бу хакта әдәбият белгече Г.Р. Гайнуллина болай дип яза: “Әбинең бу яман халәте күптәннән үзгәрешсез: “ихатада башка корылмалар күптән ишелеп беткән”. Кеше һәм дөньяның трагик каршылыгын символик белдерүче көзге үтә шомлы төн вакыты образы укучы күңелендә шөбһәле көтү хисе урнаштыра: “Көзге үтә шомлы төн иде” (Г.Р. Гайнуллина, Лекцияләр, кыскача курс).

Бу вакыйга янә бер деталь – каен белән үрелә. Каен милли мәдәниятебездә кайгы символы буларак карала, чөнки мифологиябездә дә ул шулай яктыртылу таба. Бу әсәрдә әби тормышын халык тормышы белән тәңгәлләштерү аша аның кайгысын халык кайгысы итеп гәүдәләндерә. Әсәрдән өзек китерик: “Караңгы булса да, череп укмашкан саламны әрсез җил иркенә бирмичә түбә өстенә рәт-рәт тезелешеп яткан каен бастырмалар аермачык күренеп тора иде” (А. Гыйләҗев, 17 б.). Халык күргән кайгыларның сәбәбен автор аның үз сүзен әйтеп бирә алмавы, күндәмлегендә, кирәкмәгән дәрәҗәдә түзем булып яшәргә омтылуында күрә. Автор киләчәктә хаталар булдырмас өчен үткәнне анализлап нәтиҗәләр чыгара белү кирәклеген әйтә: “Карчыкның бөек рухы, җимерек йорты белән саубуллашып китә башлагач, борылып карадым...” (А. Гыйләҗев). Өметне иртә өзәргә ярамау турында да искәртә автор. Татар халкын берләштерүче элемент буларак җырны билгели, ул моң элементы белән үреп бирелә, җыр татарны үз асылына алып кайта, тамырында үткәннәр кайтавазын торгыза дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә: “...сәҗдәгә чүккән өй дә, аның ак төшкән йомык тәрәзәләре дә юк иде, әнә шул, сабый бала беләге юанлыгы, иртә киселгән ап-ак каен кәүсәләре генә караңгылык елгасында мыштым гына, каядыр, серле, без белмәгән мәңгелек елгасына таба йөзәләр төсле тоелды” (А. Гыйләҗев).

Алга таба тагын бер әһәмиятле детальгә юлыгабыз. Автор тау ягындагы алачык һәм тау өстендәге урман белән бәйләп, биеккә үрмәләү, киләчәкле булу өчен юлны күрсәтә. Әлеге юл кешенең тойгыларын, эмоцияләрен тәртипкә салу, кирәк чакта йөгәнләп тә тору белән башлана. Моның үрнәге урамнарны тәртипкә китергән Җиһангир Сәфәргалин мисалында бирелә, ул башкаларны дә хәләл юл белән эш итәргә чакыра: "...тракторларның эресен-вагын ел әйләнәсендә урамга керүдән катгый тыйды" (А. Гыйләҗев). Кеше уйларын саф тоту өчен күңел дә керләнмәгән булу кирәклеге ассызыклана әсәрдә: "урам як коймаларын, өй түбәләрен тиешле тәртиптә тотуны таләп итә башлады", "ермакларны, вак-төяк мәкерле коры сызаларны күмдереп, бик күп җирләргә агач утырттырды" (А. Гыйләҗев). Җиһангир халыкны яңа яшәешкә илтәчәк, бәхетле киләчәккә алып барырга тиешле әйдаман буларак гәүдәләнә. Матур уйларны һәрчак тәрбияләп торырга кирәклеген дә билгели автор: "агач орлыкларын, үсентеләрне юллар үзе тапты; бер дә иренмичә агач чокырларының тирәнлеген, киңлеген көрәк сабы белән вакчылланып тикшереп йөрде; тамырлары имгәнмәсен өчен нәзек, зифа каеннарны бәби биләгән төсле генә күтәреп йөртүләрен үтенде, тәртип бозучыларга каршы шәфкатьсез дә була белде" (А. Гыйләҗев). Халыкның мескенлек халәтен автор күпер халәте белән чагыштыра. Күпер исә, мифологиядә үткән белән бүгенгене тоташтыру вазыйфасын башкарганлыктан, үз сүзен әйтеп калырга ашыкмаса, киләчәк өчен көрәшмәсә әлеге халыкның юкка чыгу куркынычы алдында торуын күрсәтеп бирә.

Казлар исә әсәргә янә бер мифологик мотив алып керә. "Каз тавышы, бәләк тавышы яңгыраганда арыкның акрын гына тавышлана башлавын ишетмәделәр дә әле. Арык шавының кемгәдер, кайчандыр хәҗәт буласын, әлбәттә берәү дә уйлап карамады; Җиһангирның сүзен уен-көлке, мәзәк дип кенә кабул иткән кешеләр аны шунда ук оныттылар да..." Җиһангир сүзләре автор сүзләре буларак кабул ителә. Автор гүя укучыларын тормыш гаугасыннан арынып үз сүзләрен ишетергә чакыра.

Бибинур образы – татар җанын, татар тарихын гәүдәләндерә. Моны түбәндәге юллар мисалында да ачык күрәбез: "Бибинур карчык, ямаулы оек үкчәләрен мәрхүмнең ике ягына тәбәнәк эскәмияләргә тезелешкән якыннарына күрсәтмәс өчен, озын күлмәк итәге белән аякларын туктаусыз төреп азапланса да, җил итәкне каерып ачты, туктаусыз исеп, көчәеп торды" (А. Гыйләҗев). А. Гыйләҗев укучыга мөрәҗәгать итеп, аңа үз асылын табу юлларын күрсәтергә тели: "Тау башына менеп туктагач, ул ирексездән аска, Аксыргак авылының күз күнеккән чуар нокталарына һәм зур булып, җәйрәп яткан буага карады". Җиһангир үлеменә ачынып елау чистарыну буларак кабул ителгән күз яше мотивына ярдәмендә төгәлләшә: "Кичерешләрнең тирәнлеген, хисләрнең үткенлеген күз яшьләре белдерә". Бу якты өметләрнең урынлы булуын күрсәтә.

Күз яше мотивы әсәр дәвамында сузылып бара.

1. Бибинурның (укучының) беренче күз яшьләре тома ятимлек белән бәйле: "Ятим, япа- ялгыз, кем өчен еласын, байтактан күзләреннән яшь чыкканы юк иде, бүген күз төпләре рәхәт кычытып дымланды".

2. Чарасызлык белән бәйле күз яше: "Хуш, Җиһангир, балам, хуш, асыл затым, хуш нәнәм! Мәңгегә хуш!"- дип, байтак үрсәләнде Бибинур".

Автор халыкның бәхетен үткәнне хөрмәтләп, зурлап яши белүдә күрә: "Җиһангирым борынгыны бик олылый иде. Өйдә җылан мөгезе генә юк. Стенада тәрәш тараклары, дага-кыңгыраулар, кутаз дисеңме, эшлея шөлдерләре, калтырчалар, киндер сосалары, балдаклы дуга тиклем бар! Ярма ташын әйткән дә юк. Аны да чыгарып ташлатмады..." (А. Гыйләҗев).

Укучыда моңа каршы туарга мөмкин булган фикерләрне исәпкә алып, автор болай дип тә өсти: “Беркем дә ата-бабалары кылганны механик рәвештә кабатлап кына яшәргә риза түгел, гәрчә ата-бабаларыбыздан кадерле мирас калган очракта да! Әгәр без һәр буынга лаеклы һәм җаваплы шундый эш йөкли алмыйбыз икән, яшьләребез авылда калмаячак!..” (А. Гыйләҗев) Милләтне гәүдәләндергән Бибинурның ямаулы ыштаны нәкъ менә аянычлы вакыйгаларның халык күңелендә калдырган авыр эзләре булып төгәлләшә. “Ямаулы ыштан аркасында оятка каласы килмәде анның” (А. Гыйләҗев). Автор әлеге вәзгыятьне тасвирлауда детальләрне бик җентекле тасвирлый ала: “...яңа ситсы арасында уралганнан соң кулдан бик озакка кадәр тәмле ис китми, тәмле ис – яшьлек исе, ак киндер исе, җитен сөлгеләр исе өс-башка да сеңеп чыга, шулай итеп, кибеттә булганнан соң, иске киемең дә яңа кебек була 66 башлый...” (А. Гыйләҗев).

Мифологиядә теге һәм бу дөнья чиген бетерүче яулык мотивы Бибинурның кисеп алган кызыл яулыгына бәйле рәвештә аны үсеш юлы булып төгәлләшә. Шулай ук әлеге яулык Бибинурның Җиһангирга булган яратуын да гәүдәләндерә: “Буа тавышын ул дөньядан Җиһангир киткәнгә генә генә ишетте! Оя таба алмыйча бүрәнә почмакларына туктаусыз бәргәләнгән божанны Җиһангир өчен генә кызганды ул бүген! Күкне кыеп-кыеп, кисәкләргә бүлеп, җир кешеләренә бүләк итәргә ашкынган карлыгачларны ул бары тик Җиһангир булганга гына күрде” (А. Гыйләҗев). Шулай да кешелекне яшәтүче, бар итүче көч мәхәббәт икән дигән фикергә алып килә безне автор. Әлеге мотив Сабантуена бәйле тагын да көчлерәк яңгыраш таба. Бу бәйрәм, уңай хис-кичерешләр белән тулы бәхетле яңа дөнья булып аңлашыла. Икенче бер чынбарлыкны гәүдәләндерә. Автор әлеге матурлыкны мондый детальләр белән тасвирлый: “табигать шулай чуклы-бизәкле була да инде. Капкалар җырлап кына ачыла, морҗалардан хуш ис кенә тарала, яшь кызларның сулышлары, адымнары үзгәрә. Аксыргак кызлары бер башка биегәеп китәләр” (А. Гыйләҗев).

Автор кеше яшәешенең бар мәгънәсен тирә-юньдәгеләргә, табигатькә, кешелеккә, җиһанга булган мәхәббәт белән бәйли. Мәхәббәтле лекенең генә тормышы мәгънәле була ала дигән фикерне укыйбыз әсәрдән. Бибинурның тормышка булган уй-хыяллары Җиһангир белән бәйле ачыла. Тик җомга көнне юлга чыккан бибинур үлемгә дучар була.

“Мәкерле, тавышсыз гына коела торган төнге яңгыр, бимазалап озата килгән черкиләр” образлары Бибинурның көрәшен, әлеге көрәшнең авырлыгын аңлатып килә. “Татар кешесенең саф-ихлас дөньясы аны буйсындырып, юкка чыгарырга теләгән чынбарлыкка каршы көрәшә. Бу чынбарлыкта кешене горур-буйсынмас итүче мәхәббәт хисе генә тормышны тулы, түгәрәк итә” дигән фикерне белдерә әдәбият галиме Г.Р. Гайнуллина.

Әлеге тирән эчтәлекне укучыга җиткерүдә автор кулланган детальләр җентекле анализ аләп итә һәм хәттә аерым курс эше дәрәҗәсендә өйрәнелергә дә хаклы.

Галимова Ә.И.,
165 нче гомуми белем бирү мәктәбе, Казан шәһәре

## Аяз гыйләҗев прозасында тәнкыйди катлам

Аяз Гыйләҗев – татар әдәбиятында тәнкыйди реализм ысулы белән иҗат иткән талантлы һәм гаять үзенчәлекле каләм иясе. Аның актив иҗат эшчәнлеге нәкъ менә илленче-алтмышынчы еллар чигендә башланып, күп еллар үткен каләмен кулыннан төшерми. Аның прозасы фикергә, фәлсәфи уйлануга, тәнкыйди бәягә бай.

Хөр фикерле, кыю, талантлы һәм үзенчәлекле әдип А.Гыйләҗев үзенең әсәрләре белән татар әдәбиятын уй-фикер торгынлыгыннан, әдәби чараларның бертөрлелегеннән арындырырга, катлаулы тормыш хәрәкәтендәге, котылгысыз үзгәрешләрнең асылын аңларга, шушы яңа рухны сәнгатьчә ачарга, үзләштерергә омтылды. А. Гыләҗевның әдәби мирасы үзенчәлекле, әдәби тәнкыйтьнең ничек булырга тиешлеген дәлилләүче бизмән дә.

Ф.Миңнуллин үзенең тәнкыйть мәкаләләрендә авторны әдәбиятны үзгәртүче һәм яңа үзенчәлекләр алып килүче буларак бәяли.  Д.Заһидуллина да тәнкыйди башлангычның әдип иҗатында зур чагылыш табуын искәртә.

А.Гыйләҗевның бу сыйфаты беренче чорда иҗат ителгән хикәяләрендә үк ачык күренә. Анализга алынган өч хикәя дә тәнкыйди рухта язылган әсәрләр булып тора. Өйрәнү юлында “Үги ана яфраклары” һәм “Өч тәгәрмәчле арба” хикәяләрендә тәнкыйди башлангычның катлам дәрәҗәсенә үстерелгән булуы ачыкланды. Ул системаны, аның төрле еллардагы сәясәтен тәнкыйтьләүгә карый. Тәнкыйтьтөп геройлар, автор-хикәяләүче тарафыннан, хронотоп бирелеше ярдәмендә дә үткәрелә. “Үги ана яфраклары” әсәрендә тәнкыйть аеруча геройлар бирелешендә көчле чагыла. Тәнкыйди фикерләр бигрәк тә бер яктан системага бәя бирүче, икенче яктан үз яшәеше белән аны раслаучы Хәнәфи образы аша җиткерелә. Аны сурәтләгәндә бер мотив – “колхоздан ризасызлык” мотивын кабатлап, А.Гыйләҗев совет системасының коллык психологиясенә нигезләнгән булуын тәнкыйть утына тота. “Тәрәзәләр” хикәясендә тәнкыйть ачы сәяси формада чагылмый. Ул, нигездә, геройларның тормышы, омтылышлары аша гәүдәләнә. “Өч тәгәрмәчле” арба хикәясендә сәяси эчтәлекле тәнкыйть бирелә. Тәнкыйть бигрәк тә хронотоп – Рәшатның көнел пространствосы һәм советсистемасының реаль бирелеше ярдәмендә уздырыла. Геройның үз пространствосында горизонталь юл белән хәрәкәт итүен, ләкин Рәшатның түгәрәк ябылуы геройның тормышы тулысынча шул түгәрәк белән бәйләнгән булуын күрсәтә. Хикәядә түгәрәк моделе кеше каршы торырга мөмкин булмаган көчләрне белдерә: алар – совет системасындагы тәртипләр, шәхес культы фаҗигасе, шулар тәэсирендә формалашкан язмыш.

Шулай итеп, А.Гыйләҗев иҗатында тәнкыйть киң мәгънәдә алынуда, ил сәясәтенең, идеология, тоталитар системаның нигезләрен күрсәтеп бирүдә, аны төрле яклап тәнкыйтьләүдә күренә. Тәнкыйть образлар системасы, аларның эчке дөньялары, образлар композициясе, хронотоп, төрле әдәби алымнар, үзенчәлекле стиль ярдәмендә үткәрелә. Әсәреннән әсәренә А.Гыйләҗев совет системасының кешене шәхес буларак үтерүен, җәзалавын, коллыкка төшерүен, ирексезлеген тәнкыйтьли, бу мотивлар аның прозасының лейтмотивы булып тора.

Исрафилова Фирая Вагыйз кызы, Абалачурта гомуми белем бирү мәктәбе,
Менделеев районы

**Тема: Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән...» повестенда әхлак проблемасы**

**Максат:** Повестьтагы вакыйгаларга, андагы образларга дөрес бәя бирергә өйрәтү. Укучыларда әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аның белән аралашу, парларда һәм күмәк эшли белү, тәнкыйди фикерләү сәләтләрен үстерү, диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен формалаштыру.Укучыларда әхлак сыйфатлары тәрбияләү.

**Дәрестибы:** Яңа белемнәрне ачу дәресе.

**Җиһазлау.** Проектор, компьютер, дәреслек, таратма материал.

**Дәрес барышы.**

**I.Оештыру, уку эшчәнлегенә мотивация булдыру**.

1.Дәрестә уңай эмоциональ мохит булдыру.

2.Өй эшен тикшерү.

**Укытучы:** Укучылар, сез өйдә “Әхлаклы кеше нинди була?” дигән сорауга җавап эзләп килергә тиеш идегез. Гомумән, әхлак нәрсә дигән сүз ул. Әгәр аңлатмалы сүзлектән карасак, әхлак – кешеләрнең бер-берсенә һәм җәмгыятькә карата мөнәсәбәтләр нормасы һәм принциплар җыелмасы дигәнне аңлата. Хәзер алдындагы кәгазьгә һәркем җавапны яза да“идеяләр кәрзиненә”сала. (“Кәрзингә” идеяләр салу. )

**II.Уку мәсьәләсен кую һәм уку эшчәнлегендәге авырлыктан чыгу юлын билгеләү.**

**Укытучы:** Димәк, безбүгенгедәрестә нәрсә хакында сүз алып барачакбыз икән? ( Әхлаклы кеше нинди була, аның эш – гамәлләре нинди? Шул турыда сөйләшәчәкбез икән.

**Укытучы:** Без аны үзебез өйрәнгән Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән...” әсәрен анализлау өстендә эшләрбез. Ә хәзер кәрзингә салынган барлык идеяләрне тикшереп карыйк. (Укучыларның язмаларын уку) Хаталы яки ялгыш идеяләр кәрзиннән кире алына. Кәрзиндә бары тик дөрес идеяләр генә калырга тиеш.

**III. Төзелгән проектны тормышка ашыру.**

**“Фаразлар агачы” методы**



1. Тактада агач рәсеме ясала.

Агачның кәүсәсенә – чишелеш сорыйторган тема язылা: “Җомга көн кич белән...” әсәрендә әхлак проблемасы.

Агачның ботакларына кәрзиндәге идеяләрне язабыз:

Әхлаклы кеше туганнарының кадерен белә, эти-әнисен хөрмәтли, кешегә яхшылык эшли.

**Укытучы:** Ә хәзер безгә әсәрнең эчтәлеген искә төшереп, әлеге фаразларны дәлилләргә кирәк.

**Безнең 1 фараз:** әхлаклы кеше туганнарының кадерен белә, дидек. Без анализлый торган әсәрдә туганнар арасындагы мөнәсәбәтләр сурәтләнәме? (Зөһрәбану белән Бибинур мөнәсәбәте. Күп еллар Зөһрәбану Бибинурга карата начарлыклар эшли, ә Бибинур туганының начарлыгына яхшылык белән кайтара). Агачның яфрагына аргумент языла да агачка ябыштырыла.

1 аргумент: Бибинур туганының начарлыгына яхшылык белән кайтара.

**Укучы:** Бибинур балаларның Сабан туйларга гына булса да кайтмавына борчыла. Сабан туе аның уенча туганнарның бергә җыелу урыны да.

2 аргумент: Сабан туе – туганнарның бергә җыелу урыны да

**Укытучы: 2 фараз:** әхлаклы кеше башкаларга яхшылык кына эшли (Без моны Җиһангир Сәфәргалин образы аркылы дәлилли алабыз).

1 аргумент: Ул авыл кешеләре өчен күп яхшылык эшли: урамнарны тәртипкә китерә;

2 аргумент: һәйкәл куйдыра;

3 аргумент: өлкәннәрнең хәлен белә.

**Укучы:** Габдуллаҗан белән Бибинур мөнәсәбәте дә моңа мисал була ала. Габдуллаҗанның хатыны Гайшә үлгәч, Бибинур башта аңа хуҗалык алып барырга булыша, соңнан аның балаларына әни булырга тәкъдим итә.

4 аргумент: Балалары аны онытсалар да, ул алар турында начар сүз әйттерми.

**Укытучы: Безнең 3 фараз** – әхлаклы кеше эти-әнисен хөрмәт итәргә тиеш. Бибинур белән балаларының мөнәсәбәтен карыйк.

1 аргумент: Бибинур үз эти-әнисен хөрмәт итә.

2 аргумент: Бибинурның балалары карап үстергән әниләренең хәлен дә белмиләр, шулай да ул аларга рәнҗеми.

**Укучы:** Габдуллаҗанның балалары бала вакытта этиләренә ышаналар: Бибинур беренче көнне шыр тоз итеп бәрәңге пешерә. Әтиләре тәмле дигәч, алар да тәмле дип ашыйлар.

3 аргумент: Гаиләдә ата – үрнәк.

**IV. Нәтиҗә чыгару. "Алты түбәтәй" алымы**

**Укытучы:** Әйдәгез,"Алты түбәтәй" алымыбелән без соңгы нәтиҗәне чыгарыйк. Сезнең алларыгызда түбәтәйләр. Үзегезнең түбәтәегез таләп иткән сорауга җавап бирәбез. Эшне ак түбәтәйдән башлыйбыз.




**Үзбәя.**



**Өй эше:** Бибинурның балаларына хат язарга.

**Фейерверк.** Без иң яхшы, иң актив, иң акыллы укучылар!

Тырышлык булса, уңышлар да булыр! Сау булыгыз, укучылар!

Мөбәрәкшина Фирдинә Рафил кызы,
аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе,
Түбән Кама шәһәре

**Туган тел һәм туган телдә әдәбият фәненнән 8 нче сыйныфларда Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” повестен өйрәнү дәресенең технологик картасы**

Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” повесте – сугыш чоры авылы кешеләренең, аеруча яшьләрнең яшәеше турындагы әсәр. Бу повестьта Бөек Ватан сугышы чорында тылдагы халык язмышы, көнкүреше сурәтләнә. Әдипнең максаты – шул чордагы тыл каһарманнарының батырлыгын укучыга җиткерү. Хәзерге буын, якты дөньяда яшәве белән сугыш чоры каһарманнарына һәм ул елларның авырлыгын иңнәрендә татыган ил кызларына бурычлы булуын онытмаска тиешлеген искәртү.

Язучының “Язгы кәрваннар” әсәрендә сугыш чорында эшне төптән җигелеп тарткан өлкән яшьтәге Хәкимҗан абзый, Сабирәттәйләр һәм аларга алмашка үсеп килүче, шулай ук бик яшьли тормыш арбасына җигелгән Ибраһим, Дамир, Әдиләләр яшәеше сурәтләнә.

Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәре татар мәктәпләренең укыту программасына кертелгән. 8 нче сыйныфлар өчен татар әдәбияты фәненең эш программасында бар. Әдип куйган максатларга ирешү өчен әсәрне укучы тарафыннан укып чыгу гына җитми әле. Моның өчен аны бар тарафтан анализлап, төпле фикер йөртергә өйрәнергә кирәк. Дәрескә куелган максатларга ирешү, нәтиҗәсе файдалы булсын өчен, дәресне гади план-конспект белән генә үткәрү җитми. Хәзерге көндә ФДББС таләпләренә туры китереп һәр дәреснең технологик картасы булу турында һәр укытучы белә. Шул нисбәттән, 8 нче сыйныфларда Аяз Гыйләҗевның “Язгы кәрваннар” повестен өйрәнү дәресен нәтиҗәле итү өчен, бу темага төзелгән технологик карта тәкъдим итәм.

**Дәреснең темасы:** Аяз Гыйләҗевның “Язгы кәрваннар” повестен өйрәнү.

**Дәреснең тибы:** әдәби әсәрне анализлау.

**Дәреснең максаты:** Әсәрдәге вакыйгаларны күз алдына китереп, геройларны һәм аларның эш-гамәлләре аша әсәрне анализлау. Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү; эпик әсәрне анализлау күнекмәләрен үстерү. Укучылар холкында тормыш һәм хезмәт авырлыкларын җиңеп чыгу, кешеләр белән үзара яхшы мөнәсәбәт булдыру сыйфатларын тәрбияләү, яшьлек хисләренең югарылыгын төшендерү.

**Дәресне җиһазлау:**

1. А. Гыйләҗевның портреты.
2. Презентация (дәреснең темасы һәм максаты, өй эше сораулары, сюжет элементлары (схема), тест җаваплары, сүзлек, идея, тема, проблема төшенчәләренә карата бирем, сораулар, өй эше).
3. Тест.

| № | Дәреснең этаплары | Кулланылган метод-алымнар | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре |
|---|---|---|---|---|---|
| I | Оештыру | Сорауларга җавап бирү. | Исәнләшү. Сыйныфта уңай халәт урнаштыру. | Исәнләшү. | Коммуникатив УУГ - Этикет саклап исәнләшү һәм хәл белешү кагыйдәләрен үзләштерү. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| II | Өй эшен тикшерү | 1.Сорау - җавап. | 1.А.Гыйҗәҗев биографиясе буенча сораулар бирү. | 1.А. Гыйләҗевнең биографиясе буенча сорауларга җавап бирү. | Регулятив УУГ - Уку эшчәнлеген аңлап оештыру, нәтиҗә чыгару юлының эзлеклелеген билгеләү. |
| | | 2. Таблица белән эш. Бирем эшләү. | 2.Бирем эшләүгә күрсәтмәләр бирү. Эш барышын аңлату. | 2.Эпик әсәрне анализлаганда кулланыла торган кайбер элементларны (композиция төзелеше, тел-сурәтләү чараларын) искә төшерүдә бирем эшләү. Таблица белән эш. | |
| III | Белемнәрне актуальләштерү | 1.Сөйләү. | 1.Эчтәлек сөйләргә бүлеп бирелгән укучылардан текстны сорау. | 1.“Язгы кәрваннар” повестеның эчтәлеген сөйләү. | Коммуникатив УУГ – тел нормасын саклап монолог төзи белү. Өйрәтелгән материал буенча мәгънә бирә алу. Регулятив УУГ – булачак нәтиҗәне, аның күләмен күзаллау. Укучының материалны ничек һәм нинди күләмдә үзләштерүен аңлавы. Танып-белү УУГ - эзлекле фикер йөртүгә нигезләнгән, аңлап сөйләм оештыру, гомумиләштерү, чагыштыру, анализлау. Аңлап сөйләп оештыру. |
| | | 2. Тест эшләү. | 2. Тест эшләтүгә күрсәтмәләр бирү. | 2.А. Гыйләҗев иҗаты һәм “Язгы кәрваннар” повесте буенча тест эшләү. | |
| IV | Яңа белем күнекмәләрен формалаш-тыру | 1.Сүзлек өстендә эш. | 1.Сүзләрне яздыру һәм мәгънәләрен аңлату. | 1.Дәфтәргә сүзләрне аңлатмалары белән язу. Сүзтезмәләр, җөмләләр төзү. | Танып-белү УУГ - Танып белү максатыннан мөстәкыйль билгеләү, эзләнү методларын куллану, чагыштыру, анализ, гомуләштерү. Коммуникатив УУГ – әңгәмә оештыра белү. Өйрәтелгән материал буенча мәгънә бирә алу һәм башкалар. |
| | | 2.Сорау-җавап. Анализ.<br>3. Таблица белән эш. Цитаталар уку. | 2.Сораулар бирү. Анализлау. Өстәмә мәгълүмат җиткерү.<br>3.Таблица тутыруга күрсәтмәләр бирү. | 2. Әсәр язылган чорга сорауларга җавап биреп характеристика бирү.<br>3.Образларны билгеләү һәм характерлау.Таблица тутыру.<br>Цитаталар уку. | |
| | | 4. Сүзлек өстендә эш. (терминнар) | 4.Биремгә күрсәтмә бирү. | 4.Идея, тема, проблема төшенчәләрен кабатлау өчен тест эшләү. | |
| | | 5.Әңгәмә. | 5. Сораулар бирү. | 5.Әсәрнең идея, тема, проблемасын билгеләү өчен әңгәмәдә катнашу, сорауларга җавап бирү. | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| V | Белемнәрне ныгыту | 1.Схема белән эш. Таблица тутыру. | 1.Ярдәмлек өчен схема күрсәтү. | 1.Тактада таблицага җавапларны тутыру. Схема белән эш. | Регулятив УУГ - Уку эшчәнлеген аңлап оештыру, нәтиҗә чыгару юлының эзлеклелеген билгеләү. Шәхси УУГ - Шәхес буларак үзеңне формалаштыру, тормышка яраклашу. Әхләкый кагыйдә дә ориентлашу. Коммуникатив УУГ – эзлекле төгәл итеп сөйли белү, әңгәмә оештыру. |
| | | 2. Сорау-җавап. | 2. Сораулар бирү. | 2. Сорауларга җавап бирүеп авторның позициясен ачыклау. | |
| | | 3.Карточкалар белән эш. Сәнгатьле уку.<br><br>4.Әңгәмә. | 3.Карточкалар тарату. Җавапларны тыңлау, дөрес җавапны билгеләү. Тел-стиль үзенчәлекләрен билгеләүдә ярдәм итү.<br>4.“Кешедәге күркәм һәм начар сыйфатлар. Кешеләрнең үзара мөнәсәбәте” дигән темага тәрбияви әңгәмә оештыру. Сораулар бирү. | 3. Карточкалардагы сорауларга җавапны сәнгатьле укып җавап бирү. Тел-стиль үзенчәлекләрен билгеләү.<br>4.Әңгәмәдә катнашу. Сорауларга җавап бирү. | |
| VI | Йомгаклау | Сорауларга җавап. | Укучыларның әсәргә мөнәсәбәтен ачыклау өчен сораулар бирү. | Сорауларга җавап бирү. Әсәргә булган мөнәсәбәтне әйтү. | Регулятив УУГ - Фаразлау – булачак нәтиҗәне, аның күләмен күзаллау. Бәя кую - укучыларның материалны ничек һәм нинди күләмдә үзләштерүен аңлавы, хатаны тану һәм аны төзәтә белү. |
| VII | Өй эше бирү | 1.Инша язу.<br><br>2. Мәкалә язу.<br><br>3. Рәсем ясау. | 1.Биремнәрне яхшылап аңлату.<br><br>2.Мәкалә язарга бер-ике укучы,<br>3.Рәсем ясарга оста укучыларны билгеләү. | 1.Өй эшен төгәл үтәү. “Кешеләрне шатландыру–үзе бәхет” дигән темага инша язып килү.<br>2.“Язгы кәрваннар” повестена карата тәнкыйть мәкаләсе язып килү.<br>3.Әсәрдә ошаган күренешкә рәсем ясау. | Коммуникатив УУГ – тынлый белү, эш-гамәлне контрольга алу, сорау куя, җавап бирәбелү. Укытучының сөйләмен тыңлау һәм аңлау. |
| VIII | Билге кую | | Билге кую. | | Коммуникатив УУГ – Бәяләү, сорау куя белү. |

Кушымта 1

1. Сораулар.

А.Гыйләҗев кайларда белем алган?

А.Гыйләҗевнең сугыш чоры авылы яшьләренең тормышын чагылдырган беренче повесте ничек атала?

Татар театры сәхнәсендә драматургның нинди пьесалары уйнала?

Язучының повесть жанрындагы әсәрләре.

Кушымта 2

2. Таблица белән биремнәр. (Термин белән аңлатманы туры китерергә).

| | |
|---|---|
| Конфликтны барлыкка китерүче сәбәпләр, аның алшартлары белән таныштыру. | 2.Экспозиция |
| Конфликтның зураюы, тирәнәюе, аны чишәргә омтылышлар ясау. | 4.Вакыйгалар үстерелеше |
| Әсәрдә сөйләнәчәк тарихтан бик күпкә элек булган вакыйгаларны ниндидер максат белән әсәр башында сөйләп кую (сирәк очрый). | 1.Пролог |
| Конфликтка нокта куелу, проблеманың хәл ителүе. | 6.Чишелеш |
| Конфликтның башлану ноктасы. | 3.Төенләнеш |
| Соңгы нәтиҗә, геройларның алдагы язмышларын хәбәр итү яки автор мөнәсәбәтен ачыклау. | 7.Эпилог |
| Әсәрдәге вакыйгаларның, көрәшнең иң югары ноктасы. | 5.Кульминация |

Кушымта 3

3. Тест

1. Бу әсәрләрнең кайсысын А.Гыйләҗев язмаган ?

а) “ Кәҗүл читек”; ә) “Өч аршын җир”; б) “Җомга көн кич белән”;

2. А.Гыйләҗев яшәгән еллар?

а) 1906-1944; ә) 1900-1999; б)1928-2002;

3. “Язгы кәрваннар” повестенда вакыйга кем исеменнән сөйләнә ?

а) Дамир; ә) Хәкимҗан абзый; б) Ибраһим;

4. Әсәрдә вакыйга кайда һәм кайчан бара ?

а) сугыштан соңгы чорда авылда; ә) сугыш чорында, авылда; б) сугыштан соңгы чорда Сарсаз глубинкасында;

5. Кәсле авылына симәнәгә орлыкка ничә чана кузгала?

а) 65 чана; ә) 75 чана; б) 55 чана;

6. Хәкимҗан абзыйны ни өчен колхоз рәисе итеп билгелиләр ?

а) фронтовик булганга; ә) каты куллы, таләпчән булганга; б) авыл халкы тәмле сүзгә сусаганга;

7. ...... , “күрәләрме - күрмиләрме” дигән сыман аска карап, табынга бер кыерчык бодай ипие куйды.Аның ипие яңа туган ай кебек балкыса да , табын уртасында ахыргача утырып калды. Сүз кем турында бара ?

а) Әдилә; ә) Гөлбәдәр; б) Сәрвәр апа.

Нургалиева Халидә Әбүзәр кызы,
Тымытык авылы гомуми урта белем мәктәбе, Азнакай районы

**Аяз Гыйләҗев иҗатына багышланган дәрестән тыш чара эшкәртмәсе**

**Алып баручы (укытучы):**

Күк йөзе кайчан матур?
Булса ул әгәр аяз.
Әдәбият нигә матур?
Туганга күрә Аяз!

Сарман ягы горурлыгы
Булып дөньяга килә.
Аның язган әсәрләрен
Татар дөньясы белә.

Әйе! Илһам Шакиров, Зөһрә Шәрифуллина, Гөлдания Хәйруллинакебек җырчы сандугачларны дөньяга китергән Сарман төбәге әдәбиятыбызга Г. Тукай исемендәге, РСФСР ның М. Горький исемендәге Дәүләт бүләгенә, Татарстан Республикасының халык язучысы исеменә лаек булган Аяз Гыйләҗев кебек бөек әдипне дә бирде.

Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 нче елда Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туа. Казан университетында укый. Казакъстан якларында төзелешләрдә эшләп ала. Университетны тәмамлагач, журналларда әдәби хезмәткәр һәм редактор вазифалары башкара. Аяз Гыйләҗев! Ул – татар әдәбиятының күренекле прозаигы, татар театры сәхнәсенә кызыклы пьесалар биргән драматург. Мәктәп программасында аның “Язгы кәрваннар”, Өтәч менгән читәнгә” әсәрләре өйрәнелә. “Җомга көн кич белән”, “Йәгез,бер дога!” әсәрләренә кыскача анализ ясала.

А. Гыйләҗев “Балачак сукмаклары” дигән хатирәләрендә бала чагында хәтерендә калган истәлекләр белән уртаклаша. Аның әти-әниләре – укытучылар. Әтисен, яшь мөгаллимне, Югары Баграж дигән керәшен авылына эшкә җибәрәләр һәм Аязның бала чагы әнә шул юмарт күңелле, кунакчыл, гади,үтә кешелекле, рыясыз-хәйләсез керәшеннәр арасында үтә.

Хәзер язучының бала вакытын чагылдырган истәлекләренең кайберләренә тукталып китик әле...

**I укучы:** Үзенең истәлекләрендә А. Гыйләҗев кыярга бәйле вакыйгаларны бик кызыклы итеп яза: “Җәйләрнең берсендә әнием ындыр түрендәге кыяр түтәлләре арасына барып кергән.Мин терсәкләремә таянып, артымны туңкайтып, борын очым белән җир сөреп, чәнти бармак кадәрле үскән кыяр малаен кимереп ятам икән. Әни, соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп: “Улым, нигә кыярны ятып ашыйсың? - дип сораган. Мин, аллы-күкле янып: “Үзең өзмәскә куштың ич!” - дип җавап биргәнмен, имеш. Әни сөйләгәннәрдән шулар исемдә калган.

Тагын бервакыт мин каравыл өе адәмнәре янына үз бакчабыздан бер кесә кыяр тутырып килдем. Бусын үзем дә ап-ачык хәтерлим!..Дәү-дәү, көрәк сакаллы керәшен дәдәйләрмине кызык өчен генә кыяр урларга җибәргәннәр дип уйлыйм, борчак кузагы хәтле кыярларны күреп: ”Ник мондый вакларын өздең?” - дип сораганга,”Олыракларын күтәреп булмый шул аның!”- дип җавап бирдем. Үзем оялып, пешеп-янып идәнгә текәлдем һәм нәп-нәни кыярларны идән ярыгыннан берәм-берәм базга шудыра башладым.

**II укучы:** Аяз Гыйләҗевнең йорт хайваннары белән булган вакыйгалар турындагы истәлекләре дә шактый: “Җәйләрен су коенырга йөрибез, авылга авып торган тау тезмәләре битләреннән җиләк җыябыз, олы малайларныңат коендырганын бергәләп карыйбыз. Мин атларга якын ук килергә куркам, читтән генә, сагаеп, яр буе таллары арасыннан карап торам. Ник дигәндә, берзаман әти белән мәктәпнең Аманат исемле атына утырып кайттык та, әти Аманатны тугарып җибәрде, мин сарай ишеген ачарга йөгердем. Аны-моны искәрмичә барам, башын чайкый-чайкый артымнан фырлап килгән Аманат кинәт җилкәмнән умырып алды да мине алагаемга чайкап җибәрде. Акырып еларга тотындым, аркам канады, Аманат тешләренең эзе шактый вакыт җөйләнеп торды.”Аткамы, бүтән хайваннаргамы, телең белән тәмләп эндәшмичә, бер чакта да алдына төшмә!” - дип өйрәтте әти. Мин гомерем буе аның киңәшен тоттым, тик, ни хәл итәсең, йорт тирәсендәге мал-туарлар, кош-корт әтинең киңәшен белмәгәннәрдер шул: үз гомеремдә мине өч тапкыр каз талады, дүрт-биш мәртәбә кәҗә тәкәсе сөзде, колхозның иң дәү ата дуңгызы төртеп екты, бер тапкыр Имәнле урамында ана күркә кычкыртып талады”.

**III укучы:** Бервакыт Аязлар авылында көчле яшенле яңгыр ява, пожар чыга, унбер өй нигезенә кадәр утырып яна.

“Шул көннән, - дип яза А. Гыйлаҗев,- мин болыттан, яшен утыннан, күк күкрәвеннән курка башладым. Офык читендә караләҗым болыт куера башладымы, өйнең берәр почмагына кереп качам. Тик яшен камчысының агы шулкадәр көчле, кермәгән тишеге, үтә алмаган почмагы юк. Чоланда дәү агач сандыгыбыз бар – артына кереп посам, яшен, чартлый-чартлый, мине эзләп таба. Толыпка уралып, мич арасына кереп утырам – колагымны ярырдай күк күкри. Ахырда әмәлен уйлап таптым. Олылар йоклый торган караватт башына әни мендәр-ястыклар өеп куя иде. Чак кына болыт кабарды исә, шул мамык тавын ишеп төшерәм дә ястык-мендәр астына кереп йомылам. Яңгыр килгәндә ишек-тәрәзә тыгызлап ябыла, мич төннекләре томалана, өебез бәләкәй, бөркү, эссе. Ястык арасында мунча ләүкәсеннән мең яман, тын җитми, шыбыр тиргә батам, манма су булам, ләкин курку барысында җиңә.

“Курку – иң явыз көчләрнең берсе”, - дип аңлата эти, мине батыраерга чакыра. Бу курку хисеннән мин озак арындым. Хәзер яшенне бар дип тә белмим. Курку – хатирә булып кына калганда, әллә ни зыянлы түгел икән үзе!”

**IV укучы:** Аяз Гыйләҗевнең Әндрияна дәдәйләргә кунакка барып кайту вакыйгасы онытылмаслык булып хәтеренә сеңеп калган.Сөенечле дә, фаҗигале дә булган ул хәл.

Хуҗалар аларны искиткеч кунакчыл каршылаганнар. “Кичләрнең берсендә өстәл тирәсендә тәмләп бәрәңге дурычмагы белән чәй эчеп утыра идек,- дип яза Аяз Гыйләҗев, - кече яктан дурычмак өйгән тәлинкә күтәреп чыгып килүче Әндриян дәдәйнең хатыны лып итеп урындыкка утырды, тәлинкәсе идәнгә шапылдап төште, майлы дурычмаклар идәнгә тәгәрәде. Олылар:”Ни булды? Ни булды?” – дип, апа тирәсендә бөтерелделәр. “Башыма кемдер күсәк белән китереп сукты!” - диде апа, әз-мәз хәлен җыеп. Олылар дару эзләргә тотынды, мин тәмам аптыраштта калдым. Нинди күсәк? Кем сукты? Өйдә бездән башка беркем дә юк ләбаса?Уллары Никипар белән Ибан да өйдә юк. Алар Зәйдән килгән кунак абыйны буа койрыгындагы камышлыкка үрдәк атарга алып китканнәр. Кичке чәйгә алар да кайтып җитәргә тиеш. Апабыз елапмы-елый, бәргәләнә генә, чыдый алмый. Әндриян дәдәй чакыруы буенча бераздан өйгә фельдшер килеп керде. Биргән даруларны эчмәде Андриян дәдәйнең җәмәгате, гел бер сүзне кабатлады: ”Бәла килде безгә, хәсрәт килде. Башыбызга кайгы төште!”

Эңгер-меңгер иңгәндә, кабык арбага салып, Әндриян дәдәйнең кече улы Ибанның җансыз гәүдәсен алып кайттылар. Эш болай булган икән. Зәйдән килгән сунарчы камышлар селкенгәнен абайлаган да шул төшкә төбәп атып та җибәргән... Ядрәләре туп-туры Ибанның күкрәгенә килеп төшкән икән, йөрәгенә үтеп кергән. Ибан аһылдап кычкырган да шунда ук җан биргән... Шул секундта әнкәсенең башына күсәк белән органдай булган. Ана сизгерлегенә тиңнәр юк!

Әндриян дәдәй сап-сары нарат такталардан улына табут ясый... Нарат ылыслары белән, чәчәкләр белән бизәлгән караватта Ибан ята. Аның башы очында кара яулыгын бәйләгән әнисе утыра. Ишегалдында, ике кулын аермаска йозаклап, һавада селки-селки, бичара сунарчы, Әндриян дәдәйнең кардәше йөри.

Мин бүген фаҗиганең ни икәнен, ата-ана хәсрәтен беренче тапкыр үз күзләрем белән күрдем. Ибанны ничек, кая күмүләре исемдә калмаган. Хәер, моның әһәмияте бар идемени хәзер? Әче күз яшьләренә төрелгән бу көн, нарат ылыслары арасында сузылган Ибанның балавыздай йөзе иң авыр хатирәләр булды шикелле”.

**V укучы:** “Язгы кәрваннар” әсәрендә җитмеш биш кеше, чана тартып, алтмыш биш чакрымдагы элеваторга чәчүлек орлык алырга баралар. Чаналарга өс-башлары таланган, йолкынган, ашарларына да булмаган хәлсез кешеләр җигелә. Бик зарури

идемебу газаплы юл? Сугыш чоры, аның законнары кырыс дип аңлата килдек. Менә ул “закон” – көзен интегеп бер якка, алты чакрымдагы элеваторга ташыганнар иде, язгы юл өзегендә бөтенләй икенче яктан, алтмыш биш чакрымнан алып кайталар. Юлда йөрәге авыру Сабирәттәй үлә.

- Безне шулай әрле-бирле йөрткән бәндәләрнең кулы корысын! Тамакларыннан аш үтмәсен! - дип рәнҗиләр кәрванчылар. Берни белән дә аклап булмый торган бу рәхимсезлек җәмгыятьнең сыйфаты, идарә итүнең ысулы иде.

“Язгы кәрваннар” повестенда Әдилә белән Ибраһим арасындагы самими, саф хисләр бөтен әсәргә үзгә бер нур, яктылык сирпеп, аны эчтән җылытып, балкытып тора.

Хәзер Әдилә белән Ибраһим диалогын тыңлап китик. **(VIII сыйныф укучылары әсәрдән өзекне сәхнәләштереп күрсәтәләр)**

- Кайтыр юлың ерак, усал маэмайлар күп, озата барыйммы?
- Эшең булмаса, бар. Иркен яшәдегез, ахры, Чаллыда?
- Нигә?
- Бер матур белән танышкансың икән.
- Каян белдең?
- Дамир сөйләде.
- Ә, Татлы тамыр! Сөйләр ул!
- Бер дә ояты юк! Әйбәт кыздыр бит?
- Беркем белән дә танышканым юк. Кирәге-кирәкләре бер тиен.
- Арзан бәяләдең син кызларны.
- Мин укырга бардым ич анда, Әдилә. Тутаңның балалары җылашып калдымы?
- Җыламый нишләсеннәр? Миңаияләнделәр. Олы кызын алып кайттым әле, бездә торып торыр.
- Җизнәң нихәлдә?
- Җизнәгә нәрсә? Куенында яшь кәләш, авыз ерык...
- Өмете синдә икән дип сөйләделәр.
- Аның өмете булгандыр да, минем өмет башкада шул!
- Кемдә инде ул синең өметең?
- Бик тиз белер идең бугай.Әллә оныттыңмы?
- Нәрсәне, Әдилә?
- Оныткан, икмәктер, оныткан!
- Әйт инде!
- Минем чәчне тартып китүеңне! Яңагыңа чалтыратуым хәтереңдәме? Әллә син башка кызларның да чәчен тарта идеңме?
- Онытмадым, Әдилә! Башкаларныкын тарткан булмады, кояштыр!
- Сөям дигән ымың түгел идемени ул, Ибраһим?
- Ай-һай, каты чәпәгән идең яңакка!
- Онытырлык булмасын дидем, Ибраһим... Егетләрнең хәтере кыска бит аларның... Яшене нинди, күкрәве шундый булсын дидем! Син дә чәчне тарткан идең бит... Яңагың шешмәгән идеме, кая, карыймчы, эзе калмаганмы? **(Әдилә Ибраһимның яңагыннан сыйпый)** Кытыршы.

**VI укучы:** “Әтәч менгән читәнгә” әсәрендә күрше булып яшәүче Мирфатыйх, Гөлмәрьям һәм Сәләхетдин, Гөлбикә гаиләләре арасындагы мөнәсәбәтләр сурәтләнгән. Яшь чакларында шушы ике гаилә арасында какшамас татулык хөкем сөрә. Ишле бала-

чагалы ике йорт арасында бернинди яшерен сер, гайбәт, көнчелек юк. Авторул вактларны болай сурәтли: “Нинди матур чаклар бар иде! Ничаклы гөнаһсыз,эчкерсез бәйләнешләр яши иде Сәләхетдин белән Мирфатыйхлар арасында. Юри дә,күңел өчен дә,кирәктә дә, кирәкмәстә дәйомышка йөриләр иде; барлык эшләре уртак булды, эш җитми иде тату күршеләргә; ризыкларын бүлешәләр иде алар: өреле ашлар, угыз коймаклары. Мунчадан соң ирләр чәй генә эчә иде; дару-дәва дигәндә дә бергә сулыйлар иде: үләннәр, кура җиләге, андыз тамырлары; читән эт биеклеге генә, чебиләр өчен генә иде, кош-корт, мал-туар да бик тату иде; бүләкләр дә бик тыйнак, кечкенә, әмма “юк кына әйбер дәолы бүләк, чөнки һәммәсендә хөрмәт билгесе, эчкерсезлек үрнәге, дуслыкны ныгыта торган җылы ишарәләр була иде”.

Берзаман Сәләхетдин бишекле мотоцикл сатып ала. Гаиләләре белән төялеп, сабан туена төшәләр. Киңәшсез-нисез кинәт булгангадыр, күршеләр шаккаталар, Мирфатыйх хатыны Гөлмәрьямнең күзе шуларда гына була.Икенче көнне үк ул кибеттән көзгеле шкаф сатып ала, ә Сәләхетдин Гөлбикәсе шкафның ике көзгелесен алып кайтып утырта, һәм... шуннан китә йортка әйбер ташу.

Әле генә түр башында татулык, хөрмәт иде, үзләре иде, хәзер исә өй эче берсеннән – берсе кыйммәт әйберләр белән тула, әйбер арткан саен көнчелек тә арта; әйберләр затлырак була барган саен, кешеләрнең үз кадерләре кими. Әйберләр белән кешеләрнең урыннары алышына, кеше өйбер колына әйләнә. “Көнчелек“ дигән сүз кергән арага тиз арада дошманлык та кереп оялый. Сәләхетдин белән Мирфатыйх кан дошманнарга әйләнәләр. Тату дөнья чәлпәрәмә килеп җимерелә, һәрнәрсәгә бәя куела башлый, яшәүнең-тормышның кыйммәте кеше җаныннан, җылы мөнәсәбәтләрдән җансыз әйберләргә күчә. Тотылмаган, файдаланылмаган җиһазлар, өй хуҗаларының үзләренә – кешеләргә урынны тарайталар, кысрыклыйлар, әйтерсең аларның иманнарын суыралар. Ике күрше, аларның хатыннары гына түгел, хәтта балалары да көнчелек, усаллык корбаннарына әйләнәләр.

Сәләхетдиннең I сыйныфны бетергән малае Зәйтүн, рогатка белән таш атып, Мирфатыйхларның Гәрәйхан кушаматлы әтәчләрен читән башыннан бәреп төшерә. Шуннан соң Мирфатыйх малае Әнәс белән сыйныфташы Зәйтүн арасында көчле бәрелеш булып ала. **(2 укучы Зәйтүн белән Әнәс арасындагы конфликтны сәхнәләштереп күрсәтәләр)**

- Нигә атасың безнең әтәчкә, бүксә?

- Мә, кара! Менәтерәк! Бармы әйберем, бармы?

- Син аттың аңа, бүксә.

- Атмадым. Сезнең карт әтәчегез үзе егылып төште.

- Безнең әтәч картмы? Безнең әтәчме?

- Карт, карт. Безнең әтәч сезнең карт йолкышны борып кына сала. Безнең ата каз да сезнең ата казның җанын ала.

- Ала! Җанынмы? Һе, килеп кенә карасын.Сезнең ул арык каздан бәбкә дә булмый әле. Ә безнең куа сыер ике бозау китерде.Икене, икене!

- Һе, икене! Белдең! Берсен фермадан урлап кайткач, ике булды. Гарьлек, гарьлек! Карт йолкышлары, үз хәлен белмичә, читәнгә менгән иде, мәтәлеп төште! Гарьлек!Карт булмаса, тавыкларыгыз безнең әтәч янына кереп йөрмәс иде, кабак баш.

- Чуен маңгай! Тимәссеңме безнең әтәчкә яңадан?

-Җибббәрр! Яңадааан атмааам!

**VII укучы:** Аяз Гыйләҗевнең иҗатын тулы итеп күз алдына китергән кеше әйтер: автор иманын җилләр агымына карап алыштырып торган әдип түгел икән. Каләменнән чәчелеп калган таза орлыклар, алардан үсеп чыккан шытымнар әдип йөргән сукмакларның йөз кызартмаслык олы юлларга барып чыкканлыгын күрсәтә. Бу сукмаклар ахыр чиктә Аяз Гыйләҗевне хакыйкать биеклегенә алып килгәннәр.

Шагыйрь Гамил Афзал бу язучыбызның иҗатындагы төп пафосны шактый дөрес тотып алды:

Син бик усал, ач арыслан кебек,
Усаллыгың җитәр йөз елга.
Юаш кына малай идең элек,
Усаллата икән бу дөнья.

Халык шагыйре Г. Афзал үз каләмдәшен “усал” дип кенә әйтеп калмый, ни өчен аңарда бу сыйфатның барлыкка килүен дә аңлатып бирә: “усаллата икән бу дөнья”. Шулай, иҗат ул – шәхси үткәнеңнән, биографияңнән аерылгысыз. Аяз Гыйләҗевнең җәмгыятькә карата булган “усаллык” барлыкка килүенең сәбәпләрен без чын-чынлап аның “Йәгез, бер дога” әсәре басылып чыккач кына аңладык.

Шәхес культы елларының дәһшәтен җәмәгатьчелеккә төшендереп бирүдә “Йәгез, бер дога!” романының (1994) әһәмияте аерата зур булды. Булачак язучы рәшәткәле вагоннарда, кысан машиналарда, урыны-урыны белән җәяүләп, “ристан” хәлендә Свердловск – Петропавел – Карабас – Актас – Волынка – Майкудун – Чиләбе төрмә-лагерьларын әйләнеп чыккан. Ни өчен утырткannар? Бары тик сталинчыл режимга битараф булганы, халыкны изүнең бу рәвешен хупламаганы, шуны ныгытуга өлеш кертмәве өчен. Егерме ике яшьлек егет яманаты чыккан илле сигезенче маддә буенча гаепләнә. Рәсми хакимиятнең тоткан юлына аңлы рәвештә каршы булган шәхескә әверелә. “Акылны төрмә кадәр баета торган мәктәп юк“, - ди ул.

Бу “мәктәп”тән А. Гыйләҗев менә нинди сабак алып чыга: “Октябрь – дөньяның иң кара сәхифәсе ул. Нәрсә ул пролетариат диктатурасы? Тормыш кануннарын ертып-ертып алга үткән берәүнең чикләнмәгән власте ул. Ил каршында да, Алла каршында да җавап бирмәячәк явыз шәхеснең өстенлеге”.

Моңарчы Октябрь инкыйлабы, хезмәт ияләре бәхете өчен ясалды, дип аңлатып киленде. Әмма бәхет кеше сөякләренә нигезләнә алмый.

Халыкның иң хезмәт сөючән, эш рәтен белүче, иң акыллы, иң сәламәт өлешен юк итеп төзелгән җәмгыять ничек итеп бәхетле дип атала алсын? Әйбәт әйберне бик тырышып мактауның кирәге булмый, ул үзе турында үзе сөйли.

Сталинның рухи атасы, алманлы яһүди К. Маркс – җәмгыятьне яңача үзгәртеп коруның иң олы юл күрсәтүчесе – явызлыкта шигърият күрде. “Россиянең татарларны яулап алуы – үтә уңай күренеш“ дип язып чыкты. Аның варислары да ул мактаган әлеге рәхимсез ысулларны (азчылык милләтләрне чәнечкеле биләйләр белән кысып тотуны) үзләренә мирас итеп кабул кылдылар. Явыз гамәлләрнең нигезен, шул рәвешле, явыз теория тәшкил итте. А. Гыйләҗев әсәрдә Көнчыгышның бөек фәлсәфәчесе Конфуцийның мондый сүзләрен китерә: “Черек агачтан асыл сурәтләр юнып булмый”. Шуның кебек , К. Маркснең талап алу сугышларын хуплавына корылган теориясе беренче социализм иленең үз эчендәге һәм аның тирәсендәге халыкларга күпме күз яше һәм җәбер китерде.

Кешелекнең яшәү рәвеше, гамәле, фәлсәфәсе – иң затлы тәгълимат – дингә нигезләнергә тиеш. А. Гыйләҗев әнә шундый нәтиҗәгә килә. “Динсез диярлек гаиләдә үссәм дә, - ди ул, - Коръән укый башласалар, тәнемә каз тиресе чыга. Тел музыкасын,

Коръән сүзләренең яңгырашын гипнозга тиңлиләр. Коръән аятьләре адәм улларын я кузгаталар, я тынычландыралар. Берәү дә битараф кала алмый". Язучы хаклы: Коръән Кәрим – кеше өчен туры юлның, изгелекнең, саф күңеллелекнең ачкычы, фатиха бирүче, юл күрсәтүче.

А. Гыйләҗев, үзе белән бергә җәбер-золымны, михнәт-хәсрәтләрне бүлешкән кешеләрне искә төшергәннән соң, "күчкәннәр һәм калганнар рухына", ягъни үлгәннәр һәм исәннәр намена дога кылырга өнди. Әсәрнең "Йәгез, бер дога!" дип исемләнүенең әнә шулай тирән мәгънәсе бар. Әйе, мондый кешеләр изге догага лаек, җаннары җәннәттә булсын.

Төштә генә күргәндә дә тетрәндерерлек мондый куркыныч хәлләр киләчәктә өндә була күрмәсен. "Кешеләр, сак булыгыз!" – дип әйтергә тели автор. Әсәрнең рухы шушы изге ният белән сугарылган. **(Белгән укучылардан догалар укытыла)**

**Алып баручы:** Без хәзер җәмгыятьнең сыйнфый яктан катлы-катлы булып әверелә баруын ачыграк тоябыз. Ләкин бу катлаулану җитмешенче-сиксәненче елларда ук барлыкка килгән иде. Ул чакта өстен катлау булган кешеләр моны бик үк күзгә ташламыйча эшләде. Хәзер исә шул ук кешеләр, пәрдәләргә төренмичә генә, меңнәрнең күз алдында, халык өлешенә кереп, байлык туплыйлар. Аяз Гыйләҗев боларны шактый элегрәк күрде, әсәрләрендә шуларны халык хөкеменә чыгарды. Бу аның соңгы утыз елда җәмгыятьне тирәнтен өйрәнүен, аңлавын күрсәтә иде. Ул өйрәнү бездәге социализмның күз буяу, алдау икәнлеген ачыклады, аның асылына төшендерде. Иҗаттагы гаделлеге аның каләмен саташтыра алмады. Аның әдәбиятта гына түгел, җәмгыятьтә тоткан урыны да әнә шуның белән билгеләнә.

А. Гыйләҗев әсәрләре – совет хакимияте чорының сәнгатьчә тарихы, ахыр чиктә аның ни өчен җимерелеп төшүенең сәбәпләрен тирән итеп аңларга ярдәм итә торган әдәби елъязма ул. Килер буыннар бу әсәрләргә еш мөрәҗәгать итәр әле. Чөнки аларның кыйммәте бүгенге көн белән генә чикләнми. А. Гыйләҗев чәчкән таза орлыкларның яңа буыннар күңелендә бәрәкәтле үсентеләр бирәсенә безнең ышанычыбыз зур.

Халикова Лиза Ахатовна,
«Джалильская СОШ№2», Сармановский район

## План-конспект классного часа «Их было четверо»

**«Классный час есть форма прямого общения воспитателя со своими воспитанниками».**

**В.П.Созонов**

Цель: расширить знания учащихся о писателях и поэтах родного края

Задачи: формировать чувства патриотизма, любви к родной земле, воспитывать уважение к своим корням; развитие уважительного отношения к старшему поколению; развивать познавательный интерес, интерес к истории и литературе родного края; прививать любовь к чтению; развивать речь, творческие способности детей.

Сегодня мы познакомимся с семьей творческих людей Гилязовых. Аяз Гилязов родился 17 января 1928 года в селе Чукмарлы в семье учителя. Детство провёл в деревне Верхний Баграж (Заинский район). Получил неполное среднее образование в местной школе. Вернулся в родной район, где закончил Сармановскую среднюю школу. В 1948 году поступил в Казанский государственный университет. В 1950 году был арестован и

сослан в карагандинский лагерь, где находился пять лет. В 1955 году был реабилитирован. После освобождения вернулся в Казань и продолжил учёбу. Через полтора года начал сотрудничать с журналами «Чаян» и «Азат хатын». Стал редактором отдела прозы журнала «Совет эдэбияты» (сейчас «Казан утлары»). АязГилязов в 1963 году окончил Высшие литературные курсы при СП СССР. После этого стал считаться профессиональным писателем. Писал рассказы, очерки, фельетоны, статьи. Позднее, излюбленным жанром Гилязова стала повесть. В 1958 году написал АязГилязев написал свою первую повесть «Их было четверо». Избранные произведения: «Три аршина земли» «Жемчужина Зая», «В середине», «За околицами луга зеленые», «Весенние караваны» «Диляра», «Любовь и ненависть», «В пятницу вечером», «Взлетел петух на плетень».

Награды и звания: заслуженный деятель искусств ТАССР (1978 г. – за заслуги в области литературы и искусства), Государственная премия Республики Татарстан им. Г. Тукая (1983 – за повести «В пятницу вечером» и «Взлетел петух на плетень»), заслуженный деятель искусств РСФСР (1985), Государственная премия РСФСР имени М. Горького (1987 – за сборник повестей «При свете зарниц»), народный писатель Республики Татарстан (1993 – за большие заслуги в развитии татарской литературы)

Одним из важнейших принципов в литературном творчестве А.Гилязова является категория нравственности. С этой категорией тесно связаны его основные идейно-эстетические взгляды.

В своем творчестве писатель исходит из основополагающего общечеловеческого принципа: нравственно то, что приносит людям счастье и радость. Вместе с тем, нравственное в произведениях А.Гилязова выступают разными своими гранями, в частности, образцом нравственности для него является чувство выполненного долга. Так, в повести "Четверо" тринадцатилетние подростки с гужевым транспортом возят хлеб на элеватор. Время военное. Мальчишки голодные, плохо одетые, возят последний хлеб колхоза, предназначенный для весеннего сева. Потому что фронт требует хлеба, без него победа невозможна. Юные герои повести это прекрасно понимают и всеми силами стараются выполнить возложенные на них важное задание. Будучи еще подростками, эти мальчики своим поведением демонстрируют не только зрелость, но показывают и высокую нравственность, понимание ответственной задачи того времени. При этом автор особо подчеркивает, ото нравственным ориентиром для этих мальчиков, взявших на свои хрупкие плечи основную тяжесть крестьянского труда того сурового времени, являются их отцы, героически сражающиеся на фронте с иноземными захватчиками. Воодушевленные ратными подвигами старших, мальчики тоже чувствуют себя бойцами, участниками общего дела. Свой гражданский и нравственный долг они видят в том, чтобы вовремя доставить в приемный пункт столь необходимый для фронта-хлеб.

Ради этого они жертвуют своим здоровьем, не жалеют сил и верят в то, что своевременно доставленное зерно тоже является могучим и грозным оружием в борьбе с фашистскими захватчиками. Высшим нравственным поступком этих голодных и оборванных мальчиков является то, что даже будучи на грани истощения, потери сил, они не трогают колхозного зерна, считая это позором, большим грехом в столь тяжелое для страны время. Возможно никто не осудил бы их, если бы они взяли из обоза чуть-чуть хлеба для того, чтобы немножко подкрепиться и лучше выполнить столь ответственное поручение колхоза и односельчан. Но мальчишки не допускают и мысли об этом. Вообще, эти полуграмотные мальчики отличаются целостностью характера и чистотой помыслов.

По убеждению А.Гилязова, корни нравственного подвига, нравственной чистоты его юных героев следует искать, прежде всего в народных традициях, в народной нравственности. Коллективный воспитатель – их отцы, матери, братья и сестры – формировали в их душах чувство красоты – могучий источник нравственной чистоты, духовного богатства. Благодаря им они научились видеть красоту окружающего мира, духовное благородство, доброту, сердечность и на основе этого утверждать прекрасное в самом себе.

Шайдуллина Ильмира Салиховна, Ахметгалеева Ландыш Зиннуровна,
«Джалильская СОШ №2», Сармановский район

## Листья мать-и-мачехи

### Внеклассное мероприятие для учащихся 5-7 классов

**Вид деятельности:** игровая, коммуникативная, трудовая, восприятие художественной литературы, познавательно- исследовательская.

**Программное содержание:**

Воспитывать уважительное отношение национальному и культурному наследию используя произведениетатарского писателя нашего земляка АязаГилязова «Мать-и-мачехи»**,** формировать у детей представление о первоцветах, закрепляя признаки ранней весны; познакомить детей с одним из первых первоцветов – «мать-и- мачехой», выявить роль в природе; воспитывать бережное отношение к растениям, желание заботиться о них.

**Планируемые результаты:** развитие интегративных качеств «любознательный, активный», «эмоционально отзывчивый», «овладевший средствами общения и способами взаимодействия со взрослыми и сверстниками».

***Материал:*** картинки с изображением мать – и – мачехи, её основный частей; презентация

***Предварительная работа:*** беседы о приходе весны, первоцветах, значении растений в природе и для человека; рассматривание картинок с изображением первоцветов, чтение художественной литературы о них.

*Цель:* развивать познавательный интерес к живой природе, наблюдательность, учить детей делать элементарные выводы.

*Игровая задача:* разгадать тайну природы.

Вступительное слово: В одном из ранних произведений А. Гилязова растительный образ вынесендаже в заглавие речь идет о рассказе «Листья мать-и-мачехи». Этот рассказ, незаслуженно и не замечанный литературоведами, является шедевром А.Гилязова. В нем с огромной психологической силой и поразительной тонкостью передана атмосфера свидания Галимзяна и Сюмаи, на котором молодой человек должен был сделать предложение своей возлюбленной. А.Гилязову удалось передать поэтичность натуры, чистоту, благородство героев и целомудренное сдержанность их отношений. Мотив первой любви сопроваждаются у татарского писателя неожиданным образов листьев мать-и-мачехи.

«Галимзян держал в руках растения мать и мачехи начал рассказывать.

- Кто нашел это название был поэтом. В основном наши дедушки были поэтами. Смотря на небо видели млечный путь и находили по нему большую медведицу. На землю смотрели на дне холодной ямы видели бесцветные листья и дали название им мать-и -мачеха.

- Странное имя …. - произнесла Сюмая

Галимзян продолжил свой рассказ. Это растение появляется в начале весны когда начинает таит снег.

- В некоторых деревнях называют его подснежниками. У нас называют «кимэшэбашы» мне кажется это означает слова «весна».

- Да я тоже видела цветок – желтый, растет около берега, - вспомнила Сюмая.

- Цветки есть, а листьев нет. Листья никогда не встречаются со цветком, когда появляются листья цветков уже не бывает,- произнес Галимзян.

Девушка спрашивает: - Никогда - никогда не встречаются? Очень жалко.

Они начали собирать эти таинственные холодные листья и от листьев пахло болотом. Галимзян протянул девушке листья и улыбаясь сказал:

- Вот возьми!»

Это отрывок из произведения АязаГилязова «Листья мать-и-мачехи»

Какие чувства вызвало у вас этот отрывок? Как вы думаете, о чем мы с вами сегодня будем говорить ?

Правильно о растении мать-и-мачехи.

**Почему цветок МАТЬ-и-МАЧЕХА так называется?**

**1 ученик:** Это растение настолько неприхотливо, что встретить его можно буквально везде, особенно на пустырях, на песчаных берегах, вдоль железнодорожных насыпей.

- Не правда ли, очень интересное название у этого растения? Есть несколько легенд о происхождении этого цветка, все они связаны с несчастной материнской любовью. Вот одна из них.

Легенда гласит, что давным-давно мужчина полюбил другую женщину и ушел из своей семьи. От прежней семьи у него осталась доченька с чудесными желто-золотистыми волосами. Новая жена сильно заревновала к свое дочери и решила ту просто убить. Заманила ребенка на крутой обрыв и толкнула вниз. Мать увидела, что дома доченьки нет, и побежала ее искать. Нашла, к сожалению, мертвую. Забежала она в дом к мачехе и притащила ее к обрыву. А потом в женской борьбе обе упали с обрыва.

Вот и выросли на этом месте маленькие золотисто-желтые цветочки под стать златокудрой девочке.

Правда эта была или всего лишь вымысел людей, однако название растения может быть произошло из-за особенностей строения его листьев... Листья у мать-и-мачехи крупные, необычные: сверху они зеленые, гладкие, жесткие, холодные как злая мачеха а снизу беловатые, покрытые мягкими волосками и как будто теплые нежные как родная мать. За эти особенности растение получил свое имя. Латинское название растения означает «Выводящее кашель». Народные названия: подбел, камчужная траваЯвляется первоцветом. Первоцветы - это первые растения, которые зацветают ранней весной.

**2ученик:** (где произрастает?) Мать-и-мачеха появляется в середине апреля. Распространена почти на всей территории европейской части СНГ, на Кавказе, в Сибири и Средней Азии.

Растет на влажных глинистых почвах по обрывистым берегам рек и ручьев, на пустырях, мусорных местах, откосах дорог и насыпей, лесных полянах, опушках, выработанных карьерах, осушенных болотах. Довольно часто образует сплошные заросли.

Оказывается, в земле у этого растения находится толстое корневище с богатым запасом питательных веществ. Этот запас растение сделало летом. Корневище

расположено неглубоко в земле. Весной, как только прогреется верхний слой почвы, из цветочных почек корневища развиваются цветочные побеги и появляются желтенькие цветочки мать-и-мачехи. Когда цветы отцветают, на их месте появляются шарики-пуховики, как у одуванчика, только поменьше. После увядания цветов уже из других почек корневища вырастают новые побеги с большими зелеными листьями.

**3 ученик: (**значение для человека) Используется со времен Древнего Рима. Это растение широко применяли Диоскорид, Плиний, Гиппократ.

Применяется как лекарственное средство. В медицинской практике листья растения применяются при бронхитах, ларингитах, как отхаркивающее и противовоспалительное средство, а также при желудочно-кишечных заболеваниях как вяжущее.

Благодаря содержанию в листьях значительного количества слизи мать-и-мачеха оказывает обволакивающее действие на слизистые оболочки рта, горла и гортани, защищая их от раздражения. В народной медицине отвар, настой, сок - при туберкулезе легких, бронхиальной астме, бронхите, плеврите, воспалении легких, насморке, гриппе, воспалительных процессах полости рта, зубной боли, артрите, миозите, аллергии, эпилепсии, малярии, отеках, одышке, желудочно-кишечных заболеваниях, язвенной болезни желудка, катаре желудка, болезнях сердца, мочевого пузыря, почек; наружно - при кожных болезнях, мастите, фурункулах, рожистом воспалении, язвах, ожогах, а также для укрепления волос и при обильной перхоти. Измельченные сухие листья курят при одышке, затрудненном дыхании и для уменьшения зубной боли.

**4 ученик:** (значение для животных) Растения являются убежищем для насекомых и кормом. Всю зиму животные ничего вкусного и свежего не ели.

Медонос, дает пчелам нектар и пыльцу, особенно в то время, когда в природе нет никакого взятка.

В ветеринарии - при заболеваниях органов пищеварения и дыхания, а также наружно при ушибах, гноящихся ранах, воспалениях кожи.

**5. Физкультминутка.**

| | |
|---|---|
| Как прекрасны и просты<br>Мать-и-мачехи цветы, | Развести руки в стороны. |
| Вырастают из-под снега,<br>Как забытые мечты. | Присесть, затем подняться на носки. |
| Среди улиц и полей,<br>Средь берёз и тополей, | Махи руками вправо, влево. |
| Словно солнечный брызги<br>На проснувшейся земле. | Руки на поясе, прыжки вокруг себя. |
| Не ярки, не горячи,<br>Льют горячие лучи, | Круговые вращения руками. |
| И сидят весёлой стайкой,<br>Как весенние грачи. | Присесть, обхватить колени. |
| Тихой нежности полны,<br>Хрупкой прелестью сильны – | Встать, потянуться, руки в стороны и вниз. |
| Любопытные глазёнки<br>Новорожденной весны… | Повороты головы вправо, влево. |

**Мы рассмотрели строение, применение растения мать-и-мачехи. Давайте сейчас познакомимся с биографией Аяза Гилязова, который использовал и назвал свое произведение именем этого цветка.**(Дается информация про писателя).

**Дидактические игры**

1. Кто быстрее? Собирать мозаику

*Материал для игры:* карточки с изображением растений (по нескольку карточек каждого растения).

Ход игры: Нужно раскладывает карточки с изображением разных растений. Называет одно из имеющихся растений. Например, мать -и -мачеха. Дети собирают все карточки с изображением мать и мачеха.. Побеждает тот, кто быстрее найдет названное растение.

2. Найди по описанию.

*Материал:* карточки с изображением растений.

Ход игры: Ведущий называет характерные особенности растения мать и мачехи, не называя его. Дети отыскивают его изображение среди карточек. Побеждает тот, кто быстро и правильно найдет или назовет отгадку.

3. Художники.

Ход игры: «Художник» принимает заказ — нарисовать «портрет» того или иного растения и старается точно передать особенности внешнего вида. По окончании работы организуется выставка рисунков.

**А сейчас давайте отгадаем загадки:**

1.Я знаменита не цветами,
А необычными листами:
То твердыми, холодными,
То мягкими и теплыми. ( Мать-и-мачеха)
2.Золотым лучом согрет
Вырос солнышка портрет!
Но у желтого цветочка
Временно листочков нет (Мать-и-мачеха)
3.Жёлтый глаз из-под земли
Первым дарят нам они.
Как их правильно назвать,
Если им земля, как мать? (Мать-и-мачеха)
4.Появись на пригорке
Желтенькие точки,
Это солнцу улыбнулись,
Первые цветочки (Мать-и-мачеха)

**Учащиеся читают стихи про мать-и-мачеху Л. Акиншина**

**1 ученик:**

Мать-и-мачехи цветки
Словно солнца огоньки.
На пригорочкерастут,
Прям из снега - и цветут! **(Л. Дунина)**

**2 ученик:**

На опушке - огоньки,
Целая проталинка.
Коротышки стебельки
И цветочек маленький.
Листьев нет - она цветёт,

Холодом охвачена.
Пчёлкам самый ранний мёд
Дарит мать-и-мачеха. **(Джулия Рум)**

3 **ученик:**

4 Огонечки желтые
Из сухой травы.
Это мать-и-мачехи
Первые цветы.
Солнышко пригрело
И растаял снег.
Желтые цветочки
Солнышка привет.
Мать-и-мачеха проснулась,
Приоткрыла жёлтый глаз,
Потянулась, оглянулась...
- Снег? В апреле? Вот те раз!...
Возмутилась Медуница:
- Так не долго простудиться!
Я по плечико в снегу -
Распуститься не могу!...
Отступать, Весна, не гоже!
Разберись-ка ты с Зимой!
Будь с упрямицей построже -
Прогони её домой!

**(Лернер)**

**4 ученик:**

Как прекрасны и просты
Мать-и-мачехи цветы,
Вырастают из-под снега,
Как забытые мечты.
Среди улиц и полей,
Средь берёз и тополей,
Словно солнечный брызги
На проснувшейся земле.
Не ярки, не горячи,
Льют горячие лучи,
И сидят весёлой стайкой,
Как весенние грачи.
Тихой нежности полны,
Хрупкой прелестью сильны –
Любопытные глазёнки
Новорожденной весны…

**(А. Полетаева)**

**5 ученик:**

Как странно, листочек большой,
Пушистый внутри, очень гладкий снаружи,
Нашли на опушке лесной.
Он рос там, в траве, возле лужи.
«Растение это – всем нужно!» -
Сказал, очень гордо мне дед.
«Для тех, кто случайно простужен,
Лекарства безвреднее – нет!
Но, скрыта в листочках загадка,
Сейчас помогу отгадать!
Ведь с той стороны, где так гладко -
Его станут мачехой звать.
Пушистая - матерью будет!
Недаром сумели назвать,
Его мать – и – мачехой люди.
Теперь вот и ты, будешь знать!»

**(А. Максакова)**

**6 ученик:**

Снег лежит ещё, не тает.
Солнце сильно пригревает.
Слышен птичьей шум и гам.
То скворцы слетелись к нам.
На кустах набухли почки.
И покрылись травкой кочки.
Распускается цветок,
Словно желтый огонек.
**Мать- и- Мачеха** назвали.
Дети все узнали.
Значит к нам пришла весна.
Долгожданная она.

**Заключение:** Мать-и- мачеха - первоцвет, поэтому появление в конце марта-начале апреля среди снега на проталинах,,на кручах и склонах первых желтых цветков этого растения считается в средней полосе верным первоуказателем теплых дней. Образ этого

растения в произведении А.Гилязова не просто деталь повседневной жизни героев. Мы узнаем о том, что мать и мачеха растет не только на склонах оврага, по дну которого течет река родник Хайри, но и по берегам речушки Чюке, недалеко от деревни. Образ растения у автора приобретает символическое значение. А. Гилязов в своем произведении изображает, как под влиянием любви преображается окружающий мир, да и сами герои.

Шакирова Эльмира Финус кызы, Зиннәтуллина Лилия Ринат кызы,
Җәлил гимназиясе, Сарман районы

**Аяз Гыйләҗевнең тормышы һәм иҗатына багышланган
"Тамчы-шоу" интеллектуаль күңел ачу бәйгесе**

**Максат**: Прозаик һәм драматург Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев турында булган белемнәрне тирәнәйтү, иҗатына кызыксынуны арттыру. Укучыларның иҗади сәләтләрен, активлыкларын һәм фикерләү сәләтен үстерү. А. Гыйләҗев иҗатына карата соклану һәм районадашыбыз белән горурлану хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлау:** проектор, ноутбук, өстәлләр, ак битләр, каләмнәр, А. Гыйләҗев портреты, китаплар күргәзмәсе, презентацияләр.

**Алдан эшләнгән эш:** А.Гыйләҗевнең тормышы, иҗаты һәм әсәрләре белән укучыларны таныштыру.

**Уен барышы**

**Алып баручы.** Хәерле көн, хөрмәтле укучылар, укытучылар! Бүген биредә Аяз Гыйләҗев иҗатын яратучы, әдәбият белән кызыксынучы укучылар җыелган. Кичәдә 5 әр укучыдан торган 2 команда А.Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗаты буенча үзара көч сынашачаклар.Ә без аларга бары тик күтәренке кәеф, уңышлар теләп калабыз.

Ә хәзер командалар үзләренә исемне А.Гыйләҗевның бер әсәреннән табалар. Бу әсәрдәге төп геройларның исемнәрендә хәрефләр буталып бирелгән. (ы р а и х ф м т й ныкылар, и ә т л ә д х н с е н некеләр ) Хәрефләрдән сүзләр төзергә, девиз уйларга, эмблема ясарга. (Командалар әзерләнә.)

**Алып баручы.** Сарман ягы күренекле шәхесләре белән бөтен тирә-якка билгеле як. Сарман дигәндә, данлыклы "Сарман" җыры искә килеп төшә:

Сарман буйларында яшел алан
Печәннәре җитәр бер заман ... (Җыр яңгырый.)

Шушы җырны ишетү белән үк Сарман буйларына чыгасы, аның табигатенә сокланып йөрисе, кешеләре белән аралашасы килә. Туган ягын яратмаган, аның матурлыгына сокланмаган кеше бар микән?! Күренекле әдипләре, мактауга лаек шәхесләре булса, мондый горурлык хисе бермә-бер арта. Сарман төбәгеннән никадәрле күренекле шәхесләр чыккан. Аяз Гыйләҗев – искиткеч талантлы һәм гаять үзенчәлекле әдипләребезнең берсе. Аның тормыш юлы да бик гыйбрәтле.

Аяз Гыйләҗев әсәрләренең тәрбияви кыйммәте әйтеп бетергесез зур. Алар – безнең милләтебезнең рухи байлыгы, милли үзенчәлекләре турында чорыбыз вакыйгаларына бәйләп язылган әдәби әсәрләр. Язучының халык тәҗрибәсенә нигезләнгән иҗтимагый – фәлсәфи карашлары безне яхшыны яманнан, дөреслекне ялганнан аерырга өйрәтә. А.Гыйләҗевнең омтылышлары, идеяләре, фикерләре бик актуаль, алар бүгенге көннең проблемалары, әһәмиятле мәсьәләләре белән авазадаш. (Презентация күрсәтелә.)

**Алып баручы**. Сәламләү һәм үзләре белән таныштыру өчен сүзне командаларга бирәбез.

**1 нче команда.** Безнең исем - “Мирфатыйхныкылар”. Безнең девиз: “Без тырыш, без җитез, барысын да белербез бик тиз”. Эмблема: лимон төсле Жигули.

**2 команда**. Безнең исем - “Сәләхетдиннекеләр”. Безнең девиз: “Уйларбыз, белербез, биеккә менәрбез”. Эмблема: чия төсле Москвич.

**Алып баручы.** Әйе, А. Гыйләҗевнең “Әтәч менгән читәнгә” әсәрендәге элек дус, ярдәмләшеп яшәгән күршеләр, Мирфатыйх белән Сәләхетдин арасындагы читән биегәя, аның арасыннан кояш та үтми башлый. Тупланган байлык аркасында башка нәрсәләргә күзләре капланган ике гаилә үзара дуслык киртәләрен дә атлап чыга. Сәләхетдиннәр һәм Мирфатыйхлар гаиләсе йөрешми башлый, берсен-берсе узып яшәргә керешә. Гаиләдә һәр кеше конфликтка керә. Әйдәгез, күмәк уеныбыз белән күршеләрне дуслаштырыйк әле.

**Алып баручы.** Шулай итеп, беренче турга кереп китәбез.

**I тур “Батыр- берне, белемле - меңне егар!”**

I турда командаларга 10 сорау бирелә. Кайсы команда беренче төймәгә баса, шул командадан бер укучы җавап бирә. Команда дөрес җавап бирмәгән очракта, каршы команда җавап бирә ала.

1. А.Гыйләҗев кайчан һәм кайда туган?
2. Балачак еллары кайда уза?
3. Әти-әнисенең исемнәре ничек?
4. Аяз урта мәктәпне кайда тәмамлый?
5. Ул кайчан КДУга укырга керә?
6. А.Гыйләҗевне кайчан кулга алалар?
7. Тоткынлыкта кичергәннәре турындагы әсәрен атагыз.
8. Тоткынлыкта бергә булган венгер дустының исеме ничек?
9. Нинди әсәрләре өчен А.Гыйләҗев 1983 нче елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була?
10. Кайчан “Татарстанның халык язучысы” дигән мактаулы исем бирелә?

**Алып баручы:** Безнең беренче турыбыз тәмам. Сүз жюрига бирелә.

**II тур. “А. Гыйләҗев истәлекләреннән.”**

**Алып баручы**. Чираттагы турның шарты: әлеге фотолар турында кыска һәм аңлаешлы итеп әйтергә. Сүзне бәйгечеләребезгә бирәбез. **Экранда фотолар:**

1.



2.



3.



4.



5.



6.



7.



8.



1. Мирсәет һәм Мөгаттәрә Гыйләҗевләр уллары Аяз, Алмаз һәм Азат белән.
2. Аяз – студент.
3. Аяз Багражда салдырган йорт.

4. Аяз – сәяси тоткын.
5. Аяз Гыйләҗев тормыш иптәше Нәкыя апа белән.
6. Уллары: Мансур, Рәшат, Искәндәр.
7. «Йәгез, бер дога!» исемле романның герое – венгрияле Арпад Галгоци А. Гыйләҗевнең улы белән.
8. А. Гыйләҗев балалары һәм оныклары белән.

**III тур. “Кем җитезрәк?”**

**Алып баручы.** Ә хәзер А.Гыйләҗев әсәрләреннән өзекләр яңгырар. Сүз кайсы әсәрләре турында барыр икән?

1.“...Бүген җомга көн. Бүген ул тып-тыныч. Тыныч диярлек. Ниһаять, үзенә язганны башкарды, дөньядагы барлык бурычын үтәде. Балаларына да ачу сакламады ул, Зөһрәбануны да кичерде...” ( А.Гыйләҗев “Җомга көн, кич белән”)

2.“...Хатыннар Сабирәттәй чанасы тирәсенә җыйналгач, мин үзебезнең өс-башыбызның нинди таланган, йолкынган иске-москы булуына игътибар иттем. Ябык идек без, ямьсез идек. Кояшлы март көнендә, тау өстендәге ап-ак кар арасында барсы аермачык күренде, йончыган идек без, арыган идек...” (А. Гыйләҗев “Язгы кәрваннар”)

3.“...Милләтнең иң зур байлыгы – хәтер. Уртак хәтерсез милләтләр, милләт булудан туктап, гавам, халык төркеменә әйләнәләр... Милли хәтер бары тик үз җирендә бердәм булып яшәгәндә генә саклана ала һәм буыннар дисбесенең бөтенлеген, тулылыгын саклый...” (А. Гыйләҗев “Йәгез, бер дога!”)

4. “... Китте кытаклау, купты тавыш, кузгалды ыгы-зыгы, әкәмәт! Моңа күрше-тирә этәчләре дә игътибар иттеләр: муеннарын сузып күкне күзәттеләр - тилгәннәр эскадрильясы очып килгәнме әллә?! Уңнан да, сулдан да йомылып этәчләр чаба башлады. “Бүгеннән Югары очта беренчелек миндә!” дип шауладылар алар, бер-берсенең күзен чокып алырга әзер торып. Түшләр киерелде, бугазлар бушады...” (А.Гыйләҗев “Этәч менгән читәнгә”)

**IV тур. “Сүзләр җыябыз”**

**Алып баручы.** Слайдка күз салыгыз әле. Анда хәрефләр бирелгән. Шул хәрефләрдән нинди сүз килеп чыгар? **МРЧЫУАКЛ - Чукмарлы**

**Алып баручы.** Сүз әйтелде. Ә хәзер сез бу хәрефләрдән яңа сүзләр төзергә тиеш буласыз. Сезгә бер минут вакыт.

**Алып баручы**. Вакыт бетте. Ә хәзер кара-каршы берәмләп төзелгән сүзләрне әйтә барабыз. Чукмар, чук, ук, ар, ул, алу, ука, урак, умач, уч, Ык, кура, ... (Сүзләр әйтелә, жюри нәтиҗә чыгара)

**V тур “Хаталарны тикшерү”.**

“Җөмга көн, кищ белән”,
“Этәщ менген читәнгә ”,
“Мәхәббәт хәм нәфрәт”,
“Мен чакырым юл”,
“Жиз кыңгырав” әсәрләре. ( Нәтиҗә ясала.)

**VI тур. “Тиз җавап”. Капитаннар бәйгесе.**

Бирелгән сорауларга капитаннар “Әйе”, “Юк” сүзләре белән җавап бирәләр.

**1 команда капитанына сораулар:**

1. Аяз Гыйләҗевнең 3 кызы бар. (Юк)
2. Ул 1928 нче елда туа. (Әйе)
3. Аяз сүзендә 3 иҗек бар. (Юк)

4. Язучы Зәйдә туган. (Юк)
5. Аяз Гыйләҗев сәхнә әсәрләре дә язган. (Әйе)
6. Гыйләҗев Моабит төрмәсендә утыра. (Юк)
7. А. Гыйләҗевнең тормыш иптәше –Нәкыя. (Әйе)
8. Аяз көйләр дә язган. (Юк)
9. “Өч аршин җир ” әсәрен А.Гыйләҗев язган. (Әйе)
10. Ул М.Горький исемендәге премия лауреаты. (Әйе)

**2 нче команда капитанына сораулар:**

1. Чукмарлы авылы Зәй районында. (Юк)
2. А.Гыйләҗевнең 3 улы бар. (Әйе)
3. Нәкыя сүзендә 2 иҗек бар. (Юк)
4. Язучы Югары Багражда туган. (Юк)
5. Бибинур – А.Гыйләҗев әсәренең герое. (Әйе)
6. Язучы Казахстанда тоткынлыкта була. (Әйе)
7. А. Гыйләҗевнең улы –Искәндәр. (Әйе)
8. А.Гыйләҗев балалар өчен бик күп әкиятләр язган. (Юк)
9. А. Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәре бар. (Әйе)
10. А. Гыйләҗев – Татарстанның халык рәссамы. (Юк)

**Алып баручы.** Уен барышында безнең “күршеләребез” дә дуслашты. А. Гыйләҗев “Әтәч менгән читәнгә” әсәрендә авылның, аның һәр кешесенең аерым көнен дә, үзара мөнәсәбәтләренең ерак тарихын да тасвирлый, милли йола күренешләренә (әйтик, Сабантуйга), аларны ямьсезләндергән хәлләргә дә зур урын бирә. Ул – кыю каләмле язучы. Ул хөкүмәт, җитәкчеләр, кешеләр тарафыннан җибәрелгән хаталарны әсәрләре аша искәртә, җитди сәяси, әхлакый һәм милли проблемаларны укучы алдына куя. Ул татар милләтенең киләчәге өчен борчыла. Бер әңгәмәсендә ул болай ди: "Мин язуын яздым, менә шуларны укырлык татар кешесе булырмы? Менә нәрсә борчый мине”. Үз милләте өчен янып-көеп яшәгән бөек шәхесне зурлау, якташыбызның иҗатын онытмау, аның бай мирасын киләчәк буыннарга җиткерү бездән тора. Халык көче – бердәмлектә! Ә берләшер өчен бер-беренә читән аша кул сузу да җитә.

Кичә “Күршеләр” җыры белән тәмамлана. (Л.Вилданова көе, Ф.Рәхмәтуллин сүзләре).

**Алып баручы.** Сүз жюрига бирелә. Бүләкләү тантанасы.

Адлер Эльвира Демьян кызы, Загитова Ләйлә Азгар кызы,
Актүбә 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Азнакай районы

## Дүрт аяклы дустыбыз
## (Тәрбия сәгате)

**Максат:** Аяз Гыйләҗевнең “Муйнак” хикәясе аша укучыларга кече туганнарыбызның кеше тормышындагы роле турында аңлату; Аяз Гыйләҗевнең әсәрләренә кызыксыну үстерү, үз фикереңне дөрес итеп җиткерә белү; Этләр турында белемнәрен тагын тирәнәйтү, этләргә хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлау**: Аяз Гыйләҗев китапларыннан күргәзмә, А. Гыйләҗев портреты, “Йорт җәнлекләре-безнең тормышта” презентация.

**Тәрбия сәгате.**

Хәерле көн, укучылар! Менә тагын бер якты көн туды, без шуңа сөенеп, сәламәтлек, шатлык-куанычлар белән дәресебезне башлыйбыз.

Йорт җәнлекләре турында әңгәмә. Презентация карау

Этләр һәрвакыт кешеләргә хезмәт итәргә әзер. Кайда гына хезмәт итмиләр икән этләр! Чигебезне явыз дошманнардан гына түгел, наркотиклардан да саклыйлар. Коткаручы этләр дә бар. Алар суга батучыларга, янгын вакытында авыр хәлдә калган, адашкан һәм төрле һәлакәткә очраган кешеләргә ярдәмгә киләләр. Кайбер этләр көтү көтәләр. Сукыр һәм инвалид кешеләргә хезмәт күрсәтүче этләр дә бар. Бөек Ватан сугышында этләр яралы солдатларга санитарлардан да алдан ярдәмгә килгәннәр. Тәннәренә граната бәйләнгән этләр дошман танкларын шартлатканнар. Хуҗасын саклар өчен үз-үзен корбан итүче этләр дә бик күп.

Кеше этләрнең өч йөзләп токымын китереп чыгарган. Аларның барысының да борынгы бабасы бүре булуга ышануы да авыр. Эт асраучылыкның хуҗалыкта әһәмияте зур. Аучылар һәм эт яратучылар белән беррәттән, эт асраучы меңләгән малайлар һәм кызлар үзләренең дүрт аяклы дусларын мавыгып үстерәләр, тәрбиялиләр һәм өйрәтәләр.

Буген без дәрестә хуҗасына тугрылыклы эт турында укырбыз. Аяз абый Гыйләҗев язган “Муйнак” хикәясе акыллы, яхшыны яманнан аера белә торган эт турында.

Хикәяне берничә кисәккә бүлеп укырга тәкъдим итәр идем.

**1. Муйнак белән Хәлимнең дуслыгы.**

Беренчедән, эт – кешенең иң якын һәм тугры дусты. Ул беркайчан да дустына, хуҗасына хыянәт итми, аны сатмый, алдамый. Юкка гына "Эт – кешенең дусты" дип әйтмиләр.

**2. Муйнакның авыл кешеләре арасындагы хөрмәте.**

Муйнакны бу гаилә кешеләре генә түгел, күршеләр һәм дуслар да бик ярата. Бөтен кеше яратса да, аның өчен иң җаваплы кеше – малай һәм аның бәхете тулысынча Хәлимгә бәйләнгән. Әгәр дә малай Муйнакны ашатырга онытса, бу инде чүп чиләген түгеп керергә оныту гына түгел, ә яраткан хайваны ачлыктан тилмерәчәк дигән сүз. Әгәр дә ул авырып китеп, малай аны вакытында дәвалый алмаса, ул үлеп тә китәргә мөмкин бит. Димәк, йорт хайваны тоту бик җаваплы һәм җитди эш.

**3. Муйнакның Таҗетдинны яратмавы.**

Кайчакта җылы хисләр җитми. Күп кенә кешеләр үзара тупас сөйләшә, ярдәмнең ни икәнен белми, әдәплелекнең бер кешеләргә этләрнең сыйфатлары җитми. Кешелеклелек, ярдәмчел булу, бер-беребезгә карата генә сыйфаты да юк аларда. Ә этләрне шәфкатьле, тугры булырга беркем дә өйрәтми. Алар үзләре теләп безнең өйне саклыйлар, сәбәпсез беркайчан да кешегә усал итеп өрмиләр.

**4. Муйнак белән Таҗетдин арасында дошманлык.**

Яхшы күңелле кеше белән усал кешене аера беләләр этләр, чөнки кайбер кешенең аягына сыдырылып йөриләр, ә кайберәүләрнең янына да килмиләр. Кемнең кем икәнен шуннан да чамалап була инде! Кешеләр арасында шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек күбрәк булсын иде!

**5. Таҗетдинның Муйнакны харап итүе.**

Куркак кеше үзеннән көчсезне юлыннан алып ташлап җиңдем дип күкрәк кага.

**6. “Чүмеч” Таҗетдинының кыңгыр эше.**

Кыңгыр эш кырык елдан сон да беленә, ди татар мәкале. Күңеле начар, гамәлләре ямьсез кеше җир йөзендә яшәгән вакытта үз җәзасын ала.

**Муйнак –тыйнак эт. Муйнак - шаян эт. Муйнак - гадел эт. Муйнак – акыллы эт- җөмләләренә хикәядән мисаллар китерергә.**

Аяз Гыйләҗевнең хикәяләрендә йорт җәнлекләре аерым бер урын алып тора. “Муйнак” хикәясе этләрнең кешеләргә тугрылыклы булулары, күңеле начар кешене аера белүләре, үзенә яхшы мөгалләмәдәге кешеләргә ничек кенә булса да яхшылык эшләргә теләве, кешеләргә ышанулары турында. (Укучыларның дәрескә карата фикерләре).

**Тугры дус.** Этләрнең тугры дус булулары турында китаплар укыганым, кинофильмнар караганым бар минем. Шуларның иң истә калганы "Белый Бим − черное ухо" дигәне булгандыр. Бим дигән эт хуҗасына тугры булуы аркасында күп җәфалар күрә. Бу фильм кешеләрнең дә төрле булуын күрсәтә. Берләре – шәфкатьле, эткә ярдәм итәргә тырышалар. Икенчеләре исә – рәхимсезләр. Алар Бимны үлемгә дучар итәләр. Мин бу фильмны һәммә кешегә, олысына да кечесенә дә карарга (яки китабын укырга) киңәш итәр идем. Кайсыдыр илдә хуҗасына тугры булган эткә һәйкәл дә куелган диләр.

Сез өегезгә эт алып кайттыгыз икән, ул сезне үзенең хуҗасы итеп таный. Кая барсагыз да, ул сезнең белән бергә булыр, сезнең хакка теләсә нинди авырлыкка да түзәр. Сезне яклар, саклар, чөнки эт – кешенең турылыклы дусты. Ләкин сездә алар турында кайгыртырга, аларны дөрес ашатырга һәм карарга кирәклеген онытмагыз.

**Миңа эт нигә кирәк?** Беренчедән, мин үземнең этем булуын телим. Минем аны үземчә тәрбиялисем килә. Мин эт тәрбияләү турында күп китаплар укыдым. Этләрнең нинди нәселдән булулары, үзенчәлекләре турында язылган язмаларны да җыеп барам. Димәк, мин этләр турында күбрәк беләм һәм шуңа күрә миңа нәкъ менә эт кирәк.

Икенчедән, минем этләрне өйрәтәсем килә. Эт өйрәтүчеләрне дрессировщиклар диләр. Минем "Ко мне, Мухтар" фильмындагы кебек, этне төрле әмерләремә буйсынырга өйрәтәсем килә. Бу бит шундый кызыклы шөгыль. Менә шуңа күрә мин әти-әниемнең миңа эт бүләк итүләрен телим.

**Минем этем.** Безнең Актырнак исемле этебез бар. Ул түп-түгәрәк, кап-кара, бик матур көчек. Йоннары ялт-йолт итеп тора. Артык зур да түгел. Тәпи очлары ап-ак, башында да ак тап бар. Тәпиләре ак булганга, без аңа Актырнак дип исем куштык та инде.

Без аны җылы сөт белән дә, тәмле аш, файдалы боткалар белән дә сыйлыйбыз. Ул, рәхмәт әйткәндәй, шатланып койрыгын болгый. Алгы тәпиләрен күтәреп иркәләнә. Мин аны һәркөн урамга алып чыгам. Үзе бәләкәй генә булса да, ул бик җитез, тиз йөгерә. Ул урамда артымнан чаба, өрә һәм минем белән шатлана-шатлана уйный. Без аны бик яратабыз.

Актырнак юынырга бик ярата. Ул тәмле итеп сөяк белән аш ашый. Мин аны кечкенәдән төрле һөнәрләргә өйрәтә башладым. Мин берәр җирдән кайтсам, ул мине шатланып каршы ала, басып, битемне ялый; күрешергә кулымны сузсам, тәпиен бирә. Минем төрле әмерләремне дә үти: бас дисәң – баса, утыр дисәң – утыра, ят дисәң – ята. Безгә чит кеше килүен әллә кайдан сизеп ала, өрә башлый. Каргаларны бер дә яратмый ул. Биби, чебиләрне алып китәрләр дип курка, ахры.

Мин Актырнакны үзем белән урманга алып барам. Монда ул үз тавышьгаа үзе сокланып йөри. Бик каты өрә. Урманның эченә үк кереп, әллә кайнардан әйләнеп кайта. Миңа нәрсәдер ашыгып-ашыгып сөйләргә тели. Бик кызык эт ул. Миңа аның белән бик күңелле.

**Этләр яхшылыкның кадерен белә.** Ничек яратмыйсың инде шундый тугры дусларны! Тик кешеләр кайвакыт үзләренең тугры дусларын ташлыйлар. Хуҗасыз калган этләр урамда ачлы-туклы яшәргә мәҗбүр булалар. Урамда шундый этләр күргәч, күңелемә авыр була. Шундый этләр өчен приютлар күбрәк ачылса, әйбәт булыр иде.

Чернова Ирина Григорьевна,
Сарсаз-Баграж төп гомуми белем мәктәбе, Зәй районы

# Аяз Гыйләҗев “Язгы кәрваннар” әсәре

| **Тема** | **Аяз Гыйләҗев “Язгы кәрваннар” әсәре** |
|---|---|
| **Максат** | 1. Укучыларны язучы иҗаты һәм тормыш юлы турындагы белемнәрен тулыландыру;<br>2. Аларда мөстәкыйль танып бирү һәм иҗади фикерләү сәләтен үстерү;<br>3. Халкыбызның үткәненә тирән ихтирам, кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләү. |
| **Бурыч** | Укучыларның фикерләү активлыгын, сөйләм телен үстерү.<br>Укучыларда УУГ (танып белү, регулятив, коммуникатив, шәхескә кагылышлы) формалаштыру. |
| **УУЭ** | *Шәхескә кагылышлы УУГ:* укучының башкарган эшенә җаваплылык хисен арттыру.<br>*Регулятив УУГ:* хәл ителгән һәм хәл ителергә тиешлене чагыштырып, уку бурычларын кую; максатны гамәлгә ашыру чараларын сайлап алу һәм аларны куллану; бәяләү.<br>*Танып белү УУГ:* тиешле мәгълүматны табу һәм аерып алу; төрле рәвештә бирелгән мәгълүматны кабул итү һәм укыганны анализлау.<br>*Коммуникатив УУГ:* башкаларның сөйләмен ишетү һәм тыңлау; үз фикерләренә ышандыра белү; иптәшеңне тыңлап, фикереңне тулы һәм аңлаешлы итеп әйтеп бирә белү. |
| **Төп төшенчәләр** | Сюжет, матурлык, лирик герой, әсәр эчтәлеге. |
| **Предметара бәйләнеш** | Татар теле, әхлак тәрбиясе |
| **Төп ресурслар**<br><br>**Өстәмә ресурслар** | Куллану өчен дәреслек*:*Әдәбият: А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Ә.Ганиева, 8 нче сыйныф өчен дәреслек-хрестоматия<br>*Техник чаралар:*Компьютер, экран, проектор, презентация. |
| **Эшчәнлекне оештыру формасы** | Фронталь, индивидуаль, парлап, төркемнәрдә эш. |

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** |
|---|---|---|
| **1 этап. Оештыру өлеше, мотивация.**<br>**Максат: дәрестә укучылар белән уңай психологик халәт тудыру** | Хәерле көн, укучылар! Әйдәгез әле, кулларыбызны тотышыйк та күңелдән генә бер-беребезгә изге теләкләр телик, дәрестә ярдәм итик. Бер-беребезгә карап, елмайыйк әле, бүлмәбез шатлык хисе белән тулсын.<br>Укучылар, әйтегез әле, нинди теләкләр теләдегез?<br>Мин дә сезгә уңышлар телим. Дәрестә игътибарлы булыгыз, бер-берегезгә ярдәм итегез, актив катнашыгыз.<br>Дәрестә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре искә төшерелә, аларның ни өчен кирәклеге кабатлана. | Укучылар кулларны-кулга тотынышалар, күңелдән генә бер-берсенә изге теләкләр телиләр. Бер-берсенә карап елмаялар.<br><br>Берничә укучы теләкләрне кычкырып әйтәләр. |
| **2 этап. Актуальләштерү.**<br>***Максат: бүгенге темага нигез булырлык итеп, үтелгәнне кабатлау.*** | - Без сезнең белән үткән дәрестә А. Гыйләҗев һәм аның иҗаты белән таныштык.<br>Татарстанның әдәби җәмәгатьчелеге Аяз Гыйләҗевне талантлы һәм үзенчәлекле прозаик, хөр фикерле, кыю каләмле әдип, кызыклы драматург, кыскасы, зур язучы дип таныды. Бу әдипнең исеме Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Мөхәммәт Мәһдиев кебек классикларыбыз белән бер рәттә торырга лаеклы.<br>Аяз Гыйләҗев татар әдәбиятын уй-фикерләрнең торгынлыгыннан коткарып, | |

| | | |
|---|---|---|
| | алтмышынчы-сиксәненче еллар әдәби агымын дәррәү кузгатып, хөрлеккә таба борып җибәрде, әдәби чараларны да кыю рәвештә яңартты. Аның «Өч аршын җир», «Язгы кәрваннар», «Өтәч менгән читәнгә», «Җомга көн кич белән», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Яра», «Балта кем кулында», «Йәгез, бер дога!», «Урамнар артында яшел болын» кебек проза әсәрләре, күп санлы пьесалары (алары кырыклап) бүгенге һәм үткән тормыш агымын тирәнрәк аңларга ярдәм итте, татар әдәбиятына яңача рух өрде, замандашыбыз образларын сәнгатьчә ача алды.<br>Шуңа күрә аны язучылар берлегенең рәисе Мөхәммәт Мирза (Илфак Ибраһимов) «әдәбиятыбызның имән баганасы» дип атады.<br>- Бөек Ватан сугышы башланганда А. Гыйләҗевка 13 яшь була. Автор сугыш афәтенең үз күңеленә ни рәвешле тәэсир итүен “Язгы кәрваннар” әсәрендә тасвирлый.<br>- Укучылар, язучы яшәгән чор нинди чор ул?<br>- Әсәрне язганда язучы шул чорга хас булган нинди әдәби метод кулланган?<br>- Бу елларны язучылар тарихка, истәлекләргә әйләнеп кайттылар. Социалистик реализм методы язучыларга стандарт таләпләр куйды һәм нәрсә турында язарга өйрәтте, билгеле бер юнәлештән тайпылмаска кушты. Мондый таләпләр язылган әсәрләр берсе-берсенә охшый башладылар, шуңа күрә алар коллектив идеалыннан качарга тырыштылар. Шәхесләр үз уйларын, үз кичерешләрен язу юлларын эзләделәр.<br>- Әсәр нинди жанрда язылган? *(“Әдәбият белеме” сүзлегенә мөрәҗәгать итәбез. )* | Социализм чоры.<br><br>Социалистик реализм методы.<br><br>Повесть – тормыш күренешләре тезмәсен үзәк бер сызык буенча гәүдәләндерүче, нигездә аз геройлы, әмма характерларны хәрәкәттә күрсәтүче, тар композицияле урта күләмле чәчмә әсәр. |
| **3 этап. Мотивация (эшкә кызыксыну) тудыру.**<br>***Максаты: укучыларны төп эшчәлеккә җәлеп итү.*** | Укучылар без ел саен май аенда нинди зур бәйрәмне билгеләп без?<br>Әйе, Бөек Җиңү бәйрәмен. Ә быел Бөек Җиңүгә ничә ел була? Без бу бәйрәмне кайсы ел фасылында билгеләп үтәбез?<br>Ә нәрсә соң ул “яз”? Нәрсә символы булып тора? Яз бит ул төсләргә бик бай. Әйдәгез әле без дә аны төсләр күзлегеннән карап ачыйк. *(Алты эшләпә методын кулланырга мөмкин.)*<br>*1. Ак төс – мәгълүмат.*<br>Сорау: ә нәрсә соң ул яз?<br>*2. Кызыл төс – хис-тойгы.*<br>Сорау: яз сүзен ишетү белән күңелдә нинди хисләр уяна? | Бөек Җиңү бәйрәменең 73 еллыгы.<br><br>1. Кыш, җәй, көз шикелле үк ел фасылы.<br>2. Яктылык, матурлык, яшәрү, яңару, уяну, җылылык, күңел күтәренкелеге, дәрт, ярату һ.б.<br>3. Табигать йокысыннан уяна, кояш ныграк җылыта, язгы кар сулары ташып ага, яшел үлән |

| | | |
|---|---|---|
| | *3. Сары төс – оптимист.*<br>Сорау: яз ул нинди чор?<br>*4. Кара төс – писсимист.*<br>Сорау: язның кимчелекләре бармы?<br>*5. Яшел төс – иҗади.*<br>Сорау: яз турында шигырьләр, җырлар ишеткәнегез бармы? Алар нинди рухта язылган?<br>*6. Зәңгәр төс – нәтиҗә.*<br>*Сорау*: Гомумиләштереп нәтиҗә чыгарыйк. | баш калкыта, кыр эшләре, бакча эшләре башлана. Һәр җирдә тереклек, хәят, күңеллелек башлана. Язның бер көне ел туйдыра, - дигән халык.<br>4. Март бураннары, салкын-көчле җилләр, күңелгә шом сала торган язгы аҗаганнар, көчле ташулар, баткаклык.<br>5. “Яз килә, яз көлә”, “Яз, яз, яз, җитә”, “Язгы әкият”, “Язгы күкрәү”, һ.б. Алар барысы да күтәренке рухта язылган. Бу шигыйрьләрне укыгач, күңел күтәрелә, шатланасы, сөенәсе килә.<br>6. Ничек кенә булмасын, кешеләр язны көтеп алалар. Яз - ул яңа тормыш башлану чоры. |
| **4 этап. Уку мәсьәләсе кую**<br>**Максат:** ***Дәрескә максат кую*** | -Укучылар, без бүгенге дәрестә нинди әсәр өйрәнербез икән? - Әдәбиятыбыз күркәм, кодрәтле сүзияләренә бай. Үзенчәлекле, берәүне дә кабатламый торган, дөреслекне ярып салучы язучы А.Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәре белән танышырбыз бүген. | *Парларда эш.*<br>Без сугыштан соңгы вакыйгалар турында язылган әсәр өйрәнербез. Әсәргә анализ ясап, эчтәлеген табарбыз. Автор фикерен ачыкларбыз. |
| **5 этап. Уку мәсьәләсен чишү.**<br>***Максат:*** хикәянең эчтәлеген анализ нәтиҗәсендә табу; әсәрне<br>аңлау өчен шартлар тудыру. | А. Гыйләҗев иҗатында зур урын алып торган бер тема – сугыш чоры яшүсмерләренең язмышы, яшәве. Гомерләренең иң кадерле еллары олылар белән берлектә ил проблемаларын чишеп узган ул буынны әдип бер генә вакытта да, бер генә яктан да начар итеп күрсәтми. Аларның мәхәббәте дә эчкерсез, исәп-хисапларга корылмаган, аларның дуслыгы да риясыз.<br>Әйдәгез әле укучылар, әсәрнең язылуына тарихи шартлар белән танышыйк.<br>- Әсәрнең сюжеты нәрсәгә корылган?<br><br>- Әсәрнең төп темасы?<br><br>- Төп геройлар?<br><br>- Дөрес, укучылар, ә хәзер теманы ачарга ярдәм иткән төп вакыйгаларны атагыз. | - Тарихи тормыш-чынбарлыгына.<br><br>- Сугыш чоры авылы кешеләренең, аеруча яшьләрнең яшәеше.<br><br>- Сугыш чорында эшне төптән җигелеп тарткан Хәкимҗан абзый, Сабирәттәйләргә алмашка үсеп килүче, шулай ук бик яшьләй тормыш арбасына җигелгән Ибраһим, Дамир, Әдиләләр.<br>- Беренче төп вакыйга – көзен җыелган ашлыкны Чаллы элеваторына илтү. Икенче төп вакыйга – яз көне чәчүлек орлыкны 65 чакрымдагы ерак Кәследән алып кайту.<br>- Автор шул чор авылы кешеләренең хезмәтенә карата гаделсезлек турында яза. Көз көне чәчүлек орлыгы да калдырмыйча, барлык ашлыкны элеваторга илттерәләр, ә язын, атлар күтәрмәгә калгач, аны яңадан алып кайтырга кирәк була. |

| | | |
|---|---|---|
| | - Шушы вакыйгаларга нигезләнеп, автор нәрсә әйтергә теләде икән? | Язучы пейзаж ярдәмендә шул чорның асылын ачуга ирешә алган. |
| | - Әсәрдәге пейзажның чор һәм андагы вакыйгаларга бәйләнеше бармы?<br>-Фикерегезне дәлилләгез. | (Укучылар әсәрдән укый.)<br>“Җанны өшетә торган салкын коры кич килде... Бүген битләрне аяусыз чәнчеп, кием – салымнарны әрсез йолыккалап, коры салкын җил исте, суытты, көн ямьсезләнде...”<br>“Көн суык, Көн шыксыз. Юл кантарланып бозланып каткан...”<br>“ Барыбызның да курыкканы буран иде әле була җепшек, кара март бураннары! Кешенең адымын салмакландыра, акылын җуя, израта, зиһенең томалый, авыр кар дөньяны да, күкне – җирне, нужалы юллардагы адәм балаларын да күмеп китә... |
| | - Шулдай да әсәрдә киләчәккә өмет, ышаныч барлыгы сизеләме? | Әйе, мәсәлән, автор болытлы, шыксыз көннәрне сурәтләгәннән соң болай дип яза: ”Иртәнге кояш! Рәхмәт сиңа. Күңелләрдә өмет, тәндә көч... Иртән кояш күренмәсә, кешеләр сирәк көләләр...”<br>Әсәр ахырында тагын мондый юлларда китерелә. “Көн матур. Чалт аяз. Кар өстенә карасаң, күзләр чагыла...”<br>Димәк, тормыш табигатьнең үзе кебек: караңгы төне дә, кояшлы көне дә бар.<br>Газаплы, авыр көннәргә алмашка якты, өметле яшәеш киләчәк. Бары тик түзәргә, бердәм булырга, яшәргә тырышырга кирәк. |
| | - Язучы әсәрнең исемен нәкъ менә яз белән бәйләгән. Ни өчен дип уйлыйсыз?<br><br>Әйе, өмет, теләк сүнмәгәндә, яшәү чынлап та матур булачак.<br>Әсәрдә яшьләр – төп көч. Алар якты, гадел тормышка алып чыга. Алар авырлыклардан курыкмаучы, үз сүзләрен әйтә ала торган, сөю һәм хыял белән яшәүче буын.<br>-Ә нәрсә соң ул ярату? Аяз Гыйләҗевнең ”Язгы кәрваннар” әсәрендә ярату, ничә һәм нинди төрле?<br>*Дәлилләрне слайтта күрсәтергә мөмкин.* | Яз - ул мотив буларак, киләчәккә өмет. |
| | 1. Дамирның көнләшүеннән бавыры кабарган...<br>а) ...Сөям дигән ымың түгел идемени ул, Ибраһим?..<br>б) ...без бер-беребезгә сарылабыз.. | 1. Ибраһим, Әдилә һәм Дамир өчпочмагы.<br>2. Әнинең яратуы.<br>3. Табигатьне ярату.<br>4. Хайваннарны ярату. |

| | | |
|---|---|---|
| | - Яратам мин сине, Әдилә!...<br>- Мин дә, Ибраһим...<br>2. Әнкәй куанды., мыштым гына елап җибәрде, мунча якты, әнкәй җәйгән җылы урында яту нинди рәхәт!...<br>3. Көн матур, кояш чыкан. Их! Яратам соң шундый җылы көннәрне.<br>4. Дамирга ат җене кагылган, ярата ул атларны, бигрәк тә яшь колыннарны.<br>5. Яратам мин кешеләрне,- диде Сәрвәр апа. Дәү Казанда бәрәңге пешерде, каяндыр бал алып кереп чәй эчерде.<br>Заманның никадәр авыр булуына карамастан кешеләрнең рухи ныклыгы сүрелмәгән, күпме генә михнәт күрсәләрдә, алар кешелеклелек сыйфатларын югатмаганнар.Алар нindиләр?<br>Без яшүсмерләрнең һәркемне сокландырырлык әхлакка ия булуын, рухи батырлыкка омтылуларын күрәбез. Язучы, мондый әхлакның нигезләре патриархаль гаиләдән килә, авыл чынбарлыгында тәрбияләнә, ди | 5. Кешеләрне ярату.<br>1. Кешеләрне шатландыру - үзе бер бәхет.<br>2. Шәфкатьлелек.<br>3. Бер-берсе белән уртак кайгы һәм шатлык бүлешү.<br>4. Өлкәннәргә ярдәм.<br>5. Бар да уртак.<br>6. Кече өйле, олы җанлы, кешеләр.<br>7. Бердәмлек, кешелеклелек. |
| **6 этап. Рефлексия.**<br>***Максаты: Дәрестә эшләгән эшләргә нәтиҗә ясау*** | Дәрестә нинди УМ чиштек? Ничек эшләдек? Ниләр белдек?<br>- Укучылар, сез сугышны ничек аңлыйсыз?<br><br><br>- Ә сезнең сугышны күргәнегез бармы?<br>- Сугыш нәрсәгә китерә?<br><br>-Укучылар, әсәрнең әһәмияте нәрсәдә? Сез ничек уйлыйсыз?<br><br><br><br>-Дәресне тормыш белән бәйлик.<br><br>- Аяз Гыйләҗев әсәрләренең тәрбияви кыйммәте әйтеп бетергесез зур. Алар безнең милләтебезнең рухи байлыгы, милли үзенчәлекләре турында чорыбыз вакыйгаларына бәйләп язылган әдәби әсәрләр. Безнең чор кешеләренең яшәү рәвешләрен киләчәк буыннарга да алып бару вазыйфасы тапшырылган аларга. | Без...Сугыш ул ике ил арасындагы кофликт дип беләбез, ике ил арасындагы кораллы көрәш.<br>Минем сугышны кинода яки рәсемдә генә күргәнем бар, өлкән кешеләр сөйләве буенча гына беләм. Бик куркыныч нәрсә икәнен тоябыз.<br><br>Шуны әйтәсе килә, безнең күзлектән караганда сугыш ул:<br>1. Югалту.<br>2. Ятим балалар.<br>3. Тол аналар.<br>4. Үлем.<br>5. Гариплек һәм чир.<br>6. Ачлык.<br>Әсәрнең әһәмияте шунда: сугыш чоры балаларының батырлыгына, чыдамлылыгына сокланып алар белән горурланып яшәргә, безне тормыш авырлыклары алдында сынмаска өйрәтә.<br>А.Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәрендәге сурәтләнгән геройлар бүген безнең арабызда да яши. Дөрес, аларның сафы елдан-ел сирәгәя. Тыл ветераннары олы хөрмәткә лаек. |
| **7 этап. Дәрескә** | Укучылар, бүгенге дәрес темасын | Укучылар гомуми билге куялар. |

| | | |
|---|---|---|
| **гомуми бәя.** | үзләштерүегез буенча билгеләр куюыгызны сорыйм.<br>Билгеләр саны ачыклана.<br>Укучылар белән килешенгән (укытучы һәм укучы килешкән) билгеләр көндәлекләргә һәм журналга куела. | Үзбәя. Үзбәя өчен критерийлар:<br>а) дәрестә нинди УМ чиштек? Ничек эшләдек? Нилəр белдек?<br>*ораууларга үз фикерен тулы, төгәл, аңлаешлы итеп әйтеп бирә алса – "5";*<br>*б) куелган сорауларга җавап тулы булмаса – "4";*<br>*в) дәрестә нинди УМ чиштек? Ничек эшләдек? Нилəр белдек? дигән сорауларга укытучы яисә иптәше ярдәме белән генә сөйләп бирсә -"3";*<br>*г) укытучы яисә иптәше ярдәме* |
| **8 этап. Өй эше бирү** | Өй эшен сайлау мөмкинлеге бар. – А.Гыйләҗевнең әсәрен укырга; сугыш чоры һәм сугыштан соңгы авыр еллар турында тыл ветераннарыннан язып алынган истәлекләр алып килергә; "Кешеләрне шатландыру – үзе бәхет" дигән темага сочинение язарга | |

Мирзамуратова Гөлшат Морат кызы,
Мөслим гимназиясе, Мөслим районы

**Күрше хакы – Аллаһ хакы**

(Аяз Гыйләҗевнең "Әтәч менгән читәнгә"әсәре буенча)

Дәреснең максатлары: Дидактик максат: Аяз Гыйләҗевның "Әтәч менгән читәнгә"әсәренең эчтәлеген үзләштерү. Үстерешле максат: повестьны анализлау, дәрес материалын тормыш белән бәйләп, чагыштырып нәтиҗә ясау күнекмәсен үстерү. Тәрбияви максат: әхлакый-этик бәяләү күнекмәләре формалаштыру, көнчелек хисенең үзеңә начарлык булып кайтуын танып белү өчен җирлек тудыру.

Планлаштырылган нәтиҗәлелек:

Предмет нәтиҗәлелеге: хикәянең темасын, идеясен, проблемасын формалаштыру.

Метапредмет нәтиҗәлелеге:

Регулятив гамәлләр: геройларга характеристика бирүдә, әсәрнең темасын, проблемасын, идеясен ачуда үз эшчәнлегеңне планлаштыру, проблеманың чишелеш юлларын күрсәтү, дөрес һәм ялгыш эшләнгән эшне аера белү, үзара контроль булдыру, үз эшчәнлегеңне бәяләү.

Танып- белү гамәлләре: төшенчәләрне билгели, йомгаклый, аналогияләрне таба, сәбәп-нәтиҗә элемтәләрен урнаштыра, нәтиҗә ясау күнекмәләре.

Коммуникатив гамәлләр: төркемдә эшли белү күнекмәсе булдыру, үз фикерен дәлилле итеп башкаларга җиткерә белү, хаталарыңны лаеклы рәвештә таный һәм төзәтә белү күнекмәләрен формалаштыру

Шәхескә кагылышлы нәтиҗәлелек: герой кылган гамәлләр аша яхшыны начардан аеру, күршеләр белән яхшы мөгамәлә урнаштырырга, сабыр булырга өйрәнү.

Предметара бәйләнеш: Әдәбият, татар теле, әхлак тәрбиясе

Дәреснең тибы: белемнәрне ныгыту һәм системалаштыру

Танып-белү эшчәнлеген оештыру методлары: тикшерүле, өлешчә эзләнүле

Танып-белү эшчәнлеген оештыру формалары:фронталь, индивидуаль, парлап, төркемнәрдә эш.

Төп төшенчәләр: конфликт, идея, тема, проблема.

Ресурслар: төп: куллану өчен дәреслек: әдәбият.11нче сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү мәкт. 11 нче с-фы өчен д-лек / А.Г. Әхмәдуллин ред.- Төзәт. 4 нче басма. Казан: Татар.кит. нәшр., 2011. Әдәбияттан хрестоматия: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 11 нче с-фы өчен/ Төз. А.Г. Әхмәдуллин, Т.Н. Галиуллин, Н.Г, Юзиев. – 3 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2005. – 447б

Проектор, экран,ноутбук, фонохрестоматия

**Дәрес барышы**.

I. Оештыру өлеше. Уңай психологик халәт тудыру.

Хәерле көн, укучылар! Бер-беребезгә карап елмайдык, барыбызга да уңышлы эш сәгатьләре телибез.

II. Актуальләштерү.

Укытучы: Укучылар, хәзер сезгә гыйбрәтле хәл турында сөйләп китәм. Мәдинә шәһәрендә Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) янәшә күршесе яһүди карчыгы яши иде. Ул яһүди карчыгы гомер буе пәйгамбәребезнең бакчасына чүп-чар ташлый торган булган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) күршесенең бу начар гадәтенә, күрше хакы өчен, игътибар итмәскә тырыша, бакчадагы чүп-чарны җыештырып алып, бер чокырга күмә. Бу хәл байтак гомердән бирле шулай дәвам итә. Көннәрдән бер көнне Пәйгамбәребез (с.г.в.) бакчасына чыга һәм күрә: бакчасы чип-чиста, чүп-чар юк. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) эче пошып, күрше яһүди карчыгының хәлен белергә дип керә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) бу яһүди карчыгына йомшак кына болай дип эндәшә: «Бүген күренмәдегез, бакчамда чүп-чар юк, борчылып кердем, әллә авырып киттегезме?» Яһүди карчыгы, үзенең гаебен вә хатасын танып, Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең искиткеч күркәм холкына сокланып, аңа иман китерә һәм исламны кабул итә.

Сорау: Әгәр дә безнең ишек төбебезгә яки бакчабызга чүп-чар ташлап, безне шулай мыскыл итсәләр, без нишләр идек?! Әлеге хикәят сезгә ничек тәэсир итте? Аны тыңлаганда сез нәрсә турында уйландыгыз? Аңа нинди исем бирер идегез? Аның дәресебез белән берәр бәйләнеше бармы? (Көтелгән җавап: бу хикәят күршеләр белән үзара мөнәсәбәт турында. Аны тыңлаганда үзебезнең күршеләр белән аралашкан вакытларны искә төшердек. Әлеге хикәятне «Ташка каршы аш белән ат» дип исемләргә булыр иде. Күршеләр белән мөнәсәбәтләрне без бүген укып килгән әсәрдә дә күрдек.

III. Уку мәсьәләсен кую һәм чишү.

Укытучы: Укучылар, бүгенге дәресебезнең уку мәсьәләсен ничек билгеләрбез? Дәрескә нинди исем бирербез? («Күрше хакы – Аллаһ хакы». Аяз Гыйләҗевның “Әтәч менгән читәнгә”әсәре буенча).

Укытучы: Аяз Гыйләҗев“Әтәч менгән читәнгә” повесте Татарстан АССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. “Шәхсән минем үземне “гыйбрәтле” геройлар ныграк кызыксындыра. Мин шундый кешеләрне яратам: үзләре яшәгән чорга битараф булмаган, мәхәббәт һәм нәфрәтне сиземли торган кешеләр“, - ди автор. Димәк, ул сокланган кешеләр аның әсәрләренә герой булып күчкән.

Укучылар өйдә әсәрне укып килгән булырга тиешләр. Аларның әсәрне укып бетерүләре белән кызыксыну, аңлашылмаган урыннарны ачыклау.

«Бер-береңнән сорау алышу» алымын кулланып укучылар бер-берсенә эчтәлек буенча сораулар бирәләр. (Эчтәлекне ачалар.Тиз арада әсәрне укып чыккан кебек сораулар төзү, җавап бирү. Кем? Нәрсә? Кайда? Ничек? Нинди? Нишли? сорауларын файдаланырга).
Төркемнәрдә эш. Түгәрәк буенча хат язу алымын куллану. Әсәрдәге төп вакыйгаларны хронологик тәртиптә язып кую.
Әсәрдә түбәндәге сюжет сызыкларын билгеләргә була.

- Әтәчнең егылып төшүе
- Фирүзә кайгысы.
- Җәмил өмете.
- Вәзилә теләге.
- Хәйдәр белән Мидхәт теләге.
- Зәйтүн белән Әнәс каршылыгы.
- Хәйретдин язмышы.

Үзбәя өчен критерий:
а) вакыйгаларның берсен тапса –“3”;
б) вакыйгаларның беренче икесен тапса, сюжетын сөйли алса –“4”;
в)вакыйгаларның барысын да тапса, сюжетын сөйли алса –“5”.

Укытучы: “Әтәч менгән читәнгә”әсәрендә үзенчәлекле сюжет, бигрәк тә әсәрнең үзенчәлекле конфликты игътибарны җәлеп итә. Нәрсә соң ул конфликт? Ул кемнәр арасында, нинди сәбәпләр аркасында барлыкка килә? (Көтелгән җавап: конфликт – (каршылык) – вакыйга-күренешләр, гомумән, хәрәкәт нигезенә салынган характерлар һәм хәлләр, карашлар һәм тормыш принципларының бәрелешүе. Ике якның берсе булса да каршылык кичерә икән, димәк чынбарлыкта конфликт барлыкка килә дигән сүз. Кешеләр арасындагы киеренке ситуация, гайбәт, көнчелек конфликтны барлыкка китерүче сәбәпләр булып тора.

Әсәр башында киң җиһанга дәһшәтле аваз салырга җыенган кызгылт этәч читәннән егылып төшә. Гәрәй-ханнан байтак җәбер-җәфа татыган йолкынган каурыйлы, кутырлы кикрикле бик күп аксак-туксак этәчләр сөенә. Әтәчкә карата шулвакыт күрше этәчләрнең мөнәсәбәте күренә. Кайсыдыр тавык этәчкә теләктәшлек белдерә, кайсысыдыр күрше тавыгы ягына чаба. Әтәч һәм читән кебек символик образлар аша автор безне вакыйгалар эченә кертеп җибәрә. Уйланырга җирлек тудыра. Әлеге конфликт уңай хәл ителә. Әтәч үзен кулга ала.Кычыткannар арасыннан уктай атылып чыгып, келәт эченә кереп кача. Шулай итеп ике гаилә арасында барган төп конфликтка нигез салына.

Гәрәй-ханның читәннән егылып төшү сәбәбен исә этәчнең хуҗасы Әнәс һәм Сәләхетдин малае Зәйтүн арасында килеп чыккан гаугадан аңлап алабыз. Әнәс Гәрәй-ханны яклап Зәйтүнгә ташлана, Зәйтүн дә үзләренең өшегән кикрикле ак әтәчләре белән, ата казлары белән мактана. Әнәс мәктәптә гел яхшы билгеләр генә алса, Зәйтүн исә өчлеләр ала.Әнәскә беренчене яхшы билгеләренә генә бетергән өчен өр-яңа кепка бүләк итсәләр, Әнәскә начар укыгач, бүләк эләкми. Малайның күңелендәге үч алу тойгысы тышка бәреп чыкты һәм аның беренче ударын Гәрәй-хан татыды.Әлеге каршылыкта Әнәс өскә чыкты. Зәйтүн гаебен танырга мәҗбүр булды.Әтәчкә яңадан атмам, - дип вәгъдәләр бирде. (Зәйтүн белән Әнәс арасында конфликт).

Гаилә башлыклары Сәләхетдин белән Гөлбикә, Мирфатыйх белән Гөлмәрьям арасында булган вакыйгалар төп конфликтны тәшкил итә. Сәләхетдин белән Мирфатыйх – гаилә башлыклары. Кайчандыр түбән очның ике якын дусты булалар. Гөлбикә белән Гөлмәрьям заманында шулай ук ахирәт дуслар була. Беренче мәхәббәт хатын да алар

икесе исеменнән берьюлы ике егеткә атап яза. Туйны да икесе дә бер җәйдә, атна аша гына уздыралар, башта Гөлбикәнекен, аннан Гөлмәрьямнекен. Югары очтагы ике яшьти дуска – Сәләхетдин белән Мирфатыйхка кияүгә чыгалар. Икесенең бер очка, күрше киленнәр булып төшүләренә чиксез куаналар, “Бергә гомергә!” дип җырлар җырлыйлар. Ләкин дуслык какшый. Тормыш үзгәрә. Алар инде күптән бер-берсенә йомышка йөрмиләр, бәрәңгене аерым утырталар, аерым алалар. Ике арадагы читәннең кемнеке икәнен онытып бетергәннәр иде, читән тагын метр ярымга биегәйгәч кенә Сәләхетдиннәрнеке икәнлеге исләренә төште. Комсызлык һәм көнләшү хисе аларның кешелеклелек сыйфатларына күзләрен яба.Кайчандыр дуслар булып аралашып яшәгән гаиләләр арасына якын барырлык булмый. Дус һәм тату яшәүче гаиләләр арасында килеп чыккан каршылыкның сәбәпләре нәрсәдә? Сәләхетдин районнан мотоцикл алып кайта. Сабантуйда мотоциклга утырып йөргән Сәләхетдин гаиләсен күрү белән Мирфатыйх хатыны Гөлмәрьямнең эче яна, күзенә ак-кара күренми. Әлбәттә, алар ачыктан-ачык талашмыйлар. Ләкин гаиләләр арасында яшерен конфликт барлыкка килә. Сәбәбе – көнчелек. Ләкин әлеге конфликтны психологлар телендә без уңай конфликт дип күрсәтә алабыз. Чөнки ул әлеге гаиләнең максатын, кызыксынуларын тормышка ашыра. Ягъни ике гаилә дә узыша-узыша шкаф, трельяж, холодильник сатып ала. Сервантлар да буш тормый: Гөлмәрьям дә, Гөлбикә дә дистәсе белән чәшке-чынаяк, кашык-чәнешке, бәллүр вазалар, путалы чәркәләр, балчык сыерлар, мөгездән көмешләп ясаган әкәмәтләр, буш диңгез кабырчыклары, тагын әллә ниләр кайтарып тутыралар.Тормыштагыча әйтсәк Мирфатыйх белән Сәләхетдин гаиләсе ак көнләшү белән бер-берсен уздырып яши башлый. Ләкин вакыйгалар уңай хәл ителми, киресенчә куерганнан куера бара.

- Фирүзә һәм классташлары арасында конфликт.
- Хәйдәр белән Мидхәт арасында конфликт.
- Җәмил белән Вәзилә арасында конфликт.

Сюжет элементларын билгеләү.

Повестьта сюжет сызыклары ике гаилә – Сәләхетдиннәр һәм Мирфатыйхлар арасындагы ярыш, дошманлыкны төрле яклап яктырта. Әтәч егылып төшү вакыйгасы – төенләнеш. Ике гаилә мөнәсәбәтләре үстерелә – вакыйгалар үстерелеше. Мидхәт белән Хөйдәрнең, узышып, машина бәрдерүе, Гөлбикәнең кулы сыну, Сәләхетдиннең дә кулын сындыруы – мөнәсәбәтләрнең иң биек ноктасы. Хәйретдин агай авырып, аның янына килгән Сәләхетдин белән Мирфатыйхның Хәйретдин белән туган булуларын белүләре, яңа зиратка күмелгән Хәйретдин агайның үзе артыннан туганнарын да алып китү куркынычы конфликтның чишелүенә китерә.

Төп һәм ярдәмче конфликтларны, сюжет элементларын билгеләүгә үзбәя.

Үзбәя өчен критерий:

а) конфликтның икесен тапса, сюжет элементларының икесен генә күрсәтсә –“3”;

б) конфликтның беренче дүртесен тапса, сюжет элементларының өчесен күрсәтсә –“4”;

в) конфликтларның барысын да тапса, сюжетын элементларының барысын да билгеләсә –“5”.

Укытучы: Укучылар ничек уйлыйсыз, без барыбыз да төрле характерлы. Менә шушы тормышта булган каршылыкларга бөтен кешенең дә мөнәсәбәте бертөрлеме? (Көтелгән җавап: юк, әлбәттә. Тормыш авырлыкларын төрле кеше төрлечә кабул итә. Шуңа күрә кайбер кешеләр башкалар белән бик җиңел аралаша, кайберәүләр берәү белән дә уртак тел таба алмый).

Укытучы: Әйдәгез әле, без сезнең белән бүген психологлар булып алыйк. Психолог буларак геройларга бәя бирик. Конфликтның килеп чыгу сәбәпләрен ачканда психологлар шәхеснең үз-үзен тотышына карап өч төрле моделен күрсәтәләр. Конструктив модель, деструктив модель, конформист моделе.

А) Конструктив модель.

Әлеге кешеләр үзләре конфликтны төрле юллар белән чишәргә омтылалар. Кешеләргә уңай мөнәсәбәттә торалар. Алар ачык күңелле, аз сүзле, башкалар белән теләп аралашалар.

Б) Деструктив модель.

Әлеге төркемгә керүчеләрне конфликт тудыручылар дип атасак та дөрес булыр. Аларның берәүгә дә ышанычы юк, кешеләргә карата тискәре мөнәсәбәттә, аларга шикләнеп карыйлар.Кешеләр белән аралашканда әдәп-әхлак мәсьәләләре онытыла.

В) Конформист моделе.

Бу төркемгә керүчеләр – пассив кешеләр. Башкаларга юл куя белүчән.

Шул рәвешле гаилә башлыкларын, хуҗабикәләрне тикшереп карыйк әле. Укучылар һәр төркемдә бирелгән модельгә туры китереп бео образга характеристика бирәләр. (Көтелгән җаваплар: Мирфатыйхның улы – Җәмил. Егет үз тырышлыгына ышанып яши. Төрле ситуациядә дә үзен кулга ала белә. Мин дигәнен дәлилли, максатына ирешү юлларын таба. Каршылык килеп туса хәл итәргә уңай вариант эзли. Кешеләргә яхшы мөнәсәбәттә, ихтыяр көче нык. Үзенчә максатына ирешә барганы өчен бәхетле Җәмил. Ул авылда физкультура дәресләре алып бара. Читтән торып Казанда педагогия институтында укый. Әсәрдә нәкъ менә конфликтлардан кача белүе белән аерылып тора. Чөнки Вәзилә белән уртак тел таба алмасын аңлый ул. Шунда ук чиста күңелле, авыл тормышыннан, сыер савудан курыкмый торган Сәкинәне сайлый. (Конструктив модель)

Сәләхетдиннең бишенче улы Зөфәр кешеләргә яхшы мөнәсәбәте, игътибарлы булуы белән аерылып тора. Йорт эшләрендә әти-әнисенә булышып үссә дә, байлык аны кызыксындырмый. Үзенең әйберсен берәүдән дә кызганмый. Мал кадерен белми, дип әрләсәләр дә исе китми Зөфәрнең. Спорт белән шөгыльләнә. Укытучысы Җәмил абыйсы белән уртак тел таба. Апасының котыртуларына карамастан әшәкелек эшләүдән тыелып кала белә. (Конструктив модель).

Сәләхетдиннең хатыны Гөлбикә апа авылдашларының берсен дә мактамый, һәммәсенә ачы сүзе, зәһәр агулы теле кагылып үтә. Менә аның ябык кешеләргә карата әйтелгән сүзләре: карачкы, ач бет, ач әрвах, үлемнән калган, зираттан җәяү качкан, сөйкемсез, шыр сөяк, колга, токмач кунасы, шүрәле, котсыз.

Симез кешеләргә карата да сүзләр әзер. Ит бүкәне, кышлау умарта, апара чиләге, сыра мичкәсе, чучка лаканы, буаз сыер, мышкылдык, черек печән кибәне, метер баганасы. Ул кешеләрне кыяфәтенә карап ябыклыгын, симезлеген тикшерә. Аларны кимсетергә дә кыенсынмый. Авыл хатыннарының һәммәсен үтергеч бер мыскыллау белән арттырып сөйләргә ярата ул. Димәк, кешеләргә карата шундый мөнәсәбәттә торган кеше белән кем генә аралашырга теләр икән соң? Нәтиҗәдә кеше күрә алмаган хатын малае белән машинада барганда аварияга очрап кулын сындыра.

Аның кызы Фирүзә дә әнисеннән калышмый. Классташлары аның әрем телен бик тиз татый башлый. Камыт аяклы булып йөреп күрсәтә, күзен чалшайта, стена газетасында мыскыл итәсе кешесе турында көлкеле мәкалә бастыра, кыяр борын асып, шакшы камыт кигертеп сурәтен ясап куя. Каршы төшкәнне, сүзен кире какканны өнәми Фирүзә. Кешеләрне кичерә белми. Аның якын дуслары булмый. Классташлары холкыннан

курыкканга, үзләрен мыскыл итүгә чара таба алмаганга гына, аңа ничек тә яраклашырга тырышалар. Битенә бетчә чыгу аның өчен зур кайгыга әйләнә. Чөнки ул үзен бөтен кешедән өстен итеп сизә. Шул вакытта Фирүзә үз эченә бикләнә. Нәтиҗәдә Фирүзәгә дә туры итеп сүз әйтүче табыла. Классташлары алдында Җәмил аңа күрше авылдан машина көтеп ятканчы, җәяү кайтырга куша. Шул рәвешле Фирүзәне урынына утырта.

Гаилә башлыгы Сәләхетдинне дә без башта уңган хуҗа итеп күрәбез. Газетадан укып, яңалыклардан хәбәрдар булып торган кеше начармыни? Җитмәсә, үзенең яраткан шөгыле бар. Тирә-якта аннан да шәп кыяр үстерүче, кыяр тозлаучы булмый. Ләкин аның күршесенә су шәп килә, ә Мирфатыйхның түтәлләре кибеп утыра, авыл башына хәтле су барып җитә алмый. Су сибәргә, су ташырга берәүнең дә вакыты юк, һәркемнең үз мәшәкате. Кем гаепле? Үз-үзләрен генә кайгыртып йөрүче гаилә әгъзаларымы, әллә күршесе Мирфатыйхмы? Югыйсә Мирфатыйх та үз тормышы белән яши. Килгән суны шлангтан сиптереп яшелчәләр үстерә. Сәләхетдингә суның барып җитмәве турында белми дә югыйсә. Ә Сәләхетдин үзләренең сусыз калуын күршесеннән күреп, аларга кереп гауга чыгара. Нәтиҗәдә берсе-берсенә юл куймый. Моңа тагын бер сәбәп – аракы да килеп кушыла. Шул рәвешле Сәләхетдиннең кулы сынып, ул хастаханәгә эләгә. Әлеге образлар каршылыкны тагын да көчәйтү өстендә эшли. Кешеләр белән мөнәсәбәтләрен җайлау турында уйлап та карамыйлар. (Деструктив модель)

Хәйретдин агай – Язкилде авылының өлкән, хөрмәтле кешесе. Ул әсәрдә үзенчәлекле урын алып тора. Кеше фикере белән тиз килешә. Бәхәсләрдә катнашмый ул. Хатыны Сабира вафатыннан соң аны Чиләбедә төпләнеп калган улы Мидхәт үзләренә алып китәргә була. Бармас өчен карышып карый ул, сәбәп таба. Ләкин бу каршылыкта Мидхәт җиңә. Очсыз хакка каралты-куралар сатыла, өй-җиһазларын күрше-коланга истәлеккә тарата. Ләкин өч ел дигәндә Хәйретдин агай кайтып та җитә. Минниса карчыкка йортка барып керә. Председательгә гозерен җиткерү белән авылда каланча сафка баса. Эшчәнлеге, юмартлыгы белән ул авылдашларының ихтирамын казана.Тормыштагы хәлләргә битараф булып кала алмый. Ташу агызганнан соң су буенда кеше башын тибеп уйнаучы балаларны күреп йөрәге әрни.

Укытучы. Ике гаиләне алга таба күзәтәбез. Алар арасында ярдәмләшеп яшәү онытыла. Тискәре конфликт нәтиҗәсендә ике якның да бер-берсенә таянычы, ышанычы кими, бердәмлек югала. Конфликт тирәнәя бара. Монда инде без комсызлык һәм көнләшү кебек сәбәпләрне күрсәткән идек. Икенче бер сәбәп ул кешеләрнең үзләрендә. Әлеге гаилә кешеләре нинди соң алар? Бәлки мин-минлекләрен онытып, яңадан матур гына аралашып яшәргә дә мөмкинлек бардыр? Конфликт ничек хәл ителә? (Көтелгән җавап: барысы да геройларның шәхси сыйфатларында. Конфликтны чишкәндә дә безгә Хәйретдин агай ярдәмгә килә. Авыл зиаратын ташу агызганнан соң яңа зиаратка урын билгеләсәләр дә, авылдашлар туганнарын анда күмәргә куркалар. Чөнки зиратка беренче күмелгән кеше үзе артыннан туганнарын да алып китә, дигән ышану яши. Хәйретдин агай исә, хәле хәл икәнен белгәч, үзен яңа зиратка җирләүләрен сорый. Менә шунда инде моңарчы үзара ярышып яшәүдән генә тәм тапкан Сәләхетдин атыраштa кала. Ул бит Хәйретдин агайга якын туган. Мирфатыйх та үзенең туганлыгын исенә төшерә.Кан дошманга әйләнгән ике дус Хәйретдин агайның йортында очрашалар. Берәүнең дә бу дөнья белән алай тиз генә исәп-хисабын өзәсе килми. Хәйретдин агай да терелергә тиеш. Хәттә акча мәсьәләсе дә куркыныч түгел. Элекке дуслар Хәйретдин агайны санаторийда үз хисапларына дәваларга риза. Шул рәвешле конфликт хәл ителә. Хәйретдин агай аларны хәйләкәр генә озатып кала).

Укытучы: Конфликтның чишелеше идеягә ишарә ясый. Ягъни без геройларның яшәү мәгънәсе турында уйланабыз. Әлеге ике гаилә гомер буе ярышып яшәп нәрсәгә иреште соң? Бу дөньяда байлык туплап бәхетле булып буламы? (Көтелгән җавап: бәхетне кеше тырыш хезмәте белән эшләп табарга тиеш. Кешеләр белән нинди мөгамәләдә буласың, үзеңне дә тормышта шундый мөнәсәбәт көтә).

Укытучы: конфликт әдәби әсәрдә сюжетның нигезе булып тора. Әсәрдә сюжет сызыкларын, төп һәм ярдәмче конфликтларны билгеләдек. Төп конфликт әсәрдә теманы билгеләүче үзәк элемент ролен башкара. Әсәр нинди темага язылган дип әйтә алабыз? (Көтелгән җавап: темасы – көнчелек. Байлык артыннан куу, комсызлык, саранлык, әхлак кагыйдәләрен оныту, кешеләрнең бер-берсенә ихтирамы югалу, мәхәббәтнең кадере китү, мал җыю, олыларга, үткәннәргә хөрмәт югалу кебек кешедәге тискәре сыйфатларны тщнкыйтьли автор).

Укытучы: Автор әсәрдә нинди проблемалар күтәрә? (Көтелгән җавап: байлыкның көнләшү китереп чыгаруы; мәхәббәттне байлык яки үз теләгеңә алмаштыру; игелекле кешенең хөрмәтле булуы; авылда матурлык һәм үткәннәргә хөрмәт югалу; татар авылына эчкечелек, комсызлык чире үтеп керү; хатын-кыз тыйнаклыгының югала баруы).

Укытучы. Әсәрнең теле сатира тудыруына да игътибар иткәнсездер. Әсәрдә канатлы гыйбарәләр булып китәрдәй нинди җөмләләргә игътибар иттегез? Һәр төркем бер гыйбарә таба, мәгънәсен аңлата. (Көтелгән җавап: ихтималның арты киң! (Тормыштагы нәни вакыйгалар да көтелмәгән зур нәтиҗәләр китереп чыгара) Җиңелгәнне җиңгә бөтерәләр! (Баш бирмәскә, җиңелмәскә) Шулпасы кешедә кайнаса да, ите бездә пешәр! (Читтән файда күрү) Сүздән сүз чыкты, уйны уй ялгады. (Хәйдәр белән Мидхәтнең авылда дошман булсалар да, шәһәрдә аралашып яшәргә мәҗбүр булулары). Хәзер иң ярлы кеше дә җәяү йөрми. Алма агачыннан ерак тәгәрәми,тәгәрәсә дә шул агачныкы булып кала. Ул-атага, кыз-анага охшый.

Алты эшләпә алымын файдаланып төркемнәр, үзара фикерләшкәннән соң эшләпә кигән укучылар җавап бирә.

Ак эшләпә. Нинди яңа мәгълүмат белдегез? Конфликтның килеп чыгу сәбәпләрен ачканда психологлар шәхеснең үз-үзен тотышына карап өч төрле моделен күрсәтәләр. Әлеге белемнәр миңа кешеләр белән аралашканда аларны яхшырак аңларга мөмкинлек бирер дип уйлыйм.

Сары эшләпә. Өйрәнгән мәгълүматның уңай яклары. (Көтелгән җавап. Без бүген бик күп кызыклы мәгълүмат алдык. Кешенең конфликтлы ситуациядә үз-үзен тотышы безгә киләчәктә кешеләр белән аралашканда бик файдалы булыр дип уйлыйм).

Кара эшләпә. Өйрәнгән мәгълүматның тискәре яклары. (Көтелгән җавап. Геройларның тискәре характер сыйфатлары кешеләр белән аралашканда, тормыш иткәндә аларга файдага караганда зыянны күбрәк китерәдер дип уйлыйм. Әсәрдә яктыртылган саранлык, көнләшү, байлык туплау кебек сыйфатлар бүгенге көндә дә кешеләр арасындагы тискәре сыйфатларның берсе).

Кызыл эшләпә. Сездә нинди хисләр туды? (Көтелгән җавап: авыл тормышының матурлыгына соклану хисе, яшьләрнең бер – берсенә мәхәббәт хисе сокландыра, Нәфрәт хисе, курку хисе).

Зәңгәр эшләпә. Фикерләрне гомумиләштерү, йомгак ясау. (Көтелгән җавап: без яраткан образлар әсәрдә нидер дәлилли, көтә, өметләнә, расларга омтыла. Минемчә әлеге повестьны укыган кеше әсәрнең буеннан-буена яшәү мәгънәсе турында уйлана. Кеше белән кеше, кеше һәм тирәлек, кеше һәм яшәү рәвеше арасында, кеше һәм җәмгыять,

кешенең үз эчендә һәрвакыт конфликт булып тора. Шунсыз дөнья бармас, мондый матур әсәрләр язылмас иде).
Яшел эшләпә. Иҗади фикерләр. (Көтелгән җавап: әлеге гаилә өр-яңадан тату, дус, бердәм булып бик матур гомер итәрләр дип уйлыйм. Байлык артыннан куу яхшылыкка илтми. Байлык, комсызлык, саранлык кешенең аңын томалый, әхлак кагыйдәләрен оныттыра, кешелеклелек сыйфатларын юкка чыгара.Гаделлек, хәләл хезмәт белән тапкан акча гына сөенеч китерә. Кешеләрне түбәнсетү бәхетсезлеккә илтә. Кешеләргә игътибарлы, олыларга ихтирамлы булсаң,күршеләреңне зурласаң, ата-анаңа ярдәм итеп яшәсәң, хәләл хезмәтеңә ышанып көн күрсәң, кешеләрне яратсаң, һичшиксез бәхетле булырсың, - ди автор).

**IV.** Рефлексия.

1. Өй эше алу. Әсәрне укыганнан соң туган уйлар. Яки фаразлар агачы ясарга.
2. Рефлексия.

- Сезгә дәрес кайсы ягы белән кызыклы булды?
- Дәрестә максатка ирештекме, аның өчен без нәрсә эшләдек?
- Әсәр безгә нәрсәләр турында сөйли?
- Үз тормышыбызда кулланыр өчен нинди яңалык алдыгыз?

3. Дәрескә гомуми бәя. Дәрестәге эшчәнлекнең һәр этабында үзбәя куйдырып, гомуми бәя чыгару, нәтиҗә ясап укытучының бәяләве максатка ярашлы. Берничә укучыдан үзбәясен аргументлаштыруны сорау.

Сәетова Флүзә Флүр кызы,
Әлмәт шәһәре 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе

**Аяз Гыйләҗев “Өч аршын җир” повесте**

| | |
|---|---|
| **Тема** | Аяз Гыйләҗев “Өч аршын җир” повесте. |
| **Дәреснең максаты** | *Белем бирү.* УкучыларныА. Гыйләҗевнең “Өч аршын җир” повестенең эчтәлегенә төшендерү, әсәрне анализлау.<br>*Үстерү.* Монологик һәм диалогик сөйләм телен үстерү, үз фикерләрен дәлилли, нәтиҗә ясый белүләренә ирешү.<br>*Тәрбияләү.* Укучыларда гомумәхлакый сыйфатлар, туган илгә, якын кешеләргә карата мәхәббәт хисе тәрбияләү. |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | *Предмет буенча УГГ:* чәчмә әсәргә анализ ясау, темасын аңлау һәм формалаштыру, идеясен күрсәтү<br>*Танып белү УУГ:* булган белемнәргә таянып, “туган җир” төшенчәсенә кагылышлы мәгълүматны табу, гомуми нәтиҗәне чыгару;<br>*Коммуникатив УУГ:* ишетә һәм тыңлый белү күнекмәләре формалаштыру, фикерләү сәләтен үстерү;<br>*Регулятив УУГ*: әсәргә анализ һәм нәтиҗә ясый белү.<br>*Шәхси УУГ:* үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру. |
| **Предметара бәйләнеш** | Әхлак тәрбиясе , рәсем сәнгате |
| **Ресурслар:** | Төп: Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). 7нче сыйныф. Ике кисәктә. 2нче кисәк / Ә. Р. Мотыйгуллина, Р.Г. Ханнанов, Г.Г. Мулласалихова. – Казан: “Мәгариф - Вакыт” нәшрияты, 2014.(34-41нче битләр)<br>Өстәмә: мультимедиа проекторы, экран, ноутбук, А. Гыйләҗев “Сайланма әсәрләр”, презентация |

| | |
|---|---|
| **Эшчәнлекне оештыру формалары** | Фронталь, парлап, төркемнәрдә эш |
| **Төп төшенчәләр** | Тема, идея, туган җирдән аерылу, сагыну, анализлау, чагыштыру, гомуми нәтиҗә |
| **Дәрес тибы** | Белем һәм осталыкларны системалаштыру дәресе |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| **I.Оештыру. Эшчәнлеккә мотивлаштыру** | Балаларда яхшы кәеф, уңай психологик халәт тудыру. | Укучылар дәрескә әзерләнәләр, укытучыны, бер-берсен сәламлиләр |
| **II.Актуальләштерү, уку максатын билгеләү** | Слайд 2. "Иленнән аерылган – канаты каерылган"<br>-Укучылар, сез "Иленнән аерылган – канаты каерылган" мәкален ничек аңлыйсыз?<br>- Әйе, кеше өчен туган җир бик кадерле. Бу темага багышлап бик күп әсәрләр, шигырьләр, җырлар иҗат ителгән.<br>- *Өй эшенә А. Гыйләҗевнең* "Өч аршын җир" повестеннән өзекләрне укып бетерергә иде. Ничек уйлыйсыз, бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшербез? | - Әгәр кеше туган җиреннән аерылса, оча алмый торган кош кебек була.<br>- Туган җиреннән киткән кеше аны сагына, кайтасы килеп яши.<br>- Без бүген "Өч аршын җир" әсәрен анализларбыз. |
| **III. Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру.<br>Уку мәсьәләсен чишү.** | Слайд 4. Сүзлек өстендә эш.<br>Теләк – желание<br>Васыять – завещание<br>Сукбай - бродяга<br>Язмыш – судьба<br>Күмү – хоронить<br>Дөнья кую — скончаться<br>Аршин - единица измерения длины<br><br>А. Гыйләҗевның "Өч аршын җир" повестен анализлау.<br>-Әсәрдә нинди вакыйга сурәтләнә?<br>-Юлда алар белән нинди хәл килеп чыга?<br>-Алар каян кайталар?<br>-Сез моны каян аңладыгыз?<br><br>-Чыннан да, Шәмсегаянның туган ягыннан озак аерылып торуы ачык сизелә. Ул терелеп киткәндәй була. Бу рухи авыруга дәва булса да, физик авыртуны дәваламый булмый. Аларны хастаханәгә илтәләр.<br><br>Вәсилә Фәттәхова башкаруында "Туган як" җырын тыңлау.<br><br>-Шәмсегаян белән Мирвәли хастаханәдә | Укучылар сүзләрне укыйлар, тәрҗемә итәләр, бер-берсенә әйтәләр.<br><br>-Мирвәли белән Шәмсегаян туган авылларына кайтып баралар.<br>- Шәмсегаян авырып китә. Аны хастаханәгә салу өчен поездда төшереп калдыралар .<br>- Чит җирләрдән кайталар.<br>- Чөнки авыру Шәмсегаянга арыш исе, тургай сайравы, күккүзләр дәва була. Ул үзенең туган җирен сагынган, аңа һәрбер әйбер кадерле. Шуннан аның туган ягына озак кайтмый торуын аңларга була.<br><br>40 биттән диалогны укыйлар. |

| | | |
|---|---|---|
| **Ял вакыты.** | нәрсә турында сөйләшәләр? Табып укыгыз әле.<br>-Шәмсегаян нинди васыять әйтә?<br><br>-Шәмсегаянның бу теләген сез ничек аңлыйсыз? Алар авылдан күптән чыгып киткәннәр. Шуна да карамасатан, Мирвәлигә дә авылда калырга куша.<br><br>-Кызганычка каршы, Шәмсегаян дөнья куя. Ничек уйлыйсыз: Мирвәли аның васыятен үтәрме?<br>- Әсәрнең исеме ни өчен “Өч аршин җир” дип атала?<br>-Шулай итеп, әсәрнең темасын ничек итеп билгеләп була?<br><br>-Бик дөрес. Туган җир һәрвакыт йөрәктә. Кеше олыгайган саен туган якка тартыла, ешрак уйлый башлый. Гомеренең соңгы минутларын булса да туган җирендә үткәрәсе килә.<br>- Дәрес башында әйткән мәкальне искә төшерик әле.<br>- Бу мәкальне Шәмсегаян язмышына бәйләп буламы? | <br><br>-Үзен Карачурага алып кайтып күмүен тели.<br>- Чөнки кеше өчен туган җиреннән дә кадерле, якын җир юк. Аның туган җиреннән аерыласы килми, иренә дә, сукбай кебек читтә берүзен йөрмә, ди.<br>Укучылар төркемнәрдә фикер алышалар. Һәр төркем үзенең фикерен әйтә, дәлилли.<br>-Кешене күмү өчен өч аршын җир кирәк.<br>-Әсәрнең төп темасы – кеше өчен туган якның кадерле булуы.<br>-Чит җирдә ничек кенә рәхәт булса да, кеше туган җирен онытмый, сагына.<br>-“Иленнән аерылган – канаты каерылган”<br>- Әлбәттә. Шәмсегаян туган җирен бер дә онытмый, бик кайтасы килә. Ләкин ул исән килеш кайтып җитә алмый. Ул үзен канаты кайрылган кош кебек хис итә. Соңгы васыяте дә туган ягы белән бәйле. |
| **IV. Йомгаклау һәм рефлексия.** | Синквейн алымы белән нәтиҗә чыгару.<br>1нче юл. Теманы ачыклаучы сүз, исем. Кем? яки Нәрсә? соравына җавап бирә торган сүз.<br>2нче юл. Теманы сурәтли торган ике сыйфат. Нинди?<br>3нче юл. Синквейн темасына хас булган 3 фигыль. Нишли?<br>4нче юл. Теманың эчтәлеген ачучы фраза, җөмлә (афоризм, мәкаль, цитата)<br>5нче юл. Темага карата бер синоним сүз (нәтиҗә, ассоциация)<br>Нәтиҗә ясау. Бөек шагыйребез Г. Тукай туган җиргә чиксез мәхәббәтен шигырь юлларына салган:<br>Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,<br>Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем. | <br>-Туган җир.<br><br><br>-Якын, кадерле.<br><br>-Сагындыра, уйландыра, елата.<br><br>- Туган илнең кадерен читтә йөрсәң белерсең.<br>-Туган як, туган йорт, әти-әни. |
| **V. Өй эше, бәяләү** | 1. “Мин чит җирдә” темасына сөйләргә өйрәнергә.<br>2. Туган җир турында мәкальләр тупларга.<br>3. “.Үз илем - алтын бишек” темасына инша язарга<br>Укучыларның эшчәнлеген бергәләп бәяләү. | Укучылар үз мөмкинлекләреннән чыгып, биремнәрне сайлап алалар<br>Укучылар бергәләп билге куялар |

Исрафилова Ильмира Мөдәрис кызы,
Җәлил гимназиясе, Сарман районы

**Җәннәт аналарның аяк астында**
**(Аяз Гыйләҗевның “Җомга көн кич белән” әсәренә анализ)**

Максат: Укучыларның иҗади фикер йөртү сәләтен үстерү, үз фикерләрен эзлекле, төгәл итеп әйтә алуларына ирешү. Әсәрнең актуальлеген ачыклау; повестьтагы образлар системасын өйрәнү, аларны барлау; әсәрнең идея-эстетик кыйммәтен ачуда аларның ролен билгеләү. Укучыларда безнең иң кадерлеләребез булган эти-әнигә хөрмәт, ихтирам хисләре тәрбияләү, җылы караш формалаштыру, әсәргә карата кызыксыну уяту, матурлыкка соклана белүләренә ирешү.

Материал: 9 нчы сыйныф өчен туган телдәге әдәбият дәреслеге

Җиһазлау: Аяз Гыйләҗев портреты, китапларыннан күргәзмә, әсәр эчтәлеге буенча презентация.

Метод һәм алымнар: проблемалы укыту, әңгәмә.

Дәрес барышы.

1. Оештыру, уңай психологик халәт тудыру. Тема һәм максат белән таныштыру.
2. Уку мәсьәләсен кую.

- Кош очар өчен, кеше бәхет өчен яратылган. Бәхетле булу өчен бик күп нәрсә: тамак тук, өс бөтен, көнкүреш уңайлыгы, сине ярата торган кешеләр – эти-әни, бигрәк тә синең тирәндәге кешеләрнең сине ихтирам итүе кирәк. Һәр кеше – үзе бер дөнья. Тәүфыйклы кешенең йөзеннән нур балкып тора. ”Кешелекле булу – һөнәр түгел, теләсә кемнең кулыннан килә торган нәрсә. Яшәүнең нигезе – игелек, бер-береңә ярдәм кулы сузу. Сез уйлап карагыз! Әгәр дә үзегез ач һәм ялангач урамда калсагыз, ата-анагыз һәм ярдәм итәрлек туганнарыгыз булмаса нишләр идегез!? Бер хәерче бала хәлендә булыр идегез. Сезне ашаткан, киендергән, тәрбия иткән кешеләр кемнәр? Әлбәттә, эти-әниләрегез. Сез аларны “Сөябез, яратабыз!” диярсез, ләкин ата-ананы сөю фәкать тел белән генә түгел, бәлки аларга игътибар һәм аларны зурлау аша буладыр, дип уйлыйм мин.

Шәфкатьле булу – барлык күркәм гадәтләрнең башы, әдәплелекнең нигезе. Бары шәфкатьле бала гына бәхетле, мәрхәмәтле, кешелекле була ала. “Җәннәт аналарның аяк астында”, - дип әйткән Мөхәммәт пәйгамбәр

Без бүген дәресебездә Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” әсәренә йомгак ясарбыз. Әсәрне анализлау барышында балаларның шундый мәрхәмәтсез булып чыгуында кемнең гаепле булуын ачыкларга тырышырбыз. Җәмгыятьме, әллә эти-әни тәрбиясе шундый йогынты ясаганмы?

Укытучы: Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән...” повесте – авыл темасына язылган иң матур әсәрләрнең берсе, авылның гореф-гадәтен, көнкүрештәге милли үзенчәлекләрен чагылдырган повесть. Бу әсәре өчен язучыга 1983 нче елда Татарстан АССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә. “Башка әсәр язмаса да, “Җомга көн кич белән...” повесте белән генә дә, Аяз Гыйләҗев татар әдәбияты тарихында калыр иде”, - дигән фикер белән Тәлгать Галиуллин бик хаклы.

Аяз Гыйләҗевнең язу манерасы – кырыс реализм, халыкчан образларга бай җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары, кайсы чор турында һәм нинди темага язса да, кешенең катлаулы рухи дөньясын, эш-гамәлләрен анализлау. Ул үзенең әсәрләре аша кешене тәрбияли, яшәргә өйрәтә, тормышта килеп туган авырлыклардан куркып калмаска,

үзеңне яратырга, гел кеше турында гына уйламаска өйрәтә. Әхлаксыз адәмнәрнең дөньяда күп булуын, алардан үзеңне саклый белергә кирәклеген аңлата.

Татар халкында ата-анага, туганнарга карата кечелекле мөнәсәбәт, ихтирам хисе – рухи-әхлакый тәрбиянең нигезен тәшкил итә. Таза әхлагы, үзенчәлекле тәрбия чаралары, милли йолалар, гореф-гадәтләре җимерелүгә йөз тоткан милләтнең киләчәген күз алдына китерү кыен түгел. Аяз Гыйләҗев укучыларын әсәрендәге вакыйгалар аша милләтнең киләчәгенә куркыныч янавын кисәтә. Бу проблема бүгенге көндә дә бик актуаль проблемаларның берсе булып тора. Әсәр ни өчен "Җомга көн кич белән" дип аталды микән? ( Бу вакыйга исеме үк татар халкының изге көнен искә ала торган җомга кичендә була. Татар халкының изге кичендә изге күңелле Бибинурның җаны өзелә. Элемтә үзәгендә эшләүче кыз – Миңлегөл, Казаннан корреспондент килүе, балаларыңның сине ташлавы турында язачак дигән сүзеннән соң, килгән кеше өйгә дә керми калмас дип уйлап, Җиһангирның әтиләренә, кирәк-яраклар сорап торырга дип, юлга чыга. Кич, инде караңгы була. Шул вакытта аның каршысына кыргый этләр өере килеп чыга. Ул этләр арасында үзенең этен танып ала, аңа эндәшә. Ләкин эт тә аның яхшылыгын инде онытkan була, аны якламый. Бибинур карчыкны кыргый этләр өзгәли).

- Әсәрнең төп герое кем? (Әсәрдә төп герой – Бибинур. Ул – татар хатын-кызларының сабырлыгын, кешелеклелеген, уңганлыгын, батырлыгын һәм кирәк булганда тәвәккәллеген чагылдырган образ. Бибинур – язучының иң яраткан герое. Аяз Гыйләҗев әйтүе буенча, бу образны ул 20 ел буе уйлап йөргән.

- Бибинурга хас сыйфатларны атап китик әле. (Бибинур – егерме яшьлек кыз, чит кеше кайгысын, аның тирән хәсрәтен уртаклашып кына калмый, бәлки, ятим сабыйларның бәхете һәм киләчәге хакына үзенең матур яшьлеген дә корбан итә, үз баласын күрү һәм үстерү бәхетеннән дә колак кага. Ул үзенә сүз кушкан яшь, чибәр Мирзаһиттан баш тарта, балалар турында уйлый. Бибинур үзеннән өлкән Габдуллаҗанга, аның әнисез калган өч баласын кызганып, кияүгә чыга. Хатын-кыз һәм аналык бурычын үтәүне изге гамәл, саваплы эш дип кенә санамый ул, бәлки шул матур сыйфаты белән халкыбызның намусынаклый, олы җанын күрсәтә, әхлагының саф, чиста, кешелекле булуын дәлилли. Ул гомерен башкаларга багышлаган, артык тыйнак, артык намуслы булган. Аның бу сыйфатларын кешеләр бәяләмәгәннәр, авылдашлары аны аңламаганннар. Көннәр буе колхоз эшендә чиләнеп, төннәр дәвамында чит балаларны карый, кеше арасында ким-хур булып, рәнҗеп, ятимлекләрен сизеп, күңелләре кителмәсен дип, ул аларны үз балалары кебек тәрбияли, мәктәптә укытып кына калмый, һәммәсенә мәктәптән тыш белем бирә. Бибинур – олы җанлы, изге күңелле, риясыз, кешеләргә гел яхшылык кына эшләргә омтылган кеше).

- Габдуллаҗан сугышта үлеп калгач, Бибинур балаларны ташларга уйлыймы? Ул аларны балалар йортларына биреп үз тормышын көйли ала идеме? (Габдуллаҗан сугышта үлеп калгач та, ул балаларны ташламый, аларны үстереп аякка бастыра. Балалары гына аның яхшылыгын тиз оныталар, аның янына кайту түгел, хат та язып салмыйлар. Бибинур ятим балаларны интернатларга таратса да, берни әйтеп, аны кешелексезлектә гаепләп булмас иде. Үз газиз балаларын урамга чыгарып ташлаган ата-аналар Җир шарында җитәрлек).

Укытучы: Автор бу әсәрендә балаларның үги аналарына карата шундый мәрхәмәтсез булуларының сәбәпләрен эзли, укучы алдына сорау куя кебек. Кая монда Бибинурның яхшылыгына рәхмәт, ни өчен гомере буе кешеләргә гел изгелек кенә кылып яшәгән Бибинур карчыкның әчке күлмәгендә дә, ыштанында да ямау өстендә ямау?

(Балалары аңа ярдәм итмәү генә түгел, аның өендә булган барлык әйберсен дә алып киткәннәр: җиз поднос та, самавар да, тегү машинасы да балаларында. Бибинур соңгы мизгелгә кадәр үзенең үги балалары турында кешеләрдән начар сүз әйттерәсе килми).

- Бибинур зиратка ни өчен бара? (Үзендә җаваплылык сизә, өч баланы үзенә алуы белән Гайшә алдында үзен бурычлы саный, Гайшә белән сөйләшә, хәлен уртаклашыр өчен килә).

- Укучылар, Бибинурның Гайшә белән сөйләшүеннән нәрсә аңладыгыз? (Балалар мине ташласа да, сине онытып бетерүләре генә җанны кыйный, ди ул. Бу дөньяда беребез дә мәңгелек түгел, минем дә сезнең янга килер көннәрем якынлаша, Сез мине караңгы чырай белән каршыламагыз яме, дип сөйләшә ул Гайшә белән).

-Бибинур тормыш авырлыгыннан зарланамы, балаларын гаеплиме? (Зарланмый, балалары турында начар сүз әйтми, кешеләр сөйләгәнне дә яратмый. Ул аларны гел яклап чыга. “Мин ярдәмгә мохтаҗ түгел, ди ул, пинсәм чыга, Сабирга ике ел буена ай саен утызар тәңкә акча салып тордым, Идел буенда дача кордылар, ди. Аннан районыбызда музей ачтылар, кыз чагымнан килгән тастымалларны, паласларны, энҗеле калфагымны сатып, Нәҗипкә дә өлеш чыгардым. Тик бер үкенечебез калды: бала сөеп туймадым мин. Балаларның балаларын күрмәдек без синең белән,- дип үкенә Бибинур. Балаларыбыз начар дип кеше юкка сөйли, кыенсынып ятма! Түзик... Кеше хәлен кеше беләмени?..”)

- Ни өчен Бибинур балаларын Сабан туена көтә? (Туганнар очраша торган иң зур бәйрәм. Үзләренең тамырларын белмәсәләр, буыннар чылбыры өзелер, дип курка. Синең катыңа җыйнаулашып, балалар белән бергәләшеп килә алсак, нинди сөенеч булыр иде дә... Беркем дә кайтмаса, ул Сабан туеның ни яме калыр?- дип борчыла ул).

- Бибинурның холык-фигылен, игелеклелеген, шәфкатьлелеген ачарга ярдәм итүче тагын нинди геройлар белән таныштыгыз? (Ярдәмче геройларның берсе-Зөһрәбану. Зөһрәбану-Бибинурның туганы гына түгел, хәтта бер карында бер үк вакытта Бибинур белән яралган кеше. Автор аны бик уңышлы сайлаган. Зөһрәбану-әсәрдә сирәгрәк очраса да, Бибинурның характерындагы түземлелек, сабырлык, кешелеклелек сыйфатларын ачуда зур роль уйнаган персонаж. Ул бөтен дөньяга ачулы, каты күңелле, әче телле, явыз. Аның кылган явызлыклары да үзенә генә бәхетсезлек булып кайта бирә, начар холкы аркасында ирсез кала. Ялгызлык аны тагын да явызрак итә. Зөһрәбануның хәтта тышкы кыяфәте дә үзгәрә. Бибинур күпме мәшәкать чигеп яшәсә дә, күзеннән зәңгәрлеге, иреннәннән елмаюы качмый. Геройларның һәрберсенең тышкы сурәте эчке дөньясы белән туры килә.Туганы никадәр генә әшәкелекләр эшләсә дә, Бибинур үзенең олы йөрәге белән аңа тартыла, картлык көнендә булса да, Зөһрәбануга ир дә табыла. Галикәй бит Бибинурга өмет итеп йөргән була, Бибинур, бу юлы да игезәгеннән кыенсынып, үзенең бәхетеннән баш тарта).

- Җиһангир образы турында нәрсә әйтә аласыз? (Әсәрдә Җиһангир образы буыннар дәвамы, яңа чорның яңача фикер йөртә торган кешесе. Кыска гына вакытка булса да, Җиһангир карчыкка нинди олы хисләр алып килүен белмичә дөнья йөзеннән китә. Бу моңлы мәхәббәт – язучының психологик ачышы – олы хиснең картлык көнендә дә кабынып китәргә мөмкин икәнлеген исбатлый.

Бөтен барлыгын биләгән мәхәббәте соңарып, кояш баер алдыннан килә; бөтен көчен, дәртен, яшьлеген кеше балаларына биргән Бибинур инде картайган, матурлыгын югалткан. Ә кешенең рухи дөньясының тирәнлеген кем аңлаган. Бөтен җегәрен алган, җелеген суырган, үзләре ятимлек газапларын күрмичә үскән балалар үз гаиләләрен корып,

шәһәрдә урнашып калалар һәм үги аналарын бөтенләйгә оныталар. Нәкъ “ит яхшылык, көт явызлык” дигән татар халык мәкалендәгечә. Әллә үги аналары бар, әллә юк алар өчен).

- Кем ул Галикәй? (Галикәй – олы буын вәкилләренең матур сыйфатларын үзенә туплаган герой буларак Бибинур образын тулыландырып тора. Аның балалары да Бибинурныкыннан әллә ни аерылып тормый. Автор үз баласы булган картларның да күбесе бәхетле тормышта яшәми дип әйтәсе килә. Шул рәвешле, язучы аталар-балалар проблемасын да күтәрә).

- Бибинур образын бирүдә язучы символик образлар да куллана. Буа тавышы турында нәрсә әйтә аласыз? (Әсәрнең буеннан-буена иң еш кабатланып килгән символик образ - буа тавышы. Бу тавыш әсәрнең башыннан ахырына кадәр ишетелеп тора).

- Символик образ – юл турында нәрсә әйтә аласыз? (Әсәрдә кабатланып килгән символик образ – юл. Беренче тапкыр ул бу юлдан Җиһангирны күмәргә бара, ә икенче тапкыр бу юл -аның язмышының соңгысы була).

- Эт турында фикерләрегез бармы? (Эт – шулай ук символик образга керә. Бу образ Бибинур балаларының кылган эшләренә ишарә булып тора.Балалары Бибинурны рухи үтергән булсалар, үзе тәрбияләп үстергән эте аның физик үлеменә сәбәпче була).

- Укучылар, әсәрдә нинди каршылыклар белән очраштык? (Бибинур белән авыл халкы арасындагы каршылык, балалар белән Бибинур арасындагы каршылык, табигать арасындагы каршылык)

- Язучы Бибинур язмышын сурәтләп, миһербанлылык, мәрхәмәтлелек, гуманизм проблемаларын калкытып куя. Балаларның шундый мәрхәмәтсез булып чыгуында кем гаепледер дип уйлыйсыз? (Бу очракта нәсел тамыры һәм шәһәр мохиты тәэсире кешелеклелек төшенчәсеннән көчлерәк булып чыгалар. Иң гаҗәбе шунда: Бибинур карчык аларга үпкәләми, рәнҗеми, эшләре күптер, вакытлары юктыр, үзләре генә бәхетле булсыннар дип, тел-теш тидертми).

- Кешеләрдә яхшылык сыйфатлары кими баруның сәбәпләре нәрсәдә дип уйлыйсыз? Бу күренеш заманга бәйлеме? (Әлбәттә, заманга бәйле. Кешеләр байлык, дәрәҗә артыннан куып, ата-анасын, туганнарын оныта, көнчелек, тупаслык сыйфатларын алга куя, туганлык, үзара ярдәмләшү, олыларны олы итү, мәрхәмәтлелек, миһербанлылык сыйфатлары югалып бара)

- Укучылар, бүгенге тема сездә нинди хисләр калдырды? (Балалар, әти-әниләргә мәрхәмәтле булсыннар иде, аларга булышсыннар, авыр сүзләр әйтмәсеннәр, рәнҗетмәсеннәр иде).

- Аяз Гыйләҗев бу әсәрендә Бибинур карчыкның шәхесе аша кешеләрне борчыган иң җитди мәсьәләне – балаларның ата-анага карата каты күңелле булуын күтәрә. Ни өчен гомерен кеше бәхете өчен корбан иткән кешеләр, гадәттә, үзләре бәхетсез булалар? Язмышның усал шаяруымы бу? Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр ничек тәэсир итә бу өлкәгә? Бу сорауларга җавапны өздереп кенә әйтеп булмый. Ләкин Бибинур карчыкның хакыйкатьтән куркуы, үзен аямыйча яшәве фаҗигагә китерә. Бибинурның фаҗигале үле ме – коточкыч гаделсезлек, әшәкелекнең тантанасы. Әдип әгәр әхлак кагыйдәләре бозылса, олы фаҗигагә юл ачык, дия кебек. Аяз Гыйләҗев – кыю каләмле язучы. Ул хөкүмәт тарафыннан җибәрелгән хаталарны яшерми, әсәрләре аша искәртә, җитди сәяси һәм милли проблемаларны укучы алдына куя. Ул татар милләтенең киләчәге өчен борчыла.

“Бибинур” кинофильмы шушы әсәргә нигезләнеп төшерелгән. Искиткеч осталык белән куелган, бүгенге көндә иң кирәкле әхлак мәсьәләләрен күтәргән татарча фильм. Бер

генә анага да Бибинур күргәннәрне күрергә, башыннан кичерергә язмасын! “Ана күңеле- балада, бала күңеле – далада”, - дип юкка гына әйтмиләрдер шул. Ана үлгәнче үзенең баласы турында кайгырта, ә бала башында тормыш мәшәкатьләре, вакыт юклык, төрле бетмәгән сәбәпләр... Минем уйлавымча, Аяз Гыйләҗев бу әсәре аша безгә - яшь буынга эндәшә. Милләтебез асылына, тамырларына кире кайтырга, нигезен югалтмыйча, гореф-гадәтләрен онытмыйча, гаилә традицияләрен саклап калырга тиеш. Соңга калырга ярамый, артка әйләнеп карап, туры юлга чыгарга өнди язучы безне.

Миннибаева Индира Әхтәм кызы,
Салагыш урта гомуми белем бирү мәктәбе, Әгерҗе районы

**Аяз Гыйләҗев иҗаты - дәрестән тыш чараларда**

“Әдәби бәйге” уенының кагыйдәләре белән танышып китик. Бәйгедә 1-4 сыйныф укучыларыннан торган төркемнәр катнаша. Эшне алдан төгәл итеп башкарган төркемгә 5әр балл куела, иң ахырдан бәйгегә жюри тарафыннан нәтиҗә ясала. Бәйгедә алты тукталыш була.

**Максат.**А.Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗаты таныштыру.

**Бурычлар**.Балаларның белемнәрен яңа идеяләр, формалар,алымнар белән баету. Кеше һәм табигать тормышындагы уртаклык турында аңлатуны дәвам итү.Үзләреннән кечерәкләргә, кече туганнарыбызга ярдәмчел, игътибарлы, матурлыкка соклана белүләренә ирешү.

**Беренче тукталыш “Чукмарлы”авылы.**

**1.Башваткыч.** Саннарны хәрефләр белән алыштырып бәйгедә сүз кайсы язучы турында барганлыгын белербез.

| 3 | 10 | 5 | | 11 | 7 | 4 | 6 | 8 | 9 | 2 | 1 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **В** | **Е** | **А** | **Й** | **З** | **Л** | **Ы** | **Ә** | **Җ** | **Я** | **Г** |

2018 елның гыйнвар аенда күренекле язучы һәм драматург Аяз Мирсәет улы Гыйләҗевкә 90 яшь тулды. Ул зурлар өчен бик күп әсәрләр, пьесалар иҗат иткән. Шул ук вакытта кечкенә яшьтәге мәктәп балаларына да бик матур хикәяләр язган. Аяз абый Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган.

**2. “Я, кем белә?”уены**. Әгәр хәрефләрне юллап дөрес урнаштырсагыз, Аяз Гыйләҗев кечкенә яшьтәге мәктәп балаларына нинди хикәяләр язды микән? Шуны белерсез!

| **К** | **У** | **Ы** | **С** | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Р** | **А** | **Т** | **У** | **М** | |
| **М** | **А** | **Н** | **Й** | **У** | **К** |

**Икенче тукталыш: “Югары Баграж”авылы.**

Язучының балачагы һәм мәктәп еллары Зәй районы Югары Баграж авылында үтә.

**1.”Серне тап”.** Әгәр сез язылган язуның серен тапсагыз, Аяз Гыйләҗевнең тагын бер әсәр исемен белерсез.

**“чагуднас мәһ судлИ, услА”**

**2.”Буталмыш” уены.** Бу уен газета-журналларда бик күп басылып чыкканы бар. Туры почмак ясап хәрефләрдән сүз төзергә кирәк. Һәр яңа сүз калын хәрефтән башлана. Әгәр дөрес йөреш ясасагыз, балалар өчен язылган бер хикәядәге герой исемнәрен табарсыз . Алар кайсы хикәя геройлары?

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Х** | ә | **М** | и | р | к | |
| **Т** | л | и | с | ә | ә | |
| а | ж | м | и | **М** | й | |
| т | е | **Ә** | н | ә | ү | |
| д | и | ж | а | е | л | |
| **Г** | н | м | н | т | н | а |
| а | л | и | **М** | у | й | к |

**Өченче тукталыш: Казан (Идел буе) федераль университеты.**

Казан шәһәренең югары уку йорты. Русиянең иң борынгы университетларының берсе. 1948-1950 елларда Аяз Гыйләҗев – Казан дәүләт университеты студенты.

**1.Кроссворд.** Бу сүзләр кайсы хикәягә карый?

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 9.<br>1. | | | | | | |
| | | | 2. | | | | | | |
| | 3. | | | | | | | | |
| 4. | | | | | | | | | |
| 5. | | | | | | | | | |
| | | 6. | | | | | | | |
| | | | 7. | | | | | | |
| | 8. | | | | | | | | |

Сулдан уңга таба:

1. Малайның аяк киеме.
2. Төп геройның зарыгып көткән “кунагы”
3. Әтисе эзләгән эш коралы
4. Әбисе һәрвакыт бара торган кибет.
5. Шарф урала торган урын.
6. Әбисенең кулындагы кирәк-яраклары төшеп киткән җир
7. Әти-әнисе эштә вакытта малайны караучы кеше.
8. Көпшә буйлап аска-өскә хәрәкәт итүче матдә

Өстән аска таба:

9. Әсәрдәге төп геройның исеме

**Дүртенче тукталыш: “Иҗат”**

Аяз Гыйләҗевкә дә шәхес культының газапларын татырга туры килә. 1950 елның мартыннан башлап 1955 елның августына кадәр Казахстанда тоткынлыкта була.

1957нче елның мартыннан 1961 нче елның августына кадәр А.Гыйләҗев матбугат эшендә: “Чаян” һәм “Азат хатын” ( хәзер “Сөембикә”) журналлары редакциясендә әдәби хезмәткәр, “Казан утлары” журналында проза бүлеге мөхәррире вазифаларын башкара.

1961-1963 нче елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укып кайтканнан бирле Аяз Гыйләҗев, язучы-профессионал сыйфатында,әдәби

иҗат эше белән шөгыльләнде.Мәсәлән, “Өч аршин җир”, “Әтәч менгән читәнгә”, “Җомга көн кич белән”, “Язгы кәрваннар” һ.б.

1. **Синквейн**. Хәзер без дә иҗат белән шөгыльләнеп алыйк әле.“Муйнак” һәм “Алсу, Илдус һәм сандугач” хикәяләренең идеясе буенча синквейн төзергә.

**Бишенче тукталыш “Бүләкләр”**

“Җомга көн кич белән” һәм “Әтәч менгән читәнгә” повестьлары өчен А.Гыйләҗев 1983 нче елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Татар әдәбиятын үстерүгә зур көч керткәне өчен Татарстан Республикасының халык язучысы дигән мактаулы исем бирелгән.

Әдәбиятны һәм театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән исемнәргә лаек булган. Әле М.Горький исемендәге премия лауреаты да.

1. **“Паспорт”**

Аяз Гыйләҗевнең “Матур” дигән әсәренең паспортын төзергә.

1.Язучының исем-фамилиясе

2.Әсәр жанры

3.Төп геройның исеме, яше, нәрсә белән шөгыльләнә.

4.Ярдәмче геройларның яше, нәрсә белән шөгыльләнә

5.Портретның сурәтләнеше( өзек)

6.Вакыйга барган урыннарның сурәтләнеше( әсәрдән өзек)

7.Төп геройның кичерешләре

8.Сурәтләү чаралары

9.Төп уе, идеясы

10.Әсәргә карата синең фикерең, сиңа нәрсә бирде?

**Алтынчы тукталыш “Йомгаклау”**

Халыкчан образларга бай, җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары, кайсы чор турында һәм нинди темага язса да,кеше шәхесенең катлаулы рухи дөньясын, эш-гамәлләрен анык итеп күрсәткән олуг әдипләребезнең берсе ул – Аяз Гыйләҗев. Без аның бик горурланабыз! (Бәйгегә нәтиҗә ясала, истәлекле бүләкләр тапшырыла).

Сиякина Нәфисә Равил кызы, Генерал-майор В.А.Хапаев исемендәге
Тәтеш кадет-интернат мәктәбе, Тәтеш районы

## Интеллектуаль уен “Әдәби марафон”

Максаты: Укучыларның язучы иҗаты һәм тормыш юлы турындагы белемнәрен ныгыту; сәнгатьле уку күнекмәләрен һәм фикерләү сәләтләрен үстерү; аның иҗаты үрнәгендә укучыны үз халкын хөрмәт итүче, туган илен, туган телен һәм әдәбиятын яратучы шәхес итеп тәрбияләү.

Катнашалар: 8 -11 сыйныфта укучы татар балалары.

Җиһазлар: Аяз Гыйләҗев портреты, А.Гыйләҗев китаплары, аның турында язылган китаплар һәм журналлар, автор үзе катнашында видео, “Минем таныш өянкеләр” җыры (аудиоязма), презентация, проектор, компьютер.

**Уен барышы**

Аяз Гыйләҗевнең яраткан “Минем таныш өянкеләр” җыры яңгырый. (С. Хәким сүзләре, Р. Яхин музыкасы).

Җырның тавышын азайтып әдип катнашында видео күрсәтелә. (3-4 мин)

А.б.: Хәерле көн, кадерле укучылар, хөрмәтле хезмәттәшләр! Без бүген татар халкының мәшһүр язучысы Аяз Гыйләҗевнең 90 еллыгына багышланган интеллектуаль уенга җыелдык. Мәктәбебездә яраткан язучыбызның туган көнен билгеләп үтәргә тиешле әзерлек эшләре үткәрелде. “Иҗат” түгәрәгенә ятрап йөрүчеләр фәнни җитәкчеләре белән берлектә проект эше алып бардылар. Бүген үткәреләчәк уен бу катлаулы эшнең нәтиҗәсе булып тора. Ул 2 команда арасында үткәрелә. Жюри составына татар теле укытучылары, түгәрәкнең сәләтле членнары, Аяз Гыйләҗевнең тормыш һәм иҗат юлын иң яхшы белүчеләр кертелде.

I. Өй эше. Командалар әдип иҗатына багышлап әзерләгән өй эшен (“визит карточкасы”) күрсәтәләр.

Беренче команда: “Әдәби манзара”

Сибгат Хәким. “Язгы кәрваннар”

1 нче укучы: Бу шигырьнең авторы күренекле татар шагыйре Сибгат Хәким. Ул Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” повестен укыгач, хисләнеп “Бара юлдан язгы кәрваннар” мәкаләсен яза. Анда ул: “...Язгы кәрваннар повестен мин Казан утлары журналы битләреннән җылый-җылый укыдым. Син анда, үзең кичергән яшьлек еллары рухын саклаган хәлдә , каләм көчеңнең олпатлыгын раслагансың. Түзмәдем, шул исемле шигырь яздым”, - дип яза. Үзенең шигырьләр китабын А.Гыйләҗевкә бүләк иткәндә, болай дип искәртеп язып куя: “Аяз туган! Әдәбиятта членнар күп, чын язучылар, художниклар аз. Син – шул азларның берсе”.

Икенче команда: “Иҗатчылар” (Барлыгы 6 балл)
(Ркаил Зәйдулланың “Аяз Гыйләҗевкә” исемле шигырен яттан сөйлиләр).

2 нче укучы: Бу шигырен Ркаил Зәйдулла Аяз Гыйләҗевкә багышлый һәм әсәрендә аның “Йәгез, бер дога” романын телгә ала. Бу әсәрендә ул: “Милләтнең иң зур байлыгы – хәтер. Уртак хәтерсез милләтләр, милләт булудан туктап, халык төркеменә әйләнәләр... Милли хәтер бары тик үз җирендә бердәм булып яшәгәндә генә саклана ала...” – дип яза. Язучы фикеренчә, “... әдәбият нигезендә миллилек ята. Әгәр язучы татар халкының төбенә төшә алмаган икән, аның яшәеш рәвеше белән рухланмаган икән, татар халкына мәхәббәте юк икән – ул инде татар әдибе түгел”. Күренекле язучы, тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин А.Гыйләҗев турында болай дип язып калдырды: “...ул чын мәгънәсендә татар әдибе, татар халкын тирәнтен аңлаган, аның турында чын күңеленнән кайгырган, янган-көйгән язучы. Миллилек ягыннан аны Ә.Еники, М.Мәһдиев белән янәшә куеп була”.

II. Викторина.(А.Гыйләҗевнең тормыш юлы буенча) (Слайд №3)

1. А.Гыйләҗевнең туган авылы.
2. Ул Татарстанннның кайсы районында урнашкан?
3. Бала чагы һәм мәктәп еллары кайсы авылда уза?
4. 1950 елда А.Гыйләҗев тормышында нинди вакыйга була?
5. Аны ничә елга ирегеннән мәхрүм итәләр?
6. Ни өчен?
7. Ул 1950-1955 елларны кая үткәрә?
8. Кайларда белем ала?
9. А.Гыйләҗев нинди жанрларда яза?
10. Ул нинди мактаулы исемнәргә лаек була?
11. Тормыш иптәшенең исеме ничек?
12. Алар ничә бала тәрбияләп үстерәләр, алар кемнәр?

(Сораулар әле беренче әле икенче командага бирелә яисә экрандагы викторина сорауларына ике команда да язмача җавап бирәләр. Вакыт узгач, җаваплар укыла. Дөрес җавапка бер балл куела)

III. “Геройларны таны!” уены (Слайд №4)
(А.Гыйләҗевнең кыска гына проза әсәрләреннән бирелгән өзекләр белән танышып, әсәр исемен һәм төп геройны әйтергә. Дөрес җавапка 2 балл куела)

1. ...Әби утлы бер кисәкне алды да бүреләргә таба китте.

2. ( “Ян, учагым, ян!”, Сәрби түти)

3. ...Әтисе өстенә таяк беркетелгән , бик күп сызыклар төшерелгән сары такта кисәге алып кайтты. “Ул суык килгәнне күрсәтә”- диде әтисе. Малайның исеме ничек? ( “Суык”, Искәндәр)

4. ... Кыз озак уйлап тормады, бияләен тагып куйган җепне өзеп алды да өчпочмакны песинең муенына бәйләп куйды һәм як-ягына каранып песинең колагына:

- Искәндәрнең үзенә генә бир, берәү дә күрмәсен,- дип пышылдады. Кызның исеме ничек? ( “Матур”, Разыя)

5. ...Менә, колакларны ярып, мылтык шартлады. Эт соңгы мәртәбә күзләрен тутырып карады да, эһ тә итмичә егылды. Этнең кушаматы ничек? Хикәянең исеме ничек? ( “Муйнак”, Хәлим)

6. ...Сандугач шул килүеннән китмәде. Шунда оя ясады, бала чыгарды. Бик яратты ул аларның бакчасын. Балаларга бик күп сөенечле минутлар, рәхәт иртәләр алып килде ул сандугач... ( “Алсу, Илдус һәм сандугач”, Алсу, Илдус)

7. ... Малай автобуска җитез генә сикереп менде, тәрәзә яныннан урын алды. ...Автобуска гади генә чалбар, кирза итекләр кигән ап-ак сакаллы бер карт керде. Урын эзләп як-ягына каранды, булмагач, капчыгын һәм кечкенә сумкасын идәнгә куеп, үзе дә шунда басып калды. Малай, картка карап, аскы иренен сузып, чыраен сытты. Малайның исеме ничек? ( “Рәтле кешеләр”, Искәндәр)

IV. Блиц-турнир.Командирлар бәйгесе. (Слайд №5,6)

1. Әдип-галим Тәлгат Галиуллин Аяз Гыйләҗев турында болай дип яза: “Башка бернинди әсәр язмыйча “...” повесте белән генә дә ул татар әдәбияты тарихында калыр иде. (“Җомга көн, кич белән”)

2. “Йөрәк ярам”, - дип яратып атый бу повестен А.Гыйләҗев үзе. Аның сюжеты итеп башкорт дусты Нәҗип Әсәнбаевның гаиләсендә булган хәлне ала. Повестьта сурәтләнгән драматик фаҗига дистә еллар үткәч кенә сәхнәгә күтәрелә. (“Өч аршын җир”)

3. Аяз Гыйләҗев бу әсәрендә яшәүгә мәгънәбиреп торучы өметнең нинди зур, көчле булуын исбат итә. М.Юныс бу турында: “ ...повестьны Д.Лондонның “Яшәү мәхәббәте” һәм Э.Хемингуэйның “ Карт һәм диңгез” хикәяләре рәтенә куярга мөмкин”. (“Язгы кәрваннар”)

4. “Бу повесть- җаныма иң якын әсәр, минем йөз аклыгым”, - дип яза А.Гыйләҗев. (“Яра”)

5. “А.Гыйләҗевнең бу әсәре, аның сүз рәссамы булуын раслый. Хикәя мәхәббәт турында поэма булып яңгырый”, - дип яза әдәбият белгече Ф.Галимуллин. Аның төп герое –яшь егет. Бүген ул сөйгәне белән мәхәббәт аңлашырга тиеш. Ул комбайнер булып эшләсә дә бүген ак күлмәктән, бар нәрсәгә игътибар итә... (“Үги ана яфраклары”)

6. Язучының бу повестендә төп герой – аксакал карт. Тәмле телле, керсез күңелле ул. “Милли традицияләрне, әти-бабаларыгыздан килгән әхлак нормаларын югалтмагыз, дуслык-туганлык хисләренә йөрәгегездә урын калдырыгыз”,- ди ул тупланган байлык аркасында башка нәрсәләргә күзләре капланган, үзара дуслык киртәләрен атлап чыккан ике гаилә членнарына... (“Әтәч менгән читәнгә”)

V. Кроссворд чишү. Тапкырлар һәм зирәкләр бәйгесе (слайд №7, 8 сораулар; слайд № 9 җаваплар)

Вертикаль буенча

1. А.Гыйләҗевкә багышлап язган шигырьнең авторы.

Син бик усал, ач арыслан кебек,
Усаллыгың җитәр йөз елга.
Юаш кына малай идең элек,
Усаллата икән бу дөнья. (Г.Афзал)

2. Тәнкыйтьче Ф.Миңнуллин фикеренчә: “...ул - фәлсәфи повесть. Аның үзәгенә антка тугрылык, мәңгелек мәхәббәт, мәңгелеккә омтылыш кебек җитди мәсьәләләр куелган”. (Яра)

3. Аяз Гыйләҗев - күренекле драматург, ....(прозаик)

4. Әдипнең беренче булып басылган проза әсәре. (Ян, учагым, ян!)

5. “....мине язучы ясады, дисәм дә ялгыш булмас”- дип нәтиҗә ясый А.Гыйләҗев. (Ачлык)

6. Яра повестенең герое. (Зәйтүнә)

7. Сугыштан авыру хәлдә кайткан геройның исеме. (Габдулла)

8. “Үги ана яфракларында” Галимҗан образына капма-каршы куелган образ. (Хәнәфи)

9. Бибинур карчыкның үлгән көне. (Җомга)

10. Үз туган туфрагына кайту турында гомеренең соңгы көннәренә кадәр уйлаган, әмма исән-сау вакытта кайта алмаган геройның исеме. (Шәмсегаян)

11. Әтисенең малын колхозга бирмәс өчен котычкыч җинаять эшләгән геройның исеме. (Мирвәли)

Горизонталь буенча

12. Кроссворд дөрес чишелсә, авторның исеме һәм фамилиясе килеп чыгарга тиеш. (Аяз Гыйләҗев)

VI. Уенга нәтиҗә ясау.

А.б. Яраткан язучыбызга багышланган уен тәмамланды. Барыгызга да зур рәхмәт. Киләчәктә дә бергәләп татар телендә класстан тыш чаралар үткәрергә насыйп итсен. Хәзер сүзне жюрига бирәбез. (Җиңүчеләргә бүләкләр тапшырыла)

Шәймәрданова Лилия Нур кызы, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче беренче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы, Сарман районы

## А.Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” әсәре буенча йомгаклау дәресендә “РАФТ-технология” алымын куллану

(Осталык дәресе)

Һәр дәрес укучы файдасына эшләргә тиеш. Киләчәк кешесе әхлаклы, кешелекле, хезмәт итәргә сәләтле, эшлекле шәхес булырга тиеш. Яңалыкны кабул итү, аны тормышка ашыру бервакытта да җиңел генә бармый, әлбәттә. Ләкин бүгенге мәктәп инновацион педагогик технологияләргә йөз белән борылырга тиеш, бу – заман таләбе. Безгә, туган тел мөгаллимнәренә, тагын да кыенрак. Яңа шартларда без, беренче чиратта, укучының актив эшчәнлегенә – төркемнәрдә, парларда эшләүгә, проблемалы һәм проектлы укыту методларына юнәлтелгән эшчәнлекле төрдәге заманча белем бирү технологияләрен

куллану кирәклеген аңларга һәм шул юнәлештә җиң сызганып эшкә тотынырга кирәк. Дәресләребез мавыктыргыч, кызыклы булганда гына, без укучылар, әти-әниләр белән уртак тел таба алачакбыз.

Бүгенге көн дәресенең яңалыгы нәрсәдә соң? Бу дәресләр укытучы һәм укучы арасында үзара хезмәттәшлеккә нигезләнә. Укучыларны эшкә этәрү, кызыксындыру максатыннан эш күбрәк төркемнәрдә оештырыла. Төркемдәге һәр бала үз фикерен әйтә, башкалар фикерен ишетә ала. Дәресләрнең уңай ягы шунда: дәрестә барлык бала да сөйләшә, төркемдәге балаларга үз фикерен җиткерә. Балалар бер-берсен тыңларга, бергәләп карар кабул итәргә өйрәнәләр.

Укучыларга туган телгә мәхәббәт һәм кызыксынуны ничек уятырга соң? Бу мәсьәләне, укытуның нәтиҗәле алымнарын кулланып, гадәти булмаган дәресләр, укучыларны үзлекләреннән белем алырга өйрәтү аша ирешергә мөмкин. Дәрестә һәр укучыны кызыксындыра белергә һәм эшләргә өйрәтергә кирәк. Дәрес укучы өчен артык катлаулы булмаска, аны эзләнүгә этәрергә тиеш. Монда миңа “РАФТ-технология” алымы ярдәмгә килә.  “РАФТ-технология” алымы – билгеле бер тематикага корылган иҗади эш төрләренең берсе.

Түбәндәге  таблицада РАФТ алымының аббривиатурасы бирелгән.

| Роль | Аудитория | Форма | Тема |
|---|---|---|---|
| Бирелгән теманың кем тарафыннан ачылуын билгеләү | Кемгә текстның багышланганын билгеләү | Жанрны, форманы сайлау | Тематиканы, төп фикерләрне билгеләү |
| КЫСКАЧА | | | |
| Р(оль) – бу эш кем исеменнән; | А(удитория) – бу эш кемгә адресланган; | Ф(орма) – хат, брошюра, интервью, эссе, буклет, альбом стенгазета, һ.б. | Т(ема) – текст нәрсә турында. |

Максаты: Төркемнең һәр катнашучысын кызыксындырып актив эшчәнлеккә тарту, мотивлаштыру; иҗади сәләтне үстерү, һәр укучының үз фикерен белдерүе өчен шартлар тудыру. Эшнең методикасы мондый:

Укучыларга кызыклы, мөһим, актуаль  булган теманы  сайлыйбыз. Укучылар бу теманы бик төптән, тирән үзләштергән булырга тиеш. Шулай ук  фантазиягә бай булу, иҗадилык, креативлык таләп ителә.

Дәрес алдыннан укучылар өчен шушы форматлы таблица әзерләнеп куярга кирәк. Барлык фикерләрне без  шул  таблица графаларына аңлаешлы итеп яза барачакбыз.

Дәрескә күп санлы дидактик күрсәтмә материал әзерләү яхшы. Алар  укучыларга теманы истә калдырырга, аңа  эмоциональ якын килергә ярдәм итәчәкләр.

РАФТ алымы укучыны темага тагын да якынрак тирәнрәк килергә, иҗади фикерләүне үстерергә, үзеңне төрле яктан ачарга, импровизацияләргә, куелган шартларны анализларга, үз фикереңне белдерергә ярдәм итә.

Хәзер бу алымның конкрет дәрестә куллану мисалын карыйк.

9 нчы сыйныфта А.Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” повестеннан өзек өйрәнелә. Өзекләрне өйрәнеп бетергәннән соң, йомгаклау дәресе үткәрелә. Гадәттә, дәрестә геройларга характеристика бирелә, әсәргә анализ ясала. Шул эшләрне тәгаллләгәннән соң без әлеге алымны бик уңышлы куллана алабыз.

Төркемнәрдә роль бүлешәбез. Бибинур әби ул авылда,җәмгыятьтә яши. Аны авылдашлары белә. Алар  төрле оешмаларда эшлиләр. Шулар аша Бибинур әбинең аяныч тормышы турында җитәкчеләр дә белә ала. Укучылар үзләре төрле төрле социаль төркемнәрне тәкъдим итәләр. Төркемнәр санынча рольләр җыелу кирәк.

Аннан таблицаның икенче баганасына хатны кабул итәрлек аудитория булырдай төрле өлкәләрдәге кешеләр, оешмалар һ.б. язылып куела. Бу очракта без Гайшәгә дә, Габдуллаҗанга да хат юллый алмыйбыз, ә менә Бибинур әби үстергән балаларның һәркайсына хат язып була.

Өченче баганага бирелгән социаль рольләргә туры килгән төрле жанрлар сайлана. Без хат язуны алабыз.

4нче графага төп фикерләр, идеяләр языла. Монда инде без мәрхәмәтсезлек, рәхмәтле була белмәүлекне ачкан, аш белән атканга таш белән ату кебек фикерләрне язабыз.

Укучылар төркемнәрдә үзләренә туры килгән рольдән чыгып хат язалар. Аннан шул эшләре белзн таныштыралар. Бу очракта бер үк төрле идея төрле яклап ачыла һәм үтемлерәк аңлашыла. Дәреснең нәтиҗәлелеге дә югарырак була.

Шәйдуллина Гөлнара Индүс кызы, Ләшәү-Тамак “Таң” балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы

**Матуркайга ярдәм итик!**

(Балалар бакчасында якташларыбыз иҗатын өйрәнүне оештыру буенча тәҗрибә уртаклашу)

Максат: Якташ язучылар иҗатын өйрәнүне дәвам итү. Сәнгатьле сөйләүне камилләштерү. Сиземләү тойгысы, кызгану хисе, ярдәмгә килү, юату хисләрен тәрбияләү. Эшкә сәнгать белән карау, бергә дус-тату эшләү.

Җиһазлау: А.Гыйләҗев турында презентация, Сарман районы картасы, районыбыз гербы, йомшак песи уенчыгы, пластилин, такта, өчпочмак рәсеме.

Алдан алып барылган әзерлек эшләре: сәнгатьле сөйләүче баланың эти-әнисенә әдипнең “Матур” хикәясен бирү һәм баланы аның эчтәлеген сөйли белергә әзерләүләрен сорау.

**Шөгыль барышы**

- И сәнмесез, балалар. Хәерле иртә. Әйдәгез әле бер-беребез белән матур итеп исәнләшик! (Балаларның җавабы)

- Х әзер барыгыз да менә шушы стенага эленгән карта янына килегез әле, балалар. Бу без яшәгән район сурәтләнгән карта. Без яшәгән район ..... (Сарман) районы дип атала. Ә без яшәгән авыл ....... (Ләшәү-Тамак, Дүсем) дип атала.

Безнең районда җырчылар, бию осталары, язучылар, шагыйрьләр, театрда уйнаучы артистлар туган. Без аларны сәнгать кешеләре дип йөртәбез. Ә менә бу авылда (картада күрсәтелә) язучы Аяз Гыйләҗев туган. Авылның исеме Чукмарлы дип атала. Бу авылда берәрегезнең туганнары яшәмиме? Хәзер урыннарыбызга утырышабыз да игътибарны экранга юнәлтәбез. Анда без язучы Аяз Гыйләҗевне күрәбез (слайд 1). Менә бу, балалар, ул язган әсәрләр (слайд 2-5). Алар бик калын. Ләкин тиздән сез укырга-язарга өйрәнәчәксез. Аннан бу китапларны укырсыз. Алар бик кызыклы. Алар сезне тәртипле яшәргә өйрәтерләр.

Мәче елаган тавыш ишетелә.

Тәрбияче. Балалар, кем анда елый микән? Яле, карыйм әле!

Ишек артында мәче елап утыра.

Тәрбияче. Кем син? Ник елыйсың болай өзгәләнеп?

Песи. Минем исемем Матур. Ничек еламыйм инде мин. Зур кайгы төште башыма, шуңа бик кайгырам, елыйм!

Тәрбияче. Балалар, ягез әле йомшак песиләрне алып яратыгыз, сыйпагыз әле. Нинди сүзләр әйтерсез микән? Ә мин Матурны юатам. Бәлки аның кайгысы бетәр. (Балалар йомшак уенчыкларга юату сүзләре әйтәләр).

Матур. Мин әзрәк кенә тынычландым. Бик зур рәхмәт сезгә, балалар, рәхмәт!

Тәрбияче. Хәзер сөйлә инде, нәрсә булды соң сиңа?

Матур. Минем кайгымны Аяз абый Гыйләҗев менә бу китабында тасвирлаган.

Тәрбияче. Пескәй, без бит әле укый белмибез. Син безгә үзең сөйлә.

Бер бала. Мин беләм песи турында. Әни миңа бу китапны укыды.

Тәрбияче. Шулаймыни?! Сөйлә инде безгә, песигә ни булган? (Бала “Матур” хикәясенең кыскача эчтәлеген сөйли).

Матур. Менә күрдегезме инде. Мине ачуландылар. Минем бик ашыйсым килгән иде. Ул өчпочмаклардан шундый тәмле ис килде.

Тәрбияче. Балалар, Разыя иселе кызчык дөрес эшләгәнме соң? (Балаларның җаваплары)

Тәрбияче. Нигә? (Балаларның җаваплары: Песи аңламый бит ул. Ул өчпочмакны Искәндәргә бирәсе икәнен белмәде).

Тәрбияче. Дөрес, балалар. Монда Разыя үзе ялгышкан. Песи андый бурычны үти алмый шул. Аңа итле әйберне бирсәң, ашый да бетерә. Ләкин без Разыяны начар кыз дип әйтә алабызмы? Балаларның җаваплары: юк).

Тәрбияче. Ни өчен? (балаларның җаваплары: Ул бит дустына ярдәм итәргә теләгән. Ул – әйбәт дус).

Тәрбияче. Әйе, балалар. Разыяның авырган дустын күрәсе килгән. Ул аны сагынган. Аңа ярдәм итәм дип, күчтәнәчкә өчпочмак бирмәкче булган. Сез дә шундый ярдәмчел, яхшы дус булыгыз, бер-берегезгә ярдәм итегез.

Әйдәгез әле Матурның кәефен күтәрү өчен аның белән бергәләп биеп алыйк. Матуркай, син тәгәрәккә бас. (Физкуль-тәнәфес ясап алу).

Тәрбияче. Ял иттегезме, балалар? Матуркайның күңеле тәмам яхшырсын өчен, мин сезгә аңа күчтәнәч әзерләргә тәкъдим итәм! Ул нәрсәне бик ярата әле, балалар? (Өчпочмакны).

Тәрбияче. Әфәрин! Ә сезнең әниләрегез, әбиләрегез өчпочмак пешерәме? Карап торганыгыз бармы, аны ничек пешерәләр? Сезнең булышканыгыз бармы? (Балаларның җаваплары)

Тәрбияче. Әйдәгез, хәзер бергәләп Матуркайга күчтәнәч итеп пластилиннардан өчпочмак ясап бүләк итик. Ул безнең бүләккә бик шат булыр. Шулай бит, Матур?

Матур. Әйе, әйе.

Үрнәк күрсәтү. Балалар белән эшләү. Матурга күчтәнәчне бирү. Песи рәхмәт әйтеп чыгып китә.

Тәрбияче. Балалар, без бүген кемгә ярдәм иттек, кемне юаттык? (Балаларның җаваплары)

Тәрбияче. Хайваннарны рәнҗетергә ярыймы? (Балаларның җаваплары)

Тәрбияче. Сезнең песиегез Матур кебек еламасын. Авыр сүзләр әйтмәгез. Шөгылебез шуның белән тәмам!

Нуриева Миләүшә Вәгыйз кызы, Җәлил бистәсенең 5 нче санлы
“Әкият” балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы

**“Тылсымлы сүзләр”**

(Уртанчылар төркемендә шөгыль конспекты)

Максат.“Тылсымлы сүзләр” төшенчәсенә аңлатма бирү. Балаларның аларны сөйләмнәрендә куллануларына ирешү. Ягымлы сүзләр белән таныштырып аларны куллана белергә, үзеңне матур тотарга өйрәтү. Дуслык хисләре тәрбияләү.

Сүзләр өстендә эш: рәхмәт, рәхим итеп, исән бул, гафу ит, рәхим итеп, ашларыгыз тәмле булсын, тәмле йокы, хәерле иртә һ.б.

Җиһазлау. Сюжетлы рәсемнәр, А.Гыйләҗев рәсеме, китаплары, буяу өчен әзерләнгән песи рәсеме, алдан әзерләнгән видеоязма.

Барышы:

- Балалар, әйдәгез, бер-берегезгә карап матур итеп елмаегыз әле. Бергәләп исәнләшәбез хәзер. Ничек рәхәт булып китте. Исәнмесез-саумысез, балалар. Безнең телебездә әнә шундый ягымлы, көч, рәхәтлек бирә торган сүзләр бар. Мин аларны “Тылсымлы сүзлләр” дип йөртәм. Ә сез тылсым (волшебство) сүзен ничек аңлыйсыз? Тылсым кайда күп була? (Балаларның җаваплары).

- Исәнмесез, рәхмәт, хәерле иртә – әнә шундый матур, тылсымлы сүзләр. Ә сез тагын нинди тылсымлы сүзләр беләсез. (Балаларның җаваплары).

- Мин сезгә хәзер рәсемнәр күрсәтәм. Сез шул рәсемнәргә туры килгән матур сүзләрне әйтерсез.

Өстәл янында ашарга утыру, торып китү, кереп баручы каршылау, йокларга ятарга әзерләнү, сумка күтәрешеп керү һ.б. шундый рәсемнәр күрсәтелә. (Балалардан: Ашыгыз тәмле булсын, Тәмле булды, рәхмәт. Рәхим итегез. Йокыгыз тәмле булсын. Рәхмәт кебек сүзләр әйттерү).

Менә безнең телебездә никадәр матур сүз бар. Аларны әйтергә генә онытмаска кирәк.

Елап торган малай рәсемен күрсәтә.

- Ә менә бу рәсемдәге малайга рәхәт түгел, балалар. Ул елаган. Ник елады микән? Малайлар, кызлар кайчан елый? (Балаларның җаваплары).

Елап торучы песи рәсеме күрсәтелә.

- Монда да күңелле рәсем түгел. Песи елап тора. Ул ник елый икән? (Балаларның җаваплары)

- Әйдәгез сорыйк әле, безнең песиебез ник елый соң? Пескәй, ник елыйсың,сөйлә әле.

Язма буенча песинең сөйләвен тыңлау.

- Мин Матур исемле песи. Минем хуҗам Разыя исемле кыз. Аның Искәндәр исемле дусты бар. Искәндәр беркөнне бик нык авырып китте. Разыяга ансыз бик күңелсез булды. Разыя урамга да чыкты, тик дусты булмагач, аңа рәхәт булмады. Ул көнне әнисе өйдә өчпочмак пешерде. Разыя ашады да берсен Искәндәргә бирергә уйлады. Тик аларга керергә әнисе рөхсәт итмәде. Авырган кеше янына кермиләр, диде. Шуннан Разыя минем янга килде. Ул минем муеныма бер өчпочмакны бәйләде. Шул күчтәнәчне Искәндәргә бирергә кушты. Ә мин аны ашадым. Ул бик тәмле иде. Разыя мине бик ачуланды. Миңа хәзер авыр.

- Ярар, елама, Матуркай. Ул сине гафу итәр. Ә гафу итсеннәр өчен нинди сүзләр әйтергә икәнен сиңа балалар әйтер. (Балаларның җаваплары)
- Бар, син кайт та Разыяга шулай дип әйт. Ул сине гафу итәр.
- Балалар,ә бу песи безгә менә шушы китаптан килгән бит. Китапның авторы Аяз Гыйләҗев. Ул – безнең якташыбыз. Аяз Гыйләҗев бик күп китаплар язган. (Китапларын күрсәтү).
- Ә песиләр нәрсәләр эшли белә? (Балаларның җаваплары)

Ял итү. Песи кебек юыну, киерелү, йөгерү кебек хәрәкәтләр ясау.

Экраннарда "Морозко" әкиятеннән өзек күрсәтелә.

- Укучылар, бу песи матурга охшаганмы? Ул әйбәт песиме? (Балаларның җаваплары).
- Без хәзер бергәләп матур песи ясап карабыз. Рәсемнәрне дөрес итеп буясак, безнең песиебез Матур кебек матур булыр.

Рәсемнәрне буяу, эш урынын тәртипкә китерү. Иң матур эшләрне билгеләү.

- Матур бу рәсемнәрне күрсә, бик куаныр мде. Ә без кәефебезне күтәрер өчен матур сүзләр куллана алабыз. Кабатлап алыйк әле аларны.

Рәсемнәр кабат күрсәтелә, тылсымлы сүзләр кабатлана.

- Сау булыгыз, балалар. Рәхмәт сезгә. Шөгылебез тәмам.

Шәрифҗанова Ләйсән Касыйм кызы,
Яр Чаллы шәһәре, 54 нче гимназия

## Бала хыялы
## (Аяз Гыйләҗев. "Суык" хикәясе)

| | | |
|---|---|---|
| Класс: 3 | | |
| Предмет:әдәби уку | | |
| Тема: Бала хыялы. Аяз Гыйләҗев "Суык" | | |
| Максат: Аяз Гыйләҗев иҗаты белән таныштыру. Текстта ориентлашырга һәм төп фикерен ачыкларга өйрәтү,сөйләм телләрен баету, аңлап уку күнекмәләре формалаштыру, фикерләүне үстерү; күзәтүчәнлекне, кызыксынучанлыкны үстерү; | | |
| Предмет буенча нәтиҗәләр :<br>Шәхси эшчәнлек: үзбәяләү сәләте формалаштыру, иҗади эшчәнлек булдыру.<br>Танып-белү эшчәнлеге: кирәкле информацияне дәреслектән таба белү.<br>Регулятив эшчәнлек: әңгәмә кору, сорауларга җавап бирә белү.<br>Коммуникатив эшчәнлек: группада хезмәттәшлек итү. | | |
| Төп төшенчәләр: ярдәмчеллек, бердәмлек. | | |
| Пространство оештыру: фронталь, индивидуаль, төркемнәрдә эш | | |
| Чыганаклар:Әдәби уку, 3 класс, 1 нче кисәк, 89-96 б | | |
| Җиһазлау:ПрезентацияPowerPoint – "Аяз Гыйләҗев" | | |
| Предметара бәйләнеш:русский язык, татар теле, әдәби уку, математика, әйләнә-тирә, физкультура | | |
| **Дәрес этабы** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** |

| | | |
|---|---|---|
| **I.Оештыру. Эшкә кызыксыну тудыру.**<br><br>Максат:дәрескә уңай атмосфера тудыру | 1.Уңай психологик халәт тудыру.<br>-Хәерле көн, укучылар. Көннәребез имин, кәефләребез күтәренке, эшләребез уң булсын дигән теләкләр белән әдәби уку дәресен башлап җибәрәбез.<br><br>2. Тел разминкасы.<br>- Укучылар, бүгенге һава торышы турында сөйләп китик әле. | -Укучылар бер-берсенә карап елмаялар, теләк телиләр<br><br><br><br><br><br>-Бүгенге һава торышы турында әңгәмә. |
| **II. Белемнәрне актуальләштерү.**<br>Максат:элек үзләштергән белемнәрне искә төшерү. | 1. А. Әхмәтгалиева “Болытта җиләк үсә” | – Укучылар өлешләп эчтәлеген сөйлиләр |
| **III. Уку мәсьәләсен кую.**<br><br>Максат:<br>яңа белемнәр кабул итүне оештыру, дәреснең темасын, максатын билгели белү | 1.Табышмакларның җавапларын тап.<br>- Аягы юк, кулы юк,<br>Ишек ачуга өй эченә йөгерә.<br>Бу ни була? Кем белә?<br><br>-Кулсыз, күзсез, буяусыз<br>Ясый ул төрле бизәк.<br>Җеркем аны өйрәтми,<br>Ул үзе шундый зирәк.<br><br>-Укучылар, ничек уйлыйсыз, ни өчен мин бу табышмакларны сайладым икән?<br>-Нинди максат куярсыз үзегезгә ? Әдәби уку дәресенең максаты нинди? | <br><br><br>-Суык<br><br><br><br>-Суык<br><br>-Буген суык, кыш көне турында сөйләшербез<br>Аңлап, сәнгатьле укырга өйрәнергә, укыган буенча үз фикереңне әйтә, иптәшләрнең фикерләрен тыңлый белергә. |

| | | |
|---|---|---|
| **IV.Яңа материал өстендә эш.**<br><br>Максат:<br>күзаллау булдыруда ярдәм итү;мисалларкитереп раслый белү | 1.Аяз Гыйләҗев биографиясе белән танышу.<br>Прозаик һәм драматург Аяз Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында туган. Бала чагы Зәй районынының Баграж авылында уза. Мәктәптә Сарманда укый. Аннан соң Аяз Гыйләҗев Казан дәүләт университетында укый. Аяз Гыйләҗев “Чаян”, “Азат хатын” журналларында эшли. Мәскәүдә укып кайткач иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. Балалар өчен дә әсәрләр яза.<br>2.Әдәби әсәрнеберенчел кабул итү.<br>- Балалар, без бүген сезнең белән Аяз Гыйләҗевнең “Суык” дигән әсәре белән танышырбыз.<br>- Ничек уйлыйсыз, ни өчен бу әсәр “Суык” дип атала?<br>- Сүзлек эше: кара чукмар, термометр,тәти, терекөмеш , ярык-йорык, бишмәт.<br>-Укытучының укуы.<br>-Бу әсәр нинди жанрга керә?<br>-Хикәядәге төп катнашучыларны әйтегез. | -игътибар белән тыңлыйлар<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>-Балаларның җаваплары тыңланыла.<br><br><br>-Укучылар сүзләрнең мәгънәсен аңлатуда ярдәм итәләр<br>- Игътибар белән тыңлыйлар.<br>- Хикәя жанры<br>- Әби, әти, Искәндәр, автор, термометр. |
| **V. Яңа белемнәрне ныгыту**<br><br>Максат:<br>ишетеп, күреп тану күнекмәләрен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү. | 1.Текстны анализлый барып, укучылардан кабат укыту.<br>- Термометр малайны нәрсәсе белән кызыксындыра?<br>-Ни өчен әби малайга термометрны бирми?<br>-Искәндәр термометрны нәрсә белән чагыштыра?<br>- Малай суыкны нинди итеп күз алдына китерә?<br>-Искәндәр ни өчен суыкның башына чүкеч белән сугарга уйлый?<br>-Искәндәр тәртипсез малаймы, әллә хыялыймы?<br>-Синең белән бәләкәй вакытта шундый хәлләр булганы бармы?<br>**Күзләргә физкультминутка.** | Укучылар укыйлар, укылган өлешне укытучы ярдәмендә анализлап баралар<br>-ул суык килгәнне күрсәтә<br><br>-Термометр ул уенчык түгел<br><br>- песи белән<br><br>– Суык бик дәү, йөнтәс тышлы тун кигән, борын тишекләре чынаяк зурлыгы бер әкәмәт нәрсә кебек<br>– Искәндәрнең суыкка бик ачуы килде һәм ул аның башына чүкеч белән сугарга уйлады<br>– Хыялый малай<br><br><br>-Укучылар җавабы |
| **VI. Мөстәкыйль эш.**<br><br>Максат: укучыларның игътибарлылыгын тикшерү, хаталарны төзәтү | 1.Төркемнәргә биремнәр бирү.<br>1 төркем: Термометрны ватарга ярыймы? Ватылган очракта нишләргә кирәк?<br>2 төркем: Искәндәр мәрхәмәтле малаймы? Ул сезгә ошадымы? | <br>-Җаваплар әзерләнә, Һәр төркемнән бер укучы җавап бирә |

| | | |
|---|---|---|
| | Ни өчен? Дәлилләгез.<br>3 төркем:Өлкәннәрне тыңламауның бәласе нидә? Син бу хикәяне укып үзеңә сабак алдынмы? | |
| **VII. Белемнәрне гомумиләштерү.**<br><br>Максат: алган белем һәм күнекмәләрне ныгыту һәм гомумиләштерү. | -Суык тиеп чирләгәндә нишләргә кирәк?<br>-Мәтрүшкә үләне турында син нәрсәләр беләсең?<br>-Дару үләннәрен җыю кагыйдәләрен искә төшер | укучыларның җаваплары |
| **VIII. Рефлексия. Уку эшчәнлегенә нәтиҗә.**<br>Максат: дәрестәге эшчәнлекне анализлау,белемнәрне бәяләү, дәрестә алган белемнәрнең әһәмиятен аңлау, аларны киләчәктә куллана белү | -Дәрес сезгә ошадымы?<br>-Аеруча да нәрсә кызыклы булды?<br>-Нинди яңалык белдегез?<br>Матур җавапларыгыз, төпле фикерләрегез өчен рәхмәт. | -укучыларның җаваплары |
| **IX. Өй эше**<br>Максат: өй эшен хәбәр итү, аны башкару ысулын аңлату | Өй эше төркемнәрдә бирелә. Һәр өзеккә исем кушарга, план төзергә | |

Хафизова Айсылу Дамир кызы, Фазлиева Гүзәл Дамир кызы,
Александровка төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

## Җөмлә төрләрен кабатлау

| Тема | Җөмлә төрләрен кабатлау | |
|---|---|---|
| Теманың максаты | 1.Белем бирү: җөмлә төрләре буенча алган белемнәрне һәм җөмләләр белән эшләү күнекмәләрен ныгыту.<br>2. Фикерләү сәләтен үстерү: укучыларның сөйләм телләрен, иҗади фикер йөртү сәләтләрен, танып-белү активлыгын һәм мөстәкыйльлекне, бәйләнешле сөйләм телләрен үстерү.<br>3. Тәрбияви: туган телгә мәхәббәт, бер - берсенә ихтирамлылык, игътибарлылык тәрбияләүне дәвам итү. | |
| Планлаштырылган нәтиҗә | Предмет күнекмәләре | Универсаль уку эшчәнлеге |
| | Җөмлә төрләре турында алган белем һәм күнекмәләрне ныгыту, сөйләмдә һәм язуда дөрес җөмлә төрләрен аера белү осталыгын камилләштерү | Шәхескә юнәлтелгән: әхлак, этика нормалары кысаларында үз урыныңны билгеләү, юнәлеш ала белү, үзләштерелгәнгә бәя бирү.<br>Регулятив: каршылыкларны җиңеп чыгу сәләтенә ия булу, көтелгән нәтиҗәне сиземләү.<br>Танып – белү: уй-фикерне |

| | | |
|---|---|---|
| | | сөйләмә һәм язма формада аңлап һәм ирекле оештыру; эш-хәрәкәтләрнең алымнарын һәм шартларын, эшчәнлекнең барышын һәм нәтиҗәләрен тикшереп һәм бәяләп бару.<br>Коммуникатив: класс белән эшләгәндә классташлар фикерен исәпкә алып эш итү, күршең белән хезмәттәшлек итү. |
| Предметара бәйләнешләр | Әдәбият | |
| Ресурслар<br>-төп<br><br>-өстәмә<br><br><br><br><br><br>Җиһазлау: | Дәреслек: Г.М.Сафиуллина, С.М.Ибраһимов татар теле , 41-43 битләр; эш дәфтәре ;<br>1. Зәкиев М. З. Хәзерге татар әдәби теле синтаксисы һәм пунктуациясе. Укучылар һәм студентлар өчен кулланма. – Казан. Тат.кит.нәшр.,1984.<br>2. А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр. –Казан: “Хәтер”нәшрияты, 2004<br>Интерактив такта, проектор, ноутбук, презентация, таратма материаллар (карточкалар, тестлар, схемалар, А.Гыйләҗев портреты) | |
| Төркемнәрне оештыру | Төркемнәрдә, индивидуаль һәм парлы эш | |
| Оештыру технологиясе | Һәр этапның өйрәтү һәм үстерү биремнәре | Һәр этапның диагностик биремнәре. |
| I этап.<br>Оештыру моменты.<br>Максат – төркемнәрнең дәрескә хәзерлеген күзәтү, барлау; белем алырга әзерлек алып бару. | I этап. Оештыру.<br>1.Дәрескә әзерләнү. Нинди максат белән килдегез?<br>Хәерле көн, укучылар!<br>Хәерле көн барчагызга<br>Телимен чын йөрәктән.<br>Башлыйк, дуслар, дәресне<br>Шундый изге нияттән.<br>Эпиграф: “Халкым теле – хак телем син, йөрәк телем.<br>Киләчәгем өчен мәңге кирәк телем.<br>(Лена Шагыйрьҗан)<br>Бүген сезнең белән җөмлә төрләрен кабатларбыз, белем дәрәҗәсен ачыкларбыз. Белемле икәнегезне күрсәтерсез дип ышанам. | Саф ана телебездә укырга , язарга, сөйләргә өйрәнергә дип килдек. |
| II этап<br>Актуальләштерү.<br>Максат – белем алуга карашларын ачыклау, алдагы дәрестә алган белемнәрен тикшерү. | II этап.<br>Укучылар әзерләп килгән сорауларын бирәләр.<br>Җөмләләрне укыйлар. | II этап.<br>Соруларга дөрес җаваплар. (Шәхескә караган универсаль уку эшчәнлеге) |
| III этап.<br>Ныгыту өстендә эш. | IV этап.<br>1. ”Хатаны тап” уены (Танып белү | IV этап.<br>1. Диагностик |

| | | |
|---|---|---|
| Максат - җөмлә төрләре буенча алган белемнәрне һәм җөмл әләр белән эшләү күнекмәләрен ныгыту. | универсаль уку эшчәнлеге)<br><br>2.Дәреслектәге 63 нче күнегүне дәфтәрләрдә эшләү, җөмләләргә тасвирлама бирү.<br>Сүзлек өстендә эш<br>Кандала үләне – нык тармакланып үсүчән, ак яки сары чәчәк ата торган начар исле үсемлек. (донник)<br>Чабыр төнәтмәсе – тумар баш үләненнән кайнаткан төнәтмә. (чабрец)<br>Рәшә – игеннәр өлгергән чорда басу өстендә тирбәлүче җылы һава дулкыны. (Коммуникатив универсаль уку эшчәнлеге) | бирем:<br>3 кагыйдәнең билгеләмәсен әйтү, шуның берсе хаталы, укучы хатаны табарга тиеш (Шәхескә караган универсаль уку эшчәнлеге)<br><br>2. Диагностик бирем: Дәфтәргә җөмләләрне язу, җәяләрне ачу. Җөмлә төрләрен билгеләү. Үзтикшерү. (Шәхескә караган универсаль уку эшчәнлеге) |
| IV этап.<br>Алган белемнәрне гомумиләштерү. | IV этап.<br>1. Мөстәкыйль эш. Бирелгән схемалардан җөмләләр төзергә.<br>1. Гади, ике составлы, раслау, җәенке, хикәя җөмлә.<br>2. Гади, ике составлы, инкяр, җәенке, сорау җөмлә.<br>3. Гади, бер составлы, раслау, җәенке, тойгылы җөмлә.<br>(Шәхси универсаль уку эшчәнлеге) | IV этап.<br>1. Диагностик бирем: Схемаларга туры китереп, җөмләләрне уйлап дәфтәргә язарга. (Танып белү универсаль уку эшчәнлеге) |
| V этап. Контроль.<br>Максат –укучыларның игътибарлылыгын, хаталарны тикшерү һәм төзәтү. | V этап.<br>1. Тест чишү.<br>Җөмлә төрләре буенча тест<br>1. Билгеләмәгә туры килгән җөмләне табыгыз.<br>Йомычкалар шылтырап торган коры иде.<br>(А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 220 нче бит)<br>1) Хикәя, раслау, ике составлы, җыйнак җөмлә.<br>2) Хикәя, инкяр, бер составлы, җәенке җөмлә.<br>3) Хикәя, инкяр, ике составлы, җыйнак җөмлә.<br>4) Хикәя, раслау, ике составлы, җәенке җөмлә.<br>2. Җөмләнең төрен билгеләгез.<br>Берәм-берәм авыр, саллы йолдызлар кабынды.<br>(А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 220 нче бит)<br>1) гади 2) кушма<br>3. Җөмләнең төрен билгеләгез.<br>Татымады, дөнья тәмен, өлгермәде. (А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 223 нче бит)<br>1) раслау;<br>2) инкяр.<br>4. Җыйнак җөмләне табыгыз.<br>1)Байтак җир бит. (А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 225 нче бит)<br>2) Яз явымлы иде быел. (А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 226 нчы бит) | V этап.<br>1. Тестларны дөрес чишү |

| | | |
|---|---|---|
| | 3) Бибинур ышанып бетмәде. (А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 232 нче бит)<br>4) Почта тәрәзәләре бар да ачык. (А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 241 нче бит)<br>5. Оештыручы үзәкнең санына карап, җөмләләр нинди төрләргә бүленәләр?<br>1) раслау һәм инкяр.<br>2) бер составлы һәм ике составлы<br>3) гади һәм кушма<br>4) җәенке һәм җыйнак<br>6. Җөмлә нинди мөнәсәбәт нигезендә барлыкка килә?<br>1) хәбәрлекле 2) төгәлләүле<br>3) аныклаулы<br>7. Әйтү максаты буенча җөмләләр нинди төрләргә бүленәләр?<br>1) хикәя, сорау, боеру<br>2) бер составлы, ике составлы<br>3) раслау, инкяр<br>4) гади, кушма<br>8. Җөмләнең төрен билгеләгез.<br>Сабан туена төгәл бер атна бар. (А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 246 нчы бит)<br>1) җыйнак 2) җәенке<br>9. Җөмләнең төрен билгеләгез.<br>Бибинурның моңа әллә ни исе китмәде.(А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 248 нче бит)<br>1) раслау 2) инкяр<br>10. Инкяр җөмләне табыгыз.<br>1) Сабирҗан солдатның йомык күз кабагы сикереп куйды. (А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 249 нчы бит)<br>2) Монысына ул кистереп кенә җавап бирә алмас. (А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 252 нче бит)<br>3) Киткән кошларның һәммәсенә хәерле юл теләде. (А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 253 нче бит)<br>4) Тоташ яңгыр астында кайттык. (А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 257 нче бит)<br>11. Раслау җөмләне табыгыз.<br>1) Ат тарта алмый, мескен. (А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 257 нче бит)<br>2) Абзарда сыер мөгри, сарыклар кычкырыша иде. (А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 257 нче бит)<br>3)Каршы сүз әйтмәсләр. (А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 259 нчы бит)<br>4) Утны сүндергәч, бибинур ятарга ашыкмады. (А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 264 нче бит)<br>(Регулятив универсаль уку эшчәнлеге)<br>2. Иҗади диктант.<br>Сишәмбе көн кичәгедән дә ягымлырак, ямьлерәк булып туды – Саба нтуена кергән атнада табигать шулай чуклы-бизәкле була инде ул. | 2.Диагностик бирем: Җәенке җөмләләрне җыйнак җөмләләргә әйләндерергә, кушымчаларны үзгәртергә мөмкин.<br>- Нинди әсәрдән алынган?<br>- Нәрсә турында бара?<br>(Шәхси универсаль уку эшчәнлеге) |

| | | |
|---|---|---|
| | Игеннәр күзгә күренеп калка.Чөгендер, бәрәңге басуларының кара җире күренми башлый. Ул кошлар, иртәнге шәфәкътән кичкә кадәр өзлексез сайрашалар, берсе тукталса, икенчесе алып китә. Капкалар җырлап кына ачыла, морҗалардан хуш ис тарала, яшь кызларның сулышлары, адымнары үзгәрә.(А.Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр, 269 нчы бит). (Шәхси универсаль уку эшчәнлеге) | |
| VI этап. Рефлексия. | VI этап.<br>Җөмлә төрләре буенча презентация карау | VI этап. |
| VII этап. Йомгаклау. | VII этап.<br>1.Өй эше. 1вариантка: А.Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән" повестьтеннән бер составлы җөмләләрне генә язарга.<br>2 вариантка: А.Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән" повестьтеннән ике составлы җөмләләрне язарга.<br>2. Укучыларның дәрестәге эшчәнлеген бәяләү. | |

Шәгалиева Гөлназ Нәҗип кызы,
Актүбәнең 2нче урта мәктәбе укытучысы, Азнакай районы

**Аяз Гыйләҗевнең иҗаты һәм тормыш юлы -"Могҗизалар кыры"уенында**

Максат: уен аша күренекле язучы иҗатына кызыксыну уяту. Аның әсәрләрен уку теләге булдыру. Логик фикер йөртү күнекмәләрен камилләштерү, игътибарлылык тәрбияләү.

Уенга катнашучы: 9 нчы сыйныф укучылары (татар төркеме)

Җиһазлау: презентация, биремнәр өчен кирәкле атрибут

Уенның барышы

Укытучы. Укучылар. Без узган дәрестә күренекле язучы Аяз Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән" әсәреннән өзекләр белән таныштык. Аяз Гыйләҗев – талантлы һәм үзенчәлекле прозаик. Ул – татар әдәбиятын уй-фикерләренең торгынлыгыннан коткарып, алтмышынчы-сиксәненче еллар әдәби агымын дәррәү кузгатып, хөрлеккә таба борып җибәрүче язучы. Халык язучысы Аяз абыйның мирасы – татар халкы өчен генә түгел, бөтен кешелек дөньясы өчен зур хәзинә! Ул мәңгелек! Аяз Гыйләҗев киләчәктә тә иң күп укылачак, алай гына да түгел, бер кулыңа килеп эләккәч, кат-кат укылачак әдип! Аяз Гыйләҗевнең иҗат колачы шактый киң. Без аны беренче чиратта, күренекле прозаик буларак хөрмәт итәбез. Тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин аның күпкырлы иҗатын җирдән бәреп чыккан кайнар чишмә белән чагыштыра.

(Слайларда әдип иҗаты турында фикерләр язмасы күрсәтелә)

Укытучы. Сез телевизор экраннарында күрсәтелә торган "Могҗизалар кыры" уенын яратып карыйсыздыр. Мин бик яратам бу уенны. Бүгенге дәресебез нәкъ менә шушы уен форматында булачак. Ул 3 турдан тора. Һәр турда 3 укучы катнаша. Җиңүчеләр финалда ярышачак. Уен тәртибен беләсез. Алай да искә төшереп үтү комачау итмәс. Экранга карыйбыз.

("Могҗизалар кыры" уеныннан өзек язмасы күрсәтелә)

Укытучы. Сайлап алу турын башлыйбыз. Сорауларны игътибар белән тыңлыйбыз. Һәркем нәтиҗәле эшләргә омтылсын иде. Бөтен биремнәрнең Аяз Гыйләҗевнең тормышы, иҗаты белән бәйләнгән булуын онытмагыз.

1 турга сайлап алу сораулары экранда күренә. Бирем: артык сүзне тап.

1. Зәй, Сарман, Түбән Кама, Казан
2. “Җомга көн кич белән”, “Әтәч менгән читәнгә”, “Буранда”, “Йәгез, бер дога!”
3. Драматург, прозаик, шагыйрь

Укытучы. Беренче тур җиңүчеләре билгеле. Аларны барабан артына чакырабыз. (Уен тәртибе буенча дәвам итә)

Бирем. Аяз Гыйләҗевнең әтисенең исеме ничек? (**Мирсәет**)

Җиңүче билгеләнә.

Музыкаль пауза. (Әти-әниләр турында җыр өзеге яңгырый)

2 турга сайлап алу сораулары экранда күренә. Бирем: Артык сүзне тап.

1. Сарман мәктәбе, КДУ, Мәскәү нефть институты, Югары әдәби курслар
2. Искәндәр, Лилия, Мансур, Рәшат
3. Рус, венгр, төрек, француз

Укытучы. 2 нче тур җиңүчеләре билгеле. Аларны барабан артына чакырабыз.

2 нче тур өчен бирем. Бибинур яшәгән авыл исеме. (**Аксыргак**)

Музыкаль пауза. Туган як, туган җир турында җыр язмасы

3 турга сайлап алу сораулары экранда күренә. Бирем: Артык сүзне тап.

1. Галикәй, Зөһрәбану, Нәкыя, Бибинур
2. Тегү машинасы, самавыр, үтүк, чигүле сөлгеләр.
3. Шәфкатьле, артык юаш, хәйләкәр, изге күңелле

Укытучы. 3 нче тур җиңүчеләре билгеле. Аларны барабан артына чакырабыз.

3 нче тур өчен бирем. “Җомга көн кич белән”әсәре буенча фильм төшерелгән. Ул ничек атала? **(Бибинур)**

Экраннарда фильмнан өзек күрсәтелә.

Укытучы. Уенның җиңүчеләре билгеле. Инде мин аларның өчесен дә финалга чакырам.

Финал өчен бирем. Фильмда Бибинур ролен уйнаган актрисаның фамилиясе.

(Экранда Ф.Әхтәмова турында материал бирелә)

Супер уен өчен бирем. А.Гыйләҗевнең 5 ел гомерен уздырган лагерь атамасы.

Укытучы. Уен тәмам. җиңүче билгеле. Минем сезгә бер теләгем бар. Укыган әсәрләрне онытмагыз, китаптан аерылмагыз. Туган телебезне яратыгыз. Аяз Гыйләҗев туган телебезнең бүгенгесе һәм киләчәге турында кайгырып, борчылып яшәде. “ ... Мин милләттәшләремдә, җирдәшләремдә, замандашларымда әле сүнеп бетмәгән, заманның явыз тизлеге белән капланып өлгермәгән Туган илгә мәхәббәтне кайтарырга телим...” , - дип яза ул. Бүген туган телебезнең язмышы күбебезне борчый. Аяз Гыйләҗевнең безгә туган телне саклау, кадерләү, ярату турында бик акыллы киңәшләр бирә. Менә аларның кайберләре: (экраннарда)

“Иң беренче үз телеңне камил бел! Аңа зур хөрмәт белән кара, башкаларны шуңа өйрәт. Онытма: синең телең дөньядагы иң камил, иң бөек ундүрттелнең берсе. Теленнән йөз чөергәннең- теле көяр!“

“Үз халкыңның үткәнен бел, аның чын тарихы белән кызыксын. Өйрән һәм башкаларга да шуны сөйлә. Үткәне юкның – киләчәге дә юк!”

“Татар халкы олуг әдәбиятлы, зур мәдәниятле милләт. Аның әдәбият-сәнгатен үзләштер, даими кызыксынып бар, өйрән һәм башкаларга да шуны сөйлә, өйрәт! Үзенекен кире каккан – үзен кире каккан!”

Бу сүзләр бүгенге дәреснең кагыйдәләре булып күңелегездә калсын. Дәрес тәмам.

## Эчтәлек

**ТӨЗҮЧЕЛӘРДӘН** ........ 3

Ландыш Шәйдуллина, Сарман районы татар теле һәм әдәбияты укытучыларының район методик берләшмәсе җитәкчесе

**Гыйбрәтле язмыш сәхифәсе** ........ 4

Габдулхакова Инсия Зуфаровна, «Джалильская СОШ№2», Сармановский район, Мирсаяпова Гульназ Зуфаровна, «СОШ №17»г. Альметьевска

**Рассказы Аяза Гилязова** ........ 6

Ситдикова Розалия Хадиулла кызы, Мөбарәкшина Гүзәл Гарифҗан кызы, Казан шәһәре, Совет районы, 111 нче рус -татар урта гомуми белем мәктәбе

**Мин намуслы яшәдем** ........ 7

Зиннәтова Лилия Максут кызы, Алабуга шәһәре, 10нчы санлы урта гомумбелем бирү мәктәбе

**Аяз Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән"әсәренә анализ ясау** ........ 11

Рәхмәтуллина Рәмзия Рафик кызы, Чишмә гомуми урта белем бирү мәктәбе, Алексеевск районы

**КВН (Аяз Гыйләҗевнең "Язгы кәрваннар" әсәрен йомгаклау)** ........ 14

Шакирова Рузалия Сәгыйть кызы, Гали Акыш исемендәге 84 лицей-интернат, Яр Чаллы шәһәре

**А.Гыйләҗевнең "Язгы кәрваннар" әсәренә образлар бирелеше ягыннан анализ** ........ 18

Гыйзәтуллина Линиза Минехөрмәтулла кызы, Галәветдинова Гүзәлия Хәмит кызы, Казан шәһәре, Идел буе районы, 19 нчы гимназия

**Халык йөрәгенә уелып кергән "Бибинур"** ........ 21

Васильева Римма Николай кызы, М.К.Кузьмин исемендәге Иске Тәрбит урта гомуми белем бирү мәктәбе, Кайбыч районы

**Аяз Гыйләҗевнең "Әтәч менгән читәнгә" повесте** ........ 24

Гайнуллина Рузанна Сергей кызы, Пәрәү гомуми урта белем мәктәбе, Лаеш районы

**Аяз Гыйләҗев. "Язгы кәрваннар" әсәренең 1нче бүлеген өйрәнү** ........ 28

Әсәдуллина Әлфия Мансур кызы, Хәбибуллина Миләүшә Хәмит кызы, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы ........ 31

**Сез һәрвакыт безнең белән, Аяз ага Гыйләҗев** ........ 31

Асылгәрәева Розалия Әнәс кызы, Тихонова Резедә Рәфәт кызы, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче мәктәбе, Сарман районы

**Аяз Гыйләҗев - татар әдәбиятының мәңгелек сүнмәс уты** ........ 33

Фахразиева Лилия Фәнүз кызы, 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Әлмәт шәһәре

**Әдәбиятыбызның имән баганасы** ........ 36

Нуретдинова Айгуль Гамирзяновна, "Джалильская СОШ №2"; Сармановский район, Валиахметова Заря Азатовна,"СОШ №16" г.Альметьевск

**Аяз Гилязов – писатель жизни татарского народа** ........ 43

Михайлова Әлфия Мостафа кызы, Ләке төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Татар әдәбиятының имән баганасы - Аяз Гыйләҗев** ........ 46

Һадиуллина Гөлнара Әкмәлетдин кызы, Сарман гимназиясе, Сарман районы

**Һөнәрне ничек сайларга?** ........ 49

Шакирова Дилбәр Сәгыйть кызы, Тау Иле урта гомуми белем мәктәбе, Мамадыш районы

**Аяз Гыйләҗев - безнең күңелләрдә**......50

Ильина Дилүзә Рафак кызы, Ләке төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Татар теленнән белемнәрне барлыйбыз**......53

Гайфуллина Зөлфия Нуриман кызы, Муртазина Альбина Николай кызы, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче, Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Аяз Гыйләҗев - татар әдәбиятының мәңгелек сүнмәс йолдызы**......59

Газизова Рәмзия Асфан кызы, Бәдертдинова Илсөяр Изаил кызы, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче,

Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**А.Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән" әсәрендә Ана образы**......61

Әгълиуллина Рәсимә Мөхәмәтгали кызы, Зарипова Эльмира Мансур кызы, Тайсуган төп гомуми белем бирү мәктәбе, Әлмәт районы

**Сугыш чоры балаларының батырлыгы һәм сугыш китергән афәт**......62

Салимгараева Альфия Мидхатовна, Гордюшина Лилия Зульфаровна, "Джалильская СОШ №2", Сармановский район

**Классный час: «Память сердца»**......66

Токранова Эльвира Ильяс кызы, Балык Бистәсенең 2 нче урта мәктәбе, Балык Бистәсе районы

**Аяз Гыйләҗевнең "Язгы кәрваннар" повестенда шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләре**......71

Идрисова Гөлшат Язкәр кызы,Әсәдуллина Әлфия Мансур кызы, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче, Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Җәннәт аналарның аяк астында**......73

Гыймалетдинова Нурзия Минәхмәт кызы, Кизләү төп гомуми белем мәктәбе, Алексеевск районы

**Бәхет өчен нәрсә кирәк?**......75

Габдулхакова Инсия Зуфаровна, Зямилова Гульнур Раисовна, МБОУ«Джалильская СОШ№2», Сармановский район

**Классный час: «С любовью к животным. Знакомство с творчеством АязаГилязева»**......78

Габдуллина Раушания Сәлим кызы, Түбән Каманың 29 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе

**Сагынабыз сине, Аяз абый!**......79

Закирова Роза Ахмед кызы, Муллагалиева Халидә Миннесаяф кызы, Менделеев шәһәренең беренче гимназиясе

**Кеше язмышы кем кулында?**......82

Хәлилова Гөлүсә Зөфәр кызы, Балык Бистәсенең 2нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Балык Бистәсе районы

**А.Гыйләҗевнең " Җомга көн кич белән..." повесте**......83

Ибрагимова Альфира Наил кызы, Хабибуллина Гөлнара Флорис кызы, Зур Нөркәй урта белем бирү мәктәбе филиалы – Юлтимер төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Шушы яктан, шушы туфрактан без**......88

Гордюшина Лилия Зөлфар кызы, Нуртдинова Гөлнар Салихҗан кызы, икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Әнием йөрәге - әдәби әсәрләрдә**......91

Халиуллина Люция Гатуф кызы, Александровка төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**А.Гыйләҗевнең тормыш юлына һәм иҗатына багышланган"Тамчы шоу" уены**......93

Баязитова Гөлфинә Фәһим кызы, Казан шәһәренең 117нче гомуми урта белем бирү мәктәбе

**Туган җирдән аермасын язмышлар** ....... 95

Нәбиуллина Гөлназ Ринат кызы, Яр Чаллы шәһәренең 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе

**Аяз Гыйләҗев «Җомга көн кич белән» әсәрен анализлау тәҗрибәсеннән** ....... 107

Смирнова Гөлнара Рәшәт кызы, Менделеевск шәһәренең 1 нче гомуми белем бирү мәктәбе

**“А.Гыйләҗев: тормыш тәрәзәләре” темасына квест эшкәртмәсе** ....... 111

Данилова Зөлфирә Сәләхетдин кызы, Әшрәфуллина Розалия Илдар кызы, Алабугадагы 10 нчы урта мәктәп

**Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм иҗатына багышланган “Нәрсә? Кайда? Кайчан?” интеллектуаль уены** ....... 115

Гарифуллина Ландыш Ринат кызы, Алабирде урта гомуми белем бирү, Тәтеш районы

**Мәхәббәт ул – тылсым** ....... 118

Яхина Алсу Халит кызы, Ләшәү-Тамак төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Дус беленер авырлыкта, ир беленер батырлыкта** ....... 120

Шайдуллина Гөлназ Ришат кызы, Ләшәү-Тамак төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Аяз Гыйляҗев**нең торм**ыш юлы һәм иҗаты, “Язгы кәрваннар”повесте** ....... 123

Мингалеева Рәмзия Әхмәтзакир кызы, Масловка урта гомуми белем бирү мәктәбе, Балык Бистәсе районы

**Аяз Гыйләҗев “Җомга көн, кич белән...”** ....... 125

Харисова Ильсеяр Музагитовна, Галиева Лейсан Анваровна, Талипова Ляйсан Равилевна, «Джалильская СОШ №2», Сармановский район

**“Главное ценность – человек”** ....... 131

Җәлилова Миләүшә Ринат кызы, Азнакай шәһәренең 1 нче урта гомуми белем мәктәбе

**А.Гыйләҗевның “Җомга көн кич белән...” әсәрен йомгаклау** ....... 134

Нуртдинова Раушания Равил кызы, Кәлимуллина Әлфия Нәҗиб кызы, А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш мәктәбе, Сарман районы

**“Мәхәббәт һәм нәфрәт җырчысы”** ....... 137

Мусина Гузель Фаритовна, Юнусова Резеда Фадитовна, «Джалильская СОШ №2», Сармановский район

**A.M.Gilyazov. “On Friday evening”** (А.М.Гилязов «В пятницу вечером») ....... 145

Александрова Әлфинур Әбүзәр кызы, Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Якташыбыз - Аяз Гыйлаҗев** ....... 149

Кирилова Алсу Мансур кызы, Минзәлә шәһәренең 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе

**Мәктәптә, инновацион технологияләр кулланып, Аяз Гыйләҗев иҗатын өйрәнү** ....... 152

Афзалова Луиза Әкрам кызы,Шәйдуллина Ландыш Камил кызы, икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Хаталар кабатланмасын!** ....... 156

Шәйхелисламова Лилия, Бариева Фәнүсә,икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Аяз Гыйләҗевның тормышы һәм иҗаты** ....... 161

Салихова Гөлнара Атлас кызы, Яңа Кәшер санатор интернат-мәктәбе, Әлмәт районы

**Татар әдәбиятының алтын баганасы** ....... 163

Гайсина Гөлүсә Рифхат кызы, 19 нчы урта мәктәп, Яр Чаллы шәһәре

**Татар әдәбиятының алтын баганасы** ....... 170

Гаскәрова Ләйсән Минифәвис кызы, икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**А.Гыйләҗевнең "Матур" хикәясе**....175

Умнова Лилия Иван кызы, Мәләкәс урта мәктәбе, Тукай районы

**А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» әсәренә мифопоэтик анализ**....178

Умнова Лилия  Иван кызы, Тукай районы Мәләкәс гомуми урта белем бирү мәктәбе

**Сынмаганнар, сыгылмаганнар**....185

Баһавиева Лилия Данис кызы, 43 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе

**Аяз Гыйләҗев "Өч аршин җир" әсәре**....192

Гыйниятуллина Раилә Хәбибулла кызы, 43 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе

**Аяз Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән" әсәре**....194

Бәдриева Фәридә Рәис кызы, икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**А. Гыйләҗевнең "Матур" хикәясендә дуслык темасы**....195

Нәҗметдинова Чулпан Мөнир кызы, Сарман аграр көллияте, Сарман районы

**Аяз Гыйләҗев иҗатында Туган җирем сукмаклары**....197

Гимадиева Гөлнар Фоат кызы, Яр Чаллы шәһәренең 1 нче урта мәктәбе

**Мәктәптә Аяз Гыйләҗев иҗатын өйрәнүнең куелышы**....201

Гыйлемханова Сиринә Мөрсәлим кызы, Балык Бистәсенең 2нче урта мәктәбе, Балык Бистәсе районы

**Әдәбиятның алтын баганасы**....205

Гыйльфанова Ильмира Альберт кызы, Сарман гимназиясе, Сарман районы

**Нәниләрнең хыялы** (А. Гыйләҗев "Суык" хикәясе)....208

Садриева Гөлнара Миңнулла кызы, Баек төп гомуми белем бирү мәктәбе, Мөслим  районы

**Аяз Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән"әсәрендә автор позициясе һәм повестьның сәнгати үзенчәлекләре**....210

Тимергалиева Илсөя Рифкать кызы, Яр Чаллы шәһәренең 54 нче гимназиясе

**Аяз Гыйлажевнең 90 еллыгына багышланган класстан тыш чара**....212

Шәрифуллина Румия Рифгать кызы, Песәй урта мәктәбе, Менделеев районы

**Аяз Гыйләҗев әсәрләрен продуктив уку технологияләренә**....215

Алтынбаева Светлана Сәгыйдулла кызы, Азнакай шәһәренең  2 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе

**Ана – бөек исем**....218

Хайруллина Әлфия Камил кызы, Хосусый белем бирү оешмасы №23 Менеджер урта мәктәбе, Әлмәт районы

**Аяз Гыйләҗевнең "Әтәч менгән читәнгә" әсәрендә рухи матурлык һәм ярлылык темасы буенча дәрес эшкәртмәсе**....221

Шакирова Суфия Шамил кызы, Хосусый белем бирү оешмасы №23 Менеджер урта мәктәбе, Әлмәт районы

**Аяз Гыйләҗевнең тууына 90 ел**....225

Гильфанова Фәнүсә Мәгсүмҗан  кызы,  Кызрачева Нурзия Мәрвәр кызы, А. Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомумбелем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Бердәмлектә көч. А.Гыйләҗевнең "Дүртәү"әсәре**....228

Шәйдуллина Чулпан Камил кызы, Ихсанова Римма Ильяс кызы, икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман  районы

**Бара юлдан язгы кәрваннар** ........ 232

Вахитова Ләйсән Асаф кызы, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче, Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Ялгышулар кыйммәткә төшә** ........ 234

Шәйхулова Миләүшә Фәгыйль кызы, Җиңү бистәсе урта гомуми белем бирү мәктәбе, Азнакай районы

**Аяз Гыйләҗев иҗатына багышланган дәрес** ........ 237

Юнысова Әлфия Вәдүт кызы, Әлмәт төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**А.Гыйләҗев "Дүртәү"** ........ 242

Харисова Илзирә Алмаз кызы, Иске Кәшер урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**"Матур" хикәясендә кем матур?** ........ 245

Хәбибуллина Сөмбел Габдулла кызы, Әтәс төп гомуми белем бирү мәктәбе, Актаныш районы

**Аяз Гыйләҗев "Язгы кәрваннар" әсәре буенча сценарий** ........ 246

Сабирҗанова Җәмилә Фаткылгаен кызы, Казан шәһәре, Яңа Савин районының 91 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе

**Федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыру шартларында Аяз Гыйләҗев иҗатын өйрәнү. А.Гыйләҗевнең "Өч аршын җир" повесте** ........ 249

Ганиуллина Римма Ясир кызы, Сарман гимназиясе, Сарман районы

**Нәрсә ул бәхет?** ........ 254

Галимова Гүзәлия Рамис кызы, Буа шәһәренең лицей-интернаты (сәләтле балалар мәктәбе)

**Бибинур – рухи матурлык символы** ........ 256

Салихова Айгөл Роберт кызы, икенче санлы Җәлил урта гомумбелем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Аяз Гыйләҗевнең "Йәгез, бер дога" исемле роман-хатирәсендә репрессия елларының чагылышы** ........ 261

Шафигуллина Алия Фәрид кызы, гомуми үсеш төрендәге 4 нче "Сандугач" балалар бакчасы, Сарман районы

**Аяз Гыйләҗевнең "Суык" хикәясе өстендә эш** ........ 262

Гарифуллина Альфинур Флеровна, Садыкова Ильмира Зуфаровна, «Джалильская СОШ№2», Сармановский район

**Литературный сценарий «Давайте помолимся!» Карлаганская страница Аяза Гилязова** ........ 263

Тазирова Валентина Валериан кызы, Сарсаз-Баграж гомуми төп белем бирү мәктәбе, Зәй районы

**Аяз Гыйләҗев биографиясендә Баграж ягы** ........ 268

Шакирҗанова Гүзәлия Зиннур кызы, Мөхәммәдиева Дамира Заһит кызы, Кече Урыссу төп гомуми белем бирү мәктәбе, Ютазы районы

**Аяз Гыйләҗевнең "Суык"хикәясе** ........ 272

Антонова Гөлзада Александр кызы, Ләке төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**А. Гыйләҗев. Күктау** ........ 274

Садыкова Алсу Наил кызы, Менделеевск шәһәренең 1 нче гомуми белем биру мәктәбе

**Ана хакын хакламаучыларны аклап буламы?** ........ 277

Вәлиәхмәтова Гөлшат Шәмгун кызы, Яңа Кәшер санатор интернат-мәктәбе, Әлмәт районы

**Аяз Гыйләҗевның тормыш юлына һәм иҗатына багышланган "Могҗизалар кыры" интеллектуаль уены** ........ 280

Мияссәрова Ләйлә Кәбир кызы, Шәнгәрәева Нәзифә Наил кызы, икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**А.Гыйләҗевнең “Матур” хикәясендә кунакта** ........ 282

Низамиева Нурфия Гарәпша кызы, Казан шәһәре, 37нче гимназия

**А.Гыйләҗевнең 90 еллыгына багышланган кичә** ........ 285

Мәхмүтова Резедә Рафаэль кызы, Казан шәһәренең 14 нче номерлы урта гомумбелем бирү рус-татар мәктәбе

**Аяз Гыйләҗев тормышы һәм иҗатына багышланган “Тамчы шоу” интеллектуаль тапшыруы (уены)** ........ 287

Тажетдинова Рүзилә Илгизәр кызы, Сарман гимназиясе, Сарман районы

**Аяз Гыйләҗев. "Алсу, Илдус һәм сандугач"** ........ 289

Хәмәтҗанова Фәнүзә Сәгыйрь кызы, Сарман урта мәктәбе, Сарман районы

**“Исем” темасы буенча якташ язучы Аяз Гыйләҗев әсәрләрен файдаланып эшләнгән күнегүләр** . 291

Нигматуллина Флүзә Әсгать кызы, Яңа Кәшер санатор мәктәп- интернаты, Әлмәт районы

**Без белергә тиеш** ........ 293

Халиуллина Роза Барый кызы, Яңа Кәшер санатор мәктәп-интернаты, Әлмәт районы

**Аяз Гыйләҗев безнең күңелләрдә** ........ 295

Ситдыйкова Чулпан Индус кызы, Ситдыйкова Эльвера Дамир кызы, Мөслим лицее, Мөслим районы

**Кейс методы аша Аяз Гыйләҗевнең “Тәрәзәләр” хикәясен анализлау** ........ 297

Михайлова Эльвира Илгиз кызы, Әгерҗе шәһәре 2 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе,

Әгерҗе районы

**Аяз Гыйләҗевнең “Үги ана яфраклары” хикәясе буенча** ........ 300

Ясәвиева Гөлфинә Минирасит кызы, Песәй урта гомуми белем бирү мәктәбе, Менделеев районы

**Ян, учагым, ян! «Тамчы - шоу» интеллектуаль уены** ........ 302

Гатин Рафис Исмәгыйль улы, Нуртдинова Гөлнар Салихҗан кызы, икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Аяз Гыйләҗев иҗаты веб-биттә** ........ 304

Ихсанова Лилия Фаизовна, Евстафьева Людмила Фёдоровна, Джалильская СОШ №2, Сармановский район

**Жизнь и творчество писателя – земляка Аяза Гилязова** ........ 308

Исмәгыйлева Минзирә Рәсим кызы, Садыйкова Гөлсинә Солтан кызы, Казан шәһәре, Киров районының татар телендә белем бирүче өченче гимназиясе

**Татар әдәбиятының алтын баганасы-Аяз Гыйләҗев** ........ 310

Валеева Ләйсан Мидхәт кызы, Түбән Каманың 9 нчы санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе

**А. Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» әсәрендә пейзажның бирелеше** ........ 312

Шайхулова Гөлназ Фаяз кызы, Яңа Кәшер санатор мәктәп-интернаты, Әлмәт районы

**Гарәп-фарсы алынмаларын кабатлау** ........ 315

Ләйсән Сафина, Мөслим лицее, Мөслим районы

**А.Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” әсәрендә Бибинур образы** ........ 321

Ризатдинова Эльвира Хәниф кызы, Вахитова Люция Мансур кызы икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**“Хафиз бабай әкияте”нә анализ** ........ 324

Хәсәнҗанова Клара Әхмәт кызы, Әлмәт шәһәренең 12 нчы урта мәктәбе

**Аяз Гыйләҗев “Матур” әсәре** ........ 326

Ханов Разил Зөлфәт улы, П.Днепров исемендәге Рус Шуган төп гомуми белем бирү мәктәбе, Мөслим районы

**А. Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән" әсәрендә детальләрнең роле** ........ 328

Галимова Ә.И., 165 нче гомуми белем бирү мәктәбе, Казан шәһәре

**Аяз гыйләҗев прозасында тәнкыйди катлам** ........ 330

Исрафилова Фирая Вагыйз кызы, Абалачурта гомуми белем бирү мәктәбе, Менделеев районы

**Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән...» повестенда әхлак проблемасы** ........ 331

Мөбәрәкшина Фирдинә Рафил кызы, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе, Түбән Кама шәһәре

**Туган тел һәм туган телдә әдәбият фәненнән 8 нче сыйныфларда Аяз Гыйләҗевнең "Язгы кәрваннар" повестен өйрәнү дәресенең технологик картасы** ........ 334

Нургалиева Халидә Әбүзәр кызы, Тымытык авылы гомуми урта белем мәктәбе, Азнакай районы

**Аяз Гыйләҗев иҗатына багышланган дәрестән тыш чара эшкәртмәсе** ........ 337

Халикова Лиза Ахатовна, «Джалильская СОШ №2», Сармановский район

**План-конспект классного часа «Их было четверо»** ........ 343

Шайдуллина Ильмира Салиховна, Ахметгалеева Ландыш Зиннуровна, Джалильская СОШ №2, Сармановский район

**Листья мать-и-мачехи** ........ 345

Шакирова Эльмира Финус кызы, Зиннәтуллина Лилия Ринат кызы, Җәлил гимназиясе, Сарман районы

**"Тамчы-шоу" интеллектуаль күңел ачу бәйгесе** ........ 350

Адлер Эльвира Демьян кызы, Загитова Ләйлә Азгар кызы, Актүбә 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Азнакай районы

**Дүрт аяклы дустыбыз** ........ 353

Чернова Ирина Григорьевна, Сарсаз-Бagраж төп гомуми белем мәктәбе, Зәй районы

**Аяз Гыйләҗев "Язгы кәрваннар" әсәре** ........ 356

Мирзамуратова Гөлшат Морат кызы, Мөслим гимназиясе, Мөслим районы

**Күрше хакы – Аллаһ хакы** ........ 361

Сәетова Флүзә Флүр кызы, Әлмәт шәһәре 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе

**Аяз Гыйләҗев "Өч аршын җир" повесте** ........ 368

Исрафилова Ильмира Мөдәрис кызы, Җәлил гимназиясе, Сарман районы

**Җәннәт аналарның аяк астында** ........ 371

Миннибаева Индира Әхтәм кызы, Салагыш урта гомуми белем бирү мәктәбе, Әгерҗе районы

**Аяз Гыйләҗев иҗаты - дәрестән тыш чараларда** ........ 375

Сиякина Нәфисә Равил кызы, Генерал-майор В.А.Хапаев исемендәге Тәтеш кадет-интернат мәктәбе, Тәтеш районы

**Интеллектуаль уен "Әдәби марафон"** ........ 377

Шәймәрданова Лилия Нур кызы, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче беренче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы, Сарман районы

**А.Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән" әсәре буенча йомгаклау дәресендә "РАФТ-технология" алымын куллану** ........ 380

Шәйдуллина Гөлнара Индүс кызы, Ләшәү-Тамак "Таң" балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы

**Матуркайга ярдәм итик!** ........ 382

Нуриева Миләүшә Вәгыйз кызы, Җәлил бистәсенең 5 нче санлы “Әкият” балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы

**“Тылсымлы сүзләр”** ....................................................................................................................384

Шәрифҗанова Ләйсән Касыйм кызы, Яр Чаллы шәһәре, 54 нче гимназия

**Бала хыялы** ..............................................................................................................................385

Хафизова Айсылу Дамир кызы, Фазлиева Гүзәл Дамир кызы, Александровка төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Җөмлә төрләрен кабатлау** ........................................................................................................388

Хафизова Айсыл Шәгалиева Гөлназ Нәҗип кызы,

Актүбәнең 2нче урта мәктәбе укытучысы, Азнакай районы

**Аяз Гыйләҗевнең иҗаты һәм тормыш юлы -”Могҗизалар кыры”уенында** ………………………...388